ISSN 0206-4189
Индекс 73210

# КАЗАН УТЛАРЫ

11.2007



# МӘҢГЕЛЕК ШӘҺӘРЕБЕЗ СӘХИФӘЛӘРЕННӘН

*Пристань һәм Кремль*



*Галиев (Баруди) мәчете*



*XX гасыр башында алынган фотосурәтләр.*
*Абдулла Дубин коллекциясеннән.*

# Казан утлары
# Qazan utları

2007

**11**

(1021)

ОЕШТЫРУЧЫЛАРЫ:

*«Татмедиа» массакүләм коммуникацияләр буенча Татарстан Республикасы агентлыгы һәм Татарстан Республикасының Мәдәният министрлыгы*

*БАШ МӨХӘРРИР*

**Равил Фәйзуллин**

*ИДАРӘ:*

**Харрас Әюпов**
**Зилә Вәлиева**
**Мөдәррис Вәлиев**
**Тәлгат Галиуллин**
**Миркасыйм Госманов**
**Алмаз Гыймадиев**
*(җаваплы сәркәтип)*
**Илфак Ибраһимов**
**Туфан Миңнуллин**
**Хатыйп Миңнегулов**
**Назиф Мириханов**
**Гәрәй Рәхим**
**Факил Сафин**
**Ренат Харис**
**Зиннур Хөснияр**
**Розалина Шаһиева**
**Рәфикъ Юныс**
*(баш мөхәррир урынбасары)*

---

*Мөхәррирләр:* **Мансур Вәли, Рәдиф Гаташ, Марат Закир, Камил Кәримов, Раиф Мәрданов, Рашат Низами, Рәдиф Сәгъди.**

*Гамәли хезмәткәрләр:* **Гөлзадә Бәйрәмова, Радик Вәлиев, Лилия Гатауллина, Флера Сабирова, Тәгъзимә Шиһабиева.**
*Исәп-хисап бүлеге:* **Асия Рәхимова** (баш бухгалтер), **Эльвира Камалова.**

---

✉: 420066, Казан, Декабристлар урамы, 2.
☎☎: Баш мөхәррир—292-38-60.
Баш мөхәррир урынбасары—292-36-49.
Җаваплы сәркәтип, компьютер үзәге—541-38-77.
Шигърият, публицистика, фән һәм сәнгать бүлеге—292-38-61.
Чәчмә әсәрләр һәм әдәби тәнкыйть бүлеге—292-39-63.
Гамәли хезмәткәрләр—292-39-65.
Исәп-хисап бүлеге—292-93-16.
**Факс**—(843) 541-38-77.
**E-mail:** kazanutlari@telebit.ru.

# КАЗАН УТЛАРЫ

ӘДӘБИ-НӘФИС ҺӘМ ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ЖУРНАЛ

1922 ЕЛНЫҢ МАЙ АЕННАН БАШЛАП ЧЫГА

*Бу санда*

**ШИГЪРИЯТ ҺӘМ ЧӘЧМӘ ӘСӘРЛӘР**

Рафикъ ЮНЫС. Хәтер авазы. *Тарихи вокаль цикл өчен текст*... 5
Резеда ВӘЛИЕВА. Зәңгәр чәчәк, хәлең беләм... *Шигырьләр*. 56
Нурихан ФӘТТАХ. Аклан. *Хыялый роман*. 66
Наил ШӘРИФУЛЛИН. Соңарган сөю. Хикәя. 107
МИҢНЕРУЙ. Беренче кар. *Шигырьләр*. 115

**ДРАМА ӘСӘРЛӘРЕ**

Рабит БАТУЛЛА. Мур кырылышы. *Фаҗига-хроника*... 9

**ТАТАР ХИКӘЯЛӘРЕ ХӘЗИНӘСЕННӘН**

Хәсән САРЬЯН. Туган як моңы. 59

Фәния МИҢНЕГУЛОВА. «Укытучы булулары кыен икән...» *Истәлек-хатирә*... 62

**ТАТАРСТАННАН ЧИТТӘ ЯШӘҮЧЕ КАЛӘМДӘШЛӘРЕБЕЗ**

Мөхәммәт ЗАКИРОВ. Эзләрендә йолдыз кабына. *Шигырьләр*. 99
Илдус ФАЗЛЕТДИНОВ. Мәңгелектән башын алган гомерем. *Шигырьләр*. 101
Мөнир ВАФИН. Җиргә атылган алмадай... *Шигырьләр*. 103
Фәрит СУФИЯРОВ. Оя корыр бәхет кошлары. *Шигырьләр*. 105

**ТАРИХ**

Карл ФУКС. Казан татарлары... 125

**ПУБЛИЦИСТИКА**

Мөхәммәт МИРЗА. Узып барышлый. 117
Фәнзаман БАТТАЛ. Бу дөнья кемгә кала? 141

**ЛИРОН ХӘМИДУЛЛИНГА 75 ЯШЬ**

Равил ФӘЙЗУЛЛИН. Аксакал әдипләребезнең берсе. 148

**ФӘН**

Адлер ТИМЕРГАЛИН. Миллият сүзлеге. 160
Фирдәвес ГАРИПОВА. Авылларыбыз тарихы. 165

**ӘДӘБИ ТӘНКЫЙТЬ**

Гүзәл КАЮМОВА. Сәнгатьчә табышлар. 154

**ГАБДЕЛҖӘББАР КАНДАЛЫЙНЫҢ ТУУЫНА 210 ЕЛ**

Габделҗәббар КАНДАЛЫЙ. *Шигырьләр*. 173

**КОЯШ ТИМБИКОВАНЫҢ ТУУЫНА 70 ЕЛ**

Әхмәт РӘШИТ. Хәтерләрдә калды. 176

Берлекнең яңа әгъзалары. 185
«Казан утлары» архивыннан. 186
Иҗтимагый-мәдәни тормышыбыздан. 188

## В ЭТОМ НОМЕРЕ:

*Журнал выходит один раз в месяц*

«Проза и поэзия»: Р. ЮНУС. Текст для исторического вокального цикла «Эхо памяти», стихи Р. ВАЛЕЕВОЙ; роман Н. ФАТТАХА «Аклан» (продолжение), рассказ Н. ШАРИФУЛЛИНА «Запоздавшая любовь».
«Драматургия»: Р. БАТУЛЛА. «Исторические диалоги» (окончание).
«Из сокровищницы татарских рассказов»: Х. САРЬЯН. «Мелодия родного края», статья Ф. МИННЕГУЛОВОЙ об авторе.
«Творчество татарских поэтов Башкортстана»: стихи М. ЗАКИРОВА, И. ФАЗЛУТДИНОВА, М. ВАФИНА, Ф. СУФИЯРОВА.
«Новые имена»: стихи МИННЕРУЙ.
«История»: К. Фукс. «Казанские татары...» (окончание).
«Публицистика»: М. МИРЗА. «Проездом», Ф. БАТТАЛ. «Кому останется этот мир?»
«Литературная критика»: статья Г. КАЮМОВОЙ о драматургии Р. Хамид.
«К 210 летию Г. Кандалый»: стихи Г. КАНДАЛЫЙ;
К 75-летию Л. Хамидуллина статья Р. ФАЙЗУЛЛИНА; статья А. Рашита к 70 летию К. Тимбиковой.
«Юмор-сатира»: К. АДГАМОВ «Покажи язык», стих. М. САТТАРОВА.
Страницы из «Татарской энциклопедии».
Новые члены Союза писателей.
Слово читателя.
Дневник общественно-культурной жизни.
На наших обложках: «Ожидание зимы»; писатель В. НУРИЕВ.

## IN THIS ISSUE:

*The magazine edits monthly*

«Prose and poetry»: R. YUNUS. Text for historical vocal cycle «Echo of memory», verses by R. VALEEVA; novel by N. FATTAH «Aklan» (continuation), story by N. SHARIFULLIN «Late love». «Dramatic art»: R. BATULLA. «Historical dialogues» (ending). «From treasury of Tatar stories»: H. SARYAN. «Melody of native edge», article by F. MINNEGULOVA about author.
«Creativity of Tatar poets from Bashkortostan»: verses by M. ZAKIROV, I. FAZLUTDINOV, M. VAFIN, F. SUFIYAROV.
«New names»: verses by MINNERUY.
«History»: K. Fux. «Kazan Tatars...» (ending).
«Publicism»: M. MIRZA. «Travel». F. BATTAL. «Whom there will be this world?»
«Literary criticism»: article by G. KAYUMOVA about dramatic art of R. Hamid.
«To 210th anniversary of G. Kandaly»: verses by G. KANDALY;
To 75th anniversary of L. Hamidullin article by R. FAYZULLIN; article by A. Rashit to 70th anniversary of K.Timbikova.
«Humour-satire»: K. ADGAMOV «Show tongue», verse by M. SATTAROV. Pages from «Tatar encyclopedia».
New members of Union of writers. Reader's word.
Diary of social-cultural life.
On our covers: «Winter expectation»; writer V. NURIEV.

* Авторлар фикере редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин.
* Редакциягә килгән кулъязмалар рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
* Басмаханә гаебе белән киткән җитешсезлекләр өчен редакция җавап бирми, брак журналларны алыштыру мөмкинлеге юк. Алар хакында 519-44-61 телефоны белән басмаханәнең техник контроль бүлегенә хәбәр итәргә кирәк.

Журнал редакциянең компьютер үзәгендә җыелды һәм битләргә салынды.
Басарга кул куелды 31.10.2007 ел. Офсет ысулы белән басыла. Кәгазь форматы 70X108 1/16.
Учетн.-изд. табак 14,2. Басма табак 12 (16,8). Заказ С–1381 Тираж 6451.
Журнал Татарстан Республикасының Мәгълүмат һәм матбугат министрлыгында теркәлгән.
Теркәлү таныклыгы № 7.

«Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылды.
Казан, Декабристлар урамы, 2

© «Казан утлары», 2007 ел.



Рәфикъ
Юныс

# ХӘТЕР АВАЗЫ

ТАРИХИ ВОКАЛЬ ЦИКЛ ӨЧЕН ТЕКСТ

## Айдала

**Айдалада ай нуры да,
Айдалада таң нуры.
Ай нуры да таң нуры.
Атым тоттым туп-туры.**

**Айдалада зәңгәр күккә
Чөйдем соры карчыга.
Карчыгам, карчыгам
Очты кояш каршына.**

**Айдалада йөргән чакта
Аттым елгыр капланны.
Капланны, капланны
Аттым-ектым, капланды.**

**Зәңгәр күкнең төбе юктыр,
Офыкларның чиге юк.
Күңелемнең сайрамаган,
Җырламаган җире юк!**

**Айдалада ак кылганнар
Айкала да чайкала.
Айдала, айдала,
Айкала да чайкала.
Айдала, айдала,
Айдалада эз кала...**

## Атла, кәрван

**Атла, кәрван, атла, кәрван төн иленә.
Бармы, бармы бу дөньяда адәм кадре?
Яңа җирдә, яңа җирдә сакла безне,
Син ташлама, син ташлама безне, Тәңре!**

**Без күбәүләр, без күбәүләр, без меңәүләр.
Күчә безнең, күчә безнең ил-йортыбыз.
Изге каберлекләр кала, кала дала.
Дала кала, аны ничек онытырбыз?**

---

Рәфикъ ЮНЫС (1943) — *шагыйрь, публицист; Татарстан Язучылар берлегенең Г. Исхакый исемендәге премиясе лауреаты. «Вакыт чылбыры», «Син һәм мин» һ. б. шигырь җыентыклары, «Татарстан референдумы» исемле тарихи-документаль китап авторы. Казанда яши.*

Юеш тынлы урман иле, серле тараф,
Сыйдыр безне, сыйдыр безне, дөнья тыгыз.
Шом салмагыз, шом салмагыз, ябалаклар,
Бәхет юра, бәхет юра, Казык йолдыз!

Без йөрәкле, без гайрәтле, без куәтле.
Йодрык итеп туплар безне ханның әмре.
Тик шулай да, тик шулай да сакла безне,
Син ташлама, син ташлама безне, Тәңре!

Атла, кәрван, атла, кәрван төн иленә.
Яктырт юлны, балкыт юлны, борынгы Ай.
Яңа җилдә җилфердәрләр иске тулар[1],
Яңа җирдә без яшәрбез борынгыдай.
Атла, кәрван...

## Ага базар

***(Югары тавыш)***—Идел-су буенда
Бардыр базар.
Ага базардыр бу,
Ага базар!
***(Түбән тавыш)***—Идел-су буенда
Бардыр базар.
Ага базардыр бу,
Ага базар!
Алыш-биреш,
Биреш-алыш!
Сиңа файда,
Миңа табыш!
Булмасын һич
Белми калыш,
Күрми калыш—
Кил дәябы-ы-ыш!
Базар-базар-базарда,
Базар-базар-базарда
Кайнашабыз, аңлашабыз,
Җайлашабыз үзара.
—Бар, бар базарга,
Бар да бардыр базарда!
—Бар, бар базарга,
Бар да бардыр базарда!

—Шәрекътән, Гарептән,
Ераклардан
Киләдер тауарлар
Кәрван-кәрван!
—Шәрекътән, Гарептән,
Ераклардан
Киләдер тауарлар
Кәрван-кәрван!
Сәүдә итмеш—
Сату итмеш.
Миннән артмыш,
Сиңа җитмеш.
—Бүз аргымак!
—Турка ефәк!
—Алтын-көмеш!
—Татлы җимеш!
Өлгер-җите-е-еш!
Базар-базар-базарда,
Базар-базар-базарда
Кайнашабыз, аңлашабыз,
Җайлашабыз үзара.
—Бар, бар базарга,
Бар да бардыр базарда!
—Бар, бар базарга,
Бар да бардыр базарда!

—Иделле, базарлы,
Кол Галиле—
Дөнья күзендәдер
Болгар иле!
—Иделле, базарлы,
Кол Галиле—
Дөнья күзендәдер
Болгар иле!
Сәүдә кылмыш—
һөнәр кормыш,
Юллар ермыш.
Яна мичләр,
Кайный тормыш.
Чыңлый тәңкә—
Дәшми кылыч,
Монда елы-ы-ыш!
Базар-базар-базарда,
Базар-базар-базарда
Кайнашабыз, аңлашабыз,
Җайлашабыз үзара.
—Бар, бар базарга,
Бар да бардыр базарда!
—Бар, бар базарга,
Бар да бардыр базарда!

[1] Ту—байрак, әләм.

## Поскынчы җыры

Ослан-таудан күзлим киң дөньяны.
Нинди шом бар кошлар тавышында?
Алтын Казан кояш чыгышында.
Канлы шәфәкъ кояш баешында.
Алтын Казан кояш чыгышында,
Канлы шәфәкъ кояш баешында
...баешында.

Ничәнче ай инде, ничәнче ел
Яна шәфәкъ канлы хәбәр булып.
Яшермиме тынлык җил-давылны?
Яндадыр күк дошман еравылы[2].
Яшермиме тынлык җил-давылны?
Яндадыр күк дошман еравылы
...еравылы.

Тирбәтә су яшел каекларны,
Кабарта җил ап-ак җилкәннәрне.
Ник сискәнә Идел, ник борчыла?
Бу җилкәннәр барып җитәрләрме?
Ник сискәнә Идел, ник борчыла?
Бу җилкәннәр кайтып җитәрләрме?
...җитәрләрме?

Тулган айдай якты калам минем,
Әй, пакь калам, иманнурлы калам!
Көфер куллар сиңа үрелмәкче,
Исән кала күрче, газиз Казан!
Кара куллар сиңа үрелмәкче,
Исән кала күрче, газиз Казан!
...газиз Казан!

## Сынма, кылыч!

Тетридер Казан-йорт,
Дөрли Казан.
Ут-ташлар чәчридер
Диварлардан.

Хәтәргә ор—
Өркер хәтәр.
Аллаһы әкбәр,
Аллаһ әкбәр.

Сынма, кылыч!
Чыда, корыч!
Соңгы орыштыр бу,
Соңгы орыш!

Утчагар[3] гөрселди,
Кешни атлар.
Шашынып думбылдый
Дум-думбаклар[4].

Хәтәргә ор—
Өркер хәтәр.
Аллаһы әкбәр,
Аллаһ әкбәр.

Сынма, кылыч!
Чыда, корыч!
Соңгы орыштыр бу,
Соңгы орыш!

---

[2] Еравыл, яравыл — гаскәрнең алдагы өлеше, авангард.

[3] Утчагар — туп.

[4] Дум-думбак — барабан.

Акса да безнең кан
Болакларга,
Безнең дан җан алыр
Оныкларда.

Хәтәргә ор—
Өркер хәтәр.
Аллаһы әкбәр,
Аллаһ әкбәр.

Сынма, кылыч!
Чыда, корыч!
Соңгы орыштыр бу,
Соңгы орыш!

Үләбез баш ими
Җәлладләргә.
Очрашырга язсын
Җәннәтләрдә.

Хәтәргә ор—
Өркер хәтәр.
Аллаһы әкбәр,
Аллаһ әкбәр.

Сынма, кылыч!
Чыда, корыч!
Соңгы орыштыр бу,
Соңгы орыш!..

## Тарих җиле

*Көнем өчен түгел, денем өчен.*
Мәкаль.

Булган көчле, гайәр чаклар.
Булган шанлы чаклар.
Хөр җилләрне узып чапкан
Безнең ярсу атлар.

Тоя йөрәк, ашкыл[5] йөрәк,
Тоя тарих җилен.
Нигә көнем—булмый икән
Телем, халкым, илем?

Баса алмый йөрәгемне,
Үткәннәргә чабам.
Тарих җиле дәва: без бит
Башлам түгел, дәвам.

Тарих көле тояклардан
Каладыр бөркелеп.
Нигә көнем—булмый икән
Илем, халкым, телем?

Чабам, чабам үткән аша
Киләчәккә таба.
Тарих уты ат ялына,
Йөрәгемә каба.

Хаклар гадел хакланмыйча
Сүрелмәс бу ялкын.
Нигә көнем—булмый икән
Илем, телем, халкым?

[5] Ашкыл—ашкынучан *(неол.)*.

Рабит Батулла

# МУР КЫРЫЛЫШЫ

ФАҖИГА-ХРОНИКА

## Туктамышхан белән сугыш

*Идел буе. Кондырча янындагы яу кыры.*

С а к ч ы *(чыга)*. Туктамыш ханның гаскәре бихисаптыр, Аксак Тимернең гаскәре дә бер офыктан икенчесенә сузылган иде. Менә шушы ике кодрәт Идел буенда Кондырча болынында очрашты.

Т и м е р *(сугыш киеме кигән)*. Изге ата Исрафил хәзрәт, бу яуга фатихагызны бирегез.

К а р а д ә р в и ш. Бисмәләһ ир рахмән ир рахим. Үәл гадияти дабхә. Фәл мүгрияти кадхә. Фәл мугириати субха. Фәәсәрәнә биһи нәкъга. Фәүасатна биһи җәмга. Иннәл инсәәнә лираббиһи ләкәнүүд. Йөрәк кагып, тупырдап чапкан атлар, тоякларыннан ут чәчрәтеп узышучы чаптарлар, таң атканда Җиһад өчен яу чапкан аргамаклар, тузан белән каплаган чабышкыйлар, дошман өеренең уртасына бәреп кергән юргалар исеме белән ант итәмен ки: бәндәләр, чыннан да, шөкерсезләр. Йа Илаһем, Тарагай нәселле әмир Тимер хәзрәтләренә җиңү китер, ул тугры колына ярдәм ит, зинһар. Пәйгамбәребез Мөхәммәд Мостафа салаллаһу галәйһи вә сәллам бер уч туфрак алып, кяферләр гаскәренең өстенә орган кеби, мин дә шулай гамәл кылам. *(Бер уч туфрак алып, һавага ата.)* Дошманнарның күзе томалансын, хак мөселманнарның күзе ачылсын!

*Тимер Карадәрвиштән читтәрәк, Күгелташка:*

—Аллаһка ышан, ләкин үзең дә тик ятма! Тутамыш хан көчле һәм хәйләкәр. Аның гаскәре минекеннән күбрәк. Ул бу җирләрне дә миннән яхшырак белә. Ышанычлы кешеләрне җибәр, алар Туктамышның байрак йөртүчесен сатып алсын. Иң мөһим мизгелдә генә безнең хәбәр буенча ул байракны төшерсен!

К ү г е л т а ш. Баш өсте, тәкъсирем! *(Чаптырып китеп бара.)*

*Быргы яуга чакыра. Сугыш куренешләре. Яу тавышлары. Атлар кешни, уклар сызгыра, кешеләр акыра, йөз меңләгән тояк тавышлары ишетелә...*

*Сугыш башлануга көмеш төстәге сөңге башлары кызыл алмазга әверелде, зөмруд кылычларның йөзләре нар суында юылды. Дошманнарның киселгән башлары укларның әче сызгыруы астында сикерә-сикерешә тояк асларына тәгәри иде. Аларның йөрәкләре кайнар канны комга түгеп бетерде. Туктамышның батырлары куәтле һөҗүм итеп, дошманның йөрәгенә курку салды. Тимер сугышчылары артка борылып, кача башлады.*

*Тимернең бимазалы чыраенда шөбһә*

*Ахыры. Башы 10 санда.*

*шәүләсе кабынды. Анын гаскәре чигенә. Тимер кул ишарәсе белән әмер бирде. Чүпрәкне таза дегеткә манып, ук башына урап, аңа ут төртеп, йөзләгән укчы һавага ут атты. Койрыклы йолдыз кеби янучы бу утлар байракчыга хәбәр иде.*

*Дошман артыннан куып баручы Туктамыш хан гаскәренең байрагы кинәт юкка чыкты. Һөҗүмчеләр атларын тыеп, бер урында бөтерелә, нишләргә белми аптырап калдылар. Ул арада качып баручылар атларын кинәт кирегә борып, каушаганнар өстенә ябырылды. Туктамыш гаскәре камалышта иде. Уртада калганнарны тәмам турап бетерделәр.*

*Бөек җиңүнең хәбәре буларак, Тимернең байраклары мәетләр өстендә җилферди иде. Бераздан тузан болыты, төтен тарала төште, Кояш бөек җиңүе белән әмир Тимерне котларга дип, балкып килеп чыкты. Бичара Туктамыш калдык-постык гаскәрләре белән, яраланган эт кеби, көчкә качып котылды. Атының тояклары җир келәмен тиз-тиз үлчәп, офыкка кереп югалды.*

*Ай йөзле бихисап татар гүзәлләре, әйтерсең лә аларны атаклы рәссамнар фирдәвестәй хур кызларыннан күчереп ясаганнар, яу кыры буйлап, һәлак булган сөеклеләрен эзли чыккан. Аларның барысын да әсир итеп, Тимернең яугирләренә өләшеп чыктылар. Төнге салкынча чатырларда ул гүзәлләр арыслан тырнагына эләккән җәйраннар кеби дәрт вә гайрәт тырнагында чәбәләнә иде.*

*Сугыш туктаганнан соң яу кыры офыктан офыккача мәетләр, ат үләксәләре белән капланаган иде. Каргалар, саесканнар, козгыннар Тимернең җиңүен бәйрәм итә.*

*Тереләр тын гына мәетләрне җирләп йөри.*

*Җиңүче Аксак Тимер үзенең яраннары белән җиһангир чатыры янында җыйналдылар. Аларның барысы да яу киеменнән. Алар арасында Карадәрвиш тә бар иде.*

К а р а д ә р в и ш. Машалла, Тарагай углы әмир Тимер хәзрәтләре! Сезләр җинелмәс Туктамыш ханның умырткасын сындырдыгыз.

Т и м е р. Динебезне бозучыларның барысын да шушы язмыш көтә.

К а р а д ә р в и ш. Котлыйм ихластан, зафәр килә сезгә баба Тукластан.

Т и м е р. Котлауларны тыңлап торырга вакыт тар. Яугирләрем! Бу җиңүне Аллаһ Тәгалә үзе күреп торды. Бу җиңү минем хакыйкать юлында булуыма дәлил. Дошманнарга сулыш алырга ирек юк! Без моннан туп-туры Бөек Болгар каласына сәфәр чыгабыз. Изге ата Исрафил хәзрәтләре, ач изге Коръәнне. Шул хәл итсен чабаргамы, чапмаскамы яу дененнән язган Гадулла хан өстенә?

*Яу мотрибчылары йола аһәннәрен яңгырата башлады. Карадәрвиш, акрынайтылган хәрәкәтләр белән, салмак кына Коръәнне кулына алды, акрын гына ачты. Барысы да сихри мохиттә, тез өстендә иде.*

К а р а д ә р в и ш *(көйләп укый).* Иннә-әлләзинә кәфәруу лән тугнийя гәнһүм әмүәллү һүм үә ләә әүләәдүхүм миәналлаһи шәй-әү үә үүәләикә асхәәбү ннәәрри һүм фииһәә хаалидун. *(Барысы да сәҗдәгә китә.)* Хактыр ки, көфер иткәннәрне маллары да, балалары да һич нәрсәдән, Аллаһның газабыннан коткара алмас. Садакаллаһул газыйм!

Т и м е р. Яугирләрем, без Исламны эчтән бозырга маташучы Туктамыш хан илендәге монафыйкларны кырдык. Аллаһ сездән разый булсын! *(Гаскәр җавабы: амин!)* Без сезгә Алтын Урданың казнасыннан алынган ганимәтне һәм үзегез үтергән дошманның үлҗә малын тигез итеп тараттык. Сез канәгатьме? *(Ра-ас!)* Изге сугышта шәһид киткәннәргә тиешле малы гаиләләренә кайтарылсын! *(Гаскәр җавабы: ра-ас!)* Сез яңадан яңа җиңүләр яуларга әзерме? *(Җавап: ра-ас!)* Алга, Идел ярларына, динне бозучы, халык алдында көферлек кылучылар, шәригать кануннарын бозучыларны Аллаһ Тәгалә минем кылычым белән җәзалый. Бөек Болгарның монафикъларын кылычтан узгарыгыз! Ганимәт, үлҗә малы үзегезгә булыр! Яуга-а! *(Җавап: яуга-а.)*

*Яуга чыгар алдыннан гайярь яугирләр икешәр кылыч тотып, шашып бииләр.*

Т и м е р. Яугирләрем, алга! Изге сугышка!

К а р а д ә р в и ш. Аллаһу әкбәр!

*Аксак Тимер шул сәфәреннән Бөек Болгар шәһәренә яуга чыкты. Тетрә,*

*Болгар! Калтыра, Болгар! Синен өскә дәһшәтле гаскәр, кодрәтле яугир Аксак Тимер килә! Габдулла хан, син бөтен казнанны, алтын-көмешенне, малларынны, хатыннарынны, кызларынны, колларынны бирү бәрабәренә котылырга теләрсен, ләкин Аксак Тимер синен ул шартына күнмәс! Чөнки ана кан кирәк, дан кирәк, ул болгарларны кырып, казнанны талап, кызларынны бәйләп алып китәчәк. Бу әче тәкъдирне Ходам башкаларга күрсәтмәсен!*

*Бөтен гаскәр тәкбир әйтә.*

Аллаһу әкбәр, Аллаһу әкбәр,
лә иләһә илләһу Аллаһу әкбәр.
Аллаһу әкбәр, вә лиллә һи әлхәмде.

*Болгарлар сонгы сулышларына чаклы каты орыштылар, ләкин көчләр тигез түгел иде. Аксак Тимер гаскәре Болгарны тар-мар китереп, Абдулла ханны якыннары белән утта яндырып, казнаны талап, исән калганнар белән бергә хан кызы Гайшә тутайны да алып, ватанына кайтып китте.*

## Әсир тутай

*Сәмәрканд тирәсендәге әмир Тимер корган Баги-Чинар бакчасы. Гүзәл табигать манзарасы. Иштелер-ишетелмәс ләззәт вә рәхәтият бирүче аһәң ишетелә. Сайрар кошлар авазы яңгырап тора. Кайладыр челтерәп чишмә ага. Тирә-якта чәчәкләр, гөлләр, төрле матур җимеш агачлары үсә. Бакча уртасында ханәкә. Тимер белән Гайшә бикә әңгәмәсе.*

Т и м е р. Кил җаным, Гайшәм бикәм, утыр янымa... Нигә син шулай боек, нигә син күнел ачмыйсың? Бу бакчаны мин махсус синен өчен кордырдым. Бу—безнең никахыбыз бүләге булсын, дидем. Мондагы матурлык синеке. Бу—синен сараен, бикәчем!

Г а й ш ә. Тәкъсир! Җан җәрәхәтем әле йомылмаган.

Т и м е р. Ләззәти тән-бәдән рәхәте—йомар өчен җан җәрәхәтен.

Г а й ш ә. Җенси нәфес тәме түгел, кайгы гаме колиһәгә.

Т и м е р. Гайшәм! Мин җиде икълимнең бишесен яулаган әмир. Мин бик күп гүзәлләр күрдем үз гомеремдә. Аларның барысы да дип әйтерлек ата-анасыннан, якыннарыннан мәхрүм калды, ләкин аларның кайгылары озакка сузылмады. Бу гүзәллек, бу зиннәтләр, бу хәзинә аларның яраларын тиз төзәтте. Минем олы хатыным Мәликә бикәнең дә яу вакытында ире үтерелде, балалары һәлак булды. Бак, Мәликә бикә онытты, ул хәзер минем хозурымда. Ул мине назлый. Син дә назла мине. Син бит минем никахлы хатыным. Син—патшабикә!

Г а й ш ә. Миннән артык наз көтмәгез, тәкъсир. Мин вөҗүдемә каршы баралмыйм.

Т и м е р. Мин синең назынны яулар өчен ни кылырга тиеш, Гайшәм бикә?

Г а й ш ә. Мин вәгъдәмне үтәдем, ике ир туганымның җаны бәрабәренә мин сезләрнең хатыны булырга ризалык бирдем. Мин сезләрнең никахлы хатыны. Мин үтәрмен хатын вазифаларын һич тайчанмый. Әмма вакыт кирәк, вакыт.

Т и м е р. Вакыт сина гына түгел, мина да кирәк. Вакыт көтми, уза тора. Күпме гомер инде калгандыр? Дөрес, вакыт кирәк, мин әнә шул вакыт эчендә җиде икълимне синең аягын астына салачакмын!

Г а й ш ә. Кирәкми яу, тәкъсир, кирәкми кан, тәкъсир, кирәкми мина икълимнәр. Мина кирәк бары тик үз Болгарым. Ә ул хәрәбәләр булып кына калды.

Т и м е р. Мин Болгарны элеккесенә караганда да гүзәлрәк итеп торгызырмын, Гайшә. Тик син мина назлырак бул... Күгелташ! *(Күгелташ керә.)*

К ү г е л т а ш. Әмерен көтәм, әмирем.

Т и м е р. Җимерек Болгар каласын элеккесеннән дә матуррак итеп төзесеннәр. Болгардан алган хәзинә, малларның барысы да Болгарны торгызырга китсен.

К ү г е л т а ш *(пышылдап)*. Әмирем, Болгардан алган хәзинә, акчалар Сәедләр Бистәсен коруга кереп бетте инде.

Т и м е р. Ә син сиздермә, ризалык биргән бул!

К ү г е л т а ш *(кычкырып)*. Сездән

әмер, әмирем, бездән үтәү. Болгар каласы урынында тагын да мәһабәтрәк кала калкып чыгар, тәкъсир.

Т и м е р. Әмерем жиренә житкезелсен!

К ү г е л т а ш. Әмерең, әмирем. Башым аста, йөзем түбән! *(Китә.)*

Т и м е р. Мин әмир Хөсәен кебек комсыз түгел. Ул комсызлыгы аркасында харап булды. Ә хатыны мина калды. Әмир Хөсәен ул ерткыч жанвар кеби, яңа хатыннарын ул көч белән, ризасызлык белә ала килде. Мин көчләү, талау ягында түгел, Гайшәм бикәм. Мин ризалык аша гамәл кылырга күнеккән. Синең сараеңа киттек, жаным. *(Эчкәригә кереп китәләр.)*

## Җиһангирның хатыннары

*Мәликә бикә, Түкәл бикә, Сарана бикәләр белән жилпәзәче кызлар, жарияләр чыга. Алар бакчада йөренә. Мәликә бикә Аксак Тимернең олы хатыны, ул кызыл ефәктән тектерелгән, алтын ука белән чигелгән кин-озын күлмәк кигән. Аның күлмәге кыска жиңле, күкрәгендә ачыклык юк, күлмәкнең итәге жирдән сөйрәлгән булыр иде, итәкне жиргә төшермичә берничә кәнизәк арттан тотып йөри. Ханымның йөзе жинел ак челтәр белән капланган. Башында очлы кызыл башлык. Башлыктан иң өстенә хәтле ап-ак ефәк челтәр асылынып тора. Озын очлым-башлык бик күп мәржәннәр белән бизәлгән, алар арасында эре кызыл асылташлар, алтын кысаларга утыртылган фирүзә ташлар елкылдый. Битен каплабрак торучы челтәр алтын ука белән чигелгән. Очлымның аскы өлеше энжеләр белән бизәлгән такыя. Һәм маңгай турысында өч эре кызыл алмаздан торган шәй.*

*Башка хатыннар да кимен куймаган, барысының да киемнәре затлы, берсенеке фирүзә төсендәге күлмәк, өченчесенеке яшькелт зәңгәр күлмәк. Башлыкларындагы алмазлар саны тигез.*

М ә л и к ә *(жилпәзәче кызга)*. Күзең чыкмагандыр бит! Нигә жилпәзәнне минем авызыма тыгасың? Өстән генә жилпе.

Ж и л п ә з ә ч е. Кичерегез, ханым бикә.

М ә л и к ә *(Түкәл бикәнең итәген тотып баручы кызларга)*. Нигә аның күлмәген жирдән сүрисез! Куй көтүе артыннан чыккандай тузан болыты куптардыгыз! *(Түкәл бикәгә.)* Ә син, ачыгавыз, тузан исен сизмисеңме, ефәк итәгеннең пычранганын күрмисеңме?

Т ү к ә л. Ярамый ич, итәгемне артык күтәрсәләр.

М ә л и к ә. Күтәрсәләр, монда эт күрәме синең балтырларыңны?

Т ү к ә л. Күрмәс. Сөләйман пәйгамбәр Бәлгыйс патшабикәнең аякларын күрер өчен итәген күтәрттергән бит.

М ә л и к ә. Синең аякларыңны да Бәлгыйснықы кебек йон басканмыни?

*Хезмәтче кызлар пырхылдап көлә.*

Т ү к ә л. Ю-ук, минем аякларым төкле түгел.

С а р а н а. Минем дә аякларым төкле түгел.

М ә л и к ә. Житте! *(Алдан китә.)*

И т ә к ч е л ә р. Кичерегез, хан бикәләр. *(Бикәләр артыннан бакча түренә китәләр.)*

Б е р е н ч е ж а р и я. Ханбикәләр утлы табага басканнармы соң бүген?

И к е н ч е ж а р и я. Бүген генә булса икән! Олы бикә бер жанына урын табалмый.

Б е р е н ч е. Урта бикә дә пошаманда.

И к е н ч е. Урта бикә олы бикә өчен кайгыра ул.

Б е р е н ч е. Бу эштә аның ни катнашы?

И к е н ч е. Олы бикә кәефсез булса, кече бикәгә эләгә. Олы бикә бөтен ачуын кече бикәләрдән ала башлый.

Б е р е н ч е. Ни өчен?

И к е н ч е. Хужабыз әмир Тимер дүртенче хатын алып кайтканнан бирле олы бикә йоклый алмый.

Б е р е н ч е. Һи, олы бикә Мәликә хатын әмир Тимер Түкәл-бикәне алып кайткач та шулай кыланган иде.

И к е н ч е. Әмир Тимер олы бикәне генә ярата иде. Ул гел-гел аның эчкәри-

сендә төн узгара иде. Түкәл бикә килгәч, хуҗабыз олы бикәнең йортына сирәгрәк керә башлады. Сарананы алып кайткач, Түкәлнең ятагы бушап калды. Менә хәзер әмир Тимер дүртенче хатынлы булды. Һо-о, монысы Болгар әмире Габдулланың сөекле кызы Гайшә барысын да егып салды. Яу сәфәреннән кайткаңнан өч ай узды; өч ай буе хуҗа Тимер яшь бикәч куенынннан чыкмады.

Б е р е н ч е. Гайшә бикә дөнья гүзәле бит. Картлык көнендә Тимер чыннан да гүзәлләр гүзәленә тиенде инде.

И к е н ч е. Олыбикә Мәликәне дә, урта бикә Түкәлне дә, кәнизәкләрен дә онытты.

Б е р е н ч е. Олы хатыннар оныты-ла инде алар.

И к е н ч е. Болгар кызлары укымышлы шул алар, болгар кызлары чибәр шул алар. Әйләнә тирә ханнары, падишаһлары Болгардан кыз ала.

Б е р е н ч е. Алар янына бал сылап куйганнармы соң?

И к е н ч е. Болгар кызлары матур була беләләр, яраттыра беләләр, ди бит. *(Ханбикәләр якынлаша.)*

М ә л и к ә *(жариялэргә китәргә ишарәли, ханбикәләр генә кала).* Дәүләт эшләрен онытты түрәбез. Яу артыннан яу чаба иде.

Т ү к ә л. Аның яу чабуына караганда Сәмаркандта ятуы мең тапкыр артык.

М ә л и к ә. Аның яу чапмыйча, Сәмаркандта ятуыннан сиңа, миңа ни файда? Ничә көннәр ир заты күргәнем юк.

Т ү к ә л. Минем дә.

М ә л и к ә. Синең дә. Син әле ир тәмен тоя белмисең.

Т ү к ә л. Исем дә китми. Еллар буе яныма кермәсә дә сүз әйтмим. Йокым тыныч уза.

С а р а н а. Минем дә исем китми...

М ә л и к ә. Синең ана булганың юк шул, синең хатын буларак уянганың юк шул. Ә минем ике ир белән, ике әмир белән яшәп караганым бар. Мин ул ләззәтнең ни икәнен беләм, көндәшем. Әмир Хөсәен белән без тату яши идек, ләкин ул салкын ир иде. Яу артыннан яу чапты, комсыз иде ул, ана хатынынан битәр мал кирәк иде, байлык кирәк иде. Әмир Тимер ул башка, көндәшем. Әмир эчендә ирләр шайтаны утыра. Ана сыланган саен сыланасы килә. Минем өлешемә башта син кердең, ул да никахтан соң эчкәриеннән чыкмый ятты. Инде менә хәзер ниндидер бер Болгар чебеше синең төннәреңне урласын әле! Гарьлегеннән егылып үләрсең, валлаһи.

Т ү к ә л. Болгар әмире Габдулланың кызы Гайшә бикәч ул гүзәлләр гүзәле бит. Синең белән минем кебек үшән түгел.

М ә л и к ә. Нәрсәсе гүзәл инде шул чебешнең? Таптың сүз!

С а р а н а. Ие...

Т ү к ә л. Гүзә-әл шул, олы бикәм, көндәшем, Гайшә бикәч дөнья бәһасе бикәч.

С а р а н а. Гүзәл дип инде...

М ә л и к ә. Сөйләмә шуның турында!.. Чыңгыз канлы Казган ханның сөекле кызы, Тарагай углы әмир Тимернең олы хатыны Мәликә-бикә...

Т ү к ә л б и к ә. Чыңгыз канлы Тарма Ширин ханның сөекле кызы Түкәлбикәләрнең кайнар куенын...

М ә л и к ә. Әмир Тимер Болгар әмиренең кызы Гайшә бикә куенына алыштырды!

С а р а н а. Мин бернәрсә дә әйтә алмыйм.

*Күгелташ, Караләрвиш белән Сакчы керә.*

К ү г е л т а ш. Ханым бикәләр, әмирегезне вә яшь бикәчне каршы алырга әзерләнегез! *(Эчкәригә кереп китә.)*

М ә л и к ә. Сәедләр сәеде Исрафил хәзрәтләре. Зөфаф кичәсе ничә көн, ничә төн булырга тиеш диелгән китапта?

К а р а д ә р в и ш. Ханым бикәләр, зөфаф кичәсе никахлы ир белән никахлы хатынның теләгенә күрә, диелгән китапта.

Т ү к ә л. Никахлашканнан соң әмир Тимер минем белән өч көн, өч төн зөфафлап ятты.

С а р а н а. Минем янда ике төн кунды...

М ә л и к ә. Минем белән бер көн, бер төн булды.

Т ү к ә л. Ә нигә әмир Тимер җәнаплары Болгар кызы Гайшә бикә белән өч ай зөфафлыйлар?

М ә л и к ә. Коръәндә ир үзенең никахлы хатыннарын тигез күрергә, тигез асрарга диелгән түгелме?

К а р а д ә р в и ш. Сабыр төбе сары алтын, бикәләр. Чак кына көтеш кирәк!

*Чакыру музыкасы. Эчкәридән Күгелташ чыга. Ул тирә-якны карап-тикшереп уза. Аксак Тимер белән Гайшә бикә күренә. Алар тантана киемендә. Сарайдагылар аерылып аларга юл саба, баш ияләр. Тимер ханәкәдәге урынга утыра, аның уң кырына Мәликә, аннан Түкәл, Сарана, аннан Гайшә бикә урнаша.*

Т и м е р. Күгелташ!

К ү г е л т а ш. Әмерен, әмирем.

Т и м е р. Бүгенге көннән минем олы хатыным Болгар әмире Габдулланың кызы Гайшә бикә саналыр! Олы бикәм Мәликә хатын икенче хатыным булыр. Уртанчы хатыным Түкәл бикә үз урынында калыр, Сарана бикә дүртенче урында булыр.

К ү г е л т а ш. Башым өсте, әмирем. *(Ул ишарә ясый, олы хатын Мәликә урта урынга, Гайшә бикә беренче урынга күчә, Түкәл үз урынында кала. Сарана бикә кырыйга утыра.)*

К а р а д ә р в и ш. Никахың котлы булсын, әмир түрәм.

Б а р д а. Котлы булсын!

## Яу артыннан яу

К ү г е л т а ш. Әмирем! Анда ерак илләрдән илчеләр көтә өч ай инде.

Т и м е р. Илчеләрне мин зөфаф узмыйча кабул итмим, беләсең ич, сыйлансыннар, күрсеннәр илемне, кышлакларга, авылларга барып йөрсеннәр.

К ү г е л т а ш. Ләшкәрләрең, тәкъсир, гасабида, алар яу тели. Тик яткан-да алар ни кылырга белми. Үзара сугыша башладылар.

Т и м е р. Сабырлат син аларны! Булыр яу, яраннарым! Шундый яулар булыр, исләрегез, акылларыгыз китәр, бахырларым! Аллаһ миңа химаячы! Рәсүлебез миңа юл күрсәтә. Шуңа күрә, минем әле кяферләрдән, монафиклардан җинелгәнем юк!

К ү г е л т а ш. Нәрсә әйтим төмәнбашларга?

Т и м е р. Тояк кыздырсыннар! Бәйгеләрдә катнашсыннар. Озакламый яу сәфәренә чыгарбыз, иншалла!

К ү г е л т а ш. Әмерен, әмирем! *(Китә.)*

Т и м е р. Хәзер мине киңәшчеләрем белән генә калдырыгыз! *(Ханым бикәләр, жарияләр китә.)* Сәедләр сәеде Исрафил хәзрәтләре! Туктамыш баһадирны, Болгар Габдулласын тар-мар иткәнемдә синең киңәшләрең чиксез файдалы булды.

К а р а д ә р в и ш. Аллаһ сиңа ярдәм итте, тәкъсирем.

Т и м е р. Тәшәккүрләрем сиңа, сәед хәзрәтләре... Инде озак ял иттек, туйлар ясадык, яу түле җыелды. Ләшкәрем түземсезләнә, аларның атларына камчы, кулларына кылыч кирәк!

К а р а д ә р в и ш. Ярты сүздән сезне аңладым, тәкъсир. Форсат ачык, әмирем. Фарсы иле—Шираз башкаласы. Анда атаклы баһадир, курку белмәс, җинелү белмәс шаһиншаһ Әлмансур тәхеттә утыра. Бай ил. Бай казна. Кодрәт иясе шаһиншаһның биләмәләре чиксез. Ул чиксезлекне тагын да киңәйтергә уйлар. Аның күзе иң беренче Сәмаркандка төшәр, Мәвәрәәннәһергә багар.

Т и м е р. Ислам иле! Мөселманнар шәһәре! Үзе басып кермәсә, аңа яу чабу ярамас, пирем. Зинһар, Коръән ач, Исрафил хәзрәт.

К а р а д ә р в и ш *(серле музыка, Коръән ача).* Жиденче сүрә, сиксәненче аять: Лутны да пәйгамбәр итеп җибәрдек. Ул әйтте: сездән элекке кавемнәр дә кыла алмаган фәхешлекне эшләргә җыенасызмы? Чөнки сез шәһвәти ләззәт өчен, хатыннарыгызны ташлап, ирләргә якынаясыз. Дөресен әйтим, сез хәттин ашкан бер бозык халык икәнсез. *(Коръәнне ябып куя.)* Әмир хәзрәтләре, сезләр бит Исламны сафландырырга алынган мәсих кеби олуг зат! Фарсыларда, Ширазда, аңа күрше Ислам илләрендә тәтәй йортлары, комар уеннары, төнге ханәкәләр тоталар, ул ханәләрдә, хәтта бәгъзе түрәләр женси ихтыяжларын канәгатьләндерер өчен малайлар тота—анда фахишлек чәчәк ата. Сез шуны беләсезме?

Т и м е р. Ишеткәләгән идем, ләкин мин моңа ышанмаган идем.

К а р а д ә р в и ш. Без Ширазда үзебез булдык, тәкъсир. Барысы да хак!

Т и м е р. Шаһиншаһ Әлмансурмы шушы эшләргә фатиха бирә?

К а р а д ә р в и ш. Фатиха бирәме, юкмы, нәмәгълүмдер. Әмма аның бил-

әмәләрендә фахешлек кылына. Ул аны белми, күрмиме, белмәмешкә, күрмәмешкә салышамы?

Т и м е р. Кинәшен, хәзрәт?

К а р а д ә р в и ш. Яу чабарга! Тармар итәргә! Саф Исламны кайтарырга!

Т и м е р. Аллага тапшырдык! Гаскәрләрем, унбашлар, йөзбашлар, меңбашлар, унмеңбашлар, йөзмен башлар, Шираз тарафына яу сәфәре игълан ителәӘ!

*Ике йөз мең кешелек гаскәрнең хуплау авазлары. Карнай тавышлары, барабан дөпелдәүләре. Ат тоякларының дала буйлап чабып узганнары ишетелә.*

*Ике йөз меңлек гаскәр, яндагы атлар белән дүрт йөз мең ат, илле мең дөя Ширазга яу сәфәренә чыкты. Ләкин алдан кисәтелгән шаһиншаһ Әлмансур өч йөз меңлек гаскәре белән Аксак Тимергә каршы төште. Әлмансур солых сорады, Аксак Тимер солыхны кабул итмәде. Орыш башланды. Бу орышта Аксак Тимер ярты гаскәрен югалтып кайтып китте. Җиңелү әчесен татыган кансыз әмир янә яу әзерләде, өч йөз меңлек гаскәр китте Шираз каласына. Аксак Тимер тагын кылычын сындырып кире борылды. Сигез тапкыр алалмады Аксак Тимер Шираз каласын. Тугызынчысында җанбаз Тимер биш йөз меңлек гаскәр туплап яуга китте. Шаһиншаһ алты йөз мең гаскәрен каршы куйды. Аксак Тимер икеләнеп калды. Бу юлы да ул җиңелсә, бетте солтанат, китте хакимлек, юкка чыкты тәхет, тәхет урынына ләхет кенә калачак... Шаһиншаһ тагын солых тәкъдим итте:* ***без икебез дә мөэмин мөселманбыз, туктатыйк бу кан коешны. Килешик, татуланыйк. Менә сиңа, әмир Тимер, солых бүләгесе, итеп күп хәзинә, солых бүләгесе итеп, тугыз хәтәр чабышкый. Фил сөягеннән эшләнгән алмазлардан ясалган шахмат уены. Ал, әмир Тимер, без татуланыйк.*** *Аксак Тимер бүләк алыр өчен түгелдер, җиңеләсен белептер, ахрысы, бүләкне алып, солыхка кул куйды да олы бүләкләрне күтәреп Сәмәркандка кайтып китте. Аксак Тимернең кәефе кырылган иде. Аны хәтта асылташлар белән тулы сандык та, урам-урам постаулар да, киләп-киләп комачлар да кызыксындырмады. Башка яулардан да ул шушыннан артык байлык алып кайтмый иде. Ни өчен Әлмансур җиңелмәгән килеш, карышырга куәте бар килеш солыхка тартыла, яу килгән саен олы бүләкләр, ганимәт малы чаклы бирнәләр белән аны озатып кала? Шаһиншаһ Әлмансур аның горурлык сызлавыгына баскан иде. Монарчы бер генә патшадан да мондый үҗәт каршылыкны күрмәгән Тимер әмир бу җиңелүне кичерә алмады. Аның җиңелгән дошманнарына карата бервакытта да үчлеге булмады, җиңелгән, җиңгән, хәтта әсир төшкән ханнар яки солтаннарны да ул кыерсытмас, аларны тиң күреп, янына утыртыр иде. Ләкин шаһиншах Әлмансур башка, аның куәте, аның дәрәҗәсе, аның акыл белән эш йөртүе, оста сугышуы, билбирмәслеге Тимернең җен ачуын чыгарган иде.*

## Нахак яла

*Сәмәркand сарае. Аксак Тимер шаһ Әлмансурдан җиңелгәч нык үзгәрде, ул һәрвакыт кәефсез халәттә арлы-бирле йөрени. Әмирнең хатыннары: Мәликә, Түкал, Сарана бикәләр күренә.*

М ә л и к ә. Галиҗанәбем, син яуларда йөргән чакта, сараеңда яңалыклар булып алды бит әле.

Т и м е р. Нинди яңалык ул, бикә?

М ә л и к ә. Синең сөекле яшь хатының Гайшә бикә...

Т и м е р. Дәвам ит, хатын!

М ә л и к ә. Әйтергә дә хәтәр, хуҗам.

Т и м е р. Кизәнгәнсең икән сук, суккансың икән—үтер! Башлагансың икән, мине котыртып калдырма, азагына чаклы әйтеп бетер, ни булды сараемда?

М ә л и к ә. Ни инде...

Т ү к ә л. Әйтмә син аны, ханым бикә.

С а р а н а. Мин әйтмәс идем.

Т и м е р. Ни булды, әйт! Нигә сез өчәү генә йөрисез? Кайда Гайшә бикәч?

М ә л и к ә. Гайшә бикә, сиңа тугры хатын булып чыкмады, әмирем.

Т и м е р *(ярсуын тыеп)*. Мәликә хатын! Син нинди сүз әйткәненне аңлыйсыңмы? Кайда исбат? Кайда дәлил?

М ә л и к ә. Синең сөекле Гайшәң ханәкәсендә төннәрен яраннарыңның берсен кабул итә.

Т и м е р. Исбат! Дәлил! Юкса, үзеңнен башың тәгәрәп төшәчәк!

М ә л и к ә. Гайшәннең кул сандыгында бер һәдия белән бер хат ятыр.

Т и м е р. Хакмы шул? Хатынны хыянәттә гаепләр өчен дүрт шаһит кирәк, хатын! Кайда синең ике шаһитең?

М ә л и к ә. Әмирем, без икәү, шулар өстенә кулсандыктагы ике дәлил. Менә була дүртәү.

Т и м е р. Түкәл бикә, син дә шаһидәме?

Т ү к ә л. Ни инде... Әйтмик дидем мин сиңа...

С а р а н а. Ие шул.

Т и м е р. Кертегез Гайшәбикәне.

М ә л и к ә *(ишек ягына кычкыра)*. Гайшә бикәне кертегез!

Г а й ш ә *(керә)*. Әмиремә иминлекләр юлдаш булсын!

Т и м е р. Хатыннарым әйтә, имеш, син ханәкәнә яраннарымның берсен аласың икән! Дөресме шул?

Г а й ш ә. Әмирем, мин ялгыш ишеттемме? Кем, кая, кемне алган?

Т и м е р. Син дөресен әйт, хатын. Кем ялган сөйли, кем исбат китерә алмый, шуның башы чабылачак.

М ә л и к ә. Синең уңышсыз яуларың турында ишеткәч, өч хатын кочаклашып төннәр узгара идек, шул төннәрнең берсендә, аннан тагын берничә төн Гайшә бикәнең ханәкәсенә гел бер шәүлә узып китә иде. Таң алдыннан гына шул ук шәүлә яшертен генә сарайдан чыга иде.

Т и м е р. Бер хатыным яраным белән хыянәт итте. Аның ахыры ни булып бетте?

М ә л и к ә. Яраның качып котылды, хатыныңның башын чабып өзден, тәкъсир.

Т и м е р. Дөрес сөйлиме Мәликә хатын, Түкәл бикә, әйт.

Т ү к ә л. Ни инде... күрдек...

С а р а н а. Мин берни дә әйтмим.

Т и м е р. Кемне күрдегез? Кем иде ул кеше?

Т ү к ә л. Танымадык.

С а р а н а. Мин берни дә күрмәдем.

Т и м е р. Барыгыз, Гайшә бикә ханәкәсеннән сандыгын алып килегез. *(Хезмәтчеләр чыгып йөгерә.)*

Г а й ш ә. Әмирем, бу—бөһтан, бу—яла, бу—ялган! Хыянәттәме соң минем уем? Үзең беләсең бит минем хәсрәтемне!

Т и м е р. Ике шаһит җитә гаебеңне раслар өчен.

М ә л и к ә. Мин беләм кем икәнен.

Т и м е р. Кем?

М ә л и к ә. Шәех Исрафил хәзрәтләренең колы Мостафа!

Т и м е р. Мостафа?

М ә л и к ә. Рас! Мостафа! *(Сандыкны алып киләләр.)*

Т и м е р. Ачыгыз сандыкны! *(Мостафаны китерегез.)*

М ә л и к ә. Ачкычы Гайшә бикәдә.

Т и м е р. Ач!

Г а й ш ә. Әмирем, бу нинди афәт? Минем гаебем юк.

Т и м е р. Ачкыч!

Г а й ш ә *(ачкычын суза)*. Әмирем!

М ә л и к ә Китер әле! *(Гайшә кулыннан ачкычны тартып ала. Сандыкны ача. Аннан хат белән алмаз кашлы йөзек килеп чыга.) Менә, җаным!*

Т и м е р. Бу йөзек синекеме?

Г а й ш ә. Юк, минем йөзек түгел бу?

Т и м е р. Кемнеке? Каян килеп эләккән ул синең кулсандыкка?

Г а й ш ә. Белмим!

Т и м е р. Хатны ачып укыгыз!

М ә л и к ә *(укый)*. Күктәге Чулпан йолдызым син, Гайшә бикә. Күктәге Зөһрә йолдызым син, Гайшәбикә. Күктәге тулган аем син, Гайшәбикә. Сине күрми торсам, янамын, көямен, кибәмен... Ләззәтле кочагыңда үлсәм, мин үземне бәхетле санар идем. Сине өзелеп сагынучы, сөюче Мостафаң.

Г а й ш ә. Йа Аллам, бу нинди афәт, бу ниндидер куркыныч төш, мин беркемне дә белмим, минем бу хатны күргәнем дә юк.

Т и м е р. Ничек килеп эләккән соң ул синең сандыкка? Ачкыч синдә генә бит.

Г а й ш ә. Белмим, белмим. Минем гөнаһым юк. Бу—яла! *(Капланып үкси.)*

*Сакчыны алып керәләр.*

Т и м е р *(хатны суза)*. Бу синең язумы?

С а к ч ы. Юк, мин яза белмим.

Т и м е р. Димәк, син минем хәләл хатыным янына төннәрен кереп йөрүче, димәк, син мәхәббәт хатын кемгәдер әйтеп яздыручы.

С а к ч ы. Әмирем, ялган! Мин яза белмим! Кешегә дә әйтеп яздырмадым. Мин Гайшә бикә ханәкәсе ишегенең кайсы якка ачылганын да белмим. Зин-

һар, ялгышмагыз, әмирем, хатыныгызның да, минем дә гаебем юк. Хата кылмагыз, зинһар, бу кем тарафыннандыр кылынган явыз гамәл.

Т и м е р. Күгелташ!

К ү г е л т а ш. Әмерен, әмирем!

Т и м е р. Икесен дә кылычтан узгарырга!

К ү г е л т а ш *(кылычын суырып чыгара).* Әйдәгез! *(Икесен дә ике сакчы тотып ала.)*

Г а й ш ә. Гаебем юк, әмир.

С а к ч ы. Гаебем юк, тәкъсир. Бу—яла!

Т и м е р. Зиначылар! Сезгә үлем! Алыгыз хыянәтчеләрне! *(Алып китәләр.)*

К а р а д ә р в и ш *(керә).* Тәкъсирем, монда ни булды?

Т и м е р. Зиначылар тотылды!

К а р а д ә р в и ш. Зиначылар? Кемнәр алар, кабахәтләр?

Т и м е р. Анын берсе синең колың Мостафа.

К а р а д ә р в и ш. Мостафа? Булмас!

Т и м е р. Икенчесе—минем сөекле хатыным Гайшә бикә.

К а р а д ә р в и ш. Шаһидләр бармы?

Т и м е р. Ике хатыным, сөяркәсенең хаты, *(яраннар хатны Карадәрвишкә тоттыра, Карадәрвиш хатны игътибар белән кат-кат укый.)* аңа бүләк ителгән алмаз кашлы йөзек. Аларнын башлары чабылачак.

К а р а д ә р в и ш. Әмирем Тимерем! Сабыр булыш кирәк. Монда нидер аңлашылмый. Тукта, тукта, ашыкмыйк, кире кайтарып алып булмаслык хата булачак, тәкъсир.

Т и м е р. Дәлилләр житәрлек, хәзрәт!

К а р а д ә р в и ш. Тәкъсирем, мин Мостафа белән бер йортта торамын. Мостафанын төнлә чыгып йөргәне юк. Мин күкрәгемә кулымны куеп, Алла исеме белән ант итеп әйтәмен ки: Мостафа бу эшне кылмас!

Т и м е р. Шаһидлек шиккә алынды.

К а р а д ә р в и ш. Икенчедән, минем колым яза белми. Өченчедән, бу хатны ир кулы язмаган, тәкъсирем. Өченчедән, бу зәгъфәран буяудан ясалган кара белән язылган. Тикшерт, әмирем, зәгъфәран кара кайсы жариядә яки кайсы хатынында бар.

Т и м е р. Шаһидлеккә шик артты.

Т ү к ә л *(кинәт калтырый, жылый башлый).* Йа Аллам, Ходаем, үзең сакла!

К а р а д ә р в и ш. Бу алмаз йөзекне мин Чаршау базарында сату итүче Сархан сәүдәгәрнең лаукасында күргән идем. Анын бәһасе йөз алтын дирхәм иде. Барып сорагыз Сархан сәүдәгәрдән, бу алмазны аннан кем сатып алды икән?

Т и м е р. Ялган шаһидлек ачыла бара.

Т ү к ә л. Әйттем, әйттем мин, алай итмик дидем.

Т и м е р. Син нигә үкерәсен, Түкәл бикә?

М ә л и к ә. Үкерми, үкерер шул, зәгъфәран кара Түкәл бикәдә генә. Алмазны ул сатып алып кайтты да сандыкка ачкыч ятатып, хатны, йөзекне салып куйды.

Т и м е р. Дөресме шул?

Т ү к ә л. Мин сатып алып кайттым алмазны, мин яздым хатны Мостафа исеменнән, мин салдым сандыкка боларның барысын да. Мәликә бикә акчасына йөзекне мин барып алдым. Гөнаһлы булдым.

М ә л и к ә. Ялганлый, тоз күз. Минем ни катнашым бар? Үзең кылгансың, үзең жавап тот. Мине катыштырма!

Т ү к ә л. Әмиребез Болгардан Гайшә бикәне алып кайтканнан бирле бер жанына урын табалмый ул. Төннәрен пошкырып чыга. Гайшә бикәне ике тапкыр агуларга маташты. Агу ясап миңа бирде, Гайшәнең ашына сал, диде. Мин ул эшкә бармадым. Инде менә монысында ялгыштым. Кичерә күр мине, әмирем.

К а р а д ә р в и ш. Ант итә аласыңмы?

Т ү к ә л. Валлаһи газыйм, валлаһи газыйм, валлаһи газыйм, эш мин сөйләгәнчә булды, ул мине котыртты, куркытты.

К а р а д ә р в и ш. Эш узганчы, әмеренне кире ал, тәкъсир.

Т и м е р. Алып керегез икесен дә!

И ш е к с а к ч ы с ы. Тоткыннарны кертегез!

*Күгелташ, Сакчы, Гайшә керәләр.*

Г а й ш ә. Корьән тотып ант итәм, Аллаһ исеме белән ант итәмен, минем гөнаһым юк каршында. Мин үлемнән курыкмыйм, ләкин зиначы исеме белән дөньядан китәсем килми. Хатыннарын ялган сөйли!

С а к ч ы. Валлаһи, валлаһи, валлаһи, гаебем юк Аллаһ каршында да, синен каршында да. Бу бала да гөнаһсыз.

Т и м е р. Йа Ходам! Сараемда ниләр кылына. Әмерем шул! Мәликә бикә, сина сиксән таяк, Түкәл бикә сина кырык таяк! Алыгыз!

Т ү к ә л. Әйттем, әйттем, алай кылу гөнаһ, дидем.

С а р а н а. Ие шул...

*Хатыннарны алып чыгып китәләр. Артта чырыйлап кычкырган авазлар ишетелә.*

Т и м е р. Газизем минем Гайшә бикәм, кичер мине карт тилене, кеше сүзе кеше үтертер, ди. Ярый әле шәех Исрафил хәзрәтләре килеп керде. Юкса, икегезнен дә башыгыз оча иде. Кинәшчемә чиксез тәшәккүрләр. *(Тимер Гайшә бикәне эчкәрегә чаклы озата да кире борыла.)* Йа Алла, дошманым шаһ Мансурдан жинелгәндә сараемда ниләр кылына!

## Мәкерле хәйлә

*Сәмарканд. Әмир Тимер кинәшчеләре арасында пошаманда.*

К ү г е л т а ш *(керешли)*. Әмирем, анда Шираз шаһиншаһы Әлмансурдан тагын илчеләр килгән.

Т и м е р. Ни булыр бу? Ни өчен Әлмансур яу артыннан ук илче юллаган? Кинәшегез, яраннарым?

К ү г е л т а ш. Аларнын бик күп бүләкләре бар.

К а р а д ә р в и ш. Кабул итәргә кирәк. *(Тимерне яраннарыннан аерып, бер читкә алып чыгып, яшертен сүз әйтә.)* Тәкъсирем, бу—шаһиншаһнын бер хәйләседер. Үзен жинган патшалыклардан да син шаһиншаһ Әлмәнсурдан алган байлык кебек ганимәт алганын булмады. Ул синен жинеп, биргән байлыгын кире кайтарырмын, дип уйлый, күрәмсен. Хәйләгә каршы хәйлә кирәк, әмирем. Шаһиншаһ Әлмансур бүләксанак белән алдап-йолдап, арка ягына төшәргә маташмыймы?

Т и м е р. Нинди хәйлә, пирем?

К а р а д ә р в и ш. Син хәзер үк куй бәрәнен бугазлат та, бер чүмеч жылы бәрән канын эчеп бетер. Илчеләр кергәндә ятып тор. Без сине сырхау, диеп игълан итәрбез. Бәрән канын эчкәч, синен йөзен ап-ак булыр. Хәлен китәр. Күрсеннәр илчеләр: син бик каты хасталангансын икән. Алар кергәч, шул канны тазга кос. Син тагын да агарырсын. Алар: әмир Тимер үпкәләрен косып бетерде, ул инде бу дөнья кешесе түгел, дип уйлап сөенеп кайтып китәр һәм шаһларына синен үлем ястыгында ятканынны житкерер. Шаһиншаһ гаскәрен таратып, тыныч кына яшәп ятканда, син зур гаскәр белән яуга чыгарсын, шаһ Әлмансур Ширазга гаскәр туплап өлгергәнче син каланы басып алырсын.

Т и м е р. Хуп! Яраннарым!

К ү г е л т а ш. Әмеренне көтәм, әмирем.

Т и м е р. Тиз булыгыз, куй бәрәне суеп, бер чүмеч канын мина китерегез.

К ү г е л т а ш. Башым өсте, йөзем түбән, тәкъсир. *(Ашыгып чыгып китә.)*

Т и м е р. Чыгып әйтегез, илчеләр бераз көтсеннәр. Әмир Тимер каты хаста, бераз хәл алсын, аннан сон чакырырбыз, дип әйтегез. Озак тормас, күреп, бәхилләшеп калыгыз, дип бераздан аларны яныма алып керерсез. *(Йомышчы чыгып китә.)*

К а р а д ә р в и ш. Тәкъсирем, чыннан да синен хәлен китәр, косасын килә башлар. Түз! Алда сине бөек жину көтә.

К ү г е л т а ш. Менә тәкъсир, бер чүмеч жылы кан. *(Тимер чаршау артына кереп канны эчә.)*

К а р а д ә р в и ш. Жиз таз, комган, тастымал, су алып килегез.

*Хезмәтчеләр чыгып йөгерә, озакламый кушкан нәрсәләрне алып керәләр. Тимер чаршау артыннан чыга. Ул агарынган. Эчен тотып, тәхетенә кырын ята.*

Т и м е р. Чакырыгыз!

К ү г е л т а ш. Шираз Шаһиншаһы Әлмансурнын илчеләрен кертегез!

*Сакчы илчеләрне алып керә. Алар йола буенча баш ия. Тимер ынгыраша. Карадәрвиш Тимернен баш очында ясин укый.*

К а р а д ә р в и ш. Бисмилләһ иррахмән ир-рахим. Йәә сиин. Үәл Куръәнел хәким. Иннәкә ләминәл мүрсәли-

ин. Галәә сыйратим мустакыйиим...

Б а ш и л ч е. Бөек зафәр иясе әмир Тимер. Хастан узар булсын!

К а р а д ә р в и ш *(һәм башкалар).* Амин!

Б а ш и л ч е. Әмир Тимер җәнаплары! Шираз шаһиншаһы Әлмансур хәзрәтләре солыхнын дәвамлы булуын теләп, сина вә синен хатыннарына ошбу һәдияләрне юллады. Зинһар, ихластан биргән бүләкләрне ихластан кабул итсән иде.

К а р а д ә р в и ш. Әмир Тимернен хәле начар.

*Тимер укшый башлый. Таз алып киләләр, комган белән су тотып торалар. Әмир Тимер чаршау артына кереп, мул итеп тазга кан коса. Чаршау артыннан хәлсез Тимерне алып чыгалар, кырын яткызалар. Хезмәтчеләр илчеләр күрерлек итеп, тазны алып чыгып китәләр.*

Б а ш и л ч е. Лә хәүлә вә лә куәте!

К ү г е л т а ш. Бүләкләрегез өчен әмиребез Тимер чиксез рәхмәтләр әйтә, ләкин анын бүләкләрдә гаме юк инде.

К а р а д ә р в и ш. Васыятен әйтеп өлгерсә ярар.

К ү г е л т а ш. Кичерегез могътәбәр илчеләр.

Б а ш и л ч е. Әйдәгез, кайтып шаһиншаһка бу хәбәрне ирештерик.

Т и м е р. Үләм! Бәхил калыгыз... яраннарым...

*Күгелташ, Сакчы илчеләрне озата чыга. Илаулап хатыннар, жарияләр керә.*

М ә л и к ә. Әмирем, жаным бәгырем, ни булды сина?

Т ү к ә л. Сау-таза йөргән кеше шулай кинәт егыламы?

С а р а н а. Мин берни дә белмим.

Г а й ш ә. Аллаһ Тәгалә барысын да тигезли ул.

К ү г е л т а ш. Ханым бикәләр, әмиребезнен хәле авыр. Зинһар, аны борчымагыз.

М ә л и к ә. Нишләрбез синнән башка-а.

Т ү к ә л. Ташлап китмә безне, әмиребез.

Г а й ш ә. Барысы да Аллаһу Тәгалә кулында.

К ү г е л т а ш. Чыгып торсагыз, яхшырак булыр. *(Хатыннар китә.)*

*Тимер саф су белән авызын чайкый, күп итеп су эчә. Ана хәл керә башлый.*

Т и м е р. Фу-у, чыннан да, үлә яздым.

К а р а д ә р в и ш. Елга бер тапкыр жылы кан белән ашказанын пакълендерү озын гомергә сәбәпче була, тәкъсирем.

Т и м е р. Хәзер үлеп ашыйсым килә!

К ү г е л т а ш. Кыздырылган бәрән ите белән кымыз-буза сезне көтә, тәкъсир.

*Тимер үләргә яткан кеше булып шундый ышандырырлык итеп кыланды ки, илчеләр генә түгел, үзенен якыннары да анын үлем түшәгенә егылганына инанган иде. Хәер, Тимернен мондый күз буулары бәрән каны белән генә булмады. Ул бернича тапкыр үзенен үлгәне турында халык арасында, сарайдагылар арасында ялган хәбәр тараттырды. Анын үлгәнен ишеткәч кем сөенә, кем көенә, кем битараф булып кала, әмир шуларны хисапка ала һәм алга таба эш йөреткәндә тегеләрнен язмышларына сизелерлек тәэсир итә килде.*

*Дастархан. Падишаһнын ашханәсендә. Учакта куй кыза. Мул табын янында ашау-эчү, шау-шу, сакыйлар шәраб, кымыз, буза тараталар.*

## Оттыру

*Баги-Чинар. Тимер аштан сон бакча буйлап йөренә.*

Т и м е р. Адәм көлкесе! Шул фахиш Әлмансурдан ничә тапкыр жинел, имеш! Ул мине мыскыл итте. Гаскәре минекеннән күбрәк булса да, көчле булса да ул мина олы һәдияләр биреп солых төзеде. Оят, валлаһи!

К ү г е л т а ш. Балки чыннан да солыхта яшәеш кирәктер, тәкъсир. Юкса, без яу саен халыкны кырдырабыз түгелме?

Т и м е р. Ә дин бозучы монафикъ-лар иркендә яшәсенме? Минем мәсих-лык вазифам бар: ул—динне сафланды-ру. Мин дөньяга килгән сәгатьтә атам Тарагай изгеләрдән Коръән ачтырган. Тимер сүрәсе ачылган, анда язылган: күкләрдә вә Җирдә булган барчасы Ал-лаһка тәсбих әйтә. Аллаһ җиңелү белмәс кодрәт һәм хикмәт иясе. Күкләрдәге, Җирдәге бөтен байлык Аныкы. Без ти-мерне дә иңдердек, чөнки тимердә су-гышлар өчен хәтәр куәт бар һәм тыныч-лыкта ул инсаннарга файдалы... Шуңа күрә, атам миңа Тимер исеме куштыр-ган. Мин Коръәннән алынган исемем-не аклаячакмын! Киңәшен, Исрафил хәзрәтләре?

К а р а д ә р в и ш. Тәкъсирем! Бу уңышсыз сәфәрләрең синең бөек уңышыңа күпер булып ятсын!

Т и м е р. Амин, хәзрәт!

*Тәхетханәдә Тимер, Карадәрвиш, Сакчы, Мәликә бикә, Түкәл бикә, Са-рана бикә, җариәләр.*

К а р а д ә р в и ш. Тәкъсирем, киле-шенгән вакыт инде күптән чыкты, өч айга урнашкан мин синең янда ике елга якын хезмәт иттем. Син мине азат ит бу вазифамнан. Мин ватаныма—Гранадага кайтып китим.

Т и м е р. Сарай казнасындагы хәзинәдән син ни телисең, хәзрәт?

К а р а д ә р в и ш. Дәрвиш кешегә ни кирәк? Азатлык белән саф һава кирәк!

Т и м е р. Мәйлен, хәзрәт. Гранада-дан Кастилия еракмы?

К а р а д ә р в и ш. Ерак түгел, бер атналык юл. Кастилиянең башкаласы Толедо якын гына.

Т и м е р. Шәех Исрафил хәзрәтләре, мин сиңа яңа вазифа йөклим. Гранада-ның хәлифе Мөхәммәд Бишенчегә һәм дә Кастилия короле...

К а р а д ә р в и ш. Кастилия короле-нең исеме Һәнрих Өченче, тәкъсир.

Т и м е р. Кастилия короле Һәнрих Өченчегә син миннән илче булып ба-рырсыңмы?

К а р а д ә р в и ш. Ышанычыгызга күрә, рәхмәтләрем.

Т и м е р. Күгелташ, илчеләремне юлга әзерлә. Аларга егерме хезмәтче күндер.

К а р а д ә р в и ш. Дикъкатеңә чик-сез рәхмәтләрем, тәкъсир.

Т и м е р. Аерылышыр алдыннан колың Мостафа белән шахмат уйнарга телим.

К а р а д ә р в и ш. Мәйлен, тәкъси-рем.

С а к ч ы. Шартлары ничек соң?

Т и м е р. Минем шартым шул, әгәр дә мин отсам, сез монда минем хозу-рымда каласыз. Минем сезне җибәрәсем килми. Миңа синдәй киңәшче кирәк, Исрафил хәзрәт.

С а к ч ы. Мин отсам?

Т и м е р. Шартыңны әйт!

С а к ч ы. Болгар явына атланып бар-ган Акбәкәл исемле атыгызны куймая-чаксыз!

Т и м е р. Куймаячакмын!

С а к ч ы. Яу бәрәбанынны куйма-ячаксыз!

Т и м е р. Юк! Ул комарга куелмас! Башка нәрсә сора!

С а к ч ы. Кичә күр, тәкъсир, кичә күр. Алайса, кече хатының Гайшә бикә-не куй!

Т и м е р *(сикереп тора, хәнҗәренә тотына).* Ахмак! Тастаракай! Ни сөйләгәнеңне колагың ишетәме? Димәк, чыннан да сезнең арада кышы-мышы булган?

С а к ч ы. Юк, тәкъсир, гөнаһ юк. Ләкин мин аны үзем өчен сорамыйм. Илче булып кайткач, без Гранада хали-фе Мөхәммәд Бишенчегә, Кастилия ко-роле Һәнрих Өченчегә нинди бүләк алып кайтырбыз? Аларның алмазлары баз тулы. Комачлары киштәләп, аларга иң яхшы бүләк ул синең җариәләрең-нең берсе, анысы Мөхәммәд хәлифкә; хатының Гайшә—корольгә.

Т и м е р. Булмас эшне сөйләмә! Әмир Тимернең хәләл хатынын даулый-сың! Әмир Тимер хатынын җирәбәгә салмас!

К а р а д ә р в и ш. Тәкъсир, шахмат-та кем ота, кем оттыра бит әле! Уен-нарның отышы күбесе синең кулда була килде. Отыш Мостафа ягында булырмы әле, юкмы, нә мәгълүмдер. Падишаһ отса, безне ота. Маллар тигез түгелме, тәкъсир?

Т и м е р. Анысы шулай! Мине от-кан кеше сирәк!

К а р а д ә р в и ш. Без ике гүзәл хатынны диңгез кырындагы ике пади-

шаһка алып китеп, арагызда бик файдалы килешү корсак, арагызда сәүдә кәрваннарны, мал төягән көймәләр йөри башласа! Колым Мостафа белән монда калып, синең янда Коръән укып утырсак ничек? Фикерем шул: син оттырсаң да оттырмаячаксың, икесе дә синең өчен файда гына!

Т и м е р. Һым, анысы дөрес! Ярый! Тезегез шакмакларны! *(Күгелташ чыгып китә.)*

К а р а д ә р в и ш. Шартнамә язып лязем, тәкъсир.

Т и м е р. Языгыз! *(Хаттатлар шартнамә яза.)* Мостафа отса, бер жариям, Гайшә бикә исемле хатыным миннән талак алып, чит патшага һәдия булыр. Мин отсам, шәех Исрафил белән аның колы Мостафа белән гомерлеккә сараемда киңәшче сыйфатында кала! Ике яклы килешү, имзам, мөһерем. Алыгыз!

*Шартнамәнең бер данәсе хаттатта кала, икенче данәсен Мостафа кесәсенә тыгып куя. Эчкәридән Күгелташ чыга.*

К ү г е л т а ш. Шахматлар әзер, тәкъсир. Шаһидләр ян-якка бастылар.

Т и м е р. Аллага тапшырдык!

*Шахмат ханәкәсе.*

*Барысы да шахмат өстәле ягына килә.*

*Гайшә бикә, шобага салынган жария, Карадәрвиш бакчага чыга..*

Г а й ш ә. Рәхмәт, изге ата. Син мине хурлыклы үлемнән коткардың. Инде нишлим? Әгәр дә Мостафа отса, әгәр дә әмир отса?

К а р а д ә р в и ш. Гүзәлләрнең язмышы шул, кызым. Алар кулдан кулга, илдән илгә күчеп йөри. Кыз кеше ватанында үлә алмый. Ул ире кулында. Әгәр дә Мостафа отса, син Испаниягә китеп, анда королева булачаксың. Әгәр дә әмир отса, аның сөекле хатыны булып калачаксың, ничек булса да син патшабикә булудан туктамаячаксың.

Ж а р и я. Изге ата, мине нинди язмыш көтә?

К а р а д ә р в и ш. Сиңа да шул ук язмыш әзерләнгән, кызым. Син Гранада халифе Мөхәммәд Бишенченең сараена төшәчәксең! Фикерем шул, Мостафа отса, сөенегез, сөенечегезне әмиргә күрсәтмәгез. Монда сезнең язмыш тиз үзгәрүчән. Бүген бар ул патшалык, иртәгә юк. Бүген сез әмирнең хатыны, иртәгә бер юлбасар кулында. Ни булса да кайгырмагыз! Язмышыгыз шобагага куелган. *(Шахматчылар ягына кереп китә.)*

Ж а р и я. Кайгырмаем әле. Кем куйнында ятсак та бер түгелме?

*Жария кулына гөслә ала, уйный башлый. Гайшә бикә музыкага бирелеп китә. Монлана.*

Г а й ш ә.
Сызыла бәгърем, сызла жаным,
Сызылып бет, йөрәк маем.
Сызлап, сызылып, бахыркаем,
Егълап туймый Гайшәкәең.

Ел кебек тоелыр анда айлары.
Сызар ла йөрәкнең майлары.

Сандугачлар кайда сайрыйдыр?
Сары яфракларның астында.
Күп йөрмәм, тиз китәрмен инде,
Ятармын чит туфраклар астында.

Ел кебек тоелыр айлары,
Сызар ла йөрәгенең майлары.

*Шахмат уены ягыннан шау-шу ишетелә.*

Ж а р и я. Кем отты икән, ханым бикә?

Г а й ш ә. Кем отса да сиңа барыбер түгелмени?

Ж а р и я. Барыбер түгел, минем моннан китәсем килә. Сөймим мин Аксак Тимерне.

Г а й ш ә. Аны кем сөя икән?

*Уенчылар чыга. Шау-шу.*

Т и м е р. Ничек шулай булды соң?

К а р а д ә р в и ш. Уенда харам юк, тәкъсир.

Т и м е р. Харам юк, әмма ничек кол мине отты? Ни гомер аны мин ота килдем. Хәйран, вәйран!

С а к ч ы. Тәкъсир, сез филегезне сакламадыгыз. Шулай итеп, ат белән ике яклы чатал-сәнәккә килеп эләктегез.

Т и м е р. Ярый, шигем дә бар минем ул хатынга. Талак! Талак! Талак! Алыгыз сез Гайшә бикә белән бу жариямне! Гранала халифе Мөхәммәдкә жариям, Гайшә бикәне Кастилия короле Һәнрихка тапшырыгыз! Хәерле юл! Кастилиядән илче булып янә миңа килерсезме!

Карадәрвиш. Иншалла!

Тимер. Озатыгыз! Хуш, Гайшә бикә! Синең минем яннан китеп торуың мәгъкуль. Син янымда чакта күңелем тыныч булмас. Ә минем эшлисе эшләрем бихисап! Минем әле ләшкәрем илә дингез кырыендагы Гранада, Кастилия җирләренә атым Акбәкәлемнең тоякларын бастырасым бар.

Карадәрвиш. Хушча калыгыз барчагыз да.

Тимер. Китмә, дисәм дә китәрсең, кал дисәм дә калмассың. Хуш, шәех Исрафил хәзрәтләре.

Карадәрвиш. Күрешергә насыйп әйләсен.

Тимер *(хезмәтчеләренә)*. Хәлиф белән корольгә һәдияләрне кызганмагыз!

*Күгелташ, Карадәрвиш, Сакчы, Гайшә бикә, Җария һәм тагын берничә хатын-кыз китә. Тимер монсулана, аның күңеле тула, ахрысы. Ул ачынып хәнҗәрен суырып чыгара да, кемгә кадарга белмәстән, мендәргә кадый. Мендәр йоны белән бүлмә тула.*

Тимер. Хуш, Гайшәм бикәм!.. Үз кулларым белән ятларга тапшырдым *(Шашкан кыяфәттә йөренә.)* Кичер мине, Гайшәм бикәм! Отылдың, Аксак Тимер, оттырдың, Аксак Тимер! Күгелта-аш!

Күгелташ *(атылып керә)*. Әмирем!

Тимер. Гаскәрне тупла! Фарсы иленә, шаһиншаһ Әлмансур өстенә яу чыгабыз!

Күгелташ. Гаскәр тупланган! Әмерең, әмирем! Бәрабаннар! Карнайлар!

*Бәрабан, карнай тавышлары дөньяны каплап китә.*

## Шаһ Мансур белән сугыш

*Аксак Тимер гаскәрләре ком чүле буйлап бара.*

*Гаскәрләре таулар арасыннан бара. Текә кыялар, төпсез упкыннар сугышчыларны сагалап тора. Кайберләрен таудан тәгәрәгән ташлар баса, кайберләре упкынга оча.*

*Бара торган бердән-бер юлны таудан ишелеп төшкән кыя каплый. Кешеләр атларны, дөяләрне ян-якларына такталар бәйләп, арканнар белән кыялардан аска төшерәләр. Бөтен гаскәрне арканнар белән аска төшереп бетерәләр.*

*Ниһаять, гаскәрләр киң далага килеп чыгалар. Атларны утлауга җибәреп, кешеләр чатыр кора башлый.*

*Шираз каласының манзарасы. Мәһабәт манаралар, кәрвансарайлар.*

*Шаһ сарае. Бакчада балалар уйный. Шаһзадә Сөрәйя сеңелләренә карап куана. Шаһбикә таганда йокымсырый. Агач күләгәсендә шаһ Мансур китап укый.*

*Шулчак каравыл манарасындагы күзәтче бактанның шөбһәле авазы яңгырады.*

Бактан. Карагыз, анда офык ягында болытмы ул, әллә томанмы?

Икенче. Йа Аллаһым! Бу дошман явы булса кирәк!

Бактан. Гауга быргысын кычкырт! Гауга бәрабанын как!

*Шаһ бакчасы. Атылып хәбәрче керә.*

Әлмансур. Ни булды?

Хәбәрче. Харап булдык, шаһым, дошман явы капка төбендә!

Әлмансур. Дүрт якка дүрт чапкын юллагыз! Барысы да коралланып монда килсен!

Хәбәрче. Каладагы барча яугирләрне дә чакырыгыз! Кылыч тота алган һәммә кеше ватанын сакларга атылсын!

*Урамнар буйлап чапкыннар чабыша.*

—Сугыш! Коралланыгыз, дошман явы капка төбендә!

*Аксак Тимер станы. Яугирләр арасында сугыш алдында була торган киеренкелек.*

Тимер. Бер кая да китә алмас ул шаһиншаһ Әлмансур! Матур гына итеп

капкаларны ачар, безне калага кертер һәм казнасындагы бөтен хәзинәсен үзе чыгарып безнең алга салыр, иншалла!

*Бәрабаннар дөпелди, кәрнай, сорнайлар каты тавыш белән уйный.*

*Каравыл манарасыннан Әлмансур Тимер гаскәрләренен хәрәкәтен күзәтә. Шәһәр тулысы белән дошман гаскәре белән уратып алынган. Башка өлкәләрдәге гаскәрләр Ширазга ярдәмгә килә алмаячак. Эш мөшкел.*

—Ант бозучы Аксак Тимер!—*дип кычыра Әлмансур.*

*Берничә ярдәмчесе белән Күгелташ шәһәр диварларына якын килә.*

К ү г е л т а ш. Һе-ей, шаһиншаһ җәнаблары! Әмир Тимер килде! Ач капкаларын, күтәр пәрдәләрен! Җиңелмәс баһадир әмир Тимер килде. Без дүрт йөз мең гаскәр белән килдек.

Ә л м а н с у р. Һе-ей, Күгелташ! Әмиренә кайтып әйт, бездә дә бар ул дүрт йөз мең гаскәр. Ләкин шулар өстенә бездә сугыш филләре бар. Һәр фил өстендә ун кеше сыярлык мөнбәр бар. Анда утырган укчыларымның уклары сезнең күкрәкләргә батар, филләрем барыгызны таптап сытар. Соңгы тамчы каныбызга кадәр орышачакбыз.

К ү г е л т а ш. Карарбыз, кем кемне сытар!

*Атын борып, Күгелташ чатырлар ягына чаптырып китте. Аның артыннан сызгырып, үртәү сүзләре кычкырып калдылар.*

*Тимер илчеләрнең кайтканын көтә. Күгелташ үзенең егетләре белән Тимер каршысында туктый.*

К ү г е л т а ш. Тәкъсирем, алар орышачаклар!

Т и м е р. Бәрабаннар!

*Һәр дөянең ике ягына да олы сугыш бәрабаннары асканнар. Бәрабан аскан дөяләрнең саны унау. Бәрабанчылар үҗәт рәвештә тукмаклары белән бәрабаннарга оралар.*

*Ат өстендә ун карнайчы карнайга өрә. Ун ат өстендәге кәрнайлар юан тавыш белән, сорнайлар әче тавыш белән яу маршын уйный.*

*Тимернең атлы гаскәре һөҗүмгә китте. Тояк тавышлары, ат кешнәгән авазлар, дөбердәү, шартлау, әйтерсән лә, дөнья бетә, әйтерсен лә җир җимерелә.*

*Эчендә шом юшкыны булса да, шаһ Әлмансурның чырае тыныч күренә. Аның карашы дошман явында.*

*Тимер гаскәрләре якынаеп килә. Әлмансур кулы белән өч тапкыр изи.*

*Капкалар ачыла, ачык капкалардан сугыш филләре борыннары белән быргы авазлары чыгарып, атылып чыкты, филләрнең аркаларында такталардан корылган саклагыч манаралар, алар эчендә унар укчы урнашкан.*

*Дошманның атлы гаскәре белән фил гаскәре йөзгә йөз каршы килә. Фил өстендәге укчылар атлылар өстенә ук яудыра, күп кенә атлылар, атлар күкрәкләренә ук алып, егылалар. Алар ат тояклары, фил аяклары астында калып, тәмам һәлак була. Филләрдән куркып, атлар шашардай булып кешни, кая барырга белми. Филләр азау тешләрен ат корсагына батыра, кешеләрне чөеп-чөеп ыргыта. Йөрәкләренә курку төшкән атлар, жайдаклар кире борылып чаба, ләкин алар һөҗүм итеп килүче башка атлыларга килеп бәрелә, арттан филләр таптап килә. Дошман гаскәре күп мәетләр, яралыларын калдырып станына кире кайтып китә. Филләр дә кире борыла.*

*Диварлар, манаралардан карап торучы Шираз кешеләре бәйрәм итә, кычкыра, биләр, җырлыйлар.*

*Тимер ыстаны. Хәрби киңәшмә. Анда әмир Тимер, башкарачы Күгелташ, меңбашлары Миран белән Сөләйман һәм башка хәрбиләр катнаша.*

Т и м е р. Нишләргә? Атлар филләргә каршы барырга курка. Сүзегезне көтәм, яугирләрем!

К ү г е л т а ш. Төнлә филләр киләсе юлларга очлы ягын өскә каратып тимер калаклар куярга.

Т и м е р. Шымчылар сизәр.

М и р а н. Сумала яки җир мае агызып, филләр якынаюга ут төртергә.

Т и м е р. Үзебезнең атлар уттан куркыр.

С ө л ә й м а н. Иң җегәрле йөз дөя сайлап алырга кирәк...

*Тимер ыстанында халык мәш килә. Балта осталары озын корыкларны очлый. Ул корыкларны һәр дөянең янягына ныгыталар. Баш-башларына коры чыбык, салам бәйлиләр. Коры чыбык белән салам өстенә тиз яна торган сыекча сибәләр.*

*Әлмансур ыстаны. Тимернең чираттагы һөҗүмен кайтарырга әзерлек бара. Филләрнең өзелгән каешларын, кыйшайган манараларын рәтлиләр.*

*Тимер ыстанында сугышка әзер дөяләрне тезгәннәр.*

Ә л м а н с у р *(көлемсери).* Нәрсә эшли ала ул Аксак Тимер минем филләремә каршы дөя көтүе чыгарып?

*Капка алдында сугыш филләре яуга әзер тора.*

*Күгелташ яман аваз чыгарып, бәрабанчыларга кычкыра. Бәрабаннар дөпелди. Дөяләр ташкыны чабып китә.*

*Әлмансурнын сигналы. Филләр дөяләргә каршы чаба.*

*Филләр дошман явын сытып китте дигәндә генә, дөячеләр саламга ут ташлый. Бер юлы йөз ялкын гөлтләп кабына. Барган шәпкә дөяләр утлы корыкларын филләр корсагына батыра. Ялкын филләрне куркыта. Корсакларына утлы корык кергән филләр аркаларындагы кешеләрне сытып, җиргә авалар. Калган филләр нишләргә белмичә артка борылып чаба, алар үз артларыннан килгән башка филләрне бәреп, үз кешеләрен таптап, шәһәр тарафына ыргыйлар.*

*Күгелташның кул ишарәсеннән соң, ярсыган атларга юл ачыла. Тимернең атлы гаскәре кыргый авазлар чыгарып, җан-фәрманга шәһәр ягына томырыла. Атлылар юлында фил гәүдәләре, дөя үләксәләре, кеше мәетләре аунап кала. Тимер яугирләре качып баручыларны рәхимсез рәвештә кыра, чаба, турый. Бичаралар шәһәр капкасына кереп качмак була, ләкин алар дошман кылычыннан, ат тояклары, дөя аяклары астында изелеп калалар.*

Ә л м а н с у р *(куркынган).* Капкаларны ябарга-а! Капкала-ар!

*Капкаларны ябарга өлгерми калалар, качучылар артыннан атлылар да капкага ыргыла, тимернекеләр шәһәргә бәреп керә. Урам сугышлары башлана.*

*Шаһ Әлмансур ике кылыч белән үзен үзе белештерми орыша. Көчләр тигез түгел, ул ике ук, биш-алты кылыч ярасы алып, җиргә егыла. Дошман яугире анын очлымсыз калган шәрә башына кылыч ора.*

*Шираз капкасы төбендә каты сугыш бара.*

*Шәһәр эчендә үтереш, талаш, кырыш дәвам итә.*

*Яу кыры. Анда мәет җыючылар тын гына эшли. Тимернең бик күп яугирләре дошман мәетләренең башларын кисеп, җыялар да арбаларга салып каядыр алып китәләр. Мәйдандагы әсирләрнең дә башлары чабыла. Аларнын башларын да арбаларга төяп алып китәләр. Киселгән һәр башны зур казаннарга салып пешерәләр, аннан соң баш тиресен тунап, ап-ак баш сөякләрен тау итеп өя баралар иде.*

С а к ч ы. Дәһшәтле, кодрәтле Аксак Тимернең дүрт йөз мең кешелек гаскәре Шираз каласына ябырылды. Бу — җиде икълимнең бишенчесен яулау иде. Бу Тимернең иң олы җинүләренең берсе булды. Шаһ Әлмансур шәһәр язмышын рәхимсез дошман кулына тапшырды. Җинүчеләр капчыклап-капчыклап саф Һиндстан алтынын, хисапсыз күп алмазлар, әйдәүчеләре белән меңләп сугыш филе һәм бихисап гүзәлләрне алып, ватаннарына кайтып китте. Иң кыйммәтлесе, иң кадерлесе, әсирләр арасында шаһиншаһның сөекле кызы, гүзәл шаһзадә Сөрәйя иде.

*Байлык төягән дөяләр, атлар, арбалар Сәмаркандка таба йөри. Күгелташ артка, Шираз тарафына борылып карады. Гүзәл шәһәрдән хәрабәләр генә калган иде. Шул хәрабәләр янында җитмеш мең кешенең баш сөягеннән корылган манара ап-ак булып җемелдәп, кояшта чагыла. Бу имәнгеч күренештән Күгелташның тәне чымырдап китте.*

*Чатыр корулы фил өстендә кайгылы шаһзадә Сөрәйя тирбәлә.*

## Шаһзадә бикәч Сөрәйянең хәле

*Сәмарканд.*

*Бөек җиңүче әмир Тамерлан бөек тантана белән башкалага якыная. Барча халык җиңүчеләрне каршы алырга чыккан. Бәйрәм. Җырлыйлар, биләр. Урамның бер ягыннан икенчесенә тарттырылган арканнарда җанбазлар осталыкларын күрсәтәләр.*

*Алым саен куй кыздырыла, адым саен казаннарда пылау әзерләнә.*

Тавышлар.
—Машалла, Тимер бәк! Машалла, яугирләр!

*Ханәкәдә кайгыга баткан шаһиншаһ Әлмансурның сөекле кызы шаһзадә бикәч Сөрәйя утыра. Аның янында ахирәтләре бөтерелә.*

Беренче ахирәт. Сөрәйя тутай бикәч! Ник син шулай моңлы?

Икенче ахирәт. Ник син шулай кайгы йотасың?

Беренче. Тирә-якта нинди гүзәллек.

Икенче. Әйләнәндә матур күбәләкләр.

Беренче. Аллы-гөлле чәчкәләр.

Икенче. Сирин сәхра, ширин былбыллар.

Беренче. Сайрар кошлар, хуш бөрки бадәм, сандал агачлары.

Икенче. Байлык-муллык белән тулы бакчалары.

Беренче. Өстең тулы затлы кием, алтын укадан, бизәнгәнең алмазташлар, энҗе-мәрҗәннәр.

Сөрәйя. Күрмим мин ул матурлыкны, күрми күзем хозурлыкны. Тамагымнан үтми тәгам-ризыклар. Нигә миңа затлы кием, нигә миңа алмазташлар? Читлектәге кош кебек мин. Сайрар кошны затлы читлеккә ябып, аны бәхетле иткән кеше бармы? Мин сагынам ватанымны, Ширазымны... юксынам атам-анамны, кызганамын бичара бабамны... *(Күңеле тула.)*

Икенче. Бәгъре өзгәләнә бичараның...

Беренче. Фарсы хакиме шаһиншаһның иң сөекле кызы булып дөньяга кил дә, колиһә булып ят җирләрдә каңгыр, имеш.

Икенче. Хатын-кызның тәкъдиредер. Бәргәләнмә, Сөрәйя бәгим. Өлешеңә тигән көмешең. Язмышыңа буйсын!

Беренче. Дикъкать итмә, бәгим, аның сафсатасына.

Сөрәйя. Минем атам Шираз шаһиншаһы Шаһ-Мансур, анам исә Баһдад шаһзадәсе Җәмилә иде, минем никахланмыш җегетем атаклы шагыйрь Шәмсетдин Хафизның туруны Шәһрияр иде. *(Җылый.)* Аксак Тимер Ширазыбызны ничә тапкыр килеп җимерде. Соңгысында ул атам-анамны, бөтен сарай әһелләрен кылычтан узгарды. Шәһриярым яу кырында яраланган, диделәр. Ә мине Аксак Тимер кол итеп Сәмаркандка алып кайтты.

Икенче. Сөрәйя бәгим, әмиребез турында алай хөрмәтсез сөйләмә.

Беренче. Тсс! Монда ханбикәләр килә.

Сөрәйя. Нәселемне кырган, башкаламны җимереп талаган, ярты халкымны кылычтан узгарган бәдбәхетне мин ничек дип атарга тиеш?

*Бер-бер артлы хатыннар керә. Иң алда әмир Тимернең беренче хатыны Мәликә бикә, аннан икенче хатыны Тукәл бикә, Сарана бикә һәм аларның җарияләре күренә.*

Мәликә. Кем ул бәдбәхет, кызым? *(Шомлы тынлык.)* Кем ул? Әмиребез Тарагай углы Тимер турында түгелдер бит?

Тукәл. Дәшмәү—ризалык галәмәте.

Сарана. Мин дәшмим.

Мәликә. Дәшмәү—артык горурлык галәмәте.

Беренче. Олуг ханбикәбез, Сөрәйя бикәч менә бу тамырга абынып китте дә егыла язды.

Мәликә. Тамырның ни гонаһасы? Аяк астына карап йөреш кирәк!

Тукәл. Тамырга абындым, дип кан тамырын кисмәссең бит?

Сөрәйя. Мин тамырга абынмадым вә дәхи кан тамырымны кисәргә җыенмыйм да.

Мәликә. Син нинди аваз илә гәп

орасың, кызыйчык? Каршыңда...

Т ү к ә л. Сиңа монда Шираз җире түгел! Бу—Сәмәрканд!

М ә л и к ә. Хорасанны, Гүргәнечне җир белән тигезләп, ясмык чәчтергән бөек яугир...

Т ү к ә л. Алтын Урданы, Ак Урданы, Күк Урданы тетрәтеп торучы түрә...

С а р а н а. Шулай шул.

М ә л и к ә. Каф таулары артындагы илләрне буйсындырган...

Т ү к ә л. Иранны аяк астына салган Тарагай углы әмир Тимернең кече хатыны, Чыңгыз канлы Тарма Ширин ханның сөекле кызы Түкәл бикә...

М ә л и к ә. Чыңгыз канлы Казган ханның сөекле кызы, Тарагай углы әмир Тимернең олы хатыны Мәликә бикә басып торганын онытма, кызыйчык.

С а р а н а. Мукшы бәгенең кызы Сарана.

С ө р ә й я *(аларга охшатып).* Алдыгызда Фарсының Шираз каласындагы шаһиншаһ Мансурның сөекле кызы, Хорасанны, Гүргәнечне, Урдаларны аяк астына салган Тарагай углы әмир Тимернең иң яшь, иң гүзәл, иң кече хатыны Сөрәйя бикәч басып торганын онытмавыгызны үтенәм!

М ә л и к ә б и к ә. Сөбханалла!

Т ү к ә л. Машалла!

С а р а н а. Шулай шул.

М ә л и к ә. Фарсының шаһиншаһлары кызларына тәрбия биргән булсалар икән.

С ө р ә й я. Тәрбиялеләр каршысында без тәрбияле, ханым-бикә.

М ә л и к ә. Озакламый монда әмиреңкиләчәк. *(Кәнизәкләргә.)* Зөфаф кичәсендә киявен кабул итәргә ул әзерме?

Б е р е н ч е. Әзер, ханым-бикә. Бикәч юындырылган, тәне корытылган, җофар мае белән уылган, хушбуйлар сибелгән.

М ә л и к ә. Боерыгыз, әмирләрнең әмире шаһ Тимер.

*Яраннары белән Аксак Тимер керә. Ике кәнизәк Сөрәйяне әмир каршысында тезләндерә. Сөрәйя теләр-теләмәс кенә баш ия. Хатын-кызлар бер якка, ирләр икенче якка китеп югала.*

Т и м е р. Мәрхабә, хуш килдең шаһ кызы Сөрәйя туташ.

С ө р ә й я. Мин туташ түгел!

Т и м е р. Ха! Үзенең кыз булмавы белән мактанганнарны беренче тапкыр күрәм.

С ө р ә й я. Мин кызчык түгел! Мин башканың никахындагы хатын!

Т и м е р. Нинди никах? Нинди башка? Әйе, ишеткән идем, син шагыйрьләр шагыйре Хафиз Ширазиның торыны белән ярәшелгән, дигәннәр иде.

С ө р ә й я. Никахлашкан!

Т и м е р. Ярый, синеңчә булсын! Син аның никахындагы хатын, ди. Ләкин сугыш-яу шартларында җиңелгән, һәлак булган патшаларның, яугирләрнең хатыны үзеннән-үзе талаклы була. Ягъни, ганимәт хокукында, үлҗә хокукындагы хатынга әверелә. Аннан соң синең никахлы ирең яуда һәлак булган, диләр.

С ө р ә й я. Ялган! Ул хәбәрсез югалган.

Т и м е р. Ярый, хуш! Хәбәрсез югалган икән, без аннан хәбәр алырбыз. Хәбәр дә, талак та алырбыз.

С ө р ә й я. Шәһриярым исән! Күңелем сизә, ул исән.

Т и м е р. Шуннан ни үзгәрә, бикәч?

С ө р ә й я. Шуннан шул, син миңа өйләнә алмыйсың. Чөнки Шәһрияр беркайчан да миңа талак әйтмәячәк!

Т и м е р. Кызым! Мин инде яшь кызлар белән сүз куертып утырудан узган. Синең хакимең, булачак ирең белән шушылай дорфа сөйләшкәненне мин уен буларак кына кабул итәм. Синең нәфис сының, гүзәл чыраең, укымышлы булуың, шулар белән бергә синең нык холыклы, батыр булуыңа мин сокланам. Шуңа күрә, синең сүзләреңә мин ачуланмыйм. Минем мондый сүзләрне ишеткәнем шактый күп булды. Торабара бөтенесе дә тәкъдиренә буйсына. Һәм андыйлар мине хәтта ярата-сөя башлыйлар.

С ө р ә й я. Ә мин уйнамыйм! Мин уйнамыйм, Тарагай углы әмир шаһ Тимер! Мин ихластан сөйлим. Мин дорфа түгел, әмир. Мин күңелемдәге шулай житкерергә тырышам. Син, хакимем, булачак ирем, Тарагай углы шаһ Тимер, син күпме шаһлыкларны, күпме ханлыкларны алган, күпме кызларны үзенә хатын иткән әмир. Син аңларга тиеш минем хәлемне. Минем сөекле атам, сөекле анам, туганнарымның барысы да һәлак булды. Шаһиншаһның казнасы таланган, халкы кырылган, нинди бай-

гүзәл Шираз каласын син җир белән тигезләден, шаһның бердән-бер кызы исән калган. Аның никахлы ире бар. Әгәр дә мин Шәһриярымның исән икәнен сизенмәсәм, ике дә уйлап тормастан бәгъремә хәнҗәр батырыр идем. Мин сине түгел, Шәһриярымны көтәм. Син мине талап ала аласың, син минем колларым-аякларымны чатын-чатка аерып ташлый аласың, ләкин мин сиңа үз ихтыярым белән бирелмәячәкмен, сине инкарь иткән, сине җене белән сөймәгән, сиңа чиксез нәфрәтле булган шушы зәгыйфь бикәчне көч белән, ризасызлык белән алырга синең вөҗданың җитәрме!

Т и м е р. Бәгъреңә хәнҗәр батыру "катиле нәфес" дип атала, кызчыгым. Коръән Аллаһу Тәгалә биргән җанны үз кулың белән чыгаруга каршы. Андыйларны хәтта зиратка да җирләмиләр, читкә, кяферләр кебек, каракларны каргаган кебек догасыз күмәләр, җирләмиләр, таптап күмәләр.

С ө р ә й я *(әче итеп көлә).* Коръән турында сөйләп торган көне! Тәһарәтсез авызың белән Аллаһның китабы Коръән турында фәлсәфә куертырга синең хакың юк, җәллад. Кяферләр белән сугышыр өчен Ислам байрагын тотып чыккан булсаң, мин сине аңлар идем, син Коръән исеме белән мөселманнарны кырып, җәннәткә кермәк телимсең? *(Әче көлү.)* Ха-ха-ха... *(Көлүен кинәт туктатып, җитди).* Суфыйларның сафсатасы белән чагыштырганда синең көфер сүзен чүп кенә, Тимерлән! Син тел тегермәне корырга яратасың, Тимерлән! Кичер мине, зинһар, мин синең бәдәнеңне кимчелегенә кагылырга тиеш түгел идем, тиеш түгел идем... Ярсыйм, үкерәм, мин акылдан язамдыр... кичер мине... мин сине аксак килеш тә сөяр идем, мин сине чулак килеш тә яратыр идем, әгәр дә син шулай кансыз булмасаң. Синең бит җаның аксак, синең рухың чулак, әмирем! *(Тимернең сабыр халәте үзгәрә. Ул шушы киребеткән кызның мантыйгына сокланa да, аңа җавап табуның ничек кыен икәнен дә төшенә бара сыман. Ул батып бара торган кеше тотынырга салам эзләгәндәй, як-ягына каранып алды. Ни әйтергә сүз табалмагач, кызны туктарыга теләп бары тик: Сөрәйя, Сөрәйя, дип кабатлый.)* Син бит килешү антын бозып, атамны алдап, хыянәтчел рәвештә бәреп кереп кенә аның гаскәрен җиңә алдың. Башка калаларны, башка илләрне чәнчә бармагыңны селкетеп кенә алырга күнеккән кешене Шираз шаһиншаһы Әлмансур еллар буе кыерлады, еллар буе син безнең илдән шәҗәрәңне кушучлап тотып кайтып киттең. Без бит сиңа бәреп кермәдек, син безнең капка төбенә килеп, сөяк көткән алама эттәй ялманып кангырып йөрдең. Мәрхүм атам шаһиншаһ Әлмансур шушы җиңүләренә күрә "Әлмансур Зафәри" кушаматын яулаган баһадир. *(Сөрәйя шундый гайрәт белән сөйли, ул берни дә курыкмый, көчләүдән дә, үтерүдән дә, җәзалардан да курыкмас дәрәҗәдә шашкын ки, бу мохиттә ул—хуҗабикә, ул—җиңүче кыяфәтендә. Дәһшәтле әмир Аксак Тимер каушап калганмы, әллә ул: бу бәхетсез бала үлеме алдыннан соңгы сүзен әйтеп бетерсен, дипме гамәлсез, хәрәкәтсез калган. Бу кечкенә кызчыкның нинди куәткә ия икәненә ул шаккатканмы? Әллә бу кызны нинди җәзага тартырга кирәклеге турында баш ватамы? Сөрәйя инде үзен-үзе белештермәс дәрәҗәгә җиткән.)* Соңгысында да син атамны җиңә алмый идең, җиңә алмый идең. Чөнки атам ике арадагы солых булганына күрә, ваемсыз кала бирде, атам сиңа дөнья бәһасе торган маллар, затлы киемнәр, хәзинә бүләк итте. Синең белән орышмас өчен ул казнасындагы бөтен малын бирердәй иде, син антны боздың, бүләкләрне алдың, хаиннәрчә посып кына, игълансыз гына, куркак шакал кебек килеп бастың да, атам шаһиншаһ гаскәрен җыеп өлгерә алмый калды. Шулай да син тиз генә Ширазны ала алмадың. Ярты гаскәрең кырылып бетә язды. Син каушап калдың. Атам арткы капкадан чыгып, нибары ике йөз кешесе белән синең ике йөз меңлек гаскәреңнең артына төште, рәхәтләнеп туралдылар безнекеләр синең нәҗесләреңне, син артыңа борылганда, синең янында биш йөз генә яраның калган иде, калганнары шәһәр капкасына ябырыла иде. Шунда атам, куркусыз атам, каһарман атам үзенең кешеләре белән синең янга бәреп керде, атам сиңа өч тапкыр кылыч белән чапты, ләкин ике яраның гәүдәләре белән сине каплап өлгерде. Атам янә һөҗүм итте, син агарган, каушаган идең, сине курку белмәс, үлемнән

курыкмас жан, дип данлыйлар, син атамнан курка идең, атам сине аркылы чаба иде, насыйп булмады. Син күреп тордың, синең мәркәзеңә бәреп керә алган баһадир Әлмансур һаман орышты, һаман орышты, аның күкрәгенә ике ук кадалды, ботына сөңге батты, ләкин ул якын килгәннәрнең жанын кыя торды. Ул тагын синең янга бәреп керде, ләкин аты сөрлегеп, ул ияреннән егылды, синекеләр саранчадай аны урап алдылар. Атам жан ачуы белән кычкырды: мин Әлмансур шаһиншаһ, мине әмир Тимер жәнаплары янына алып барыгыз, дисә дә син чабарга куштың. Кабих жаннарың аның шәрә калган башына ун кылыч чаптылар. Син аны үтерергә куштың. Чөнки син атамның исән калуыннан курка идең. Шатлан, кабихжан, син безне жиңдең. Ләкин мөслимнәр канын агызганың өчен сиңа кыяматтә жавап бирергә туры килер. Син ике сүзнең берендә: мин Коръән кушканча гамәл кылам, мин Пәйгамәр юлыннан барам, дисең. Син атлаган саен Коръән ачтырып, үз явызлыкларыңа аклану эзлисең. Ачтыр Коръәненне, әмир Тимер. Син надан, син укый да, яза да белмисең, синең укырга, язарга өйрәнергә вакытың булмады, чөнки син гомерең буе жаннар кыйдың, таладың, бастың, кырдың, адәм башларыннан, мөселман баш сөякләреннән манаралар кордырдың. Синең тарихта калдырган һәйкәлләрең шулар булыр. Бисмилләһ ир рахмән ир рахим! *(Ян кырда махсус жайланмада торган Коръәне алып, Тимергә суза.)* Теләсә кайсы сәхифәсен ачыгыз, тәксир. Коръән ни ди икән сезнең жәнапларыгыз хаккында? Ачыгыз! *(Тимер Коръәнне ала, ача, ачкан килеш Сөрәйягә суза. Сөрәйя башта укый, аннан китапны ябып, яттан сөйли.)* Коръәни Кәримнең тугызынчы, ягъни Тәүбә сүрәсенең дүртенче аяте: килешүне азагынача бозмагыз! Аллаһ гаделсезлек эшләүдән сакланганнарны сөя! *(Тагын бер бит ача.)* Коръәни Кәримнең уналтынчы сүрәсе, туксан икенче аяте: күзәнәкләрен тыгыз итеп бәйләгән бәйләвен сүтеп ташлаган хатын хәлендә калмагыз. Бер халык икенчесеннән өстен булырга мөмкин. Ләкин ул өстен халык өстен булмаганын ялган ант биреп кыерсытмасын. Аллаһ сезне шулай сынап бага! Син сыналдың инде, Аксак Тимер, синең урының тәмугъта!

Т и м е р *(кинәт ярсый, кылычын суырып чыгара, Сөрәйягә кизәнә).* Токымыңны ор-раем!

С ө р ә й я *(урыныннан һич кузгалмыйча, кычкырып көлеп Тимернең кыланмышларына бага).* Син мине урталай чапсаң, миңа яхшылык кына кылган булырсың. Минем һәлак буласым килә. Изге орышта шәһид китәсем килә минем! Чап син мине, Тимер! Чап! Урталай яр! Минем йөрәгем, үпкәләрем, бавырым урталайга аерылсын, аннан кайнар кара кан аксын, син алырга теләгән женсемә син кергәнче кылычың керсен! *(Тимер кылычын төшерә, ул ихтыярсыз.)* Дөреслекне күтәрә алмыйсың, Тамерлан. Мин бит сиңа чүп кенә. Мин яклаучысыз бичара бикәч. Син мине тураклый аласың, ләкин син мине жиңә алмыйсың. Синдә куәтле ир рухы, миндә гайрәтле хатын рухы яралган. Алар тигез! Минем беркемем юк, минем бер нием юк. Ярлы янудан курыкмас, ди аталарыбыз. Бәс, мин сиңа тугрысын чыраеңа чәпәп әйтәмен. Мин кулың белән изә-изә миннән камыр ясый торган зат түгел. Мин үзем тимерне кулым белән изеп, камыр ясый торган зат! *(Ул тынып кала, хәлсезләнә. Тимер дә каушаган, кылычын кынына тыгып куя, сабыр. Озак тынлык.)*

Т и м е р. Сөрәйя бикәч, син мине кире чыкмас тарлавыкка ябып куйдың. Мин хәзер шул тарлавыктан чыгу жаен табарга тиеш. Сине көч белән алырга яки сине иреккә жибәрергә яки сине урталай чабарга. Мин сине иреккә жибәрер өчен Шираз тикле Шираздан монда алып кайтмадым. Сине иреккәаткару ул Тимернең йолаларына туры килми. Чөнки монда кергән хатын-кыз кире чыга алмый, аларның барысы да минем хатыным яки харам хатыным булачак. Мин сине урталай чаба алам, ләкин бүген түгел. Шулай булгач, бер генә юл кала, син минем хатыным яки жариям булырга тиеш. Ләкин мин сиңа иң кулай юлны күрсәтәм, син минем иң сөекле никахлы хатыным булырсың!

С ө р ә й я. Атамны чабып, анамны бугазлаган кешенең юрганы астында мин ничек ятармын икән, бөек әмир Тимер? Син бит хатыннарыңның юрган астында кайнар булуын телисеңдер, мин сиңа ничек кайнар булыйм, мин сине

ничек кочаклыйм, мин сине ничек үбим? Мин бит синнән жирәнәм! Курыкмыйм, жирәнәм мин синнән жирән сакаллы әмир. Син мәетне кочачаксын бит юрган астында. Син мәетләрне сөясенмени, шаһ Тимер?

Т и м е р. Канымны кыздырма, бикәч! Үзем Тимер булсам да, сенерләрем тимер түгел, алар бер шартлар. *(Кинәт кылычын чишеп ташлый, жөббәсен сала. Янаулы атлап Сөрәйягә таба килә, бикә икенче якка күчә. Тимер тәвәккәл атлый.)* Син, кызый, артыгын кыланасын. Мин сине ирексезләмәскә уйлаган идем. Хәзер барысы да үз урынына утырыр.

С ө р ә й я *(кинәт куеныннан хәнжәр чыгара).* Тагын бер атла, бәгыремдә шушы фарсы пычагы булыр. Син фарсы пычагынын ни икәнен яхшы беләсен. Ике ягы да үткен хәнжәр "Әжем пычагы" дип атала. Мин шушы әжем хәнжәрен йөрәгемә батырам да, син минем мәетемне көчләрсен. Сина мәет сөю хас! Синен турыда ишеткәнем бар иде. Имеш, Аксак Тимер яна жирләнгән чибәр кызларны каберләреннән казып алып шулар белән ләззәтләнә, дип.

Т и м е р. Бөһтан! Яла! Нахак сүз сөйләп, гөнаһасын кая куярсын?

С ө р ә й я *(көлә).* Ә син кая куярсын гөнаһларынны?

Т и м е р. Куй пычагынны! Яхшылап сөйләшик.

С ө р ә й я. Без сөйләштек бит инде, барысы да анлашылды.

Т и м е р. Теләгенне әйт.

С ө р ә й я. Мине ватаныма кайтарып куй.

Т и м е р. Һәй, кем бар анда! *(Ханбикәләр керә.)* Сезләр! Сөрәйя бикәчкә ин олы хөрмәт, ин олы хезмәт булсын! Башыннан бер бөртек чәче төшсә дә башыгыз белән жавап тотарсыз. Сөрәйя минем әчкәриемдә булсын. Аны әзерләгез! *(Китә. Әмир бикәләр керә.)*

М ә л и к ә б и к ә. Хуш килден, шаһиншаһзадә Сөрәйя бикәч.

Т ү к ә л. Мәрхаба, гүзәлбикә. Әмиребез ни сәбәпле сине аерым хөрмәткә куйды, бикәч?

М ә л и к ә. Гүзәл булгангадыр.

С ө р ә й я. Сез дә гүзәл.

Т ү к ә л. Акыллы булгангадыр.

С ө р ә й я. Сез дә ахмак түгел.

М ә л и к ә. Алайса, ни өчен?

С ө р ә й я. Чөнки мин анын турында ни уйласам, шуны әйттем.

Т ү к ә л. Ни диден?

С ө р ә й я. Аксак, чулак, денсез, кяфер, жанкыючы, тәмугъ кисәве, дидем.

М ә л и к ә. Ул сине кылыч белән чапмадымы?

С ө р ә й я. Күреп торасыз сана! Минем никахлы ирем бар. Минем әле аннан талак алганым юк. Мин әчкәригә кермәсмен!

М ә л и к ә. Каян килгән Алланын кашка тәкәсе! Керерсен! Син түгел башкалар да керде.

*Чапкын керә.*

М ә л и к ә. Ни бар, кем син, каян син чапкын?

С ө р ә й я. Ихласжан! Хәбәр бармы Шәхриярымнан?

Ч а п к ы н. Шаһзадә Сөрәйя бикә, синен никахлы ирен таулар арасында, алган жәрәхәтләреннән вафат булды. Аны мин үз кулларым белән жирләдем. Урыны жәннәттә булсын! *(Сөрәйягә яулык бирә.)*

М ә л и к ә. Иннә лилләһи вә иннә иләйһи рәжигун.

С ө р ә й я. Шәһриярым! Жаным минем, муенында минем яулыкны ахырынача саклап йөрткән. Хуш, бәхил бул, ярым, Шәһриярым.

Ч а п к ы н. Авыр туфрагы жинел булсын!

С ө р ә й я. Менә мин хәзер тол хатын! Хуш, бәхил бул, Ихласжан!

*Сөрәйя әчкәригә уза.*

Б е р е н ч е ж а р и я. Ханымбикәләр, сезләрне дастархан көтә.

К ү г е л т а ш *(ашыгып керә).* Ханым бикәләр, кичерегез, мин кисәтмичә генә. Әмир сарайда күренмәдеме?

М ә л и к ә. Сарайда ана ни калган, ул зөфаф кичәсе уздыра яна кәләш куенында.

К ү г е л т а ш. Йа Ходам! Кайда әмир?

М ә л и к ә. Әчкәридә.

К ү г е л т а ш. Харап булабыз бит.

М ә л и к ә. Ни булды, Күгелташ? Яу бармы?

К ү г е л т а ш. Яу булса куаныр идем, Маликә бикә. Мур килә!

М ә л и к ә. Мур килә? Әстәгъфирулла!

К ү г е л т а ш. Мур кыра җылкыларны, мур кыра куйларны, мур кыра дөяләрне, кешеләрне мур кыра.

М ә л и к ә. Качарга кирәк!

К ү г е л т а ш. Мурдан качып котылып буламыни, Мәликә бикә.

*Эчкәридә чырыйлап кычкырган хатын-кыз тавышы ишетелә. Бераздан Сөрәйяның гәүдәсен күтәреп, Тимер чыга, Сөрәйяның күкрәгендә хәнҗәр. Тимер гәүдәне унайлы урынга яткыза.*

Т ү к ә л. Син аны үтердең?.. Ул бит сиңа хыянәт итмәде, син аның җанын кыярга тиеш түгел идең.

С а р а н а. Мин берни дә күрмәдем.

Т и м е р. Ул үз хәнҗәрен бәгыренә батырды! Мин аны коткарып калалмадым.

Ч а п к ы н. Әйе, бу шаһзадә Сөрәйянең хәнҗәре. Сөйгәне Шәһриярның туй бүләге.

К ү г е л т а ш. Мур килә!

Ч а п к ы н. Бу—кылган гөнаһларыбызга күрә җибәрелгән җәза!

Х а т ы н н а р. Мур килә! Качыгыз, мур килә!

Ч а п к ы н. Аксак Тимер муры килә икълимгә! Аксак Тимер муры!

*Тимер явынын хәрәкәте. Бер офыктан икенчесенәчә атлы гаскәр, җәяүлеләр, дөя җайдаклары сузылган.*

## Король Һәнрих Өченченең тәхеткә утыруы

*Чыннан да, Койрыклы йолдыз узып киткән елда Кастилия короле сараенда бер зәгыйфь бала дөньяга килгән иде. Әтисе—король Хуан да, әнисе—королева да шул төнне вафат булды. "Чирләшкә Король" кушаматы алган Һәнрих сабый чактан ук сырхау булса да, зиһенле, үҗәт булып үсте. Чире аркасында аның дуслары да күп булмады. Сеньорлар үз балаларын Һәнрих белән уйнатмаска тырыштылар. Бичара сабый янында иң якын дусларын санарга бер кул бармаклары да артып кала иде. Чиркәү каршындагы мәктәптә укып, аннан пажлар мәктәбенә бирелгән берничә ятим баладан башка аның якын дуслары булмады. Ләкин үҗәт Һәнрих үзенең король углы—инфант, ягъни принц икәнен бер генә мизгелгә дә онытмады. Пажлар мәктәбендә укыганда да, университетта да тарихны, фәлсәфәне, патшалар турындагы китапларны ул су кебек эчә иде. Аның тырышлыклары бушка китмәде, ул, ниһаять, тәхеткә утыра алырлык шәхес икәнен исбат итте һәм король булды.*

*Кастилиянең башкаласы Толедо. Король сарае. Тәхетханә. Король Һәнрих белән канцлер Салазар.*

Һ ә н р и х *(озак кына ютәлләгәннән соң тын ала, башындагы таҗын, карышкысын идәнгә бәрә).* Король, имеш. Инаугурация уздырдылар, янәсе, Хуан углы Һәнрих Өченчене кануни король итеп тәхеткә күтәрделәр... Мин нинди король, дустым Салазар, мин нинди король? Минем турыда халык арасында, бигрәк тә сеньорлар, монахлар арасында ни сөйлиләр? *(Салазар таҗны алып, тузаннарын өрештергәләп, тәхет янындагы калкулыкка куя, еракка тәгәрәгән карышкыны сак кына алып, корольнең уң тарафына сөйи.)* "Чирләшкә король" минем исемем! Чирләшкә король озак тормас, аның урынына башка инфантны, ягъни варисны әзерләргә кирәк. Чирләшкә өйләнергә охшамаган, анда хатын-кызлар кайгысы юк, ул маврлар, басклар, яһүдләр белән күбрәк аралаша. Беләсеңме, мөселманнар, яһүдләр белән аралашканга, мине "еретик" дип атыйлар кайбер монахлар. Мин еретик түгел, мин чын христиан, ләкин башка диндәгеләр белән кешеләрчә мөнәсәбәттә булырга кирәк, дип уйлыйм. Арагон, Португалия, Кастилия, Леон, Валенсия, Кордова, хәтта Гранада—бөтенесе бер булып, бөек Испанияне тәшкил итәргә тиеш. Безнең корольләр үзара сугышып, бер-берсен талап ята. Маврлар җиде йөз ел безнең өстә тора. Ә инквизиция христианнарны кыра, яһүдләрне талый, маврларны үтерә. Яһүдләрне, маврларны, баскларны күпләп кырып, католик динен ныгытып булмый, дустым Сала-

зар. Халыкта нәфрәт уятып кына була. Маврлар, яһүдләр тагын да ныграк үрчи, тагын азау яра. Испания булсын дисәк, сеньорларның казнасы түгел, король казнасы бай булырга тиеш. Минем казнам буш. Сеньорлар бай, алар—король, мин король түгел. Узган атнаны кыяфәтемне үзгәртеп, мин шәһәрдә йөрдем. Һәр магнатның сараенда банкет. Кардинал Бардини сараендагысы иң бае, корольләр көнләшерлек мул табын. Мәҗлесләрдә шау-шу, акырыш-эчеш, кочыш, шулар арасында бер генә сүз: король чирләшкә, король малай гына әле, башка король кирәк! Корольнең казнасы буш, яшермичә кычкыралар. Нишлим, Салазар? Алар мине мыскыл итә!

С а л а з а р. Атагыз король Хуан епископларга, инквизиторларга азынырга юл куймады, ул яһүдләрне талауга, аларны күпләп үтерүгә дә каршы чыкты, әмма ул мәрхүм булгач, магнатлар да, епископлар ныграк азды.

Һ ә н р и х. Иң яманы, Салазар, шул: аларның барысы да католик дине исеменнән гамәл кыла. Католиклар исеменнән католик динен җимерергә алынган җинаятьчеләр алар, дустым. Бөек Инквизитор Бонифаций шул җинаятьләрне хуплый кебек. Аның урынында ниндидер тиле, комсыз, рәхимсез кеше утыра. Аңа маврның мөселман булуы нәфрәт чыганагы түгел, маврның бай булуы кирәк. Аңа яһүдләрнең башка дин тотуы фәлән дә тормый, аңа яһүдләрнең байлыгы кирәк.

С а л а з а р. Имештер, бу Бөек Инквизитор чын түгел, элеккегесенең игезәге икән ул. Чын түрәне үтергәннәрме, каядыр ябып куйганнармы, дип сөйли халык.

Һ ә н р и х. Имешләр күп, дустым Салазар. Минем атам Хуанны да мин туган көнне агулаганнар, дип сөйли халык. Мин Койрыклы йолдыз узып киткәндә туганмын. Шул төнне үк анам да кинәт өзелгән, баладан үлә. Мине яхшылап карамаганнар, сабый чагымнан ук мин үпкә чирле булганмын. Сәер хәлләр сарайда, Салазар. Имешләрнең кайсысы дөрес, кайсысы уйдырма, шуны гына белеп булмый.

С а л а з а р. Сеньорлар арасында һәр көн сугыш-сүеш.

Һ ә н р и х. Христиан христианны суя.

С а л а з а р. Граф Ниебла белән сеньор Понсе арасындагы сугышта өч йөз илле кеше һәлак булды. Граф Кабра белән граф Альфонсо үзара сугышканда, өч мең кеше үтерелгән. Толедода яһүдләр мәхәлләсендә яһүдләрне талап, өч менен кылычтан узгарганнар. Ересьта гаепләп, ике мең дүрт йөз кеше яндырылган.

Һ ә н р и х. Исусе Христосе! Кырылып бетә бит халык. Бу нинди афәт? Бу нинди галелсезлек!

С а л а з а р. Инквизиция тагын мең ярым кешегә аутодафе әзерли.

Һ ә н р и х. Кая бара дөнья?

С а л а з а р. Шулар өстенә, королем, Франция ягыннан басып кергән юлбасарлар илне талый. Гасконлылар, германнар, инглизләрдән торган әтрәкәләм, өер булып оешалар да, урман юлларында, тау тарлавыкларында гына түгел, хәтта шәһәрләрне, замокларны да талый, яндыра, кешеләрне кыра башлады. Аларның башында француз рыцаре Бертран Дюгеклен, инглиз башкисәре Ричард Ланкастерский тора. Аларны йөз мең флорин бәясенә Бонифаций белән Француз короле Тилемсә Карл Кастилиягә өстергән.

Һ ә н р и х. Йөз мең алтын флорин, дисеңме?

С а л а з а р. Йөз мең алтын флорин, королем.

Һ ә н р и х. Рәхимсез Бонифаций белән Җүләр Карлга шулкадәр акча түгү нигә кирәк, Салазар? Комсыз Бөек Инквизитор белән тумас борын акылдан язган Карл үзләре саранлык белән дан тота, аларның үзләренә кирәк алтын флориннар.

С а л а з а р. Бонифаций белән Тилемсә Карл юлбасарларга ул алтын флориннарны чыгарып тоттырмый, королем, бездән талап алынган маллар, акчалардан Папа белән Карлга бирелгән малның йөз мең флорины талаучыларга калачак.

Һ ә н р и х. Йа Аллам, йа Исусе Христосе, ни өчен барысы да Кастилиягә ябырыла? Ни өчен мин король булып утыргач кына бу афәтләр килә. Ул йөз мең флоринны алып калыр өчен юлбасарлар бездән миллион алтын флорин таларга тиеш булып чыга бит! Йа-а, дөнья-а, үләм мин бу тәхеттә. *(Җенләнә, тәхеттән төшеп, тәхетне типкали, өс*

*киемнәрен салып ыргыта.)* Нигә мин инфант булып тудым икән, нигә миңа атам мирас итеп шушы тәхетне калдырды икән! Суялар, кыралар, кая качыйм? Кемнән ярдәм сорыйм? Бүген, менә хәзер сеньорларның армандаросы булырга тора. Мин бу җыелышка әзер түгел, мин ни әйтим аларга? Аларның тәкъдимнәренә ничек каршы чыгыйм? Алар минем тарафыма борылып та карамаячак. Әйтерсең лә, тәхеттә король түгел, бер уенчык малай утыра.

## Илчеләр

*Салазар алгишек янында ниндидер ыгы-зыгы ишетеп, чыгу ишегенә юнәлә.*

С а л а з а р. Король хәзрәтләре!

Һ ә н р и х. Кем бар анда, магнатлар җыелышы башланырга тора, соңыннан килсеннәр.

С а л а з а р. Король хәзрәтләре, еракерактан илчеләр килгән. Алар Бөек Татар иленең падишасы әмир Тамерланнан! Илчеләрне король гадәттә өч көннән соң кабул итә торган иде.

Һ ә н р и х. Нигә кирәк ул церемонияләр, дустым? Вакыт уза тора. Хәзер үк керсеннәр. *(Салазар корольгә киенергә, өстен-башын рәтләргә булыша. Король тәвәккәлләп тажны башына кия, кулына карышкысын тота.)* Бөек Татар иленең падишасы әмир Тамерланнан илчеләре, дидеме? Кайда соң ул Бөек Татар иле?

С а л а з а р. Мажарстаннан ары, славяннардан да ары, кар илләреннән ары, Чипанго диңгезе буендагы ил, королем. Чынгыз, Батый илләре ул, королем. Дөньяның аргы читендәге ил ул Татар иле.

Һ ә н р и х. Бөек Тартария хакиме Тамерланның миндә ни йомышы булыр икән? Алар нинди телдә анлаша икән соң? Чакырыгыз телләр белүчене!

С а л а з а р. Королем, алар гарәпчә, татарча, фарсыча аңлаша. Бөек Мәвәраэннәһер, Сәмәрканд, Хорезм һәм Татар илләренең хакиме әмир Тамерланның бөек илчесе Исрафил хәзрәтләре!

*Тантаналы рәвештә илчеләр керә. Мөселман илчеләре киемендә Карадәрвиш, Сакчы, бер-ике хезмәтче күренә.*

С а л а з а р. Илчеләр, сез Кастилия короле Һәнри Өченче хозурында!

Һ ә н р и х. Хуш килдегез, илчеләр! *(Салазарга.)* Бу кыргый татарлар испанча аңламый булса кирәк! Шулай да "кыргый татарлар", "вәхши татарлар" дип мәгълүм бу халыкны кысык күзле, сирәк сакаллы, кәкре аяклы, дип әйтәләр иде. Болар кешегә охшаган, лабаса.

К а р а д ә р в и ш. Татарлар арасында сез әйткән кебекләр дә бар, тәкъсир, гомумән алганда, татарлар бик мәһабәт халык. Испаннардан ким түгел.

С а л а з а р. Иисусе Христосе, сез безнең телне каян шулай яхшы өйрәндегез?

К а р а д ә р в и ш. Минем уң кулым—Мостафа Гранадада туган, ул испанчаны, французчаны, итальянчаны, гарәпчәне, татарчаны, фарсычаны бик яхшы белә, королем. Жиде икълимнен бишесен яулаган бөек җиһангир әмир Тимер хәзрәтләре сезгә менә шушы хатны, килешү язуын һәм һәдияләрен озатып калды. *(Хезмәтчеләр берничә сандыкны тәхет янына куеп, артка чигә.)* Әмир Тимер җәнаплары Кастилия белән сәүдә итмәк тели, сездән нинди маллар безгә, бездән нинди маллар сезгә китерергә мөмкинлеге турында бик кызыксына.

Һ ә н р и х. Бу гаҗәеп бер матур гамәл, бөек илче Исрафил хәзрәтләре. Сөйләгез, илчеләр, кем ул әмир Тимер, аның гаскәре күпме, аның теләге нинди? Ихтимал, аның сәүдә, алыш-биреш теләгеннән тыш безгә карата башка бер ихтыяры бардыр.

К а р а д ә р в и ш. Бөек королем, бөек әмир Тимер сезләргә тагын бер һәдия юллады. Ул сезнең өйләнмәгән яшь король икәнегезне ишетеп, сезгә үзенең иң гүзәл җарияләренең берсен күндерде. *(Гайшә бикәне алып керәләр. Ул шәрыкча бай киенгән. Гайшә тез йөгенгән килеш кала бирә.)* Кабул кылып алыгызлар, король җәнаплары.

Һ ә н р и х. Иисусе Христосе! *(Ютәлләп ала).* Глориан дей! *(Гайшәне әйләнеп чыга.)* Талифа куми!

К а р а д ә р в и ш. Калык! Аягыңа бас, ди, кызым...

Һ ә н р и х. Талифа куми! *(Гайшә калка.)*

К а р а д ә р в и ш. Бөек королем, хозурыгызда Алтын Урданың бер олуг вилаятендәге Габдулла ханның кызы Гайшә бикә булыр бу кыз. Затлы нәсел, затлы кан. Атасы, кардәшләре яуда һәлак булгач, аны әмир Тимер үз хозурына алдырган иде. Бөек әмиребезнең изге теләге: сезнең илә дустанә мөнәсәбәтләрдә булу, бәс, шуна күрә, атаклы яугир Тамерлан үзенең ин кыйммәтле асылташын сезгә юллады.

Һ ә н р и х. Искиткеч асылташ, Салазар. Бөек илче Исрафил җәнаплары, шундый гүзәллекне исән-сау алып килеп житкергәнегез өчен чиксез рәхмәтләрем. Ләкин безнең католик дине йолалары аны мина хатын итеп алырга рөхсәт итми.

К а р а д ә р в и ш. Жариягез, хезмәтчегез, ястыкчыгыз итеп алыгыз, королем.

Һ ә н р и х. Хуш! Без уйлашырбыз әле бу турыда. Кунакбикәне урнаштырыгыз! *(Хатын-кызлар Гайшәне алып китә.)* Инде тел төбендә, астарлы сүзеннең астында ни ятканын безгә бәян ит, илчем!

К а р а д ә р в и ш. Мин ялгышмаганмын, Аллага шөкер! Мин ялгышмаганмын. Кастилия короле зиһенле зат икән!

Һ ә н р и х. Мин дә ялгышмадым шикелле. Синең сүзең әле төкәнмәгән.

К а р а д ә р в и ш. Дөрес, минем сүзем әле төкәнмәде. Бүгенге көнең синең тууына караганда да хәтәррәк. Чөнки Кастилия короленең казнасы буш. Казна хәзинәсен юлбасарлар гына талап бетерә алмый, казна хәзинәсен епископлар, хәерче монахлар, Бөек Инквизитор гына ашап бетерә алмый. Казнаны үз магнатларың талый. Алар талаган хәзинә һәр илнең короле, падишасы, әмиренең байлыгыннан да артык.

Һ ә н р и х. Иисусе Христосе! Син боларны каян беләсең, Тамерлан әмиренең илчесе? Син күрәзәчеме? Әллә син сихерчеме?

К а р а д ә р в и ш. Мин сихерче түгел. Синең бу канцлерың ышанычлы кешеме?

Һ ә н р и х. Патшалыгымда шул минем бердәнбер таянычым. Салазар!

К а р а д ә р в и ш. Салазар?

Һ ә н р и х. Дустым Салазар! Без аның белән пажлар мәктәбендә бергә укыдык.

К а р а д ә р в и ш *(Салазарга сокланып карап тора).* Салазар! Сөбханалла! Салазар, синең сул беләгеңдә көрән миңең бар! Дөресме?

С а л а з а р *(аптыраган, жинен сызганып).* Дөрес! Ә сез аны каян белдегез?

С а к ч ы. Тамерланның илчесе күрәзәче бит!

К а р а д ә р в и ш. Король җәнаплары, синең яхшы дустың бар, шөкер! *(Каранып ала)* Безне тынлап тормыйлармы? *(Салазар белән Сакчы ишекләрне тикшереп килә.)* Сарайда диварларның да колаклары бар, королем. *(Корольне бер кырга алып, яшертен, ярым пышылдап.)* Бөек Инквизитор Бонифаций урынында юлбасар Педро Бургос утыра!

Һ ә н р и х. Иисусе Христосе!

К а р а д ә р в и ш. Тсс! Чын Бонифацийны яшертен генә куып, ана тач охшаш каракны, башкисәрне утырттылар.

Һ ә н р и х. Баш китәрлек сүзләр сөйлисез сез, илче. Әгәр боларны башкаларга сөйләсән, сине инквизиторлар яндырып үтерәчәк. Сез боларны каян беләсез?

К а р а д ә р в и ш. Чөнки мин үзем чын Бонифаций!

Һ ә н р и х *(ютәлли башлый, Карадәрвиш ана дару каптыра, король тиз тынычлана).* Бу нинди дару?

К а р а д ә р в и ш. Тибет тауларыннан жыелган үлән—жәншән тамырының тузаны. Мә, ютәл кытыклый башлагач, шушыны иснә. *(Дару бирә.)*

Һ ә н р и х. Акыл житмәслек сүз сөйлисең син, илче! Мин синнән курка башладым. Син гади кеше генә түгел, син маг яки сихерче яки тылсымчы.

К а р а д ә р в и ш. Теләсән ничек уйла, ләкин сине коткарырга кирәк, сине генә түгел, корольлекне коткарырга кирәк, корольлекне генә түгел, католик динен, Кастилияне коткарырга кирәк. Кастилияне маврларга, яһүдләргә, гарәпләргә, төрекләргә хач сәфәрләре оештырып кына коткарып булмый, яу артыннан яу чаптылар христианнар Ислам илләренә. Мөселманнар, яһүдләр үрчи барды, байый барды, куәтләнә барды. Яна ысуллар кирәк, король.

Һ ә н р и х. Кем син?

К а р а д ә р в и ш. Мин хаиннәр тарафыннан сарайдан куылган чын

Бөек Инквизитор Бонифаций. Мин сине коткарырга килдем. Мин ватанны коткарырга килдем. Ал мине үз яныңа.

Һ ә н р и х. Син мөселман илчесе, син Ислам динендәге кеше, мин сине сараема алсам, кардинал Бардини икебезне дә учакка ташлатачак.

К а р а д ә р в и ш *(шәрык киемнәрен салып ташлый да, испанча кием белән кала. Сакчы да шулай ук кием алмаштыра. Алар икесе дә почмакка карап чукына башлый).* Без икебез дә чын христиан. Минем исемем Бонифаций, сарайда мине Пилигрим дип атарсыз, Мостафаның христиан исеме дон Олонсо булыр.

Һ ә н р и х. Могҗиза бу, Салазар!

С а л а з а р. Бу могҗиза безнең файдага, королем.

Һ ә н р и х. Салазар, син сул ягымда, Пилигрим, син минем уң кулымда торырсын. Патшалыгымда эт баш сыер аяк, тәртип юк.

К а р а д ә р в и ш. Королем, зинһар, сак бул! Магнатлар синнән куәтле. Аларда гаскәр һәм байлык. Иң башта казнадан талап алынган байлыкны кайтарырга кирәк. Ышанычлы сакчыларыңны һәм палачларыңны чакыр, аларны пәрдә артына постырып куй. Аннан соң магнатларны, кардиналны чакырырсың. Үгезне мөгезеннән алыр вакыттыр! Кинәт һөҗүм ит! Каушап калсыннар!

Һ ә н р и х. Бар, дустым Салазар, минекеләрне һәм палачларны чакыр, иң башта епископ-инквизитор Бардинины, аннан соң магнатлар керсен. Кардиналларның җыенын башлыйбыз! *(Салазар чыгып китә.)* Казнасы буш фәкыйрь Кастилиянең Чирләшкә короле Һәнрих Өченченең югалтыр нәрсәсе юк. Аның ата-анасы вафат, аның сәләмәтлеге юк, ул озын гомерле булмас, аның хатыны, балалары юк, король мотлак ирекле, мотлак азат. *(Ютәлләп ала. Дару каба, тынычлана.)* Тәвәккәл таш ярган, ди. Мин дә тәвәккәлләдем! Иисусе Христосе, ярдәмеңнән ташлама! Аме-ен!

## Чирләшкә король

*Кардинал Бардини, аның артыннан магнатлар керә. Болар үзләрен корольдән өстен тота, аларның һәрбесенең берничә замогы, гаскәре бар. Чынлыкта алар корольгә буйсынмый. Кардинал Бардини тәкәллефсез генә узып, король янына утыра. Магнатлар да корольдән арттырыбрак киенгән. Алар да үзләре теләгән урыннарга урнаша. Бардини король янында басып торучы Дәрвиш белән Сакчыны күреп ала.*

Б а р д и н и. Иисусе! Король җәнаплары! Сараеңда яңа магнатлар барлыкка килдеме?

Һ ә н р и х. Минем икенче канцлерым Пилигрим һәм аның хезмәтчесе дон Олонсо... Бу—кардинал-инквизитор Бардини хәзрәтләре. Ул минем мәгънәви атам, гөнаһлыларның гөнаһларын ярлыкаучы. Гөнаһлар ул ярлыкап кына бетәрлек булмаса, аларны учакта яндыру—аның изге вазифасы.

Б а р д и н и. Бу йөзләр бер дә таныш түгел кебек.

Һ ә н р и х. Алар бик ерактан, кардиналым, Константинополь шәһәреннән. Хәзерендә Пилигрим шартлы рәвештә, вакытлыча минем киңәшчем, ягъни икенче канцлерым вазифаларын үти.

Б а р д и н и. Бөек Кардиналның рөхсәте, һич югында кардиналыңның фатихасы кирәк булмадымыни, король җәнаплары?

Һ ә н р и х. Сеньор кардинал, бюрократия уйнамыйк инде.

Б а р д и н и. Ичмасам, киңәшкән булырга кирәк иде.

Һ ә н р и х. Киңәшкән булам бит инде. Менә бу минем икенче киңәшчем Пилигримм, аны сараема хезмәткә алырга сез каршы түгелдер бит? *(Тынлык.)* Сеньорлар-магнатлар, сараема яңа хезмәткәр алуыма сез дә ризадыр бит? *(Тынлык.)* Дәшмәү—ул ризалык галәмәте! Язызыз! Бу кәгазьгә корольнең мөһере, имзасы сугылып, яңа канцлер Пилигрим вазифаларын башкарырга тотынсын!.. *(Карадәрвиш корольгә якын тора, ара-тирә иелеп аңа киңәшләр бирә.)* Хәзер король сараендагы киңәш җыелышын башларга тиеш идек. Ләкин җыелыш башлана алмый! *(Халык шаулаша башлый: ни өчен, ничек? кебек сүзләр ишетелеп куя.)* Барыгыз да тәхетханәдән чыгыгыз! Сарайдагы олы җыелышка, элеккеге корольләр янына, тәхет залына, король Педро Дүртенче,

король Энрико Икенче, король Хуан янына ничек керә идегез? Минем янына да, ягъни королегез янына да шулай керегез! Йола шулай куша!

С а л а з а р. Барыгыз! Барыгыз да!

Б е р е н ч е   м а г н а т. Бу нәрсә була инде?

И к е н ч е. Бала-чага уены уйныйбызмы?

Ө ч е н ч е. Чишеләсе бер кочак мәсьәләләр бар, без монда уен уйнап маташабыз.

С а л а з а р. Корольгә ике тапкыр кабатлатмагыз!

*Магнатлар теләр-теләмәс кенә чыга. Кардинал утырып кала.*

Һ ә н р и х. Кардинал-инквизитор Бардини җәнаплары, бу боерык сезгә дә кагыла.

С а л а з а р. Кардинал, рәхим итегез!

Б а р д и н и. Һәнрико!

С а л а з а р. Король ике тапкыр кабатламый! Чыгыгыз!

*Бардини чыгып китә. Дәрвиш, Сакчы, Салазар шатланып, бер-берсенә баш бармакларын күрсәтәләр. Һәнрих аягүрә баса. Музыка.*

С а л а з а р. Кардинал Бардини җәнаплары, сеньорлар! Король сезне кабул итәргә әзер!

*Бардини, магнатлар тәзәтенә-тәзәтенә керәләр. Барысы да аягүрә басып тора. Һәнрих утыра. Шуннан соң гына Бардини һәм башкалар урнаша.*

Һ ә н р и х. Кардиналлар җыены башланганчы мин Бардини җәнапларына бер сорау бирермен... Әйтегез әле, хөрмәтле кардинал, Кастилиядә ничә король бар?

Б а р д и н и. Кастилиядә бер король.

Һ ә н р и к о. Кем инде ул король?

Б а р д и н и. Сез, Һәнрико Өченче җәнаплары!

Һ ә н р и к о. Ялган! Дөрес түгел җәнаби-кардинал!

Б а р д и н и. Мин башка корольне белмим. Ә-ә, сез ничә кеше тарихта Кастилия короле булып торды, дип сорыйсызмы? Фернан Гонсалес, Гарсия Фернандес, Санчо Фернандо...

Һ ә н р и к о. Юк! Мин бүгенгесен сорыйм. Бүген Кастилиядә ничә король бар? Сеньор, Альфонсо Фредрико, сез җавап бирегез.

А л ь ф о н с о. Бер генә король, җәнабем!

Һ ә н р и к о. Сеньор Луис, сез ни әйтерсез?

Л у и с. Мин... ни... король...

Һ ә н р и к о. Утырыгыз, сеньор Луис... Мин киемемне алыштырып шәһәр буйлап йөрдем, замокларны барлап чыктым. Халык арасында йөрдем. Сеньорларның бәйрәмнәрендә катнаштым. Хезмәтче кыяфәтендә мин кардинал-инквизитор Бардини сараена да үтеп кердем. Гәрчә, ул туйларга мин чакырылмаган идем. Чирләшкә корольне кем туйга чакырсын, авыру корольне кем замокка, сараена кунакка алдырсын! Бай яшисез сеньорлар, бай яшисез. Минем сеньорларым муллыкта яши, дип куандым. Ә шәһәрләр арасында йөргәндә мин соңгы плащымны сатып тамак ялгадым. Кем король бу илдә? Ялган сөйлисез, галиҗанәпләр, Кастилиядә король берәү генә түгел, Кастилиядә кимендә утыз король барын мин барлап чыктым. Мине санасаң, утыз бер король, ләкин мине корольгә санаучы юк. Сеньорлар арасында минем исемем Чирләшкә Һәнрих, монахлар арасында мине күптәннән табутта күрәләр. Алар мине Тере Мәет Һәнрих дип атый. Замоклары, сарайлары берничә булган сеньорлар кызларын Чирләшкә корольгә түгел, бай юлбасарларга димли. Кастилия короле Хуан углы Һәнрих юлбасар дәрәҗәсендә дә түгелмени? Мине кардинал әллә кайчан инде чиркәүгә алып кереп, дога укып, яхшылап җирләде. Җирләмәгән булса, тере король алдында сез шундый әдәпсезлекләр кылмаган булыр идегез. Корольнең хәзинә казнасы буш, минем майордомым, ягъни акча эшләрем өчен җавап бирүче хисапчым эшсез утыра. Санарга акча юк казнада. Пешерергә ит юк казанда! Королегезнең теш казнасына кыстырырга ипие, эчәргә шәрабы юк. Чөнки Кастилиядә утыз король тыгына, ашый, чөмерә. Алар яһүдләрне талый, маврларны сыга, еретиклардан акча каера. Бүгеннән Кастилиядә бер генә король— Һәнрих Өченче генә булачак. *(Магнатлар арасында ризасызлык, шау-шу куба.)* Салазар!

Салазар. Каравыл!

*Як-яклардан, уртадан баштанаяк коралланган сакчылар кереп, шпагаларын ялангач тотып, магнатларны урап алалар. Уртада кып-кызыл киемле өч палач калкып чыга.*

Һәнрих. Менә исемлек. Һәр сеньор казнадан алган акчаны кайтарырга, һәр сеньор үз биләмәләреннән король карамагына ун-унбиш мең атлы, кораллы сугышчы бирергә тиеш. *(Сеньорлар арасында шау-шу.)* Урыныннан кузгалган һәр каракны шпага тишеп узачак. Бу—бер. Мин сабый чакта, мин авырып ятканда казнадан урлаган акчаларны кем кайтармый, аның урыны җәһәннәмдә булачак! Аңлашылдымы? Имза куймаганнарның һәрберсен аерым бүлмәгә, каты сак астына, зинданга урнаштырыгыз. Магнатның ышанычлы кешесе сарай казнасына тиешле акча китереп биргәч яки имза салгач кына сеньорны азат итегез! Миңа үпкәсакларга уйламагыз. Миннән үч алу юлына да басмагыз! Минем югалтасы нәрсәм юк. Әмма мин әҗәлемә чаклы илдә тәртип урнаштырырга тиешмен! Тиешмен! Бетте! Салазар!

Салазар *(исемлекне укый).* Мин—Севилья замогының сеньоры Ордонио Рамиро король казнасыннан бурычка алып торган илле мең алтын мараведины шартнамәгә кул куйган көннән алып, бер атна эчендә кайтарып бирергә ышандырып, имзамны куям... Имза, елы, ае, көне... *(Рамиро кәгазьгә имза сала.)* Мин—Леон замогының сеньоры Гарсия Бермудо...

*Гарсия кул куя. Имза салу сөреше арткы планга күчә. Һенрих белән Бардини алга чыга.*

Бардини. Сез, король җәнаплары, кардиналга да имза салдырмыйсыздыр бит?

Һенрих. Мин сездән икеләтә алган булыр идем, кардинал җәнапләре, сез хәйләкәр инквизитор, сез шартнамә язмыйча гына казнаны талагансыз.

Бардини. Инквизиторлар белән бил алышырга азапланганнарның үз билләре сынды, король.

Һәнрих. Бу янаумы, кардинал-инквизитор?

Бардини. Ничек аңларга телисез, шулай аңлагыз.

Һәнрих. Король Хуанны да без агуладык, дип әйтергә теләмисездер бит, кардинал?

Бардини *(шартлый яза).* Король җәнаплары, сез артыгын кылана башладыгыз түгелме?

Һәнрих. Бусын да янау дип аңларга кирәкме, кардинал?

Бардини. Инквизиция барысын да күрә, барысын да белә, король җәнаплары.

Һәнри. Инквизиция барысын да белә, барысын да күрә. Илне юлбасарлар талый, кая карый инквизиция? Җавап бирегез, кардинал-инквизитор! Чит ил башкисәрләренең ватаныбызда кылган кабәхәтлекләре турында инквизиция белмимени? Әллә күрмәмешкә салышамы?.. *(Тынлык.)* Сез, кардинал-инквизитор, атам үләсе көнне аның сараенда булгансыз, шулаймы?

Бардини *(сагаеп кала).* Сез моның белән ни әйтмәкче буласыз?

Һәнри. Сез, кардинал-инквизитор, король Хуан үләсе көнне аның сараенда булдыгызмы?

Бардини. Булдым! Мин аутодафе эшләре белән килгән идем. Шуннан ни?

Һәнрих. Болай гына! Шунда булганыгызны гына беләсем килгән иде.

Салазар. Король җәнаплары! Барысы да имза салды. Ике сеньор гына риза булмадылар.

Һәнрих. Кемнәр?

Камердинер. Сеньор Опелио белән сеньор Диего Лопес.

Һәнрих. Зинданга ташлагыз! Инквизициянең еретикларны җәзалый торган бүлмә аша алып барыгыз да, аерым камераларга ябыгыз.

Опелио. Минем казнага бурычым юк! Мин ул акчаларны каян алыйм?

Диего. Король җәнаплары, минем йортым, авылым янды, минем хәзер генә кайтарып бирерлек малым юк.

Һәнрих. Гранадага якын җәйләүләрдән маврыларның елкы, куй көтүләрен ничә тапкыр куып алып кайттың? Син инде янган йортыңны тагын да яхшырак итеп төзеп кердең. Алыгыз!

*Опелио белән Диегоны алып чыгып китәләр. Магнатлар үз урыннарына утыра. Кардинал белән король дә урынна-*

*рына кайта. Тәхетханәдә кыен тынлык урнаша.*

Һ ә н р и х. Көн тәртибе?

С а л а з а р. Король Һәнрих Өченче сараендагы тәхетханәдәге утырышның көн тәртибе, кардинал-инквизитор һәм магнат-сеньорларның теләге: Франциядән бәреп кергән юлбасарлар илебезне, замокларны, калаларны, көтүлекләрне, кешеләрне талыйлар, хатыннарны көчлиләр, кызларны урлап алып китеп, таулар арасына качалар. Бу афәттән котылу чаралары, тәкъдимнәр!

Һ ә н р и х. Нишлибез, сеньорлар? Илебезне талап-корытып торучыларга каршы көрәшәбезме, әллә үзара сугышып ятабызмы?

А й я л а. Король җәнаплары, ул башкисәрләрне Франция короле Тиле Карл белән Бонифаций яллап безнең илгә керткән, дигән хәбәр бар.

Һ ә н р и х. Йөз мең алтын флорин бәрабәренә аларны чыннан да Тиле Карл белән Бонифаций җибәргәне ачык, сеньорлар.

А й я л а. Хөрмәтле сеньорлар, чыннан да, илдә тәртип урнаштырырга вакыт җиткәндер шәт. Чит илләрдән кереп талаганнары җитмәгән, бер-беребезне талыйбыз. Каты кул кирәк! Педро Дүртенче, Энрико икенче, Хуан кебек батыр король кирәк. Король җәнапләре Һәнриконы мин хуплыйм! Аның фәрманнарын тулысы белән кабул итәм. Иң беренче мин король карамагына егерме мең коралланган атлы сугышчы бирәм. Һәм иң башта әтрәк-әләм башкисәрләргә каршы көрәшкә үзем алынам.

Һ ә н р и х. Рәхмәт, Педро де Айяло. Син, сеньор Айяло бабам король Энрикога да, атам король Хуанга да күп еллар тугры хезмәт иткән батыр рыцарь. Хөрмәтле кардинал-инквизитор, сеньорлар, Педро де Айялоны ватаныбыз алдында күрсәткән батырлыклары өчен, башкалабыз Толедоның баш алькальды, ягъни баш хөкемдары итеп билгелим! Сугыш вакытында яки юлбасарларны эзәрлекләү заманасында Педро де Айялоны баш командор итеп куям. Ул вазифалы чакта, аның әмере—минем әмерем кебек, һичкарусыз башкарылырга тиеш. *(Алкышлар.)* Сеньор Айяло, вакыт кыса, юлбасарлар тагын да катырак кыса, шушы эш буенча кыскача фикерегез?

А й я л а. Король җәнаплары, һәр сеньорлыктан һич югында бишәр мең генә сугышчы җыелган очракта тау араларына, тарлавыкларга, качкыннарның оясына, тау куышларына һөҗүм оештырып була. Як-якларга шымчылар җибәреп, юлбасарларның кай тирәдә икәнен чамаларга, анынчы гаскәрне туплап өлгерергә, моның өчен бер атна вакыт кирәк.

Һ ә н р и х. Магнатлар ни ди?

А й я л а. Монда ризалык сорап торыш артыктыр, җәнабым. Кем күпме сугышчы бирә ала, мәгълүм бит.

Р а м и р о. Мин алты мең атлы бирәм!

Г а р с и а. Мин өч мең атлы бирәм.

Һ ә н р и х. Бер атнадан тауларга һөҗүм башкарырлык гамәлме?

А й я л а. Башкарырлык гамәл, королем.

Һ ә н р и х. Тәмам! Икенче көн тәртибе!

С а л а з а р. Сеньорлар, замоклар арасындагы талаш, кырылышны туктату ысуллары.

Һ ә н р и х. Артык сүз—ертык сүз! Ике күрше сеньор арасында кан коеш булса, гаепле кешене җәзага тартырга. Үлем җәзасына! Ун мең кеше үлгәнче бер сеньор үлсен! Фәрманым бөтен вилаятьләргә дә иртәгә үк чапкыннар аша җиткерелсен. Тәмам! Өченче көн тәртибе!

С а л а з а р. Кара халык өстенә сеньорлар салган салым, сеньорлар өстенә епископлар тарафыннан салынган салым, епископлардан кардиналлар җыйган салым акчаларын чиркәүгә, Бөек Инквизиторга ничек тапшырылуы турында.

Һ ә н р и х. Салымнар үтәп булмас дәрҗәдә авыр. Халык риза түгел, халык комсыз монахлардан зарлана, халык инквизиторларның рәхимсезлегеннән иза чигә. Ишетеп торасыз, күреп торасыз халык баш калкыта. Карахалык түзем, ул түзеп-түзеп тора да, бер кузгала. Халык кузгалса, аны тыюы шактый озакка сузылачак. Ни кылабыз?

А й я л о. Шушы салымнар, җир салымы, уңыш салымы, чиркәү салымы—барысы да кара халык сыртында. Шулар өстенә "гөнаһларны ярлыкау" дигән кыйммәтле салым уйлап таптылар монахлар, епископлар.

Б а р д и н и. Сеньорлар, Felix sulpa! дигән нәрсә бар. Гөнаһның бәһасе, кыйммәте, бәясе, дигән сүз ул "феликс сульпа". Языкның кирәклеге.

Һ е н р и х *(әче итеп көлә).* Сезгә— инквизиторларга гөнаһлылар бик кирәк, әгәр дә кеше гөнаһ кылмаса, сез кемнең гөнаһларын ярлыкар идегез, кемнән акча җыяр идегез? Феликс сульпа! Кешеләр һәрдаим гөнаһ кылырга тиеш, алар гөнаһ кылмаса, чиркәү нишләр иде, кешеләр гөнаһлы булганда гына инквизиция, котоликлык яшәячәк. Кешеләр гөнаһ кылмыйлар икән, аларны гөнаһ кылырга мәҗбүр итәргә яки гөнаһ кылган итеп күрсәтә белергә кирәк, инквизициянең төп максатларыннан берсе, булмаган гөнаһ өчен җәзалау. Халыкны куркытып тоту өчен кирәк ул суд процесслары. Чиркәүгә, монахларга гөнаһ кылмый торган саф кешеләрнең кирәге юк! Менә бөек парадокс кайдан килә! Бәс, чиркәү салымнарын, гөнаһларны ярлыкау салымнарын кыскартырга яки бөтенләй бетерергә кирәк!

К ү б е с е. Дөрес! Халык җиңел суласын!

Б а р д и н и. Сез ни кыласыз, сеньорлар. Моңарчы халыкны чиркәү, инквизиция тотып килде.

Һ ә н р и х. Тотып килде, ләкин гөнаһ кылучылар азаймады.

Б а р д и н и. Бөек Инквизитор салымнарны кыскартырга рөхсәт бирмәячәк! Бу гамәл ересь белән бер тигез.

Һ ә н р и х. Моннан соң чиркәүгә дигән салымны беркая да җибәрмәскә! Мин чыгарган фәрман түгел, атам-бабам фәрманы. Король контадорлары турындагы фәрманны архивтан табып алыгыз! Анда король контадорлары, ягъни салым-ясак җыючылардан хисап алу вазифалары гамәлгә кертелгән. Салым җыю каты контрольдә тотылсын! Үтәгез! Тәхетханә утырышы ябык!

*Таралалар. Король, Салазар, Карадәрвиш, Сакчы кала.*

## Ата белән угыл

С а л а з а р. Дүртенче көн тәртибен карамадык, король җәнапләре!

Һ ә н р и х. Дүртенче көн тәртибен менә хәзер карыйбыз.

С а л а з а р. Күршеләрдәге, ерак күршеләрдәге, бөтен дөньядагы сәяси, икътисади мохит. Бөек җыелыш алдында король җәнапларының яңа канцлеры сеньор Пилигрим нотык сөйли.

Һ ә н р и х. Җиде йөз илле алтынчы елда Астурия короле Фруэлага илчесе Бермудо кайтып, маврлар турында хәбәр сала. Бермудо маврларны куркыныч, җиңелмәс батырлар итеп, аларның гаскәрен иксез-чиксез дип, испаннарның йөрәгенә курку сала. Король Фруэла җиңелә. Бераз хәл алгач, Фруэла илчесе Бермудоның башын чаптыра. Икенче илчесе Овиедо Кордовадан кайтып, маврларны зәгыйфь итеп сурәтли. Фруэла тынычлана, маврлар ул гаскәр җыеп өлгергәнче Фруэланы килеп баса. Король Фруэла тагын җиңелә. Бераз хәл алгач, король Овидеоның да башын чаптыра. Татарлар турында арттырып сөйләсәң, без куркырбыз, каушарбыз, бу безгә зыян булыр. Синең башың чабылыр. Татарлар турында аларның куәтен киметеп сөйләсәң, без тынычланырбыз, алар куәтләнер, бу да безгә зыян. Бу очракта да башың чабылыр. Син, Пилигрим, коры дөреслекне сөйлә. Без шуннан ни кылырга кирәклекне аңларбыз.

К а р а д ә р в и ш. Хөрмәтле король Һәнрих җәнаплары, могтәбәр камердинер. Биредә дүрт мөһим мәсьәлә алдыбызга ятты. Аларның һәрберсе дә бик әһәмиятле. Үзара талаш та, юлбасарларның азуы да, салымнарның тәртипкә салынмавы да, фәкыйрьлекне мактаучы бай монахларның әхлаксызлыгы да— барысы да җанны тырный торган, бүген хәл ителәсе мәсьәләләр, ләкин мин әйтәсе көн тәртибе каршысында алар бик кечкенә күренер. Королем, Испания сеньорлары динебез өчен бер-берсенең канын коймый, алар байлык өчен, шәхси үч өчен сугыша. Бу көчне динне яклау тарафына, ватанны саклау тарафына юнәлтергә кирәк. Кардиналларның, монахларның җинаятьләрен фаш итәргә кирәк. Ләкин иң олы афәт, иң олы кырылыш...

С а л а з а р. Мур кырылышы...

К а р а д ә р в и ш. Мур кырылы-

шыннан да куркыныч афәт якынлашканын берсе дә сизенми, анламый, күрми. Янәшәдә генә мөселман дәүләтләре: Кордова, Гранада, Балеар утраулары. Ярты Пиреней мөселман маврлар кулында... Янәшәдәге христиан дәүләтләре: Византия, Константинополь, Болгария, Юнанстан төрек солтаны Баязид Елдырым кулында. Баязит Елдырымның бер миллион кылыч туплярлык куәте бар. Ул Бурса каласын яулап ала. Яулап ала, ләкин җимерми, халкын таламый, ул Бурсаны гөлчәчәккә күмә, ерак таудан Бурсага су китертә, мәчетләр, мәдрәсәләр төзетә, хасталарга хастаханәләр салдырта. Юксылларга, мохтаҗларга бушка ашау ханәләре төзетә. Шуна күрә, башка калалар да аңа капкаларын ачып торалар. Акшәһәр, Бәйшәһәр, Конья шәһәрләре аңа капка ачты. Халык аңа күп итеп сугышчы бирә. Шуннан Баязид Византия, Косоволарны яулады. Озакламый ул бөтен Ауропаны басып алачак. Баязид Елдырым гайрәтле солтан, акыллы солтан. Әгәр аңа комачау итүче булмаса, биш-алты елдан ул Пиреней ярымутравын да, Англияне дә килеп басачак. Чөнки аңа каршы торырлык көч юк. Аның иле чәчәк ата, шул ватанда үскән сугышчы Баязид Елдырым өчен утка да керә, суга да чума. Сугышта җиңелгән дошманнан алган ганимәт маллары төрекләр арасында тигез бүленә. Сугышта һәлак булган яугирнең малы гаиләсенә кайтарыла. Сугышчы ни өчен үлемгә барганын аңлап бара. Баязид Елдырым безнең иң куркыныч дошманыбыз.

Һ ә н р и х. Баязид Елдырымны җиңәр көч бармы?

К а р а д ә р в и ш. Королем, сабыр итсәгез ул мәсьәләгә дә килеп җитәрбез, иншалла...

Һ ә н р и х. Мин сабыр, мин түзем.

К а р а д ә р в и ш. Ислам-төрек дәүләте Баязид Елдырым исән булганда иң бай мәмләкәткә әвереләчәк. Баязид Елдырым белән тигез, шулай ук дәһшәтле татар ханы Туктамыш бар. Ул Алтын Урдага баш. Бай ил, алты йөз меңлек кылыч туплый ала торган бөек Туктамыш ханның иле Идел, Чулман, Ак Урда, Нугай Урда, Кырым Урда, Әзербайҗан иле, Кавказ илләре, Бөек Болгар дәүләтен, урыс-славян, чирмеш-чуаш-башкорт илләрен үз эченә ала. Коточкыч куәт, бетмәс гайрәт бар Алтын Урдада. Алтын Урда ислам-татар дәүләте... Өченче куәт бар Бөек Тартариядә. Анысы сезгә мәгълүм әмир Аксак Тимер—Тамерлан. Бөек Тамерланның империясе Мәвәрәәннәһер, Хәрәзем, Иран, Күк Урда, далалар, тауларны үз эченә ала. Тамерлан сигез йөз мең кылыч туплый ала. Тамерлан җиңелү белмәс баһадир. Тамерлан иле—ислам-түрк дәүләте.

Һ ә н р и х. Әгәр бу сүзләрең хак булса, ахырзаман киләдер.

К а р а д ә р в и ш. Дөрес, ахырзаманга ерак түгел.

Һ ә н р и х. Татарлары кем дә, төрекләре кем? Алар маврмы соң?

К а р а д ә р в и ш. Түрк тә, татар да—барысы да бер нәсел, барысы да мөселман. Маврлар мөселман-гарәпләр. Әгәр дә диннәре уртак, телләре бер халыклар шушы өч мөселман баһадир байрагы янында берләшә калса, аларга Гранада, Кордова, Мавритания, Мысыр мөслеманнары килеп кушылса—без мәңгегә юкка чыгачакбыз, королем. Ауропаның йоны күккә очачак. Католиклар да, православныйлар да татарларның ат тояклары астында туфрак булачак. Һуннар патшасы Атилланы гына искә төшерегез, тәкъсир. Алар бер нәсел.

Һ ә н р и х. Димәк, бу өч баһадирның берләшүенә киртә куярга кирәк.

К а р а д ә р в и ш. Мин ялгышмаганмын! Сез зиһенле рыцарь... Бу өч баһадирны үзара талаштырырга, дошманлаштырырга кирәк. Алар үзара сугышса, зәгыйфьләнәчәк, алар сугышкан арада христианнарга берләшергә кирәк. Бөтен Ауропаның, Кастилия, Франция, Англия, Германия, Италия, Балкан илләренең, мажарларның, урысларның бер генә максаты булырга тиеш, шушы җиңелмәс өч баһадирны үзара дошманлаштыру, аларны зәгыйфьләтү, ул арада көч туплап, Ауропаны, динне саклап калу. Һәм, ниһаять, коллыктан котылу!

Һ ә н р и х. Кем алына аларның арасын бозарга?

К а р а д ә р в и ш. Кемнәр алына, дип сорагыз... Өч кеше житә, дип уйлыйм мин. Шушы өч җиңелмәс баһадирны җиңәргә нибары өч кеше җитә. Без—фәкыйрегез Туктамыш белән Аксак Ти-

мерны сугыштырдык. Туктамыш татарларының йөз илле мене Кондырча болынында ятып калды. Без—фәкыйрегез Аксак тимер белән Бөек Болгар падишасы Габдулла ханны чәкәштердек. Идел ярында болгарларның йөз мең сугышчысы һәлак булды. Алтын Урда зәгыйфьләнде. Ләкин аждаһаның койрыгы гына киселде, белгәнегезчә, әкияттә аждаһаларның өзелгән коерыгы урынына янасы үсеп чыга. Туктамыш хан һәлак булмады, ул яраланды гына, аның куәте житәрлек. Хәзер ул котчыккыч куәт туплап ята. Аксак Тимер ул гайрәтле баһадир, акыллы әмир. Ләкин Аксак Тимердә зиһният юк.

Һ ә н р и х. Акыл белән зиһен икесе бер түгелмени, Пилигрим?

К а р а д ә р в и ш. Юк, королем, акыл башка, зиһен башка. Акыл өстенә зиһенле дә булса, кешене жинеп булмый. Аксак Тимер акыл иясе, ул акыллы яугир, акыллы гаскәр башлыгы, шахматта аны жингәннәр сирәк. Ләкин Аллаһ Тәгаләсе аны зиһенле итмәгән. Аксак Тимер никадәр генә кырыс булса да, беркатлы бәндә. Ул шикчән булса да, бик тиз ышанучан кеше. Мин аларның дин тотудагы булган кечкенә генә аермаларын зур гаугага әверелдердем. Аксак Тимер бик диндар кеше. Коръән ачтырмыйча, ул сәфәр чыкмас. Ләкин Коръәнне ул өстән-өстән генә белә. Күп вакыт үзе Коръәнгә каршы килә торган гамәлләр кыла. Туктамыш белән Тамирлан һичшиксез тагын сугышачак. Чөнки аларның арасыннан кара мәче узып китте инде. Туктамыш жинелүенең үчен кайтарыр өчен, Аксакка каршы гаскәр туплап ята. Алар сугышканнан соң, кайсы гына жинсә дә, Туктамыш Аксакнымы, Аксак Туктамышнымы, жингән якны Баязид Елдырым белән сугыштырырга кирәк.

Һ ә н р и х. Монысында нинди хәйлә?

К а р а д ә р в и ш. Хәйлә бар, королем. Аксак Тимер Туктамышны тагын жинәр, дип уйлыйм. Баязид Елдырымга яу белән йөрер өчен Тамирланга сылтау кирәк. Ул шул сылтауны эзли булса кирәк. Икесе дә мөселман, икесе төрк-татар. Коръән буенча мөселман мөселманга кылыч күтерергә тиеш түгел. Сәбәп яки сылтау булса, мөселман мөселманның бугазын чәйнәячәк. Төркиядә Кара Йосыф исемле бер харами, юлбасар бар. Ул таулар арасыннан уза торган бай кәрваннарны талый, Тәбризне, Кавказ, Кырымны тетрәтеп тора. Аксак Тимергә әнә шул турыда сөйләргә кирәк. Талан-ган кәрваннарның хужалары ярдәм сорап, Аксак Тимергә килергә тиеш. Аксак Тимер ярдәм сораган һәр илгә ярдәм итәргә атлыгып тора. Дошманы ярдәм сорап килсә дә, Тимер ана рәхәтләнеп ярдәм итәчәк. Гаскәрен шул илгә кертәчәк. Аның халыклар арасында ярдәмчел мөселман дәрәжәсен яулыйсы килә. Чыннан да ул бик күпләргә ярдәм иткән зат. Тимер эзәрлекләгенне сизенгәч, юлбасар Кара Йосыф Баязид Елдырымга барып сыеначак. Аксак Тимер: халыкларны талаучыны яклыйсың, дип Баязидка яу чабачак. Византия, Болгария, Юнанстан Аксак Тимергә илчеләр жибәрсен. Ул илчеләр Аксак Тимердән ярдәм сорасын, имеш, Баязит Елдырым аларны талый, кыерсыта, имеш, алар Аксак Тимер химаясына кереп, ана баш орырга тели. Аксак Тимернең көймәләре юк, ул дала кешесе. Тегеләр ана Баязидка каршы сугышканда дингез ягыннан көймәләр белән килеп, ярдәм итәрбез, дип вәгъдә бирсеннәр. Баязид белән Аксак Тимер сугыша башлагач, көймәләрен кирегә борсыннар. Шулай итеп, арыслан белән юлбарыс икесе генә сугышып калыр. Кем жинсә дә безгә файда.

Һ ә н р и х. Мин синең чын Бонифаций икәнеңә ышана башладым бит, Пилигрим.

К а р а д ә р в и ш. Моны хәзергә калдырып торыйк, юлбасар Педро Бургосны фаш итәргә озак калмады. Татарларны хәлсезләндергәч, иркенләп каракны фаш итәргә алынырбыз.

Һ ә н р и х. Мин сине нинди дәрәжәгә күтәрим дә, сина нинди бүләк бирим икән?

К а р а д ә р в и ш. Татарларны жину, Педро Бургосны фаш итү минем өчен иң зур бүләк булыр, королем.

Һ ә н р и х. Каян табыйм мин әлеге үзләрен корбан итәрлек фидаиләрне?

К а р а д ә р в и ш. Аның беренчесе синең янында тора.

Һ ә н р и х. Салазармы?

К а р а д ә р в и ш. Әлбәттә.

Һ ә н р и х. Ничек?

К а р а д ә р в и ш. Салазар минем углым.

Һ ә н р и х. С а л а з а р. Ничек?

К а р а д ә р в и ш. Синең анаң Леонора белән без яшьли таныш идек. Синең ананны сөйгән кебек мин бер генә хатынны да сөя алмадым. Ул сине пажлар мәктәбенә тапшырып, үзе вафат булды.

С а л а з а р. Атам!

К а р а д ә р в и ш. Улым, Салазарым! *(Кочаклашалар.)* Жылашырга вакыт тар. Ватан бездән ярдәм көтә. Озакламый Баязид Елдырым Мажарстанга яу чыгачак. Бу яуга каршы Изге Рим империясенең короле Сигизмунд житәкчелегендә Франция, Англия, Ләһестан, Шведция, Германия, Болгария гаскәрләре хач сәфәре әзерли. Бу яуга Бонифаций фатиха биргән. Сез дә, королем, бу яудан читтә калмассыз.

Һ ә н р и х. Мин анда батыр рыцарь Педро Айяло командалыгында гаскәр юлларммын.

К а р а д ә р в и ш. Ярамый!

Һ ә н р и х. Ни өчен?

К а р а д ә р в и ш. Айяло иң кирәкле кешең. Шундый тугры терәгенне сугышка, үлемгә юллыйлармыни? Ул сиңа монда кирәк. Кардиналлар, комсыз монахлар, гаделсез сеньорлар белән көрәштә Айяло синең уң кулың. Син күз буяр өчен генә бераз гаскәр бир. Шул гаскәр эчендә синең якын дустың, минем бердәнбер улым Салазар булыр. Баязид Елдырым бу хач гаскәрен жиңәчәк. Ә Салазар аңа әсир төшәчәк, ул яшь, солтан аны үз янына алдырыр. Салазар Исламны кабул итәр.

С а л а з а р. Теләсә нинди эшкә риза, ләкин мине динемнән яздырмагыз.

К а р а д ә р в и ш. Христос синең юри генә мөселман булганыңны күреп тора.

Һ ә н р и х. Син Ватан өчен, динебезне саклар өчен мөселман булып, Коръән укып, намаз кылып йөрергә тиешсең.

К а р а д ә р в и ш. Бу саваплы эш, сөекле улым. Бәс, минем дустым Олонсо сиңе гарәпчә Коръән укырга, төрекчә сөйләшергә өйрәтә башлар. Сине солтан тәржемәче буларак бәяләр. Телләр белгән кеше югалмый ул. Татарга тылмач кирәкми. Ә христианнарга тылмач кирәк. Чөнки христианнар үз телләреннән башка телләрне белми. Белергә дә теләми.

Һ ә н р и. Ризамы?

С а л а з а р. Риза, королем! Риза, атам. Ярый, мин сугышта катнашырмын, исән калып әсир төшәрмен, калган вазифам нинди булыр?

К а р а д ә р в и ш. Баязидны Аксак Тимер белән сугышырга котырту. Сездермичә генә аларның йомшак якларын өйрән. Әйтик, Баязид Юнан жирләренә басып керсә, Юнан короле Аксак Тимердән ярдәм сорый. Аксак Тимер Баязид белән сугышырга мәжбүр булачак. Ул барып чыкмаса, юлбасар Кара Йосыфны мактап, солтан белән дуслаштырып, Тамирланның ачуын кабарт.

Һ ә н р и х. Икенче зат кем ул?

К а р а д ә р в и ш. Аңысы мин фәкыйрегез! Руи!

Һ ә н р и х. Руи?

Д ә р в и ш. Руи-Бонифаций!

Һ ә н р и х. Өченчесе?

К а р а д ә р в и ш. Минем тугры сакчым Олонсо. Ул Кастилия короленнән солых, килешү хаты белән олы бүләкләр алып, мин дәрвиш Исрафил, Олонсо Мостафа кыяфәтендә Аксак Тимергә барып житәргә тиешбез. Аксак Тимер чит илчеләрне бик яхшы кунак итә. Туктамышны жиңгәч, Тамирлан Баязид өстенә барачак. Баязидны жиңгәч, ул, һичшиксез, Кытайга яу чабачак. Кытайның да, Тамирланның да көче зәгыйфьләнәчәк. Аурупа олы афәттән котылачак.

Һ ә н р и х. Католикларны коткаручы дүртенче баһадир кем ул?

К а р а д ә р в и ш. Дүртенче баһадир ул барысына караганда да баһадир. Аксак Тимернең иң сөекле хатыны Гайшә бикә.

Һ ә н р и х. Ничек?

К а р а д ә р в и ш. Гайшәнең Тамирланга үче бар. Ул Гайшәнең атасын, туганнарын яндырып үтерде. Без Гайшәне алып, кире Самаркандка кайтып китәрбез.

Һ ә н р и х. Әгәр Тамирлан ышанмаса?

К а р а д ә р в и ш. Инанамын ки, Тамирлан ышаначак. Һәм ул аны тагын да ныграк сөячәк. Никах яңарткан бер төндә Гайшә бикә аның шәрабына агу салачак. Шулай итеп, без Кытайны тармар килүдән коткарачакбыз, үзебез дә татарлар, мөселманнар, төрекләр золымыннан котылачакбыз.

Һ ә н р и х *(көлә)*. Каян килеп чыктың син, Пилигрим Бонифаций? Син

мине үлемнән алып калдың бит, рәхмәт. Менә хәзер шатланырга да була. Биергә дә була. Һәй, шәраб китерегез!

*Лакей ливреелары кигән хезмәтчеләр, тантаналы музыка янгырап торганда алтын төпсәләргә куелган шәраб кадехләрен алып чыгалар. Кадехләр берберсенә бәрелешеп серле музыка кебек зынгылдыйлар.*

## Корольнең кәләш сайлавы

*Корольнең сарайда ышанычлы өч дусты бар иде. Анын берсе сеньор Айяло, икенчесе—канцлер Салазар, өченчесе—донья Леонора. Атаклы, әмма атасы маврлар белән сугышта һәлак булган каһарман Карлос Вианның ятимә калган кызы Леонораны сарай тәрбиясенә алганнар иде.*

*Толедо сарае. Король Һәнрих белән донья Леонора.*

Л е о н о р а. Һәнри, мин синең өчен бик куркам, җаным. Син коточкыч дәһшәткә каршы куйдың үзеңне. Сак бул!

Һ ә н р и х. Леонора, син минем өчен кайгырма. Мин барысын да алдан уйладым. Рәхмәт сиңа! Син һәрвакыт мине сакладың, мине дәваладың. Минем синнән якын кешем юк. Син мине аякка бастырган кеше.

Л е о н о р а. Һәнри! Минем дә синнән башка якын кешем юк. Мин атам-анам вафатыннан соң сарайда доньялар мәктәбенә тапшырылган ятимә. Син пажлар мәктәбендә укыганда бик еш авырый идең.

Һ ә н р и х. Мин бакчада башка инфантлардан артка калып, озак кына ютәлләдем. Минем буылып ютәлләвемә игътибар итмичә пажлар уза торалар. Мин аларга үпкәләмим, чирләшкә инфантның кемгә кирәге бар. Мин пажлар сафының иң артына бастыралар, миңа аерым савыт, аерым кашык тоталар. Мин аерым бүлмәдә йоклыйм. Мин гел ялгыз. Син шунда доньялардан аерылып, яныма килдең.

Л е о н о р а. Принц, сине ташлап киттеләрмени, Ходаем? Принц, мин сиңа ничек ярдәм итим. Әйдә, мин сине пажлар ятакханәсенә алып кайтып куям.

Һ ә н р и х. Син ютәл йоктыру турында да уйламыйча, миңа якын килдең. Мине кочаклап аягыма бастырдың... Минем йөрәгем чеметеп куйды. Миннән җирәнмәгән кеше дә булыр икән. Мине кызганучы да дөньяда бар икән, дип уйладым.

Л е о н о р а. Авыру йоктыру турында уйлыйлармыни ул вакытта.

Һ ә н р и. Шуннан соң мин ютәлем килмәсә дә сафтан аерылып арттa калам. Син шундук пәйда буласың. Син килмәгән көнне миңа күңелсез була. Син килмәгән көнне мин сагышка батам. Син килеп чыккач, авыруым артка чигә.

Л е о н о р а. Мин инде синнән башка яши алмый идем.

Һ ә н р и. Шулай итеп, син мине караучы, мине саклаучы фәрештәгә әврелдең.

Л е о н о р а. Мин синнән башка яшәвемне күз алдыма да китерә алмыйм. Мин сине өзелеп сөям, Һәнри.

Һ ә н р и х. Мин дә сине үлеп яратам, Леонора.

Л е о н о р а. Ләкин минем күңелем сизенә, эчтән нидер тоям мин, Һәнри, без аерылышырбыз кебек, без гомергә бергә була алмабыз кебек.

Һ ә н р и х. Мин дә синән башка тора алмам сыман.

Л е о н о р а. Мин синең яннан беркая да китмим.

Һ ә н р и х. Бала чактан ук син миңа анам да, апам да, сөйгән ярым да булдың. Ләкин, чыннан да, без алга таба бергә була алмыйбыз.

Л е о н о р а. Ни өчен, Һәнри?

Һ ә н р и х. Чөнки минем китмәс, төзәлмәс авыруым бар.

Л е о н о р а. Мин авыру йогуыннан һич курыкмыйм. Монарчы йокмады бит. Моннан соң да йокмас.

Һ ә н р и х. Юк, җаным, авыру йокмаса да безгә аерылырга кирәк.

Л е о н о р а. Күз алмам, Һәнри, син ни сөйлисең? Сиңа ни булды? Берәрсе гайбәт җиткердеме?

Һ ә н р и х. Юк, синең турыда гайбәт була алмый, булса да, мин ул гайбәтлә-

рне чынга алмас идем. Син изге зат, син миһербанлы жан, син наз иясе. Син минем бәгырем түрендә чыкмаслык булып урын алган илаһи зат.

Л е о н о р а. Жаным, рухымның иясе... Безгә ни комачаулый соң?

Һ ә н р и х. Минем гомерем санаулы гына.

Л е о н о р а. Ташла бу сүзләреңне, Һәнри! Үпкә авыруы белән житмешкә житкәннәр бар.

Һ ә н р и х. Мин башка, жаным. Мин үлемгә дучар.

Л е о н о р а. Авызыңнан жил алсын, король !

Һ ә н р и х. Мин сиңа өйләнә алмыйм, Леонора!

Л е о н о р а. Һәнри, жаным туктат бу сафсатаңны!

Һ ә н р и х. Мин сиңа өйләнә алмыйм.

Л е о н о р а. Чөнки син король, мин сарайда тәрбия алган бер ятимә кыз. Кардинал, канцлерлар, сеньорлар жыены никахка фатиха бирмәячәк, шулаймы?

Һ ә н р и х. Анысы да бар. Ләкин аларны мин жинә алыр идем...

Л е о н о р а. Шулай булгач, ни комачаулый? Әгәр алар никахны хупламаса, без никахсыз гына очрашырбыз.

Һ ә н р и х. Сарайның диварлары колаклы, түшәмнәре күзле... Леонора, мин дөньяга авыру туган баланың атасы буласым килми. Мин өйләнмәячәкмен.

Л е н о р а. Йа, Иисусе Христосе! Өйләнмә! Тик мине генә яныңнан кума!

Һ ә н р и х. Леонора! Мин авыру, ләкин Алла тарафыннан миңа бирелгән кыска гомеремне мин корольлекләрне берләштереп, Бөек Испания дәүләте кормак булам. Бу минем изге максатым. Иң беренче безне урап алган Кордова, Гранада илләрен маврлардан арындырыш кирәк. Мин Бөек Инквизиторның комсызлыгына юл куярга тиешмен. Мин булачак Кастилияне татар-төрек варварларыннан коткарып калырга тиеш. Минем шәхси тормышым юк, була да алмый. Өйләнеп, бала-чага үрчетеп, көнкүреш мәшәкатьләренә батсам, мин шушы дүрт бөек максатымнан читләшермен, дип куркам. Мин мотлак азат булырга тиеш. Минем дошманнарым аз түгел. Минем бабам Энрико, атам Хуан шул юлда һәлак булган. Гаиләмне, тынымны, балаларымны шушы фетнәләргә кушып, жанымны, канымны тинтерәтмәсеннәр өчен мин өйләнмәячәкмен. Бу юлдан мине хәтта олы мәхәббәтем дә тайчандыра алмас.

Л е о н о р а. Аңладым, Һәнрико. Син мәхәббәтеңне корбан итәсең.

Һ ә н р и х. Мин олы мәхәббәтемне ике тапкыр корбан итәм.

Л е о н о р а. Ничек, ни өчен ике тапкыр?

Һ ә н р и х. Гранаданың халифе Мөхәммәд куәтле ир. Аның илендә байлык, корал, гаскәр. Ул Кастилиянең борын төбендәге иң хәтәр куркыныч. Маврлар, мөселманнар халкыбызны җиде йөз ел буе коллыкта тота, бу коллык богауларын ватып ташларга вакыт житеп килә, Леонора. Әгәр дә без Гранаданы хәлсезләндерсәк, Кордованы тиз алырбыз.

Л е о н о р а. Син сәясәткә алып кереп киттең мине.

Һ ә н р и х. Гранада халифе Мөхәммәдне син солых төзегәндә сарабызда күрдең. Ул да сине күреп алган.

Л е о н о р а. Шуннан ни?

Һ ә н р и х. Ул миннән сине сорый.

Л е о н р а. Ничек сорый?

Һ ә н р и х. Ул сине хатынлыкка алмак була.

Л е о н о р а. Син ни сөйлисең, Һәнри, син мине маврга сатып жибәрмәкче буласыңмы?

Һ ә н р и х. Тынычлан, Леонора. Тыңлап бак мине. Мөхәммәд халиф сиңа үлеп гашыйк булган. Әгәр дә син аңа кияүгә чыксаң...

Л е о н о р а. Аңладым мин сине, король, син мине сатасың, син мәхәббәтеңне сатасың, кыргый мөселманга, маврга син мине сатасың.

Һ ә н р и х. Мин Испаниянең киләчәге өчен, католиклык куәтләнсен өчен синнән—сөеклемнән ваз кичәм. Мин олы мәхәббәтемне корбан итәм. Әгәр мине сөйсәң, син дә үзеңне корбан ит. Син мине, ватаныбызны, динебезне ихластан сөйгәнеңне исбат ит. Син халиф Мөхәммәдкә кияүгә чык!

Л е о н о р а. Котчыккыч сафсата!

Һ ә н р и х. Фидаилек, бөек максат өчен бөек корбан!

Л е о н о р а. Аңладым, король! Миңа хәзер ни теләсәң, шуны боер миңа.

Һ ә н р и х. Кичер мине, жаным. Га-

епләмә! Каргама да! Син Мөхәммәд хәлифкә чыгып...

Л е о н о р а. Хәлиф христианкага өйләнә алмый, король!

Һ ә н р и х. Син Ислам динен кабул итәрсең!

Л е о н о р а. Изге Мария! Иисусе Христосе! Денемнән язарга кушасың? Католик динен сафландырырга алынган король мине Христостан ваз кичеп, Исламны кабул итәргә боерамы? Мин үземә-үзем кул салачакмын!

Һ ә н р и х. Алайса, син Мөхәммәд хәлифнең харамына төшәсең! Ләкин синең максатың: мәхәббәттән тилергән маврның башын әйләндерү, аны дәүләт эшләреннән биздерү, кирәге чыкса, аның ашына агу салу.

Л е о н о р а. Мин барысына да риза, король!

Һ ә н р и х. Ләкин син хәлифкә назлы булырга тиеш. Аны гүзәллегең, акылың белән хәйран-вәйран калдырырга тиешсең.

Л е о н о р а. Мин риза, король!

Һ ә н р и х. Сине Мөхәммәд хәлиф илчелеге көтә, Леонора.

Л е о н о р а. Һәнри, жаным, онытма мине. *(Кочаклап үбә.)*

Һ ә н р и х. Бәхиллә мине, жаным, Элеонора! Шулай кирәк!

Л е н о р а. Хуш! *(Тәвәккәл атлап чыгып китә.)*

Һ ә н р и х. Йөрәгемнән каерып алып, ятларга бирдем сөеклемне! Христоска, Испаниягә булган мәхәббәтем женси мәхәббәттән куәтлерәк!

*Сакчы белән Гайшә керә.*

С а к ч ы. Король жәнаплары, Гайшә бикә хозурыгызга килде.

Һ ә н р и х. Хуш килдең, Габдулла хан кызы Гайшә бикә.

Г а й ш ә. Сәламәтлек телим сезгә, король.

Һ ә н р и х. Рәхмәт, сәламәтлек миңа бик кирәк. Гайшә бикә, ватаныңны Тамирланны искә аласыңмы?

Г а й ш ә. Ватанымны бик сагынам, Болгарым төшләремә керә. Чыдап булмас жирсү били жанымны, хөрмәтле король, әмма Аксак Тимерне мин юксынмыйм, мин аны сагынмыйм, мин аны искә алам, бары тик үч алу хыялы белән генә.

Һ ә н р и х. Алайса, минем сиңа бер гозерем бар.

Г а й ш ә. Жәнаби король, мин сезнең хозурыгызда.

Һ ә н р и х. Сине миңа ерак илләр аша атаклы түрә шаһ Тимер һәдия итеп юллаган икән. Мин сине һәдия буларак кабул иттем.

Г а й ш ә. Мин сезнең идарәдә, король.

Һ ә н р и х. Сине кая куярга, сине нишләтергә, дип баш ватам.

Г а й ш ә. Синең ихтыярың, король, мин синең колың, мин синең хезмәтчең, мин синең хатының була алам. Мин бит жиңелгән ханның бичара кызы гына. Сез—жәнабе король хәл итегез.

Һ ә н р и х. Син мөселманлыкны ташлап, христианлыкка күчәргә ризамы?

Г а й ш ә. Минем ихтыярга куелса, мин денемнән ваз кичмәс идем, мин, әлхәм дулилләһ, мөэмин мөселманмын.

Һ ә н р и х. Әгәр дә син миңа кияүгә никахлашып чыгарга ризалык бирсәң, сине, һичшиксез, чукындырырга кирәк.

Г а й ш ә. Әстәгъфирулла.

Һ ә н р и х. Юкса, чиркәү еретик белән мине кушмаячак.

Г а й ш ә. Мин сезнең харам жариянез генә булып калырмын, ахрысы.

Һ ә н р и х. Ихтыярың! Ләкин харам жариясе булудан да син азат булырсың.

Г а й ш ә. Ничек? Мин иреклеме?

Һ ә н р и х. Әлбәттә.

Г а й ш ә *(король алдына тезләнә).* Чиксез рәхмәтләрем сезгә король жәнаплары. Димәк, мин илемә кайтып китә алам?

Һ ә н р и х. Әлбәттә, ләкин бер шартым бар.

Г а й ш ә. Нинди шарт ул, король?

Һ ә н р и х. Син минем илчем белән Сәмәркандка, шаһ Тимер янына кайтып, аның яхшы мөнәсәбәтен яулыйсың. Аның белән яуга бергә йөрисең: мин синнән аерым тора алмыйм, мин синнән калмыйм, дип ант итәсең һәм жае чыкканнан соң аның ашына, шәрабына менә шушы агуны саласың. Шулай итеп, син янып һәлак булган атаң, анаң, башка туганнарың, Бөек Болгарның үчен алачаксың.

Г а й ш ә. Мин ике куллап риза.

Һ ә н р и х. Олонсо! Калганын син аңлатып бирерсең! *(Сакчы белән Гайшә китә.)*

**К а р а д ә р в и ш** *(керә).* Эшләрен ничек, королем?

**Һ ә н р и х.** Мин аны корбан иттем.

**К а р а д ә р в и ш.** Бу—мактауга лаек корбан, сир. Бу—батырлык. Бу рыцарьларның олы сугышта кылган батырлыкларыннан мең тапкыр кыйммәтрәк, король ! Синең миссиян шундый корбаннар таләп итә. Тагын бер корбан сорый олы максат, сир.

**Һ ә н р и х.** Арагонда эшең ундымы, Пилигрим?

**К а р а д ә р в и ш.** Арагон короле Мартин мине бик яхшы кабул итте. Синең тәкъдимеңне ул биш куллап каршы алды. Король Мартин ике илне берләштерергә риза.

**Һ ә н р и х.** Кит аннан! Чынлапмы?

**К а р а д ә р в и ш.** Иисус Христос шаһит! Король Мартин Арагонны тулысы белән Кастилиягә кушарга риза.

**Һ ә н р и х** *(Карадәрвишне кочаклап әйләндерә).* Йөз яшә, Пилигрим!

**К а р а д ә р в и ш.** Ләкин аның шарты бар, сир.

**Һ ә н р и х.** Нинди шарт? Үтәлерлекме, үтәлмәслекме?

**К а р а д ә р в и ш.** Король Мартин Арагон патшалыгы белән Кастилия патшалыгын бергә кушарга ризалык бирәчәк, әгәр дә Кастилия короле Һәнрих Өченче аның кызы Изидага никахлап өйләнсә!

**Һ ә н р и х** *(артына утыра).* Иисусе Христосе! Авва Мария! Нинди коточкыч шарт!

**К а р а д ә р в и ш.** Шулай, королем, шарты бик җиңел түгел...

**Һ ә н р и х.** Син аның кызын күрдеңме соң?

**К а р а д ә р в и ш.** Күрдем. Сөйләшеп тә утырдык.

**Һ ә н р и х.** Ул бит дөнья ямьсезе! Ул... пәри чабаклаган убырлы карчык бит, канцлерым.

**К а р а д ә р в и ш.** Арттырмагыз, король, ул кадәр ямьсез түгел ул Изида. Матур түгел ул, әмма убырлы карчык түгел бит инде. Ана егерме биш кенә яшь. Ул утырып калган карт кыз... Син әле яңа гына иң сөекле зат, иң саф җан, сине дәвалаган, сине өзелеп сөйгән кешенне—Леонораны корбан иттең. Олы максат өчен моннан да олы корбанның монарчы булганы юк. Инде Изидага өйләнүең ул синең батырлыгың, Испаниянең килчәге өчен бәһаләп бетергесез батырлык. Эшлә син ул батырлыкны! Арагон белән Кастилия кушылып, Испания хасил итү хөрмәтенә Изидага гына түгел аждаһаның үзенә өйләнергә дә була! Ә принцесса, Изида гүзәл булмаса да, бик акыллы, королем!

**Һ ә н р и.** Ярый! Күндердең! Хәл иттек! Арагон короле Мартинга кызы Изиданы Кастилия короле Һәнрих Өченчегә кияүгә сорап илче-яучылар җибәрегез!

*Бирнәгә алтын таулары вәгъдә ителгән булса да, бер генә король дә, бер генә сеньор да, бер генә кабальеро да, хәтта тол калган ирләр дә король Мартинның кызы Изиданы ярәшмәде. Кастилиянең яшь короле утырып калган карт кыз Изидага өйләнүе христиан дөньясын шаккатырды.*

## Баязид Елдырымның Аксак Тимергә әсир төшүе

*Төркия. Анкара янында Тимер ыстаны. Яңа гына сугыш Аксак Тимер файдасына тәмамланган. Аксак Тимер күчмә тәхетендә утыра. Аның янында берничә хаттат тезләренә рәмел тактасы куеп, канат-каләм белән язалар. Муеннарында кара савыты. Хаттатларның арка ягыннан, алар язганны карап, хаталарын төзәтеп Ибраһим-бахшы йөри.*

**И б р а һ и м.** Һиндстан сәфәреннән алып кайткан ганимәткә корылган Җәмигъ мәсҗеденең гүзәллеген сүз белән сөйләп, каләм белән язып бетергесез, тәкъсирем. Мәсҗеднең арка капкасы белән гөмбәзен Күк гөмбәзе һәм Киек Каз юлы белән генә чагыштырып булыр иде. Мәсҗеднең гөмбәзе, әгәр дә Күк гөмбәзе булмаса, Җир йөзендә бер ялгызы гына булыр иде.

**Т и м е р.** Мин үзем өчен йөрмим яу артыннан яуга. Мин бөтен кешелекнең сәгадәте өчен кешеләрнең канын коям. Бу гүзәл мәсҗеднең нурында бер мин

гена коенмыймын, барысы да коена, бу мәхәббәт Аллаһ йортында мин ялгызым гына намаз укымыйм, һәр теләгән кеше Аллаһ йортына керә ала, догасын укый ала... Һиндстанга, монафикълар, фетнәчеләр иленә, таш сыннарга табынучылар ыстанына барып, алар кулыннан алган байлыкны мин үземә тотмадым. Әйтте миңа сәед углы сәед Исрафил хәзрәтләре, Һиндстанны алсаң, андагы алтын таулары сине җиде икълимнең дүртесенә падишаһ итәчәк, дип яуга фатиха бирде. Яу алдыннан Коръән ачтырдым, Әнфәл сүрәсенең утыз тугызынчы аяте чыкты; анда акка кара белән язылган: пәйгамбәр, фетнәләр беткәнгә чаклы, Аллаһның дине тулысы белән урнашканга чаклы кяферләр белән орыш. Аннан соң Тәүбә сүрәсенең җитмеш өченче аяте ачылды: и, пәйгамбәр, кяферләргә һәм монафыйкъларга каршы Җиһад ит. Аларга кырыс бул. Аларның барыр җире—җәһәннәм, диде миңа Аллаһу Тәгалә.

Мин Аллаһ юлында Җиһад иттем. Эрзерум янында мин гаскәремне туктаттым, гаскәрем бөтен тау итәген, даланы кара күч кебек сарган иде. Шәһәр шул кара күч уртасындагы утрау кебек кенә булып калган иде. Мин тау түбәсеннән гаскәремә бактым. Һәм уйладым: менә мин бер үзем, япа-ялгызым, әллә нинди куәтле көчем дә юк кебек, ләкин шушы чиксез гаскәрнең һәр яугире аерым алганда, бөтен гаскәр, һичшиксез миңа буйсына. Мин бер-бер әмер бирә калсам, ул әмерем төп-төгәл җиренә җиткереп башкарылачак. Мин шул турыда уйлап, безне барлыкка китерүче Аллаһка чиксез рәхмәтләр укыдым. Ул мине шушы колларга башлык итеп куйды. Мин бу турыда голәмәдән сорадым. Ни өчен шушы хисапсыз халык миңа буйсына, дидем. Алар әйтте: сиңа Аллаһның нуры төшкән, Аллаһ сине олы иткән, шуңа күрә, син Аллаһтан алган көч белән куәтле. Әгәр дә кылмышларында хаким гадел булса, аның буйсынарлары аңа һич икеләнмичә хезмәт итәчәкләр, дошманнары аннан кан калтырап торачаклар, диделәр. Идел-Урал, Тәбриз-Кавказ, Мисыр-Фарсы, Төрек-Көрт җирләрен—җиде икълимнең дүртесен—Һиндстанны яулап алдым. *(Дәһшәтле итеп көлә.)* Алышмагыз минем белән, дидем. Карышмагыз миңа, дидем. Юк бит! Алышалар, карышалар! Җиңәрләренә ышаналар! Аксак Тимерне, Чулак Тимерне җиңәр көч бармы бу дөньяда? Булса, әйтегез! Һич сүзем юк! Җинсеннәр мине! Җиңелгән кешегә шул кирәк! Җиңелсәң, ыңгырашма! Җиңгәнсең икән, җиңүең белән ләззәтлән! Аллаһ сиңа җиңү китерде!

Дәһли каласын алганда минем кулда йөз мең монафикъ әсир иде. Мин аларны Сәмәркандка алып кайтырмын, дип уйлаган идем. Ләкин Дәһли каласына һөҗүм иткәндә бу йөз мең әсир арттан төшеп, миңа комачау ясар иде. Шуңа күрә, мин Аллаһ кушуы буенча бер мизгел эчендә аларның башларын чаптырдым. Шулай итеп, минем арка ягым тыныч калды. Шуннан мин Дәһлине байлыгы-ние белән кулга төшердем. Һиндстанның алтыны, көмеше, алмазлары, мәрҗәннәре, башка асылташлары безнең казнага күчте.

Җиңелмәс солтан, Рум вилаятенең падишасы, Сивас, Урта диңгезнең буерыкчысы Баязид солтанны да мин аркасына салдым. Әгәр мин тәкъва мөселман булмасам, әгәр дә мин Аллаһ юлында Җиһад кылмасам, әгәр дә мин пәйгамбәребез Мостафа салаллаһу галәйһи вә сәлам үрнәгендә яшәмәсәм, миңа бу җиңүләр килер идеме? Юк! Һич килмәс иде. Димәк, әмир Тимер хак юлда!

Бүгенгә җитеп торыр!

*Чыгып китә. Ханәдә Ибраһим бахшы хуҗа булып кала.*

И б р а һ и м. Барлас углы Таргатайның углы Шаһ Тимер хәзрәтләре 1336 елда Киш каласында дөньяга килде. 1370 елда ул Мәвәрәеннәһернең хакиме булды. Башта ул Чыңгыз нәселле Тулык Тимернең углы Ильяс Хуҗаны үтерде, аннан соң ул әмир Хөсәенне кылычтан узгарды, Балх каласына хуҗа булды. Малик Гыясетдинне әсир алып, Хорасанны кулына алды, аннан соң Сизуар, Нишпур илләрен дәүләтенә кушты. Сарбедарларның түрәсе Хуҗалы Мохидне үзенә буйсындырды, 1383 елда Кандагарны тар-мар итте, аннан соң Мазендаранны, 1384 елда Җалаир солтанны куып, Әзәрбәйҗанга бәреп керде, Тәбризне, Карс, Тифлис калаларын буйсындырды, Мозафарныкылар кулыннан

Ширазны тартып алды, шуннан соң ул Дәшти Кыпчак ягына китеп, Туктамышны җинеп, Себер якларын инләп алды, 1399 елда Һиндстанны аркылыга буйга таптап чыкты. Дәһлине, 1400 елда Суайс, Халеб, Шам-Сүрия, Баһдадны тар-мар китерде. Аннан соң җинелмәс төрек солтаны Елдырым Баязидның ярты гаскәрен кырып, ике йөз мең кешесе белән солтанны әсир итте. Шаһ Тимер утыз алты ел җинелмәс падишаһ булды. Ул Дәһли каласы янында йөз мең әсир индусны кылычтан узгарды. Үз ватаннарын саклап сугышкан, Тимергә буйсыныргa теләмәгән батырларның тере гәүдәләреннән манаралар кордырды, әсир төшкән ун меннәрчә батырларны шәһәр диварларыннан аска аттырды, мәетләр өелеп диварга житкәч, атылган батырлар имгәнеп үлми калалар иде, үлми калганнарын әмир Тимер әрдәнә итеп өйдереп ут төрттерә иде. Исфаган янында житмеш мең кешенең баш сөягеннән манара кордырды. Житмеш мең мөселман башын кисеп алып, казаннарда пешекләп, ап-ак баш сөякләреннән тау өйдерде... *(Ибраһим саташа башлый.)* Әмир Тимер кая гына барса да артыннан елга-елга кан агызды, илче итеп җибәрелгән хатыннарны, сабыйларны менләгән ат белән таптатып, изеп бетерде. *(Ибраһим үзалдына сөйләнә-сөйләнә йөреп китә.)*

*Алдарак Аксак Тимер йөри, әсир төшкән Баязид Елдырым белән берничә әсир һәм сакчылар керә. Баязид солтан яу киемнәреннән, ләкин ул теткәләнеп беткән.*

Т и м е р *(мыскыллы көлә).* Хуш килдең, бөек солтан Баязид Елдырым хәзрәтләре!

Б а я з и д. Мөшкел хәлгә төшкән солтаннан мыскыллы көлү куәтле ир эше түгел.

Т и м е р. Кичер мине, солтан, мин сине мыскылламадым! Мин синнән алда җинелгән ханнарны, әмирләрне, түрәләрне, падишаһларны, шаһиншаһларны, раджаларның язмышын күз алдына китереп елмайдым. Алар да әтәчләнде, Аксак Тимерне җинәрбез, дип хыялландылар. Беркатлы да булсалар булырлар икән. Умырткалары сынгач кына алар минем хаклы икәнемне, минем гаделлек сакчысы икәнемне аңладылар. Сина әйттем ләса, хат юлладым ләса. Күкләрнең вә җирләрнең хуҗасы Аллага шөкер, мина ул җиде икълимнең күбесен һәдия итте. Җиде икълимнең күбесе минем алдымда баш орды, алар буйсынарлык камыты киде. Чөнки мин: Аллаһ куйган чикләрдин хәттин ашмадым. Синең турыда да бөтен җиһан белә, синең нәселеңне дә, затлы каннан икәнеңне дә беләбез. Син шундый белемле, итагатьле кеше тәртәгә тибәргә тиеш түгел идең. Иленне, муллыгынны саклыйсың килсә, Мәккә юлларын талап торучы хәрами Кара Йосыфны тотып мина бир, дидем. Таланган кәраван ияләре, таланган калаларның башлыклары мина илче күндерделәр: алар канэчкеч башкисәр Кара Йосыфтан коткаруымны үтенделәр. Мин халыкның үтенеченә каршы бара аламмыни? Юксыллар, ярдәмгә мохтаҗларга ярдәм итмәсәм минем йокым кача. Син Кара Йосыфны тотмадың. Син аны тота алмадыңмы, әллә аны якладыңмы? Халыкларның ялваруына бакмадың. Бәс, икебезнең гаскәр орышачак дидем. Һәм синең кара тәкъдиреңә юл ачылачак, дидем. Тыңламадың акыллы кеше сүзен. Бу бичара хәлгә төшүеңә син бары тик үзең генә гаепле. Бу—үз кулларың белән утырткан әналә агачларның җимешләре. Мин сездән бик аз гына сорадым. Син шул сүзләремә колак салмыйча, минем теләгемә каршы булган гамәл кылдырдың, мин сине җиңдем. Мин сина кяферләр белән булган орышларыгызда ярдәм итәргә тәдбир корган идем. Синең кире холкың үз башыңа булды. Кызганыч, шулай килеп чыкты!

Б а я з и д. Харап иттең син Ислам дөньясын, әмир Тимер.

Т и м е р. Ни сөйлисең син? Мин Ислам өчен җанымны, канымны кызганмыйча гамәл кылам. Килешми бөек солтанга—нахак яла ягу, килешми. Мин сине кол шәкелендә тотмам. Син абруйлы кунак буларак минем хозурымда буларсың. Минем яуларымда катнашырсың, әгәр теләсәң, кылыч ал, атка мен, без Кытайны яуларбыз, аннан Аурупага, Юнан, Франк якларына сәфәр чыгарбыз да, диңгез кырыендагы илләргә хуҗа булырбыз.

Б а я з и д. Мин кылыч кешесе түгел

инде, Тимер. Мин кол, мин әсир. Син миңа нинди генә хөрмәт күрсәтсәң дә, нинди генә затлы кием кидерсәң дә мин солтан түгел. Син мине аңламассың, чөнки син солтаннар нәселеннән түгел!.

Т и м е р. Әйе, мин синең кебек затлы кан түгел, мангулдан азган чала татар, мин укымаган, язмаган, бары тик кылыч айкаган бәндә.

Б а я з и д. Шулай! Шуңа күрә, син дөньяның кая барганын белмисен, аңламыйсың, аңларга да теләмисең. Син Исламны эчтән жимерергә алынган Иблис! Син Коръәнне белер-белмәс надан монафикъ. Син Ислам исеменнән, Коръән исеменнән Пәйгамбәр исеменнән Исламга, Коръәнгә, пәйгамбәргә каршы гамәл кылучы монафикъ. Синең шушы наданлыгыннан чит патшалыкларның илчеләре, жасуслары, шымчылары бик нык файдалана. Алар өч бөек шәхесне талаштырырга, сугыштырырга, бер-берсен тар-мар итәргә сине котыртты. Син Туктамышны бетерден, син Баязид Елдырымны пыранзаран китерден. Ә христиан илләре, Аурупа синең шушы гамәлләреңне күзәтеп "Тамирланга рәхмәт" дип кул чабып, алкышлап тора. Ауропадан, йолкыш кына илдән, йолкыш кына бер илче килсә, син аны пәйгәмбәр күргәндәй, күтәреп аласың, мөселман илчеләрен син түбән табынга утыртасың. Синен Франк, Испания, Византия илләрендә мәшһүр буласың килә. Алар синең белән уйный, алар синнән көлә.

Т и м е р *(көлә)*. Син мине чыгырымнан чыгармакчы буласың? Юк, мин жинелүченең үте сытылганнан әйткән сүзләренә дикъкать итмим. Минем жинүем алардан өстенрәк. Кытайны алганнан соң син күрерсен. Мин Византиягә, Римга, Англиясенә чаклы атымның тоякларын бастырачакмын

Б а я з и д. Мин анынчы тормам, Тимер. *(Хәле китә.)*

Т и м е р. Ярдәм итегез, алып чыгыгыз! *(Баязидны алып чыгып китәләр.)*

Ч а п к ы н. Шаh Тимер хәзрәтләре Кастилия короленнән илчеләр кайтты.

Т и м е р *(айнып)*. Ә? Илчеләр! Араларында сәед Исрафил бармы?

Ч а п к ы н. Сәет Исрафил бар, тәкъсирем.

*Илчеләр керә.Карадәрвиш, Сакчы, Гайшә.*

Т и м е р. Хак! Мин саташам! Күземә күренәме миңа якын кешеләр? *(Жылый.)* Сәед Исрафил хәзрәтләре! Күрешер көннәрем дә булыр икән *(Кочаклашалар).*

К а р а д ә р в и ш. Тәкъсир, мин синнән башка яши алмыйм икән.

Т и м е р. Бу кем?

К а р а д ә р в и ш. Бу синен сөеклең Болгар ханы Габулланың кызы Гайшә бикә.

Т и м е р. Йа Аллам, син һаман миңа юл күрсәтәсең. Гайшәм бикәм...

Г а й ш ә. Әмирем! Мин дә синнән башка тора алмыйм икән? Нигә миңа Каситилия, нигә миңа Испания, нигә миңа корольләр, син булганда алар чүп кенә.

Т и м е р. Жаным, Гайшәм, күпме хатын-кызлар күрдем, сине оныта алмый йөдәдем. Күпме каннар койдым, сине оныта алмадым, күпме жаннар кыйдым, сине оныта алмадым.

Г а й ш ә. Кастилия короле чирләшкә, ул өйләнә алмый, синең бүләгенне кабул итә алмый. Аңа чыгар өчен мин христиан динен кабул итәргә тиеш идем, Аллам сакласын, диненнән язган—деннәннән язган.

Т и м е р. Күгелташ! Бу бәйрәм ләса, оештырыгыз табын, дәстархан.

К ү г е л т а ш. Баш өсте! *(Китә.)*

Т и м е р. Гайшәм бикәм кайткан! Мин Гайшәм бикәм хөрмәтенә Кытай илен басачакмын!

К ү г е л т а ш *(керешли)*. Рәхим итегез, буза, кымыз, шәрап, ачы бал, чишмә суы.

Т и м е р. Гайшәм бикә ни эчә?

Г а ш ә. Чишмә суы.

Т и м е р. Миңа шәрап салыгыз! *(Сарай әһелләре төпсәләргә куеп касәләр ташый.)*

*Гайшә сиздремичә генә Тимер касәсенә агу сала. Тимер йотлыгып эчә.*

*Бәйрәм башлана. Буталыш, шау-шу, мылтык ату, карнай кычкырту.*

*Тимер исерә төшә. Бәйрәм дәвам итә, Гайшә бикә һәм башкалар йөреп китә.*

*Янычар кыяфәтендәге Салазар керә.*

С а л а з а р. Тәкъсирем!

Т и м е р. Янычар! Син төгәл башкардың вазифаңны, Янычар. Сивас халкы исеменнән хат язып, илчеләр әзерләп җибәрү дә, Кара Йосыфтан зарланып, башка илләр исеменнән хатлар язуың да Баязидка муенчак кигезергә ярдәм итте. Ал!.. Күгелташ!

К ү г е л т а ш *(керә).* Әмерен, әмирем!

Т и м е р. Бу адәмгә һәдиян әзерме?

К ү г е л т а ш. Әзер, тәкъсир *(Кечкенә сандык бирә).*

Т и м е р. Һиндстан мәрҗәне, Дәһли алмазлары синә!

С а л а з а р. Тәшәккүр, пирем!

Т и м е р. Син үзең кайсы яклардан, Янычар?

С а л а з а р. Мин Кастилиядә туган, Баязид Елдырымның Изге Рим империясе гаскәрләре белән булган орышында әсир булдым. Менә, ничәмә-ничә ел Баязидка хезмәт иттем.

Т и м ер. Һәм мина да.

С а л а з а р. Сезгә дә, тәкъсир. Хәзер инде мин сезгә генә хезмәт итәрмен. Минем сезнең уң кулыгызда Кытайга барасым килә.

Т и м е р. Машалла! Барырбыз! Күгелташ! Янычарны казна хисабына куй!

К ү г е л т а ш. Башым өсте! *(Китә.)*

Т и м е р. Кастилия короле Һәнрихкә мин илчеләр җибәргән идем, барып житмәделәрме соң? Хәбәрләре юк!

С а л а з а р. Життеләр, тәкъсир. Король сезнең илчеләрне бик яхшы кабул итте. Инде кайтып житәрләр, шөт.

К ү г е л т а ш *(керә).* Тәкъсир! Бөек солтан Баязид Елдырым фани дөньядан бакыйга күчте.

Т и м е р. Иннә лилләһи вә иннә иләйһи рәжигун. Әсирлек хурлыгын кичерә алмады.

С а л а з а р. Аның үлүе яхшырак, тәкъсир. Ул мәгъруp кеше иде. Иреккә җибәрсәң дә ул яшәмәгән булыр иде. Баязидның билен сындырып, син Ауропага хисаплап бетергесез игелек кылдың. Иисус Христос синең бу яхшылыгыңны онытмас! Ул сине җәннәткә кертәчәк, сир.

Т и м е р. Иисус Христос? Мине җәннәткә кертәчәк?

С а л а з а р. Аптырамагыз, сир, безнең Иисус, сезнең Исагыз, кай якларда аны "Гайсә" дип тә йөртәләр.

Т и м е р. Гайсә пәйгамбәрме мине җәннәткә кертәчәк?

С а л а з а р. Әйе, Иисус Христос, пирем.

Т и м е р. Ташлале Христосыңны! Гайсә диген.

С а л а з а р. Гайсә диден ни дә, Иса диден ни дә, Иисус диден ни, барыбер аларның барысы да бер христиан алласы!

Т и м е р. Тукта, тукта, ничек инде Гайсә Алла булсын! Кәфе-ер! Алла берәү генә. Син монафикъ, син мәҗүси, син потпарәст, син берничә аллага табынгансың булып чыга! Сине яргуларга, үтерергә кирәк. Мин гомерем буе җиде икълимнен бишесен кылыч белән айкадым. Җир йөзен сиңдәйләрдән пакъләндерү өчен. Нәҗес, кит яныбмнан! Син Баязид янына җибәрелгән жасус, шымчы, әләкче, Иблис. Мин сине суям!

С а л а з а р. Мин үз вазифамны башкардым инде, мин христианнарны синең кулың белән коткарып калдым. Син Елдырымны бот арана тыгып куйганнан соң Византия—бөтен Көнбатыш илләре бәйрәм итә. Мине синең суюың гына куркыта алмый, Шаһ Тимер, Әмир Тимер, падишаһ Тимер! Бәйрәм итә христиан дөньясы. Сине, Шаһ Тимер, Ватикан, чиркәү, христианнар изге итеп канунлаштырачак, мин моны үз өстемә алам. Син христиан изгесе, син Исламның тамырына балта чапкан каһарман, син мәңгелек.

Т и м е р *(саташа бара).* Син саташкан яки мин саташкан.

С а л а з а р. Мин саташкан, сир! Син безнең католик динен, Ауропаны Баязидтан коткардың. Сине Христос җәннәткә кертәчәк, син аның Җирдәге хәлифе, аның кушканнарын үтәүче. Рәхмәт синә. Ауропа илләре синең бу батырлыгыңны онытмас, Кастилия, Португалия, Франция, Византия сине изге Георгий ордены белән бүләкли. *(Хачлы орден алып, Тимер янына килә. Аның күкрәгенә хачны калый.)*

Т и м е р. Мин саташам бугай, мин төш күрәм. Алла да мин шундый бер төш күргән идем, имеш, пәйгамбәребез Мостафа салаллаһу галәйһи вәссаллам, минем күкрәгемә тәре-хач калаклап куйды. Кычкырып уянып киттем. *(кычкыра)* мине уятыгыз, мин саташа-ам!

*Кунаклар, яраннар йөгерешә.*

К ү г е л т а ш *(керә).* Тәкъсир! Ни булды?

С а л а з а р. Берни дә булмады, Күгелташ.

Г а й ш ә. Әмирем, күкрәгеңдә ни ул? Бу бит Кастилия короленең батырларга бирелә торган ордены.

Т и м е р *(горур)*. Әйе, кара алтыннан эшләнгән бу нәмәстәкәйне миңа төшемдә пәйгамбәребез Мостафа салаллаһу галәйһи вәссәллам үз кулы белән такты.

Г а й ш ә. Әстәгъфирулла!

*Тимерне барысы да җиңү белән, Гайшәнең кайтуы белән, Кытайга һөҗүме белән җиңүләр теләп котлыйлар. Тимер авырая бара.*

К ү г е л т а ш. Әмирем! Ятып торыйк, Кытайга яуга чыгар алдыннан сиңа ял кирәк. Алда Кытай диварлары тора.

Т и м е р. Аксак Тимер каршысында алынмаган дивар юк!

*Күгелташ Тимерне алып чыгып китә.*

К а р а д ә р в и ш. Булдымы?

Г а й ш ә. Булды.

С а к ч ы. Озакламас!

*Кинәт акырган аваз ишетелә. Аксак Тимер кулына кылыч тотып атылып чыга.*

Т и м е р. Кытайга-а! Җиде икълимнең бишенчесен яуларга-аа! Ачыгыз Коръән, анда минем бу яңа сәфәрем турында ни язылган икән? Ач, Исрафил хәзрәт!

К а р а д ә р в и ш. Фетнә тулысы белән юк ителгәнгә чаклы бары тик Аллаһ дине калганчыга кадәр сугышыгыз!

Т и м е р. Сугышыгыз! *(Гайрәт белән кылыч кизәнеп җиргә кадый, үкереп җылый.)* Димәк, мин гомерем буе хаксызга кан койган булып чыгаммы? Сәед Исрафил хәзрәт, сәедләр мине хата юлга өндәгәнмени? Алар Коръәнне юри бозып аңлатканнармыни? Баязид, Баязид, ник сөйләдең син миңа бу сүзләрне? Янычар! Янычар! Син шаярдың гына шулаймы? Син христиан җасусы түгел, син бит чын мөселман. Син миңа кызык булсынга гына уйлап чыгардың бит бу тәрене! Коръәндә язылган бит: ля кум дине кум вәлиаддин, кяферләргә үз диннәре, безгә үз динебез, дигән бит Аллаһу Тәгалә. Нигә миңа моны элек аңлатмадыгыз? Сәед Исрафил син дә мине алдадыңмы, суям! Үтерәм! *(Баязид Елдырымның рухы пәйда була.)* Баязид?

Б а я з и д. Туктат син кан коюларыңны, шаһ Тимер.

Т и м е р. Син дә кан коясың бит, Баязид.

Б а я з и д. Мин Ислам дәүләтләрен киңәйтү өчен сугышам.

Т и м е р. Мин дә Исламны көчәйтү өчен кан коям. Мин Җиһад юлында.

Б а я з и д. Син Иблис юлында, Тимер. Йөрмә Кытайга. Шушында туктап кал.

Т и м е р. Кытай мәҗүсиләр, потпәрәстләр иле.

Б а я з и д. Ля кум дине кум вәлиәддин. Һәркемнең дине үзенә. Сугымчы кәсапчылар да йөзәрләгән малның җанын кыйганнан соң туктап кала, сөннәтче бабалар да йөзләгән баланы сөннәткә утыркач, гамәлен туктата. Чөнки кан тотачак. Алар гаделлек кысаларында кан койса да, вакыты житкәч, туктап кала. Син адым саен мөселман канын коясың. Аларның каны сине бер тотар бит, Тимер. Туктат кан коюыңны!

Т и м е р. Мин Коръән буенча гамәл кылам.

Б а я з и д. Синең нәселең асылда мангул, син мангулдан азган чала татар. Синең ата-бабаң мәҗүсилек, ярымбуддачылыктан Исламга күчкән. Ислам сезнең телегезгә менгән, рухыгызга сеңмәгән. Сез намазны фәкать үзегез өчен генә укыйсыз, ә чын мөселман башкалар файдасы өчен Аллага гыйбадәт кыла. Вәхши бары тик үзе өчен генә ураза тота, намаз укый. Аның тупас-каткан бәгыре үз карыны турында гына кайгырта. Зиһенле адәм башкаларның иминлеге турында уйлый. Коръәнчә гамәл кылмыйсың син, Шаһ Тимер. Син хыянәт иткән яшь хатыныңның башын чабып өзең. Ул мөселман иде. Коръәндә тугры булмаган хатынны үтерергә димәгән, тиешле җәзасын гына бирергә, дигән, ихлас тәүбә итсә, гафу итәргә, аңа кагылмаска кушкан. Коръәнчә булса, син мөселманның канын агызмас идең. Син Аллаһу Тәгалә вазифаларына үреләсең! Моннан да олы гөнаһның булуы мөмкинме? Син кя-

ферләр белән бер басмада торасың. Сина Аллаһың Әфгандагы Исфизар каласының ике мең мөселманың тереләй җиргә күмәргә рөхсәт иттемени? Исфагандагы житмеш мең кешенең баш сөягеннән тау өяргә сина пәйгамбәрең куштымыни? Минем карамактагы Сивас каласын алганнан соң тыныч тормышлы дүрт мең мөселманны тереләй күмәргә сина Коръән куштымыни? Йөз мең индусның башларын чаптыру да синең саваплы эшләреңә языламы? Бөек Болгарны җир белән тигезләвең өчен дә син Аллаһтан әҗер көтәсеңме? Сәбәпсезгә үтерелгән хайван өчен дә Аллаһу Тәгалә җавапка тартырмын, дигән, сәбәпсезгә үтерелгән бихисап кешенең каны, җаны өчен дә җәннәт өмет итәсеңме? Син кяфер, синең урының җәһәннәмдә! Ул сина хас! Син гомереңбуе акыл белән эш йөрттең, син гомерең буе ике маңгай күзең белән генә дөньяга бактың. Синең күңел күзең сукыр. Син күңел күзең сукыр килеш Коръән укыйсың, аның асылына төшенә алмыйсың. Күңел күзең сукыр булганга син миһербансыз!

*Баязид юк була.*

Т и м е р *(башын ике кулы белән тотып иелеп төшә).* Беләм... Күңелем кошы күкрәк читлегемне ярып иреккә чыгып очар... минем соңгы тәхетем Аллаһ янында... ул җан өрүче дә, ул җанны алучы да... Мин үлгәч, чәч-баш туздырып, акырып җылаган булып кеше көлдермәгез... Кайсы хатыннарның ирләрен акырып-җылап үлемнән алып калганнары бар? Киемнәрегезне ерткалап әрәм иткәнче сез мәетем янында тыныч кына Фатиха сүрәсен укып утырыгыз. Аллаһтан минем гөнаһларымны ярлыкавын үтенегез...

*Өрәкләр чыга, аларның барысы да башсыз. Алар әкренәйтелгән кинокадрлар кебек Тимерне урап ала. Ул кинәт кычкырып аягүрә баса.*

Ө р ә к л ә р. Син алдың безнең җанны-ы! Кая куйдың җаныбызны-ы! Кайтар җаныбызны-ы, Аксак Тиме-ер! Дәмәшкъта син чаптырган башлар бу, җиде йөз мең баш... Кайда безнең башлар? Ялга син безнең башларны...

Т и м е р. Каравыл! Сакчылар! Кемнәр бола-ар! *(Өрәкләр китә.)* Ля кум дине кум вә лиаддин... *(Саташа бара.)* Мин вәхшиме, Баязид? Мин вәхши түгел, мин мөселман, мин һәрвакыт гадел булдым... Мин кяферләр белән бер басмада, мин гяур... Мин монафикъ. Ю-ук, мин кяфер түгел, мин монафикъ түгел, мин Аллаһның юлында булдым... Пәйгамбәребез Мөхәммәд... Мостафа... салаллаһу... галәйһи вәссаллам... Житмеш мең баштан тау өйдердем... йөз мең кешенең башын чаптырдым, ун мең кешене тереләй җиргә күмдердем... Су-у, тамагым яна-а, су-у. *(Гайшә аңа су бирә.)* Бу агу-у, яндыра-а, мине агуладылар! А-а...

*Халсезләнә бара. Сүзләре аңлашылмый, ул ава-түнә чаршау артына кереп китә дә егыла.*

К ү г е л т а ш. Җан тәслим кылды бөек Тамирлан!

Г а й ш ә. Этләргә этләрчә үлем!

К а р а д ә р в и ш. Акыллы, бөек адәм иде, ләкин зиһенсез иде, мәрхүм.

К ү г е л т а ш. Гайшә бикә, син иректе, син Болгарына кайтып китә аласың.

Г а й ш ә. Минем Болгарым юк. Мин абыйларым янына Казанга кайтып китәм.

К ү г е л т а ш. Хәерле юл. Сезнең монда калуыгыз хәвефле булыр. Хәзер әмир вафатыннан соң тәхет өчен сугыш башланачак. Исрафил хәзрәт, Мостафа бәк, сез дә иректе. Дүрт ягыгыз кыйбла.

К а р а д ә р в и ш. Күгелташ, безнең күптәннән инде дүрт ягыбыз да кыйбла.

К ү г е л т а ш. Астарлы сүзеңне аңлатып бир, хәзрәт.

К а р а д ә р в и ш *(Испания монахы кисемендә кала).* Әверелеш сәнгате!

К ү г е л т а ш. Әстәгъфирулла! Сәед хәзрәт! Сез Кастилиядә иман алыштыргансыз түгелме!

К а р а д ә р в и ш. Испаниядә түгел, без монда иман алыштырдык, Күгелташ. Без асылда католик монахлары!

К ү г е л т а ш. Әмирем! Йа Алла, димәк, башка сәедләр дә чын сәед түгел, сәед чапаны бөркәнгән христиан монахлары булып чыга. Менә ни өчен алар Коръәннең сугышырга өндәгән урыннарын гына ачканнар икән.

К а р а д ә р в и ш. Хакыйкать шул-

дыр ки, Күгелташ, Коръән сугышырга өндәми, ул бары тик азатык сугышын гына Җиһад дип саный. Коръән йортына басып кергәннәргә каршы сугышырга куша. Җиһад басып алу сугышы түгел, Җиһад гадел сугыш. Тимер Коръәннең бер өлешен генә үз файдасына алган.

К ү г е л т а ш. Ул сәедләргә ихластан ышана иде.

К а р а д ә р в и ш. Исламны сәед булмаган ялган изгеләр боза килде, Күгелташ. Динне тамырыннан белмәгән мөселманны алдавы бик җиңел. Бу яһүдтән азган мөселман галиме Әбу Сәбәдән килә. Ул Исламның нигезенә еллар буена эчтән кимереп ята торган мәзһәб кертте, шигыйлар мәзһәбе. Артык аерма да юк кебек, ул бары тик Галине дә хәлиф итәргә кирәклеген язды. Әнә кара, шигыйлар белән сөнниләр хәтта бер-берсенә кыз бирмиләр, өйләнмиләр. Мөселман кешесе бик ышанучан, беркатлы ул. Мәрхүм Тимер акыллы иде, ләкин анда зиһен юк иде. Зиһенсезлек Исламны астан, эчтән кимерә. Һәрхәлдә мин, мин генә түгел, король, король генә түгел, бөтен католиклар, католиклар гына түгел, бөтен Аурупа Аксак Тимергә мәңге рәхмәтле. Хуш, Күгелташ, Тамерланның тугры яудашы, бәхил бул! Безне Испаниядә Һәнрих Өченче король көтә.

К ү г е л т а ш. Төштер бу.

Д ә р в и ш. Төш кенә булса икән, бу өн—Күгелташ, Испания короленең кулы монда хәтле житә. Яшәсен христианар! Алла безгә үзе ярдәм итә! *(Китәләр.)*

К ү г е л т а ш *(шашар дәрәҗәдә).* Йа, кодрәтле Аллаһым, дөнья буталды... Нәрсә соң бу? Аллаһ юлында, дөньяда тәртип урнаштырабыз, дип, без бөек әмир Тимер бәк белән кяферләргә хезмәт иткән булып калабызмыни? Никадәр куәт, никадәр гайрәт сарыф иттек, никадәр зиһен салдык! Никадәр каннар койдык, никадәр җаннар кыйдык, барысы да Исламга зараргамыни? Әмирем, тор, аягыңа бас! Терел дә тормышынны яңадан башла! Хаталарыңны төзәт, гөнаһларыңны ю! Ятим калган миллионлаган сабыйлардан син гафу сора! Аллаһ сине ярлыкасын! Син инде Аллаһ каршында җавап тотасындыр! Ярлыкармы безне Аллаһ, әмир Тимер?

## Корольнең соңгы көне

*Атка атланган Карадәрвиш белән Сакчы ыргып чаба. Аттан төшеп алар көймәгә утыра. Көймәдән соң тагын иярдә менәләр; ыргып, томырылып чабалар. Атларын яндырганчы куалар. Ниһаять, алар Толедога кайтып житте.*

*Король сарае. Король янында көмәнле королева Изида утыра.*

К а н ц л е р. Король Һәнрих Кастильский җәнапларының чакыруы буенча илчеләр килде. Арагон короле Хуан Беренче илчеләре *(Тантаналы рәвештә илчеләр керә, йола йөгенүләре биюгә әверелә)*, Наварра короле Карл Өченче илчеләре, Византия императоры Мануил Икенче илчеләре, Франция короле Карл Дүртенче илчеләре....

Һ ә н р и х. Хөрмәтле корольләрнең хөрмәтле илчеләре. Мин сезне бүген католик диненең зиһниятле шәхесләре аркасында ирешкән бөек җиңүләребезне бәйрәм итәр өчен чакырдым. Күрше мөселман маврларының куәтләре какшады, төрек солтаны Баязид тар-мар ителде, үзе шушы кайгыны кичерә алмыйча вафат булды. Бөек татар ханы Туктамыш, Идегәй гаскәрләре хәзер вак төркемнәргә аерылды, үзләре һәлак булды. Иң куркыныч Аксак Тимер дә, ниһаять, җинелде, ул Кытайга сәяхәт вакытында вафат булды. Мин бүген үземнең исемемнән, сезнең исемнән шушы җиңүдә катнашкан каһарманнарыбызны күп илләрдән килгән иң олы бүләк, орденнар белән бүләкләргә тәкъдим ясадым, һәм ул бүләкләр әзер. Гранада халифен дәүләт эшләреннән аерып, аның хәрби куәтләрен зәгыйфьләндерүдә үзен кызганмаган зат—ул дөнья Леонора. Ул Гранада хәлифе Мөхәммәднең башын әйләндереп, принцлар арасында низаглар чыгуга сәбәпче булды. Нәтиҗәдә Кастилия Гранададан аерылды. Хәзер Гранада үзе Кастилиягә салым түли баш-

лады. Леонора өч илнең ордены белән һәм гомере буе түләнә торган алтын белән айга мең сум франк пенсия белән бүләкләнә. *(Тантаналы чыгыш, доньля Леонорага бүләк тапшырыла.)* Икенче баһадирыбыз, ул минем җан дустым сеньор Салазар. Анын хезмәте бәһаләп бетергесез, ул Аксак Тимер белән Баязидны кара-каршы сугыш кырында очраштырган зат. Ана бер замок, биш дәүләтнең каһарманы дигән орденнары, ике мең алтын франк пенсия. *(Алкышлар.)* Берләштерелгән Испаниянең онытылгысыз, мәнгелек каһарманы, утнысуны кичкән монахы Пилигрим Руи белән анын якын дусты сеньор Олонсо, икесе ике миллион гаскәрне җингән каһарман. Алар Аксак Тимер белән Туктамышны, Тукмыш белән Идегәйне, Аксак Тимер белән Болгар падишасы Габдулланы чәкәштергән затлар. Икесе дә биш илнең алтын орденнары белән бүләкләнә. Пилигрим Руига ике замок, дон Олонсога бер замок, өчәр мең алтын франк пенсия беркетелә. *(Алкышлар.)* Яшәсен католик зиһнияте! Яшәсен Ауропаны коткарган каһарман испаннар! Бәйрәм итәбез!

*Тантана, шу-шу, төпсәләр белән шәраб чыгарыла, тәгам бирелә, бииләр. Алгы планда Һәнрих белән Руи (Бонифаций).*

Б о н и ф а ц и й. Эшнең яртысы бетте, сир.

Һ ә н р и х. Котлыйм! Рәхмәт сина, Бонифаций. Син булмасаң, мин бетә идем.

Б о н и ф а ц и й. Бетмәс өчен тагын көрәшәсе бар.

Һ ә н р и х. Инквизитор Бонифацийнын ялган икәнен фаш итү синең белән минем бурыч.

Б о н и ф а ц и й. Кардинал Бардини мине таныды булса кирәк.

Һ ә н р и х. Сак бул!

Б о н и ф а ц и й. Син дә сак бул, королем!

*Һәнрих королеваны биергә чакыра. Бонифаций янына кардинал Бардини килә.*

Б а р д и н и. Котлыйм сине Пилигрим Руи-Бонифаций. *(Кулә.)* Сокланам мин сина Бонифаций дустым. Тсс! Синең серне бер мин генә беләм. Сакчын Олонсо белә булыр. Өч кеше белгән сер сер була алмый инде ул. Ихтимал, король дә бу турыда беләдер... Кайларга гына барып чыкмагансын син, дускай.

Б о н и ф а ц и й. Сездән качып йөри торгач, мин дөньяны ике кат әйләнеп чыктым, кардинал. Ә сез мин югында монда күпме гөнаһсыз җаннарны теге дөньяга аткардыгыз икән?

Б а р д и н и. Тиешлесенең барысын да. Әле аткарасылар күпме. Син Һәнрих король белән генә Бөек Кардиналның көчен зәгыйфьләндереп була, дип уйлыйсын. Бу тиле кеше хыялы. Инквизициягә каршы барган кеше чиркәүдән мәхрүм ителә, анын мәетен зиратка да җирләтмиләр.

Б о н и ф а ц и й. Минем бу янаулардан куркыр вакытым узган, кардинал.

Б а р д и н и. Йә, король белән бергәләп Бонифаций янына барып: син ялган, менә ул чын Бонифаций, дип әйтсәгез ни буласын күз алдына да китерә алмыйсыз. Мин сина ярдәм итәргә әзер, мин сине тәхетенә кайтарырга да телимдер, ләкин бу эш мөмкин түгел, кардиналларнын күбесе бу Бонифацийны хуплый, ялган икәнен белсәләр дә аларга шушындый Бонифаций кирәк, аларга таларга, көчләргә булсын, синең кебек пакь Бонифацийнын бер генә кардиналга да кирәге юк, хәтта халыкнын үзенә дә кирәгең юк синең. Син юкка чыккан идең бит инде, сине: юлбасар Педро, дип тотып алганнар да асканнар, дип тә ишеттек.

Б о н и ф а ц и й. Әйе, мине: Педро юлбасар, дип тотып, үлемгә хөкем иттеләр. Ләкин мин исән, күреп торасын.

Б а р д и н и. Ә син: мин—Бөек Кардинал! Юлбасар Педро минем урында гы ялган түрә, дип кычкырдыңмы, ләкин Бөек Кардинал икәнлегенә синең исбатын юк.

Б о н и ф а ц и й. Исбатым бар!

Б а р д и н и. Бу җинүләрдән соң сез ни кылмак буламсыз инде? Әлбәттә, Педронын ялган түрә икәнен фаш итәргә алынначаксыз.

Б о н и ф а ц и й. Анысы инде безнең эш, кардинал де Бардини җәнаплары. Сабый чактагы якын дустым, бер-беребезне коткарырга ант эчкән дустым, Бардино! *(Китә.)*

Б а р д и н и. Багарбыз, Руи де Бонифаций, кем алдан өлгерер. *(Ишарә ясый, Балтазар күренә. Ул бөкрерәк. Норсыз чырайлы, үте сытылган бер бәндә.)* Пилигримнан күзеңне алма, сиздермичә күзәт. Ике мең алтын мараведи кесәңдә булыр.

*Икесе ике якка китә. Бәйрәм дәвам итә. Һәнрих белән Леонора очраша.*

Л е о н о р а. Һәнри!

Һ ә н р и х. Леонора!

Л е о н о р а. Мин һаман сине оныта алмыйм. Өйләнә алмыйм, дип алдасаң да, син мине маврга сатсаң да, мин сине барыбер өзелеп сөям.

Һ ә н р и х. Алай әйтмә, Леонора! Күреп торасың, мин үзбаш кеше түгел. Корольләрдән дә ирексез кеше дөньяда юк. Без дәүләт турында уйларга тиеш, дин турында. Кичер мине.

Л е о н о р а. Кичердем инде. Минем белән бер биесәң тагын да ныграк кичерермен.

Һ ә н р и х. Биим, Леонора, рәхәтләнеп биим, ләкин бу минем синең белән соңгы биюем булыр. *(Бииләр.)*

Л е о н р а. Ни өчен? Сарай гайбәтләреннән куркасыңмы?

Һ ә н р и х. Юк, мин гайбәттән курыкмыйм. Минем гомерем аз калып бара.

Л е о н о р а. Һәнри!

Һ ә н р и х. Шулай, жаным. Хуш! Бәхил кал. *(Каты ютәлли башлый, бию туктый, барысы да король янына жыела.)*

С а л а з а р. Ни булды, Һәнрих, король жәнаплары?

Һ ә н р и х. Хәлем китте.

Л е о н о р а. Һәнри!

И з и д а. Король, сиңа ни булды?

*Һәнрих буылып ютәлли, Бонифаций йөгереп килеп, аның авызына дару сала, король тынычланган кебек була, аны алып кереп китәләр. Бәйрәмнен яме китә. Бонифаций ялгыз кала. Арттан кара шәүлә булып Балтазар керә.*

Б а л т а з а р. Пилигрим жәнапләре, мин сезнең батырлыкка шаккатам... Минем исемем Балтазар.

Б о н и ф а ц и й. Балтазар? Кайдадыр ишеткәнем бар бу исемне, гажәеп матур яңгырашлы исем.

Б а л т а з а р. Мине бозык хатын урамга ташлап киткән. Монахлар табып алып, мине чиркәүдә үстерделәр.

Б о н и ф а ц и й. Балтазар! Балтазар! Син...

Б а л т а з а р. Тумыштан гарип мин, сеньор. Мине монахлар Бөкре шайтан, дип йөретә. Мин аларга ачуланмыйм. Шайтан булгач, мин шайтан вазифаларын үтәргә тиеш. *(Хәрәкәт ясый, Бонифаций эчен тотып бөгелеп төшә.)*

Б о н и ф а ц и й. Койрыклы йолдыз узып киткәндә тагын бер бала туар, аны-сы дөньяга мәкер ташыр, диләр. Син башкисәр Педро юлбасарның уйнаштан туган углы Балтазар булып чыктың.

Б а л т а з а р *(ярсып тагын пычагын яралыга батыра).* Син уйнаштан тумаган, ләкин син миннән дә гарибрәк, Пилигрим. *(Китә. Сакчы күренә.)*

С а к ч ы. Бонифаций! Йа Исусе Христосе! Бонифацийны үтергәннәр.

С а л а з а р *(король ягыннан атылып чыга).* Король жәнаплары жан тәслим кылды.

С а к ч ы. Бонифаций!

С а л а з а р. Ни булды? *(Бонифацийны күрә.)* Атам, атакаем!

*Б о н и ф а ц и й* (соңгы сулышы белән). *Улым, Салазар... мине...*

С а л а з а р. Атам, атакаем!

Б о н и ф а ц и й. Салазар... улым... *(Үлә.)*

*Уртага жыелалар. Хатын-кызлар илаулап жылый.*

К а р д и н а л. Икесе дә вакытсыз вафат. Әмма бу ике каһарманны Испания онытмас, аларның жанын кыючы жинаятьчеләрне инквизиция һичшиксез эзләп табачак һәм тиешле жәзасын бирәчәк. Аме-ен!

*Ирләр хоры жыела. Алар мәет өстендә укыла торган доганы хор белән жырлый.*

С а л а з а р. Ауропаны, христианнарны мөселманнар, татарлар мурыннан коткарып калучыларның рухы жәннәттә булсын!

Х о р. А-аме-ен!

*Сарай эчендә хатын-кыз кычкырган*

*аваз, аннан соң яңа туган бала тавышы яңгырый. Эчкәредән кулына биләүле бала тоткан Дая чыга.*

Д а я. Испания короле Һәнрих Өченченең улы, тәхет варисы дөньяга килде.

Х о р. Аллилуйя... Аллилуйя...

*Чиксез кин, чиксез биек күктә канатларын җилпемичә генә мәгърур бөркет оча. Аста таулар, тарлавыклар, тау елгалары, иген кырлары җәйрәп ята.*

*Кайнарташ аланындагы ташка таба кара елан шуыша. Бәхетсезлегенә күрә, урман тычканы елан каршысына ук килеп чыкты. Кара елан яшен тизлеге белән тычканны чакты. Тычкан чикылдап алды да юлын дәвам итте, ләкин ерак йөри алмады, иләс-миләс килеп егылды. Елан бичараны кабып йотты. Аннан соң ризыкны ләззәтле йокы белән эшкәртер өчен таш өстенә шуыша башлады.*

*Үткер күзле бөркет канатларын җыйды да аска, туп-туры Кайнарташ аланына таба атылды. Бер мәлдән инле тук елан ач бөркетнең тырнаклары арасында боргалана иде.*

*Бераздан еланнан бушаган кайнар таш өстенә яшь егет белән яшь кыз килеп утырды.*

Тәмам.

***Соңгы сүз:*** *Еллар узар, аз гомерле король Һәнрих Өченче башлап җибәргән изге эш тагын да куәтләрәк дәвам итәр. Аннан соң Испан тәхетенә утырган корольләр, бигрәк тә король Фердинанд белән королева Изабелла заманында (унбишенче гасыр азагы, уналтынчы гасыр башында) мавларны куып, Испания Америка кыйтгасындагы бик күп җирләрне яулап алыр һәм иң куәтле дәүләтләрнең берсенә әверелер. Америка кыйтгасында испан телле берничә дәүләт корылыр.*

*2005*

*Алхәбәр. «Казан утлары»—2008.*

Радик Фәизов

## ЗАБАСТОВКА

ТОРМЫШ ЯЗГАН ХИКӘЯЛӘР

Совет хакимияте чорында берниндә ачыктан-ачык ризасызлык белдерүләр, эш ташлаулар булмады дигән фикер яши. Дөрес түгел бу. Безнен Магнитогорскида да булды андый забастовкалар. Хәтта бер генә дә түгел, ике тапкыр. Һәм аларның икесенә дә мин үзем шаһит булдым.

...Кешеләр генә үтеп йөри торган тар ишектән керсәк, андагы хәлләр! Депо тулы халык, тик берсе дә эшләми. Кешеләрнең йөзендә ачу, тәвәккәллек. Ниндиләр шомлы халәт...



Резеда
Вәлиева

# ЗӘҢГӘР ЧӘЧӘК, ХӘЛЕҢ БЕЛӘМ...

## Зәңгәр чәчәк

**Зәңгәр чәчәк, күзләреңдә**
**Энҗеме соң, яшьме соң,—**
**Ник карыйсың мөлдерәтеп,**
**Ник бер сүз дә дәшмисең?**

**Зәңгәр чәчәк, моңсуланып,**
**Карама миңа һаман.**
**Мин үзем дә синең кебек**
**Сагыну утында янам.**

**Зәңгәр чәчәк, хәлләреңне**
**Әйтмәсәң дә беләм бит,**
**Авыр икән аерылулар,**
**Сагынулардан үләм бит...**

**Зәңгәр чәчәк, өзгәләнеп,**
**Сарылма арышларга.**
**Буйсынмас әмәлләр юктыр**
**Язылган язмышларга...**

## Күл буенда

**Күл буенда ялгыз бер Тал,**
**Башкаен суга иеп,**
**Өзгәләнеп яшен түгә,**
**—Сагынам ла, сагынам...—диеп.**
**Керфекләреннән өзлексез**
**Мөлдер-мөлдер яшь тама,**
**Шул сылуның аһ-зарыннан**
**Моңга тулгандай һава.**

Резеда ВӘЛИЕВА—*шагыйрә; күпсанлы китаплар («Якты йолдызым», «Китмә, Сөю», «Күңелем гөлләре» һ. б.), популяр җырлар авторы. Казанда яши.*

—Ничек очрадың юлымда
Җаным янган чагында,
Мин дә утта бит, бәгърем, дип,
Туктап калдым янында.
Күз яшьләрен сөртә-сөртә,
Әйттем:—Талым, сабыр ит.
Сөйлә миңа хәлләреңне,
Ялгыз башка авыр бит...
Йөрәк сагышын түгәргә
Мине көткәндәй, Талым,
Талгын җилдә бөгелә-сыгыла
Сөйләп китте аһ-зарын:
—Яши иде янәшәмдә
Баһадирдай бер Тирәк,
Гайрәтле иде, мәхәббәтле,
Андыйлар илдә сирәк.
Янымда аның булуы
Миңа бик кирәк иде,
Тормышыма ямь иде ул,
Җаныма терәк иде.
Кичләрен мин, аңа баглап,
Җырларым җырлый идем,
Ул, талгын гына тибрәлеп,
Таң калып тыңлый иде.
Рәхәт иде яшәүләре,
Бәхетле иде җаным,
Дөньяларда безнең кебек
Парлар булырмы тагын?..
Ачы язмыш давыллары,
Тамырларын каерып,
Алып китте бәгыремне,
Йөрәгемнән аерып...
Инде юк парым, канатым,
Бу җирдә ялгыз яшим.
Җилләр йолкый толымнарым,
Сыкранып түгәм яшем...

Тыңладым да, авыр сулап,
Әйттем: Әй, моңлы Талым,
Сабырлык сорыйк Ходайдан,
Сабырлык сорыйк, җаным...

## Күзләр җитә...

Йөзләреңдә нурлар булып янар өчен,
Күзләреңнән яшьләр булып тамар өчен,
Шул күзләргә тик бер генә багар өчен,
Нишлим икән, әйтче, бәгърем, нишлим икән?
Хисләремне упкыннарга атыйм микән,
Әллә синнән ераккарак качыйм микән,
Әллә йөрәк серләремне ачыйм микән,
Нишлим икән, әйтче, бәгърем, нишлим икән?
Нигә күрдем таңдай якты йөзләреңне,
Ник тыңладым «Сөям», дигән сүзләреңне,
Онытa алмыйм сагыш тулы күзләреңне,
Нишлим икән, әйтче, бәгърем, нишлим икән?

Юк, чакырма мине кайнар кочагыңа,
Җаным атма татлы газап учагына,
Күрәсеңме, сары яфрак тәрәз чиртә,
Хуш, бәгърем, җиһаннарда күзләр җитә...

## Сайрар кош идем мин...

*Кайгылардан җаннар азат түгел,*
*Кара үлем җирдә барында...*

Сайрар кош идем мин
Иркен күгемдә,
Тик якты җырлар
Иде күңелемдә.
Яшәдем җырлап
Сөю турында,
Үз Кояшымның
Назлы нурында...
Яшәдем бәхет—
Шатлыкка тулып,
Гөлләр илендә
Сандугач булып...
Яз дип тормадым,
Көз дип тормадым,
Җырладым һаман
Бәхет җырларын.
Иртәләрем гел
Чат аяз иде,
Көзләрем гүя
Җылы яз иде.
Сизмәдем ничек
Гомер үткәнен.
Сизмәде күңелем
Ниләр көткәнен...

Чат аяз көндә
Яшьнәде яшен.
Каралды күгем—
Сүнде Кояшым...
Сүнде Кояшым,
Гөлләрем сулды.
Илһам канатым
Каерылды, сынды...
Инде мин сайрар
Сандугач түгел,
Иртәсен-кичен
Сагышта күңел...
Кояшын сагыныш
Сызлана күңел.
Күрәсең, бәхет
Гомерлек түгел.
Гомерлек түгел...

## Улларым, күз нурларым

Иң беренче җырларым
Сезнең өчен җырладым,
Сездер илһам чишмәләрем—
Улларым, күз нурларым.

Сикәлтәле юлларым—
Кайгыларым, уйларым,
Кайгыларым җиңеләйтә
Улларым, күз нурларым.

Нәүмизлекне тоймадым,
Мәхәббәтем җуймадым:
Мәхәббәтем җимешләре—
Улларым, күз нурларым.

Ялгыз аккош булмадым,
Кыяга атылмадым,
Иңнәремдә пар канатым:
Улларым, күз нурларым.

Җырлавымнан тынмамын,
Бәхетемне зурлармын.
Рәхмәт сезгә, бәгырьләрем—
Улларым, күз нурларым!

Кыскарадыр юлларым,
Сиңа сузам кулларым:
Хәвефләрдән сакла, Раббым,
Улларым—күз нурларым...

Хәсән
Сарьян

# ТУГАН ЯК МОҢЫ

Карта битләрендә анын сурәте сәламәт кеше йөрәгенә охшап тора. Ул—Башкортстан, минем туган жирем. Йөрәктәге кан юллары шикелле, анын туфрагын да бик күп елгалар сугарып үтә. Шуларнын ин өлкәне, халкыбызга ин якыны—былбыл монылдай гүзәл Агыйделдер.

Агыйдел!

Бармы безнен чын татар жырларында синнән дә күп жырланган гайре бер елга!..

Әгәр дә мин елына бер сина кайтып, чабатасыз малай чагым кебек, иртә танда салкын чыклар ярып буйларынны бер әйләнмәсәм; чык күзедәй ак суында сары сагышларымны бер басмасам; бабамнарнын сөяге түшәлгән жылы туфрагына битем куеп орынмасам,—мин үземне башка жирдә, хәтта Казанымда да бу тикле дә нык ватанлы тоймас идем.

И иртәләрен ак томанлы Ак Иделем!..

Мин Агыйделнен түбән карасан йөрәкләр купмалы Төбә яры читендә басып торам. Миннән бик түбәндә, Кызыл яр тирәли, кыелып-кыелып керәшәләр очып йөри. Дөнья моннан капыл киңәеп, күз кабагыдай ачылып китә: ун ягымда зәнгәр дымдай рәшәләнеп, офык өстенә Йолдыз-Тау уелып төшкән; сул ягымда—Питер тавы, анын очлы борыны Агыйдел аръягындагы Кызкала тавына төбәлеп каткан төсле. Моннан ике йөз ел элек империяне дер селкеткән Пугач явы Казанны алмага барышлый бу жирләрдән дә янгырап үткән. Алар әнә шул Питер тавы өстенә урнашканнар. Әби патша гаскәрләре исә аларга каршы Идел Эченнән[1] килгән булса кирәк: нәкъ Питер тавы турысына—уйсу япан жиргә хәзерге спорт сарайларыннан да зуррак итеп, камалы бүректәй түгәрәк тау өйгәннәр дә, шунын артында һөжүмгә көч туплаганнар. Әүвәл таудан тауга атышканнар дип сөйлиләр. Белмим, ул ераклыктан туп атышулары бәлки өеп тау ясаулары шикелле бер риваять кенәдер, әмма ләкин каты сугыш булуы хак. Әби патша гаскәрләре Агыйделне кичеп, авыр һөжүм белән Питер тавы төбенә үк килеп житкән; шулай булмаганда Пугачев егетләре болай да текә борын очына, иненнән иненә чокыр казып, жирдән ныгытма өймәсләр иде (ул өемнәр бүген дә машинадан биек). Шуннан бирле бу тауны, үзен Петр III дип игълан иткән Пугачев «исеме» белән, Питер тавы дип йөртәләр.

Идел Эченен көнчыгыш тарафында тагы, аяз көннәрне күгелжем рәшә сирпеп, ә яшенле янгыр килгәндә кара кучкылланып ятучы иләмсез зур ике

[1] Безнең як халкы Агыйделне күп вакыт Идел дип кенә йөртә, шуңа күрә аның унар чакрымга җәелеп, язларын су астында кала торган әрәмәле, болынлы түбән ягын элек-электән Идел Эче дип әйткәннәр, ә таулы биек ягын Кыр Ягы диләр.—(Автор искәрмәләре).

әүлия зираты бар. Боларын исә Алыпның агасы Бисрәк батырдан калган диләр: Агыйделне атлап чыккач, чабатасын салып, туфрагын кагып киткән, имеш... Калган җирләрдә ерак тау тезмәләренә кадәр болын да әрәмә, болын да әрәмә. Минем аста гына Күгәрчен, Акман, Каттарлау, Чәгерче болыннары... Алардан эчкәре—язын су басмас чикләрдән авыллар, бүлем-бүлем урманнар башланып китә: Чумар, Мәнәк, Кәлтәй урманнары... Һәр тарафта күпме кавем гомер кичкән чын табигать. Тик ул хәзер әүвәлгечә тын гына түгел: инде бу төбәкләргә дә тимерле-бетонлы, БелАЗлары белән зур сәнагат килеп керде. Әнә теге Кызкала тавыннан ары, Нугай, Кырым-Сарай якларында инде шаулатып нефть чыгаралар; ялкынланып янган утлары төн буена соргылт күк йөзендә нәҗәгайдай уйнап тора...

Мин Агыйдел буйларының искитмәле яменә карап, мина кадәр унике буын элек болгар угланы Гәрәй бабабызның яр-юлдашы, карендәш якыннары белән Казан йорты Масрадан баш бирмичә чыгып киткән, арлар[1] иле аша ике Идел кичеп, бу җирләрдә торак тапкан чагын гүя үзем күргәндәй күз алдына китерә алам... Борынгы Чулман белән Ак Идел килеп кушылган бер кыйтга. Кеше кулы тимәгән урманнар, киекле болын-тугайлар. Кичә-көнлек бу тараф, кичә-көнлек ул тараф җирләрдә чын кышлак кормыйча башкортлар (истоклор) ыругы гына быел монда, ярен анда җәйләп-кышлап йөри. Ыруг җирләре күп, хәтта чикләре дә мәгълүм түгел: болын-тугайларында елкылдап чапкан елкы көтүе; елга-күлләрендә балык, кондыз; карт юкә, имән куышларында аюлар гына менгән кыргый корт балы... Башкорт инде Болгарын белә, Казанын белә. Алар аша ул дин алган, хәреф алган, алардан күреп иген игү эшенә дә ихлас бирә башлаган. Ул Болгарның үсүенә дә, һәлакәтенә дә шаһит. Бәлки шуңадыр, болгар дигәндә күнеле дә япандай киң, иркен...

Ә чынлап уйласаң, кемнәр генә килеп сыенмаган башкорт иленә! Бату ханның исәпсез-сансыз бәни әс-фарлар кавеме[2] баскынынннан соң Дәште Кыпчак бетеп—кыпчагы, Бөек Болгар җимерелеп—болгары агылып килгән; Аксак Тимер белән Туктамыш хан арасындагы яман кыргыннан соң икенче кабатка янә болгар агылган; инде Казан җиңелгәч, егерменче йөзгә кадәр тукталмаган өченче агым килә. Башкорт инде бу агымны туктата да алмый,— йә үзе буш җирләргә күчеп китә, йә тел берлеге, дин берлеге аркасында килгән беренә өлеш чыгара. Ул шулай Гәрәй бабабыз белән карендәш якыннарын да үзенә сыендырган. «Танып тамагыннан алып Ак Иделнең түбән тарафы ике якка таралмыш сулары, койгучы елгалары, тугай-камышлары, арка вә яланлары илә сезгә булыр; суларыннан кондыз, урманнарыннан киек тотарсыз...» дигән. Гәрәй бабаларыбыз яңа ватанда нигезе болгардагыча һиммәт кышлак йортлар корып, башкорт белән ут күрше булып, өйләнешеп, кыз бирешеп, «Идел буйлары вә урманларында бал корты илән, суларында кондыз, камасы илән, яланларындагы йөкерек төлкү, сусарларыйна сунар кылыб, сука илән җир сөреб, иген игеб гани улганлар...» Башкорт туфрагында нәсел шулай башланып киткән.

Пугач явыннан күп алда, инде җиденче буын Акман бабабыз Болгар иленнән[3] яңа гына килгән Апанай (Әпәнәй) гаиләсе белән туганлашып, янә мөселман диненә чыккан бер мари кешесен алып, Идел Эченнән Кыр Ягына—иген ундырышлы җирләргә күчеп утырган. Төрле юллар, ысуллар белән башкортның үзеннән йә ак патшадан башкорт җирләрен алу-алмауларына, ягъни бары тик җирле-җирсез булуларына карап, безнең нәселдә дә унике

[1] Удмурдларны элек ар дип атаганнар.

[2] Сары тәнле халык, сары раса.

[3] Хәзерге Татарстан җирен башкортлар 19 нчы йөзгә кадәр Болгар иле дип йөрткәннәр.

буын дәвамында башкорты булган, типтәре булган. Ләкин, нинди генә рәвешкә кермәсеннәр, алар үзләренең асыл болгарлыгын иман кебек саклаганнар (чөнки татар исеме татар халкына унтугызынчы йөз ахырында гына ныклап йога башлый); нәсел башын Казан йорты Масрага, бик борынгысын Болгарга илтеп бәйли торган булганнар. Безнең телебез дә, йөзебез һәм моңыбыз да үзебезчә калган. Гәрәй бабамнар белән бергә күчеп килгән марилар безне әле һаман: «суаз» ди. Ә суаз яки суар—болгарның бер кабиләсе булган. Рәхмәт онытмауларына.

Ә сезнең «Казанны яу алган көй»не ишеткәнегез бармы? Минем—бар. Ул көйне безгә анам ягыннан туксан яшенә җитеп үлгән бабам уйнаган иде. Тик мин аны ике генә кабат ишетеп калдым. Кайгылы сугыш чоры иде. Берсендә сугышта ирләре, уллары үлгән сагышлы аналар җыелып үтенгәч уйнаса, икенче кабатында үзе генә моңланып уйнады: өченче улының да үлү хәбәре килгәннән соң иде монысы. Йөзендәге бер сырын да кыймылдатмыйча, яшьсез генә уйнады-уйнады да: «Җитәр, күп уйнасаң көйнең дә төсе уңа» дип, үзедәй карт венский тальянын сандыкка салып куйды. Казан моңы шулай, бабамның хәсрәт тулы йөзе сыман, күңелемә уелып төшсә дә, авызымнан көй булып чыга алмады. Тиздән бабам үзе дә бу дөньядан китте,—шулай итеп моңын йөрәгемә салды да, көен үзе белән мәңгегә алып китте...

Мин Агыйделнең түбән карасаң башлар әйләнмәле Төбә яры өстендә басып торам. Миннән бик түбәндә, ин аста, эссе җәйдә кимеп, ярлары ачылып беткән Агыйдел ага. Ага да ага, ага да ага... Синең суларың белән генә дә буш диңгезләр тулып түгелгәндер инде, Агыйдел! Ярларың да, кеше гомере сыман, кителеп-кителеп кенә юыла тора, юыла тора... Пугач явын бастыргач, башкорт иленең Салаваттай асыл ирләрен асып, күпме дар агачы агызганнар синнән, Агыйдел! Алар сал өстендә, җил-дулкынга чайкала-чайкала акканнар да акканнар, акканнар да акканнар—гел бер таба, гел түбәнгә таба...

Агыйдел!

Синең ак суына халык азатлыгы өчен бу җирләрдән дә көрәшеп үткән Чеверев, Чапаев каһарманнарның да каны коелган бит!.. Аклар афәте дә үткән моннан. Нәкъ менә мин басып торган яр читенә бастырып, күпме коммунистны атып киткәннәр аклар. Ул шәһидләр каны да синең суыңда бит, Агыйдел! Бәлки ярың да шуңа кызылдыр...

И газиз аналарыбыздай күпне күргән Агыйделем!..

Бу сугыш елларында без әтиләребезне пристаньнан туры фронтка озатып җибәргәч, тыннарыбыз бетеп шушы ярга менә идек тә, соңгы кабат карап калырга теләгәндәй, пароходның куе төтене Йолдыз-Тау зәңгәрлегенә эреп югалганчы карап тора идек. Китте дә утка керде, китте дә утка керде безнең әтиләр...

Агыйдел!

Мин синең бүгенге тыныч, иркен-рәхәт, якты ярыңда басып торам. Миннән бик түбәндә, кызыл яр тирәли, уйнап-уйнап керәшәләр генә очып йөри. Илгә иш булган Илешем басуларында да, болгар бабаларыбыз шикелле, иген игүдән башканы белмәгән, теләмәгән халкым эшли—Илем даның үстерәләр. Тик мин әле үткәннәрне уйладым. Чөнки бүгенгенең берсе дә төче камырдан гына әвәләп ясалмаган,—урак өстенең монарланып кызган һавасында битләргә ягылып үткән җепселдәй, барыбызның да бик ерактан өзелмичә килгән тамыры бар, тик без аны белмибез генә. Хуп, бик ерактан килгәнен күбебез белмәсен дә ди, анысы тарихка калсын ди, ә якынын барыбыз да җитәрлек микъдар беләбезме соң? Инде бабайлар гына түгел, әтиләребез дә, кайтмаска китеп, җәйге сулар кебек саега, бетә баралар. Ә бер уйласаң, шушындый да шаулы гасырыбызның кырык елы эчендә генә дә алар гомеренә нәкъ өч сугыш, өч революция туры килгән!.. Без шуларны

белергә тиешме? Тиеш! Онытмаска тиешме? Тиеш! Алар кабызган революцион ут, каннан канга күчеп, безнен йөрәкләрдә дә янарга тиешме? Тиеш! Ниһаять, без бөек бәрелешләрдә алар яулап, безнең кулга тоттырган бөек бәхетнең, Икмәкнең кадерен белү өчен дә үткәннәрне белергә тиеш. Алар кигән чабатаны сөйләгәндә дә чырай сытып түгел, ә күңел колагын салып, чабатага ихтирам белән тынларга тиешбез...

Мин Агыйделнең еракларга төбәлеп торган Төбә яры өстендә битләремне астан искән жылы, дымлы, чәчәкле болын жиленә куеп басып торам. Күз күреме җирләрдә болын да әрәмә, болын да әрәмә; ә шулар эченнән, ярдан ярга тибеп, колындай уйнаклап, Агыйделем ага.

Агыйдел!

И минем туган җирем—унике буын буена сулап туймаган сулышым!..

*Февраль, 1972.*

**Искәрмә**

Хәсән Салихҗан улы Сарьян 1930 елның 24 мартында Башкортстанның Илеш районы Иске Аю авылында туа.

Язучылык эшенә тотынганчы ул шактый зур һәм катлаулы тормыш юлы уза: студент, артист, клуб мөдире, журналист... «Кызыл таң» газетасында, «Һәнәк» һәм «Азат хатын» журналларында әдәбият бүлекләрен җитәкли.

1960 елның көзендә Уфадан Казанга килгән әдип әдәби иҗат эшенә чума, хикәяләр остасы буларак танылa. Повесть жанрында да «Әткәм һөнәре», «Бер ананың биш улы» дигән әсәрләре белән абруй казана. Аның әсәрләрендәге лиризм, җылылык, теленең халыкчанлыгы укучыны битараф калдырмый. Ул үзе дә татар теленең аңлатмалы сүзлеген төзүдә катнаша, тел һәм стиль мәсьәләләрендә күп кенә хезмәтләр яза.

Укучыбызга тәкъдим ителгән «Туган як моңы» дигән хикәясе җитмешенче еллар башында язылган. 1980 елны Татарстан китап нәшриятында басылган «Егет язмышы» дигән китабына кертелгән.

Хәсән Сарьян 1978 елның 21 сентябрендә, иҗатының чәчәк аткан чорында, кинәттән вафат була.

---

# «УКЫТУЧЫ БУЛУЛАРЫ КЫЕН ИКӘН...»

ИСТӘЛЕК-ХАТИРӘ

...1957 елның сентябрендә Башкорт дәүләт университетының икенче курс студентлары булып оештык. Бер ай колхозда эшләгәннән соң, туган якка кайтып килү сәбәпле, мин октябрь аенда башланган дәресләрнең беренче көненә сонладым. Килү белән яңалык ишеттем: безне татар теленнән бер яшь кеше укытачак икән, ул бер дәрес үткәргән дә инде.

...Менә дәрескә дәшеп кыңгырау шалтырады. Безнең кызлар, мут елмаешып, бер-берсе белән ымлашып, укытучының кергәнен көтәләр. Берсе: «Ну, бүгенге сораулар үткән дәрестәге кебек генә булмас, чыдасын гына»,—дип әйтеп куйды.

Менә аудитория ишеге ачылып, безнен каршыга 27-28 яшьләр тирәсендәге бер ир-егет кереп басты. Урта буйлы, пөхтә итеп үтүкләнгән, үзенә кып итеп килешеп торган кызгылт-көрән төстәге костюмнан, кара чәчле, киң маңгайлы, калын пыялалы күзлек кигән кеше.

Яна укытучыны без бердәм басып каршы алдык. Аны күрүгә, безнең кызларның күзләрендә аптырау билгесе чагылды һәм, бу бит үткән дәрестә кергән кеше түгел, дигән пышылдау ишетелде. Укытучы, берни сизмәгәндәй, ягымлы итеп исәнләште

һәм барчабызга да урыннарыбызга утырырга кушты. Шуннан үзе белән таныштырды.

—Мин Хәсәнов Сарьян дигән кеше булам. Сезнең курста татар теле дәресләре алып барачакмын.

Безнең төркемдә 25 студент булып, өчәве генә егетләр, мәктәп эскәмиясеннән генә килгәннәр дә, педучилище һәм урта мәктәп тәмамлаганнан соң берничә ел эшләгән стажлылар да бар иде. Ике егетебез армия хезмәтен тутырып кайткан. Укырга педучилищены тәмамлап килгән «свежий белемле» бик чая өч кызыбыз бар иде. Менә тотындылар болар яшь укы-



Хәсән Сарьян—уртада. Икенче рәттә (уңнан беренче) әлеге язма авторы Фәния Миңнегулова. 1958 ел.

тучыга сораулар яудырырга! Нинди сораулар бирүләре хәтердә калмаган, ләкин укытучыбыз бирешмәде, һәр сорауга җавап табып торды. Бер пар дәреснең сорау-җаваплардан торган беренче өлеше сизелми дә үтеп китте: «бәйге»нең тәмамлануын белдереп, кыңгырау шалтырады. Укытучыбыз, калын пыялалы күзлеген салып, маңгаена бәреп чыккан тирен кулъяулыгы белән сөртеп алды да: «Уф, укытучы булулары бик кыен икән!»—дип, авыр сулап куйды.

Ә дәреснең икенче яртысында инде ул бөтенебезне дә үз авызына каратты.

Йә Хода, татар халкының мең еллык әдәби мирасы, мең еллык әдәби теле бар икән ләбаса! Безнең борынгы бабаларыбыз болгарлар дип аталган икән. Дәүләтләрнең йөзек кашы Болгар ханлыгы булган бит! Ә аның башкаласы, шәһәрләрнең шәһәре—Шәһри Болгар! Шул болгар ханлыгы чорында язылган асылташка тиң «Йосыф вә Зөләйха» кыйссасы безнең көнгәчә исән-имин килеп җиткән икән! Авторы да билгеле—Кол Гали...

Безгә, үсмер чагыбыз 40-50 нче елларга туры килгән һәм, татар әдәбияты «ярлы» булу сәбәпле, Пушкинның «Евгений Онегин»ын, Толстойның «Война и мир»ын татарча тәрҗемәдә татар әдәбияты дәресләрендә өйрәнгән буынга, бу мәгълүматлар бик зур ачыш иде. Чөнки бу елларда татар әдәбияты титаннары Г. Ибраһимов, К. Тинчурин, Н. Исәнбәт, Хәсән Туфаннарның исемнәре һәм әсәрләре безгә билгесез, ә Муса Җәлил әле «кайтып җитмәгән» иде.

Укытучыбыз шулкадәр илһамланып сөйләде, гүяки халык тарихы, тел язмышы турында хикәяләми, ә поэма укый иде. Без монарчы беркем дә сөйләмәгән, сөйләргә җөрьәт тә итмәгән дәреслекне беллек.

Укучыларыннан бары тик биш-алты яшькә генә олкән булган (арада укытучыбызның яшьтәшләре, хәтта анардан өлкәнрәк апабыз да бар иде), бер-ике ел гына элек үзе дә шушы студент эскәмиясендә утырган яшь кешенең шулкадәр мәгълүматлы булуына барыбыз да таң калдык. Танауларын күтәреп, сынар өчен «имтихан» оештырган кызларга да яңалык иде аның сөйләгәннәре. Укытучы безнең барчабызны да әсир итте. Без аны хөрмәт белән кабул иттек һәм бик яраттык. Язучы вафат булганнан соң басылып чыккан җыентыкны укып чыккач *(Х. Сарьян, «Егет язмышы», Казан, 1980)*, шуны аңладым: киләчәктә кәгазьгә төшәчәк әсәрләрендәге моңнарын, сагышларын, соклану-горурлану хисләрен безнең күңелләргә «бушаткан» икән ул!..

Сарьян абый безгә хәзерге татар теле морфологиясе курсын укыды. Беренче карашка «күңелсез» күренгән материалын да кызыклы итеп бирә белә иде. Лекциясен ул, кайбер укытучылар кебек, дәфтәрдән карап укымый, ә иркен рәвештә сөйли. Сөйләм барышында карточкаларга язылган мисаллардан файдалана. Бераз вакыттан соң, ничек чыга минем лекциям, аңлашыламы, әзлекләме дип, алгы

партада утырган бер студентканың дәфтәрен алып укып карады да, ару гына була икән, дип, канәгать булуын белдерде.

Хәсәнов Сарьян бик талантлы укытучы иде...

«Тел хасиятенең тирән тарлавыкларына төшә белгән әдипкә гыйлемлек сәләте тумыштан бирелгән. Аңа бәрәкәтле мәйдан гына кирәк булган». *(Марсель Галиев, «Догалы еллар» әсәреннән).*

Бу сүзләргә өстәп тагын нидер әйтү мөмкин түгел. Тел гыйлеме буенча эшләгән булса, чыннан да, Хәсән Сарьян зур уңышларга ирешкән галим булыр иде. Ул гыйлем юлыннан китәргә ниятләре турында без—шәкертләре белән дә уртаклашкан иде. 1958 елның язында ул, бик дәртләнеп, аспирантурага керергә әзерләнүен әйтте. Ә көзен, бик кәефсез генә, үзенең бу нияте тормышка ашмавын сөйләп бирде. Аспирантурага керер өчен чит ил теленнән дә имтихан бирергә кирәк икән. Европа телләре урынына гарәп теленнән тапшырырга мөмкин дигәннәр һәм ул шул телдән әзерләнгән. Ә имтиханнар вакыты килеп җиткәч, бу мөмкинлек тыелган. Шул сәбәпле ул бик уңайсыз хәлдә калган... «Алданрак әйткән булсалар, мин немец теленнән дә менә дигән итеп әзерләнгән булыр идем»,—дип сөйләгән иде ул безгә, бик көнелсезләнеп...

Укытучыбызның гарәп теленнән имтихан тотарга җыенуы безнең өчен буй җитмәс нәрсәгә үрелү кебек тоелган иде. Истәлекләрдә Х. Сарьянның төрек телендә бик әйбәт сөйләшүе, гарәп хәрефләре белән язылган китапларны бик житез укуы, аңа бу гыйлемне әнисе өйрәткәне турында язалар. Чыннан да, аның әнисе бик укымышлы кеше булгандыр, улына төрек телен генә түгел, гарәп телен дә өйрәткән булгандыр дип уйлыйм. Шулай булмаса, аспирантурага керер өчен шул телдән имтихан тотарга җыенмаган булыр иде...

Лекция темасын тәмамлагач, Сарьян абый «лирик чигенүләр» ясый, үз тормышында булган кызыклы вакыйгаларны сөйләп ала

Бөре педучилищесын тәмамлаган җәйне, институтка керер алдыннан, үзләренең авылына килгән бер театр җитәкчесе чакыруы буенча, спектакльләрдә уйнап йөргән (ул сукырлар театры булган икән, безгә анысын ачыклап әйтмәгән иде). Шул эш өчен түләнгән акчага ул үзенә костюм-чалбар, көзге пальто сатып алган, аягына да ару гына кием хәстәрләгән. Пединститутка укырга килгән егетләрнең күбесе сырма фуфайкалардан. Егетләр Сарьянның киеменә кызыгалар, ничек шулай яхшы киенүе турында сорашалар. «Минем әти шахтада эшли, мина акча җибәреп тора» дип әйттем, шуңа ышандылар, дип көлдергән иде безне.

«Лирик чигенү» минутларында сүз мәхәббәт темасына да кереп киткәли иде (аудитория тулы кызлар бит!). «Мәхәббәт бармы ул?»—дигән сорауга: «Мәхәббәт бар ул, тик өйләнешеп яши башлагач, мәхәббәт романтикадан гадәти якынлыкка, бер-береңә күнегүгә әверелә, кешедә бурыч, гаилә, тормыш иптәшең, балалар алдында җаваплылык, тугрылык хисе өстенлек ала»,—дигән фикерне әйткән иде. Күренекле башкорт шагыйре Шәриф ага Бикколның бер шигырендә «Мәхәббәт очар канат кына түгел, ул җилкәгә киелгән камыт та» дигән юллар укыган идем. Бу—сугыш гарасатларын үтеп, олпат яшькә җиткән шагыйрь сүзе... Яше утызга да җитмәгән ир-егетнең аксакаллар акылына әле булса исем китә.

***

Башкорт дәүләт университетында эшләгән 1957-59 нчы елларда Хәсәнов Сарьян студентларның әдәби-иҗат түгәрәгенең җитәкчесе булды. Ул иҗади яшьләрнең кумиры иде. Шул чорда ике ел рәттән мине әдәби-иҗат түгәрәгенең сәркәтибе итеп сайладылар һәм миңа төрле кызыклы утырышлар, вакыйгалар, очрашуларның шаһиты булырга туры килде.

Түгәрәк утырышларында башлап язучыларның шигырьләре, хикәяләре тикшерелә. Иҗатчылар бер-берсенә язмаларының уңыш-кимчелекләрен күрсәтәләр, киңәшләр бирәләр. Әдәби кичәләр, яңа басылып чыккан әсәрләр турында диспутлар, туган тел, милли моңнар язмышы турында борчулы сөйләшүләр оештырыла. Мондый чараларга башкорт иҗат түгәрәге әгъзалары да кушылып китә иде. Гомумән, ул вакытта татар һәм башкорт иҗади яшьләре үзара бик дуслар, бер-берсенең утырышларында актив катнашалар. Үзара дусларча ярыша-ярыша кульязма журналлар чыгаралар. Аеруча мөһим чаралар тоташ факультет күләмендә үткәрелә иде.

Хаксызга гаепләнеп репрессиягә эләккән мәшһүр язучыбыз Галимҗан

Ибраһимовның 70 еллык юбилеена багышлап, университет күләмендә үткәрелгән кичә бик нык хәтердә калган. Бик күп язучылар, галимнәр, укытучыларыбыз бөек әдип турында истәлекләрен сөйләгәннәр иде.

Барлык мондый чаралар әдәби иҗат түгәрәге кураторы Хәсәнов Сарьянның активлыгы һәм оештыру сәләтенә ия булуы турында сөйли.

Түгәрәк утырышларында Сарьян абыйның үз иҗаты турында да сүз чыга иде. Хикәяләрне ничек язуы турында кызыксынуыбызга ул: «Үзеннән-үзе килеп чыга инде ул, аны ничек аңлатасың? Кайчак нинди дә булса әсәр укыгач, күңелгә илһам килә. Мина бигрәк тә америка язучысы О. Генри әсәрләре ошый. Аның хикәяләрен укысам, башымда яна сюжет туа»,—дигән иде.

Бер утырышта ул Сарьян исеме астында басылган «Альберт» дигән хикәясен укыды. Ул хикәя «Әдәби Башкортстан» (хәзерге «Агидел») журналының 1957 нче елдагымы бер санында басылган иде «Нигә хикәягезне фамилиясез, исемегез астында гына бастырдыгыз?»—дигән сорауга да, горурланып: «Мин үз исемемне бик яратам. Әрмәнстанның Сарьян фамилияле рәссамы бар. Ә минем исемем фамилиягә охшап тора, псевдоним уйлап торасы да юк»,—дип җавап бирде.

Шуннан соң сүз әсәр героеның исеменә күчте. Ни өчен, нинди максат белән икәнен үзе дә белмичә, нинди дә булса берәр югары уку йортына керер өчен имтихан бирергә килгән бер абитуриент егет турында ул хикәя. Автор аны тәнкыйть белән, «кире образ» итеп сурәтли. Шуна күрә ана исемне дә Альберт дип кушкан. Гомумән, Сарьян абый кешегә (балага) исем кушу мәсьәләсенә бик җаваплы карый, татар, башкорт баласына чит ил исемен кушуны өнәми. Шул унайдан үзенен улына Рәфкат исемен кушуы турында да сөйләгән, гарәпчә мәгънәсен дә аңлаткан иде, ләкин аның әйткәне хәтердә калмаган. (Кызыксынып эзли торгач, Рәфкат исеменен ике мәгънәгә ия булуын ачыкладым: 1) зур дәрәҗә; 2) озата баручы, юлдаш булучы.)

Бу чорда түгәрәккә йөрүчеләр арасыннан чын шагыйрь, чын язучылар үсеп чыкты. Яшь шагыйрь Әхмәт Гайсин түгәрәкнен йөзек кашы иде. Студент чагында ук хикәяче «даны» алган Мансаф Гыйләҗев бүгенге көндә билгеле язучы, юмористик хикәяләр остасы булып танылды. Шагыйрь һәм публицист Муса Сиражи, абруйлы радиожурналист Сәләх Сукбаев, популяр җырлар тексты авторы Вил Казыйханов әдәби түгәрәкнен актив әгъзалары иде. Старостабыз Мариус Максютов, озак еллар «Кызыл тан» гәзитенен үз хәбәрчесе буларак, матур-матур фәһемле мәкаләләре белән укучыларын кинәндерде. Беренче курста укыган чагында ук сүзләрнен килеп чыгышы (этимологиясе) турындагы докладлары белән чыгыш ясап, студентларның гына түгел, укытучыларыбызның да исләрен китәргән Рифкать Әхмәтьянов Казанда тел галиме, филология фәннәре докторы, профессор дәрәҗәсенә ирешкән...

***

Укыту эшенә тотынганда тәүге чиркәнчыкны бездә алганга микән, Сарьян абый безнен төркемне якын күрде, икенче курсны тәмамлар алдыннан, 1958 елның маенда безнен белән коллектив фотога төшкән иде. Төс-чырае белән студентлардан берни белән аерылмаган яшь-яшь укытучыбызны уртага алып төшкәнбез.

1959 елның көзендә дүртенче курска укырга килгәндә Сарьян абыебыз университетта юк иде. Эштән ни өчен киткәнлеген без белмәдек. Казанга күчеп киткәнлеген ишеттек. Укытучыбызның «Әткәм һөнәре» һәм «Бер ананың биш улы» повестьларын йотлыгып, шул ук вакытта тетрәнеп укыдым.

Татарстанның күренекле язучысы булып танылган Хәсән Сарьянның вафатыннан соң басылган истәлекле әсәрләрен яратып укыган кебек, кызыксынып укый барам. Укытучыбызның нинди хәлләр кичергәнен шул язмалардан беләм. Иң нык тетрәндергәннәре Татарстан язучысы Марс Шабаевның «Туган җиренен баласы иде...» («К. У.», 1998, № 9) һәм Башкортстан язучысы Расих Ханнановның «Җаннарны кыя... кыя...» («Тулпар», 1999, № 5) мәкаләләре булды.

Казан чорындагы Хәсән Сарьянны—үз эченә йомылган, аз сүзле, кырыс табигатьле дип сурәтлиләр. Ә минем хәтердә ул ачык йөзле, ихлас күңелле, авызыннан җәүһәрләр сибүче тел остасы булып саклана.

**Фәния МИҢНЕГУЛОВА,**
*пенсиядәге укытучы, хезмәт ветераны.*
*Башкортстан.*

Нурихан
Фәттах

# АКЛАН

ХЫЯЛЫЙ РОМАН

***

Мәмлине алты яшеннән Типкә би карамагындагы ир балалар әндериенә бирделәр. /Әндери төркем—хәрбиләштерелгән балалар, үсмерләр төркеме/ Бөтен каладан кечкенәләр әндериендә егерме бала җыелды. Биш ел буена алар үзләреннән биш-алты яшькә өлкәнрәк үсмерләрнең йомышчысы, булышчысы булып йөрделәр. Иң элек алар өлкәннәр янына утырып ашаргаэчәргә, өлкәннәрнең вак-төяк йомышларын үтәргә, ашаган табак-савытларын юарга, коралларын карарга-сакларга өйрәнделәр. Тора-бара өлкәннәр өчен дә, үзләре өчен дә аш-су пешерә башладылар, кулларына балта-пычак тотып кисә, юна башладылар—уенчык кораллар эшләделәр. Йә булмаса камыштан яна куыш ясауда катнаштылар. Елдан-ел алар башкара торган эшләр, йомышлар, бурычлар катлауланганнан катлаулана барды. Әкренләп алар корал тотарга да, төрле сугыш, көрәш алымнарына да өйрәнделәр. Ялан аяк, ялан баш көе эсседә, суыкта, янгырда бер-бер артлы тезелеп, корал тотып ерак аралар үттеләр һәм биек тау башларына, шома кәүсәле агачларга үрмәләделәр. Аларны шулай ук йөзәргә, атта йөрергә һәм үгез өстендә сикереп уйнарга өйрәттеләр. Алар бары олы туй һәм бәйрәмнәрдә генә өйләренә кайтып, атааналарын һәм туганнарын күреп килделәр дә, кышкы суыкларда гына биек, иркен өй эчендә, учак янында утырдылар. Мондый чакта алар җырга-биюгә һәм санарга өйрәнделәр, озын җырулар һәм дастаннар ятладылар. Башка чакта ел тәүлегенең теләсә кайсы вакытында алар тышта, кырда-яланда йә булмаса суда-дингездә булдылар.

Атлантиданың изге патшалары—мака сарлар Алтын уртада изге ташка уеп яздырган изге язуда лелек яшьләре бала чактан ук чыныгып, теләсә нинди кыенлыкларны, теләсә нинди дошманны җиңәрлек кыю һәм батыр булып үсәргә тиешләр диелгән иде. Мәмлиләр нәкъ менә шундый чыдам, кыю һәм батыр булып үсәргә тырыштылар да инде. Биш-алты ел йомышчы-булышчы булып йөргәннең соңында, алтынчы елны аларның үзләренә йомышчы малайлар бирделәр. Үзләренең һәртөрле күнегүләрен туктатмыйча алар хәзер юеш борынлы бүлтерекләрне өйрәтә башладылар.

Аларның барысына да—кечкенәләргә дә, өлкәнрәк үсмерләргә дә Әмәк атлы пир ата баш булды. Чи утынга ут кабызып янгыр астында казан асарга да, төрле корал ясарга да, йөзәргә, йөгерергә, сикерергә, ук-сөңге атарга да—барысына чынлыкта аларны бер кеше—пир ата өйрәтте. Пир ата ун ел буена һәркемнең иң якын кешесенә, ата-анасыннан, туганнарыннан да якынрак киңәшчесенә һәм сердәшенә әверелде. Ләкин бу вакыт эчендә һәркемнең

*Дәвамы. Башы узган санда.*

пир атадан башка якыннары да барлыкка килде. Ун ел буена бергә торып, бергә ашап, бергә төрле уеннарда катнашып, аларның бик якын дуслары—иптәшләре барлыкка килде. Алай гына да түгел, алар егерме үсмер үзара да бик дус, тату бер әндери төркем булып житештеләр. Аларның бу дуслыгы хәтта туганлык якынлыгыннан да көчле булды. Бер-берсе өчен алар утка-суга керергә, теләсә нинди дошманның бугазын чәйнәп өзәргә әзер кебекләр иде. Бит аларны мәңгелек йола да, пир ата да нәкъ шуна дуслыкка-татулыкка, үзара ярдәмләшүгә өйрәтте дә. Үсмерләрнең кайберләре үзара мәңгелек ант эчтеләр. Дөрес, бу хакта алар бик шауламыйлар. Моны алар бары үзләре генә беләә. Бу шундый изге нәрсә, моны ант эчүчеләрдән башка беркем күрмәскә, сизмәскә тиеш дип исәпләнелә. Ләкин, шуна да карамастан, кемнең кем белән дус булуын, кемнең кем белән ант эчешүен үсмерләр әйтмичә дә бик яхшы беләләр. Андый нәрсә шундук кешенең йөзенә чыга, сүзендә, кыланышында, үз-үзен тотышында сизелә башлый.

Зөлмәт белән Мәмли дә менә шундый яшерен ант эчәр дәрәҗәдәге якын дуслар булдылар. Бу дуслык өлкәнрәк төркемнең өченче елларында көчәеп китте. Еш кына Мәмли дусты Зөлмәт белән ант эчү турында уйлый башлады. Зөлмәт тә, икәүдән-икәү генә калгач, пышылдап кына бу турыда сүз ачкалаганы булды. Ләкин башкаларныкы кебек аларның дуслыгы шулай да ант эчүгә, бер-берсенең тәнен җәрәхәтләп, бер-берсенең канын татуга кадәр барып житмәде. Көтмәгәндә алар арасына салкын жил үтеп керде.

Ир балаларны бала чактан ук батыр, эшчән, булдыклы, кыю кешеләр итеп тәрбияләргә тырышкан лелегләр кыз балаларны да исләреннән чыгармыйлар. Ир балалар тулысынча аталар, ирләр карамагында булган кебек, кыз балалар тулысынча аналар, әбиләр карамагында булды. Билгеле бер яшькә житкәч, кыз балаларны да махсус төркемнәргә жыйдылар. Алар анда булачак аналарга кирәк булган серләргә өйрәнделәр. Эрләү, туку, тегү-чигү кебек кул эшләренә өйрәнделәр. Күбрәк вакытларын алар калада—түбә астында йә булмаса бакчада, агач күләгәсендә үткәрделәр. Ләкин таурлар илендә лелегләр каласын кыргый кабиләләр чорнап алган иде. Алар белән ике арада бәрелешләр булып тора һәм беркайчан да яу куркынычы юкка чыкмаган, көн тәртибеннән төшеп калмаган иде. Шуна күрә би дә, каланың өлкәннәре дә ир балаларны гына түгел кыз балаларны да кыю, нык рухлы, чыдам итеп тәрбияләүгә бик нык игътибар иттеләр. Шунлыктан еш кына кыз балаларны да әледән-әле кырга-яланга алып чыктылар. Алар да атта йөрергә, йөзәргә, йөгерергә, сикерергә өйрәнделәр һәм һәр төрле гимнас уеннарда катнаштылар. Кыскасы, булдыклы хатын һәм ана итеп кенә түгел, үз кызларын лелегләр батыр сугышчы итеп тә тәрбияләргә тырыштылар.

Хатын-кыз буларак, тәрбияче аналар, билгеле, үз кызларының матурлыгы турында да онытмадылар. Син никадәр батыр һәм кыю булма, әгәр син дөньяга кыз кеше булып тугансың икән, яшь ирләрнең күз явын алырлык, башын әйләндерерлек чибәр түгелсең икән, беркайчан син бәхетле булмаячаксың. Яисә, Аллам сакласын, гомер буена кысыр, ялгыз калачаксың. Андыйларның урыны ишек төбендә, аяк астында.

Менә шуна күрә аналар кызларының батырлыгына гына түгел, матурлыгына да бик нык игътибар иттеләр. Бу мәсьәләдә аларның әллә нинди хәйләләре, әллә нинди серләре һәм осталыклары бар иде.

Яшь кызларның сәләтен, булдыклылыгын тикшерү һәм аларның күнелен күтәрү өчен әледән-әле һәртөрле сынаулар-ярышлар үткәрелде. Бу сынаулар-ярышлар башлыча борынгы йолаларга, дингә кагылышлы рәвештә үткәрелә иде.

Ярышларның иң зурысы, иң тантаналысы җәй узгач, яна арпа өлгергәч була. Арпа урагына төшкән беренче көнне бөтен калала Арпа ана туе уздырыла.

Беренче көн урылган яңа арпа аеруча изге санала. Урылган башакларны уып шул ук көнне беренче он тарталар һәм изге күмәч—әнәчә пешерәләр. Беренче арпадан изге ботка—карга боткасы пешерелә һәм изге эчемлеккә—сырага баш салына. Арпа туе өч көн буена дәвам итә. Өч көн буе бөтен кала ял итә, туй итә. Аксөякләр зурлап аш-су ясыйлар, бер-берсен кунакка чакыралар, колларга, караларга карата ягымлырак, юмартрак булырга тырышалар. Кала уртасында би өенә каршы, түгәрәк мәйданда һәм таштан өеп ясалган биек сәкедә яшьләрнең җыры-биюе була. Кала янында төрле уеннар, ярышлар үткәрелә.

Кала халкы шулай Арпа туен зурлап, олылап күңел ачып уздыра да, өч көн үткәч ныклап торып уракка төшәләр. Урак вакытында арпаны бары ир затындагы коллар, каралар гына ура. Кала аксөякләренә, хатын-кызга, бала-чагага да эш җитәрлек була. Кораллы ирләр туктаусыз каланы һәм ашлык басуларын саклый, яшьләр күбрәк үз эшләре белән булашалар. Кечкенә балаларны—малайларны, колларына чүлмәк тоттырып, урылган җирдәге башак җыярга чыгаралар.

Арпа урагына төшкән чакта һәр елны шулай була. Бик күпләр өчен ул быел да шулай булды. Бары тик Мәмли өчен генә быелгы Арпа туе башкачарак булды.

Беренче башак туе һәр елдагыча Аккала урнашкан калкулык астында, Аксу елгасы дингезгә килеп койган төштә, иркен болында булды. Иң элек кече яшьтәге кыз балалар, малайлар үзләренең төрле һөнәрләрен күрсәттеләр. Җырладылар, биеделәр, йөгерделәр, сикерделәр. Кечкенәләрдән соң өлкәнрәкләр чыкты. Иң ахырда, төштән соң уртага өлкән яшьләр чыга башлады. Кыз балаларны да, ир балаларны да—һәр чыгышны халык шаулатып, кул чабып, яисә кычкырып алкышлап утырды. Аеруча тәэсирле чыгышлардан соң, бик озаклап, алкышлап кул чаптылар.

Арпа ана туенда булачак ярышларга Мәмлиләр җәй буе әзерләнделәр. Ул көнне туйда, халык алдында нинди ярышлар буласы алдан ук билгеле иде. Алар ерактан багана башына эленгән түңгәләккә ук аттылар, иске саламнан ясалган балбал карачкысына сөңге ыргыттылар. Аннан соң йөгерештеләр, бил алыштылар һәм иң ахырда йодрык белән сугыштылар.

Мәмлиләр төркеме чыккач, халык уртагарак җыела төште, кысыла төште һәм шау-шу тынып калды. Болар бөтен каланың быелгы буй җиткән яшьләре, озакламый кемнендер кияве булачак яшьләре иде.

Ук атуда, сөңге ыргытуда һәм йөгерүдә яшьләрнең барысы да катнашты. Бишнең өч төрендә җинеп чыгучыларны сайлап алып бил алышырга куштылар. Бил алышучылардан башта дүрт кеше сайланып калды, аннан соң иң батырлар икегә калдылар.

Болар Зөлмәт белән Мәмли иде. Алар болай да башкаларга караганда буйга калкурак, тазарак та иделәр. Иң ахырда алар гына торып каласын күпләр алдан ук белеп тордылар. Иң кызыгы, иң әһәмиятлесе Зөлмәт белән Мәмли көрәше булачагы алдан ук билгеле иде. Моны алар үзләре дә бик яхшы белделәр һәм алдан ук бу ярышка ныклап әзерләнделәр.

Башка ярышларда да, күнегүләрдә дә иң ахырга гел алар кала һәм ахырда алар бер-берсен җиңә алмыйча шактый озак азапланалар, көч түгәләр иде. Тик шулай да Зөлмәт көчлерәк иде ахрысы.

Зөлмәт кечкенәдән эшләп үсте. Аның куллары таза, беләкләре таш кебек нык. Мәмли им өендә яралган атасыз бала буларак бабасы йортында үсте. Алты яшеннән төркемгә бирделәр. Ул холыксызрак, үпкәчел һәм көнчел дә иде бугай. Зөлмәт үзенең көчлерәк икәнен белә һәм инде ничә көн менә алдан үзенең көндәшен җиңү турында хыяллана. Хәер, алай артык хыялланмады да бугай. Ул моның шулай булачагына чын күңелдән ышанды.

Чөнки башкача булырга мөмкин дә түгел. Чөнки Сурияне ул инде күптән яратып йөри.

Җинәргә тиеш иде. Бил алышта ул аны чыннан да җинде—кулындагы сөнгесе белән күкрәгенә китереп кысты да, җирдән тартып алды да баш аркылы күтәреп орды. Тапталып беткән каты җир дөпелдәп китте, тау битен тутырып утырган халык аһ итте, шаулатып, кычкырып җибәрде һәм пир ата Зөлмәтнен җингәнлеген белдереп, анын сөлгеле уң кулын югары күтәрде.

Беркадәр хәл алгач, тын алгач, алар йодрык сугышы башладылар. Алар икесе дә ялан аяк, ярым шәрә, кара чәчләре өч толымга озын итеп үрелгән, җәй буе шәрә йөргән, кояшта кара янган күкрәкләре, беләкләре таш кебек каты иде. Көрәш башланыр алдыннан ярдәмче малайлар аларга күн бияләйләрен китереп бирделәр. Һәркем бер-берсенә кырыйн күз белән генә карап, бер-берсен күздән ычкындырмыйча яхшылап күн бияләйләрен киделәр, йодрыкларын йомарладылар. Йомышчы малайлар бияләйләрне беләзек турысыннан махсус бияләй каешы белән кысып бәйләп куйдылар. Пир ата уртага чыгып кул селтәгәч тә, ике яшь үсмер шундук йодрыклары белән шап та шоп бер-берсен тукмарга тотындылар.

Бу юлы да аларны тын да алмый менләгән күзләр күзәтеп утырды, йә булмаса берәрсенә теләктәшлек белдереп, үзләренең хисләрен сиздереп, бөтенесе бердәм аһылдап куйдылар яисә кинәт кенә кычкырып җибәрделәр. Ирәннәр инде шактый арыганнар иде. Шулай булса да беркемнен дә бирешәсе килмәде һәм алар, әле берсе, әле икенчесе кызып китеп, бер-берсен тукмауларын дәвам иттеләр.

Башлыча Зөлмәт һөҗүм итте. Мәмли исә йодрыклары белән битен каплап, сакланырга гына тырышты.

—Хәл җыя, хәл җыя!—диделәр белгечләр Мәмли турында.

—Тукма ныграк, тукма!—дип кычкырдылар икенче яктан Зөлмәтне дәртләндереп.

Сәхнәдәгеләр аларны ныклап ишетмәделәр дә. Алар, ялан аяклары белән таптанып, беләк тычканнарын нык кабартып, әледән-әле бер берсенә очынып куныл алдылар. Кинәт Мәмлинең уң як янагына, күз турысынарак, таш кебек авыр йодрык килеп тиде. Мәмлинең күзеннән очкыннар чәчрәп китте һәм ул, анын җуеп, каядыр төпсез бушлыкка мәтәлде.

Зөлмәтнен сул кулы да уң кул кебек көчле һәм саллы иде. Мәмли, ахрысы, менә шуны онытып җибәрде. Баш түбән бушлыкка мәтәлгәндә ул бары шул турыда уйларга гына өлгерде. Аннан сон, бик еракта булып, колак төбендә ниндидер күк күкрәгән тавыш ишетелде. Шуннан сон бөтен дөнья тынып калды. Күпмедер вакыттан сон сул як күзен ачып караса, ул үз алдында ниндидер ят кешеләр, ят күренешләр күреп шактый гаҗәпкә калды. Ниндидер яшь, чибәр җегет шатланып нидер кычкыра һәм тау битендәге кемгәдер кул болгый. Үрелгән озын чәч толымы күкрәгенә салынып төшкән, битеннән шыбырдап тир ага, кин күкрәге күрик кебек бер күтәрелә, бер төшә.

Ул аңа озак карый алмады, бик каты авыртуга түзә алмыйча, күзен янадан йомды һәм янадан онытылып китте. Ләкин береаздан анын янадан әлеге җегетне күрәсе килде. Бу юлы җегет янында ул башаклары белән аска каратылган арпа көлтәсе күреп алды. Баштарак ул берни аңламады. Башаклары аска каратылган көлтә нишләптер кыймылдый, тирбәнә иде һәм иң гаҗәбе шул, ул көлтәнең кешенеке сыман ике аягы бар иде! «Саташам бугай» дип уйлады ул артык пошынмыйча гына. Шулай да анын мондый нәрсә белән килешәсе килмәде—ул болай да үзсүзле һәм үҗәт кеше иде. Ул, күзләрен ныграк ачып карады һәм шул чакны әлеге башы аска каратылган сәер көлтәнең көлтә булмыйча, көлтә сыман итеп, биленә арпа сабаклары бәйләнгән кеше икәнлеген шәйләп алды. Ул кешенең башында да шундый ук арпа көлтәсе

тырпаеп тора иде. Ләкин башындагы көлтәнең башаклары аска таба түгел, югары кайтарылган иде.

«Арпа-ана бит бу!» дип уйлады шунда Мәмли сөенү сыман бер тойгы белән. Арпа-ана... булып киенгән кыз... каланың иң чибәр, иң булдыклы кызы иң батыр җегетне котларга килгән. Әнә ул матур куллары белән алтын табак тоткан. Табакта—яңа арпа оныннан пешкән әнчәә. Әнчәне ул быелгы батырга—теге ят җегеткә бирде... Димәк, алар быел... өйләнешәчәкләр... каланың иң батыр җегете белән иң чибәр кызы...

Җирдә кузгала алмый сузылып яткан, җиңелгән яшь җегет күңеленә шундыйрак уйлар килде. Ул нишләптер үкенмәде дә, әрнемәде дә, хурланмады да. Аның янадан уң як чигәсе бик каты авыртты. Ул янадан күзләрен йомды һәм шул чакта, нииндидер чит нәрсә булып, күңелендә сәер бер тойгы калкып калды. Арпа анасы булып киенгән кыз ана... Сурия булып тоелды. Сурия батыр җегеткә әнчәә бирде. Мондый нәрсәнең булуы мөмкин түгел! Бу, билгеле, төш кенә булырга тиеш.

Аңын җуйган Мәмлине читкә алып һәм дүрт тәгәрмәчле арбага салып калага алып кайттылар.

Мәмли әле аңын җуйды, саташты. Кайчакта күзләрен ачкандай итеп, нәрсәнедер исенә төшергәндәй булды. Аның туктаусыз башы авыртты. Бәйләнчек нәрсә булып һаман бер үк күренеш пәйда булды. Мәмли хәзер аның өнме-төшме икәнен дә аермады—Зөлмәт Мәмлидән кычкырып, эче катып көлә имеш! Кайчан булды соң әле бу? Бик күптән, бала вакытта ук булды түгелме соң? Нишләп зур Зөлмәт болай көлә икән соң?

Көндәгечә иртән кояш чыкты. Күп тә үтмәде үзән уртасында оя-оя булып утырган камыш куышлардан йокылы ирәннәр атылып чыга башладылар. Алар яшьләр иде, анадан тума шәрәләр иде. Битләренә төшкән озын чәчләрен артка сыпырыштырып, ачылып җитмәгән күзләрен уыштырып алар ут капкандай читкә йөгерделәр.

Куышлардан бер ярты чакырым чамасы ераклашкач та, шәрә яшьләр Аксу елгасына килеп төртелделәр. Вак ташлар өстеннән шаулап, ашыгып аккан елга артык киң дә, тирән дә түгел иде. Тик аның ярлары гына текә иде. Ирәннәр, бер-берсен узышып, шыбырдашып яр астына коелдылар. Берәүләр, һау-һаулап, кычкырып, бар көченә аска сикерде һәм исән-имин җиргә баскач, су чәчрәтә-чәчрәтә елга аша чыкты да каршыдагы ярдан өскә үрмәли башлады. Икенче берәүләр, сикереп тормыйча, яр битеннән шуышып кына төштеләр һәм, эре ташлар өстеннән зур-зур атлап, шулай ук икенче якка омтылдылар. Кайберәүләр ялгыш басып аякларын авырттырдылар, кайберләре мәтәлеп китте. Арада бер-берсенә бәрелешеп, җиңелчә генә, тавыш-тынсыз гына йодрыклашып алучылар да булды. Икенче якта тигезлек әкренләп үргә күтәрелде. Ирәннәр, яр өстенә килеп менгәч тә, кызулыкларын киметмәскә тырыштылар. Шулай да үргә каршы йөгерү җиңел булмады. Йөрәкләр ешрак типте, куллар ныграк селтәнде, адымнар әкренәя башлады.

Бернинди куак-фәлән үсмәгән, ачык, шома калкулык башына яртылаш җиргә күмеп, киң авызлы чүлмәкләр утыртып куелган иде. Чүлмәкләргә исә башаксыз уклар—бер башы кызылга буялган шома таякчыклар тутырылган. Шунда ук чүлмәк янында кырыс йөзле өлкән яшьтәге күзәтчеләр басып тора. Калкулык башына менеп җиткән һәркем чүлмәкне әйләнеп үтә һәм бер үк таягын эләктерә дә, алдын-артын карамыйча кирегә йөгерә.

Аксу аръягындагы камыш куышларга җитәргә бер ике йөз-өч йөз адым кала аларны калкулык башындагы кебек үк кырыс йөзле өлкән яшьтәге багалар каршы алалар. Кызарынган, еш-еш тын алган ирәннәрнең һәркайсы багага кулындагы таякчыгын тоттырды, исемен әйтте. Бага аның исемен кулындагы такта кисәгенә билгеләп куйды. Тактага исеме билгеләнгән ирән

шундук читкә китеп барды, тиешле урынга килеп чүгәләде дә, иркенләп йомышын үтәргә тотынды. Аның бу эшен шулай ук күзәтчеләр карап тордылар.

Мәмли ул иртәдә үзен иң бәхетле кеше итеп сизде. Йокыдан ул иң беренче кеше булып уянды, куышыннан иң беренче булып чыгып йөгерде һәм елга аръягындагы чүлмәкләр янына да иң беренче булып барып житте. Тигез жирдән йөгереп барганда да, ярдан сикереп төшкәндә, су аша чыкканда да— бер кайда да төртелмәде дә, каты нәрсәгә дә басмады. Башаксыз укны ул шулай ук күзәтчегә иң беренче булып китереп тоттырды. Сөенеченнән елмаеп ул тиз генә як-ягына каранып алды—якында да, еракта да елга ягыннан килүчеләр арасында әле куышлар янындагы күзәтчеләргә якынайган беркем күренмәде. Барлык иптәшләрен ул ким дигәндә кырык-илле адымга артка калдырган иде.

Мәмли үзен жинүче итеп тойды. Ана бик тә күнелле булып китте. Әгәр бага кушса, ул хәзер берни уйлап тормыйча, янадан йөгереп китәр һәм янадан елга аша чыгып, чүлмәктән тагын бер ук алып килә алган булыр иде. Ана, билгеле, андый боерык бирүче булмады. Эшен бетергәч ул, тәмам тынычланып, күтәренке күнел белән, шулай да елгага таба китте. Хәзер инде яхшылап юынырга кирәк иде. Булачак алып ир теләсә нинди кыенлыкны жинә ала торган, батыр, таза һәм тәвәккәл генә түгел, ул чиста һәм чибәр дә булырга тиеш.

Ул багалардан ераклашып өлгермәде, ниндидер ямьсез тавыш ишетеп, ялт кына артына борылып карады. Шул чакны ул усал баганың кемнедер камчы белән сыдырганын күреп алды. Бага бар көченә сукты һәм шундый ярсып сукты, Мәмли жиһедән үргән камчыны үз тәнендә тойгандай булды. Ул сискәнеп китте, ирексездән кире килде. Бага камчысына эләккән яшь ирән аның күршесе Үти булып чыкты. Үтине шәп кеше дип булмый, билгеле, шулай да аның әчен тотып жирдә бөгәрләнеп ятуын күрү дә күнелле түгел иде. Чүлмәкле калкулыктан кайтканда ул егылыпмы кулындагы угын сындырган икән. Житмәсә, шәрә тәненә камчы төшкәч, куркудан, авыртудан ул астына да жибәргән иде. Болай булгач Үтинең эшләре шәптән түгел, болай булгач аны тагын йөгертәчәкләр. Бер кеше исә бөтен алайны тоткарлаячак иде.

Шул тирәдәге ирәннәр Үтине кызганудан бигрәк, ана ачуланырга тотындылар. Төрле яктан кычкырган тавышлар ишетелде. Мәмли күршесен якламакчы булды. Жинүче булгач ул ничектер онытылып китте һәм бага алдында күршесен якларга кирәк тапты.

—Берлеккә кичерегез аны, бага!—диде ул күзәтүчегә.

Күзәтче үзенә акыл өйрәткәннәрен яратмый иде. Жинүче Мәмлигә ул бары күтәрелеп кенә карады да, йокылы дәртсез тавыш белән:

—Алай бик кызгангач, барыгыз икегез йөгерегез, диде.—Янынннан булышып барырсың. Карап бар—тагын егыла күрмәсен, суны пычратмасын...

Аның шулай дип әйтүе булды, ирәннәр шаркылдап көләргә тотындылар. Мәмли авызын ачты да калды. Ул телләшеп, карышып торуның мәгънәсез икәнен аңлады. Ул кып-кызыл булды һәм әле булса аягына баса алмаган Үтинең кулыннан тотты да, торырга булышты.

— Әйдә!—диде ул аңа, аягына басарга булышып.

Алар янадан йөгерделәр һәм янадан ук алып килгәнче, шактый вакыт узды. Икенче мәртәбә килгәч, күзәтүче Мәмлигә:

—Бүгенге жинүен саналмый.—Икенче кирәкмәгән жиргә кысылмассын— диде.

Мәмлинең йөзе агарынып китте. «Нишләп саналмый?» дип әйтәсе килде аның. Ләкин ул телен тешләп тынып калды—өйрәтүчеләр белән телләшүнен

нәрсә икәнлеген инде аңлаган иде. Анын ачуы килде. Күзәтчедән бигрәк анын күршесе Үтигә ачуы килде. Хәер, ул аны элек тә яратып житкерми иде.

Ул көнне барысы да Мәмли белән Үтидән көлделәр. Бигрәк тә Мәмлидән көлделәр. Анын өлгерлеген, житезлеген һәм һәрвакыт диярлек өстен чыгуын кайберәүләр яратып житкермиләр иде. Еш кына аннан көнләшәләр һәм жае туры килгәндә аяк чалырга тырышалар иде. Аеруча Зөлмәт куанды. Жиргә тәгәри-тәгәри көлде, эчен уа-уа көлде.

Мәмли эндәшмәде. Үзеннән көлүчеләргә ул ачыктан-ачык ачулана да алмады, шул ук вакытта әлегә ачуын да йота алмады. «Күрсәтермен әле мин сезгә күрмәгәнегезне!»—дип уйлады ул әледән-әле үзеннән көлүчеләргә янап.

Өч көн буена калада туй иттеләр. Кешеләр яңа арпа оныннан күмәч пешерделәр, яңа арпа ярмасыннан ботка пешерделәр һәм яңа арпадан ачытырга сыра куйдылар. Шунын янына, хәлле хәленчә, куй суйды, аш-су ясады. Өч көн буена калада, якын тирәдә дингез буйларында күнелле шау-шу, уен-көлке, жыр-музыка ишетелеп торды.

Өч көннән соң бөтен кала ныклап торып уракка тотынды. Жиргә, игенгә кагылышлы эшләрнең барысын да изге саналганга, арпа уруны да барлык йолаларны саклап жиренә житкереп башкарырга тырыштылар. Һәркемнең өендә, чормасында әле борынгылардан калган таш ураклар бар иде. Күптән инде таш ураклар белән урмасалар да, беренче кишәрлекне бары таш урак белән генә урдылар һәм аны ин элек йорт башы, ата кеше, би кеше башкарды. Шуннан соң беренче кишәрлекнең арпасын бик кадерләп жыеп, көлтәләп һәм көлтәләрне ишәк сыртына салып, калага алып киттеләр. Шуннан калган барлык эшне ир затындагы каралар, коллар башкарды.

Иген игү эше тулысынча ирләр эше санала иде, шунлыктан арпа кырына хатын-кызлар якын да килмәделәр. Ләкин урак вакытында һәркемгә эш житәрлек булды. Берәүләр урылган ашлыкны калага ташып торды, икенчеләре ындыр табакта эшләде, өченчеләре сугылган ашлыкны жилгәреп, киптереп, тирән чокырларга тутырып торды. Бары тик дингез буенда, елга тамагы буенда кәмә ясаучы балта осталарын гына эшләреннән аермадылар—ул якта иртә таңнан алып кичкә кадәр балта тавышы ишетелеп торды.

Кала саклауны һәм арпа басуындагы уракчыларны саклау эшен коралны ирләр белән бергә яшьләргә дә йөкләделәр. Мондый чакта кыргый таурлар искәрмәстән килеп чыгып, йә уракчыларны, йә ашлык ташучыларны кырып ташлыйлар һәм урылган ашлыкны урлап качалар иде.

Яшьрәк үсмерләр алаен, тәжрибәле ирләр житәкчелегендә, коймага һәм манарага куйдылар. Быел соңгы елы булган Зөлмәтләр әндерен урак басуына жибәрергә булдылар. Типкә би үзенен бер-ике кешесен ияртеп, иртәдән башлап кичкә кадәр ат өстендә килеш, әледән-әле барысын күзәтеп, тикшереп йөрде. Анын үзенен ун пирәйөз арпасы, утыз пирәйөз бодае, борае, тарысы һәм башка ашлыклары, яшелчә-жимешләре бар иде. Ул би һәм кала башлыгы буларак мондый чакта үз жирләренә, үз колларына гына түгел, бөтен илкөнгә күз-колак булырга, кирәк чакта башкаларга ярдәмләшергә тиеш иде.

Менә шундый кызу урак башлану белән, икенче көнне таң аткач, Мәмли янына пир ата белән иптәшләре килде. Анын жинелүенә, егылуына инде өч көн тулган. Ул өч көннән артык ятарга тиеш түгел иде. Өч көн эчендә аягына басып, янадан элекке хәленә кайта алмаса, бер елга анын яше киметеләчәк һәм ул түбәнге әндеригә күчереләчәк яисә бөтенләй әндеридән чыгарылып өенә кайтарылып жибәреләчәк иде.

Мәмлинен бик каты башы авырта, башы әйләнә һәм ул бик хәлсез иде. Шулай да ул иптәшләрен аяк өсте елмаеп каршыларга тырышты. Корышып

беткән чандыр пир ата да сөекле оныгын—батырын аяк өсте күреп, елмайгандай итте һәм анын аркасыннан сөеп куйды.

—Сине алырга килдек, улым,—диде ул якын итеп.

Башкалар да шаулашып, үз итеп анын кулын кысарга, анын аякка басуы өчен үзләренн сөенечен белдерергә тырыштылар. Ин азактан анын янына Зөлмәт килде. Дустынын күзенә туры карамаска тырышып, гаепле сыман, ул ана кулын сузды. Үзенен жинүче дустын күргәч Мәмлинен бөтен тәне эсселе-суыклы булып китте, йөзенә кан бәрде, шулай да ул үзенен тойгыларын сиздермәскә тырышып, үз-үзен мәжбүр итеп, сузылган кулны учына алды һәм теләмичә генә күрешеп йомшак кына кыскандай итте.

—Сина үпкәм юк,—диде ул, авыз эчендә мыгырданып, кызарынып.

Шуны гына көтеп торган яшьләр хуплап, шаулашып алдылар һәм шаяртып аларнын икесен дә әйләндереп кочтылар, мактадылар. Пир ата да мактау, хуплау сүзләре әйтте. Шуннан сон ул Мәмлигә Типкә би боерыгын житкерде.

Бу юлы алар, чын сугышчылар кебек киенеп, чын кораллар белән коралланып, атка атланып, кала капкасына һәм кала урнашкан калкулык өстендәге юлдан сулга, көнбатыш яктагы кин үзәнгә—ашлык басулары ягына юнәлделәр.

Иген кырларында һәм яшелчә-жимеш бакчаларында урыласы ашлык урылып, жыеласы яшелчә-жимеш жыеп алынгач, өлкән үсмерләр әндериенә беренче мәртәбә авыр, катлаулы һәм жаваплы йомыш тапшырыла иде. Мондый чакта би кораллы яшьләрне йә булмаса берәр кабиләгә каршы сугышка жибәрә, йә булмаса кәмәгә утыртып, ерак юлга сәфәргә озата иде. Яшьләр беренче мәртәбә пир ата һәм өлкәннәр күзәтүеннән башка үзләренен белемнәрен, осталыкларын тормыш шартларында сынап карарга тиешләр иде. Үз бурычларын жиренә житкереп тиешенчә үтәгән очракта гына аларнын өйрәнчеклеге тәкәлгән исәпләнелә һәм шуннан сон алар өйләнә алалар, өйләнгәч исә тулы хокуклы ир кеше буларак, кала эшләрендә, идарә эшендә катнаша алалар, идарәгә анда-монда сайлана алалар иде.

Берничә ел инде Типкә би олы сынауга дип яшьләрне күршеләргә яуга да жибәрми, кәмәгә утыртып ерактагы илләргә сату-алуга ерак юлга да озатмый иде. Аккаладан бер илле чакрым чамасы төньяк- көнчыгышта, таулар-урманнар арасында моннан ун еллар элек, кыргый таурлардан яна жир яулап, мака сар яна кала салдырды. Таулар арасындагы үзәннәр иген игү өчен дә, мал асрау өчен дә әлләни унайлы түгел иде. Ләкин анда лелеглэр якында гына яткан бакыр һәм көмеш катламнары таптылар. Яна калага мака сар үз халкынын яртысын күчерде дә, кыргый таулар-урманнар арасында читтән китерелгән коллар, каралар көче белән бакыр һәм көмеш чыгаруны жайлап жибәрде. Бакыр кала дип аталган каланын үзенен кораллы көчләре күп түгел иде. Шунлыктан эретелгән, калыпларга салып катырылган бакыр, көмеш бәлешләрен ике-өч айга бер мәртәбә кораллы алай жибәреп, Аккалага алып кайталар иде. Аннан сон Алтын уртадан сәүдә кәмәләре килгәч, төзү агачлары, ашлык, затлы таш, чүлмәк, савыт-саба һәм чибәр коллар белән берлектә ул алтын-көмеш, бакырны да башкалага изге патша мака сарга озатып тора иде.

Быел да ул көзге эшләр беткәч өлкән үсмерләр алаен Бакыр калага жибәрергә дигән карарга килде. Шул турыда ул ин элек пир атага әйтте.

—Алга кемне куярсын икән?—диде ул ана.

Пир атанын нәрсә дип жавап бирәчәген ул, билгеле, яхшы белде. Ул моны болай гына, эче пошканнан гына сорады. Күптән инде ул Мәмлине үз кеше итеп күз алдына китерергә күнеккән иде. Мәмли, анын үги улы, ана бар яктан да ошый иде, тик менә Арпа-ана туенда анын жинелүе генә бөтен нәрсәне чуалтып ташлады.

—Барганда алдан Зөлмәт булыр, кайтканда—Мәмли,—диде пир ата, чак

кына уйлангандай итеп.

Пир атаның акыллы сүзенә бинең исе китте. Кара син аны! Ул менә никадәр баш ватып та, нишләптер бу рәвешчә уйлый алмаган иде. Аның җинелгән Мәмлинең дә, шулай ук җиңгән Зөлмәтнең дә күңелләрен кырасы килмәгән иде.

Хәзер аның бу турыда артык баш ватасы килмәде—аның кайгы-борчулары болай да җитәрлек иде. Пир ата белән сөйләшкәч, Типкә би амбарлар ягына китеп барды. Анда башкалага озатыласы ашлыкларны үз күзең белән күреп, барлап куясы һәм чүлмәкләрне тамгалыйсы бар иде.

Пир ата исә би яныннан чыккач та үзенең ирәннәре янына ашыкты. Ул аларга бинең сүзләрен җиткерде һәм иртәгә иртүк, берәр ат тагып, ерак юлга чыгарга боерды.

—Барганда Зөлмәт алдан барыр, кайтканда—Мәмли,—диде ул би алдында әйткән сүзләрен кабатлап.

Шулай дигәч тә ул игътибар белән яшьләрнең йөзенә карап алды.

Бүтән вакытта теләсә кая барганда пир ата үзе төркем алдыннан бара иде, хәтта чынлыкта ул читтән барса да, ул алдан баручы булып исәпләнелә иде. Алдан бару исә ул егерме кешелек алайга баш булуны аңлата иде. Егерме кешенең һәркайсы тиешле шартларда бөтен төркем башы, җитәкче була алса да ун башы яисә йөз башы бары бер генә кеше була ала һәм башкалар һичшиксез аның боерыкларына буйсынырга тиешләр иде. Зөлмәтләр әндериендәге үсмерләр Зөлмәтнең еш кына баш булуына ничектер үзеннән-үзе күнеккәннәр һәм аны пир атадан кала икенче кеше дип исәплиләр иде. Мәмли бар яктан да Зөлмәт белән бер чама булса да, ана бик үк теләмичә генә буйсыналар иде. Аның кыланышларында, үз-үзен тотышында башкаларны читләштерә торган кайбер кимчелекләре бар иде. Билгеле, ул да батыр һәм көчле, ләкин ул күбрәк кеше исәбенә яшәргә һәм үзеннән көчсезләрне ничектер кысарга, түбәнсетергә тырыша. Аның бу якларын көчсезрәкләр аеруча авыр кичерәләр иде.

Пир атаның боерыгын яшьләр шатланып каршы алдылар. Мәмли дә бернинди ризасызлык белдермәде. Бары тик Зөлмәтнең генә йөзе ачылмады. Ул, күрәсең, моннан соң инде бөтен алайда үзен генә иң көчле, иң батыр кеше дип исәпли башлаган иде. Ләкин пир атага каршы ул шулай да берни әйтмәде. Хәер, пир ата боерыгына каршы килергә аның әле бернинди хокукы да юк иде.

Икенче көнне алар кояш чыкканчы ук тордылар, ашадылар-эчтеләр дә шундук кузгалып киттеләр. Юл башта калкулык сыртыннан, чәнечкеле гөлҗимеш куаклары арасыннан барды, аннан соң сөзәк тау битеннән төште һәм таулар арасында сузылып яткан киң үзәнгә килеп керде. Калкулык башында шундый салкын һәм көчле булып тоелган иртәнге җил түбәндә бөтенләй юашланып калды. Күп тә үтмәде, диңгез ягындагы таулар артыннан елмаеп кояш чыкты. Дөнья шундук яктырып һәм ямьләнеп китте.

Үзән уртасыннан, куе камыш һәм тал куаклары арасыннан, сай гына, шулай да җитез генә Аксу агып ята. Кала ягыннан килгән юл, елгага якын килергә курыккандай, бераз җир читтәрәк барды да, уңга борылып, камышлы ярлар ягына каерды. Юл борылу белән, төркем башындагы Зөлмәт атын туктаткандай итте. Башкалар да туктап калдылар, җиргә төштеләр һәм, коралларын салып, елга ягына аркан борылып, иртәнге йомышларын йомышладылар. Шуннан соң янадан алар каты киемнәрен киделәр, билләрен будылар һәм коралларын кулларына алып, атларын суга якын алып килделәр. Су иясенә атап иң элек корбан бирделәр дә, ташлы яр читенә ятып үзләре дә су эчтеләр, атларын да эчерделәр.

Елга аша чыккач юл икегә аерылды. Аның берсе яр буйлап төньякка таба

китте, икенчесе унга—көнчыгышка каерды. Атлы, кораллы яшьләр ун якка юнәлделәр. Алар үзәнне аркылы чыктылар да ике тау арасындагы тарлавыкка килеп керделәр. Тарлавыкта җил бөтенләй тынып калды, шул ук вакытта кояш нурлары да юкка чыкты. Монда бераз гына дымлырак, бераз гына караңгырак һәм бераз гына куркынычрак иде. Ике яктан да таш араларыннан, таш өсләреннән каты, кәрлә куаклар, нидер теләнгән сыман, кәкре-бөкре ботакларын сузып утыралар иде. Кайбер җирдә таш астыннан тамчылап кына су саркып ята, шунлыктан аяк асты юеш һәм тайгак иде.

Ат өстендәге яшьләр, очлы ботаклардан, күзгә төртелеп торган чыбыклардан сакланып, әле күзләрен капладылар, әле читкә каерылдылар, йә булмаса башларын иделәр. Иң алдан баручы Зөлмәт унга-сулга селтәнеп җиз балтасы белән әрсезрәк ботакларны кыеп-кыеп төшерде.

Тарлавык бөтенләй боргаланып торган ташлы-түмгәкле сукмак башта үргә таба менде, аннан соң түбән таба төшә башлады. Үр менүе шактый авыр булды. Әледән-әле атларның аягы тайды, аяк астыннан шома ташлар шуып-тәгәрәп китте. Бара торгач атлар, ниндидер ят исләр сизеп, пошкыра, тынычсызлана башладылар. Яшьләр исә, Селәүсен тарлавыгы турында сөйләнелгән имеш-мимешләрне исләренә төшереп, сөңгеләрен әзер тоткан килеш, туктаусыз як-якларына каранып бардылар. Былтыр шушы тарлавыкта бер аучыга аю ташланган. Аюдан бигрәк монда һәрбер таш артында, һәрбер куак артында таур сагалап торырга мөмкин. Алар шулай искәрмәстән һөҗүм итеп, бик күп кешенең башына җиттеләр.

Тарлавык әлләни озын түгел иде, ләкин өркә-курка чыкканга һәм бик әкрен барганга ул очсыз-кырыйсыз булып тоелды. Менә, ниһаять, чытырман арасына кояш нурлары үтеп керде. Юлчылар тарлавыкның икенче ягына якынлаштылар һәм сөенеч тойгысына бирелеп, җинелчә шаулашып алдылар. Озакламый көн яктырды, ботак-сатаклар, таш катламнары, текә ташлар читкәрәк киттеләр. Күз алдында искиткеч киңлек, иркенлек ачылды. Тар сукмактан, тар аралыктан бөгелә-сыгыла килгән кораллы яшьләр барысы берьюлы диярлек билләрен турайттылар һәм барысы берьюлы диярлек елмаеп җибәрделәр. Атлар да, башларын чайкап, җинелчә пошкырып, шәбрәк атларга тотындылар. Югары күтәрелгән сөңге җизләрендә, яшь сугышчыларның каты киемендәге җиз калайларда, җиз калбикларда шатланып кояш нурлары балкыды, яшь күзләр шептекләп ниндидер ят күрмәгән нәрсәләр күрергә өмет итеп, еракка, зәңгәр офыкка текәлде.

Тигезлекнең каршы ягындагы, шәүлә сыман гына булып, күксел сыртларын кабартып, тоташ таулар тезелеп киткән. Таулар тезмәсенең сул ягында якынрак, шулай ук таулар... таулар калкып утыра. Сул яктагы таулар, якынрак булганга һәм иртәнге кояш нурлары белән яктыртылганга, аеруча биек, тамыр-томырлы һәм кыргый булып күренә. Унда исә дингез һәм дингез култыклары булырга тиешле якта әле яшеллеген җуймаган урман белән капланган тәбәнәк калкулыклар сузылып китә. Таулар арасына ташланган бик зур озынча табакны хәтерләткән бу гаҗәеп тигезлекнен уртасында, ап-ачык булып, зәп-зәңгәр булып зур гына түгәрәк күл ялтырап ята. Күлнең читендә үләне көйгән болыннар артында аеруча ачык һәм матур булып, куе-яшел төстәге камыш куаклары күренә. Күлнең аргы ягында очлы башлы камыш куышлар тырпаеп утыра. Куышлар тирәсендә, кырмыскалар шикелле, кешеләр кыймылдаша. Бер-ике җирдә иренеп кенә күккә аксыл төтен күтәрелә. Күлнең бу ягында исә биш-алты сыердан һәм унлап-унбишләп сарыктан торган көтү аптырап тора.

Күлле таба дип аталган әлеге үзәндә таурларның өч авыллы Марис кабиләсе яши иде. Марислар күрше үзәндәге, дингез буендагы Аккала кешеләре белән ачыктан-ачык дошманлашмыйлар, кайчагында калага барып алыш-биреш

итәләр, кайчагында бидән, лелегләрдән теләнеп, ашлык, җимеш-фәлән алып китәләр. Кайчагында исә үтерүдән, чәлдерүдән дә тартынып тормыйлар иде.

Сукмаксыман юл яисә юл сыман киң сукмак, күлне, таурларны унда калдырып, корыган каты үлән арасыннан таулар ягына шуышты. Сукмак буенда агарып, саргаеп беткән, эре баш сөякләре, кабырга һәм умырткалык сөякләре аунап ята. Болар, башлыча, төнлә ерткычлар ботарлаган хайван сөякләре иде. Арада кеше сөякләре дә очрады.

Таурлар әз-мәз хайван асрыйлар һәм балык тоталар. Күбрәк вакытларын исә күрше кабиләләр белән сугышта һәм юлбасарлыкта үткәрәләр. Сукмак буенда аунап яткан кеше сөякләре менә шуның нәтиҗәсе булырга тиеш иде. Күрше кабиләләр белән алар бигрәк тә баш сөяген яулап алу өчен сугышалар. Кем күбрәк баш сөяге яулап ала алган булса, андый кеше кабиләдә иң батыр һәм иң хөрмәтле сугышчы исәпләнелә. Лелегләрнең шушы сукмактан йөргәнлекләрен белгәнгә күрә, куркыту өчен, әлеге сөякләрне таурлар үзләре китереп ташлаган булырга тиеш.

Үлән арасында аунап яткан сөякләр яныннан коралларындагы, киемнәрендәге җизләрен, көмешләрен елкылдатып каты җир өстеннән җинелчә юырттырып барганда, яшьләр авыл ягында нindидер ыгы-зыгы күреп алдылар. Күл ягындагы кешеләрнең бер-берсенә каты итеп, ямьсез итеп кычкырганы ишетелде һәм күп тә үтмәде анда, берничә кеше бер төркемгә тупланып алды да, ашыгып атлыларга каршы йөгерә башлады.

Яшьләр туктагандай иттеләр, атларын килүчеләргә каршы бордылар да, коралларын җайлабрак тоттылар.

—Тукта! Качма!—дип кычкырдылар таурлар ерактан атлылар төркеменә, янап.

—Көтик әле—нәрсә кирәк икән аларга?—диде Зөлмәт сагаеп.

—Безгә каршы яу кыләләр,—диде шунда кемдер, мыскыллы көлемсерәп.

—Җиз татып карыйсы килә боларның,—диде яшьләрнең икенчесе.

—Шаулашмагыз. Үзем сөйләшәм!—диде Зөлмәт кисеп.

Ашыгып йөгергән таурлар төркеме, атлыларга бер ун адым килеп җитмичә туктап калды. Марисларның барысы да анадан тума диярлек шәп-шәрә, бары тик корсак асларына, оятлы җирләрен каплап, каешланып беткән тар гына күн кисәге асылынып тора иде. Беркайчан тарак йөзе күрмәгән, толымнарга үрелмәгән озын чәчләре, ат ялы сыман, таралып, иңбашларына төшеп тора. Кулларына алар тоткасы шомарып беркән чукмар башлы күсәкләр тотканнар иде.

—Якынрак кил, ник кычкырасың?—диде Зөлмәт, таурлар төркеменен башлыгы Мариска.

Марисның Аккалага килгәне бар, шунлыктан аны Зөлмәт тә, башкалар да күреп тә, ишетеп тә беләләр иде. Марис ялындырып тормады, бер-ике адым алгарак чыкты да, башы җиз калай белән тышланган, тоткасы көмеш белән бизәлгән зур күсәгенә таянып, Зөлмәтнең йөзенә төбәп карады.

—Курыкмасаң үзен кил!—диде ул Зөлмәткә.

Ул бик зур гәүдәле һәм бик таза кеше иде. Аның таш сыман каты шәрә тәнендә бер генә яраланмаган, җәрәхәтсез урыны юк сыман. Бу исә аның күп сугышларда, орышларда катнашып та исән калуы һәм аның чыннан да нык булуы турында сөйли иде. Муенса урынына муенына ул, нечкә көмеш чылбырга тагып, алтынланган кеше башы тагып куйган. Бу аның иң явыз дошманы—төньяктагы күрше Әнчекләр кабиләсенең өлкәне Нәреш ту башы иде.

Зөлмәт, атка атланган һәм коралланган булса да, күсәгенә таянып, аякларын аерып басып торган Марис янында шактый көчсез, өтәләнгән бала-чага булып күренде. Кыргый таурның шулай кыю сөйләнүенә, борын чөюенә хурланып

ул кызарынып китте һәм тыелып кына, шулай да кырыс итеп:

—Әйт, ни кирәк?—диде.

—Көмәч бир, ярма бир!—диде Марис.

—Сездә ашлык күп—ашлык бир!

—Ашарга бир!—дип кычкырдылар таурлар, күсәкләре белән янап.

—Монда көмәч тә юк, ярма да юк,—диде Зөлмәт, ансыз, оятсыз таурларга шулай да нәрсәдер аңлатырга кирәк табып.

—Калага бар, анда сиңа бирерләр кирәгенне!—диде шул чакны теләсә нәрсәгә кысылырга ярата торган Үти, янап. Зөлмәт, ярсып, Үтине шундук ачулы күз карашы белән өтеп алды. Зөлмәт алай башы буларак, башкаларның кысылганын яратмады.

—Ашарга бирмәсәгез, беркая китмисез!—диде Марис нык итеп һәм эре, тигез тешләрен күрсәтеп елмайгандай итеп куйды.

—Җибәрмибез!

—Китмисез!—дип кычкырдылар башка ирләр, үзләренең туын—баш кешесен яклап. Яшьләр күбрәк иде, таурларга караганда алар, билгеле, яхшырак коралланганнар иде. Бик теләгәндә алар—лелекләр, әлеге төркемне генә түгел, бөтен авылларын да күз ачып йомганчы кырып ташлый алган булырлар иде. Кайбер түземсезрәкләр чыннан да шаулаша башладылар. Монарчы бәхәскә катнашмыйча кырыйдарак торган Мәмли алгарак чыкты һәм корал белән янаучы, шаулашучы юлдашларына карап:

—Туктагыз әле,—диде,—безгә таурлар белән сугышу бурычы йөкләнмәгән. Безгә туп-туры Бакыр тауга барырга кирәк.

—Беләбез,—диде Зөлмәт, коры гына, Мәмлинең монда килеп кысылуын яратмыйча.—Кайтканда син баш булырсың—менә шунда үзеңчә эшләрсең!

—Эшләрмен дә шул!—диде Мәмли, кызарынып.

Теге йодрык сугышыннан соң иптәшләре алдында бу аларның беренче әйтешүләре булды. Моңарчы алар бер-берсенең күзенә чалынырга курыккан сыман, ничектер бер-берсеннән читтә булырга тырыштылар.

—Ничек эшләрсең икән—әйтеп карале?!—диде Зөлмәт, мыскыл сизелеп торган бер өстенлек белән.

Мәмли аның мыскылына игътибар итмәскә тырышты һәм, Зөлмәттән бигрәк, таурлар туына карап:

—Мин болай эшләрмен—безнең хәзер чыннан да үзебез белән алган көмәчебез дә, ярмабыз да юк. Теләсәк тә без сезгә берни бирә алмыйбыз. Бакыр таудан кайтканда без сезгә ярма да, икмәк тә алып кайтырбыз, хәзергә менә шуны алып тор...

Ул, шулай диде дә, алтын-көмеш тәңкәләр белән бизәлгән бил каешын ычкындырып, Мариска ыргытты.

—Минннән сиңа бүләк!—диде ул.

Таур туы уң кулындагы күсәген җиңел генә югары күтәрде һәм бил каешы җиргә төшеп өлгергәнче аны күсәк башына эләктерде дә, сул кулы белән бүләкне тотып алды, елмаеп җибәрде. Күрәсең, үзләрен җиңүче санап, башка таурлар да елмаеп җибәрделәр, куанышып шаулашып алдылар.

—Ярар, синеңчә булсын,—диде Зөлмәт Мәмлигә, теш арасыннан гына.

Якындагылар күреп тордылар—Мәмлинең таурларга биргән вәгъдәсе дә, бүләге дә Зөлмәткә ошамады. Күрәләтә аның чырае сытылды. Шулай да ул Мәмлигә каршы да килә алмады. Әле булса алар арасында киеренкелек һәм астыртын дошманлык саклана иде бугай.

—Бар, кит. Мин сине җибәрәм,—диде таур алыбы, Зөлмәткә кулын селтәп.—Кара аны, кайтканда көтеп торырмын,—диде ул ахырда, кисәтеп.

Яшьләр кузгалып киттеләр һәм юл буена шаулашып әлеге очрашу турында фикер алыштылар. Бары тик Мәмли дә Зөлмәт кенә сүзгә катнашмадылар.

Кояш төшлеккә житеп килгәндә, алда Бакыр кала күренде. Бакыр кала сирәк-мирәк әрәмәләр белән капланган биек тау башына урнашкан иде. Тау астыннан тау түбәсенә—таш киртә белән уратып алынган калага кадәр урман кисеп туры юл салынган. Урман юлыннан бер-бер артлы тезелеп атлылар килүен манара башындагы сакчылар ерактан ук күреп-күзәтеп тордылар ахрысы. Кораллы жайдаклар очлы жизләрен ялт-йолт китереп, калбикларындагы кош каурыйларын тирбәндереп, капка янына килеп житәр-житмәс, кунак килүен хәбәр итеп, быргылар кычкырды һәм көттереп-нитеп тормыйча, каерылып капкалар ачылды.

Яшьләрне Кодрәт бага үзе каршылады. Ул имәндәй таза, төз һәм зур гәүдәле урта яшьләрдән өлкәнрәк бер кеше иде. Кодрәт тархан Типкә бинең элекке йөзбашы, Типкә бигә буйсына, ләкин Бакыр каланың үзендә һәм якын тирәдәге тауларда, үзәнлекләрдә—жир өстендә һәм жир астында—барлык лелекләр һәм барлык каралар-коллар, бакыр эзләүчеләр, бакыр эретүчеләр берсүзсез аңа буйсыналар. Аның көче, кырыслыгы, йөзенә чыккан иде. Аккаладан, ерак юлдан килгән яшьләрне күрү белән ул исәнлек-саулык сорап бер-ике сүз әйтте дә, алай башлыгы Зөлмәткә бер күз карашы гына ташлап алды да, куна тактасыдай киң аркасын борып, кара чәч толымнарын селкетеп, тузанлы юлдан каядыр каралты-куралар, таш өйләр ягына китеп барды. Яшьләр башта аның таш йөзен, аннан соң таш аркасын күрү белән кинәт шып булдылар, бөрешеп калдылар һәм, шауламаска тырышып, тархан артыннан иярделәр.

Кодрәт бага аларны тар гына урамнан алып китте. Урамның ике ягында да артык биек булмаган таш өйләр, таштан, агачтан эшләнгән киртәләр сузылды. Өйараларында ботакларын жәеп утырган жимеш агачлары күренеп калды. Тар урам тиз арада кала уртасындагы киң ачыклыкка килеп чыкты. Каршыда тарханның тигез итеп киселгән, шомартылган ак таштан салынган ике катлы йорты балкып утыра, аның янындарак исә тәбәнәгрәк башка йортлар күренә иде. Кодрәт тархан аларны тыштан жиз белән тышлаган зур гына ишеге булган амбарсыман таш каралты янына алып килде. Ишек янындагы таш өстендә, сабы шомарып беткән кыска сөңгесен таяк сыман таянып бер сакчы карт утырып тора иде. Кешеләр якынлашу белән ул ашыгып урыныннан торды, тарханга баш игәндәй бер хәрәкәт ясап, читкәрәк китте. Кодрәт тархан исә билендәге киң каешка тагылган жиз ачкычның берсен алып, ишекнең йозагын борды да, авыр ишекне шыгырдатып ачып жибәрде.

Яшьләр үзләре белән озынча күн капчыклар алып килгәннәр иде. Буш капчыкларны алар ишек төбенә өеп куйдылар. Бага капчыкларны санап тикшереп торды. Шуннан соң ул яшьләрне берәм-берәм ишектән кертә башлады. Бераз гына дымлы сыман тоелган ярым караңгы амбар уртасына, идәнгә күн капчыклар өеп куелган. Капчыкларга икешәр кисәк бакыр бәлеше салынган, капчык авызы ныгытып бәйләнелгән һәм балавыз кисәге белән тамгаланган иде. Һәр бәлеш егермешәр гөрәнкә, ике бәлеш кырык гөрәнкә иде. Яшьләр берәр капчык алып чыктылар да, озынча капчыкны урталай бөкләп, эчмәк сыман итеп, буш атларының сыртына салдылар. Капчык эчендәге бакырларның берсе ат сыртының бер ягында, икенчесе икенче ягында калды. Шуннан соң капчыкка беркетелгән озын каеш бауларны атның корсак астыннын үткәреп, авыр капчыкны яхшылап бәйләп куйдылар.

Ишектән кергән-чыккан һәркемне бага санап-билгеләп торды. Ишектән чыккан һәркемнең исемен сорады һәм капчыкны ат сыртына салганчы, капчык авызын ныклап бәйләнгәнме-түгелме, тамгалы балавызның төзекме-түгелме икәнлеген тикшерергә кушты. Егерме яшь ирнең егермесе дә үзләренә тиешле капчыкны алып чыккач ул ишекне яртылаш япты да, жирдәге буш капчыкларны берәм-берәм күздән кичереп чыкты. Шуннан соң ул башын калкытты, билен язды.

—Булды. Барысы да бар. Алдым-бирдем,—дип куйды. Аннан соң ул әле һаман жыенып бетә алмаган яшьләргә күтәрелеп карады.

—Кайсыгыз баш соң әле сезнең?—диде.

—Мин,—диде Зөлмәт.

—Юк, мин,—диде Мәмли ана каршы.

Бага, берни аңламыйча аптырагандай итеп әле Зөлмәткә, әле Мәмлигә карап алды.

—Баш бер генә була,—диде ул.

—Килгәндә Зөлмәт баш булды, кайтканда—Мәмли!—диде Кодрәт багага якынрак торган Үти, аңлатып.

Кодрәт бага тамак кыргандагы сыман бер гырылдык тавыш чыгарып, көлгәндәй итеп куйды.

—Пир ата өйрәткән сезне акылга!—диде ул.—Ярар, капкадан чыкканчы—Зөлмәт, капкадан чыккач—Мәмли баш булыр. Зөлмәт! Мәмлигә әйт, бигә әйтсен, бакыр ташы чыгарырга кеше җитми. Биш кеше үлде, өчесе качкан. Кеше җибәрсен, бер ун батман яна арпа кирәк. Сыра кайнатырга.

—Әйтермен,—диде Зөлмәт теләр-теләмәс кенә.

Зөлмәт Кодрәт баганың шаяртып сөйлиме, чынлап сөйлиме икәнлеген аңлап җитмәде. Ни генә булмасын, аның мондый хәлгә тарыганы юк иде. Шунлыктан аның тизрәк моннан чыгып китәсе һәм бар җаваплылыкны үз өстеннән төшерәсе килде.

—Олуг бага—диде шул чакны Зөлмәт, «арпа» дигәннән, таурларны исенә төшереп.—Син безгә бераз икмәк бирә алмассыңмы?

Баганың йөзе үзгәреп китте һәм ул Зөлмәткә сынап карап тора башлады.

—Арпаны мин каладан алам,—диде ул коры гына.—Ачыксагыз, кайткач ашарсыз.

—Ни... безгә үзебезгә түгел...—диде Зөлмәт буталып.—Марис алып сораган иде. Аның өчен.

—Марис шулай теләнергә ярата инде ул,—диде Кодрәт коры гына. Зөлмәт нидер әйтмәкче булды, ләкин Кодрәт бага аларны куарга ук тотынды.

—Барыгыз-бар. Әнә көн дә бозылырга тора. Яңгыр яумагае бүген,—диде. Зөлмәт теләр-теләмәс кенә кузгалып китте. Башкалар аның артыннан тагыла тордылар. Кодрәт бага икеләнгәндәй итеп, ары-бире каранып торды да, кинәт кискен генә кулын күтәрде.

—Туктагыз әле!—диде ул, кычкырып.—Дүрт кешегә... бер бөтен эпи алырсыз, мич өенә, икмәк өенә борылыгыз әле.

—Безнең үзебезгә кирәкми, Марисларга кирәк,—диде шунда якында гына Зөлмәт янында торган Үти, аңлатырга кирәк табып.

Зөлмәт Үтигә ачулы күз карашы ташлап алды.

—Сиңа сүз бирелмәгән!—диде Зөлмәт усал гына итеп.—Дүрт бөтен икән—дүрт бөтен. Безгә артыгы кирәкми дә.

—Ярар, камыр өенә бара торыгыз—хәзер куып җитәрмен,—диде Кодрәт бага, бикләнмәгән ишегенә кире барып.

Кодрәт баганың сүзен барысы да ишетеп тордылар һәм күңелле шаулашып, камыр өе ягына борылдылар. Кодрәт баганың камыр өе ике катлы ак өйдән читкәрәк, соргылт ташлары чыгып торган тау янына урнашкан иде. Ул яктан бер өзлексез ниндидер тавыш-гөрелдек ишетелеп тора. Бу гөрелдеккә кеше тавышлары да, якында гына чылтырап таулардан агып төшкән чишмә тавышы да, бала-чага чыр-чуы да кушылган. Камыр өе дип тә, тегермән өе дип тә аталган бу иркен, биек өйнең бер ягында коллар калку такта—сике өстенә утырып, аяк өсте басып кул тегермәннәрендә бер өзлексез ашлык тартып он чыгаралар, икенче бүлмәдә зур мичтә бага өчен, баганың йөзләгән коллары, каралары өчен икмәк пешерәләр. Якындагы чишмәдән таза ирләр зур-зур

чүлмәкләр белән су ташып торалар, икенчеләре әледән-әле утын кертеп, мичкә ягып тора. Шунда ук җиз казанннарда эшчеләр-коллар, каралар өчен ботка пешә һәм сыра кайный. Ул яктан, үзенә бер төрле тавыш, гөрелдек һәм шакы-шокы тавышлары ишетелгән кебек, ул яктан шулай борыннарны кытыклап, яна пешкән эпи исе, тәтен исе килеп тора.

Атлы яшьләр төркеме, тегермән өенә берничә адым житмичә туктап калдылар, аларны арттан куып житкән Кодрәт ачык ишектән эчкә кереп китте һәм бераздан камыш тубылга яна пешкән түгәрәк эпи тутырып ярым шәрә яшь, таза кол килеп чыкты. Ул дүрт кешегә бер бөтен исәбенннән, кемгә туры килә, шуна эпи таратып чыкты да, таратып бетергәч, тубыл авызын аска каратып читкә китеп Кодрәт баганы күтәп торды. Камыр өеннән Кодрәт бага бер бөтен эпи алып чыкты да, төркемнең иң артында торган Зөлмәткә тоттырды.

—Монысы марисларга булыр,—диде ул.

—Ярар,—диде Зөлмәт, алтынчы бөтенне алып.

Шуннан соң алар юлга чыктылар.

Капкадан чыккач, атлылар тезмәсе янача тезелде. Койрыктагылар башка таба уздылар, Мәмли алга чыкты, Зөлмәт иң артта калды. Атларын тыя-тыя алар тау юлыннан аска төштеләр. Бакыр калада тау өстеннән чыккан таштан ташка сикереп, үзенчә шаулап аккан татлы чишмә каяндыр агачлар арасыннан түбәнгә төшеп житкән һәм куе үлән эченнән елкылдап, шуышып агып ята иде. Бер жайлы, иркен урында яшьләр туктап калдылар, жиргә төштеләр һәм атларын тибенгә жибәрделәр дә, үзләре яшел чирәмгә утырып икмәкләрен бүлештеләр. Яна пешкән һәм әле җылысы да бетеп житмәгән бодай икмәген алар бик тәмләп, кадерләп һәм әз-әзләп кенә ашадылар. Ашагач ярга ятып татлы чишмәдән су эчтеләр. Су эчкәч, бу кадәр рәхәтлеккә, бу кадәр изгелеккә исләре киткән сыман, күнел хушлыгын һәм тамак тую ләззәтен бозарга теләмәгәндәй, яшь тәннәрендә рәхәт талгынлык тоеп, беравык тынып, чишмә агышын карап утырдылар. Пир ата Әмәк аларны гел өйрәтә килде: ашау изге эш, диде, ашаганда сөйләшергә, ашыгырга кирәкми, ашагач бераз тынып утырсаң, аякларга, беләкләргә көч күбрәк килә, диде.

Алар шулай бер ярты сәгать чамасы тукланып, онытылып утырдылар. Ул арада атлар да аяк астында бераз ялманып алдылар.

—Алтынчы бөтен синдәме?—диде Мәмли, кузгалырга вакыт житкән сыман булгач, Зөлмәткә карап.

—Миндә,—диде Зөлмәт. Мәмли беренче булып аягына басты, жиргә салып куелган коралларын алды. Башкалар да бер-бер артлы аякларына бастылар һәм атларына атланып, янадан кузгалып киттеләр.

Урман юлыннан алар шактый озак бардылар. Урман эчендә көн бераз гына карангырак иде, аннан соң һава да дымлырак, авыррак сыман иде. Баш өстен ике яктан килеп кушылган куе агач ботаклары каплап алганга, яшьләр баштарак күк йөзен бөтенләй диярлек күрмәделәр. Ләкин урман бетеп, юл ачык урынга килеп чыккан иде, һәркайсы Кодрәт баганын Бакыр калада әйткән сүзләрен исенә төшерде. Чыннан да көн бозылган, чалт аяз күк йөзендә кара кучкыл болытлар барлыкка килгән иде.

—Янгыр килә!

—Ашыгырга кирәк!—диештеләр кайберәүләр, күккә каранып.

Мәмли эндәшмәде дә, артына да борылып карамады. Хәзер ул ничек әйтсә, башкалар шуны эшләячәкләр иде—ул ашыгырга дисә, ашыгачаклар, ул әкрен барырга дисә, әкрен барачаклар иде. Алай башын икеләнү биләп алды. Янгыр ява башлаганчы тарлавыктан чыгып калганда яхшы булыр иде дә, ләкин башкаларның үзе турында «куркак» дип уйлауларыннан куркып ул бу хакта берни әйтә алмады. Аннан соң, алар булачак ирләр, сугышчылар

янгырдан йә булмаса шомлы тарлавыктан куркырга тиешләр микән? Юк, әлбәттә! Аларнын тиешле кораллары бар, алар теләсә нинди куркынычны чигенергә мәҗбүр итә торган серле догалар беләләр. Шулай булгач, коткыга бирелү килешмәс.

Юлдашлары тынычсызлана башлагач, шулай да ул туктарга кирәк тапты. Куркыныч килгәндә алай башы үзенен якыннары белән киңәшергә тиеш, ди әледән-әле пир ата. Койрыкта килсә дә, Мәмлинен ин якыны шулай да Зөлмәт иде.

—Син ни дисен?—диде ул Зөлмәткә эндәшеп. Зөлмәтнен күнелендә бу вакытта бөтенләй башка төрле уйлар иде. Бу вакытта аны пир ата сүзләре дә, янгыр яисә тарлавык куркынычы да борчымый иде. Анын ничек тә алтынчы бөтеннән берәр сынык сындырып аласы килә иде. Чишмә буенда ашаган чирек бөтен икмәктән ул әз генә дә туймады. Шундый унган, кетердәп пешкән өсле бодай икмәген ашагач анын тагын да ныграк ашыйсы гына килә башлады. Ук садагы сыман каеш бауга асылынган күн янчыктагы түгәрәк бөтен икмәкнен ул рәхәт авырлыгын тоеп, татлы исен иснәп килде. Ул инде берничә мәртәбә арткарак калып, сындырып алырга укталып та карады, ләкин үзеннән алда барган Үтинен әледән-әле артка борылып каравы гына аны тыелып калырга мәҗбүр итте.

—Тоз түгел—эремәбез,—диде Зөлмәт Мәмлинен соравына каршы.

Ул шулай дигәч, башкалар шундук шып булдылар. Чыннан да, лелек янгыр күрмәгәнме әллә? Зөлмәт исә үзенчә уйлады. Күлле табага житкәнче янгыр яуса, бигрәк тә шәп булачак—янгырда кыргыйлар өйләрендә качып ятырлар.

Күлле таба үзәненә якынлашканда чыннан да беренче тамчылар төшә башлады. Зөлмәт сөенеченнән нишләргә белмәде һәм тыела алмыйча күн янчыкка кулын тыгып, түгәрәк икмәктән зур гына кисәк сындырып алды да комсызланып кабып та жибәрде. Нәкъ шул чакта оятсызланып, әрсезләнеп Үти артына борылып карады, Зөлмәтнен авыз тутырып эпи ашавын күреп алды һәм шелтә дә, ялыну да, өмет тә белдергән бер тавыш белән мөнгерәп куйды. Ул хәтта атын тыя төшеп, Зөлмәтне көтеп алды. Зөлмәт тиз генә ана да бер-ике кабарлык эпи сындырып бирде.

—Башка сорама!—диде ул ана кисәтеп.

Озакламый янгыр шәбәя башлады. Бу инде чыннан да көн бозылды һәм янгыр явачак дигән сүз иде. Мондый чакта нишләп Марис коры, жылы куышыннан чыксын?! Зөлмәт бу юлы икмәкне шактый зур итеп сындырды һәм башкаларнын юеш аркаларын күздән ычкындырмыйча, рәхәтләнеп ашавында булды. Ләкин шул чакны Үтинен ялагай йөзе күренде. Ул кулы белән битен янгырдан каплаган булып ялт кына борылып карады да, Зөлмәтнен кулындагы икмәкне күреп алды, авызын ерып елмаеп жибәрде һәм, сынык өмет итеп тагын арткарак калды. Нишлисен, тагын өлеш чыгарырга туры килде.

Марислар үзәненә аяк басканда янгыр беравык туктап торды да, яналан сибәли башлады. Мәмли дә, башкалар да ин элек күл ягына, куышлар ягына борылып карадылар. Иртәнге кебек анда кешеләр дә, төтен дә күренми иде. Бары көтүләре генә бер тирәгәрәк тупланып, күл буенда һаман баягыча аптырап тынып торалар иде. Мәмлинен дә, башкаларнын да эченә жылы йөгерде. Беркемнен дә бу янгырда күсәк белән янаган кыргый таурлар белән очрашып торасы килмәде. Зөлмәт исә тәмам тынычлангандай булды. Ул Марислар әле аларнын кайчан кайтырын да белмиләр. Бәлки әле иртәгә кайтырлар дип көтәләрдер. Бәлки, эчеп куышларында яталардыр. Бүләккә билбау алды—аларга шул житкән. Зөлмәт шулайрак дип уйлады һәм янчыктан эпинен сонгы өлешен алды да, яртысын үзе янынннан теләнеп, өметләнеп

барган Үтигә сузды.

—Икебез ашадык—җавабын да икебез бирербез,—диде ул ана кисәтеп.

—Шуның өчен асып куймаслар әле,—диде Үти көлеп.—Корсак ачты да—ашадык, бетте-китте.

—Юк, алай түгел. Урманда юлбасарлар чыкты: аларга бирдек,—диде Мәмли.

Үти, канәгать булып, шаркылдап көләргә тотынды. Шаулап яуган яңгыр тавышында аларның үзара сөйләшкәннәрен дә, көлешкәннәрен дә беркем ишетмәде. Һәркем башын иебрәк, бөрешебрәк, бары бер-берсенең аркасына караган килеш үзән аша юрттыруын белде.

Чыннан да Марис алып камыш куышында йоклап калды ахрысы. Күл ягыннан күсәк күтәреп йөгереп килүчеләр күренмәде. Тарлавыкка җитәрәк Мәмли соңгы мәртәбә артына борылып карады да, җинел сулап, бик каты кычкырып, тарлавык иясенә:

—Селәүсен иясе! Без кайтып барабыз. Юлыбызга аркылы төшмә,—дип кычкырды.

Шулай кычкырып ул кыю рәвештә ташлы сукмакка керде. Ат аягы астыннан каршыга таба яңгыр суы агып ята. Бу бер дә күнелле нәрсә түгел. Алай-болай яңгыр көчәйсә, су да көчәячәк һәм сукмактан, кыялар арасыннан баруы кыенлашачак иде. Мәмли, үзе артыннан тезелеп килгән атлыларга борылып карап алды да, атын кызулап тар аралыкка кереп китте. Ул, гадәтенчә, як-ягына да каранырга онытмады, тик шулай да уңнан сибәләп яуган яңгыр чак-чак кына аның уяулыгын томалагандай итте. Әгәр яңгыр яумаса һәм ул уяурак булса, ихтимал, тарлавык читендә, таш артында качып торган таурларны күрми калмас иде.

Марис алып ирләре, егетләр уйлаганча, яңгырдан качып куышларында ятмадылар. Алар инде күптән атлыларны тарлавыкта көтеп торалар иде. Таурлар егетләрнең һәркайсын күреп, исемнәре белән беләләр. Аннан соң аларның лелекләргә әлләни ачулары да юк һәм лелекләр белән бозылышуның бик үк яхшы түгеллеген дә аңлыйлар иде алар. Аларның бары бигә үзләре турында искә төшерәселәре, үзләренең дә лелегләр җыеп алган ашлыкка өлешләре барлыгын белдерәселәре генә килә иде. Бит алар—лелекләр, Марислар жирен яулап алдылар, алар җирендә кала салып, иген игеп, мал асрап яталар! Аннан соң башка елларны би аларга калан итеп онын, ярмасын, сырасын җибәрә торган иде. Быел әле нишләптер ашыкмый. Иртән дә алар чынлыкта лелекләргә менә шул турыда исләренә төшермәкче генә булдылар. Хәзер дә чынында аларның күнелендә яшьләргә карата ул кадәр дошманлык хисе дә юк. Бит аларның яхшы коралланган булуын һәм яхшы сугышчылар булуын алар бик яхшы беләләр.

Марис алып егетләрне берәм-берәм күздән кичерә торды. Иң алдан барган Мәмлине күреп ул бераз гына гаҗәпләнгәндәй булды. Анынча, иң алдан иртәнгечә Зөлмәт барырга тиеш иде һәм ул—Марис, тарлавык авызына кергәндә, иң элек аны туктатып, аннан тагын вәгъдә ителгән икмәк, ашлык сорарга тиеш иде. Мәмлине ул бер сүзсез үткәреп җибәрде, Мәмлидән соңгы яшьләрне дә тоткарламаска булды.

Зөлмәт нишләптер иң артта калган булып чыкты. Җайдаклар бер-бер артлы үтә тордылар. Марис бары Зөлмәтне генә тоткарларга булды. Анынча, иң арттан барса да, төркем башы әле дә Зөлмәт булырга тиеш иде. Зөлмәт алдындагы Үти узып китү белән, таур алыбы, күсәген күтәреп аның алдына төшмәкче булды. Ләкин алдан никадәр барысын да уйлап-исәпләп куймасын, тарлавык авызындагы бу очрашу Марис теләгәнчә барып чыкмады. Зөлмәт таурларны коры куышта яңгырдан куркып яталардыр дип үз-үзен тынычландырырга тырышса да, ул барыбер үзен тулысынча тыныч сизә алмады. Таур алыбы алдында да, иптәшләре һәм Кодрәт бага алдында да ул үзен гаепле сизде. Шунлыктан ана туктаусыз әле кемдер арттан ияреп, сагалап

киле кебек, әле тарлавык авызында аны кемдер күтәреп тора кебек тоелды. Чыннан да, башкалардан беркем күрми үткән таурларны ул ерактан ук күреп алды. Алар сукмакка якын гына бик зур таш артына посканнар иде. Янгыр сибәләгән якка каршы торганга, аларны атлар да сизмәделәр, егетләр дә күрми үтеп киттеләр. Зөлмәт күрде һәм шундук кыска сөңгесен җайлап тотты. Таш артында качып торган таурлар аның алдан ук сугышка әзерләнүен, билгеле, күрми калдылар. Башкалар тыныч кына узып киткәч Зөлмәт тә, күрәсең, берни күрмәс дип уйладылар ахрысы алар. Зөлмәтнең кыядан аерылып торган зур таш белән тигезләшкәч, Марис алып чүгәләгән жиреннән кинәт калкып чыкты да, кусәген югары күтәреп, сукмакка, ат алдына сикереп чыкты. Башкалар да, бик каты кычкырып, аның артыннан ташландылар.

Ләкин шул чакны күз алдында булган хәлдән исләрен-акылларын җуеп, артка чигенергә мәжбүр булдылар. Зөлмәт жиз башаклы сөңгесен Марисның янгыр астында чыланып беткән, күп яуларда яраланып беткән кин, таза күкрәгенә тондырды. Сөңге аның уң як кулбашына якын жирдән, үпкәсе турысыннан үтә-сүтә тишеп чыкты. Марис, әйтәсе сүзен әйтә алмыйча, телсез калып, бер урында катып торды да, үз артыннан сөңгене иярттеп, ташлы сукмакка бөгелеп төште. Аның юлдашлары куркышып качыша башладылар.

Зөлмәт шундук атыннан сикереп төште, ике куллап, сабыннан тотып, сөңгесен тартып чыгарды. Ике-өч адым алданрак барган Үти, атыннан төшеп, Зөлмәт янына килде.

—Кусәге белән кизәнеп… юлга чыкты… ярый әле!—диде Зөлмәт, үз-үзен акларга теләгәндәй, аңлатып.

Монда инде аңлатып торуның кирәге юк иде. Монда барысы да үзеннән - үзе аңлашылып тора. Марис юлга аркылы төшкән, кулында—кусәге. Юлдашлары качып китте. Үти аларны үз күзләре белән күрде. Тик менә янгыр яуганда кан коелуы гына яхшы булмаган.

—Нишләтергә моны?—диде шулай да Зөлмәт аптырабрак.

—Әйдә, читкә чыгарып куйыйк,—диде Үти.

Алар таур алыбын икәүләшеп читкәрәк өстерәп чыгардылар да, атларына атланып яңадан кузгалып киттеләр. Марис юлбасарны үтереп, көтелмәгән батырлык, уяулык күрсәтсә дә, нишләптер Зөлмәт үзендә әлләни куаныч тойгысы сизмәде. Таур юлбасарының үзенә карата бернинди яманлык эшләргә теләмәгәнлеген ул яхшы аңлады. Бит Марис аннан үзенә тиешле бер бөтен икмәкне генә сорамакчы булган иде!

Янгыр туктаусыз койды да койды. Атларның аяк астыннан шаулап, ташларны кузгатып болганчык су ага башлады. Тирә-як карангыланып калды һәм алда да, уңда да, сулда да рәтләп берни күренмәде. Төркем башындагы Мәмли тарлавык уртасын узганда, янгыр әле ул кадәр шәп яумый иде кебек, шулай ук аяк астындагы су да алай ук күп түгел иде кебек. Ләкин ул түбән төшә башлаганда инде янгыр көчәйде. Бер-ике мәртәбә Мәмли, туктап, артына борылып, иптәшләренә кычкырып карады, ләкин арттан килүче бер өч-дүрт кешедән башка аны беркем ишетмәде. Арттагы өч-дүрт кеше туктаусыз киләләр иде. Алай башлыгы бүтәннәрне дә шулай туктаусыз киләләрдер дип уйлады һәм тарлавыкны чыкканчы башка артына әйләнеп карамады. Тарлавыкны чыккач исә аның күңелен бөтенләй башка кайгы биләп алды. Аларга бит әле Аксуны да кичәсе бар. Янгыр вакытында таулардан үзәнгә агып төшкән сулар туп-туры Аксуга ыргыла. Андый чакта Аксу танымаслык булып үзгәрә—ярлары тула һәм тыныч чакта агымлы төрелдәп агып яткан инеш көтмәгәндә аждаһага әверелә. Менә хәзер ничек тә Аксуны чыгып калырга кирәк… әгәр инде соң булмаса…

Мәмли, артына борылды һәм янгыр аша караеп күренгән карачкыларны ашыктырып:

—Тизрәк! Тизрәк!—дип кычкырды.

Алар аны ишеттеләрме-юкмы, ул моны белә алмады. Аның үзен исә кемдер эчтән ашыктыра, куалый башлады. Ул ачык җирдән атын бик каты куып, үзән уртасына чаптырды. Башкалар да, билгеле, аннан калышмаска тырыштылар. Ләкин Марисның үле гәүдәсе белән булашып вакыт уздырган Зөлмәт белән Үти ярыйсы ук артта калдылар. Тарлавыктан ачык җиргә килеп чыкканда үзләре алдында алар беркемне күрмәделәр. Туктаусыз яуган янгыр чаршавы аша шулай да алда, бик еракта ниндидер карачкыларны шәйләргә була иде. Зөлмәт тарлавыктан чыккач, юлда инде бүтән куркыныч юк диебрәк уйлады. Аннан соң әле булса аны үтерелгән Марис борчып торды. Аңа хәзер мәетне ул юл буена дөрес ташлап калдырмады сымак булып, янгыр вакытында аның өстенә нидер капларга кирәк иде сыман булып тоелды. Аннан соң аның җаны да чыгып бетмәгән сыман тоелды. Иртәгә барып карарга, торып китмәсә... яисә ырудашлары алып китмәсәләр, яндырырга кирәк дип уйлады ул, ниһаять, билгеле бер карарга килеп. Шуннан соң аның күңеле бер урынга утыргандай булды. Ул як-ягына күзен ачыбрак карады. Ләкин күзен ачып караганда инде соң иде.

—Кара!—диде шул чакны янәшәдән барган Үти, үзән уртасына күрсәтеп. Анда Аксу ярлары эченнән шаулап, күпереп-күбекләнеп, ниндидер әкәмәт зур җанлы нәрсә булып ур Су ургылып килә иде. Алдагы карачкылар инде елга аша чыгып өлгергәннәр бугай—аларның төрле якка сибелеп, калкулык өстенә менеп барулары күренде. Артта калган Зөлмәт белән Үти дә атларын бар көчләренә куып, үзән уртасына таба ыргылдылар.

Зөлмәт Үтидән чак-чак кына алданрак ташланды. Мондый көнне ташкын күрмәгән аты башын югары күтәреп, пошкырып, йөзәргә тырышып карады, ләкин су атны йомычка урынына эләктереп алды да, бөтерелдереп, түбән таба алып китте. Ат йөзә алмавын шәйләп, куркып, чинап-кычкырып җибәрде. Зөлмәт шундук мәтәлеп төште һәм инде су төбенә китәм дигәндә себеркесыман, чыбыксыман ниндидер нәрсәгә тотынып калды. «Тал бугай»дип уйлады ул соңгы мәртәбә. Шуннан соң ул берни уйлый алмады. Аның авыр киемнәре, кораллары аны каядыр аска тартты.

Шулай да күпмедер вакыттан соң ул исенә килде. Ул үзенең атының койрыгына тотынган булып чыкты. Котырынган елга аларны Аккала турысындагы болынга, төзелеп ята торган кәмә янына, күпер баганалары янына китереп чыгарган иде. Күпер баганаларына эләгеп алар шунда янгыр туктагалганчы, су басылганчы тордылар.

Бакыр тауга киткән яшьләрне Аккалада көне буе борчылып, дүрт күз белән көтеп тордылар. Бит алар беренче мәртәбә шундый ерак юлга, куркыныч юлга чыгып киттеләр. Өлкәннәрдән башка, үзләре генә. Исән-имин барып җитәрләрме, исән-имин әйләнеп кайта алырлармы? Юлда ул-бу булмасмы—үзара сугышып китмәсләрме яисә кыргый таурлар тозагына эләкмәсләрме? Ата-ана, туган-тумача шулайрак фикер йөртте. Ата-ана балам дип кайгырды, туган-тумача якыны булганы өчен кайгырды. Пир ата үзенең шәкертләре булган өчен кайгырды. Бинең кайгысы башкачарак—кинрәк, тирәнрәк иде.

Төштән соң, көн бозылгач, аеруча коеп янгыр ява башлагач борчылу чынлыкта ут йотуга әверелде. Янгыр коеп торганда Селәүсен тарлавыгы аша үтүе дә, Аксу аша кичүе дә уен эш түгел иде. Гомумән, Бакыр тау юлында әледән-әле хәвеф-хәтәр булып тора—тарлавыкта юлчыларга әле таурлар һөҗүм итә, әле качкын коллар һөҗүм итә. Шулай булса да, яшьләргә булышка кораллы алай җибәрү турында беркемнең күңеленә килеп карамады. Яшьләр сынау үтәләр иде һәм алар ул сынауда йә җиңәргә, йә җинелергә тиешләр иде.

Коеп янгыр яуганда манма су булып кайтып кергән яшьләрне калада,

билгеле, сөенеп, шау-шу килеп каршы алдылар. Шундук аларның атларын түбәнрәк төркем әндери малайлары тотып алдылар, түбә астына алып керделәр. Жайдакларның үзләрен исә коры һәм жылы өйдә кайнар аш көтеп тора иде. Капкадан кергәндә аларны санап керттеләр. Зөлмәт белән Үтинең юклыгы беленде. Ләкин аларны эзләргә кеше жибәрелмәде.

Янгыр тынып, су бераз кими төшкәч, Зөлмәт карангыда көч-хәл белән калкурак жиргә чыкты һәм бигәнгән атын житәкләп кала капкасына килде. Капка сакчылары аны берсүзсез калага керттеләр. Үти төнлә дә, таң аткач та кайтмады. Аны өч көнгә кадәр көттеләр. Үти күренмәде. Шуннан соң аны үлгәнгә исәпләделәр. «Күрәсең, су иясе алгандыр» диделәр калада, пошынып.

Бу, билгеле, күнелле хәбәр түгел иде. Ләкин шул ук вакытта монда инде берни эшләп булмый. Су иясе дә, су бабасы да һәр елны үзенә кирәген алмый калмый. Тиешенчә корбан бирелмәгәндер яисә берәр жирдә кирәкмәгәнгә кан коелгандыр. Шуның белән күнеле булса ярый да бит... Аты-ние белән юкка чыккан Үти турында һәркем шулайрак дип уйлады. Үтинең югалуына бары Зөлмәт кенә сөенгәндәй булды. Алай-болай бер бөтен эпи турында йә булмаса үтерелгән Марис турында сүз чыгып төпченә башласалар, кем хәзер Зөлмәткә төртеп күрсәтә алыр икән? Андый кеше бер генә иде. Ул әнә юкка чыкты. Шул кирәк андый ялагайга, куркакка!

Марисның ничек үтерелүен, билгеле, Үтидән башка беркем күрмәде. Кодрәт бага биргән алтынчы бөтен икмәк турында Мәмли дә, башкалар да нишләптер онытып жибәрделәр—янгыр вакытында һәркемнең үз кайгысы булды. Янгырдан соң исә башка зуррак борчулар калкып чыкты.

Иң нык кайгыручылар пир ата белән би булды ахрысы. Яшьләр янгырга эләккән төнне алар озак кына кинәшеп, борчылып утырдылар.

Башка елларны бу вакытта әле көннәр аяз була торган иде. Бу вакытта әле шулай коеп янгыр да яумый, Аксу да шул дәрәжәдә кабарып чыкмый иде. Мондый хәл гомумән сирәк була. Бу юлы көн бөтенләй көтмәгәндә бозылып китте. Төньяктан кинәт кара болып болыт калкып чыкты. Чалт аяз күктә шомлы болыт барлыкка килүен һәм аның тиз арада көнбатыш ягындагы таулар өстеннән шуышып үтүен, бөтен түбә өстен каплап алуын каладагы һәркем күреп-күзәтеп торды. Янгыр явар алдыннан кинәт кара болытны урталай ярып, бик озын нечкә тамырсыман булып, көпә-көндез нажагай ялтырап алды. Нажагай яктысында якында тау битләре, үзәннәр, каладагы манаралар яктырып китте. Күк күкрәгән-ниткән тавыш ишетелмәде. Ничектер тавыш-тынсыз һәм бик шомлы булып килде бу янгыр. Юк, бу гади янгыр гына булмады. Бу ниндидер куркыныч, хәвефле жил һәм янгыр булды.

Нәрсәгә ишарә булды икән бу көтелмәгән жил-янгыр һәм кара болыт? Жирдә, Аккалада шулкадәр күп языклы эшләр бармы, әллә киләчәктә моннан да яманрак нәрсәләр булуын белдерүче бер-бер зилзиләме бу? Ярый ла бер кеше белән бер атны алып, шуның белән генә тынычланса. Бит диңгездә бу вакытта кемнәрдер дулкыннар белән, жил белән көрәшеп Акланга таба юл ярадыр.

Би өчен дә, пир ата өчен дә иң әһәмиятлесе хәзер менә шул иде. Югалган бер кеше һәм бер аттан бигрәк алар кайдадыр диңгездә булырга һәм төньяк ярларга йөзәргә тиешле кәмәдәге кешеләр турында кайгырдылар. Анда, ул кәмәдә танышлар да, таныш түгелләр дә булырга мөмкин иде. Ләкин кем генә булмасыннар, алар бигә дә, пир атага да, каладагы башкаларга да бик кирәкле кешеләр иде. Мондагы бик күпләрнең киләчәк язмышы күзгә күренмәгән менә шул кәмәдәге кешеләргә бәйле иде.

Ул төнне калада бик аз кеше тынычлап йоклады. Һәркем йокы аралаш, тышка колак салды. Тышта инде жил тынган иде бугай. Тынып ук житмәсә

дә, көндезге сыман ук тоелмады. Әллә соң йокы аралаш кына шулай тоелды микән?

Типкә би дә әледән-әле тышка колак салды. Тышта әле шыбырдап, бәргәләп яңгыр яуды, яңгыр тынган арада, агач ботакларын бөгеп һәм өй ташына ышкып, җил исте. Җил шулай ук моржа башында ниндидер ачык калган тәрәзә уемнарында улады. Җил-яңгыр тынган араларда аста, яр буенда, тирә-якны дер селкетеп, кыя ташларына дулкыннар бәрелгәне ишетелде. Бу көннәрдә Типкә бинен йокысы качты. Әледән-әле торып ул караңгы өй буенча йөрде, диңгез ягындагы тар тәрәзә каршысына килеп, яр буен күзәтте. Ләкин анда, ара-тирә елкылдап киткән дулкын сыртларыннан башка, таныш яр шәүләләреннән башка берни күренмәде.

«Унике ел! Унике ел!« диде ул үзалдына, күптән инде тынгы бирми торган уйларын дәвам итеп. Бер атна-ун көннән аның монда килеп аяк басуына унике ел булачак. Унике ел. Кайберәүләр өчен бу ярты гомер. Искән җилдәй үтте дә китте бу унике ел гомер. Искән җилдәй микән? Юк, алай ук түгелдер. Искән җилнең дә төрлесе була. Бер төрлесе аның җинел генә, шома гына үтеп китә—биттән, агач яфракларыннан, чәчәкләрдән сыйпап үтә дә китә. Бер төрлесе бөтен нәрсәнең астын өскә әйләндереп, кырып, җимереп китә. Синең гомер җилең ничек үтте соң, Типкә би? Кырып-җимерепме, әллә сылап-сыйпапмы? Юк, алай да түгел, болай да түгел ахрысы. Көн-төн эш белән, тырышлык һәм йокысыз төннәр белән үтте синең унике ел гомерең, Типкә би. Яртысы аның сагыш белән, әрнү һәм газап белән, яртысы... өмет һәм ышыныч белән үтте. Өмет һәм ышыныч, чиксез ярату һәм омтылыш яшәтте сине монда... кыргый яр буенда, кыргый таулар, урманнар, кыргый кабиләләр арасында. Бары диңгез генә, бары кыялар һәм яр буендагы шома ташлар гына таныш һәм якын иде сиңа монда. Аннары—күк йөзе, кояш... мәңге яктылык, тереклек чыганагы—изге атабыз бөек Кояш кына якын һәм ягымлы иде сиңа монда. Бу ташлар, таулар һәм кыргыйлар арасында.

Баштарак ул монда ничек яшәрен, ничек итеп исән калырын күз алдына да китермәгән иде. Кайчакларда аның суга ташланасы, дулкыннар кочагына кереп юкка чыгасы килгән чаклары да булды. Кайчагында исә элеккеләрне беркайчан да искә төшермәслек, күз алдына китермәслек ят һәм кыргый җиргә, моннан да ераграк җир читенә, Акуан буйларына китеп юкка чыгасы килгән чаклары да булды. Ләкин хәтер булмаган җирнең, төбәкнең беркайда да юклыгын ул бик яхшы аңлады. Пир ата да шулай диде. Кеше булып тугансың икән, теләсә кайда, теләсә нинди шартларда яшәргә кирәк, исән калырга кирәк диде. Диңгез дулкынына ташлану, Акуан ярларына, Ахирәт якларына бару беркайчан да соң түгел, анда һәркем бара, ләкин аннан кире кайтып булмый диде.

Язмыш аны менә монда китереп ташлады. Моннан ул кире кайтырга тиеш. Моннан унике ел элек аңа шулай диелде. Күктә—Кояш, җирдә—Мака сар. Аклантита сары изге, аның юсыгы изге һәм гадел. Бу хакта Алтын уртада Изге ташка уеп язылган. Ташка уеп язылган Изге Атам сүзен беркем боза алмый. Бозса... Юк, беркем боза алмый! Бозсалар, Туфан калкачак, Дөнья бетәчәк. Тәңренең теләгенә, Тәңре юсыгына беркем каршы килә алмый. Хәтта мака сар да. Хәтта... Фалия дә.

Унике ел. Газап һәм сагыш, өмет һәм ышаныч. Мака сарлар нәселеннән булган кеше сөргенгә унике елдан да артыкка җибәрелми. Изге Буга канын эчеп алар шулай юрадылар. Берничә көннән башкаладан, Алтын уртадан алтын кәмә киләчәк. Алтын кәмә белән бергә Мака сарның боерыгы киләчәк.

Тик менә көннең кисәк бозылып китүе генә яхшы түгел бит әле. Юк, яхшы түгел. Дөнья булгач, җил дә исә, яңгыр да ява, диңгез дә, дулкыннар да котырына. Ләкин хәзер түгел, бу көннәрдә түгел. Бит әле чын-чынлап

көннәр бозылырга, дулкыннар кузгалырга ин күбе—бер ай, ин азы—ярты ай вакыт бар. Башка елларда шулай булды. Ник быел гына кирәгеннән алда уянды соң әле бу төн жилләре?

Типкә бинең күнеленә шундыйрак уйлар килде. Бер урыныннан торып, аягына баскач инде ул тиз генә йоклап китә алмаячагын анлады. Анын кире урынына барып ятасы килмәде. Аннан сон ана өйнен жылысын жил алып бетергән сыман тоелды. Ул, өйдәгеләрне уятмас өчен, таш баскычтан сакланып кына атлап, аска, түбәндәге катка төште һәм идән уртасындагы учак янына килде, учакка утын өстәмәкче булды. Ләкин ул учакка якынаю белән, карангыда шәүлә сыман булып, озын күлмәк итәкләрен өстерәп Бәчкә карчык килеп житте. Өйне жылы тоту, учакка ягу анын эше иде. Ул үзен бу эшнен остасы дип, ир кеше учакка утын якса, ут анасы Әбетинен хәтере кала дип исәпли иде. Анын ятагы да шушында гына, учак янында гына иде.

—Үзем, би!—диде ул йокылы тавыш белән, би кулындагы утын агачларына үрелеп.

Типкә би каршы килмәде, сүзсез генә утын агачын кулыннан ычкындырды да, учак янындагы йомшак утыргычка утырды.

Бәчкә карчык тиз-тиз кыланып түгәрәк учакка утын өйде һәм мыштым гына килгән кебек, шәүлә сыман китеп тә барды һәм икенче бүлмәдәге урынына барып ятты.

—Танга кадәр житәр, керткән коры утын юк,—дип сөйләнде ул китәр алдыннан. Типкә би ничек утырган булса, шул көе кымшанмыйча урынында утырып калды.

***

Фалиягә өйләнеп бергә тора башлавына ике-өч ай чамасы булганда, көзге матур көннәрнең берсендә, иртәнге якта ашап утырганда кемдер капка шакыды. Капка янында кеше-кара юк иде ахрысы—шакучыга тиз генә ачмадылар. Бераз тынып торгач, шаку тавышы тагын кабатланды. Бинен күнеле, нидер сизенеп, тынычсызланып алды. Аягөсте басып ул тәрәзәдән капка ягына карап алды. Күп тә үтмәде, каралардан берсе мака сардан кеше килүен кереп әйтте. Бераздан ике кораллы ирен ияртеп, мака сар йомышчысы Йули килеп керде һәм тартынып, кыюсызланып тормастан, туп-туры бусага аша үтте дә, ашаучылар ягына якынлашты.

—Сине мака сар чакыра,—диде ул сораулы караш белән үзенә текәлгән Типкә бигә.

Мака сар аны бик сирәк чакыра иде. Телсез кеше кебек ул аптырап Йулигә карап тик торды.

—Ишеттенме, Типкә би?—диде тәкәббер Йули, бала-чага белән сөйләшкән сыман.

—Ишеттем. Барырмын,—диде ниһаять Типкә би исен жыеп.

—Барырмын түгел—барабыз,—диде Йули.—Минем белән барасын.

—Ярар алайса,—диде Типкә би бик авырлык белән генә.

Ашавыннан туктап калган Фалия барысын да күреп-ишетеп торды. Ул әле бу сөйләшүнен эчтәлеген тиешенчә анлап-төшенеп тә житмәде бугай, шулай да иренең үзгәргән тавышы, бозылган йөзе аны шундук куркуга салды. Урыныннан сикереп торып ул аны чытырдатып кочып, кочаклап алды.

—Жибәрмим! Беркая да бармыйсын!—диде ул кинәт күз яше сизелеп торган бер ныклык белән, кабаланып.

Типкә би үз-үзен мәжбүр итеп елмайды.

—Ник? Нәрсә булды?—диде ул гажәпләнгән булып.

—Жибәрмим!—диде Фалия кайнарланып.—Мин күрдем... нидер булган...

—Мака сар боерыгы үтәлергә тиеш, бикә,—диде би йомшаграк итеп.

—Беләм!—диде Фалия. Алайса ник курыктың?

Бу сүзләрен ул иренә карап әйтте, ләкин би җавап биреп тормады, ул инде тынычланган иде.

—Би кешегә курку килешми. Синең яннан китәсем килми—шуңадыр,—диде ул.

Фалия, ышанып җитмәсә дә, беркадәр тынычланды бугай. Шулай да ишектән чыкканда ул аның муенына сарылды.

—Тиз кайт!—диде ул, үпкәләгән бала сыман еламсырап.

—Кайтырмын,—диде Типкә би һәм иплəп кенә яшь хатынның кайнар беләкләреннән арынды да, нык-нык басып, капкага юнәлде.

Шул китүдән ул бүтән әйләнеп кайта алмады. «Кайтырмын» дигән сүзен үти алмады би. Дөрес, кайтудан өметен дә өзмәде, шулай да менә инде унөченче ел сөекле ише Фалияне күрә алганы юк.

Ак сарайда аны бернинди тоткарлыксыз мака сар янына алып бардылар. Ул бизәкле зур капкалар аша, тезелеп киткән алтын сыннар яныннан тигез таш җәелгән матур сукмаклардан туп-туры Ак сарайга юнәлде. Ин алдан, юл күрсәткән сыман, Йули барды, җинаятьче сыман аның артыннан Типкә би, аның артыннан кораллы ирләр барды.

Ак сарайга кергәч, матур итеп бизәлгән, ташларына канатлы балыклар, су үсемнәре, икенче ягында алтын балыклар йөзеп йөргән зәңгәр дингезсыман итеп ясалган, бизәлгән, идәнгә йомшак палас җәелгән бүлмәдә көтеп торырга куштылар. Бу вакытта мака сар кайнар су белән коенырга ярата иде. Ул аны белде һәм тыныч кына көтеп утыруында булды. Күңеленнән фараз кылды: тагын акайларга каршы яуга җибәрергә уйлый микән, әллә соң ерак илләргә барасы сәүдәгәрләрне озатып куярга кушар микән диде.

Бер ярты сәгатьтән аны агасы янына чакырдылар. Гадәтенчә Карунның йөзе тыныч, ягымлы һәм ялтыравык иде. Гадәтенчә аннан хуш исләр килеп тора иде. Аның катына килеп керү белән би шанлы тәңрегә котлау сүзләре әйтте һәм үзенең буйсынуын белдереп идәнгә егылды.

—Сиңа йомышым төште, энем,—дип сүз башлады мака сар, тыныч кына ягымлы тавыш белән.

—Тынлыйм, агам,—диде би.

Ләкин мака сар йомышын әйтеп өлгермәде, сул якка борылып, ачык ишек аша кемгәдер баш какты. Ул яктан чандыр гәүдәле корышып беткән бер карт килеп керде. Өстенә ул ап-ак киндер күлмәк кигән, кулына нииндидер юан, сырлы таяк тоткан, башы тап-такыр, аягында исә камыш чабата иде. Би шундук танып алды—бу Кәми келәүчесе булырга тиеш иде. Бөтен гомерләре буена келәүлектә яшәүче изге кәми келәүчеләре—галимнәр менә шундый була иде.

Таяклы кәмит, гәүдәсен төз тотып бүлмәгә керде, мака сарга җиңелчә баш какты, аннан соң каш астыннан гына бигә карап алды да, аякларын бөкләп туп-туры идәнгә, каты җиргә утырды.

—Таныш бул: келәүче баба Мати,—диде мака сар энесе бигә карап. Кырык ел буена кәмитләрнең келәүлегендә яшәгән. Лелег дип белмәгәннәр. Ул аларның серләрен алган. Аңлыйсыңмы, төрбәнең серен алган!

Соңгы сүзләрен ул куаныч һәм тантана белән әйтте. Гадәттә салынып торган калын кашлары астыннан күренми торган кысылып беткән комсыз күзләре аның зур булып ачылды. Анда куаныч һәм шашкын бер комсызлык иде.

—Аңлыйм,—диде Типкә би, берни аңламаса да.

—Аңласаң менә шул: җил уңай, бүген җыенасың, иртәгә кузгаласың. Кәмигә!—диде мака сар.—Җиңеп, төрбәләрен... барлык байлыкларын төяп

кайтасын. Жинә алмасан…

—Анладым, агам,—диде Типкә би, карангы чырай белән.—Жинә алмасам нәрсә булыры болай да билгеле.

—Билгеле микән?—диде мака сар энесенә сынаулы күз карашы ташлап усал гына.—Мин ышанам—син жинәрсен, диде ул, аннары шактый нык итеп, боерып.—Киләүче баба синен юл күрсәтүчен булыр. Аннан сон, син бит яшь бичәнне яратасын… Фалияне!

—Яратам, агам,—диде би, сөенеч тойгысы белән һәм, үзе дә сизмәстән, елмаеп жибәрде.

Мака сар Карун күптән инде Кәмигә каршы олы яуга әзерләнә иде. Тугыз биләмәдән һәм Аклантитa утравынын урман-таулары арасына таралып утырган авыллардан, калалардан көн саен башкалага кызылга, карага буялган сугыш кәмәләре, кораллы сугышчылар, корал, азык-төлек килә тора иде. Алар су божраларга кереп тулганнар, яр буйларында туктап калганнар һәм кузгалырга боерык булганны гына көтеп торалар иде. Бу турыда бөтен башкала халкы белде. Кәмиләргә каршы яу чыгу-чыкмау хакында төрле сүзләр йөрде. Күпчелек мака сарнын ниятен хупламады. Ни өчен дигәндә, Кәми белән Атлантита күптән инде дуслашып-туганлашып беткән иде. Ике арада туктаусыз алыш-биреш бара, туктаусыз сәүдә кәмәләре йөреп тора иде. Арада, билгеле, теләсә нинди яуга атлыгып торучылар да күп булды.

Типкә би дә мака сарнын яуга әзерләнүен белмәде түгел, белде. Тик шулай да ул, сугышчы һәм сугыш остасы булса да, бу арада яулар-сугышлар турында исеннән чыгарып тора иде. Ни генә булмасын, әле яна гына өйләнгән кеше буларак ул үзенен Фалиясе янында, үз өендә, тынычта яшәргә тиеш иде кебек. Ул сугышка бармаска тиеш иде сыман. Мондый зур яуларга элек мака сарлар үзләре йөргәннәр. Мака сар Карун барлык борынгы йолаларны, барлык изге юсык-юрыкны аяк астына салып таптады. Ул инде күптән, моннан дүрт-биш ел элек, тәхетен үзеннән кечерәк энесенә тапшырырга тиеш иде. Төрлечә хәйлә табып, ялган белән ул яналан биш елга мака сар булып кала алды. Үзе югында алай-болай баш күтәрүләреннән куркып, ул хәзер менә урынына береккәндәй, башкаладан, хәтта Алтын уртадан беркая чыкмыйча яшәп ята.

Әйе, барысы да анлашыла. Кәмигә каршы яуны ул инде күптән юри уйлап тапкан. Аны башкаладан читкә жибәрү өчен ул моны юри уйлап тапкан. Бернинди байлык та, яшерен сарайлар да юк ул төрбә астында. Аннан сон нишләп кәмиләр тора салып, жинел генә шундый атаклы төрбәләрен мака сардан талатырлар икән? Кәмиләр көчле, аларнын жирләре, байлыклары күп. Димәк, мака сар Карун аны ун менләгән кеше белән күрәләтә үлемгә озата!

Мака сар белән булган сөйләшүдән сон Типкә бинен күнеленә шундыйрак уйлар килде. Ул, әйтерсен, ике ут арасында калды. Мака сарнын кансызлыгын, ялганын белеп торса да, ул анын боерыгына каршы килә алмады. Каршылык белдерсә, анын шундук башын чабачаклар, йә булмаса, ин яхшысы, тирән базга ябачаклар иде. Берсүзсез боерыкка буйсынып, Кәмигә каршы яуга барганда да аны ни көтә икән сон киләчәктә? Ул моны белмәде. Моны беркем белмәде. Билгеле, һәркемнен жинеп, кәмәләргә бик күп байлык, коллар төяп кайтасы килде.

Алар тан алдыннан кузгалып киттеләр. Алтын уртадан туп-туры ачык дингезгә чыга торган кин арык тамагындагы сакчы кәмәләр аларга юл биреп як-якка киттеләр. Тышкы койманын су аша бер ягыннан икенче ягына тарттырып, ташка беркетелгән ыргакларга каптырып куелган авыр жиз чылбырлар чынлап су астына төште. Яр буена, койма, күпер өсләренә жыйналган менләгән халык, кул болгап, елашып һәм сонгы сәлам сүзләрен

кычкырып, аларны ерак юлга озатып калды.

Биек койма өстеннән сузылган күперне чыккач та, би әледән-әле халык ягына борылып карады. Аның ничек тә Фалияне күрәсе килде. Ләкин анда кемне дә булса тану-аеру мөмкин түгел иде. Кул болгаган, кычкырган йә булмаса елаган һәрбер яшь хатын аңа Фалия булып тоелды. Бер-ике мәртәбә ул, Фалия дип алданып, хәтта борылып кемнәргәдер кул да болгады.

Ләкин ишкәкчеләр бик тырышып иштеләр, авыр ишкәкләр шап та шоп су өстенә төшкәне генә ишетелеп торды. Кәмә җиңелчә генә дулкыннар өстеннән тирбәнеп алга, билгесезлеккә таба ыргылуында булды. Бик озак, төшкә, хәтта кичкә кадәр арттан ялт-йолт килеп аларны башкаланың алтын манаралары, җиз, көмеш коймалары, биек йортлары озатып калды. Караңгы төшкәндә исә, еракта, төньякта шәүлә генә булып, караеп таныш таулар карап тордылар.

Бардылар алар Кәмигә. Басып керделәр кәмиләрнең комлы-тузанлы җиренә. Сугыштылар, Куфу төрбәсенә дә барып җиттеләр, ләкин ул вакытта инде келәүче баба Мати диңгездә давыл вакытында аяк сузган иде. Үзенең серен ул беркемгә, хәтта бигә дә әйтергә теләмәде. Шулай итеп, бу юлы да лелегләрнең төрбә астындагы сарайларның ишеген ачарга, байлык таларга дигән теләкләре тормышка ашмады.

Коры кул белән мака сар катына кайтып күренү хәтәр нәрсә иде. Сугыш осталары, алып су башлары белән киңәшкәч, Типкә би Хана буйлап көньякка, Нубия кыргыйларына каршы яу чабарга булды. Анда алтын күп диләр. Колларны богаулаган чылбырлар да, балта-пычак ише кораллар да анда, имеш, алтыннан икән дигән сүзләр йөри иде. Чыннан да ике ай дигәндә алар Нубия тауларына да барып җиттеләр, андагы кабиләләрне җиңеп, пыр туздырып, алтыннарын ишәкләргә, елга кәмәләренә төяделәр дә, үзләре диңгез буенда көтеп торган чирү янына юнәлделәр.

Башкаладан алып чыккан кешеләрнең, кәмәләрнең яртысы чамасын югалтып, шулай да бик күп алтын һәм җәүһәр-мәрҗән ташлар алып бер елдан соң ул башкаланың диңгез ягындагы капкасына кайтып төште.

Мака сар боерыгын җиренә житкереп үти алмаса да, ул аңа ике батман чамасы саф алтын бәлешләре алып кайтты. Мондый байлык белән мака сар йөзенә күренү ул кадәр оят булмаска тиеш сыман иде.

Алтын, таш, байлык төялгән кәмәләрне капкадан үткәреп җибәрделәр, ләкин аның үзенә һәм аның юлдашларына башкалага аяк басмаска, мака сардан яңа боерык килгәнче көтеп торырга куштылар. Мака сар боерыгы озак көттермәде. Төрбәнең серенә төшенә алмаган өчен аңа юлдашлары белән бергәләп, төньяк диңгезгә таба юл тотарга һәм анда таурлар илен яулап алып, яр буенда яңа кала корырга боерылган иде. Анда, имеш, таурларда алтын тапканнар.

Менә шулай булды ул. Аларны монда сөргенгә озаттылар. Уникe елга. Икенче елны артыгыздан хатыннарыгызны, балаларыгызны җибәрерләр диелгән иде мака сар боерыгында. Бер елдан соң чыннан да сөрелгән кешеләрнең хатыннары, балалары, карт ата-аналары килде. Фалиянең этисе-әнисе дә, им өеннән алып кайткан улы Мәмли дә килде. Тик... алар арасында Фалия генә юк иде. Мака сар Карун Фалияне генә җибәрмәгән иде.

***

Алар төштән соң килеп чыктылар. Төньяк капка бикле түгел иде, капка сакчылары, дөньяларын онытып түбәндә, капка тышындагы күләгәдә ашык уйнап утыралар иде. Бакыр—тау калага бара торган юл буендагы гөлҗимеш, кыргый алмагач һәм груша куаклары арасыннан көтмәгәндә ниндидер ярым шәрә ят ирләр килеп чыкты. Алар туп-туры капкага таба килә башладылар.

Алар кулларына шома саплы күсәкләр тотканнар, ин алдан килгән тазарак, калкурак буйлы берсенен биленә каеш буылган, каешка кынылы хәнҗәр тагылган иде

Ашык уйнаучыларның берсе көтмәгәндә аларны күреп алды һәм сагасын кул очында тоткан килеш, тынып калды. Анын кыяфәтен күреп, башкалар да ул караган якка борылып карадылар һәм үзләренә якынлашып килүче таурлар төркемен күреп тиз генә аякларына бастылар, капка эченә керделәр дә, кайсы кая ташландылар, йә булмаса капка баганасына сөяп куелган коралларына тотындылар. Берсе шунда тиз арада капканы япты, шапылдатып аркылы бикне таш баганадагы ояларына кертеп куйды.

Капка сакчыларынын кереп китүләрен күреп, таурлар төркеме кызулый төште. Алар йөгерә үк башладылар һәм капка биге үз урынына урнашып та өлгермәде, тышкы яктан капканын җизле тактасына күсәк белән китереп тә тондырдылар. Капка артында ыгы-зыгы килгән, ярсып кычкырган тавышлар ишетелде.

—Ач капка! Ач, би!

—Ачмасан яндырабыз!—диделәр ярсулы таурлар авыр күсәкләре белән капка калаен дөпелдәтеп.

Каушап, аптырап калган сакчылар агач баскычтан йөгерешеп югары менделәр, чыгып торган таш, бүрәнә кырыйларына ышыкланып, ярыклардан түбән карадылар. Болар чыннан да таурлар иде. Арада таныш йөзләр дә күренде. Танышларның берсе, башкалардан калкурагы, тазарагы Марисның бертуган энесе Нарис булырга тиеш иде.

—Кем кирәк? Нәрсә кирәк?—дип кычкырдылар капка түбәсендәге сакчылар.

Сакчыларнын югарыдан килгән тавышларын ишетеп, ярсыган таурлар капка башына күтәрелеп карадылар. Кемдер таш бәрде. Таш күзәтү ярыгына килеп тиде дә, ике агач арасында кысылып калды. Капка сакчысы коты алынып, шундук читкә тайпылды—чак-чак кына артына барып төшмәде, ярый әле басма өстендәге аратагa тотынып калды.

—Би кирәк! Типкә би!—дип кычкырдылар таурлар, капка сакчыларына җавап итеп.

Ул арада юл буендагы куаклар арасыннан бер-бер артлы ярым шәрә ирләр чыга тордылар, кача-поса ялт-йолт каранып, капкага таба якынлаша тордылар. Тышкы якта капка алдында шаулашкан, баш өстендә күсәкләрен болгаган ярсулы кыргыйлар төркеме арткannan арта барды. Ни булды боларга? Нәрсә кирәк боларга? Моны капка каравылчысы гына хәл итәрлек түгел иде. Сакчыларнын берсе, яшьрәге тиз генә би сараена йөгерде, икенчесе яу килгәнен белдереп, чаң сугарга тотынды.

Тиз арада чаң тавышын ишетеп һәм шулай ук таурлар килүен күреп, капка янына кала кешеләре җыела башлады. Койма өстеннән башка капкалардагы, күзәтү манараларындагы коралды сакчылар килә башлады. Әле аннан, әле моннан таурлар ягына берән-сәрән уклар очты. Кыргыйлар ягында бер-ике кеше, шәрә тәненә килеп кадалган угын тотып, җиргә егылды. Ямьсез итеп кычкырып, чинаган тавышлар ишетелеп китте.

Шул ук вакытта сарай ягыннан капкага таба ашыгып килүче би, Тархан һәм пир ата күренде. Җыелган төркемне икегә аерып, алар туп-туры капкага якынайдылар. Типкә би өстенә алтын калайлар тезеп тегелгән кебәсен, башына җинел мамыктай җинел кош каурыйлары кадалган алтын алпагын кигән иде. Анын йөзе кырыс, тыныч һәм куркусыз иде. Ул баскычтан ашыкмыйча өскә менде, бөтен гәүдәсен күрсәтеп, койма читендәге калку урынга чыгып басты. Астан, ерактан очып килгән теләсә нинди ташны, күсәкне кире кагарга әзер булып, кулларына түгәрәк җиз калкан тотып, анын ике ягында ике

таза, яшь ир тынып калды. Алтынлы киемнәрен кояшта балкытып, күктән төшкән сихри зат кебек, бура читенә чыгып баскан бине күргәч, таурлар төркеме дә тынып калды.

Типкә би, шәрә беләкләрен күкрәк турысында кушырган килеш, башын югары тотып, каш астыннан гына түбәнгә карады, буйсынырга теләмәгән таур ирен күздән кичерде. Ул ана таныш иде. Бу теге кабилә башлыгы Марисның бертуган энесе Нарис иде. Ул әле яшь, анын ачулы йөзендә, беләкләрендә төрле җәрәхәтләр, күгәргән урыннар белән тапланып беткән күкрәгендә көч-куәт һәм яшьлек ярсуы ташып тора иде.

—Улым, тезлән,—диде Типкә би боерып, тыныч кына.

—Тезләнмим,—диде Нарис, үч һәм нәфрәт белән үзсүзләнеп. Кулына агасы Марисның җиз белән калайланган чукмар башлы, шома саплы күсәген тоткан, муенына нечкә чылбырга тагып кеше баш сөяге асып куйган иде. Бу исә анын варис урынына кабилә башы булуы турында әйтеп тора иде. Ул шулай «тезләнмим» сүзен әйтеп бетерүгә булды, таяк сыман җинелчә генә күсәген җирдән күтәрүгә булды, шундук өстән җиз башаклы, каурый койрыклы кызыл ук килеп төште. Көч белән атылып җибәрелгән ук чынлап үҗәт таурнын каршысына, каты җиргә бәреп керде, каурыйлы койрыгы калтырап, селкенеп торды да, тынып калды. Кыю, ярсу таурнын йөзендә шундук курку чагылып китте, ирексездән ул чак-чак кына артына чигенде, борылып карады, каядыр качып китмәкче булды, ләкин үзе янындагы барлык ирләрнен башларын җиргә сузып, йөзтүбән тезләнеп торуларын күреп, ынгырашуга охшаш бер өн чыгарды да, шулай ук җиргә егылды.

Типкә би сүзсез генә барысын да югарыдан күзәтеп торды. Тирә-як тып-тын булып калды.

—Тор, сөйлә, улым—ни булды, ни кирәк?—диде ул, ниһаять, илаһи бер мәрхәмәтлек белән.

Нарис тузанлы җирдән аягына басты, янадан күсәгенә тотынды, бер-ике адым алгарак атлады. Башкалар да аякларына бастылар.

—Зөлмәт кирәк!—дип кычкырды Нарис, янадан баягыча ярсып һәм оятсызланып.

—Арпа, сыра кирәкме әллә дип уйлаган идем мин,—диде Типкә би Зөлмәт сүзен ишетүгә әз генә дә гаҗәпләнмичә.

—Арпа да, сыра да кирәк,—диделәр Нарис артындагылар шаулашып.

—Минем кешеләр сезгә арпа да, сыра да алып бардылар. Баргач сезне тапмый кайттылар. Кая киттегез?—диде Типкә би шелтә белән.

Таурлар, гаепле сыман күзләрен читкә бордылар.

—Зөлмәт минем агам Марисны үтерде. Син безгә башта Зөлмәтне бир!—диде Нарис, янадан ярсый башлап.

—Кем күрде Зөлмәтнен Марисны үтергәнен?—диде би бик нык гаҗәпләнгән сыман.

—Мин күрдем!—диде беренче булып Нарис.

—Мин дә күрдем!

—Мин дә!—диделәр тагын бер-ике таур ире.

—Алайса минем улым Үтине сез ашадыгызмыни?!—диде Типкә би, әкрен генә дәһшәтле итеп.

Янадан кыза, ярсый башлаган таурлар кинәт шып булдылар. Әле генә кукраеп, күкрәк киереп, мин дип торган яшь ирләр, куркышып бер-берсенә карашып алдылар. Таурлар арасында ыгы-зыгы башланды. Читтәрәк, кырыйдарак торганнар тизрәк табан ялтырату ягын карадылар. Капка сакчылары качучыларны мыскыллап көләргә, кычкырырга, сызгырырга тотындылар. Арада хәтта таурлар артыннан уклар очты. Элек тә мондый гына бәрелешләр булганы бар иде. Типкә би качучыларга ук-сөңге атмаска

боерган иде. Берни белән сакланмаган шәрә аркага арттан ук атып калуда әлләни батырлык юк дип уйлый иде ул. Аннан соң Күлле таба Марис-Нарис таурларын кырып бетерүдән ана бернинди файда юк иде. Элек тә шулай өркетеп җибәргәч, алар икенче көнне үк калага бөтенләй юашланып, буйсыну белдереп киләләр иде. Типкә би шундук ук атучылар ягына борылып карады һәм ачу белән бар көченә:

—Атмаска!—дип кычкырып җибәрде.

Ләкин атылган укларны кире кайтарып, аннан да бигрәк, ук тиеп, җирдә егылып калган ирләрне янадан тергезеп булмый иде. Качып баручы таурлар артыннан ук атучылар исә Кодрәт тархан ирләре булып чыкты.

—Кем чакырды сезне монда?—диде Типкә би ачу белән.—Ник аттыгыз?

—Аларга шул гына кирәк тә!—диде тархан ирләренең берсе, авызын ерып, бинең сүзләрен колагына да элмичә.

Таурлар качыша башлау белән кинәт аста капка ачылып китте. Капкадан коралллы сакчылар һәм тархан ирләре бәреп чыкты. Аларның күбесе җәяүле иде, ләкин арада берничәсе атка атланырга өлгергән иде. Яхшы коралланган кала ирләре һай-һаулап, кычкырып таурларны куа киттеләр. Таурлар исә артларына борылып та карамыйча, бар көчләренә куаклар ягына элдерделәр. Алданрак йөгергәннәрнең кайберләре куаклар арасына кереп тиз арада юкка чыктылар, кайберләре читкә тайпылып, текә яр астына ташландылар. Уңлап кешене исә тархан ирләре бүлеп алдылар. Бүленгән ирләр, күсәкләре белән селтәнеп, үзләренең өстенә килгән ат башларын ярдылар, кала ирләренең кулларындагы калканнарын, сөңгеләрен бәреп төшерделәр. Күсәксез, коралсыз калган кайбер башсызраклары, тартып алмакчы булып, үзләренә таба төбәлгән сөңгеләргә таба сикерделәр. Тархан ирләре таурларны ничек тә тере килеш алырга тырыштылар, шуна күрә сөңге-кылычларын бик үк эшкә җикмәделәр. Элмәкле арканнары булганнар исә шундук табышлы булдылар. Төрле яктан чолгап алгач һәм бәҗраны кысканнан кыса баргач, кыргыйлар каршылык күрсәтүдән туктап калдылар, һәм аларны этә-төртә, кыйный-кыйный, шау-шу китереп, кала капкага таба куып киттеләр.

Бу ничектер бик тиз арада булды. Типкә би барысын да бура өстендә карап, күзәтеп торды. Беренче мизгелдә ул каушап-аптырап калды. Таурларның шулай ябырылып килүенә дә, мондый көтелмәгән сугышка да ул бөтенләй әзер түгел иде.

Башбаштаклык, капканың сораусыз-нисез ачылып китүе, тархан ирләренең сораусыз-нисез таурларга каршы ташлануы аны кинәт ярсытып җибәрде, аны кинәт йокысыннан уяткандай булды. Шулай да ачуын тыярга тырышып ул басмадан аскарак төште, Кодрәт тарханны күрмәкче булып як-ягына каранып алды. Ул аны тиз генә күрә алмады. Баксаң ул якында гына торган икән. Кемнедер эзләвен күреп, Кодрәт тархан үзе аның янына килде.

—Менә җир казучылар да, качкыннар да кире кайтты. Качкыннарны тоттык!—диде Кодрәт тархан үз-үзеннән канәгать булып, таурлар төркеменә күрсәтеп.

—Капканы кем ачты?—диде Типкә би, Кодрәтнең канәгать йөзен утлы күз карашы белән өтеп. Ана никтер капканы Кодрәт тархан үзе килеп ачкандыр сыман тоелган иде.

Бинең бозылган ачулы күз карашын күреп Кодрәтнең дә кыяфәте үзгәреп китте.

—Мин түгел, би,—диде ул мыскыллавы сизелеп торган бер корылык белән.

Типкә би ярсып капка сакчылары ягына борылды.

—Капканы кем ачты?!—дип кычкырды ул бар көченә. Капка сакчылары да, башкалар да тынып калдылар.

—Кем кизү торды?—дип кычкырды би. Арадан кысылып, башларын түбән

иеп ике ир килеп чыкты. Аларның икесе дә яшьләр, икесе дә, күрәсең әле генә таурлар артыннан чабып йөреп тирләп төшкәннәр, кызарынганнар, шуңа күрә еш-еш тын алалар иде. Болар капкага аркылы салына торган авыр бик өчен җаваплы сакчылар иде. Алар ашыгып килделәр дә, би алдына тезләнделәр.

—Кем ачты капканы?!—диде би. Бер үк сорауны кабатлап, тыела алмыйча.

—Мин,—диде ниһаять, ирләрнең берсе чак-чак кына башын калкытып.

Озын буйлы, киң җилкәле егерме яшьләр чамасында бик чибәр егет иде бу. Матур булып аның мыегы чыгып килә, үрелгән кара чәчләре салынып тора. Бу әле чын яуда да булмаган—үлемнең күзенә дә карамаган иде. Аның, күрәсең, үлемнең нинди булганлыгын күрәсе килгәндер.

—Тор!—диде би әкрен генә.

Егет бик авырлык белән аягына басты һәм үзенең гаебен аңламаган кебек, үпкәләгән сыман, бинең күзләренә сынаулы караш ташлады.

—Коралларыңны сал,—диде би боерып.

—Ник?—диде егет аңламыйча.

—Сал!—дип кычкырды кинәт ярсып Типкә би.

Шуннан соң ул тиз генә тархан ягына борылып карады.

—Тархан!—диде ул.—Яуга капка ачып без бик зур хата ясадык. Капка ачылганда мин бура өстендә, син читтә калдың. Сакчы үз белдеге белән капканы ачып...

—Үз белдегем белән түгел,—диде гаепле егет, акланмакчы булып.

—Алайса кем кушты сиңа?—диде би егеткә борылып.

—Бакыр тауныкылар!—диде егет.—Безгә эшче кирәк, диделәр. Качканнар урынына яшь таурлар кирәк, диделәр.

—Аңлашылды,—диде би. Шуннан соң ул тарханга борылып карады һәм барысына да ишетелерлек итеп: Тархан! Ирләр!—диде би. Әле генә без зур хата ясадык. Безгә үзләренең гозерләрен әйтергә, безнең белән аңлашырга-сөйләшергә килгән таурларга каршы корал күтәрдек. Таурлар безнең күршеләребез. Таллы таба күл үзәне таурлары безнең белешләр, дуслар. Без алар белән моңарчы дус-тату яшәдек, моннан соң да тату булыйк. Әлеге хатамны төзәтү юлыннан мин тотып алынган таурларның барысын да кире чыгарып җибәрергә боерам.

Шулай дигәч, ул җыелган төркемгә күтәрелеп карады. Ирләр беравык тынып тордылар да, әкрен генә ризасызлык белдереп гүелдәргә, шаулашырга тотындылар. Тархан Кодрәтнең йөзе караңгыланып китте. Ил алдында бигә каршы сөйләргә ярамаганлыгын белсә дә, беренче булып ул сүз башлады.

—Эләккән балыкны кире дингезгә җибәрмиләр,—диде ул.

—Юк, тархан, кайчагында җибәрәләр,—диде би нык итеп, каршы эндәшергә урын калдырмыйча.

—Миңа эшчеләр кирәк, би,—диде Кодрәт тархан, беркемгә дә карамыйча.

—Әнә сиңа ике эшче,—диде би, коралларын салып, башларын иеп торган капка сакчыларына күрсәтеп.

Шулай да Кодрәт тархан би белән бәхәсләшеп тормады һәм үзенең ирләренә тотылган таурларны кире чыгарып җибәрергә боерды. Тархан ирләре теләр-теләмәс кенә тоткыннарның бауларын чишә башладылар. Капканы яңадан ачтылар һәм котылуларына ышанып җитмәгән, куркынган яралы таурлар, як-якларына карана-карана ачык капкадан чыга башладылар. Каланыкылар алар артыннан көлеп, кычкырып-сызгырып калдылар.

Иң арттан Нарис чыкты—тоткыннар арасында ул да бар иде. Ул барысын да күреп-ишетеп торды. Үзләрен би коткарганын ул яхшы аңлады. Шулай да аның янынннан узганда аңа борылып карамаска тырышты.

Би аны туктатты да, шелтәләп:

—Менә, күрдеңме, улым, синең белексезлегең аркасында... дип сүз башлаган

иде, яшь Нарис ана ачулы итеп карап алды.

—Юк, минем аркада түгел, би!—диде ул.—Сезнен Зөлмәт аркасында!

«Дөрес әйтә бит ул!»—дип уйлады би үзалдына. Ләкин бу турыда ул кычкырып әйтә алмады. Башын югары тотарга тырышып яшь кабилә башлыгы капкадан чыгып китте һәм үзен көтеп торган яшь ирләр төркеменә барып кушылды. «Йөгерерләр микән»—дип уйлады би ачык капка аша таурларны күзәтеп. Алдан чыккан таурларнын күбесе инде күптән йөгереп китеп барган иде. Ләкин болары—арткарак калганнары, ничек тә үзләрен дәрәҗәле тотарга тырыштылар һәм адымнарын әз генә дә кызуламадылар, артларына да борылып карамадылар.

«Иртәгә ашлык илтеп бирергә кирәк» дип уйлады би, алар артыннан карап калып.

Төн уртасы узып, беренче әтәчләр кычкыргач, калада ниндидер ыгы-зыгы купты. Өзек-өзек тавышлар ишетелде, шыгырдап ишекләр ачылды, шак-шок басып кемнәрдер каядыр йөгереп уздылар. Бераздан, капка ягында, манараларда шомлы итеп чаң суга башладылар. Озын колга башында утлар чайкалды. Типкә би шау-шу ишетеп уянган һәм ашык-пошык өс киемнәрен киеп ята иде. Шул чакны тыны бетеп анын янына төнге кизү килеп керде.

—Күпер яна, кәмә яна!—дип кычкырды ул коты алынып.

Би ана каршы берни эндәшмәде, сөяп куйган жиреннән жиз хәнжәрен, сөнгесен алды да, бара барышлый бил каешын рәтләп ишеккә юнәлде. Яшь ирләр ике ягыннан анын юлын яктыртып бардылар. Тиз арада бигә атланырга ат китереп бирделәр. Атка атланган берничә коралы атлы ана сарай алдында зәйтүн куагы янында көтеп торалар иде. Алар ашыгып олы капкага таба юнәлделәр. Капка сакчылары шул ук сүзне әйттеләр: күпер ягында ут күренә, кычкырган тавышлар ишетелә, диделәр.

Кәмә күпере махсус сакчылар белән сакланылмый иде. Балтачылар, кизүгә бүленеп, алмаш-тилмәш шунда төн куналар—бөтен сак менә шул иде. Балта-пычкыдан һәм башка эш коралларыннан башка аларнын тагын сугыш кораллары да бар иде. Ләкин алар, көне буе арып эшләгәнгә, кичкелекне ашагач та, карангы төшү белән урынга авалар иде. Төне буе уяу булырга тиешле кизү дә, гадәттә, сөнгесен кочаклап, берәр почмакта йокы симертә иде.

Кичәгенәк таурлар белән булган бәрелештән сон Типкә би капка ябылыр алдыннан балтачылар янына барып кайтты. Таурларны озаткач, бик озак анын эче пошты. Ул үзендә ниндидер бер икеләнү һәм ризасызлык тойды. Ул тумыштан сугышчы иде. Үзенә каршы корал күтәреп яисә корал күтәрергә мөмкин булган теләсә кемгә каршы ничек, нәрсә белән җавап бирергә, кайчан ничек сугышырга—ул инде боларын үзләштергән иде. Тик менә кичәге таурлар сыман ансыз, кыргый һәм бөтенләй диярлек чын коралы булмаган сабый сыман ирләргә каршы нишләргә кирәген анын әлегәчә үзләштереп житкергәне юк иде. Анынча жиз корал белән коралланган чын ир күсәк белән коралланган иргә каршы сугышырга тиеш түгел иде. Көчләр монда күрәләтә тигез түгел. Өстендә ин яхшысы иләнмәгән болан тиресе йә булмаса ярым шәрә һәм кулында бер күсәге булган батырнын корсагын төртеп тишүдән әлләни ләззәт, канәгатьләнү алып булмый, әлбәттә.

Балтачылар янында ул озак тормады—ансын-монсын карады да, калага кайтып китте. Таурлар белән булган бәрелешне балтачылар белә иде. Ләкин әйтерсен алар да би кебек үк әлеге сугышка артык игътибар итмәделәр һәм беркемнен дә ул турыда сүз куертасы килмәде. Күрәсен, таурларга карата булган шундый карашка бирелеп би дә төнге кизүләрне кисәтергә, уяу һәм сак булырга кирәклек турында әйтергә онытты.

Алар, бинен кисәткәнен көтеп тормастан, болай да уяу һәм сак булырга

тиешләр иде. Ләкин, алдырыр, көн яздырыр дигәндәй, алар көндәгечә йокы симерткәннәр. Таурлар ничектер сиздермичә килеп, күпернең берничә жиренә ут салганнар. Борыннарына төтен исе килеп, күпердәгеләр, кәмәдәгеләр уянып киткәндә, күпернең әле бер төшендә, әле икенче төшендә ут күренә. Ирләр шундук сикерешеп урыннарыннан торалар, кайсы кая чабыша башлый. Берәүләр ут үзлегеннән чыккан дип уйлый һәм су белән, ком белән ут сүндерергә тотына. Икенчеләр якын-тирәдә шаулашкан таурларны күреп алалар, коралларына тотыналар. Читтән балтачыларга таш, күсәк, таяк ыргыталар. Каравылда бер-ике кешенең кулы, аягы имгәнә. Күпердә ыгы-зыгы, шау-шу куба, жиз калайга сугып бөтен тирә-якка чаң кага башлыйлар.

Күпердәгеләр белән таурлар арасында сугыш-бәрелеш кызган чакта кала ягыннан ашыгып кораллы ирләр килеп житте. Аларның беркадәре атлы, күпчеле жәяүле иде. Таурлар каладан килүчеләрне күреп алдылар, качыша башладылар һәм елга яр астына төшеп юкка да чыктылар. Атлылар качакларны эзәрлекләп китте, жәяүле ирләр ут сүндерергә тотындылар. Ыгы-зыгы таңга кадәр барды.

Күпергә, бигрәк тә кәмәгә әлләни зыян килмәгән иде. Шулай да монда әле эш көне буена житәрлек иде. Каланыкылардан үлүче-нитүче булмады, бары тик бер-ике кешенең кулы-аягы гына имгәнгән иде. Аның урынына жирдә төнлә кемдер хәнжәр ыргытып үтерелгән ике таур гәүдәсе табылды. Аларны би куркыту өчен таурлар килә торган якка казык башына утыртып асып куярга боерды.

Төшкә кадәр балтачылар күпернең янган, ауган баганалары урынына терәүләр куйдылар, астан янып тишелгән, ишелгән басмаларны, баскычларны алыштырдылар. Төш вакытларында төньяк таулар ягыннан, ачык калкулык итәгеннән йөгереп, ашыгып, бик күп жәяүле кешеләр килгәне күренде. Болар шул ук таурлар иде.

Балтачылар шундук чаң суга башладылар, төтен чыгарып каладагыларга хәбәр бирү өчен жир өстендәге чүп-чар, йомычка өеменә ут төрттеләр. Ирләр тиз арада катырак киемнәрен киделәр, сугыш коралларын алдылар. Таурларны, күрәсең, каладагылар да күреп алды—күп тә үтмәде ул яктан ашыгып килүче атлы чиру күренде. Атлылар ашыгып таурлар төркеменә каршы китте.

Атлы сугышчыларны күрү белән элегрәк таурлар куркып шундук качыша, табан ялтырату ягын карыйлар иде. Бу юлы алай булмады. Атлыларны алар бик кыю каршыладылар. Үзләре белән алар билләренә аскан нииндидер торбаларга, капларга, капчыкларга тутырып төрле зурлыктагы ташлар, очлы агач тамырлары алып килгәннәр иде. Атлы, кораллы, жиз киемле ирләргә алар таш ыргыттылар, күсәкләр, ботак-сатаклы агач тамырлары ыргыттылар. Кызып, ярсып килгән атлылар төркемендә әле берсе, әле икенчесе кычкырып жибәрде—таш тиеп берсенең кулы өнсез калды, икенче берсе күзенә тотынды. Кайберәүләрнең атлары яраланды һәм алар кызганыч тавыш белән чинап-кешнәп арт аякларына бастылар, тыпырчына башладылар. Би ирләрен ярсу биләп алды. Таурлар ягына шундук сөңгеләр очты, выжылдап уклар очты. Кыюланып үтә якын килгән, хәтта башсызланып ат өстендәге ирләргә килеп тотынган таурларны хәнжәр белән турадылар.

Ярсыган, кычкырышкан ярым шәрә һәм таркау кыргыйлар калкулык буенда бик күп үлекләр калдырып, ниһаять, чигенергә мәжбүр булдылар. Ләкин чигенгәндә дә алар шактый нык каршылык күрсәттеләр һәм туктаусыз лелегләр ягына таш, күсәк, таяк ыргыттылар.

Типкә би турыдан-туры сугышта катнашмады, ул арттарак күзәтеп кенә торды. Шул чакны ул кыргыйлар ягында үзенә атап кычкырган тавышлар ишетеп алды.

—Би, Зөлмәтне бир!—дип кычкырды яшь Нарис, баш өстендә озын күсәген селтәп.

Зөлмәтнең атасы Туктар сугышның иң үзәгендә сугыша иде. Күрәсең ул да Нарисның сүзләрен ишетеп алды.

—Бирермен әле мин сина Зөлмәтне!—диде ул Нариска янап һәм юан саплы сөнгесе белән уңга-сулга селтәнеп, як-ягындагы таурларны ырып-жырып туп-туры Нариска таба ташланды. Ләкин төрле яктан таурлар аның юлына аркылы төштеләр, берсе кизәнеп Туктарның атына тондырды. Чукмарлы күсәк атның күкрәгенә килеп тиде. Икенчесе күсәкне Туктарның үзенә төбәп җибәргән иде. Туктар янга авышып калды. Ачуы килеп Туктар оста аучы Нарисны ерактан сөнге белән алмакчы булды, сөнгене ул орды, ләкин очып барган сөнгене таурларның берсе күсәге белән сугып читкә җибәрде. Яшь таурның мондый өлгерлегенә исләре киткән кыргыйлар барысы берьюлы кычкырып җибәрделәр. Нарис шаркылдап көләргә тотынды.

Сөнгесез калган Туктар кабаланып сул ягына тотынды—аның да кыргыйларныкы сыман чукмар башлы зур күсәге бар иде һәм ул аны еш кына ауга да, сугышка да алып бара иде. Ләкин сугыш ыгы-зыгысында кемдер сиздермичә генә аның каешын кисеп кистәнен алып киткән иде. Аның борылып эзләнүен күреп, Нарис тагын тантана белән шаркылдарга тотынды.

—Менә ул, менә!—диде яшь батыр бәхетле таур кулындагы Туктар кистәнен күрсәтеп. Үз коралын дошман кулында күреп, аучы Туктар ах итеп җибәрде һәм ярсып туп-туры Нариска таба томырылды. Бу юлы аның юлына аркылы төшүчеләр булмады. Коралдан түгел, аның усал йөзеннән, кан баскан күзләреннән куркып, тирә-якка сибелеп беттеләр. Таурлар урман-таулар ягына кире чигенделәр.

Типкә би ирләре таурларны төньяктагы Куш-тау дигән җиргә кадәр куалап бардылар. Түбәләрендә шәрә ташлар тырпаеп утырган, итәкләре исә куе яшел урман белән капланган, бер үк биеклегендәге ике калкулыкны шулай Куш-тау дип атыйлар иде. Куш-тауга кадәрге җирләр—таулар, үзәннәр, болыннар каланыкы, Куш-таудан соң таурларныкы исәпләнелә. Куш-тауга кадәр тирә-як ачык иде. Тәбәнәк калкулыкларда һәм шулай ук калкулыклар арасындагы тигез җирләрдә яшеренеп калырлык, качып торырлык бернинди урман да, куаклыклар да юк иде. Монда кая карама—кала кешеләренең иген басулары, яшелчә, җимеш бакчалары җәелеп ята иде. Качаклар әле тар юллардан, әле ызан буйлатып, әле басу өстеннән элдерделәр генә. Куучылар бик күп таурларны кырып, чәнчеп, чабып үтерделәр. Шулай да таурларның кайберләре ике ызан арасындагы берәр ызан артына яисә берәр таш артына качып калдылар, кайберәүләр йөгереп, атлы куучылар өчен унайсызрак булган чакыр-чокырлы, куаклы җирләргә борылып йөгереп китеп бардылар.

Үз коралын дошман кулында күрү Туктарның җен ачуларын чыгарды. Ул куучыларның барысыннан алгарак ыргылып чыкты. Аның ничек тә Нарисны тере килеш кулга төшерәсе килде. Кайчагында ул шулай берәр киекне бик озак куып алҗыта да, киекне куып җитә дә, бар көченә киек өстенә сикерә һәм аны шәрә куллары белән буып үтерә торган иде. Хәзер дә аның Нарисны шулай алҗытасы, куып җитәсе һәм өстенә сикереп бар көченә кочагына аласы килде. Җиңү шатлыгы бары шунда гына тулы булачак сыман иде.

Ләкин Нарис та алай җиңел генә тоттырырга ашыкмады. Ул Туктарның үзен куа килүен һәм һичшиксез тере килеш алырга чамалавын бик яхшы аңлады. Ул әледән-әле артына борылып карады, кинәт кенә читкә борылды һәм бөтенләй икенче яктан йөгерә башлады. Аннан да бигрәк, аның янында өч-дүрт таур ире йөгерде. Нарис кебек үк алар да яшьләр, озын буйлылар һәм тазалар иде. Аларны, әйтерсең ат түгел, эт тә куып җитәрлек түгел иде. Урылган яисә сөрелгән иген кырлары беткәч, Куш-тауга таба бер чакырым чамасы буш җир сузыла. Корыган каты үлән белән капланган буш, тигез

жир сөзәк кенә булып тауга таба күтәрелә бара иде. Үргә йөгергәндә таурлар әкренәячәкләр һәм менә шунда аларны куып житеп булачак. Туктар күнеленнән менә шулайрак дип уйлады, алай-болай кирәк булса дип ул кынысыннан хәнжәрен суырып чыгарды, хәнжәрнең сабын тешенә кысып капты да, йодрыкларын йомарлап, атның тезгенен бушайтып жибәрде. Бик тиз арада ул таурларны куып житә башлады. Таурлар янә артларына борылып карадылар. Хәзер аларның эшләре шәптән түгел иде. Моны алар үзләре дә бик яхшы аңладылар ахрысы һәм алар үзара киңәшләшкән кебек, бер-берсенә елыша төштеләр. Менә шул чагында куып житеп, барысын берюлы басып алырга иде дә бит, юк, булмады, бөтен гомерләрен таулар арасында үткәргән һәм бала чактан ук туктаусыз йөгерергә күнеккән яшь таурлар әз генә дә адымнарын әкренәйтмәделәр. Шулай да, никадәр генә йөгерешче булмасыннар, алар белән ара торган саен кысыла барды. Шул чакны бер төркем булып оешкан таур ирләре кинәт як-якка сибелделәр. Юнәлешләрен үзгәртмичә шулай жыйнаулашып йөгерүләре дә, бергә тупланулары да бары бер хәйлә генә булуын Туктар бик соңлап аңлады. Аңлавын аңлады, ләкин бу вакытта инде ул төрле якка таралган качакларның кайсы артыннан куарга да белмичә аптырабрак калды. Нарисны күзләп унга-сулга караган арада кинәт аның сул ягыннан чукмар башлы, жиз калай белән ныгытылган шома саплы күсәк очып килгәне чагылып калды. Күсәк туп-туры атның башына килеп тиде. Ат кисәк чинап кычкырып жибәрде, яралы башын бик каты чайкап сөрлегеп китте һәм бөтенесен алдан исәпләп, киеренкелектә барган аучы бар көченә мәтәлеп жиргә кадалды.

Ул бик озак исенә-акылына килә алмый ятты. Күзләрен ачып караганда анын сөекле аты, дүрт аягын сузып, әледән-әле хәлсез генә тыпырчынып жирдә чалкан ята. Аның янында ирләр, атлар туктап калган, барысы да борчылып аңа карап торалар иде.

—Тоттыгызмы?—диде ул беренче сүзе итеп.

—Юк,—диде Типкә би теләр-теләмәс кенә

—Их!.. дип куйды аучы Туктар, көрсенеп.—Шундый шәп киекне кулдан ычкындырдым.

—Исән калгансың—шунысына сөен,—диде би, Туктарны юатып.

—Үзләрен дә әз кырмадык, акыл булыр—моннан соң килмәсләр,—дип куйды шунда кемдер.

Башкалар җавап бирмәде.

Ләкин алар барыбер килделәр. Икенче көнне үк түгел—берничә көннән сон, инде бетте, тынычландылар дип уйлаганда, бөтенләй көтмәгәндә, бик күп булып, ябырылып килделәр.

Икенче көнне исә диңгездә давыл купты.

*Ахыры киләсе санда.*

*Татарстаннан читтә яшәүче каләмдәшләребез*

**БАШКОРТСТАН**



Мөхәммәт Закиров

# ЭЗЛӘРЕНДӘ ЙОЛДЫЗ КАБЫНА

## Мостай урамыннан Мостай килә

*Әҗәл, дигәне, ихтимал,*
*Мәрт булыр.*
*Бәлки, чыгып йөрергә дә*
*Дәрт булыр.*

Мостай Кәрим.

**«Мостай урамы»ннан Мостай килә:**
**Чаттагы үз**
**Исеменә карый каерылып...**
**Дөнья шул диярлек: акылсызны**
**Акыллыдан булмый аерып.**

**Чыккан Мостай.**
**Аһ, бу якты дөнья!**
**Соң ул әле кемне туйдырган?**
**Урамы бар.**
**Күпме туганы бар, —**
**Бар дөньяны урам сыйдырган.**

**Бар да кала икән.**
**Ул, ниһаять,**
**Бар эшенең чыккан очына*.**
**Бар эшенең очына чыкканга ул**
**Куанамы, әллә пошына?**

**Мостай килә.**
**Аяк асларына**
**Алтын көзнең сибелә сарысы, —**
**Кайчан киткәне бар үзе белән**
**Бөек шагыйрьләрнең сагышы?**

**Мостай килә.**
**Тузгак чәчләренә**
**Карлар ява. Буран сарыла.**

Мөхәммәт ЗАКИРОВ (1950) — *шагыйрь; берничә китап авторы. Уфада яши. «Кызыл таң» газетасында эшли.*

Фанилыктан бакыйлыкка ашкан
Эзләрендә йолдыз кабына.

«Мостай урамы»ннан Мостай килә:
Сокланышмы дөнья ямена?
...Ул дөньяга мәңгелеккә кайтты,
Китү белән аннан мәңгегә.

***

Закон булып әверелгән
Законсызлык, —
Шак катмыймын;
Акыл булып түргә менгән
Акылсызлык, —
Шак катмыймын;
Хәерчелек, байлыкка да
Шак катмыймын;
Исереккә, айныкка да
Шак катмыймын...
Әле нигә бу шигырем
Язып ятам? —
Кемгә кирәк? Үз-үземә
Шаклар катам.

***

Җир шары — зәңгәр йомгак,
Тәгәри Галәм буйлап.
Йолдызлар атып шаяра
Күк-дәрья, юри уйнап.

Дөрләп кабынып, йолдызлар
Күкләрне яра-яра,
Җиргә килеп җитәр-җитмәс
Сүнәләр яна-яна.

Атылды тагын берсе
Караңгы күкләр аша.
Галәмнең күз яшедер, —
Йөрәгем еламаса...

***

Йөреп ятам.
Күктә болыт йөри.
Уртаклык юк кебек арада.
Әйтерсең дә, өем-өем мамык
Күзгә күренмичә тарала.
Тарала да...
Күкләр дәрьясында
Булмаган да кебек югала.
Йә булмаса,
Тамчы дымга мохтаҗ
Басуларны юмарт сугара.
Кай арада
Каплап ул кояшны
Диңгез булып җиргә ишелә.

*«Кошлар очырам» дигән шигыреннән.

Күпне күргән Ачлык патшасының
Бәндәләргә юлы киселә.
Яшен-күкрәү офыкларга сыймый,
Шул болытка, гүя, күкләр тар.
Йөреп ятам,
Күктә болыт йөри —
Минем дә бит шундый чагым бар.

***

Бергә шаулашканнар табыннарда,
Тормышта бер юлны куганнар
Үзләре үк этлек кылалар да,
Үзләре үк дошман булалар.

Дошман күрер өчен, ул этлекне
Мин эшләргә тиеш, әлбәттә.
Тик кая ул? Иблис булу кирәк
Мәкер дигән нечкә сәнгатьтә.

Ничек, нинди этлек эшләүләрен
Аңлаганны яхшы аңлыйлар.
Минем алда беркайчан да инде
Үз-үзләре була алмыйлар.

Күрешәбез, берни булмагандай,
Алар һәйбәт, алар һавалы.
...Уйлап баксаң, безнең фаҗигаләр —
Икейөзлелекнең дәвамы.



Илдус
Фазлетдинов

# МӘҢГЕЛЕКТӘН БАШЫН АЛГАН ГОМЕРЕМ...

* * *

Гомеремнең башы—Мәңгелектә—
Таш гасырдан маймыл бабайлар
Меңъеллыклар аша үрелеп карый:
Нәрсә эшли безнең малайлар?

Алар рухы кайчак пыскый җанда,
Кайчак дөрләп китә учактай.
...Ул чакларда тамырларга кайтам,
Маймылланып алам ул чакта.

Илдус ФАЗЛЕТДИНОВ (1975)—*шагыйрь, филология фәннәре кандидаты; Уфада яши. «Тулпар» журналында эшли, университетта татар бүлегендә укыта.*

Болгарлардан, Алтын Урдалардан
Бабаларым мине күзәтә.
Шуны сизеп, кешелеккә кайтам,
Атлавымны янә төзәйтәм.

...Мин үләрмен...
Ләкин мин үлмәмен—
Җанны саклар меңәр варислар,
Һәм көнләшеп миннән, ачуыннан
Кара янып көяр Тарихлар.

Җаным минем дәрьяларны кичәр,
Тик чыныгып чыгар ут аша.
...Мәңгелектән башын алган гомерем
Мәңгелеккә барып тоташа.

* * *

«Кеше Җирдә бары кунак кына,
Гомер—мизгел, янган шәм генә»...
Ышанмыйм мин моңа, сафсата бу—
Кеше Җиргә килә мәңгегә.

Үлгәч тә ул Җир куенына керә,
Туфрак булып янә яңара.
Күкрәгеннән чәчәк үсеп чыга,
Орлык коя—тормыш ярала.

Гомеребезне бер мизгелгә тиңләп
Йөремикче, дуслар, күңелсез.
...Кеше гомере Җирдә дәвам итә,
Җир булганда, Кеше үлемсез!

* * *

Кыяга менгәндә кеше
Ялга туктап ала.
Үткәннәргә караш ташлап,
Киләчәккә бага.

Маңгай тирен сөртеп ала,
Аннан атлый алга.

Шулай, үрләр яулаганда
Туктап була ялга.

Һәр ял саен кыя очы
Якына бара.
...Кыядан очып төшкәндә
Ялга туктап кара!

## Парадокс

Кеше туа...
Теләмичә,
Тыпырчынып, дулап:
«Ник килдем бу дөньяга!»—дип
Оран сала елап.

Кеше үлә...
Ике дөнья
Араларын ватып.
«Котылдым...»—дигәндәй кала
Елмаюы катып.

* * *

**Хыялында күкне коча,**
**Тәне җиргә тарта.**
**Кеше—мәңгелек каршылык,**
**Кеше—үзе хата.**

**Бу хатаны төзәтә ул**
**Үтеп гомер аша.**
**...Шуңа үлгәч, тәне җиргә,**
**Җаны күккә аша.**


* * *

**Бу авылда кем асаба?***
**Кем монда килгән күчеп?**
**«Син—килмешәк»,—дип тарихчы**
**Тарихтан ала үчен.**

**Янәсе, мин төп халыкның**
**Телен тартып алганмын.**
**Алганмын да, урынына**
**Үземнекен салганмын.**

**Алмадым да, салмадым да**
**Кирәкми миңа бүтән.**
**«Әллүки»ле Тукай телен**
**Мең ел йөрәктә йөртәм.**

**Авылның милләтен эзләп,**
**Ватмагыз сез башларны.**
**...Һәммәсен дә сөйләп бирер**
**Иске кабер ташлары.**



Мөнир
Вафин

# ҖИРГӘ АТЫЛГАН АЛМАДАЙ...

* * *

**Башка милләтләр безләргә**
**Карыйлардыр таң калып.**
**Без Тукай кадәр Тукайны**
**Саклый алмаган халык.**

**Аз-маз Коръән сүрәләрен**
**Әйтәлсәк тә яттан без,**

**Шагыйрьләрне асрамага**
**Бирә торган заттан без.**

**Бөек диеп аталырга**
**Бармы, юкмы хакыбыз?**
**Асрама бала хәлендә**
**Калып бара халкыбыз...**

* * *

**Кешеләр китеп баралар,**
**Кала исем, балалар.**
**Ни кыйраткан—шуңа карап,**
**Аны искә алалар.**

**Хезмәте булса—мактыйлар,**
**Хәтергә ала-ала.**

**Бөтенләй кыйратмасаң да,**
**Барыбер нидер кала.**

**Тузан кала. Һәркем җирдә**
**Нидер калдырып узган.**
**Менә хәзер күзгә керде**
**Кемнәндер калган тузан.**

Мөнир ВАФИН (1961)—*шагыйрь, публицист; татар телендәге «Сүзләр чәчтем», «Дөнья—куласа», «Йөрәгем парәләре» исемле китаплар авторы. Уфада яши.*

*Асаба—төп халык, җир хуҗасы (ред.)

* * *

Ай «төн кошы» булса да бит,
Көнне күрми ул да түзми.
Күргәнсездер, кайбер чакта
Күктә калып көнне күзли.

Кыш җәйләрне беркайчан да
Күрми диюләр дә хата.
Урман, чокыр-чакырларда
Качып-посып карлар ята.

Шул ук язмыш мине көтә,
Йөрәк сүнәр, тәннәр катар,
Көчләп йомдырылган күзләр
Качып кына күзләп ятар.

* * *

Яшь түгел, каннар мөлдери
Чал тарих күзләрендә.
Бабаларның кабер ташы
Чиркәү нигезләрендә.

Кан һәм сөяктән төзүләр
Әйләнгән гадәтенә.
Алтын Урда нигез булган
Русия дәүләтенә.

Без—төзү кирәк-ярагы,
Татарлар ныклы алар:
Шуңа күрә «безне зурлап»,
Нигезләргә салалар.

* * *

Тәрәзәңне җилләр какса
Озын, кара кичләрен,—
Ачып керт син, җилләр түгел,
Алар минем хисләрем.

Тәрәзәңә яңгыр тамса,
Ишетсәң күк күкрәвен,
Алар минем яшем булыр,
Дөнья ярып сыкравым.

Тәрәзәңә кар сарылса,
Син булганда чал «шәл»дән,
Карлар түгел, миннән хәбәр
Булыр—кардай түшәлгән...

* * *

Күпме «дуслар» дуслык имтиханын
Бирелмичә сынып калдылар,
Капчык тозны уртак ашау түгел,
Бер уч тоздан тынып калдылар.

Ә шулай да чын дус була икән,
Бар михнәтне уртак сөйрәгән.
Бер адым да мине ташлап китми
Янәшәмнән килә ...күләгәм.

* * *

Бер көн килеп оҗмах бакчасында
Безләргә дә урын табылыр.
Фәрештәләр миңа чират торыр,
Хур кызлары судай агылыр.

Алла мине үз янына дәшәр,
Утырырга бирер тәхетен:
«Синең тормыш тәмуг кебек иде,
Инде таты оҗмах рәхәтен».

Рәхмәт укырмын да... Тик җәннәттә
Әйтеп булмас аңа ямь югын.
Оҗмахтагы ләззәт арасында
Сагынырмын тормыш тәмугын.

* * *

Алмалар йөзе алланган,
Куш йодрык—зурлыклары.
Кинәт, берсе өзелеп очты—
Чәчрәде орлыклары.

Алмадай алсу йөзлесен
Эзләдем, эзләдем дә,
Җиргә атылган алмадай,
Ватылдым тезләрендә...



Фәрит
Суфияров

# ОЯ КОРЫР БӘХЕТ КОШЛАРЫ

## Ышанасы килә

Ышанасы килә могҗизага:
Гамьсез җаннар кайтыр иманга.
Күк читендә елмайган таң кебек,
Өмет яши, күңел инана.

Кыш юрганын ябар кыр өстенә—
Ышандыра шуңа ничек тә.
Быел игеннәрем уңар але,
Теләгемне Ходай ишетә.

Адашканнар үз сукмагын табар,
Егылганнар бассын аякка.
Бөлгенлеккә, мескенлеккә төшмик,
Юк, калмасын кеше оятка.

Үз парларын табар ялгызаклар,
Оя корыр бәхет кошлары.
Йөргән юлларыннан уңып кайтсын,
Нужа күрми, адәм башлары...

Ышанасы килә кешеләргә,
Игелекле булыр эшләре.
Тормыш учаклары нур балкытсын,
Сый-хөрмәтле торсын өстәле.

## Сандугачкай

Сандугачкай кайтты бакчабызга,
Сагынгандыр, беләм, оясын.
И, кошкаем, тавышыңны таныйм,
Туган җирда шатлык тоясың.

Моң-авазың белән данлыйсыңмы,
Зурлыйсыңмы газиз йортыңны?
Ышанычың артты таныш җирдә,
Бөтен булган шигең онтылды.

Фәрит СУФИЯРОВ—*шагыйрь; берничә китап авторы. Яңавылда яши.*

Талпынасың күкләреңә менеп,
Яшел тирәгеңне сайлыйсың.
Йөрәк өзгеч, ах, моңнарың белән,
Бакчам уртасында сайрыйсың.

Өметләнәм : бозлар булып каткан
Сары сагышларым эресен.
Узган гомер, үткән юлларымда
Уйландыра мине төрлесен.

Моңнар дәрьясына төшеп йөздем,
Юанычлар таптым, күрәсең!
Заманалар авыр, хәтәр чакта
Хәл белергә миңа киләсең!

## Түгәрәк күл

Түгәрәк күл яр буенда
Камышларын биетә.
Акчарлаклар канат кага
Күк өстендә, биектә.

Берчак йөгерә дулкыннар,
Ярына әллә сыймый.
Көмеш кыңгыраулар сыман,
Аһәңле моңнар чыңлый.

Бермәлне сәер тынлыкта
Пар аккошлар кагына.
Дулкыннар ярга сыена,
Якты нурлар чагыла.

Бәйдә тора тулпар сыман,
Яр читендә көймәләр.
Өнсез калган, сабырланган,
Язмышына күнгәннәр.

Төнбоеклы түгәрәк күл
Карашын күккә теккән.
Җәннәтнең бер почмагыдыр,
Күпләрне гашыйк иткән.

## Яшәү яме табармын

Ил өстенә давыл үрләсә дә,
Яшен уйнап болыт килсә дә.
Шикләндерә, куркуларга сала,
Күңел түрләрендә үлчәнә.

Илгә булган кайнар сөюемне,
Горурлану хисен белдерәм.
Эчәр суын, ашар икмәк биргән
Туып-үскән җирем, бергенәм.

Бәрәкәтле туфрагыңда шытып,
Тамырланып үскән бер гөлең.
Илгә фаҗигалар янап торса,
Аянычлы узар гомерем.

Уңышларың артса куанырмын,
Үр яуласаң ныгыр канатлар.
Кырга сыймас шатлыкларым ташып,
Мин дөньяга туам кабаттан.

Иҗат—хезмәт белән бизәләсең,
Тыныч атсын, илем, таңнарың.
Җир—тетрәп, сулар—болганмаса,
Яшәү яме синдә табармын.

*Хикәяләр конкурсына*

Наил
Шәрифуллин

# СОҢАРГАН СӨЮ

Кайчагында очраклы гына килеп чыккан очрашулар да күңелдә онытылмаслык җөй калдыра, кеше дигән затның без исәпләмәгән беркатлы гадилеге белән янәшә үрелгән аңлашылмас катлаулылыгын бөтен тулылыгы белән ачып сала, тетрәндерә, үкендерә дә икән.

Без, кешеләр, күбрәк ни өчен яшәгәнебезне белми, аңламый, гадәт буенча гына гомер сөрәбез төсле. Безнең белән акыл түгел, төрле очраклыклар, ниндидер вак мәнфәгатьләр, мин-минлекле хисләр идарә итеп килаләр. Бик сирәк очракларда гына без үз язмышыбызның хуҗасы була алабыз. Җыелып килгән ялгышлар, мең кат үкенеп тә соңыннан беркайчан да төзәтергә мөмкин булмаган гомерлек хаталар өчен газапланырга һәм гаҗизләнеп, нигә килгәнен аңламыйча, мәңгелеккә китәргә дип килгән ахры кеше заты бу каршылыклы дөньяга...

Әйе, гади генә бер очрашу иде ул.

Заманында күрше авылдан килеп укып йөргән, белем эстәүнең соңгы ике елында минем белән бер партала утырган, һәрчак шук һәм җор телле элекке сыйныфташым Дамирны мәктәп елларыннан бирле очратканым юк иде. Ялгыш кына дигәндәй авылларына—Ташлыкка барып чыккач, башта танымадым үзен. Яртылаш пеләш баш, вакытыннан алда җыерылып беткән чырай, элек очкыннар чәчеп торган шаян күзләр урынына ниндидер тоныкг караш. Заманында бик күп кызларның йөрәген алгысыткан, төн йокыларын качырган бөдрәләре дә тураеп, чуалып беткәннәр. Сыйныфның беренче чибәре саналган, безнең ишеләрне карап та күрмәгән Айсылуны нечкә биленнән тотып озатып йөргән чакларда як-якка сыпырып, тарап кына йөрткән карга канатыдай кара мыеклары да сирәгәйгән, чаларган. Өс-башы күптән сабын, су күрмәгән.

Юк, элекке Дамирдан йөз чалымнары белән исеме генә калган иде. Йа, Хода, ул гына да түгел икән әле, сул кулы беләзектән юк, аның урынына теткәләнеп беткән иске свитер җиңеннән ничектер шакмаклап киселгән беләк башы гына сәер тырпаеп тора. Мин чирканып киттем. Шәһәр тирәсендә мондыйларга бомж, сукбай диләр. Тәртипсез тормыш, үз хаҗәтләреннән колы булу күпләрне шулай вакытыннан алда юкка чыгара. Сабакташны түгел, ни өчендер заманны гаеплисем килеп китте. Заманы да бәндәгә гел кире шул аның. Ике албасты сагалап тора йомшак һәм ихтыярсыз ир-ат затын: эшсезлек һәм аракы. Ялгызлык та өстәлсә, исән калырмын димә инде. Заман алып килгән тозаклар... Тик ни өчен Дамир соң? Агым уңаена йөзә торганнарга бер дә охшамый иде бит ул теге елларны...

Шайтан суы турында уйлап ялгышмаганмын, шактый кызмача иде сабакташым. Калтыраган сыңар кулын ничектер кыюсызрак итеп сузып килеп күреште дә, хәл-әхвәл сорашкач, кинәт кенә батыраеп китеп әйтеп куйды:

—Әйдә, Әхтәм сыйныфташ, акча кызганмыйча бер ярты ал да, безгә кереп туйганчы сөйләшеп утырыйк әле. Бер-беребезне күрмәгәнгә дә ике дистә ел була бит инде.

Сәрхушләр белән һич кенә дә дуслыгым булмаса да, үз-үзен югалта барган танышымны, яшьтәшемне кызганудан, аның мондый халәтеннән ничектер сискәнеп китеп, ризалашып куйдым. Кая инде, мондый чакта вакыт юк дип яки саранланып торып булмый бит. Алты ел бергә укыган сыйныфташ. Үзенә миннән бигрәк мин аласы шешә кирәгерәген дә чамалыйм. Шулай да биек өянке астына елышкан ларек-кибеттән ул сораган нәрсә белән азмы-күпме кабымлык ише әйберләр алдык та, югары очка, Дамирларның тау битенә дип әйтерлек урнашкан йортларына таба атладык. Бер сөйләшик әле, диде бит. Тормышның төбенә бөтенләй төшеп житкәннәрнең алай ачылып китеп сөйләшәсе килер иде микән?

Мин ни дип сүз башларга, нәрсә сораштырырга белми аптырабрак барганда, ул үзе башлады. Сөйләшергә, гәпләшергә яратуы элеккечә иде Дамирның:

—Танышлар күрендеме, иң әүвәл кул турында сорыйлар. Хәтсездән инде, кыш көне салган килеш кар өстендә йоклап китеп өшеттем мин аны. Бер бияләй түбән очта, ферма янында ук төшеп калган. Атна дигәндә бармаклар, учка чаклы бөтенләй каралып, гангренага киткән иде. Кистеләр дә, группа бирделәр. Шуның акчасына жан асрыйм, яшәгән булып йөрим инде менә хәзер. Бәлки шул чакта бөтенләй жан тәслим кыласы булгандыр. Ялгызлыктан да каһәрле нәрсә юк икән ул, яшьти, дошманыңа да язмасын. Ничек эчми түзәргә кирәк? Ходай: «тагын бераз газаплансын әле бу» дигәндер инде, шуңа калдырып торгандыр.—Ул шулай, капкаларына кергәнче, бөкрәеберәк атлый-атлый үзалдына дигәндәй туктаусыз сөйләнеп барды.

—Әткәй белән әнкәй хәтсездән гүр ияләре инде.

Буйдаклар гына яши ала торган, аларга гына хас шыксыз һәм нурсыз өйгә үтеп, кыршылып беткән иске клеенка жәелгән өстәлдәге юылмаган чынаяклар арасына шешәне китереп утырткач, элекке сыйныфташ янадан сүз башлады.

—Үзем дә кайчагында шулар янына жыенгалап куям да, бөтенләй үк жыенып бетә алмыйм әле. Тормышның бер генә дә кызыгы юк. Менә шушы нәрсәне капкач кына бераз яшиселәр килеп китә.—Ул ничектер монсу елмаеп, өстәл уртасына, шешәгә ымлап куйды.

—Туктале, нигә алай дисен? Синең гаиләң, хатының бар иде түгелме соң? Алар хәзер кайда инде?

—Ашыкма, хәзер барысын да сөйләп бирәм. Өйлән, эшкә урнаш, кеше бул диясең, акыл өйрәтәсең килә инде синең.—Ул күзләредәй тоньк керле стаканнарга аракы агызды да, кабаланып һәм тәкатьсезләнеп, мине дә көтми, эчеп тә куйды.—Күптән бер эчне бушатасы килгән иде. Синең кебек ипле кешесе генә табылмады. Үзем кебек имгәкләргә аны сөйләдең ни дә, сөйләмәдең ни. Сабак алудан узган инде алар. Менә тыңла әле.

Ул акрын гына сөйли башлады. Сөйләгән саен тоньк күзләренә иплэп кенә жан керә, төс инә иде.

—Ишеткәнсеңдер дә инде, мин бит, авылны шаккаттырып дигәндәй, ар кызына өйләнгән идем. Валентинага.—Шунда ул туктап, стенага, ике тәрәзә арасына эленгән фотосурәткә озак кына карап куйды. Сурәттән матур итеп елмаеп, түгәрәк йөзле, калын толымлы, егермеләр тирәсендәге бик тә мөлаем яшь хатын-кыз карап тора иде.—Өйләнүен өйләндем, тик акыл белән, кадерен белеп яши генә белмәдем. Минем акылсызлыкларга, кимсетүләргә түзә алмыйча, хурланудан соңгы дәрәжәгә житкәч китте ул, мәңгелеккә китте.

—Авылларына, Нәрәскә мени?

—Анда гына түгел шул, алай гына булса, күптән алларына барып тезләнгән, алып кайткан булыр идем. Терсәк якын да, тешләп булмый. Суга батып үлде ул. Шуның, туганнарының, хәтта үз ата-анамның каргышлары төшкәндер ахрысы миңа. Югыйсә, мондый ук хәлгә калмаган булыр идем.

—Мин ул кадәресен ишетмәгән идем әле.

—Ишетмәсәң, менә шул. Дөньялар тәмам болганып киткән еллар иде

бит. Минем дә болганып, тәмам чуар күнелләнеп киткән вакыт шул елларда булды бугай. Район үзәгендәге сөт заводында шофер чагым. Кичләрен авылда. Илдәге, авылдагы үзгәрешләргә төкереп биргән дә юк. Яшь чак бит. Әти белән әнинең пенсияләре килеп тора. Алган акчаны үземә генә тотам. Әни дә җәлләми. Сонлап, көттереп туган бердәнбер бала бит. Өс-баш әйбәт. Кыяфәт шәп. Мин авылда беренче егет. Кызлар мәсьәләсендә бик елгыр икәнне мәктәптә укыганда ук белә идең ич инде. Солдат хезмәтеннән соң, руль артында берничә ел йөргәч, тагын да шомардым. Үзебездә, якын күрше авылларда берсен ташлыйм, икенчесен башлыйм дигәндәй. Теге видео-мидео, секс-мекс таралып маташкан вакыт. Кызларның да кайберләре заманга карап «современный»лана башлады. Аерылган яшь сатучы хатын белән, гомумән, пачти ирле-хатынлы. Шуның белән акрынлап салгаларга өйрәндек. Ул чир дә шул елларда ныклап башланды бит инде. Кибетләрдә тезелеп торалар. Җаның ниндиен тели...

Берсендә икебезгә дә артыккарак киткән. Икәүләп баш төзәттек. Шулай йөри торгач, бер матур гына иртәдә правасыз да, эшсез дә калдым. Правасын бераздан кире кайтара алдым, эшкә генә бүтән алмадылар. Җәй башланып кына килгән чак. Авылда, өйдә ятам. Шулай айдан артык яттым. Кая барасың, бер җирдә дә чакырып тормыйлар. Колхоз дигәнендә рәтле эш юк. Егет солтаны килеш фермада тирес чыгара алмыйм бит инде. Өстәвенә, түләмиләр. Шул чагында Мөктәсәр абый очрады. Нараста, күрше ар авылында төпләнеп, шундагы колхоз гаражында механик булып эшләүче туган тиешлерәк инде шунда. Аламарак кына булса да, бер «ЗИЛ» буш тора, җәен шунарда эшләп йөр, аннан соң берәр җае чыгар, ди бу. Хезмәт хакы ягын да өметле генә әйтә. Тоттым да, тәвәккәлләдем. Ун чакрым ара мени? Арлар яшәсә дә, күрмәгән, белмәгән авыл түгел. Барысы да диярлек татарча чатнап тора. Тик ятуы да туйдырды.

Эшләп киткәннең икенче атнасында шулай кырдан туралган кукуруз ташырга куштылар, силоска. Комбайн турап өйгәнне әрҗәдә таратып, таптап торырга быел гына мәктәпне бетергән бер ар кызын билгеләделәр. Безнең якта бу эшне күбрәк малай-шалай башкара. Монда ни өчендер гел кыз-кыркын. Кайбер чытлыграклары, миңа карап: «Кыче чебер пи!»* дигән булалар. Минеке генә дәшми. Кереп утырды бу кабинага, исәнләште. Карыйм, ярыйсы гына үзе. Кыйгач кашлар, безнең татар кызларыныкына тартым түгәрәк йөз. Буй-сын да бер дигән. Шактый кыю да күренә. Безнеңчәне дә ярыйсы сукалый. Унынчыны Ялтауда, татар мәктәбендә бетерәләр бит. Исемен сорап танышып киткәч: «Ташлык татарлары басты инде авылны» дигән була, үзе елмая. Мин инде, тупас нәрсә, бераз оятсызланып: «Берегезне дә басканым юк әле»,—дип ычкындырып җибәрдем. Шаяртам, янәсе. Башта аңламады. Аннан соң, аңлап алгач, читкә карап ничектер оялыбрак көлде дә, кисәк житдиләнеп, кызарып чыгып әйтеп куйды: «Сүз ул турыда түгел». Аннан соң ярты сәгатьләп сөйләшмәде. Кичкә таба инде тагын берни булмагандай иркенләп сөйләшә, көлешә идек.

Шуның белән шул, танышлыкның өченче көнендә, кич житкәч, мин, элекке гадәтне куып авылга чапмадым. Нараста калдым. Инде, үзең беләсең, озакка сузарга яратмыйм, әрсезлегем дә, әшәкелегем дә житәрлек иде. Ар кызлары алай артык ялындырып тормый диләр, мин монда вакытлы кеше, башта бер генә уй. Нинди уй икәнен чамалыйсыңдыр инде. Клублары тирәсенә барырга шөлләтә, егетләре без, әрсез татарларны бик яратып бетермиләр, кызмача булсалар, тукмап ташларга да күп сорап тормыйлар. Тыкрыклары турылап кына килеп туктыйм да, Валя озак көттермичә генә кабинага чыгып утыра. Аннан соң йә инеш буена, йә умарталыклары ягына китеп барабыз. Сизеп, белеп торам, охшата мине. Әмма үбешү, кочаклашуга алай каршы булмаган кыз башкасына якын да җибәрми. Көче шундый, үзе шатырдатып кулны каера башлый. Мин «булды, житте» дигәч, кабинаны яңгыратып,

* Бигрәк матур егет икән! — удмуртча.

рәхәт итеп көлеп ала. Тора-бара үзем дә ияләшеп киттем төсле, алай ук кулымны, нәфесемне сузмый башладым. Нәрсә әйтим, ошамаслык түгел, бар ягы да килгән. Аз гына яратам да сыман. Ләкин тулышкан күкрәкләр, тыгыз ботлар һаман ымсындыралар бит, канны кыздыралар. Бүгенге акылның чиреге генә булсачы шунда. Юк шул. Мажара эзлим. Табышын сагалаган җанвар кебек, түземлелек белән җай чыкканны көтәм. Шулай тегенең күнеленә оеткы сала башладым. Әйдә, көзгә өйләнешик, дигән булам... Баштарак гел шаярудан кабул итте. Ышанмады. Аннан соң хәтсез көннәр: «әти-әниең үлгәндә дә ар кызын алдыртмаячак» дип, минем «тәкъдимне» кире кагып килде.

Шулай итеп без моның белән көзне дә җиткердек. Кукуруз күптән урылып бетте. Валя ындыр табагында, мин йә ремонтта, йә төрле эштә. Көндезләрен бик күрешә-очраша алмасак та, сизәм, бөтенләй ияләште бу миңа. Таныш ар хатыннары да: «кияү» дип үрти башладылар. Гадилеге, ошату-яратуы беләндер инде, ындыр тирәсенә барып чыксам, йөгереп каршыга килеп җитә. Ә кичләрен кочактан чыкмый. Безнең татар кызлары кебек тартынып тормый. Тыгыз ботлары да, тулышкан күкрәкләре дә хәзер минеке, каршылык юк диярлек. Әмма мин теләгән эш үтәлми. Өйләнешү турында сүз куерткан булам. Шулай берсендә, мин тырыша, үгетли торгач, әйтте бу: «Дамир, әти-әниеңнең ризалыгын ал, алай бик өйләнәсең килгәч, мине алып кайтып күрсәт үзләренә, ниятең чыннан булса. Минекеләр сине белә инде, бәлки каршы да булмаслар»,—ди.

Менә сиңа, иске авыздан яңа сүз, минәйтәм. Монысын, кәнишне, көтмәгән идем, хәтта аптырабрак калдым. Ике авыл азмы-күпме аралашкандай итсәләр дә, шушы көнгә кадәр ар кызын алучы, яки ул якка кияүгә чыгучы юк иде төсле. «Ярар, шулай эшләрбез дә»,—дидем дә, сүзне башкага бордым. Ә ул, тәмам миңа ышанып, барысын да чынга кабул итә башлаган иде инде. Кереп киткәндә, гадәтенчә, үрелеп бер үпте дә, бик озак итеп күзләремә карап торгач, тын гына, сабыр гына итеп әйтеп куйды: «Телисеңме, Дамир, яратуым хакына мин синең фамилияңне генә түгел, сезнеңчә исем алырга да, хәтта динегезгә күчәргә дә ризамын?». Шулай диде дә, тиз генә кереп тә китте.

«Да-а, мондыйны ишеткән юк иде әле. Муеннан гашыйк булган бит бу миңа»,—дип уйлап куйдым. Әллә ниткән горурлык хисе биләп алды. «Өйләнеп җибәрсәң, эттәй тугрылыклы буласы икән үзе». Монысын инде юри генә уйлап куйдым. Бер исәбем дә юк иде башлы-күзле булырга...

Әмма барыбер өйләнергә туры килде.

Тагын бер атнадан алып кайттым мин моны үзебезгә. Җитди уйлар белән түгел, уяулыгын киметергә, морадыма ирешергә дип. Астыртын уй уйлап. Әни минем бик тә ачык йөзле, кунакчыл кеше. Әти дә ул вакытта аягында. Төш вакытында кайтып кереп тәмләп кайнар аш ашадык. Чәй эчтек. Әни кыстый гына кызны. Аркасыннан да сөеп алды. Бер нәрсә дә белми, уйламый бит. Силос ташыган вакытта әйткән идем, грузчик итеп бер яшь кызны билгеләделәр, дип. Шуннан башканы исәпләми. Ә мин эчтән генә, шулай әни, шулай, дөрес эшлисең, дип сөенәм. Мине ишеткәндәй, капка төбенә чыгып, озатып ук калды безне.

Хәйләм, үҗәтлегем, яшерен сөенүләрем бушка китмәде. Беркатлы җан, моның әти-әнисе риза, үземне бик яраттылар дип уйлагандыр инде, күрәсең. Шактый үгетләгәч, шул кичне үк теләгәнемне алдым. Алай да, «эш» беткәч, үксеп-үксеп бер елады да, мөлдерәмә яшьле күзләре белән миңа карап: «Алдамассыңмы соң, алдамассыңмы?»,—дип, нидер сизенгәндәй, кат-кат сорады. «Юк инде,—дигән булам,—бер-ике атнадан, әти терелгәч, сoратырга алып килермен үзләрен». Шулай алдый-йолдый тагын өч атналап уйнадым кыз белән. Сентябрь азагының салкынча бер кичендә, «иртәгә сорасы көнне», машинаны гаражларында калдырып, сатлык җандай юкка да чыктым. Максатка ирешелгән. Берәр айдан район үзәгендә эш тә чыгарга тора иде. Үз дигәнемне иттем бит тәки. Ял да итеп алам әле, янәсе. Алайса кыз чын-чынлап ашыктыра башлаган иде бит. Ярар, югалмас әле, Валентина, онытыр, дип уйлыйм. Кызгану хисенең әсәре дә юк.

Ә ул анда, мескенкәем, сонынннан сөйләве буенча, ашаудан, йокыдан калган, тәрәзәдән күзен алмый Ташлык юлына карап һаман мине көткән, елый-елый саргаеп, кибеп беткән.—Шул сүзләрне әйткәч Дамир озак кына дәшми торды. Мин дә нәрсә булса да сорашырга кыймадым. Стенадагы герле сәгатьнең текелдәве генә тынлыкны боза иде. Хужа кеше тагын шешәгә тотынды. Стенадагы сурәткә карап алды. Минем гел тигезеп кенә дигәндәй, эчмичә утыруга иялэнеп алдымы, кыстап бер сүз дә әйтмәде.—Өч тиенлек акыл булмаган, шыр тиле чак иде шул. Үземне әллә кемгә санаган вакыт. Башта—жил, жавапсызлык. Алай гына да түгел, кабахәтлеккә тин азгынлык, хыянәт... Кызлар, янәсе, мине күргәч, шундук ни кушсам шуны эшләргә тиеш. Дөньяга сыймаслык мин-минлек.—Дамир тагын юылмаган стаканына аракы агыза башлады. Кулы бу юлы аны бөтенләй тыңламаслык булып бәргәләнә, калтырый иде. Күзләрен яшь пәрдәсе каплады. Тамагына утырган төер аркасында тавышы калтырый иде сабакташның.—Их, хәзерге акылларым булсамы? Ничек ярата иде ул мине, ничекләр ярата иде.—Ул кабымлыксызнисез генә эчеп куйды да, күзен якындагы керле тастымал белән сөртеп дәвам итте:

—Шулай итеп качтым мин Валентинамнан.

Беренче булып Мөктәсәр абзый килеп житте. «Син нәрсә, малай актыгы, әйтми-нитми эшне, техниканы ташлап качтың»,—ди. Сүгә генә. «Синең аркада рәистән эләкте, менә шул була инде ул—ит яхшылык, күр начарлык»,—ди. Валяны да искә төшерде. Минем районнагы элекке шуклыкларны ишеткән ахрысы. «Әгәр дә мәгәр аңа кагылган булсаң, кара аны, манка, шушында килеп үзем ботарлап ташлыйм, ул сина райпо кибетендәге теге ире ташлаган маржа түгел»,—дип янап чыгып китте. Бераз шөлләп тә куйдым.

Тик, эшләп киткәч, барсы да онытылды. Ике-өч ел гына йөргән яна дип әйтерлек машина, руль артында сызгырып кына барам. Матур гына, үткен генә Тәслия исемле бер кыз белән танышып алдым. Районныкы, почта бүлегендә эшли. Икенче машина, икенче мохит, икенче гыйшык дигәндәй, шундук күнегеп тә киттем. Нәрәстә гүя булмаганмын да сыман. Онытым.

Әмма исемә төшерделәр. Нык итеп.

Ял көне иде. Туйганчы йоклап торганнан соң, ашап-эчкән генә идем, дүртәүләп килеп керделәр: Мөктәсәр абзый, йөз чалымнары күпмедер танышрак тоелган ир белән хатын, һәм иң артта ничектер бөрешеп киткән, йөзенә курку чыккан Валя-Валентина. Шунда ук барысын да аңладым. Әти-әнисе Валяны миңа китергәннәр. Мөктәсәр абзый минем якка көйдерердәй караш ташлады да, эчкәрегә өйгә куып чыгарды. Күпмедер гәпләшкәннән соң мине чакырып чыгардылар. Беренче булып әти сүз башлады, аның да чырае бик кырыс иде. «Нәселдә булмаганны кылангансың, юньсез. Шулай кыз баланы алдап качалармы? Авырлы итеп. Элеккерәк чагым булса, тотып ярган булыр идем инде, бәхетең, хәлем юк. Хатаны төзәтергә кирәк. Бүгеннән син—күзле-башлы. Вәт шул». Әни дә, шуны гына көткән кебек, Валяны кулыннан, аркасыннан алып, түргә, өстәл янына ук китереп утыртты: «Оялма, кызым, хәзер инде синең дә өй бу. Бергә яшәрбез, Алла боерса. Ходай шулай язгандыр». Шул сүзләрдән соң Валентинам беренче тапкыр башын күтәрде. Күзләрендә өмет чаткылары күренеп, миңа карады. Мин әле аптыраудан айнымаган идем, карашымны читкә юнәлттем.

Шулай яшәп киттек без аның белән. Беренче вакытларда мин дә какмадым, сукмадым дигәндәй, ярату булмаса да, язмыш белән килешкәндәй иттем. Белмим, нигә яратмаганмындыр мин аны? Ул чакларда үземнән башка берәрсен яраттым микән? Үземә-үзем хәзер шаккатам. Чибәрлеге дә, буй-сыны да, уңганлыгы да бар иде аның. Үзе бик теләгәч, әни кушкач, мулла чакырып, Валяга Вәсилә исеме кушып никах укыттык. Ашап туйгач амин тотарга да икенче атнада ук өйрәнде. Бераздан әнидән сорап берничә дога да ятлады. Тик җилбәзәк акылым аны барыбер иргемне буучы итеп кабул итте бугай. Янәсе егерме биш тулар-тулмаста көчләп өйләндертте. Үзе, житмәсә, ар кызы. Таныш егетләр жае чыккан саен көлгән булалар, алар шул рәвешле

мин-минлегемә тигән чагында гарьләнәм, үземне тозакка эләккән җанвар сыйфатында күрә идем. Богауладылар. Читлеккә яптылар. Тагын салгалый башладым. Тәслия дигәнем дә, минем хәлләрне каяндыр ишеткән булып чыкты. Тик ни гаҗәп, араны бөтенләй суытып бетермәде. Ул гына да түгел, берсендә, күнелне алгысытып, мут елмаеп, аерсаң үзем чыгам, дип тә ычкындырды. «Яшь чакларны» искә төшереп, теге сатучы хатын янына да сугылгалыйм. Язга таба тәмам сансызландым, кунарга кайтмый калган чаклар да булгалый. Ник бер ачулансын, тавыш чыгарсын шунда Валя-Вәсиләм. Башын иеп бер-ике көн сөйләшми йөри дә, шунын белән тынычлана. Ә әти киресенчә, хәле булмаса да, берсендә, яткан килеш диярлек якадан алып җилтерәтте. «Кемгә охшап мондый адәм имгәге булдың син?»—ди. «Аерам, кире авылларына илтеп куям»,—дип ычкындырган идем, икәүләп тотындылар: «Әшәкелектә йөреп тәмам сукырайгансың, күр әнә, өйләр ничек җыештырылган. Аш пешерсә, ашап туймаслык. Күзенә генә карап тора. Ни җитми соң сиңа?»—дия-дия тетмәне тетәләр. Әни елап та алды. «Улым, яхшылап әйтәм, кимсетмә киленне. Бәхетеңнең кадерен бел. Тәмам үзебезнеке бит, бөтен яклап. Татар кызлары да хәзер кырык төрле. Үкенерсең соныннан. Атаң белән икебезнен дә сәламәтлегебез ташка үлчим, бу балакай караган кебек безне беркем дә карамаячак бит»,—ди.

Мондый «тәрбиядән» соң мин бер ике-өч атнага игә киләм. Валяны юри генә алар күргәндә кочаклаган булам. Ә аңа күп тә кирәкми, бер кочаклап, ике елмайсаң, атналар буе очып кына йөри. Әмма мондый төзәлүләр, әйткәнемчә, һәрчак вакытлы булдылар.

Май башынын җылы көннәре иде. Валянын ике-өч атнадан бәби көтеп йөргән вакытлары. Әти белән әнинен дә дулкынланган чаклары. Миңа гына бер нәрсә дә кирәкми.

Бәби туганчы, дип әтиләренә кайтып киләсе килгәнлеген әйткән иде иртән Валя-Вәсиләм. Мин, азгын, шул хәлдән файдаланып каласы иттем. Кич буе Тәслия белән булган җитмәгән, төнлә аны үзебезгә алып кайттым да, артын-алдын уйламый гына, хатын белән икәү кунгалый торган келәткә алып кердем. Рәхәтен күрәм, имеш.

Ә Валя, ни сәбәп беләндер, кайтып китмәгән булып чыкты. Төн урталары тирәсендә, безнен гыйшык ин кызган мизгелдә, утны яндырып, өстебезгә килеп кермәсенме?! Белгән, сизенгән безнең анда икәнне. Ике күзеннән мөлдерәмә яшь ага. Үзе калтырана. «Дамир, никләр дип шулкадәрле мыскыл итәсен мине? Никләр дип? Минем бердәнбер гаебем сине яратуым икәнен үзен дә беләсен бит. Яратмагач, нигә йөрден соң минем белән, нигә уйнадын? Инде нишлим хәзер, инде нишлим, тиздән балабыз да туарга тора бит». Ул бөгелеп төшеп үкси-үкси елый башлады. Тәслия бар булган кием-салымын эләктереп шыпырт кына чыгып сызган иде инде. Шунда мин сирәк булса да, күнелдә кабынгалап куя торган, тик үзем дә әллә ни ышанмаган шигемне әйтеп салдым: «Кем әйтте соң әле аны минем бала дип? Бар, кайтып кит! Мин Тәслиягә өйләнәм.» Тупас итеп, кычкырып әйттем. Беренче мизгелдә Вәсиләмнең күзләре, бу акылдан шашкан ахрысы дигән кебек, шар булып ачылды. Ул тораташтай катып калды, һәм элеккесеннән дә ныграк үксеп, акрын гына келәттән чыгып китте. «Ваньмыз быремын! Ваньмыз быремын!»[1] Мин, дивана, калган яртыны эчеп бетергәч, Валяны да, Тәслияне дә онытып, урын-җиргә аудым да, йоклап та киткәнмен. Йокы аралаш кына анын: «Тон но мон кадь ик кураджоно мед луод!»[2]—дип ачынып, ярсып әйткән сүзләре колагыма эләгеп калды.

Иртән беренче булып әни чан кага башлады: Вәсилә кая да, Вәсилә кая? Сыерлар, гомер булмаганны, савылмаган килеш көтүгә китте. Мин инде үземчә анлаткан булам: «Кичә ачуланышкан идек, авылларына кайтып китте ул»,—дим. Үзем дә шулайрак фаразлыйм. Келәткә Тәслияне алып кайтканыма аз гына үкенү хисе дә бар сыман. Ярар, мәйтәм, кайтыр әле. Кайтмаса да,

---

[1] Бетте, барысы да бетте!—удмуртча.

[2] Гомерең буе миңа күрсәткән газапларыңда ян, рәхәт күрмә!—удмуртча.

кайгырган юк. Татар кызлары да дөнья тулы. Сызгырсаң, көтүләре белән килеп житәрләр. Шулай ике көн үтте. Василә һаман юк. Мине ике көн буе: «Бар, алып кайт киленне»,—дип үгетләгән әни түзмәгән, Мөктәсәр абзыйның кызы артыннан: «Берүк үпкәләмәсен, кайтсын, кызымнан да якын бит ул мина»,—дип әйтеп жибәргән. Икенче көнне иртән чаба-чаба Мөктәсәр абзый үзе килеп керде: «Валя әти-әнисенә кайтмаган!» Нәрәстән качканнан бирле, башлы-күзле килеш булып та, хатын-кызлар белән чуалганнарымны да ишеткәннән соң, мин жилбәзәкне кешегә санап бетермәгәнлектәндер инде, минем белән рәтләп сөйләшеп тә тормады: «Давай эзлә, тап, теләсәң нишлә, иманың бераз калган булса»,—дип кычкырды да, чыгып китте.

Ә мин, аны-моны уйламый гына эшкә киттем. Янәсе, кая булсын ул, кайтыр әле.

Кайтуыма, барысы да билгеле иде инде. Валя-Василәмнең үле гәүдәсен Яссытамак авылы көтүчеләре Кандырсу буасыннан тартып чыгарганнар. Нәрәстән килеп сыер савып йөрүчеләр таныганнан соң, жәсәден ат арбасына салып туган авылына алып кайтып киткәннәр. Шул хәбәрне ишеткәч кенә мин үз гамәлләремә күпмедер бәя бирерлек, үз явызлыкларымны аңларлык хәлгә килдем. Әмма соң иде инде. Мин вак, чуар жан, женазага барсам да, хәсрәттән ушымны югалтасы урында, юл буе болар мине мәетне күмгәч, тотып имгәткәнче тукмарлар, йә бәреп үтереп икебезне бер кабергә салырлар дип шөлләп бардым. Чөнки кемлегемне инде барысы да беләләр иде. Әмма юк, минем белән вакланучы булмады. Минем якка хәтта күтәрелеп тә карамадылар. Гүя мин—буш урын, анда бөтенләй юк. Шулай жирләдек без Валентинаны.

Әти бу хәлләрдән соң минем белән бөтенләй сөйләшмәс булды. Олы кеше хурлыкны бик кыен кичерә, диләр. Василәнең вафатыннан ике ай үттеме-юкмы, яткан жиреннән тыныч кына ул да китеп барды. Әниnең дә элекке көләч йөзе килене үлгәннән соң ук караңгыланып, мөлаемлелеге бөтенләй беткән иде. Минем белән сөйләшкәләсә дә, әти китеп баргач, бөрешеп, кечерәеп калды, кибекте бичара. Шул ук елны, бәрәңгеләрне алып бетереп базга салып куйгач, көтмәгәндә башына кан савып, ул да якты дөнья белән бәхилләште. Василәгә бик сөенеп, картлык көнендә килен рәхәте күрәм, үндым дип йөргән иде, булмады.

Кышка Тәслияне алып кайттым. Ул вакытларда ныклап сала башлаган идем инде. Дөресрәге, янадан районда эшли башлаганнан бирле, әле Валя исән чагында да туктау булмады төсле. Яңадан өйләнгәч, янә аз гына басылып тордым да, тагын иске гадәткә керештем. Тыелып булмый башлады. Василә белән бергә менә туам дип торган сабыемның гына түгел, әти-әниемнең үлеме сәбәпчесе дә мин идем бит. Соңга калып булса да, ниһаять, шуларны аңлый башладым. Үземә урын таба алмый йөрим-йөрим дә, тизрәк кибеткә керәм. Яңа хатын тиешлемнең холкында иплелек белән сабырлыкның эзе дә юк. Көн саен дигәндәй талаш та сугыш. Авыр мина дип аңлатып та карыйм, аңламый. Син ялкау да син алкаш. Бар белгәне, сораганы—акча. Мин дә алтын түгел, кәнишне. Кыскасы, шуны аңладым, Василәмнең кисеп ташлаган тырнагына да тормый бит бу. Кар өстендә йоклап кулсыз калгач, мин бүлнистә вакытта ук, өйдә нинди рәтле нәрсә бар, барысын да төяп аналарына кайтып киткән минем келәтләрдә куныл йөргән хатын дигәнем. Шуннан миндә өйләнү теләге дә сүнде. Әчкече белән кем яшәсен?! Аннан соң, шунысы да бар, хәзер авылда миннән рәтлерәк егетләргә дә көндез чыра яндырып эзләсәң дә өйләнер кеше юк. Илледән узганнар белән пенсионерлар гына. Аларына да айнык ир кирәк. Яшьләрне исә бәйләп тә авылда тота алмыйсың. Мәктәпне бетерә торалар, кача торалар. Ә мин менә шушы сурәткә карап яшим хәзер. Акыл да, сөю-мәхәббәт тә бик соңга калып килделәр мин адәм актыгына.

Менә, сыйныфташ, хәлләр шундый минем. Шушы стенадагы сурәт кенә минем бу дөньядагы бар юанычым.

Дөньясы да хәзер гел әллә нәрсә. Бер мин генә дә түгел, авылда биш-алтыдан артты бугай инде миндәй имгәкләр. Үлгәннәре урынына яшьрәкләр

килә тора. Кимемибез, арта гына торабыз. Ялланып юк-бар эш эшләп, шунын акчасын шушы зәхмәт суына алыштырып, эш булмаганда урлашып, тагын эчеп, янадан кайчан да булса кеше рәтенә кайтудан да уздык ахрысы. Мин үзем соңгы көнем житкәнне көтеп йөрим менә. Кайчан житәр? Ике атна элек, кача-поса гына, Василәмнең каберенә барып тезләнеп бер туйганчы елап та кайттым. Гафу үтендем. Хушлаштым. Әгәр дә мәгәр, теге дөнья булып, аны анда очратсам, кабул итмәячәк ул мине, кабул итмәячәк.—Соңгы сүзләрен Дамир көчкә-көчкә әйтеп бетерә алды.Ул калтырана- калтырана, сүзләренә буыла-буыла үкси иде. Мин аны тыймадым. Үзем дә бик тәэсирләнгән идем. Бераздан ул тынычланды. Стаканындагы соңгы аракысын эчеп бетерде. Яшьле күзләрен миңа төбәп сорады:

—Яшьти, бар микән ул теге дөнья дигәннәре, ә? Син укыган кеше бит, беләсеңдер. Әгәр булса, бер икеләнми китәр идем. Валя-Василәмне бер генә булса да күрер, күзләренә карап: мин дә сине яраттым бит, жаным, кичер, дияр идем.

Мин сыйныфташымның соравына, табигый инде, кистереп жавап бирә алмадым. Академиклар да белеп бетерми, әллә бар, әллә юк дигән төслерәк сөйләнгәндәй иттем. Стенага борчак сибү генә икәнен белсәм дә, бүтән эчмә инде, врачларга барып кара, дигән гомуми, нәтижәсез үгет-нәсихәтләр бирдем. Шәһәргә, инвалидлар жәмгыятенә барып берәр эш сорарга киңәш иттем.

Дамир мине тыңлагандай утырса да, күңеле белән кайдадыр еракта, үткән көннәрендә, Василәсе янында иде бугай. Бер жавап та бирмәде.

Ул мине озата чыкты.

—Гаепләмә инде, кемгәдер сөйләп бер тәүбәгә киләсе, бушанасы килгән иде. Бу бер истигъфар, урысча әйткәндә исповедь булды инде. Бөтенләй онытып бетермә инде, бер парта артында утырдык бит, яшьти,—дип капкасын ябып калды ул. Мин кайтып киттем.

Татарның акылы төштән соң, дигәндәй, юл буе нигә соң шунда бераз ачуланмадым үзен, нигә үтемлерәк үгет-нәсихәт бирмәдем, дип үземне битәрләп кайттым. Әллә кая, төпкә үк төшеп, мондый хәлләргә заманмы, әллә соң кеше үзе гаепле ме, дигән сорауга жавап эзләдем.

Ә кичкә таба, өйдәге мәңге бетмәс вак-төяк мәшәкать аркасында барысы да онытылган иде инде.

Икенче көнне, төштән соң, шәһәргә китәргә генә жыенып йөри идек, күрше Заһит килеп керде.

—Әхтәм, ишеттеңме, Ташлыктагы синең сыйныфташың Дамир асылынып үлгән бит,—ди. Кулымнан машинага куясы сумкам төшеп китте. Каттым да калдым. Әле яңа гына, юл уңаена сугылып, шәһәребезнең наркология бүлегенә алып китимме әллә үзен дип уйлап тора идем. Бу юлы да соңга калдым. Бөтенләйгә соңга калганымны аңладым.

Әллә ни гомер жаныма тынычлык кермәде. Заманны, Дамирнын үзен, язмышны ни өчендер битәрли алмадым. Сабакташым үлемендә мин, мин үзем гаепле төсле идем. Аны тыңлап утырмаган булсам, башкачарак булган булыр иде бит. Чарасыз булуым белән гаепле идем мин.Үткәннәрендә казынып минем алда күңелен бушатмаган, елый-елый тәүбәгә килмәгән булса, ул әле яшәр иде. Нигә бардым мин анда, ник аны тыңладым?



## Миңнеруй

### Беренче кар

Күңелләргә кинәт килгән ак уй сыман
Җир өсләрен йомшак кына ак кар кочкан.
Эрер инде, эреп бетәр, китәр инде.
Җылы күз дә көчле икән ап-ак кыштан.

Күңелләргә кинәт килгән ак уй сыман
Җир өсләрен йомшак итеп ак кар кочкан.
Артык нәфис, артык нәзек, артык матур.
Эрер инде, уйдык-уйдык куенын ачкан.

Нәфис-сылу гүзәлкәйнең шәле сыман
Яшәештән мәңгелек бер җылы алган.
Салкыннарның иң беренче зәһәреннән
Саклар өчен, талган җирне төреп салган.

Беренче кар, беренче саф мәхәббәттәй,
Бу дөньяга пакьлек бирә, аклык бирә...
Җиркәенең кайнап торган хисләреннән
Әнә инде эреп килә, эреп килә.

### Шигърият

Сагышларымны тарата,
Кайгыларымны агарта,
Дусларымны яклаштыра,
Дошманымны яраттыра
Шигърият!

Шатлыкларымны күбәйтә,
Күңелләремне киңәйтә,
Йөзләремне нурлы итә,
Сөйгәнемә тугры итә
Шигърият!

Хисләремне сөйләттерә,
Тормышымны көйләттерә,
Биеклекләргә күтәрә,
Зур бәхетләргә этәрә
Шигърият!

Миңнеруй (ГАЙФУЛЛИНА—ХӘБИБУЛЛИНА)—*шагыйрә; «Күңел чишмәсе», «Кешеләргә әле кирәк мин» исемле китаплар авторы. Аксубайда яши.*

## Кыл ашалган

Кыл өстендә гомер тора...,
Кыл ашалган.
Нинди көчләр, нинди дога
Тотып калган?!

Бик нечкәдер,тиз ертыла
Аурасы да.
Авыр бара тормышының
Арбасы да.

Хәле киткән, юк-бар җил дә
Җәберлидер.
Пыскый җаны,соң сулышы
Кадерледер.

Кыл өстендә гомер тора...
Кыл ашалган.
Нинди көчләр, нинди дога
Тотып калган?!

## Йолдызнамә

Нинди җисем, нинди йолдыз
Иртәгемә салкын юрый?
Мин бүген үк инде ялгыз,
Җан гөлләрем әнә корый.

Кайсы җисем үпкәләгән,
Ник битараф язмышыма?
Кемнәр нилләр түләмәгән
Йолдызларның ялгышына?

Йолдызнамә—адашудан
Саклар өчен язмыш юрый...
Ә йөрәгем—алдакчыдан
Яклаучыга дога юллый.

***

Язмыш читтә яшәтсә дә,
Тамырлар туган якта.
Кайтып күреп килим әле
Сау, таза, исән чакта.

***

Кичке эңгер йотты бугай
Барлык сагышларымны.
Күркәм җанлы итеп күрәм
Барлык танышларымны.

***

Күпер чыктым, ерак киттем,
Каерылып карадым.
Эзләремне саклый белгән
Сукмагымны барладым.

Мөхәммәт
Мирза

# УЗЫП БАРЫШЛЫЙ

## I

Авыл...

Кызу эш өстендә эшләгән кешеләргә комачау итүдән гайре сез нәрсә үзгәртә аласыз соң? Басу, ферма карап кына тормышны өйрәнеп булмый, анда яшәргә, авыл кешесе кичергәнне үз күңелең, акылың аша үткәрергә кирәк... Авылны талап бетерделәр... Сез йөреп кенә ул мантымас... Авыл—инде авылда яшәүчеләрнең үзләренә дә кирәк түгел... Олысы-кечесе, хатыны-ире аракы белән дуслашкан... Авыл кешесе урлашуга күчкән... һәм башка, һәм башка сүзләрне ишеттек без авылларга сәфәр чыгар алдыннан...

Утсыз төтен чыкмый дигәндәй, әле генә әйтелгәннәргә дучар булган авылларны да, һәм киресенчә, яшәргә йөз тоткан авылларны да күреп була анысы. Иң аянычлысы, әлбәттә, эчүчелек, урлашу кебек яман чир үтеп керүедер...

Авылда һичбер ни сәбәпсез генә булмый...

Авыл һәр үзгәрешкә һәрчак бик сак карый...

Бигрәк тә кемдер кайдандыр килеп, нәрсәнедер ничеккә үзгәртә дигән хәбәр-фаразларга авыл бик сак карый. Чөнки борын-борыннан килгән утрак яшәү рәвешенең бер төре буларак, авыл үзгәрешләрне дә табигый рәвештә, акрынлап кына кертә...

«Авыл тормышын үзгәртү» дигән сүзләр, гомумән, коммунистлар гыйбарәсе... Әвәл сүз галиҗәнап Җир турында барган. Беркем дә «Авыл реформасы» димәгән, «Җир реформасы» дигән. Җиргә карата, җир биләүчелеккә карата үткәрелгән үзгәреш-реформалардан чыгып авылдагы үзгәрешләр үзләре барлыкка килгән...

Җир—авыл кешесен үзенә мәңгелеккә беркетеп куйган да... Авыл кешесен генә түгел—бөтен илне-дәүләтне үзенә бәйләгән Җир!..

Җир реформаларының асылында авыл кешесенең социаль-көнкүрешен кайгыртудан бигрәк табыш алу мәсьәләсе торган...

Бар да шул тәртиптә корылган, хәл ителгән... Авыл кешесе—крестьянның тормышын көйләү генә авыл кешесенең-крестьянның үз карамагына калган... Тормышын көйләү дигәннән—аны стимуллаштыру да нәкъ менә Җир белән хәл ителгән... Крестьянның гаиләсенә, андагы ир-атларның санына карап, төп байлыгының биләмәсе—Имана Җире бүлеп бирелгән. Икмәк-иген кырын гына түгел, ә печән-болынлыкларны да һәр йорт-гаиләгә эшче кулына карап бүлгәннәр. Ә калган җирләр—алпавыт һәм дәүләт җирләре... Баксаң—Җир хуҗасыз булмаган... Хәтта иксез-чиксез җирләре булган Рәсәйдә дә Җирнең һәр дисәтинәсе исәптә булган һәм аның хакы-бәясе крестьян өчен үз җанына бәрабәр...

Рәсәйне реформалар иле дип йөртәләр. 1861 елгы Җир реформасы крепостнойлыкны рәсми бетерсә дә, империя дәүләтендә Җир һәм Эшче Куллар проблемасы кала биргән...

XX гасыр башында Столыпин үткәргән Җир реформасы бик тә баетасы булган икән дә дәүләтне... реформаторның үзенә һөҗүм ясап аны үтерү. Беренче бөтендөнья сугышы һәм большевиклар революциясе бу реформаны

бөтенләйгә көн тәртибеннән алып ташлаган...

Совет дәүләтенең коллективлаштыру реформасы—Җирнең чын хуҗаларын физик яктан юк итү һәм аларның җирләрен тартып алуга корылган канлы реформа—җитмеш ел дәвамында барыбер дә мантып китә алмыйча, планетаның алтыдан бер өлешен алып торган реформалар илендә тагын да өр-яңа реформа башлауга сәбәп булды... Әлбәттә, бу реформа өчен алшарт булып котылгысыз рәвештә коммунистик идеология һәм системаның банкротка чыгуы торды.

Инде яңа реформаның төсе-асылы нинди? Бу реформа Җирнең хуҗасызлыгы һәм Эшче Кулларның җирдән тулысынча читләштерелүе шартларында башланды... Бу реформа идарә ителәме, әллә үз агымына куеламы?

Идарә ителә дип уйлыйк... һәм үз агымына куелган дигәне дә хак... Үз агымына куелган дигән җөмләдән, бүгенге йөзмеңнәрчә авыл кешеләренең бу «билгесез реформа»ның асылына төшенмичә, бу реформаны гамәлгә ашыруга чын-чынлап катнаша алмыйча якты дөньядан китеп баруларын да аңлау кирәктер... Шулай, кайчандыр үз бабаларының иманаларын берләштереп, ахырда юкка чыгарган дәүләткә бер дәгъвасыз якты дөньяны ташлап китеп, алар Җирнең яңа хуҗаларына үзләренең өлешенә тияр көмешләрен дә биреп калдырдылар... Бу хакта бәлкем аерым фикерләү сораладыр. Әйтик, матбугатта «Илдәге җир реформаларының әхлакый үзенчәлекләре» дигән рубрика ачу кирәктер... Бу хакта каләм ияләре әле үзләренең фикере-касыйрларын җиткерер дип уйлыйк...

Шунысы бәхәссез, һәр реформаның язмышын күпмедер вакыттан соң барыбер дә әхлакый күзәнәге, асылы хәл итә...

Әйтелгәнчә, яңа реформа авыл кешесе—Эшче Кулының үз-үзеннән бигрәк шул күмәк хуҗалыкларга ышанычы бетеп барган, дәүләтнең шул күмәк хуҗалыкларның бетмәс-төкәнмәс ихтыяҗлары-сорауларыннан гарык булган шартларда башланды һәм менә дистә елдан артык дәвам итә...

Идарә ителә дигәнебез—дәүләтнең, хөкүмәтнең авылга инвесторлар җәлеп итеп, Җирнең яңа хуҗаларын булдыруга йөз тоту икәнлеген әйтү кирәктер... Дәүләт үзенең кредитларын да илне азык-төлек белән тәэмин итәргә ышандырган һәм иң мөһиме биргәнен артыгы белән кайтарып алырдай кулларга бирергә тырыша...Бу табигыйдыр. Шулай кирәктер дә... Инвестор—Җирне эшкәртүче һәм табыш алучы яңа хуҗа... Җитештерүче... Дәүләт белән җитештерүче арасындагы мөнәсәбәтләрне банклар һәм арбитраж судлар көйли бугай... Шулай итеп, һәр авыл кешесе үзал җир алып тернәкләнеп китә алмаса (киталмасы язып куелган) моңарчы «Эшче Кул» дип йөртелгән авыл кешесе үз тормышын көйләү өчен яңа җитештерүчегә ярарга-яраклашырга тиеш... Дөнья куласа, әйләнеп бер баса...

## II

«Тормышны өйрәнү өчен урып-җыю чорында язучының авылга баруының хаҗәте юк!»—диючеләр хаклымы-түгелме, әйтә алмыйм... Бу Язучылар берлеге рәисе белән Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрының ниндидер «сыр чыгаруы» гына түгел, ә язучыларның үзләренең эчке бер теләге, ихтыяҗы иде... Баксаң, авыл кешесе дә үз язучысын инде көтә-көтә зарыгып беткән... Инде тере язучылар белән соңгы кат кайчан күзгә-күз карашып очрашканын оныткан авыл кешесе—татар язучысының төп китап укучысы—очрашканда бик азга гына югалып калса да, юк, ул әле үз язучысыннан бизмәгән икән, ул аңа бер әхлакый күренеш дип карый... Теле белән барын да әйтмәсә дә, аңа төбәлгән карашында күңелендәге дистәләгән сорауларын юнәлтә... Ул карашлардан, «Сез кайда югалдыгыз соң?.. Без кемгә ышанырга тиеш соң?.. Без ничек тә яшәдек, ә безнең балаларыбызны ни көтә?.. Милләтебез, телебез, мәдәниятебезнең иртәгәсе ничек?»—дигән сорауларны укып була...

Кызу эш өстендә дигән җөмләбез хакыйкатькә ни кадәр тәңгәл килә?.. Чыннан да без бүген югарыда куелган сорауларга җавап эзләп кайтабыз икән туган авылларыбызга... Нәкъ менә кызу эш өстендә бу сорау аеруча бимазалый икән бит безне... Сорауларга җавапны без дә бирергә тиештер... Җавап бирү өчен үз күзләрең белән күрү кирәк, тотып карау кирәк... Суга кермичә генә йөзәргә өйрәнеп булмый...

...Мең проблемасы булган татар авылын, болай карап торышка, бер дә проблемалы дип уйламыйсың... Карагыз әле, күрегез, чагыштырыгыз... Каралты-куралар төзек, биек түбәле янкормалы яңадан-яңа йортлар... Койма-капкалар төзек, буялганнар, һәр ихатада диярлек гараж, мал-туар каралтылары... Ике бакча: җиләк-җимеш, яшелчә һәм бәрәңге бакчалары. Умарталар күренә... Һәр йортка газ кергән... Һәр авылда берничә кибет, мәктәп, балалар бакчасы, Мәдәният йорты, китапханәләр... Капка турларында, бакча артларында көпчәкле һәм чылбырлы тракторлар, башка авыл хуҗалыгы техникасы күренә...

Берни үзгәрмәгән кебек, элеккечә үк, авыл яннарында машина-трактор парклары да, күмәк хуҗалыкның терлек торалары да үз урынында...

Мондый күренеш башлыча «җирле үзидарә урнашкан, элеккечә әйтсәк, колхоз үзәге булган, соңгы 30-40 елда үзенең тирә-ягындагы авылларны берәмберәм йоткан зур авылларда шулай... Таза-мул тормышта яшиләр кебек... Яңа йортлар арасында, анда-санда утырып калган өлкән яшьтәге әби-бабайларның каралты-куралары да йөзен бозып тормый ул авылларның... Барып күрегез Әлдермешне, Чыбыклыны, Шәмәрдәнне, Пучыны, Байсарны, Карамалыны, Карадуганны, Черки Килдуразны, Тәкәнешне, Олыязны, Сатышны, Шәлене һәм башка дистәләрчә авылларны...

Ә теге, үзәктән читтәге авыллар чыннан да читкәрәк тибәрелгән зур каз оясы гаиләсенең зәгыйфьрәк бәбкәсе кебек аерылып торалар... Һәм, ни кызганыч, аларның киләчәгенә өмет кими... Чөнки ул авылларда «Эшче Кул» өчен иң кирәкле эш урыны—кибет, медпункт, мәктәп, китапханәләр инде ябыла... Дәүләт һәм муниципаль район хакимиятләре ул авылларда эш урыннары, социаль структуралар булдырудан бигрәк аларны әлеге хәлле үзәкләргә күчерүне отышлырак күрәләр.

«Бүген авыл бетә»,—дип чаң сугуларның тамырлары шунда... Һәм ни кызганыч, андый авыллар саны да дистәләрчә, йөзләрчә... Әйе, авылның тышкы кыяфәте бер дә начар түгел... Бу безнең халыкның, беренчедән, кан булса да түкермәвеннән һәм, икенчедән, шул хәлдә дә өметен сүндереп бетермичә яшәргә тырышуыннан... Авыл кешесенең өмете һаман да үзен күп мәртәбәләр кәкре каенга терәгән дәүләттә, хакимият җитәкчеләрендә...

Дөресен әйтим, без авылларга барганчы ук «инвесторлар» дигән яңа җитештерүчеләргә билгеле бер дәрәҗәдә каш астыннан карый идек... Безне, шәхсән, минем үземне, инвесторның йөзләрчә мең гектар чәчүлек җирен берләштереп (йөзләрчә мең авыл кешесен түгел, ә чәчүлек җирен... аларга да җир мәйданы беренчел әһәмияткә ия) халыкны тиешенчә эш белән тәэмин итеп, хезмәт хакын айлар буе түләмәве чын-чынлап аңа карата нәфрәт хисләре уяткан иде.

Нурлатка килеп төшүгә, минем юлдашларымның бу уңайдан куйган сорауларына Фатыйх Сибагатуллинның катлы-катлы, берсеннән-берсе саллырак җавапларын ишетергә туры килде.

—Авыл кешесе инвесторга, йә аның агрофирмасына гына карап торырга тиешме? Хезмәт хакын айдан айга бирмиләр,—дисез... Инвесторга иң шәп механизатор, иң шәп терлекче кирәк... Техникасын бирә, җайланмасын куя... Вакытында хезмәт хакын бирә. Авылда бөтен кешене бер инвестор эшле итеп бетерә алмый. Бу элек тә булмаган, киләчәктә дә булмаячак. Аларны сезонына карап төрле эшкә тарткан өчен тиешле 2-3 меңне ай саен бирсәң ни дә, елга ике тапкыр җыеп бирсән ни? Авыл кешесе үзенә эшне үз хуҗалыгында табарга тиеш. Гаиләдә әрәмтамак булырга тиеш түгел. Бер мөгезле эре терлектән 20-25 мең табыш алып була. Һәр гаилә кимендә 4-5 баш эре терлек асрый ала, асрарга тиеш... Бу фәкать—сатып акча кертү өчен... Икенчедән—авыл кешесе һәммәсе азык-төлек белән үз гаиләсен үзе тәэмин итәргә тиеш. Моның өчен дә мөмкинлек бар...

Авыл кешесе өчен бердәнбер чыганак аның пай җире. Йә үзе шунда көнтөн эшләп көн күрә... Йә инвесторга арендага бирә... Соңгысы аңа әҗерен намус белән түләргә тиеш...

«Вамин»ның Аксубай районындагы «Аксу» агрофирмасы генераль директоры Камил Латыйпов белән сөйләшкәндә Фатыйх Сибагатуллинның әйткәннәренә ачык мисал да табылды кебек.

—Сез—генераль директор. «Вамин» белән нинди шартларда хезмәт итәсез?

—Ел саен контракт төзелә. Ул яңартыла. Безнең агрофирмага 33 мең гектар җир беркетелде. Без нигездә сөтчелек белән шөгыльләнәчәкбез. Өр-яңа торак комплекслары төзелде. Монда бары тик Германиядән кайткан токымлы сыерлар... Аларны шушында ук күпләп үрчетү чаралары күрелә. Комплекста 40 кеше хезмәт куячак.

—Эшче куллар күпме, аларның хезмәте ничек оештырыла?

— Алар белән хезмәт килешүен мин төзим, барысы 1100 кеше. Шуларның 400е белән килешү—11 айга, 700е белән—4 айга.

—33 мең гектар мәйданда авыл кешеләренең пай җирләре бармы?

—Әлбәттә, бар, без ул җирләрне арендага алган тәртиптә ашлык һәм терлек азыгы белән түлибез.

Күренгәнчә, инвестор авылга хезмәт куяр өчен килгән... Ә 700 кешене ул 4 ай гына хезмәткә тарта, калган 240 көнен авыл кешесе ничек үткәрергә тиеш?..

Бу мәсьәлә Аксубайда да, Нурлатта да, башка төбәкләрдә дә әлегәчә ачык кала... Фатыйх Сибагатуллин—җир кешесе... Бүген Нурлат районы тулаем игенчелек полигонына әверелгән дисәк тә була... Район җитәкчесе—райондагы җирләрнең чын хуҗасы, дөньядагы иң алдынгы технологияләр, казанышлардан хәбәрдар. Россия һәм Белоруссия заводларында эшләп чыгарылган өр-яңа трактор-комбайннар иң элек Нурлат районы басуларында сынау үтә, Россия һәм БДБ илләренең орлыкчылык лабораторияләрендәге яңа орлыклар да киләчәккә фатиханы Нурлат Фатыйхыннан алалар... Ул авыл халкын ничек тә җиргә беркетергә тели... Ул—хәтта районда үзе яшь җитәкче кадрлар һәм җир белгечләре укытып, XXI гасырның чын җир хуҗаларын әзерләү турында хыяллана. Фатыйх Сибагатуллинны шул урында калдырып торып, Актаныш районының Аеш авылындагы хәлләргә тукталыйк әле...

Аеш авылы элек Ленин исемендәге колхозның бер бригадасы иде... Колхоз тәмам таякка калгач, бүленеп Аеш үзал кумәк хуҗалыгы булып оешты. Аны электән районның баш агрономы булып эшләгән Дамир Җәлилов җитәкли башлады. Менә шушы булдыклы егет аякка бастырды бит авылны. Иң авыр дигән 90 нчы елларда да биредә һәркем эшле булды һәм айдан-айга хезмәт хакы алды... Сере нидә? Әлбәттә, җитәкченең авыл кешесен бер көн дә эшсез тотмавында... Ул аларның шәхси тормыш-көнкүрешен хуҗалыгының гомуми эшләре белән тыгыз бәйләп алып бара. Җирнең чын хуҗасы да ул... Әйтик, авылда чәчүлек җирләре, болынлыклар, көтүлекләр, шәхси хуҗалык җирләре бар... Болынлык җирләре әрәм-шәрәм ителмәсен өчен, башта һәр елны җирәбә тәртибендә һәр йортка печәнлекләр бүлеп бирелә. Бер атна вакыт эчендә печән хәзерләү билгеләнә... Авыл кешесе печәнен чабып өеп куюга, кумәк хуҗалык трактор-машиналары белән аларны ихаталарга ташу атналыгы билгеләнә. Шулай итеп, ике йөз хуҗалыклы авыл 2-3 атнада печән хәзерләү дигән бик тә мәшәкатьле эшне борчылуларсыз, имгәнүләрсез генә хәл итеп куя... Шәхси бакчаларны сөрү дә көзен-язын шул тәртиптә алып барыла...

Җир пайлары бүлеп бирелгәч тә, бу авылда беркем дә үзал аерылып фермер булырга ашыкмый. Хуҗалык менә ничә еллар инде беркайдан бернинди кредит-ссуда алмый. Аның беркемгә бернинди бурычы юк. Яңа техника, җайланмалар алырга да, маллар өчен тораклар төзергә дә үз акчалары җитә. Хуҗалык барлык күрсәткечләр буенча районда алдынгы урында бара.

Дамир Җәлилов һәркемгә пай җире өчен икмәген, фуражын һәм акчалата әҗерен түли... Бүген хуҗалыкта эшләүчеләрнең уртача айлык эш хакы 5500-6000 сум.

Баксаң, Аеш крестьяннар берләшмәсе нәкъ совет чорындагы колхозлар тәртибендә хуҗалык итә һәм нәтиҗәсеннән һәркем канәгать. Авылда бөтен социаль-көнкүреш структуралары гамәлдә... Заманча мәктәп бинасы сафка басты. Хәзерге көндә Мәдәният йорты һәм китапханәгә фундамент салалар...

Фатыйх Сибагатуллин безгә инвесторларның бик «әйбәт» икәннәрен аңлатуын дәвам итә:

—Алар кирәк, әмма бөтен бер районны бер инвестор кулына тапшырырга ярамый. Бездә алар җидәү... Мин һәркайсы белән аяк терәп, Җиргә чын хуҗа булып сөйләшәм һәм таләпләремне куям... Алар бер-берсе белән ярыша-ярыша байыйлар... Алар баеган саен салымнары үсә, район казнасына керә... Ә мин аларны шул ук авыл кешеләренә кайтарам....

Бөтен бер районны баш-аягы белән бер инвесторга бирмәгән район хуҗалыкларына чыннан да сайлап алу мөмкинлекләре, ялгышны төзәтү мөмкинлекләре күбрәк кала...

Зәй районының «Зәй шикәре» агрофирмасының төп инвесторы булып Зәй шикәр заводы алынган. Бу агрофирмага янәшә колхозлар да кереп, 17 мең гектар чәчүлек җирендә иң алдынгы технология һәм заманча техника-җайланмалар ярдәмендә ашлык һәм шикәр чөгендере игелә... Авыл кешеләре эш белән тәэмин ителгән, пай җирләренә ашлык, терлек азыгы һәм акчалата түләнә... Хәтта агрофирмага берләшкән авыллардагы бюджет сферасында эшләүчеләргә дә ай саен 500 сум күләмендә акча түләп киләләр...

«Инвестор баер да, җирдән аласын алгач, китеп барыр!»—дигән фаразларны да күп ишетергә туры килгән иде. Кайда ничек булыр, әйтә алмыйм. Ә менә Зәй шикәр заводының агрофирмасы бу авылларны ташлап китәргә җыенмый кебек. Механикалаштырылган өр-яңа ашлык кабул итү һәм эшкәртү цехы (заводы дисәң дә була), меңнәрчә башка исәпләнгән терлек тораклары төзелгән... Дистәләрчә куәтле җир эшкәртү техникасы сатып алынган. Авыл араларында өр-яңадан асфальт юллар төзелгән... Авылларга берничә чакрымнан торбалар аша чишмә сулары китерелә... Беренче карашка бары да элеккечә кебек... Ә чынында яңача, барыбер яңача бит!

Баксаң, инвестиция кертүнең дә төрле формалары һәм төрләре бар икән. Тукай районының «Шильна» крестьяннар берләшмәсе, мәсәлән, үзе турыдантуры банклар белән кредит алып эшли... Кредитны берләшмә җитәкчесе үз исеменә ала. Шул акчадан трактор-комбайннар, автомашиналар, ашламалар, ягулык-майлау материаллары сатып ала, хезмәт хакын түли. Җитештергән байлыгын кредитны түләү өчен дә, җитештерүне киңәйтү өчен дә тота... Бу да нәкъ элеккечә... Яңалыгы шунда—алган кредитны түләми калдырып булмый... Кредит алганда хуҗалык җитәкчесе үзенең һәм хуҗалыгының байлыгын «залогка» салып тора... Бурычын айдан-айга ала тора, түли тора.... «Шильна»да ишетеп-күргән һәм гаҗәпкә калдырганы тагы да шул булды—биредә авыл кешеләре үзләренең пай җирләрен сатып җибәрә алалар... Авылларының, дөресрәге, басу җирләренең, пай җирләренең Чаллыга терәлеп торуын исәпкә алсак, монда гаҗәпләнерлек урын юк... Олы яшьтәге пенсионерлар үзләренең пай җирен шәһәр кешесенә йорт салу яки дача кору өчен сата икән, бу аның өлешенә тигән көмешен үзенә файдалануы дип аңларга кала...

Пай җире—үзгәртеп коруның үзенчәлекле бер ваучеры... Ваучерны адәм балалары акцияләргә әйләндерде дә төрледән-төрле фондларга һәм акционерлык җәмгыятьләренә тапшырып дивиденд—табыш көтә башлады. Ул акцияләрнең ни-нәрсә икәненә төшенмәгән ил гыйбадының күбесе аны «МММ» кебек шулерларга бүләк итеп бирде... Мавродийны әлегәчә тәүбә иттерә алмадылар... Авыл кешеләре «үзеңнеке үзеңә якын» дип акцияләрен «Алтын башак»ка тапшырды... Дистә ярым ел дәвамында «Алтын башак» кемгә дә булса 6 тиен бирә алдымы икән... Кемдер алгандыр, бәлки, мин үзем, мәсәлән, Актанышта торганда да һәм менә Казанда 7 ел дәвамында «Алтын башак»тан бер тиен әҗер алганым булмады... Хатыным ел саен «Татнефть»тән дивидендларын алганда мине үрти: «Безнеке «Кара алтын» гына булгач, түли, сезнеке «Сары алтын» булгач, түләми»,—ди...

Бүгенге реформа шартларында «Алтын башак»ның мавродийлары ни уйлый икән?.. Алар, миңа калса, чүл-далада хәлсезләнгән җәнлек-терлеген сагалап йөргән шакаллар кебек, олы яшьтәге йөзләрчә мең авыл кешеләренең пай җирләренә карап торалардыр... Таралып барган хуҗалыклар, авылларны күреп шатлана-сөенәләрдер... Алар нәкъ шундый хуҗалыкларда җитәкче булып, көн үтсенгә яшәп яталардыр кебек...

Минем туганнарым яшәгән авылга, мәсәлән, берникди дә инвестор килмәгән... Анда нәкъ элеккечә яшәп яталар... Күмәк хуҗалык үзенең «елга» исемен нинидер «агач» исеменә генә алыштырган... Аның җитәкчесе авыл кешесенә пай җирләре өчен ни ашлык белән, ни терлек азыгы белән түләргә җыенмый... Дистәләгән ирләр эшсез-ашсыз булып, киләчәккә өметләрен җуеп баралар. Авылның коты югала... Шуларны күреп һәм башкаларга күрсәтер өчен дә авылларга чыгарга тиештер язучы...

## III

Татарстан Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министры Марат әфәнде Әхмәтов җаны-тәне белән үз эшенә бирелгән, энергиясе ташып торган, булдыклы, акыллы җитәкче... Аның бүгенге авылларыбыз тормышын бөтен нечкәлекләренә кадәр белүе, бөтен Рәсәй күләмендә авылга булган вәзгыятьне тамырдан үзгәртергә теләве һәм шул шартларда да республикабыз авылларын саклап калу, алай гына түгел, гөлбакча итеп үзгәртүгә аның нигезле ышанычы булуы язучыларда аңарга карата олы ихтирам уятты. Ул бу яктан караганда Илбашыбыз Минтимер ага Шәймиевнең чын-чынлап фикердәше, теләктәше генә түгел, хезмәттәше, аның уң кулы да.

Аның белән очрашудагы сораулар һәм җавапларның кайберләренә тукталыйк:

— Министр әфәнде! Безнең республикада бер гектар җир дә тик ятмый, бары да эшкәртелә, дисез... Болай итеп без җирнең ашын бетермибезме? Чит өлкәләрдә меңнәрчә гектар җирләр эшкәртелми. Бәлки ул җирләр түл җыядыр...

—Ялгыш фикер. Җир хәтта чәчелмәсә дә эшкәртелергә, ашланырга тиеш. Чәчелмәсә, эшкәртелмәсә анда чүп-үлән үсә... Җирнең ашын үлән ашый.

— Ни өчен фермерлар турында җәелеп сөйләмисез?.. Җитәкчелек өчен фермерлар әллә кулай түгелме?

—Фермерларга карата фәкать уңай караштамын... Шул ук вакытта, Россия һәм Татарстанның авыл хуҗалыгы үсеше киләчәктә Эре Товар Җитештерүче Берләшмәләргә нигезләнер дип уйлыйм... Безнең җир мәйданнарыбыз күп. Барысын да эшкәртеп дәүләткүләм ихтыяҗны канәгатьләндерү—Эре Товар Җитештерү Берләшмәсе кулыннан гына киләчәк. Сез: «Инвестор кем ул?»— дидегез. Инвестор нәкъ менә Эре Товар Җитештерү Берләшмәсен гамәлдә тотучы, аны динамик үстерүче. Республикада кош ите җитештерү һәм сөт продуктларын хәзерләү буенча соңгы еллардагы алга сикерешне фәкать инвесторлар тәэмин итте... Бу төр продуктларны чит илләрдән һәм чит өлкәләрдән кертүне бетерүне дә киләчәктә алар хәл итәр дип уйлыйм... Моны аерым фермерлар гына эшли алмаячак...

Марат Әхмәтов фикеренчә, авыл кешесен эш белән тәэмин итү—әле проблеманың бер өлеше генә... Авыл конкуренцияне күтәрерлек, сыйфатлы һәм табышлы товар җитештерергә тиеш. Авыл үзе җитештергәнне сата белергә тиеш... һәм... ни кызганыч, үзебезнең илдә үзебезнең товарларны ил базарына чыгару буенча чишәсе мәсьәләләр хәттин ашкан.

Авыл кешесенең шәхси хуҗалыгында җитештергән «товарын» үз кулы белән базарга алып чыгып, бәясен үзе куеп сата алганы да бик сирәк бит әле... Олы юлларда чиләк-чиләк бәрәңге, яшелчә-җимеш, ашамлыклар сатып торучыларны әйтсәң генә инде. Бу эшне тулысынча диярлек арадашчылар-алыпсатарлар башкара. «Товар» сүзен югарыда ни өчен тырнаклар эченә алуымны аңлагансыздыр, товар түгел шул, чимал, чимал гына... Авылдан чималны кемнәр генә, ни-нәрсәгә генә алмаштырып алмый... Соңгы ике елда иген ашлыгының, шул исәптән инвесторлар җитештергән ашлыкның сатып алу бәясе бик түбән булды... Хәтта товар икмәген мал-терлегенә ашатып, ит-сөт җитештереп сату юлына бастылар. Дәүләт тә, йөзләрчә миллиард сум маясы була торып, ашлыкның артыгын үзенә сатып алмады. Чит илләргә сатуны оештырмады... Күрәсең, ашлык сату нефть-газ сатуга караганда арзан да, мәшәкатьлерәктер дә...

Узган гасырның башында ук мин туып-үскән Актанышта мул иген үстерә белгәннәр һәм аның үз сатып алучысы да булган... Күздән көлтәләгән арышбодаен, солы, тарысын кыш буе сугу дәвам иткән... Ә аларны Пермь якларыннан хәзерләүчеләр килеп потын 6 тиен бәһасенә сатып алганнар... Татар Ямалысы авылы янында үзләренең амбарларына капчыклардан олаулар өелә торган... Язгы ташу вакытында Агыйдел, Чулман елгалары җәелеп су Татар Ямалысының Сөтлә күле белән тоташкач, Пермьнән зур-зур баржалар килеп ярга туктаган һәм 2-3 көндә Актаныш, Мөслим төбәкләре ашлыгын Чулман буйлап Пермьгә алып менеп киткәннәр... Актаныш төбәгендә бөтен төр тиреләрне үз хәзерләүчеләре Сарапул, Ижаудагы күн эшкәртү фабрикаларына илтеп тапшырган... Бер сүз белән әйткәндә, юлсыз, караңгы бер төбәктә гомер сөрүче товар җитештерүче дә сәүдә итеп үз көнен үзе күргән...

Марат Әхмәтовның илнең азык-төлек базарыннан чит илләрдә житештерелгән товарын кысрыклап чыгару эре товар житештерүче инвесторлар кулыннан гына киләчәк дигәнгә һичбер шик калдырмый. Әмма чит илдән ул товарны кем ташый соң? Газель машинасы белән «челнок» түгел ласа... Ә куәтле суыткычлы автопоездлары булган яңа байлар, таможняда һәм ерак юлларда тоткарлыксыз үтеп китүче «текә» егетләр ташыта аларны...

Узган ел Кытайның Үремче өлкәсенең Голжа шәһәрендә һәм аның тирәсендә урнашкан вак шәһәр-авыллардагы хәлләрне күреп гаҗәпләнгән идем. Ил тулаем житештерү һәм базардан гына тора... Базарларда бөтен товар, иң беренче чиратта азык-төлек фәкать үзләренеке. Аларның бәяләре бездәгедән 2,5-3 мәртәбә арзанрак... Менә шул арзан товарны тонналап ташыйлар да инде Рәсәйнең акчакуарлары... Рәсәйнең эре товар житештерүчесе—Рәсәй инвесторы, бу очракта чит ил житештерүчесе белән түгел, ә үз иленең эре алыпсатары белән конкуренциягә керә түгелме соң?.. Сүз лимон, банан, гранат турында түгел, ә ашлык, ит, сөт, балык, яшелчә турында баруын инде беләбез. Ирексездән башка шундый уйлар килеп керә... Татар язучысының авылга тартылуы, бер карасаң, язучының һәм авыл кешесенең язмышлары бик тә охшаш булудан да... Авыл кешесе тир түгеп үстергәнен базарга алып чыгып хәләл бәясенә сата алмый... Татар язучысы да инде мең мәшәкатьләр белән, 3-4 ел чират торып нәшер иткән китабын үз укучысына илтеп житкерә алмый. Дәүләт сәүдә челтәре һәм кулланучылар җәмгыятьләре табышсыз дип китап кибетләрен ябып бетерделәр.... Базарларда шәхси эшмәкәрләр, сәүдәгәрләр ачкан «Китап сәүдәсе»ндә төп товар—төш юрау, багу-күрәзә итү, очсыз детектив, секс-порнография макулатурасы. Очрашуларга баргач, авыл кешесе бездән әхлаклы нәфис әдәбият сорый, алып килгән китапларыбызны шунда ук сатып алып бетерә... Нужа кушса, язучы да сатучыга әверелер анысы... Китап кадәр китап язган кеше аны сатарга да өйрәнер... Әмма ул китап сатып йөрсенме, язсынмы? Аллаһы Тәгалә иҗатка дип бүлеп биргән вакытын сәүдәдә үткәрерме ул?!.

Китап сату дигәннән, Алабуга шәһәрендә яшәүче бер танышымның сүзләрен әйтеп узыйм әле...

— Сез китап кибетен бетерделәр дип елап йөрисез, Кабминдагы Равил Моратовка мөрәҗәгать итегез... Ул теләсә, ярты елда республиканың бөтен районнарында кимендә бер кибет ачтыра ала...

—Ничек?—дим, гаҗәпләнеп.

— Спидтан да куркынычрак афәт—уен автоматлары баскан иде республиканы... Бала-чага гына түгел, сакалы агарганнар да шуңа алданып гаиләсен ачка тердәделәр. Равил Моратов ярты ел дигәндә себереп кенә алды ул шайтан ояларын. Мең рәхмәт аңа!.. Бөтен авылларда аракы сатуны да аңа йөкләделәр бугай... Карагыз, районның бөтен авылында хәзер чын аракы саталар... Юкса «Урам аракысы» эчеп бөтен авыл үлеп бетә иде. Ичмасам монысының зарары кимрәк... Равил Моратовка әйтегез, ачтырсын китап кибетләрен!—диде ул...

—Шулай эшләп карарбыз, әйтермен,—дидем мин.

## IV

Рәсәйдә иң өстенлекле юнәлешләрнең берсе булып авыл хуҗалыгын үстерү билгеләнүе, әлбәттә, берникадәр өмет уята. Монда да дәүләтнең теләге бик үк гадел түгел бугай. Рәсәйне авыл хуҗалыгыннан бигрәк илдә демографик кризис куркыта булса кирәк. Ике дистә ел дәвамында туучылар үлүчеләр белән чагыштырганда күпкә калыша. Ил картая, халык кими. Кешеләрне инкубаторда үрчетүгә күчеп булмас бит инде. Монда да төп ышаныч—авыл...

Авыл чыннан да үз-үзен тергезергә сәләтле. Аз гына алшартлар булуга үрчергә генә тора ул. Гражданнар сугышы, ачлык, кулакларны туган төбәктән куудан соң, Ватан сугышында бөтенләй сирәкләнеп, бөлеп калган авылны тергезү өчен өч дистә ел вакыт житте. Безнең Чалманарат авылында, мәсәлән, житмештән артык ир-егет сугышка алына. Шуларның 30 га якыны гына әйләнеп кайта. Шулардан 20-30 яшьлек үндүрт солдат гаиләсендә 84 бала туа. Бу безнең авылга гына хас күренеш түгел. Сугыштан аяксыз-кулсыз кайткан ирләр башта гаилә кордылар. Яшь гаиләләрдә балалар туа торды. Шул ук яшь гаиләләр авылда бөтен эшне алып барды. Аларның балалары үсеп житүгә, Татарстан нефтен чыгаруга, Нефтекамга, Түбән Кама, Чаллы шәһәрләрен төзергә,

Себер нефтен үзләштерергә сибелеп торды.

Хәзер күпчелек авылларда зираттагы чардуганнар саны авыллардагы йортлар саныннан күпкә артып китә.

Рәсәй ил халкын рус авыллары исәбенә күтәрә алырмы? Гаиләдә икенче балага түләнәсе пособие генә монда стимул була алырмы? Ай-һай...

Демографик кризистан чыгуда, әлбәттә, иң мөһим социаль бурыч—торак белән тәэмин итү. Авыл бу мәсьәләне дә үзенчә хәл итеп килде бит. Һәр авылда диярлек кирпеч заводлары булдырылды. Балчыкны калыпка салып, мичкә тыгып яндыру—шул ипи пешерү кебек кенә, ансаттан да ансат шөгыль бит... Авыл ирләре урып-җыю эшләреннән соң Пермь, Киров якларында 4-5 ай сезонлы урман эшендә эшләп, алты почмаклы өй бурасы һәм бөтен төзелеш материалларын әзерли алды... Алдагы сезонда шунда ук барып инде өен төзеп чыгарлык акча эшләп—2-3 ел дигәндә каралты-куралы булды. Дөрес, транспорт белән колхозлар ярдәм итте... Хәтта колхозлар үзләре үк квартирлар салып авыл кешеләренә бик очсызга сатып бирделәр. Өйле гаиләдә бала-чага туп-тулы була иде. Хәзер дә Рәсәй урманнарын кисү тукталганы юк. Әмма аларны да газ-нефть кебек читкә сату кемнәргәдер уңайлырак һәм файдалырак, күрәсең. Шулай ук авылларда кирпеч сугу да бөтенләй тукталды инде.

Авылда торак төзелешенең үзгә программасы булырга тиеш. Иң әүвәл авылның үзенең җирле мөмкинлекләрен һәм эшче кулларын файдалану исәбенә.

Бүген дә дәүләтнең авылга берни дә бирмичә генә нәрсәдер алу теләгеннән чигенгәне юк... Рәсәй сәясәтчеләре һәм финансистлары авылны төпсез мичкә диләр... Бер кулы белән нәрсәдер биреп, икенче кулы белән шунда ук тартып алучылар күп. Чиксез урыс дәүләтендә үзал яши алмаган булдыклы халыклар да авылның әлеге проблемаларын бик авыр чишәрләрдер... Гәрчә ул халыклар милли үзбилгеләнешен саклап калуда милләтнең чишмә башы булып авыл торганын аңлаган очракта да. Милли республикалар да «перспективасыз авыллар» дип андагы халыкның яшәеше өчен иң кирәкле социаль-көнкүреш структураларын һәм бигрәк тә милли мәктәпләрен ябуга баралар. Үзләре утырган ботакка балта чабарга мәҗбүр булалар...

«Сезне әйбәт авылларга гына алып баралар, сезгә гел әйбәтен генә күрсәтәчәкләр, сез бүгенге авылның чын йөзен барыбер күрмисез»,—диган иде бер каләмдәшебез без Саба районына юлга чыкканда. Аңар мин: «Безгә нәкъ шул әйбәт авыл кирәк тә бит инде... Без бары тик шул әйбәт авылны, әйбәт кешеләрне, бәхетле кешеләрне күрергә телибез»,—дидем. Шөкер, Нурлатта да, Аксубай, Баулы, Ютазы, Актаныш, Саба, Апас, Буа, Арчада да «әйбәт авылларны», «әйбәт җирләрне» күрсәттеләр безгә! Узган елларда Зәй, Тукай, Әгерҗе, Мамадыш, Чирмешән, Питрәч, Әлмәт, Бөгелмә районнарында да күргән идек әйбәт авылларны... Һәр төбәктә шундый әйбәт авыллар гел күбәеп торсыннар!.. Бу әйбәт авыллар, андагы әйбәт, яшь, акыллы, аек җитәкчеләр бездә һәм авыл кешеләренең үзләрендә киләчәккә өмет тә уята... Шул әйбәт авылларда киләчәк авылларының билгеле бер модуле формалаша... Ул модуль—тулысынча чит илләр, башлыча Европа илләре үрнәгенә дә туры килмәстер, ул модуль үзгә, үзенчә булырдыр... Үзгәлеге—киләчәктә барыбер дә авыл кешеләренең үз җирләренә үзләре хуҗа булачагы дәүләт тарафыннан гарантияләнгән, дәүләтнең турыдан-туры ярдәме һәм яклавына да нигезләнер кебек... Шулай булганда авылларыбызның тернәкләнеп китүе өметле һәм ышанычлы!..

Карл
Фукс

# КАЗАН ТАТАРЛАРЫ: СТАТИСТИК ҺӘМ ЭТНОГРАФИК ҖӘҺӘТТӘН

• • •

Мин өченче төргә керткән татар кызларынын мәхәббәте нигә шулай кыю, йөремсәк икән? Бу аларнын чагыштырмача ирекле булуыннан гына түгелдер; хикмәт шунда: Казанга, бигрәк тә кышкы айларда, Бохарадан сәүдәгәрләр еш килә, җәйләрен дә алар ярминкәгә барышлый бер-ике ай яшәп китәләр. Бохара кешесе олы яшьтәге димче карчыклар аша үзенә яшь кәләш таптыра, шарты шундый: унбиш яшьтән дә олы булмасын; мондыйлар да канәгатьләндермәсә, алар унөч, унике яшьлек кызчыкларны таләп итә башлыйлар. Әлбәттә, бай яисә уртача тормыш алып баручылар узгынчы бохаралыларга кызларын бирмиләр. Аларнын мул гына калымына житәр-житмәс яшәгән мещаннар гына кызыгып, кызларын корбан итәләр. Бохара адәме яшь кыз белән бер айдан артык тормый, өенә кайтып киткәч, аерганын әйтеп хәбәр җибәрә. Казан татарлары бохаралылардан калганнарга бик өйләнергә теләмиләр. Шулай итеп, унбиш яшьлек тол хатыннар, бигрәк тә ата-анасыз ятимәләр, якын кардәше булмаганнар ирексездән Амур канаты астыннан урын эзләргә тиеш булалар...

• • •

Татарларда туй иң зур гаилә бәйрәме. Байлар, урта хәлләләр турында әйтеп тә торасы юк, хәтта ярлылар да үз якыннарын кунак итәр өчен соңгы тиенен дә кызганмыйлар.

Шундый затлы мәҗлестә мина иң кадерле кунак сыйфатында түрдә утырырга туры килде. Менә туй башланып китә. Билгеле булганча, мөселманнарда кияү егетенә кәләшне күрү тыелган бит инде. Күпләр шулай кызны алдан күрмәгән килеш ярәшә. Арада елгыррак егет-җилән, кызыксынучан кыз-кыркын булмас димә: үз бәхетенә тигәнне алар читтән генә булса да күреп калу җаен табалар. Кәләшкә егетенең кайчан урамнан үтеп китәчәген димче хәбәр итә, кияү егетенә исә кызнын кайчан, кайсы тәрәзә төбендә утырасын, яисә кайчан ахирәте өенә кунакка киләсен житкерә. Күз кырые белән генә бер-берсен күреп калгач, егет димчегә үзенең ризалыгын яисә кире кагуын белдерә.

Ризалык алынса, ике яктан да ата-аналар катнашында калым хакы турында килешү төзелә. Бу хак—кәләш һәм кияү ягынын мөлкәтенә карап, байларда өч меңнән алып биш меңгә кадәр житәргә мөмкин. Авылда исә мул тормышлыларнын ике йөздән алып биш йөзгә кадәр, ярлыларныкы илледән алып йөз тәңкәгә хәтле суммада килешенергә мөмкин. Калымнын яртысы кыз ярәшкән чакта ук бирелә. Бу акча кәләшкә кием-салым тектерү, асыл бизәнү әйберләре алу өчен тотыла. Калымның икенче яртысы туйдан соң аерылышу булмагае дип саклап торыла. Шәригать кануны буенча, ир белән хатын кайчан тели шул чакта аерылыша һәм икенче кеше белән кушыла ала. Ир кеше аерылышырга тели икән, калымнын икенче яртысын да хатынга түләргә тиеш була. Аерылышуны хатын ягы кузгатса,

*Ахыры. Башы узган санда.*

калымның ярәшкән вакытта бирелгән яртысы кире кайтарылырга тиеш.

Ярәшкәннән соң кияү егете, үз мөмкинлегенә карап, һәр көнне кәләшкә алтын-көмеш, энже-мәрҗән кебек асылташлы бизәнү әйберләреннән гыйбарәт бүләкләрен юллап тора. Туй көнендә исә кечкенә кисмәк белән бал һәм сары май җибәрә. Бу—тайпылышсыз бер йола. Туй ашы, бала тәпие юу һәрчак шулай бал һәм майны татып караудан башлана. Гадәттә табынга сары майны бер, балны икенче савытка салып китерәләр. Кунаклар зур кашык белән бал белән майны ипигә ягып, бик тәмләп ашыйлар.

Туй мәҗлесе никахка бернич ә көн кала башланып китә. Бер көнне кияү ягында, икенче көнне кәләш ягында әле ир-атлар, әле хатын-кызлар табыны җыела. Бу мәҗлесләрдә кияү белән кәләш катнашмый.



*Фуксның гаилә портреты.*

Ирләр табынында мин кайчан телим шунда булалам, ә менә хатын-кызлар гына җыелган мәҗлесне күрү бәхетенә ничә ел буе ирешә алганым юк иде. Ниһаять, көтмәгәндә, шундый очракка тап булдым. Мин каты авыруга дучар булып, өметсезлеккә тарыган бай гына татар хатынын дәвалап, аякка бастырдым. Ул инде бик рәхмәтле калып, минем өчен бөтенесен дә эшләргә әзер иде. Уңай форсат та чыкты: нәкъ шул көннәрдә аның улы кыз ярәшеп йөри иде. Мин әлеге ханымнан хатын-кызлар көнендә туй мәҗлесен тамаша кылырга рөхсәт итүен сорадым. Көтелмәгән үтенечтән ул куркынып, тетрәнеп китте, моның мөмкин хәл түгеллеген кат-кат аңлата башлады.

Әгәр табиб булмасам, мин аның үҗәтлеген җиңеп һич кенә дә күндерә алмас идем. Бу хакта беркемгә дә тишмәгез, ике арада сер булып калсын, дип ул, ниһаять, миннән ант иттерде. Хатының белән эңгер төшкәч килерсез, баскыч төбендә каршы алырмын, диде. Шулай иттек тә. Безне ул стена буйларына катлы-катлы сандык өелгән бүлмәгә урнаштырды. Уртада ашъяулык ябылган түгәрәк ак өстәл. Өстәл өстендә төрле кипкән җимешләр салынган тәлинкәләр. Миңа сандыклар арасында урындык куелган. Моннан кунаклар утырачак зур залга ишек чыга. Ишеккә Бохара ефәгеннән чаршау эленгән. Хуҗабикә хатынымны зур залга кертте, миңа исә чаршауга тишек уеп, шуннан карап утырырга рөхсәт бирде. Кунаклар әле килеп җитмәгән иде. Зур залда стена буйларында диванга охшаш сәкеләр тезелеп киткән, алар фарсы келәмнәре белән капланган, анда-санда кечкенә мендәрләр дә күренә. Идәнгә дә келәм җәелгән. Ак яисә чигүле ашъяулык белән капланган, кыска аяклы түгәрәк өстәлләр тезелеп киткән. Һәр өстәлдә—кипкән җимешле тәлинкәләр. Бүлмә эче шәмдәлләр белән сүрән генә яктыртылган.

Менә тын залга җан өреп берәм-берәм кунаклар килә башлады. Һәммәсе дә купшыдан купшы киенгәннәр. Бүлмәгә керүгә, җиләннәрен салып, алтынсу камзул, бизәкле күлмәкләрдән калалар. Баш киемнәре төрледән-төрле: алтын-көмеш белән чигелгән яулык бәйләгәннәре дә, кондыз тиресеннән эшләнгән кырку читле, бәрхет гөмбәзле, яннан алтын чук асылынып торган башлык, алтын чачаклы ефәк калфак кигәннәре дә бар.

Һәр кунак киленгә нинди дә булса бүләк алып килергә тиеш. Якын туганнары кыйммәтле парча, күлмәклек тукыма, алтынсу яулык кебек затлы әйберләр салсалар, бүтәннәр инде калфак, күлмәккә ефәк тасма, яка бизәргә укалы тасма, калфак бизәргә чуклы, чачаклы тасма ише әйберләр бүләк итәләр. Һәр килгән кунак, күрешеп чыкканнан соң, бүләк куела торган махсус өстәлгә килә. Хуҗабикә кем нәрсә бүләк иткәнен һәммә кунакка күрсәтеп чыга.

Мәжлескә килү, бүләк салу мәрәкәсе шактый озакка сузыла. Шунысы гаҗәп, кайбер хатын-кызлар, бай гына киемле булуга карамастан, бүләксез килгән иделәр. Хуҗабикә гел минем янга кергәләп-чыккалап йөргән арада төшендереп бирде: болары ярлылар икән. Кешедән алып торып киенгән-ясанган мондый ярлыларны үзләренә акчалата сәдака бирергә чакыралар икән. Татарларның әнә шундый гадел сыйфаты бар: алар аралашу, бәйрәм мәҗлесләрендә ярлыларны читкә тибәрмиләр, аш-сыйга дәрәҗәгә карап түгел, һәммәсен тигез күреп чакыралар.

Менә кунаклар табынга түгәрәкләнеп беттеләр. Чәй эчү башланды. Бер кайнатылып, бер янартылып, ничәмә ничә тапкырлар самавыр кереп чыкты! Хуҗабикә үзенең кыз туганнары белән чынаяк тулы подносларны йөртеп кенә тора. Шулкадәр тәм белән эчәләр чәйне, ничә чынаяк каплаганнарын хәтта санап бару да мөмкин түгел. Хатынымны да пәрдә артына, минем янга чыгарып, безне хуш исле хан чәе белән сыйладылар. Без чәй эчкән арада хуҗабикә, берәр кыбырсыгы килеп кермәсен дип, сагаеп чаршау янында басып торды. Алай-болай берәрсе бу якка таба кузгала башлый икән, мин инде сандыклар арасына, алдан хәстәрләнгән урынга посарга тиеш идем.

Хатын-кызлар тәлинкәләрдәге тәм-томга нәзакәтле үреләләр, талымсызланмыйча, чама белеп кенә алалар. Кайберләре камыр ризыкларын кульяулыкка төреп куя, өйдә калган бала-чагаларга, күрәсең. Чәй эчелеп, бераз вакыт үткәннән соң кичке ашка әзерлек башланды. Ханымнар иркенләп, җәелебрәк утырдылар. Боларның аякларын шундый җайлы гына бөкләп, итәк очыннан алтынсу чигүле читекләрен генә күрсәтеп утырулары үзе бер сәнгать иде. Купшы читекләрен искәртеп, чибәркәйләрнең бер-берсе каршында көязләнүе иде бу. Келәмле идәндә түгәрәк өстәл тирәли утырган хатын-кызларның күбесе тизрәк ризык килүен көтеп кыбырсый иде шикелле. Менә туй ризыгы чыкты: сары май, бал салынган тустаганнар, телемнәп туралган ак ипи куелган поднослар башта сәкедә утыручыларга, аннары идәндә түгәрәк өстәл тирәли утыручыларга таратылды. Һәр ханымның ак ипигә сары май, бал ягып шундый бер олылык белән тәгам кабуында үзенә бер серлелек, илаһилык бар иде сыман.

Икенче булып өстәлгә бәрән ите салып пешерелгән токмач килде. Өченчегә—пилмән, дүртенчегә—кәбестә бөккәне, бишенчегә—итле бәлеш, алтынчыга—тутырган тавыктан өлеш, җиденчегә эре туралган сарык итеннән борай бәлеше, сигезенчегә—кызыл серкә салынган пешкән суган белән бозау ите, тугызынчыга—парда пешкән чөгә балыгы, унынчыга—кыздырылган бәрән ите, унберенчегә—кыздырылган каз, уникенчегә—кыздырылган үрдәк, унөченчегә—кыздырылган тавык, ундүртенчегә—кыздырылган күркә, унбишенчегә—йомырка салып кыздырылган табан балыгы, уналтынчыга—кыздырылган корбан балыгы, унҗиденчегә—гөбәдия, һәм инде унсигезенче булып, сигез төрле баллы камыр ризыклары китерелде. Бу соңгылары русларның пирожныйлары кебек, камырга төрле бизәкләр төшереп пешерелгән иде.

Шушылай озакка сузылган ашау-эчүдән соң, хуҗабикә икенче бүлмәдән кәгазь алып чыгып һәр кунакка берәр битне өләшеп чыкты. Хуҗабикә артыннан ук икенче ханым подноста печән эскерте чаклы өелгән, һәртөрле җимешләр белән бизәлгән төш-как күтәреп чыкты. Мондый сәнгатьле итеп катырылган төш-как туйларда һәрвакыт кәләш ягыннан җибәрелә.

Төш-какны табындашлар санынча бүлеп, өлкәннәрдән башлап тараттылар. Һәр кунак татып караганнан соң, үз өлешен әлеге кәгазьгә, аннары яулыкка төреп, өендә калганнарга туй күчтәнәче итеп алды.

Шунысын да искәрдем, кабыгы чистартылып туралган тозлы кыярны инде ун төргә якын майлы, итле ризык ашаганнан соң аерым бирәләр. Шуңа күрә кыярны кетердәтәләр генә.

Бу кадәр дә озакка сузылган мәҗлес мине тәмам ардырды. Октябрь аеның озын төнендә кичке 9да башланган иде, таңга кадәр дәвам итте. Табын әзерләүчеләр кабаланмый, кунаклар ашау ләззәтен суза бирә, ризык арты ризык агыла тора—бу мәҗлеснең азагы булмас кебек иде. Безнең бүлмәгә дә бу тәгамнәрнең барысы да рәттән килә торды, барысын да түгел, кайсыларын гына татып карап та тамакларыбыз туйды.

Инде тәмам яктырып беткәч, сәкедә утыручы хатын-кызлар кыймылдый башладылар; берәүләре торып басты, икенчеләре тамак туйганны белдереп учына йөткергәләп куйды. Идәндәге келәмдә утырганнарга да җан керде, кайсыберләре генә урыныннан кузгалмады. Болары ярлылар иде. Менә хуҗабикә көмеш акча салынган тәлинкә тотып чыкты. Иң беренче итеп ул мулла хатынының учына кызгылт кәгазь акча, туганнарына бер тәнкәлек көмеш, калган ярлыракларга тиеннәр сонды. Сәдака өләшү шулкадәр оста шомалык белән башкарыла ки, кемнең учына нинди акча салынганга күз дә иярми кала.

Менә шулай бәйрәм итә безнең Казан татар хатын-кызлары! Моннан да күңеллерәк бүтән бәйрәм мәҗлесе аларда булалмый.

Ә инде никах укыту мулла катнашында кияү өендә үтә, иртәгесе көнгә мин шунда чакырулы идем. Билгеләнгән вакытка килеп җиттем. Кунаклар әле күп түгел иде; өлкән яшьтәге берничә татар агае гына нидер турында тын гына гапләшеп бүлмә буйлап арлы-бирле йөриләр. Кунаклар ашыкмый гына җыелып беттеләр, муллага хәбәр иттеләр, күрәсең, ул иң соңыннан озын таягын тотып килеп керде. Вәкарь белән генә түргә узганда аңа аерым бер хөрмәт билгесе күрсәтеп, һәммәсе дә ике кулын сузып күрештеләр. Һәрчак шулай: күрешкәндә өлкән кеше сузган кулны яшьрәге куш учына ала. Кунаклар җыелган бүлмә бөтенләй буш иде, сандыклар да, өстәл-урындыклар да күренми. Идәндә генә калын-калын келәмнәр. Мулла түргә утыргач, мина да аның кырыеннан урын тәкъдим ителгәч, калганнар да, шәрыкча аягын бөкләп, келәмгә чүмәштеләр. Башта табынга чәй килде һәм калак-чынаяк чылтыраулары шактыйга сузылды. Аннары кичке ашка хәзерлек башланды. Икешәр-икешәр булып янәшәрәк утырыштылар. Һәр пар алдына тәлинкә, икешәр агач кашык куелды. Салфетка урынына озын сөлгеләр бирелде. Тәүге ризык—аерым-аерым савытларга салынган куе сары май һәм бал иде. Һәр ир заты ипигә мул итеп май, бал ягып, тәмле оеп чәйнәргә керешә. Аннары инде, мин алда хатын-кызлар мәҗлесен сурәтләгәнчә, бер-бер артлы бүтән төрле ризыклар агыла башлады.

Мәҗлес беткәндә һәр кунакка берәр стакан ширбәт бирделәр. Аны тамчысынача бушатып, сакал-мыекларны сыпырганнан соң, тамак кыру, төрле тонда (бас, тенор, альт) ямьсез итеп кикерү башланды. Бу—ашказанының табын муллыгына, тамак туюга, хуҗага рәхмәт белдерү музыкасы иде.

Шушындый гадәттән тыш концерт тәмамлангач, келәм өстенә җәелгән махсус ашъяулыкка кызыл, зәңгәр кәгазь акчалар, көмеш тәңкәләр салына. Болар инде каядыр якында аерым билгеләнгән бүлмәдә утыручы кәләш өчен җыела. Кияү куенына керәсе бүлмә йә ишегалдындагы берәр кече өйдә, яисә йортның икенче яртысында әзерләнгән була. Акча җыю ширбәт дип атала, борынгырак дәверләрдә көмеш тәңкәләрне кәләшкә ширбәтле кубокка салып китергәннәр. Ул аны кабул итеп, ярәшкән егеткә чыгарга риза булуын белдергән.

Монда исә җыелган акчаны кубокка түгел, тәлинкәгә салып, ата кеше кәләшкә алып китте. Бераздан кире кереп, кызы тарафыннан акчаның кабул ителүе хакында муллага хәбәр итте. Шул мәлдә кияүне чакыртып алдылар да, син ризамы, дип сорадылар. Кияү бер икеләнүсез «Әйе!» дип җавап бирде. Шуннан соң инде мулла калым турында сүз кузгатты. Моңа бәйле сорау-җаваплар беткәч, тамак кырды, учына өч тапкыр ютәлләгән сыман итте дә, сакалын сыпырды, бөтен ирләр дә мулла артыннан шуны ук кабатладылар. Дога уку ун минутларга сузылгандыр...

Дога беткәннән соң, мулла урыныннан күтәрелә, калганнар да аңа ияреп кузгала башлый. Туй мәҗлесендә татарлар да, руслар кебек үк, шәраб яки сыра эчкәлиләр; әмма бу бүтән бүлмәгә чыгып, яшертен генә эшләнә. Әгәренки мулла берәрсенең сәрхүшләнгәнен сизеп ала икән, бөтен гавам алдында сүгеп ташлап, тегенең йөзен кызарта.

Кунаклар китеп беткәч, яучыбикә кияүне чыбылдык эчендә кәләше түземсезләнеп көткән махсус бүлмәгә алып керә, чыгып киткәндә өсләреннән бикләп куя. Бу бүлмәдән яшь пар дүрт көн буена бер яры да чыкмый, алар янына да яучы хатыннан гайре берәү дә керми.

Дүрт көннән соң кияү егет ата-анасына күренеп китә, төнгә тагын хатыны янына кайта.

Иртәләрен үз өенә кайтып китсә дә, өч ай буе төннәрен хатыны янында уздыра. Өч айдан соң инде кавышулар сирәгәя башлый. Хатыны ир ягында кунак була да, кабат үз өенә кайтып китә. Бер, ике, өч ел шулай уза, аннары инде хатыны (кайчакта инде икешәр баласы белән) ир йортына бөтенләйгә күченә.

Гадәттә туйның икенче көнендә кияү, үз мөмкинлегенә карап, кәләшенә ин затлы әйбер бүләк итә, кайчакта икенче көнне үк хатынынннан ваз кичеп, аеруын сорап муллага мөрәҗәгать итүе дә ихтимал.

Туй мәҗлесен мина авылда да күрергә туры килде. Йолалар үтәүдә аермалык юк иде. Ризык әзерләүләре дә крестьян йортындагы кебек түгел иде. Бөккән, бәлеш, пироглар ак оннан пешерелгән, ит ризыклары барысы да ат итеннән иде. Мине ин гаҗәпләндергәне улаксыман савытка салынган ризык булды: туралган ат эчәгесе ботка белән аралаштырылган, актарылып ташланган, куркыныч кыялардан торган тау кечерәйтеп карагандагы шикелле тоела[1]. Мәҗлестә ирләр дә, хатын-кызлар да бар иде. Ирләр—төп яна өйдә, хатын-кызлар исә келәттә (җәйге кызуларда йоклар өчен анда урыннар да әзерләнгән).

Мулла фатихасы белән мәҗлес көндезге икеләрдә башланды. Башта төп сый чәй булды. Аны муллага һәм дәрәҗәлерәк ирләргә китерделәр. Яшь-җилкенчәк сыра эчте. Шушы форсат өчен бик күп итеп кайнатып куйганнар. Өстәлдә шәраб күренмәде. Кияү үз иптәш егетләре белән кичкә таба гына килде. Энгер төшәр алдыннан никах укытылды. Аннары яучы хатын кияүне кәләшнен абыйсы йортына алып кереп китте. Анда яна салынган ак өйдә егетне сөеклесе көтә иде. Икенче көнне без иртәнге 7дә юлга кузгалдык, күршедәге яшь пар бу вакытта әле Амур куенында эри иде.

Шул ук авылда мина икенче бер тамашаның шаһиты булырга туры килде. Әтисе йортыннан кызы бөтенләйгә ире йортына күчеп китәргә җыена. Кияүгә чыкканнан сон ул төп йортта ике ел ярым яшәгән, ике баласы бар. Озату бик күнелле бәйрәм түгел икән шул. Әти-әнисенен күзләрендә яшь, кызлары моннан егерме чакрым ераклыктагы чит авылга китәсе.

Ул келәттә бирнәләрен барлый. Аның тирәсенә кызыксынучан хатын-кызлар җыелган. Нинди бүләкләре барлыгын тотып карап белергә теләгәннәр сандык өстенә тиеннәр салалар. Ир ягы туганнары ике көмеш тәнкә салса, кыз ягынныкылар бирәр тәнкәлек көмеш куйдылар. Бирнә алай ярлы димәс идем: алтын белән чигелгән камзул, киҗе-мамык бөркәнчек, ситсы күлмәкләр, кызыл читекләр, башмаклар, кызыл бизәкле шәл, куян мехын астарлап тегелгән киҗе камзуллар һәм шуның ише башка әйберләр. Ашъяулык, чүпләм сөлге, урын-җир җәймәләре һәммәсе үз кулы белән бик матур итеп тукылган, чигелгән.

Бирнә бүләкләрен тәртипкә китереп җыюга төп йортта табын әзерләнде. Каймак, сары май, бал, вак бәлеш, баллы камыр кебек нигъмәтләр өстәлгә тезелгән иде.

Кияү пар ат җигелгән өч көймәле арбада ир туганнары белән килеп төште. Боларны шунда ук өстәл тирәли утырттылар. Алар чәйләгән арада киленнең әйберләрен урнаштырып та куйдылар. Әти-әнисе белән хушлашасы ханым келәттә күзгә каршында бизәнеп ясанды, кыз чагындагы киемнәрен салып икенчене киде. Аннары яучы хатын аша иренә бүләк—бәз күлмәк җибәрде. Кияү белән килгәннәрнең берсе күлмәкне алып чыкты да ин шәп көймәле арбага җигелгән атның дугасына күлмәк җиңнәрен урады, ә күлмәк итәген ат сыртына ябып куйды. Бу арбага яучы хатын белән килен утырды, ә кияү кучер урынын алды. Атлар дәррәү кузгалдылар, кызның ата-анасы, туганнары җылашып хушлаштылар, бөтен авыл басу капкасына чаклы боларны озата барды.

Татарларда бала тугач бәби туе үткәрү күркәм бер гаилә бәйрәме санала. Байларда бу—йоласына туры китереп, зурдан кубып үткәрелә. Кендек әбисе бала туарга берничә көн кала чакырыла, шушы йортта яши башлый. Күпләр кендек әбисен вакыт житкәнен сизгәч кенә дәштереп алалар. Үз әниләре дә чакыртыла, янәшәдә була. Бала исән-имин дөньяга килгәч, инде ата кешегә, туганнарына хәбәр салына. Бала туып өч көн үткәч, дини йоланы үтәргә мулланы дәшеп алалар. Мулла

[1] Фуксны «куркыткан» ризык тутырма булырга тиеш [М.Галиев искәрмәсе].

сабыйның аягын кыйблага каратып яткыра, баш очына басып, уң колагына азан әйтә, аннары сул колагына камәт[3] пышылдый, һәм баланың исемен әйтә. Муллага һәркем, үз чамасына карап, мул гына сәдака бирә. Туган-тумача, күрше-күлән ирләрне чакырып сый мәҗлесе үткәрелә. Берничә көн буена баланың тәүге теше күренсенгә дип (руслардагы кебек үк) әнкәгә бүләк ташыйлар. Балага күлмәклек, байларныкы—ефәк, ярлыларныкы—ситсы, кечкенә юрган, түбәтәй, калфак кебек бүләкләр бер өем була.

Шул әйберләргә кушып тагын чәй-шикәр алып килү зарури санала. Бу очракта да күчтәнәчләрнең муллыгы һәркемнең мөмкинлегенә карый.

Өч яисә биш яшькә җиткәч, ир баланы сөннәткә утырталар. Ни өчен өч, биш?.. Еллар саны так булырга тиеш икән. Шундый ышану бар: дүрт яисә алты яшьтә сөннәтләсәң, бала үлеп китә имеш. Сөннәтне аерым бер мулла башкара[4], моның өчен ана түлиләр. Илле сумнан алып алтын тәңкәләргә кадәр, кем ничек булдыра ала. Сөннәтләр алдыннан дога укыла...

...Дөресен әйтергә кирәк, татарлар ярлыларга шәфкатьлелек күрсәтү ягыннан русларны уздыралар, әмма ихластан түгел, ә Рәсүлнең әйтеп калдырган катгый канунынннан куркып эшлиләр моны: «Дөньялыкта мохтаҗларга күпме биргәнсез, Ахирәттә шулкадәр әйләнеп үзегезгә кайтыр; ярлыларны ничек ашатып-эчерткәнсез, үзегезгә дә шундый ук аш-су булыр, ничек киендергәнсез—шундый ук кием үзегезгә дә насыйп ителер».

Сәүдәгәр Чамас Мәхмүд хатыны, минем күршем Шәрифәбануның пәйгамбәр әйткәннәрне ничек үтәвен мисалга китерергә була. Шик юк, аның яхшылыклары ихлас күңелдән эшләнә иде, чөнки ул кындәмлеге-итагатьлелеге белән бөтен танышларын да гаҗәпкә калдыра иде. Ул уртача гына яшь, тол хатын буларак, бар булганын үзе теләгәнчә тота ала иде; ул фәкать ярлылар көнен күреп яши, алар белән бүлешмичә бер сынык ипине дә авызына алмый иде.

Көннәре менә ничек уза иде аның: таң белән иртәнге намазга баса, берничә ярлыны чакырып чәй эчертә, аннары гына үзе чәйләп ала; алар өчен дип кул эшенә утыра. Төшке ашка тагын берничә кешене дәшеп ала, үзенә ни әзерләгән, аларга да шуны ашата. Кайбер чакта көткәннән артыграк кеше килә; мондый хәлдә ул әзерләнгән бөтен ризыгын да уртак табынга чыгара, ә үзе коры ипигә кала.

Ул беркайчан да бай, купшы күлмәк кимәде: үзенә нниндине тегә, шундый укны килен булып төшәсе берәр ярлы кызга да тегеп кигезә. Шулай итеп ул, 22 яшендә тол калып, 37 яшькә кадәр гомер сөрде. Мәрхүмәне озатырга әллә күпме ярлы-ябагай җыелды! Һәрберсенә мул гына сәдака да эләкте...

***

Казан татарларының дүрт төрле бәйрәме бар: икесе—дини: Рамазан һәм Корбан, икесе—Сабан һәм Җыен—халык бәйрәмнәре.

## 1. Рамазан

Мөселманнарның елга бер була торган ураза тотуы—Рамазан ае быел 30 декабрьдән башланып, 29 гыйнвар кичәнә кадәр дәвам итте. Мәгълүм ки, Мөхәммәд пәйгамбәр үзенең Коръәнендә, Аллаһы каршында чистарыну, пакьләнү өчен, елның бер аенда ураза тотуны кертә. Дөрес, ураза тоту вакытын ул аерым бер төгәллектә билгеләмәгән; әмма аның табынучылары көн дәвамында бөтен шартын китереп ураза тоталар; төн кергәч инде, ак җепне кара җептән аерып күрерлек булып таң атканчы, күпме кирәк шулай ашый-эчә алалар. Рамазан аенда кем дә булса авырып китсә йә юлда калса, ул кеше бүтән чакта шул ук көннәр санынча ураза тотарга тиеш; ә инде моны үтәмәгәннәр, гөнаһларын юар өчен, ярлыларны ашатып торырга мәҗбүр булалар.

Ураза тотуның хезмәт кешесе өчен кыенлыгы шунда: көне буена бер тамчы су

[3] Камәт—аягүрә укыла торган дога һәм аны уку, камәт төшерү.

[4] Фукс ялгыша. Сөннәткә мулла түгел, ә махсус сөннәтче утырта [М. Г. искәрмәсе].

кабарга ярамый. Рамазан ае ел саен унбер көн алга күчә бара, шунлыктан кайсыбер елларда җәйнең бик эссе чорына туры килә, житмәсә, якты көн озынлыгы да арта; мөселманның мондый чакта ничек интегүен күз алдына китерү кыен түгел: ачык кырда, көйдергеч эссе кояш астында сусавын басарга да җөрьәт итә алмый бичара.

Мондагы татарлар көн саен мәчеткә җыелып, үзенә бер олпатлык белән галәти догаларны укып, гыйбадәт кылалар иде. Мин шунда аяк йөзенә кадәр актан киенгән бер дәрвишне, ягъни мөселман монахын күрдем.

Рамазан аеның буеннан буена татарлар, авыз ачып тамак туйдырганнан соң, төн ката өй каршына җыелып утыралар да, изге теләкләрен теләп тәсбих тарталар, Аллаһы Тәгаләне мактап салават әйтәләр.

Төне буе 26 гыйнвардан 27сенә каршы (быел 25 гыйнварда) кадер кичендә бөтен мәчетләр гыйбадәт кылучылар белән тулы иде. Олысы-кечесе, имчәк балаларга кадәр бу төндә йокларга тиеш түгел. Мәчеткә бармаганнар исә өйдә якыннары белән җыелышып, йокыны куар өчен, чәйләп утыралар. Бу төндә Аллаһ әмере белән фәрештәләр җиргә индерелә. Танга кадәр изгелек, гөнаһлардан арыну, чистарыну хисе тантана итә бу төндә; чөнки бу төндә җиргә изге китап—Коръән индерелгән.

Рамазан аеның 27нче көнендә ярлыларга хәер өләшенә. Бу—зәкят дип атала. Канун буенча һәркем үз мөлкәтенең уннан бер өлешен бүлеп бирергә тиеш[5]. Мондагы татарлар йорт-кура кебек күчемсез малны һәм кышка дип әзерләнгән азык-төлекне исәпләмиләр, зәкят әйләнештәге мөлкәт яисә товарга әйләндерелгән акча исәбеннән чыгып бирелә. Һәркем үзенең хәер бирәчәген әйтеп, суммасын билгели, аны әүвәл мулла-мәэзиннәргә, аннары ярлыларга өләшә. Бүгенге көндәге Казан байлары, сәүдәгәр татарлар: Юнысов, Апанаев, Исай Заманов, Бәшир Әитов, Сөеров, Йосыф Корбангали Әхмәри, Мортаза Кашаи, Аппаковлар һәм башка байлар зәкят өчен шактый зур суммалар чыгарып салдылар.

Инде 28 гыйнварда ук кайбер үткен күзле татарлар кояш батуга Иделнең аргы ягында, күк читендә калыккан яна ай урагын күреп алганнар; ул көнне югыйсә күкне юка болыт сүрүе каплаган иде. Бу хәбәр шунда ук Казан мөселманнары арасында таралып та өлгерә, икенче көнне инде яна ай урагы калкуга күпләр шаһит булдылар. Инде икеләнү-шик юк иде кебек, тик ике ахун арасында каты бәхәс купты, руханиларның берсе яна айның болай иртә күренүе мөмкин түгел дип бара иде. Шулай да 28 гыйнварда мин алда әйткән җыр сузуны туктаттылар, күп кенә бәхәс, каршылыклардан соң, ниһаять, дүшәмбедә (29 гыйнвар) Рамазан ае тәмамлана дигән фикергә килделәр. Мәчет яннарында күп кенә татарлар җыелышып, кояш батуга яна айны күрергә теләп тынгысыз игътибарлылык белән офыкны күзәтәләр иде. 29 гыйнварда күпләр, ниһаять, яна ай урагын тамаша кылу бәхетенә ирештеләр. Быел Рамазан 29 көнгә генә сузылды, чөнки яна ай иртәрәк күренде; әгәр күренмәгән булса, Рамазан тагын бер көнгә сузыласы иде. Мин монда шуны да искәртергә телим: татарлар безнең календарьны өнәмиләр, шуна күрә Ай әйләнешен дә аннан карап белешмиләр иде[6].

Ун еллар элек Ураза бәйрәме җәйге чорга туры килгән иде[7]. Җомга көнне сәгать иртәнге сигезләрдә яше-карты—бөтен татарлар, җәмгысе 6000 меңләп булгандыр, Яна Татар бистәсенә якын кырга җыелып күк астында гыйбадәт кылдылар. Шулкадәр күп кешенең тәртипле рәтләргә тезелешеп, бер сулыштан әле аягүрә басып, әле җиргә тезләнеп сәҗдә кылулары искиткеч күренеш иде һәм бу тамаша читтән карап торучыларга бик көчле тәэсир иткәндер. Алар әйтүенчә, гыйбадәт кылу кояш агач ябалдашы биеклеге күтәрелгәч (ел фасылына карап йә иртәрәк, йә

---

[5] «Ислам» белешмә-сүзлегендә (татар. кит. нәшр., 1993, 49 б.) әйтелүенчә, зәкят сәүдәгәрләр һәм һөнәрчеләр өчен – еллык керемнең 2,5 процентына кадәр, терлекчелек белән көн күрүчеләр өчен 12 процентка җитә. Ред.

[6] Адмиралтейство бистәсе татарлары бу бәйрәмне 29 гыйнварда, ә шәһәрнең үзендә яшәүчеләр 30 ында үткәрделәр.

[7] 1814 елның 4 сентябрендә бу бәйрәм ачык кырда үткәрелде. 1815 елның 25 августында да шулай булды. Ә инде 1817 һәм аннан соңгы елларда һава бозылу сәбәпле фәкать мәчетләрдә генә уздырылды. 1823 елның 29 маенда исә сенатор Соймонов катнашында, ике Татар бистәсе арасындагы кырда бу бәйрәм иң тантаналы төстә уздырылды.

сонрак) башланырга тиеш икән. Гыйбадәт кылу тәмамлангач, бөтенесе дә зиратка юнәлә, анда Коръәннән берничә сүрә укыла. Аннан соң инде һәркем сый табыны әзерләнгән өенә ашыга. Бу көн—гаед көне дип атала. Бәйрәм ашы итеп табада кызган майда катлама пешерелә. Аны балга манып ашыйлар. Шулай итеп, өч көн буена татарлар, гаед бәйрәме белән котлашып, бер-берсенә кунакка йөрешәләр.

## II. Корбан

Рамазан аеннан соң ике ай үткәч мөселманнарның Корбан бәйрәме уздырыла. Гарәп телендә бу сүз корбан чалуны аңлата. Мөхәммәд пәйгамбәр бу бәйрәмне Аллаһка табынуны онытмасыннар өчен халыкка керткән. Аллаһ ихтыярына буйсынуын раслап бердәнбер улын корбан итәргә ниятләгән Ибраһимны гыйбрәтле мисал итеп китергән. Әлеге бәйрәмнең көнен тәгаенләштерүдә кайбер кыенлыклар да килеп чыга. Яңа ай калкасы көннәрдә күк йөзен болыт каплау сәбәпле, мондагы татарлар ай урагын анык кына күрә алмадылар, вакытны төгәл билгели алмыйча ике ахун арасында бәхәс кузгалды. Хөрмәтле аксакал Ибраһим әфәнде бәйрәм көнен 11 ноябрьгә билгеләде, ләкин күпләр алдагы көнгә тәгаенләгән яшь имам Саттар белән килештеләр. «Фәйләсуфларга гына[8] Ай әйләнешен алдан белеп, ярашу хас, ә мөселман өммәтенә ике-өч көн сабыр итеп, күк йөзендәге Айны үз күзләре белән күреп ачыклагач, китапка карауның хаҗәте юк»,—дигән яшь хәзрәт.

Шушы көннең киченнән башлап һәммәсе ризык җыюдан тукталып тордылар, бәйрәм көннең уртасында гына корбанга чалынган мал ите табынга куелды. Кайберәүләр яңа ай калыккан көннән башлап 11 көн буе ураза тоттылар. Тугызынчы көн—Гарәфә көне дип атала. Мөселманнар җыелып төп гыйбадәтне кылалар, аннннары өч көн буена гыйбадәт кылу соңында тәгъбир әйтелә...

Бәйрәм көненә каршы, кояш чыгарга бер сәгатьләр кала, мөселманнар мәчеткә җыелып, намазның ике рәкәгать сөннәтен укыйлар.

Беренче рәкәгатьтән соң, гадәти тәкъбирне тагын өч тапкыр "Аллаһу әкбәр" дип тәкъбир әйтеп тәмамлыйлар.

Икенче рәкәгатьтән соң да шул ук тәкъбир кабатлана.

Аннары имам мөнбәрдән гарәп телендә хөтбә укый...

Шуннан соң имам татарчага күчеп, корбанга әзерләнгән хайванны ничек чалу турында киңәшләрен әйтә.

Бәйрәм таңында, мәчетләрдә гыйбадәт кылу гадәттәдегән иртәрәк башланды...

Мәчеттән һәммәсе корбанга әзерләнгән малны чалырга дип өенә ашыга[9]. Монда инде чама тартып, бүлү эше шулай куелган: әйтик, бер сарык яки бәрән бер кешегә исәпләнсә, сыер җәнлеге яисә дөя җиде кешегә тәгаенләнә; ата кеше нәсел-нәсәбен, ашка чакырыласы дин әһелләрен, ярлы-ябагайны—һәммәсен күз унында тота. Гаилә башлыгы яисә йорт хуҗасы, кем булуына карамастан, кенәзме ул, морза яисә мещанмы, бер малны үз кулы белән чалырга тиеш. Хайванны яткырганда башын Мәккә ягына каратып куялар. Муенына сызып җибәргәндә Аллаһ исеме әйтелә.

Ул көнне мин сәүдә әһеле Йосыф Исмәгыйль углы Апанаевта идем. Ихатада корбанга дип әллә ничә сарык, әллә ничә сыер җәнлеге, бер дөя дә әзерләнгән иде. Ул яраннары белән мәш килә, үзе дә чалуда катнаша; ишегалды уртасында зур казанда су кайный, әле җаны да чыгып бетмәгән ит түтәрәмнәрен шул казанга сала торалар. Ярты сәгать үтте микән, казан ит белән тулды; суын алыштырып, ике тапкыр кайнатып алганнан соң, шулпасын йотлыгып чөмерә-чөмерә, Аллаһуга багышлап, кинәнеп ит ашарга керештеләр. Дөя итенең кайбер кисәкләре кайнап пешәргә дә өлгермәгән, кискәндә калтырап тора иде[10].

Кызыгып китеп, мин дөя итен ашап карадым; сыер итеннән кызгылтрак, тәме

[8] Бу сүз белән татарлар галимнәрне атыйлар. Гади татарлар арасында философ мәгънәсен миңа: «Фәйләсуф ул рус белән хәмер эчүче татар була», дип аңлаттылар.

[9] 1834 елда Корбан бәйрәме 8 апрельдә булды. 1833 елның 19 апрелендә хәрби губернатор Стрекалов катнашында ачык кырда үткәрделәр.

[10] Яңа суелган йомшак ит кисәкләре кайнар шулпадан алып кискәндә тетрәп, калтырап торган кебек тоела. Суелу белән мул итеп әзерләнгән ит ризыгын ашарга күнекмәгән немецка тере тоелуы да гаҗәп түгел (М. Г. искәрмәсе).

ошаш, бераз йомшаграк, баллырак шикелле тоела. Шулпасы бик тәмле. Мөселман булмавым сәбәпле бу көндә мина уртак табында утыру тиеш түгел иде, шуна күрә мина махсус өстәл әзерләделәр. Татарлар бу көндә үз тамакларын гына кайгыртмадылар, ярлыларны да онытмыйча, корбан итеннән аларга да өлеш чыгардылар. Төштән сон инде туганына, якын кешесенә кунакка йөрү, мәҗлесләр, бәйрәм белән котлашу башлана[11].

## III. Сабан

Бу—һәр язда бөтен кеше катнашында үткәрелә торган борынгы татар халык бәйрәме. Быел ул болында үтә. Сул ягыннан әрәмәле үрләр каймалаган бу болын Яна Татар бистәсеннән көньяктарак, шәһәрдән өч чакрымнар арырак җирдә. Сабан—сука-сабанны аңлата, бәйрәмнең мәгънәсе: язда табигатьнең уянуын, кырларны сөрә-эшкәртә башларга вакыт җитүен тантана итү. Кайбер татар авылларында бу бәйрәмне кырлардан кар китүгә үткәрәләр.

Казанда исә Сабан сонрак була, чөнки бәйрәм үткәрәсе болын язын Идел сулары астында кала. Сабан бер җомгадан икенче җомгага чаклы атна буена бара[12]. Яшекарты төш алдыннан бәйрәм урынына җыелалар. Аркан тартып, түгәрәк мәйдан билгелиләр. Мәйдан уртасына яшь, таза татар егетләре көрәшкә чыга; билләренә бәйләнгән сөлгегә тотынып, әле бер, әле икенче якка әйләндереп бер-берсен егарга тырышып көрмәкләшәләр. Егу кайчакта бик тиз була, кайчакта бик озакка сузыла.

Чирәмгә сырты белән төшерүгә, тамашачы шау итеп ала. Җинүче егет тантаналы төстә мәйданнан чыга башлый, аңа бүләк яисә акча соналар (ун тиеннән алып егерме тиенгә чаклы). Бүләккә дигән акча татар сәүдәгәрләреннән җыелган була. Бәйрәмдә тәртип саклаучылар озын таяк тотып, үзләренең кемлеген сиздереп йөриләр. Әгәр инде көрәштә җинелгән яктан дәгъва-фәлән чыкса, әлеге бурмистрлар шунда ук ике якны җайлап, тынычландыралар. Акчага кызыктырып алар читтән көрәшчеләр дә табарга мөмкиннәр. Моны белсәләр, тавыш чыга, әмма бәхәс тирәнгә китми, тиз арада йомып та куялар. Зур низаглар булмый, чөнки бәйрәмне оештыручылар халыкны тиз тынычландыра беләләр.

Көрәшчеләр көрмәкләшкәндә бер-берсен тешләп, чәйнәп ташларга җыенган аюлар кебек тоела. Мәйданда русларның да төрле катлавыннан күп кеше була, бәйрәмнең соңгы көннәрендә инде исемле дворяннар да күпләп катнаша. Күпләргә читтән күргәндә бертөрле, кызыксыз күренгән татарлар һәртөрле уеннардан зур канәгатьлек табып кайнаша беләләр икән. Оста көрәшә белгән баһадир егет бүләкләр ала-ала бәйрәм чорында шактый суммага тиенә.

Көрәштән кала, йөгерү ярышы, ат бәйгесе үткәрелә. Озын таякка эленгән, бүләккә дигән яулык беренче килүчене аргы башта көтеп тора.

Чабыш атлары күзгә бәрелеп тормый, тәбәнәк, ябык күренә. Әмма шәп чабалар, җайдак малайлар да тезгенне оста тотып баралар.

Сирәк була торган, бөтенләй икенче рәвештәге уеннары да бар: дүрт яисә аннан да күбрәк ир-егет иңгә-иң терәлеп, йөзтүбән яталар, боларның өстен күн торыпша белән каплыйлар. Бу уенның атаманы төрле яктан ташланып, очы каты төенләнгән озын сөлгеләр белән күн җәймә астында ятучыларның сыртына тамызырга адарынганнардан сакларга тырыша. Әмма аның куллары бау белән бәйләнгән, бау очы күн җәймә астында ятучылар кулында, шуңа күрә ул һөҗүм итүчеләрне куып еракка китә алмый. Атаман еш кына җәймә астындагыларның сыртына басып, әле анда, әле монда талпына, һөҗүм итүчеләргә аягы белән селтәнә, әгәр берсенә тигерә икән, калганнары ул мавыккан арада җәймә астындагыларның сыртын каезлый башлый, тегеләр түзмичә аягүрә басалар. Алар урынын һөҗүм итүчеләр ала.

Сабанның тагын бер истә кала торган уены мондыйрак тәртиптә бара: түгәрәк

---

[11] Корбан ае ислам календаре буенча елның 12 нче, Зөлхиҗҗә аенда була. 1834 елда татарларның яңа ел бәйрәме 28 апрельдә (1250) булды...

[12] 1824 елда Сабан бәйрәме 25 майдан 1 июньгә кадәр барды. Ул елда озын таяк очына чуар яулык элеп, Казан урамнарын шау кузгатып йөргән сөрәнче аша русларны да бәйрәмгә чакырдылар.

хасил итеп, бер-берсеннән ике адым ара калдырып, 12, 15 яисә 20 кеше утырышалар. Төрле кием-салымнарны төреп, олы бер туп кебек эшләнгән төен тотып түгәрәкнең тышында берәү тора. Ул төенне түгәрәктә утыручыларның берәрсенә бирә дә үзе ике-өч адым читкәрәк китеп баса. Шул мәлдә төенне күршедән күршегә ыргытып, түгәрәк буенча кулдан-кулга йөртә башлыйлар. Ә артта торган егет, төенне тотып алырга теләп, түгәрәк тышыннан йөгерә, эләктереп ала икән, төенне кулыннан ычкындырган уенчы урынына үзе кереп утыра; түгәрәк тышына чыгып әлеге җинелгән уенчы йөгерә башлый. Уен кагыйдәсендә ике шарт үтәлергә тиеш: берсе— түгәрәктә утыручылар өчен, төенне бер йә ике кеше аша түгел, фәкать күршеңә ыргытырга тиешсең. Ә инде түгәрәк тышындагы аучы төенне ыргытырга җыенганда гына эләктереп алырга тиеш; әгәр очып барганда, яисә ялгыш җиргә төшкәндә төенне эләктерә икән—бусы саналмый; бу очракта ул янадан түгәрәктән өч адым читкә «куыла», төеннең түгәрәк буйлап китүен көтә башлый. Гадәттә, бу кагыйдәләр бозыла, аучы елдам булса, төенне ике-өч кеше аша ыргытырга мөмкинлек бирә; әгәр аның хәлдән тайганын сизсәләр, җәлләп, төенне һавада ук тотарга яисә җиргә төшкәнне алырга да рөхсәт итәләр.

Бу уенда иң ныгы үзенең елгырлыгы белән мактанучы аучыга эләгә. Түгәрәктәгеләр бу мактанчыкны хәлдән тайдыру өчен берләшеп алалар: тезләнеп утырышалар да төенне шундый тиз ыргытыша башлыйлар, аучы өч-дүрт адым артка калып ыргыла, инде дә берәрсенең мыштырдап калуы аркасында аучы төенне куып житә икән, шунда ук аны арткы якка җибәрәләр. Аучы кире борылып йөгерә башлый, әмма төеннән шактый артка кала. Бу мактанчыкны тәмам хәл итү өчен, түгәрәктәгеләр кагыйдәне бозып, төенне әле бер, әле ике кеше аша ыргытырга тотыналар, мескен аучы кайсы якка ташланырга белмичә чарасыз кала.

Бу—елгыр-җитезләр уены. Үшәнлек белән берни кыра алмыйсын монда.

Татар кызлары да катнаша бәйрәмдә, алар инде төп тамаша мәйданыннан читтәрәк, агач күләгәсенә тукталган көймәле арбаларыннан бөркәнчек аша күзәтеп торалар. Бу очракка инде алар, әлбәттә, иң купшы күлмәкләрен кигәннәр, иннеккершәнгә буянганнар, битенә юка кара челтәрдән миң кебек түгәрәкләр ябыштырганнар. Әгәр якын килсәң, алар озын җиннәре белән битен каплап бетерә язалар, һаман китмичә карап торсаң инде, битен ачалар. Куак төпләрендә хатынкызларның балалары белән чыр-чу килеп чәй табыны корып утыруларын күрергә була. Аз гына танышлыгы булганнарны да алар чәйгә кыстыйлар. Тик татар ирләренә генә табынга якын килергә ярамый.

Бәйрәмгә руслар хәмер алып киләләр, дип зарлана татарлар; күзәтү, тәртип саклау куелган булуга карамастан, кайбер татарлар исергәнче эчеп, тәртип бозалар икән. Низаг килеп чыкмасын өчен полиция һәрчак бәйрәмгә кайбер түрәләрен һәм казакларны җибәрә. Билгеле булганча, татарларга Ислам кануны буенча шәраб эчү тыелган.

Элегрәк татарлар бу бәйрәмне Арча кырында үткәреп, ачык һавада табын әзерлиләр иде (ярлылар монда бушка ашатыла). Бу сыйлану мәҗлесен алар туй дип атыйлар; әмма русларның куәте, хакимлеге үсә барган саен бу гореф-гадәт бетә барды.

Сабан бәйрәменә өлкәннәр дә килә. Әгәр алар күбәү икән, кояш баер алдыннан бергәләп кичке намазга басалар. Чирәмле кырда кыл кебек бер рәткә тезеләләр дә, сәҗдә кыла-кыла тын гына, бөек бер олпатлык саклап, гыйбадәт кылалар. Шаугөр килеп бер якта халык күңел ачканда шундый капма-каршылык сәер тойгылар уята.

## IV. Җыен

Язгы Сабан бәйрәменнән соң Казанның үзгендә һәм тирә-яктагы бөтен авылларда Җыен бәйрәме уздырыла килгән. Хәзер инде Җыен шәһәрдә үткәрелми, ә җиде атнаның һәр җомгасында, Казан губернасындагы авыллар исемнәре белән аталып, тантаналы бәйрәмгә әверелә. 1884 елда Җыен мондый тәртиптә уздырылды: 8 июньдә Шимбер җыены, 15ендә Олыяз авылында Кызылъяр җыены, 22сендә

Бәрәскә һәм Сәрдә авылларында, 29ында Бәрәзә, Комыргужа җыены, 6 июльдә Әтнәдә Мукшы җыены, Зур Битаманда Кушкапка җыены, 13ендә Сая авылында Биектау җыены һәм, ниһаять, 20 июльдә Мәмдәл, Өнсә авылларында Кабак җыены узды.

Сабан ирләр бәйрәме булса, Җыен хатын-кызларга багышлана. Риваятьләр буенча, моның башлангычы бер татар баена барып тоташа; имеш, байның кызлары бик күп булган, боларны ничек кияүгә бирергә? Ата кеше кызларын таныту өчен шундый бер сәбәп уйлап чыгара: җомга көнне авылның бөтен мөхтәрәм затларын кырда оештырылган аш мәҗлесенә чакыра. Мәҗлес вакытында кызларын күрсәтергә дә форсат табыла. Шулай итеп кызлар монда егетләрне үзләренә караталар һәм тиз арада кияүгә чыгып бетәләр. Әнә шуннан бирле кызлы әтиләр шул ук ният белән кырга мәҗлес җыялар һәм уңышка ирешәләр, имеш. Димәк ки, бу бәйрәмнең максаты—ирләр күзеннән ерак торган хатын-кызларны дөньяга чыгарып таныту буладыр.

Татарларның Җыенын күрер өчен мин Казаннан утыз чакрымнар ераклыктагы Сая авылына бардым. Килеп төшкәннең икенче көнендә ирләр алдан, хатын-кызлар ирләрдән соң, мунча керү булды. Мунчадан соң табынга чакырдылар; өстәлгә зур савытларга пилмән, татарлар әйтмешли, Казан бөкмәсе, яшел суган туралып, сөттә пешкән гөмбә ашы куелды; аннары сөт өсте кушылган каймак, кечкенә түгәрәк пирожкилар (коймак дип атала) һәм йомырка тәбәсе килде.

Көндезге икеләрдә, өйлә намазы бетүгә, төрле яклардан, җәмгысе уналты авылдан 6000гә якын кеше бәйрәм буласы кырга агылды. Монда авыллардан гына түгел, Казанның үзеннән килүчеләр дә бар иде. Җинел куллан гына бернична лавка ясалган, анда прәннек, чикләвекише нәрсәләр сатуга куелган, әмма шәрабның тамчысы да юк иде. Бернична музыкант курайда, куллан ясалган скрипкада уйнап, биергә чакырдылар. Бу, әлбәттә, ирләр ягына гына кагыла иде. Хатын-кызлар көймәле арбаларда утырган килеш кенә тамашаны күзәттеләр. Мин монда немец, француз бию көйләрен ишетеп, казачок биюен карап гаҗәпкә калдым. Табигый, моның серен беләсем килә иде, татарлар болай дип аңлаттылар: имеш, үзләренең бию көйләре туйдырып бетергән, шуның өчен казачокны, бүтән ят көйләрне уйныйлар икән. Мәйданның төрле урыннарыннан гади халык җырлары яңгырый иде...

Мондый зур бәйрәмдә очынган дәртне тагын да ныграк канәгатьләндерер өчен татар ирләре пистолеттан ату оештырдылар; үзара сөйләшү, җыр тавышлары, атлар пошкыруы, татар кызларының сагышлы аһәңе, скрипка-курай моңнары—шуңа тагын ату-шартлау тавышлары да кушылып, сәер бер тәэсир уята иде. Татар кызлары иң кәттә күлмәкләрен киеп килгәннәр, җете куе иннек кершәнгә буялган битләренә ясалма миң төртелгән; керфек-кашлары сөрмәләнгән, тешләре каралтылган, үз зәвыгына карап, күркәмлекләре бөтен төсләрдә балкып тора. Әмма бу тантаналык озакка бармый, өч сәгатьләп үтүгә, бәйрәм тарала башлады; берәүләр теләр-теләмәс кенә, икенчеләре зур канәгатьлек кичереп, мәйданнан кузгалдылар. Юлда мин шулкадәр чибәр кызларны күрүдән гадәттән тыш хисләнгән бер егетне очраттым. Аның җыры мондый иде: "Сөйкемле кызларны мин корбанын күзәткән тилгән кебек күзәттем; сөйкемле кызлар миңа май ялаган песи кебек күз аттылар".

## Мәдрәсәләр

Читтән килгәннәргә Казан татарларының хәтта кайбер Европа халыкларына караганда да белемлерәк икәнен белү сәер тоеладыр. Укый-яза белмәгән татарны үз якташлары да санга санамый, һәм ул гражданин буларак та хөрмәткә лаек булалмый. Һәр ата кеше үз баласын укый-язарга өйрәнсен, дин сабаклары алсын дип бик иртә мәдрәсәгә бирергә тырыша. Ахун күзәтүе астында һәр мәчет каршында мәдрәсә ачылган; мәчет мулласы һәр көнне дәресләр алып барып мөгаллимлек итә. Мондагы ике татар бистәсенә җәмгысе 8 мәчет бар. Шуларга караган мәдрәсәләр—дүртәү. Шәкертләре күп. Уку-укыту алымнары безнекеннән үзгәрәк; пансион белән бик аз гына охшашлыгы бар сыман. Мәдрәсә бинасы нинди дә булса татар бае тарафыннан сатып алына; бинаны җылыту һәм башка кирәк-

ракларны ул Аллаһ хакына дип үз өстенә ала. Мәдрәсә бинасы ике өлештән тора: алгы бәләкәй бүлмә һәм зур бүлмә, монысы инде театр сәхнәсе сыман, идәне берничә баскычка биегрәк. Шушында хәлфәгә дә, аның ярдәмчесенә дә, шәкертләргә дә урын табыла; мендәре, әрҗәсе, савыт-сабасы, китап-дәфтәрләре һәммәсенең үзаеры тора.

Хәлфәнең ярдәмчесе шәкертләр белән бергә яши, шушында дәресләр бирелә, шушында хуҗалык эшләре дә бара. Әгәр берәрсе авырып китә икән, терелгәнче шушында үз түшәгендә ятып тора. Мондый очракта инде гади генә чаралар белән авыруны савыктыру вазифасын хәлфә башкара. Хәлфә ярдәмчесенең ятагы чаршау белән бүленгән була. Киштәгә аның уку әсбаплары тезелеп куела. Шушында ук гадәттә читек-кәвеш тегә торган әйберләре тора: ул үзенекен генә түгел, шәкертләрнең дә аяк киемнәрен төзәткәләп бирә.

Гадәттә 7 яисә 8 яшькә чыккан балалар мәдрәсәгә алына; уку дәвере кимендә биш елга сузыла. Үзләрен фәнгә багышлап, рухани яки мөгаллим булырга теләгәннәр мәдрәсәдә тагын да озагракка кала.

Дәресләр әлифбадан башлана, аннары Һәфтияк китабыннан Коръән сүрәләрен өйрәнүгә күчәләр. Казанда басылган татар китапларыннан укыла торганнары: Пиргули, Сөббател-Газизин, Фәүзел-Нәжад, Стуани—болар шигъри яки чәчмә телдә язылган Коръән аңлатмалары (тәфсирләре), Мөхәммәд әфәнденен сәүдә эшенә караган китабы[13] һәм гарәп телендә грамматика дәреслекләре һ. б.

Ислам дине нигезләрен үзләштерүдән кала Коръәнне аңларлык дәрәҗәдә гарәп телен өйрәнәләр, моңа өстәп фарсы, Бохара телен дә кертергә була. Телне алар бер яктан сәүдә мөнәсәбәтләрен җиңеләйтү өчен өйрәнсәләр, икенче яктан гарәп-фарсы сүзләре чуарлаган төрек китапларын уку өчен өйрәнәләр; татар теленә, талымлап тормыйча, гарәп, төрек, фарсы сүзләрен кушып, югары өслүбтә яза белүне мәртәбә саныйлар. Шунысы бар: монда татар телен грамматик кагыйдәләргә таянып укымыйлар; татар, диләр алар, телгә әнкәдән өйрәнергә тиеш, мәдрәсәгә моның өчен түләүнен хаҗәте юк. Шунысы кызыклы, рус арасында яшәп тә, сәүдә мөнәсәбәтләрендә еш аралашып та, рус телен белергә теләкләре күренми. Русча яхшы белгән ник берәү булсын араларында, ә инде яза белү хакында әйтеп тә торасы юк. Нигә мәдрәсәләрдә русчага да укытмыйсыз, дип сорагач, андый түбәнлеккә төшкән шәкерткә безнең җәмгыятьтә урын юк, дип җавап бирделәр.

Мулла белән хәлфә үзләре мәдрәсәдә яшәмиләр, шуңа күрә күзәтеп тору өчен югары сыйныфтан берәр шәкертне ярдәмче-казый итеп сайлап куялар. Казый бернинди дә хезмәт хакы алмый, шәкертләрдән кергән сәдака белән канәгать була. Сәдака итеп аңа аз-азлап булса да онын, чәен-балын китереп торалар, кайчакта бакыр акчалар да бирәләр, берәр зуррак бәйрәмдә халат та (җилән, чапан) бүләк итәргә мөмкиннәр. Сәүдәгәр Сөеровның балалары һәр шимбәдә үз хәлфәсенә күчтәнәч итеп 8 каравай ипи бирәләр. Һәркайдагы кебек, монда да хәлфә никадәр каты куллы булса, бүләкне дә шулкадәр күбрәк бирәләр, ләкин барыбер аның еллык кереме 100 тәңкәдән артып китми. Мин хәлфәләрнең кереме шулкадәр аз булуына гаҗәпләнүемне белдергәч, бер хөрмәтле ахун: «Хөрмәтле әфәндегез Мәгариф министрыннан сорагыз: безнең мәдрәсәләрне үз карамагына алсын,— диде.—Без үз балаларыбызның төрле фәнне белеп чыгуларын телибез, әмма моңа нинди чаралар белән ирешергә икәнен белә алмыйбыз; галим, дин әһеле булырга теләгәннәрне Бохарага җибәрәбез әнә, чөнки монда төпле белем алыр өчен җирлеге дә, матди мөмкинлеге дә юк.».

Мәдрәсәдә дәресләр иртә таңда башлана. Ахун дин кагыйдәләренә өйрәтә. Атна буе үткәнне атна кичтә кабатлата; начар җавап биргәннәрне чыбык белән суктыралар яки идән астына ябып торалар. Хәлфәләр шәкертләрнең үз вазифаларын үтәүләрен дә, кием-салым пөхтәлеген дә даими күзәтеп торалар: нинди дә булса

[13] Сәүдә мондагы Казан татарларының төп шөгыле дип әйтергә була. Әз генә капиталы булганнар да аны товарга әйләндереп, сату эшенә керешә. Зур капиталы булганнар кытайлар белән, икенчеләре бохаралылар, фарсылар белән сәүдә мөнәсәбәтләре алып бара; берәүләре капиталын сабын кайнату һәм тагын башка төрле завод-фабрикаларга кертә. Кереме аз булганнар да ефәк, бумази тукымалар белән сату итәргә тырыша; инде ярлы дигәннәре дә печән, солы һәм башка шундый нәрсәләрне ваклап сата.

тәртип бозу ачылса, җәзага тарталар.

Шәкертләрнең ял сәгатьләре юк диярлек: атна кичтә генә өйләдән соң сабаклар бетә, шимбә иртәсендә тагын башлана.

Язу өчен алар Һиндстан әтәченен каурыен файдаланалар, су кушылган тушь—язу карасы, кәгазьнең шомасын ярааталар. Кайбер шәкертләр уку дәверендә Коръәнне дүрт мәртәбә тулысынча укып чыгалар. Сабак алу рәвеше: аякларын бөкләп, мендәргә утырып, борын эченнән бер мәкам белән көйләп укыйлар, болар бар да үзенә бер төрле күренеш хасил итә. Шәкертләр атна буе мәдрәсәдә, шуңа күрә, шобага салып, аш-су әзерләргә кизү билгеләп куялар. Пилмән яисә умач пешерә торган казан барсына да уртак. Кем кайчан тели, шунда үз өлешен ашап куя, гадәт буенча, сәгать иртәнге 8дә капкалап алалар, төшкелек кичке 6да була.

Казан татарларында хатын-кызлар да тиешле дәрәҗәдә белем ала. Укый-яза белмәгәнен таба алмассың. Аларга мондагы яна мәчет каршында мулланың җәмәгате сабак бирә. Ул ханым үз предметларын укытуга бик сәләтле. Аның шәкертләре язган хатларны, җырларны мин үз күзем белән күрдем. Моннан тыш һәр татар кызы диярлек әнисеннән яисә апасыннан чигү-тегү эшенә өйрәнеп үсә. Бигрәк тә читек, кәләпүш ише әйберләрне алтынлап чигеп, тегәргә ярaталар. Монда инде әллә нинди матур бизәкләр табып сәнгати югарылыкка ирешәләр.

## Татар басмаханәсе

Моның башлангычы 1802 елга туры килә. Татар сәүдәгәре Бурашев өч ел буена түбәндәге исемдә татар-гарәп китаплары бастыра:

1) Татар әлифбасы. 11 000 данә.
2) Коръәннең жиделән бер өлеше[14]. 7 000 данә.
3) Пиргули. 1. 200 данә.
4) Фәүзел-Нәжад. 3 000 данә.
5) Сөббател-Газизин. 3 500 данә.
6) Стуани. 3 000 данә.
7) Тулы Коръән. 2 000 данә.
8) Коръән, 30 бүлектән (Һәфтиәк). 1 000 данә.

1806 елда Йосыф Апанаев карамагына күчкәч басылган китаплар:

1) Татар әлифбасы. 19 000 данә.
2) Коръән (жиделән бер өлеше). 3 000 данә.
3) Пиргули. 1 000 данә.
4) Стуани. 1.200 данә.
5) Сөббател-Газизин. 1 200 данә.
6) Коръән (тулысынча). 1 500 данә.

Алдагы елларда бик күп данәдә Әлифба һәм Коръәннең жиделән бер өлеше басыла; Юнысов кулына күчкәч, 121 табактан торган, бик матур бизәлешле Коръән басыла. Бу төпләнгән басма Коръән Түбән Новгород ярминкәсендә 25 тәнкәгә сатыла.

Типографиядә эшләүчеләр барсы да татарлар, язу карасын, кәгазьне генә руслардан алалар. Инжилчеләр җәмгыяте чорында бу Азиат басмаханәсе үз эшчәнлеген аерата җәелдереп җибәрде. Татарлар, безнең кебек үк, үз дини китапларын таратуга ясканып тотындылар.

Бу типографиядә лектор Ибраһим Хәлфин хезмәтләреннән: Татар грамматикасы, Хрестоматия һәм дин әһеле Троянский бастырган Татар сүзлеге дөнья күрде.

Басмаханә тотучы Бурашевның 1802 елда чыгарган бер дини китапка керткән хәйләкәрлеге турында әйтмичә кала алмыйм. «Фәүзел—Нәжад» дигән китап соңына ул шигыйлар мәзһәбе файдасына берничә бит өстәгән, күрәсең, фарсыларга да китапны сатып файда алу турында уйлаган булгандыр. Сигез ел буе барган суд

14 Коръәннең жиделән бер өлешен тәшкил иткән, бәләкәй форматта төпләнгән мондый китаплар әфтияк (һәфтияк) дип аталган (М.Г. искәрмәсе).

гамәлендә Бурашев динне мәсхәрәләүче дип гаепләнә, Казан татарлары-сөнниләр тарафыннан, әлеге китапка кергән өстәмә битләр ертып алына һәм дин әһелләре, рус түрәләре каршында яндырыла.

## Татарларда чит ил кунакларын кабул итү

Бервакыт өйләдән соң без, чакыру буенча, бер татар мещанына киттек. Ул безне ачык йөз белән капка төбендә үк каршы алды, өенә алып кереп диванга утыртты. Ул юка ак күлмәк өстеннән тезгә житеп торган камзул, аның өстеннән жинел Бохара чапаны кигән иде. Хужа өстәлгә эрбет чикләвеге, йөзем ише тәмтомнар салынган берничә тәлинкә куйды; өстәлгә киже-мамыктан тукылган парчалы фарсы ашъяулыгы жәелгән. Сүз сәүдә эшләре турында барды, үзе эшкәрткән мехлар сату буенча хужа белгеч иде. Казан губернасындагы төлке, ас, чәшке һәм тагын шундый кечкенә жәнлек тиреләрен сатып алып ул Мәскәү купецларына тәкъдим итә, тегеләр исә бу тиреләрне Кяхтага жибәреп, китайкага, ягъни төсле киже-мамык тукымага алмаштыралар.

Ниһаять, хужаның хатыны кайтып керде. Безнең белән килгән ханымнар хужабикә белән үбешеп исәнләштеләр. Ярты сәгать үтүгә өстәлгә зур коштабак белән аш килде. Шулпада кечкенә, озынчарак, эченә ваклап туралган ит салынган, колакка охшаган пирожкилар йөзеп йөри иде. Ашны без агач кашыклар белән ашадык (металлдан ясалган калак тоту аларга ярамый); тәмле генә үзе. Мондый аш шулпа төренә керә; суган, борыч салына, кайчакта катык яисә серкә кушыла һәм әлеге пирожкилары белән бергә пилмән дип атала. Аннан соң безгә тозлы кыяр белән бергә вак кына туралган тавык ите китерделәр.

Табынны хужа үзе хәстәрләп торды, хатыны исә почмак бүлмәдә, чаршау артында аерым ашады.

Аннары сөтсез чәй килде, соңгы чынаякларга аракы да өстәлгән иде.

Чәй алдыннан һәм соңыннан да Дон шәрабе белән сыйладылар, хужа кеше аны тәмләп тә карамады, безнең сыман пунш эчте. Без тагын бер сәгатьләп гапләшеп утырганбыздыр, хужа акыллы кеше булып чыкты, безнең сорауларга төпле жавап бирде. Ул тагын безне берничә мәртәбә кыстап шәраб эчертте. Без сәгать сигездә генә аның белән хушлаштык. Капка төбендә жигүле ат тора, чанада безнең өчен мамык мендәрләр салынган иде, хужаның улы юл буе татарча жыр көйләп безне озатып куйды.

Казан губернасындагы татарлар сәүдәгәр, мещан, игенче крестьяннардан тора; сәүдәгәрләр арасыннан бик сирәге генә ханлык чорындагы морза нәселеннән икәнен онытмыйча үзен кенәз дип йөртә. Казанда яхшы сабын кайнату заводы тоткан кенәз Замановлар яши. Кенәз Исай Заманов Россия тәхетенә тугрылыгы белән аерылып тора, кайчандыр Пугачев фетнәсенә каршы торган һәм күндәм хезмәте өчен патшабикә Екатерина кулыннан Андреев тасмасына беркетелгән алтын медаль алуга ирешкән. Улы Әхмәтнең дә берничә медале бар. Әхмәтнең уллары Вәлид белән Мостафа эшләп чыгарган сабын яхшы сыйфатлы булуы белән аерылып тора. Кенәз Яушев губернатор кәнсәләрендә начар тылмач буларак билгеле; кенәз Ибраһим Богданов та анардан шәбрәк түгел иде. Боларның уллары хәзер Казан университеты каршындагы Татар басмаханәсендә эшлиләр. Кенәз Сәитов кызыл тукыма эшләп чыгаруы белән билгеле.

Татарларның кайберләре казна эшендә хезмәт итә, мәсьәлән, Г. Хәлфин, Казан гимназиясенең элеккеге татар теле мөгаллиме, Г. Алкин хәзерге көндә частный пристав һәм тагын башкалар. Казна эшендәгеләр чәч йөртәләр, европача киенәләр; ләкин инде мәчеткә барырга булса, үзләренең милли киемен кучәләр, чәче күренмәслек итеп чалма урап куялар. Крепостной татарлар Казан губернасында юк.

Завод тоткан Казан татарларының эш күрсәткече мондыйрак: кенәзләр—Заманов, Юнысов, Арсаев, Апанаев һәм Якупов заводларында елга 50 000 пот яхшы сабын житештерелә. Юнысов, Апанаев һәм Арсаев заводларында 150 000 кәжә тиресе эшкәртелеп Кяхтага жибәрелә. Юнысов һәм Арсаев заводларында һәр ел саен 20 000

пот парафин эшләнә һәм Санкт-Петербургка озатыла. Киже-мамык туку фабрикалары—бишәү, сәүдәгәр Аппаков, Ажемов, Уразов, Габдуллин, Бикмөхәммәтевләрнеке. Алар үз товарларын Оренбург губернасына илтеп ярминкәдә саталар. Болардан тыш ике Татар бистәсе арасында купец Алишевнын селте заводы бар. Монда елга 5 000 пот селте кайнатыла. Ике купец—Габдуллин һәм Фәйзуллиннарның фабрикалары шулай ук игътибарга лаек: монда ефәк һәм алтын жеп белән бизәкләп, күп санда читек-кәвеш тегелә. Бу һөнәргә татар кызлары гына түгел, рус кызлары да хәтсез тартыла. Бу ике фабрикадан кала читек тегү шөгылен күп кенә татарлар үз өендә жайга салганнар.

Татарлар русларга караганда чиргә азрак бирешүчән. Балигълык яшенә житкән татар кешесе һәр нәрсәдә чама белеп яшәргә тырыша. Шулай да бавыр, эч авырту белән еш интегәләр. Ваба чире вакытында күпләп кырылдылар. Бигрәк тә эссе жәйдә эч китү белән жәфаланалар, Түбән Новгород ярминкәсендә бу авыруны эләктереп, монда да иярттеп кайталар. Даруны бик теләп кабул итәләр. Үзләренең арасыннан чыккан табиблар булмау сәбәпле, мондагы рус яисә чит илдән килгән табибларны дәшеп алалар, әмма аларнын хезмәтенә бик саран түлиләр йә бөтенләй буш калдыралар.

Рус телендә чиста сөйләшә белгән татарны бөтенләй диярлек күрмәссең, ә инде русча укый-яза белүчене әйткән дә юк.

Алар русча өйрәнергә тырышмыйлар да, ипи-тозлык белсәләр, шуннан канәгать булалар.

Татарларда мин косметикага караган бер генә әйбер күрдем: Бохарадан кайтартылган кечкенә агач кисәге. Әчкелтем сутлы бу агачны месвәт-агач дип йөртәләр. Татар сәүдәгәрләре мәчеткә кузгалыр алдыннан, авыздан ис килмәсен өчен, теш-анкауны шул агач белән ышкып алалар.

Татарлар иконалар тоткан һәм дунгыз ите ашаган өчен христианнарны түбән жанлыга саныйлар.

Рус чиркәвендә ничек гыйбадәт кылганнарын алар бөтенләй белмиләр, чөнки храмга кереп күз салганнары да юк; алар өчен чиркәүдәге гыйбадәт—кыңгырау чыңы, урамда күтәреп йөргән иконаларга табынудан гыйбарәт. Яшь татар егетләре кайчакта протестантлар чиркәвенә кереп чыккалыйлар; телне белмәгәч, алар өчен мондагы гыйбадәт орган музыкасыннан һәм кулларны бутаудан гына тора. Моны гади руслар да шулай дип уйлый.

Татарлар үз фамилияләре сонында руслардагы кебек кушымча ялгыйлар. Мәсәлән: Апанай—Апанаев, Заман—Заманов, Юныс—Юнысов.

Ел әйләнәсендәге вакытны христиан календаре буенча исәплиләр, ай исемнәрен европача атыйлар. Әмма дини бәйрәмнәре Ай әйләнешенә карап билгеләнә. Шулай итеп, ел саен 11 көнгә алгарак күчә-күчә килә дә, 35 елдан соң бәйрәм көне тагын элекке эзенә кайта.

Бай саналучы купецлар: Гобәйдулла Юнысов, кереме 3 миллион; Габдерәшит Юнысов—2 миллионга якын; Корбангали Арсаев, Исхак Бушитов-Якупов, Тимербулат Якупов, Давыт Жәдегәрев, Мостафа Лебяжин, Минлебай Козловлар—ярты миллионнан артык керемгә ияләр, һәм тагын яхшы гына капиталы булган башка байларны мисалга китерергә була.

Гади халыктан чыккан татарлар арасында, рус мещаннары кебек үк, йодрык сугышына маһирлар күп. Язгы һәм көзге айларда, аяз көнне, кичке якта Кабан күле буена йодрык сугышына жыелалар. Татарлар, дәррәү кычкырып, өерләре белән русларга ташланалар, бу һөҗүмнең соңында чырайлар канга батмыйча калу сирәк була. Шуны искәрә идем: йодрык сугышында татарлар руслардан өстен чыга иделәр. Хәзерге чорда инде андый йодрык сугышы оештыру гадәте бетте диярлек.

Татарлар төрле җәмәгать чараларында, күнел ачуларда, маскарадларда бик теләп катнашалар, театрларга йөриләр, ә инде исемлеләре Казан купецлар жәмгыяте нинди дә булса вакыйгага карата үткәргән мәжлесләргә дә чакырылалар. Казанга атаклы сәяхәтчеләр килгән чакта, мин үзем дә көндезге аш мәжлесенә дин әһелләрен, беренче гильдия купецларын чакыра идем. Алар минем чакыруны бик теләп кабул итәләр иде, табында ит ризыгына кагылмыйлар, балык һәм сөтле

ризыклар гына ашыйлар, чит ил шәрабларын кире кагып, әче бал, ширбәт кенә эчәләр иде.

Хатын-кызларына без җыела торган урыннарга килү тыелса да, Арча кырында уздырылган Троица якшәмбесе бәйрәмендә аларны атынгычлар янында күрергә мөмкин. Ерак түгел генә атларын туктатып, бәйрәм тамашасын көймәле арбалардан күзәтеп торалар. Язын Казансу бозлары киткән чакта, төркем-төркем хатын-кызларның Болак биржасы янында фарфор чынаяклар сатып алып торганын күрергә мөмкин. Гомумән, татарлар безнең күнел ачу чараларында катнашырга яраталар.

Татар мещаннары вак кәсеп белән шөгыльләнә; ит, эшкәртелмәгән тире, балавыз, туңмай сата, алар өчен Татар Ратушасы янында хәтсез лавкалар ясалган. Чын сәүдәгәрләре исә руслар белән бергә Кремль янәшәсендәге Кәрван сарайда (Гостиный двор) сату итәләр. Шунысын да әйтергә кирәк, руслар урам як рәттә булсалар, татарларның лавкасы ишегалдына караган эчке якта була.

Күптән килгән гадәт буенча, масленица бәйрәме житсә, тирә-юньдәге авыллардан Казанга татарлар агыла башлый (3 меңнән 5 меңгә кадәр). Арзан гына хакка русларны атларына утыртып урамнар буйлап йөртәләр; хакны арзан алсалар да, һәрберсе атнага 20-30 таңкә акча эшли. Полициядән, күпмедер акча түләп, һәммәсе ат йөртергә рөхсәт билеты алган була.

Татар базарында, бигрәк тә кышкы айларда, ерактан килгән үз кавеме сәүдәгәрләрдән татар мещаннары түбәндәге әйберләрне сатып ала:

1) 100 000 данәгә кадәр эшкәртелмәгән тире. Моны Кама аръягыннан, Уфадан, Оренбург даласыннан алып киләләр; 600 000 сыер тиресе, бер-берсе 6 таңкә тора, 400 000 ат тиресе, 5әр таңкәдән. Боларны рус купецлары аша С.Петербургка озаталар.

2) 150 000гә якын кәҗә тиресе, моны Кама аръягындагы авыллардан, Уфадан китерәләр. Эшкәртелмәгән тире 2 таңкә тора, эшкәртү мондагы татар заводларында башкарыла.

3) 500 000 гә якын сарык тиресе, 2 сумнан, Урдадан (из ордынских) китерелә; рус сарыкларыныкы, 1 сум 80 тиеннән, Оренбург губернасыннан.

4) 150 000 потка якын туңмай, татар заводларында шәм, сабын ясау өчен. Оренбург губернасыннан бер поты 12 сумга сатып алына.

5) 10 000 потка якын балавыз, Казан губернасы, Кама аръягындагы авыллардан китерелә. Бер поты 47 сум; балавыз Мәскәүгә озатыла.

6) 20 000 потка якын бал. Гади балның поты 18 сум, үтә яхшысының поты 34 сумга бәяләнә; бал Ростов ярминкәсенә җибәрелә.

Бу мисаллар фәкать татарлар алып барган сәүдәгә карый, русларның сәүдә әйләнеше чагыштыргысыз дәрәҗәдә өстенрәк.

Бай, хәлле татар купецлары кайчакта, дөресрәге, мәҗбүр булганнан, губернатор һәм башка түрәләрне чәй мәҗлесенә чакыралар. Бу гадәттә төшлектә була. Чәйдән соң күп төрле җиләк-җимеш белән сыйлыйлар; кабымлыкка әллә ничә төрле балык, уылдык чыгаралар, шампан шәрабе агылып кына тора, әмма хуҗалар үзләре эчмиләр. Вак түрәләр дә, татарларның мондый кунакчыллыгыннан файдаланып, шактый әрсезлек күрсәтәләр.

Татарлар хәзерге көндә руслар белән килешеп яшиләр, кырык еллар элеккеге кебек, руслар тарафыннан татарларга карата әйтелгән тупас сүзләрне бүгенге көндә ишетмәссең. Шулай да, кайчакларда, атка юл сапмыйча урам уртасында мыштырдаган татарга рус кучеры: “Собака!”—дип бакырырга мөмкин. Мондый чакта татарың борын астыннан: “дуңгыз”, дип мыгырданыр да, эченнән: “син кяфер” дип уйлап куяр.

Фәнзаман
Баттал

# БУ ДӨНЬЯ КЕМГӘ КАЛА?

Биниһая озын һәм мәңгелек тарих белән чагыштырганда, кеше гомере шул хәтле кыска ки, яшисең-яшисең дә хәйран каласың: әнә, дисең, әле кайчан гына тәүге тапкыр мәктәпкә барган идем, кайчан гына гашыйк булган идем, хәзер килеп, гамәлдән чыккан, «списәйт» ителгән кеше, ягъни пенсионер булып көн күреп яткан булам...

Әйе, гомер гаҗәеп кыска. Әгәр тарихны йөзләрчә чакрымлы озынлыкка тиңләсәк, безнең гомер шуның күзгә күренер-күренмәс миллиметры гына. Яшен тизлегедәй үткән елларың хакында кайгырып та куясың, ачынып утырган җиреңнән көлеп тә җибәрәсең: шундыен да кыска гомерле бу адәми затлар Җир өстендә нинди генә гамәлләр кылып өлгермиләр—бер-берсен алдыйлар, рәнҗетәләр, талыйлар, үтерәләр, бер гомер яшәү өчен бүтәннәр хисабына ун, егерме, хәтта мең гомерлек байлык туплыйлар, кабилә-кабилә сугышалар, яңадан-яңа кораллар, агулар уйлап табып, үзара яуга ашкыналар, бер-берсен күбрәк кырган саен куанышалар, маршлар уйнатып, кан һәм мәетләр өстенә басып җиңү бәйрәмнәре үткәрәләр... Кешелек бер-берсен ашап көн күрә торган һәм әз генә дә акылы булмаган микроблар, мыжгып яткан хәшәрәтләр мохите сыман. Менә шул бөтен вәхшилекне, рухи шакшылыкны төяп, үз күчәрендә бөтерелә-бөтерелә, орбитасы буйлап әйләнә-әйләнә һәрвакыт алга баручы Җир шарына җан ачысы белән:

—Туктап тор! Мин синнән төшеп калам!—дип кычкырасы килә.

...Нинди генә сәбәпләр табып сугышмаган Җир өстендәге кешелек: каршы яктагыларның тән тиреләре ак яки кара булган өчен дә, бер төркем икенчесеннән баерак булган өчен дә, диннәрендә, телләрендә, гореф-гадәтләрендә аерма булган өчен дә, хәтта ике патша теге яки бу сөяркәне үзенеке итәргә теләгәннән дә. Шулар өстенә яңа сәбәпләр табылып тора: болары—коммунист, тегеләре—фашист, без коммунизм төзибез, теге кабәхәтләр һаман саен капитализмны куәтлиләр, без чучка сөяге кимерәбез, тегеләр ат ите ашый, оятсызлар!.. Хәтта сөннәткә утырганнар һәм утырмаганнар арасында гына да күпме сугышлар булып үткән ләбаса бу дөньяда!

Шунысы гыйбрәтле, кешелек бер генә чорда да үткәннәрдән гыйбрәт алмаган, рухи сыйфатлары җәһәтеннән чыгып караганда, борынгы замандагы кыргыйлыгыннан, вәхшилегеннән бер адым да алга китмәгән һәм шул хәлдә XXI гасырга килеп кергән...

Әле кайчан гына (бер якта—НАТОлы Америка, икенче якта—Варшава килешүе дигән хәрби блоклы СССР исән чакта) дөньяның бер яртысы икенче яртысыннан өркеп яши иде. Инде, кайбер серләр ачылгач, мәгълүм булды: баксаң, зур мәмләкәтләрнең башлыклары атом-төш ракеталарының старт биру төймәләренә дә берничә мәртәбә үреләә башлаганнар икән. Ярый, анысы үтте: СССР да таркалды-бетте, аның тирәсенә тупланган дистәләрчә дәүләтләр дә Америка кочагына таба торып йөгерде, Россия дә коммунизмнан ваз кичеп, капитализмга күчте. Дошманлашуга, сугышка сәбәп тә калмады кебек. Бигрәк тә Америка өчен куркыныч бетте сыман. Империясенең бер өлешеннән генә түгел, социалистик бердәмлектәге дәүләтләреннән дә колак каккан хәлсез-зәгыйфь Россия хәзер АКШ өчен әзер калҗа гына: тели икән—бүген ашый, тели икән—сабыр итә...

Әйе, егерме беренче гасырның башыннан ук дөньяда тынычлык өчен бөтен

шартлар да әзер кебек иде. Кабатлап әйтәм, бу яңа гасыр иминлек һәм акыл белән эш итү гасыры булырга тиеш иде сыман. Ләкин инде хәзер үк иң куркыныч, иң дәһшәтле гасырга әйләнеп баруы шиксез. Әле ун-унбиш еллар чамасы элек кенә күп илләр, кыерсытылган милләтләр өчен таяныч һәм яклаучы булып тоелган Америка агрессия һәм явызлык чыганагына әверелеп китте. Ул хәзер урамда кем очраса шуны типкәләп, һич булмаса, куркытып-янап китүче пәһлевандай хулиганны хәтерләтә. Бер илне таптап чыга, икенчесенә, өченчесенә килеп керә, шул ук вакытта дүртенче, бишенчеләренең, алтынчы, җиденчеләренең язмышын шик астына куеп өркетә...

2001 елның 11 сентябрендә шартлатылган сәүдә үзәкләренең—110ар катлы йортларның җимерелеп төшүен шомланып, куркынып күзәткән чакта ук ни өчендер Германия рейхстагын яндыру вакыйгасын, бу янгынның мәкерле гамәл булуын искә төшергән идем. Менә алты ел чамасы инде әлеге шик зиһендә көчәйгәннән-көчәя бара: монда да шул ук рейхстаг тактикасы юкмы, аның нигезендә бөтен дөньяны дер калтырату, буйсындыру, күп илләрнең байлыгына хуҗа булу мәкере ятмыймы? Беренче карашка, шундый гигант йортларны махсус җимертү башка сыймый. Ләкин, бөтен дөньяга хуҗа булу максаты белән хәл ителсә, нәрсә генә инде ул өч-дүрт мең кешенең гомере һәм ике йорт бәясе?!

Шунысын да искә төшерик, шартлатылган йортларның ялкыннары да сүнеп бетмәгән һәм әле дөнья халкы һушына да килеп өлгермәгән бер мәлдә үк президент Буш бу афәтне ислам радикализмына, мөселман экстремизмына яга башлады. (Россиядән өйрәнде, ахрысы, Буш әфәнде: монда да, шартлау яңгырауга ук, уйлап та тормастан, «чечен эзе бу!» дип игълан итәләр.) Шуны гына көткән кебек, АКШның җитәкче даирәләре Осама бине Ладен исемен төрләндерергә керештеләр, аннары хор белән ислам дәүләтләренең «изгой»лыгын (мөртәтлеген) тәкърарлау китте, «явызлык күчәре» дип тамгаланган илләр саны ишәйде, планетадагы илләр Американың дус һәм дошманнарына бүленде һәм, әз генә вакыт үтүгә, Америка Әфганстанны бомбага тота башлады. Бәй, шунысын да бөтен дөнья аңлап алды: янкилар иленең башлыклары, басып алынган Әфганстанда «демократик тәртип урнаштыру», басып алучыларга ләббәйкә укып торучы курчак хөкүмәт кую максаты белән мавыгып китеп, әлеге сәүдә үзәген шартлатучы «иң зур җинаятьче бен Ладенны» да истән чыгардылар кебек. Шунысы да көлке һәм мәсхәрә бит әле тагын: Америка дөнья каршына бер кәҗә тәкәсенең ямьсезлеген сылтау итеп бөтен көтүне кырган дуамал бәндә сурәтендә чыгып басты. Нинди акыллы дәүләт яки ил башлыгы бер бөртек кешене тоту яки үтерү өчен миллионлаган кешене бомбага тота инде, җә?! Шул мантыйксыз гамәл хакында уйлана гына башлаган кешелекне яңа абсурд, ягъни тузга язмаслык хәл хәйран вә вәйран калдырды—шул ук Америка, койрыгына Бөекбританияне дә тагып, Гыйракны өркетә башлады. Имеш, анда бөтен дөньяга куркыныч янаучы атом-төш ракеталары тулып ята. Шулай итеп, анда да сугыш башланып китте. Баксаң, атом ракеталары бөтенләй юк икән!.. Ә булса? Булса, нәрсәсе гаеп? Америкага меңнәрчә ракеталар бик тә хаҗәт икән, башка шундый ук мөстәкыйль илләрдә ни өчен бөтенләй булмаска тиеш соң әле алар? Башка илләр, Америка утка тотканда, үлем көтеп кенә ятырга тиешләр микәнни?

Хәер, тагын бер «сәбәп» булган икән әле: янәсе, Буш Сәддам Хөсәенне яратмаган-өнәмәгән икән... Ә соң мәрхүм Хөсәен Бушны бик яратты микән?

Шулай итеп, ике стандарт белән фикер йөртүнең, бәя бирүнең һәм гамәл кылуның гадел булмавына үртәлгән кешелек Америкага карата симпатиясен тәмам җуйды...

Сүз дә юк, яраталармы аны хәзер, юкмы, АКШның дөньяга хуҗа булуы бәхәссез инде. Ул һәр илне үз кубызына биетә ала. Димәк, ул максатына ирешә булып чыгамы?

Дөнья сәясәтенең яфракларын гына күрә белгән, аның тамырындагы хәйләмәкерләрен, алдагы чорларга, дәверләргә юнәлтелгән ният-максатларын аңлый алмаучы беркатлы кешеләрнең бу сорауга «әйе» дип җавап бирүләре бик ихтимал. Яшермим, элегрәк үзем дә шундыйрак фикерләр тирәсендә генә әйләнә идем. Ләкин һәркемгә мәгълүм булган тарихны, дөньяда булып үткән бихисап сугышларны акылың белән үлчәп, бәяләп үткәрсәң, янә кешелекнең хәзерге вәзгыятьләрен анализлый белсәң, шактый шомлы һәм куркыныч нәтиҗәгә киләсең: Әфганстанда, Гыйракта, Палестинада барган бу сугышлар әле иксезчиксез урманга ташланган утлы шырпы гына икән.... Минемчә, ялкыннары, дөрләп

торган дәһшәтле янгыннары, зур афәтләре алда әле. Ягъни глобаль сугыш әле башланып кына килә. Аның максаты бу юлы биләмәләр яулап алудан һәм бериш дәүләтләрнең башка илләрнең биләмәләренә, байлыкларына, халыкларына хуҗа буласы килүдән генә гыйбарәт түгел. Бигрәк тә ислам динендәге халыкларга аңлар вакыт җитте: коммунизм белән капитализм арасындагы каршылыклар гына ятмый, җәмгать, алдагы бөтендөнья сугышында. Ничек кенә сәер яңгырамасын фикерем, ул һич кенә дә игътибарсыз калырга тиеш түгел: урта гасырларда сөнге, кылыч, гөрзи кебек примитив корал белән барган тәре походлары инде «цивилизацияле», атомлы шушы гасырда дәвам итәчәк...

...Гасырлар уза торгач, дөнья хәлләренең кай тарафка баруын аңлап алгач, ислам динендә булмаган дәүләтләрнең идеологлары, сәясәтчеләре, башлыклары зур хафага калды. Алар бер сорауга—«БУ ДӨНЬЯ КЕМГӘ КАЛА?» дигән сорауга җавап эзләп баш вата башладылар. Кайгырмаслык та түгел. Чөнки, нинди генә фәнни ачышлар ясамасыннар, нинди генә хәтәр сугыш кораллары уйлап тапмасыннар, хәлләр һич кенә дә алар файдасына бармый. Христиан динендәге кайсы гына илне мисал итеп алсак та, четерекле, куркыныч фактка тап булабыз: балалар аз туа, халык картая, илдә кеше саны кими... Америка, Швейцария кебек мул тормышта яшәүче илләрдә дә шул ук хәл... (Миллионнарча эмигрантлар агылу аркасында гына артык сизелми бу.) Сәбәбе күптән мәгълүм: ныклы һәм инандырырлык диннәре булмау, булганын да санга сукмау аркасында ул илләрдә кешелекнең иң изге һәм иң мөһим саналган кануннары да үтәлми. Әйтик, мөстәкыйль ислам дәүләтләрендә, хәтта ачлык афәте килгән елларда да, карындагы баланың гомерен кисү зур гөнаһ һәм җинаять саналса, тегеләрдә исә бала табу-тапмау «гаилә бюджетыннан чыгып көйләнә». Европа берлеге илләрендә дистәләрчә кешеләрнең гомерләрен өзгән бандитларга үлем җәзасы бирү кешелексез лек, рәхимсезлек дип бәяләнсә дә, тумас борын аборт ясап гөнаһсыз сабыйларны үтерү гадәти хәл санала...

Сүз уңаенда искә төшереп үтик: 2002 елда Россиядә үткәрелгән халык исәбен алу нәтиҗәләреннән күренгәнчә, сигез елга якын сугыш барган, йөз меңнәрчә кешесе кырылган бәләкәй генә Чечняда халык санының 1989 елдагыдан да артып киткәнлеге ачыкланган. Күпләр моны Россиягә хас алдау, күз буяу дип саныйлар. Ләкин бу мәгълүматның хаклыгы шик уятмый миндә. Чөнки Дудаев чорында ук, мөстәкыйльлеккә ирешүгә үк, бу республика шәригать кануннары белән яшәүгә күчте. Һәм шул кыска гына чорда да бу милләт ныгу, ишәю юлына кереп өлгерде. Ә инде Россиянең үз мисалына килсәк (якын чит илләрдән—элекке союздаш республикалардан урысларның күпләп кайтуына карамастан!), аның халкы ел саен миллионлап кими... Ә инде егерме-утыз ел дәвамында ук халыкның икеләтә кимиячәге фаразлана. Итәк астыннан гына йөри торган хәбәр булса, ышанып та бетмәс идең, әмма аны Кремль түрәләренең үз авызларыннан да ишетергә туры килгәли.

Христиан диненә караган илләрдә халыкның нык лап кимүенә илтүче башка сәбәпләр дә күп бит әле: эчкечелек, геометрик прогрессия белән көчәюче наркомания, җенси йөгәнсезлек тудырган сифилис, СПИД кебек авырулар, бандитлыкның арта баруы, агулы, радиацияле сугыш кораллары җитештерү аркасында бозылып беткән экология һәм шуның нәтиҗәсендә табигыйлектән нык авышкан ризыклар белән туклану... Әле бит Россия кебегрәк илләрдә ачлытуклы яшәү һәм кадерсезлек тә күпләп кыра халыкны. Ә инде иң куркынычы—рухи яктан таркалу.

Шөкер, мәҗбүри атеизм чоры үткәч, диннәр турында ирекле фикер йөртү хокукына иябез. Ләкин бер нәрсәне онытмаска тиешбез: шул ук Америка идеологлары, сәясәтчеләре авызыннан «исламизм—фашизм һәм терроризм ул» кебегрәк нахак ялаларны елдан-ел ешрак ишетеп яшәсәк тә, без мөселманнар бу җәһәттән сабыр булырга, башка халыкларның диннәре турында сак һәм хак сөйләшергә, мыскыллауга бармаска тиешбез. Ә инде фактларга таянып фикерләүнең, сөйләүнең гаебе юк. Мәсәлән, христианнар өчен һичшиксез изге саналырга тиешле Библия әйтә:«Үтермә!», ди. Әмма христиан динендәгеләр бу таләпне белмиләр дә кебек—дөнья халыкларын, үз ватандашларын чебен җаны итеп тә күрмичә кыралар, төрле илләргә басып керәләр. Шул ук Библия: «Урлашма!», ди. Бөтен христиан дөньясы караклык белән дан алган. Үзебез яши торган Россиягә килсәк, бу ил халкы бөтен миргә иң бур халык булып танылган һәм моның хаклыгын исбатлап тору да кирәкми—үзебез күреп тора-

быз. Шул ук Библия кисәтеп тора: «Зина кылма, уйнашлык итмә!», ди. Россиянең күп меңнәрчә хатын-кызы тән сатып тамак туйдыра. Россинең үзендә генә түгел бит әле бу... Хәзер күпме урыс хатын-кызы бөтендөнья зинахурлары өчен җанлы матрас булып хезмәт итә. Чит ил ирләре белән сөйләшкәндә шунысын да аңладым әле: алар бу фәхишәләрне «таптаганда» Россиянең үзен «таптыйбыз» дип тә күз алдына китерәләр икән...

Сүз уңаенда бик аз милләттәшләр генә белгән тагын ике-өч таләбен әйтеп үтим әле Библиянең: Бог (бу очракта тәрҗемәне урынсыз саныйм), Адәм белән Һаваның нәселе күзгә күренеп үрчи башлагач ук, күктән төшеп, Авраамны: «Бөтен нәселең-кабиләң сөннәткә утырган булсын дип кисәткән (Исход 14:5, 6, 7). Гаҗәпме? Гаҗәп! Бөтен дөнья турында әйтсәм, ялгышмагаем дип куркам, Христоска табынучы Россия халкы ул хакта белми дә кебек... Библия христианнарны дуңгыз ите ашаудан да тыя, «нечисты они для вас, не ешьте мясо их, и к трупам их не прикасайтесь» дип тә кисәтә (14:8). Шулай да иң күп һәм яратып ашаганнары чучка ите. «Үзегез ясаган нәрсәләргә, сурәтләргә табынмагыз, аларга баш имәгез», ди Библиядә Бог һәм катгый итеп өстәп тә куя:«... ибо я Господь, Бог ревнитель, наказывающий детей за вину отцов до третьего и четвертого родов, ненавидящих Меня... не делайте предо Мною богов серебряных или богов золотых», ди. Ләкин христианнар төкереп тә бирмиләр, күрәмсең, бу кисәтүгә—ниндидер Иванов, Петров, Рублев яки Сидоров ясагансылаштырган сурәткә баш ия-ия мең ел буе табыныпмы-табыналар... Әле бит, Богны үчекләгән кебек, үзләре ясаган «бог»ны алтын-көмеш белән бизиләр.

Дөрес, бездәге православный христианнарның кайбер төркемнәре бу заветларны үтиләрдер дә, бәлкем. Чөнки Россиядә генә дә православныйлар 3500 төрле (!) сектага бүленеп беткән икән һәм шуларның һәр төре калган 3499 төренә анафема, ягъни каһәр укый, аларның диннәрен ялгыш дип таба икән. Әле шунысы да бар: күп кенә урыс галимнәре Христос белән бәйле православие дине дә яһүдләр тарафыннан Россияне җимерү өчен махсус уйлап табылган дин, дип том-том фәнни хезмәтләр бастыра торалар, «бу дингә кадәр үк безнең үз динебез, үз аллаларыбыз булган» дип исбатлыйлар, урыс халкын православиедән бик ашыгыч ваз кичәргә өндиләр. Хәер, ул динне урыслар кенәз Владимир чорында кабул кылганнар бит. Аңа кадәр дә яһүдләр бу динне Владимирга хәтле аның атасы бөек кенәз Святославка да тәкъдим иткән булганнар. Ул аны: «Вера христианска—уродство есть» дип кире каккан.

Шөкер, без мөселманнар башка диннәргә карата сабыр. Иисуска да карикатура ясамыйбыз, Библиядән дә гаеп-хата табарга тырышмыйбыз, тыкшынмыйбыз. Бары тик бер нәрсәне аптырап һәм хәйран калып күзәтәбез: христианнар үз диннәрен санга сукмыйлар.

Укучының: «Карале, бу абзый сәяси тема башлады да, дингә күчте, диюе ихтимал. Шунсыз булмый! Христиан һәм ислам диннәрен аз гына булса да чагыштырмый торып бу мөһим теманы ачып бетерү мөмкин түгел. Чөнки, әйткәнемчә, елдан-ел көчәеп баручы Бөтендөнья сугышы—диннәр арасындагы сугыш турында бу язмам. Аеруча дәһшәтле һәм мәгънәсез сугыш, параноиклар башлаган сугыш...

Һәр мөселман Коръәннең һәрбер сүзен изге дип саный, үзенең яшәеш тәртипләрен, йолаларын, гамәлләрен Коръән таләпләре белән чагыштырып тора. Минем, мәсәлән, бер генә мөселман авызыннан да: «Нишләп бу Коръәндә менә шундый гаделсезлек бар икән?» дип дәгъвә яки ризасызлык ишеткәнем юк. Чөнки аны укыганда һәр аятьнең хаклыгын күңел «Дөрес! Дөрес!» дип хуплап тора. Чөнки Коръән нәкъ менә җаныбыз теләгән омтылышларны гына таләп итә: сафлык, гаделлек, татулык, үзара ярдәмләшү, башка халыкларны да хөрмәт итү, диндәшләреңә мәхәббәт, гаиләңдә татулык... Һәм инде, әлбәттә, иң тәүге чиратта, бинииһая соклангыч галәмне, үзебезне бар иткән Аллаһның бер һәм бар икәненә шиксез иман китерү! Ислам дәүләтләрендә (мин бу очракта шәригать кануннары белән яшәүче мөстәкыйль дәүләтләрне генә күздә тотам, чөнки башка кавемнәр коллыгындагы илләрнең үз кануннары белән яши алмавын Татарстаныбыз мисалыннан да аңлап торам) фәхешлек, караклык, хулиганлык, карындагы сабый җанын кыю, үзара үтереш, шакшылык, талау кебек яман гадәтләр була алмый диярлек—Коръән Шәриф саклый! Ләкин, ассызыклап әйтергә кирәк, Коръән динеңә, тынычлыгыңа, илеңә, гореф-гадәтләреңә, малмөлкәтеңә зарар китерүче, басып керүче дошманнарыңа каршы торырга кир-

әклекне дә катгый таләп итә! Кемнәрдер басып алучылардан, дошманнардан курка икән, иленең, диненең, гаиләсенең иминлеген саклый алмый һәм, җанын кызганып, алар кабаласында яшәүгә ризалаша икән, Аллаһы Тәгаләнең хөкеме билгеле: «аларның урыны җәһәннәмнең төбендә». Аннары фәкать шәригатьчә яшәүче илләрдә сугышта шәһит киткәннәрнең җаннары туп-туры җәннәткә күчәчәгенә дә шикләнеп караучы юк дәрәҗәсендә. Менә шуңа күрә дә бу илләрнең кешеләре илбасарларга каршы сугышканда һич кенә дә курыкмыйча, җаннарын саклау турында уйлап та тормыйча, шәһит китәләр—дошманнары белән бергә үзләрен дә шартлаталар. Хәтта илбасарлар тарафыннан нәселләре кырылган, фани дөньяда яшәүнең мәгънәсен тапмый башлаган хатын-кызлар да шундый тәвәккәллеккә барырга мәҗбүрләр...

Менә бу хакыйкатьләр Америка, Англия, Израиль кебек дистәләрчә дәүләтләрдәге агрессорларның котын ала. Көн саен диярлек ишетеп, телевизордан күреп торабыз: төрле-төрле бушлар, блэрлар, шароннар һәм башкалар, тынны бетеп, аларга «бандит», «террорчы», «камикадзе» шикелле ярлыклар тагалар, дөнья җәмәгатьчелеген шуңа ышандырырга маташалар. Ә бит террорчылар дип үз илләрен, үз азатлыкларын саклаучылар түгел, бәлки басып керүчеләр аталырга тиеш! Шул ук Америкага әфганнар яки гыйраклылар сугыш белән кермәгән ләбаса! Әнә, ничәмә-ничә еллар инде фәләстиннәр 1967 елда басып алынган җирләрен Израиль оккупантларыннан коткару көрәше алып бара. Танкларга каршы таш ыргытып кына сугышып булмаганын аңламыйлар түгел, шартлаткычлар да табарга һәм дошманнары арасына кереп үз-үзләрен шартлатырга да мәҗбүрләр. (Җәяләр эчендә генә булса да бу җәһәттән үз мөнәсәбәтемне белдерергә тиешмен: әгәр дә мәгәр яһүдләр фәләстиннәр җирен түгел, фәләстиннәр яһүдләрнең җирен басып алган булса, алар белән бер диндә булуыма карамастан, нәфрәтем фәләстиннәргә юнәлер иде. Чөнки бер генә халык та башка халыкны кысрыкларга тиеш түгел дигән иманымнан чигенә алмыйм.)

Әйе, христиан динендәге агрессив дәүләтләрнең башлыклары утлы табага баскан кебек өтәләнә хәзер: «Без елдан-ел кимибез, алар үрчи... Алар сугышта җаннарын да аямыйлар, чөнки диннәренә фанатикларча бирелгәннәр. Ә безнекеләр доллар хакына гына сугыша, гомерләренә куркыныч яный, армиядән качу ягын карый. Тарих болай дәвам итсә, бу дөньяның ислам кулына күчеп бетүе ихтимал ләбаса!..»

Аңламыйлар түгел:ислам дөньясын җиңә алмыйсың корал көче белән генә. Әнә, Гыйракка җиңел генә кергән американнар бер ай үтүгә үк җиңү игълан иткәннәр иде. «Гыйраклылар безне шатланып, бии-бии каршы алдылар» дип куанганнар иде. Хәзер инде капкынга төшүләрен тәмам аңладылар: «террористлар» янкиларны утлы табада елдан-ел шәбрәк биетәләр! Баксаң, гыйраклыларның алдан ук уйланылган тактикасы булган икән ул янкиларны каршылык күрсәтмичә генә илгә кертүләре. Шулай итмәгән булсалар, дошман иң көчле бомбалары белән Багдадны да тәмам җимереп бетергән булыр иде, урыслар Грозныйны юкка чыгарган кебек... Димәк, җирдә дошман белән күзгә-күз карап сугышу мәслихәтрәк!

Тагын бер коточкыч хәлне тәмам аңладылар заманча тәре походын көчәйтергә ниятләүчеләр: мөселманнарны корал белән генә җиңү, буйсындыру мөмкин түгел. Соңгы «исламист» һәлак булганчы сугышачаклар—Коръәннән тайпылмаячаклар. Инде янкиларның кулланмаган бер генә кораллары калды—атом-төш бомбалары. Аларны куллану да гамәли яктан һич отышлы түгел. Ул очракта Җир шары тулаем, димәк, үз илләре дә радиация белән агуланып бетәчәк. Хәер, аптыраган үрдәк күлгә арты белән чума дигәндәй, кулланулары да мөмкин, чөнки җиңә алмау хурлыгы, гадәттә, сугыш чукмарларын ярсуга, акыл югалтуга китерә... Ләкин атом бомбаларын үз илләре өстенә дә ташларга тиеш була бит әле алар, исламны ахыргача корытабыз дип тотынсалар. Америкада, Европа илләрендә мөселманнар хәзер шактый күп. Франциядә 6 миллион чамасы мөселман яши икән. Алар анда гаделсезлекләргә чыдый алмыйча үз көчләрен күрсәттеләр үткән кышта. Франция җитәкчеләренең, полиция һәм армиясенең коты алынды, шәһәрләре ялкынга урала башлагач... Әгәр дә диннәр арасындагы сугыш көчәя калса, Европа илләрендәге, Америкадагы йөзләрчә миллион мөселман берьюлы күтәрелмәс дип кем ышандыра ала?..

Ләкин христиан дөньясы лидерларының һәм идеологларының тагын бер мәкерле «коралы» бар: «демократия». Һәрдаим ишетеп торабыз: Гыйракка да,

Әфганстанга да, Иранга һәм хәтта Ислам мәркәзе булган Сөгуд Гарәбстанына да «демократик тәртипләрен» көчләп кертергә ниятлиләр. Хәйләсен аңлаган кешеләр өчен әлләни катлаулы түгел: ислам илләре халыкларын «ирекле иту». Әйтик, шактый ислам илләрендә караклык өчен таяк белән кыйнау, бармак кисү, кул кисү кебек җәзалар кулланылу беркемгә дә сер түгел. Шуңа күрә аларда кемнеңдер нәрсәседер урлану—гадәттән тыш хәл. Бик тә сирәк хәл! Ягъни башка сыймаслык гөнаһ. Кайбер гарәп илләрендә милиция-полиция кебек хезмәтләр дә юк. Җинаятьләр булмагач, нәрсәгә кирәге бар аларның?! Әнә, аңладык инде, Россия агентлары Ичкериянең Катар дәүләтендә яшәүче элекке президенты Яндарбиевны барып үтергәч һәм шул җан кыючылар кулга алынгач, Катарның хокук саклау органнары бөтенләй каушап калганнар. Баксаң... кеше үтерүчеләргә карата кулланыла торган маддәләре дә булмаган икән аларның җинаять кодексында. Чөнки "демократ" урыслар кереп кан койганга кадәр кеше үтерү очрагы үзе булмаган. Моны ислам динен дошман күргән илләрдәге президентлар, сәясәтчеләр, юристлар «Катарның җинаять кодексы камил түгел» дип бәяләделәр. Шуннан соң инде әлеге дәүләт үтереш очрагына махсус закон чыгарырга мәҗбүр булды. Ә үзен демократик ил дип санаучы безнең империядә «иртән чыгып китеп, кич өенә кайтмаган», ягъни хәбәрсез-нисез югалган гади гражданнар гына да ел саен 200 меңнән артып китә икән. Әле бит бу илдә зур байлык өчен генә түгел, йөз грамм аракы өчен дә көн саен дистә меңнәрчә кеше бугазлаша, кайбер ирләр дистәләрчә хатын-кызны көчлиләр, аннары суялар. Әнә телевизор, замана герое турында сөйләгәндәй, хәбәр бирә: бер ир 109 яшь кызны сафлыгыннан мәхрүм иткән. Икенче бер егет аламасы 67 кызны көчләгән һәм хайвани ләззәттән соң үтерә барган.

Әйе, ислам дәүләтләрендә җинаятьнең җәзасы да меңнәрчә, миллионнарча кешеләр өчен гыйбрәт булырлык. Зина кылу, эчкечелек, наркотиклар куллану кебек гамәлләр өчен дә кырыс җәзалар кулланыла шәригатьчә яшәүче илләрдә. Үтерү очрагы була-нитә калса, үтерүче инде үзе дә яшәү хокукын югалта. Ислам дөньясының дошманнары бу илләрдәге халыкларның рухи сафлыгын, кешеләр арасындагы соклангыч мөнәсәбәтне, үзара гаделлекне, туганнарча ярдәмләшүне күреп кара көяләр. Шушы матур сыйфатларны җимермисең икән, христиан дөньясы бозыклыклар афәтеннән кырылган бер заманда ислам илләре халыклары рухи, матди җәһәттән дә, сан ягыннан да үсеп, көчәеп торачак! Димәк, дөнья да ахыр чиктә аларга калачак. Ә инде «демократия кертсәң», шәригать законнарын какшатуга ирешсәң, бу илләргә дә зинахурлык юлдашы булган венерик авырулар, абортлар, алкоголизм, караклык, бандитлык ташкыны агылып керәчәк... Кеше психологиясен дә белмиләр түгел «демократлар». Мәгълүм ки, һәркемнең эчендә игелеккә омтылыш булган кебек, азгынлык шытымнары да бар. Бозыклык канат җәйсә, дәүләт һәм милләт тә таркалуга, тулы деградациягә дучар була. Кыскасы, Алла мәсләгеннән аерылган халык шайтани көчләр кочагына керә... Шайтан коткысы өстенлек ала икән илдә, танкларың, бомбаларың, химик һәм бактериологик коралларың белән дә котылу юк! Хәер, мисалларны ерактан эзлисе түгел: күпме генә милләтләр һәм илләр юкка чыкмаган бозыклыклар империясе Россиядә. Кызганыч ки, үзебезнең дә, ягъни татарларның да хәле кызыгырлык түгел бу җәһәттән—кяферләргә нинди азгынлыклар хас булса, бездә дә шулар ук диярлек... Хикмәт шунда гына: кайчанга кадәр дәвам итәр бу? Татар бөтенләй беткәнчеме? Әллә соң котылу өчен ныклап иманга кайту форсаты да бармы әле? Язмышыбызны үзебез хәл итәргә тиешбез ләбаса!

...Әйе, дәһшәтле тәре походы көчәя бара. Аллага, Коръәнгә таянган халыкларның фидакарьлеген аңлаган саен «демократик» мәмләкәтләрнең башлыклары рәхимсезрәк чаралар, ысуллар уйлап табалар. Ни хәл итмәк кирәк, үткән гасыр ахырында, монысының башында зур дәүләтләр агрессив һәм дини шовинизм белән агуланган президентларга тап булды. Аларның фикерләре һәм максатлары да күп җәһәттән уртак: имеш, дөньякүләм террористларга каршы көрәшәләр. Тапкан-белгән террористлары һәрвакыт мөселманнар булып чыга... Христиан дөньясында исламга карата нәфрәт тәрбияләү идеологиясе кызганнан-кыза...

Ахыры нәрсә белән бетәр мондый катаклизмның, бу дөнья кемгә калыр? Диннәр арасында тудырылган сугыш нинди генә дәрәҗәгә җитмәсен, бер як та җиңүгә ирешмәячәк, әлбәттә. Бу сугыш та ахыр чиктә тарих алдында

мәгънәсез һәм хурлыклы сугыш булып бәяләнәчәк. Чөнки, ни хикмәттер, илләр башына дуамал, кайнар башлы җитәкчеләрдән соң зирәкләре, сабырлары килүчән. Күрәмсең, халыкларның саташулы чордан, афәт дәһшәтеннән, кан исе аңкып торган сәясәттән гайрәтләре чигәдер, тыныч тормыш итүгә ышаныч тудырырдай башлыклар сайлауга ирешәләрдер. Ничек кенә булмасын, якындагы ике-өч елда ук дөнья тынычлык чорына керер дип өметләнәсе килә. Күпмегә барыр ул? Бу сорау үз урынында кала... Әмма шунысы хак һәм шиксез: дошмани яктан күп янаулар күрүче, биниһая афәтләр кичерүче ислам дөньясы тагын да сизгерләнә, тәвәккәллеген ныгыта бара. Ул бөтен дөньяга хуҗа булырга җыенмый. Ләкин үзе дә башка диндәге көчләргә буйсынып яшәмәячәк. Чөнки Аллаһ «сугышырга килгән *(басып кергән дигән мәгънәдә.—Ф. Б.)* кяферләргә каршы аяусыз булырга, алар сугыш коралларын куйганга чаклы сугышырга» куша. *(Мөхәммәд сүрәсе, 4нче аять.)* Коръәндә болай дип тә әйтелә: «Аллаһуга гына гыйбадәт кылыгыз, башка һичбер затка коллык кылмагыз...» *(Комлык сүрәсе, 21нче аять.)* Ник, гадел түгелмени бу аять? Гореф-гадәтләреңне, туган телеңне, газиз җиреңне, максат-иманыңны, гадел кануннарыңны пычрак чабатасы яки итеге белән таптап кергән, милләтеңнең канын дәрья итеп түккән һәм Алла биргән байлыгыңны талап яшәячәк ике аяклы иблисләргә кол булу мактаулыракмыни? Әйтик, һаман-һаман демократия дип авыз корыта кайбер оккупантлар һәм агрессорлар. Бу сүзне чын мәгънәсе белән аңлыйбыз икән, демократия ул халык власте һәм гаделлек дигән сүз. Димәк, иң демократик, иң гадел дәүләтләр ислам дәүләтләре икән бит! Әйтик, бары тик ислам илләрендә генә Ходай биргән җир асты байлыклары һәр кешенең уртак байлыгы санала. Яңа туган сабыйның да, бүген-иртәгә вафат булачак картларның да, гади кешенең дә, ханнар-әмирләрнең дә өлешләре тигез бу җәһәттән. Чөнки акчасы тигез бүленә. Димәк, Коръән кушканча! Шуңа күрә ул илләрнең халыклары гадел кануннар хакына җан бирүдән дә курыкмыйлар. Беләләр: динең, телең, халкың һәм азатлыгың булганда гына үзеңне хайваннан өстен тоярга һәм үзеңне кеше дип санарга хаклысың!

Демократия дип дөнья сасытучы агрессорлар нәкъ менә ислам илләрендәге чын демократиядән куркалар икән бит! Шул ук Америкада, Англиядә, үзебез көн саен күреп торган Россиядә халыкның уртак байлыгы, урысчалатып әйтсәк, кемнәргәдер—полный куш, халыкның зур өлешенә—кукиш: намуслы халык ачлыктан, чирдән кырыла, хакимлек итүчеләр һәм аларның яраннары хезмәт кешеләрен, ач балаларны мыскылый-мыскыллый, долларлар диңгезендә коена. Димәк, христиан илләренең үзләрендә демократия, кеше хокуклары, гаделлек бөтенләй юк булып чыга түгелме соң?! Шулай икән, алар башлаган сугышны да явызлыкның, оятсызлыкның изгелеккә һәм гаделлеккә каршы сугышы дип кенә аңлый алабыз. Инде дә «Бу дөнья кемгә кала?» дигән сорауга җавап бирү нияте белән кабат бер мәртәбә уйлансак, ышаныч белән әйтә алабыз: «Гаделлек белән яшәүче халыкларга калачак!» Ләкин моны нәкъ менә «ислам динендәге халыклар җиңәчәк!» дигән мәгънәдә аңларга ярамый. Бер көн килеп, хәзергә Богларын, изге Библияләрен, гаделлекләрне санга сукмаучы халыклар да иманга килер, тирания, кан кою, талау, фәхешлек кебек меңнәрчә яман гадәтләрдән арынып, сафланыр дип өмет итәргә тиешбез. Чөнки, башка диндәге халыклар мәҗбүр итмәсә, Коръән тоткан милләтләр бер генә илгә дә яу белән, яман ният белән кермәячәкләр.

...Акыл ияләреннән кайсыдыр: «Өченче бөтендөнья сугышыннан соң җиңүчеләр булмаячак», дигән имеш. Ягъни кешелек бетәчәк... Дини, милли каршылыкларны көчәйтеп, ул сугышны тудыручы ил башлыклары да аңларлар әлеге зирәк кәлимәне... Без, гади кешеләр, шуңа гына өметләнә алабыз. Бәлки диннәр арасында баручы бу сугыш та озакка сузылмас—бетәр? Әмма... кызганыч ки, башланган сугыш бетми ул, туктап кына тора. Шуңа күрә кешелек уяулыгын җуймаска, афәтләргә каршы тору өчен һәрвакыт әзер булырга тиеш.

# АКСАКАЛ ӘДИПЛӘРЕБЕЗНЕҢ БЕРСЕ

Моннан житмеш еллар элек үк Казандагы мәшһүр Матбугат йортының (Бауман урамы, 19) Тукай клубында язучыларның җыелышлары, төрле кичәләре, юбилей бәйрәмнәре һәм башка чаралар үткәрелеп киленгән. Сугыштан соң, бигрәк тә 50 нче еллардан соң, клуб эше тагын да тернәкләнеп, җанланып китә. 60 нчы еллар башында язучыларның бу клубында аена бернічә мәртәбә әдәби-музыкаль кичәләр уза иде. Татарның атаклы шәхесләре катнаша иде ул кичәләрдә. Биредә, шулай ук, әдәбиятка, сәнгатькә юл ярырга омтылган яшь-җилкенчәкләр дә күп була иде. Университетта һәм пединститутта укучы байтак студент-шагыйрьләрнең халык алдында беренче җитди чыгыш ясап, «чиркәнчек алулары» да шушы кичәләрдә булды. Ул елларда мондый зыялы аудитория бүтән җирдә юк иде дә бугай. Шуңа күрә, гадәттә җомга көннәрендә уздырыла торган ул кичәләрне күпләр көтеп ала иде. Кемнәрне генә очратмый идең анда! Нәкый Исәнбәт, Бакый Урманче, Мәхмүт Бөдәйле, Риза Газизов, Хәй Хисмәтуллин кебек XIX гасырда ук туган өлкән кешеләр дә; ул вакытта ук классик саналган, иҗатлары дәреслекләрдән өйрәнелгән Гомәр Бәширов, Хәсән Туфан, Афзал Шамов, Шәйхи Маннур, Ибраһим Гази, Әмирхан Еники, Габдрахман Әпсәләмов, Сибгат Хәким..; классик ук саналмасалар да һәммәбез өчен абруйлы фронтовиклар—Салих Баттал, Гали Хуҗи, Мөхәммәт Садри, Әнвәр Давыдов, Зыя Мансур, Шәрәф Мөдәррис... Биредә мәдәнияткә битараф булмаган өлкән һәм урта буын кешеләрен дә, авылдан килеп, тиз генә Казанның мәдәни төркеменә керергә ашкынган яшьләрне дә, әлбәттә, күзләү органнары вәкилләрен дә күрергә мөмкин иде. Инде илле еллап вакыт узса да, шунда катнашкан байтак кешеләрнең гәүдә-кыяфәтләре, йөз чалымнары әле дә күз алдында.



Залда даими булып, бер кичәне дә диярлек калдырмый торган бер кешенең төс-кыяфәте шактый ук ачык булып хәтердә калган. Безгә инде өлкән тоелган (үзебезне булачак шагыйрьләр дип йөргән күпләребезгә ул чакта әле егерме дә юк, ә ана инде (!) утызлар тирәсе) бу кеше нишләп йөри монда? Безнең кебек сәхнәдән чыгыш та ясамый, килгән тамашачылар белән дә бик аралашмый... Безнең як кешесенә охшаган да, охшамаган да кебек. Аксыл йөзле, кысынкырак күзле. Борынгы бабаларыбызның бишеге булган Алтай ягы кешеләренә тартым... Кем бу? Яшь чак, төпченеп торырга вакыт та юк. Бу дөньяның кеме булмас!

Алты-җиде еллар үткәч әлеге кешенең кем булуы яхшы ачыкланды. Ул—Хәмидуллин Лирон Хәйдәр улы булып чыкты. Сугышта һәлак булган фронтовик баласы. Гомере буе татар дөньясы даирәсендә әвәрә килгән милләт улы. Язучы. Хуҗалык эшләрен яхшы оештыручы. Бүгенге көндәге статусы—татар әдәбиятының аксакал әдипләреннән берсе. Кемнәр ничек кабул итәр—анысы икенче мәсьәлә—бу минем шәхси билгеләмәм. Лирон ага Хәмидуллин турында үз фикеремне ачык итеп әйтергә хакым да бар кебек: чөнки ярты гасырлап аның белән азмы-күпме аралашып яшәлде, өч-дүрт ел Язучылар берлеге аппаратында бергә эшләп тә алдык әле. Лирон аганың, иҗатыннан тыш, минем өчен кызыклы, кирәкле бер ягы бар: язучылар тормышының тышкы ягын да, эчке хәлләрен дә шактый ук яхшы белә.

Унбиш елдан артык СССР Әдәби фондынын Татарстан бүлеген житәкләде. Ул оешманын төп вазифасы—язучыларнын матди базасын кайгырту иде. Ягъни, каләм ияләренен ижатын стимуллаштыру, шартлар булдыру, ярдәм итү. Кемгә фатир, кемгә санаторийга яки ижат йортына путевка-юллама кирәк. Кемгәдер шатлык килгән, кемнедер кайгы сарган... Юбилей-бәйрәмнәре дә, үлем-китем мәшәкатьләре дә, кунак каршылау-озатулар да, гомумән, язучылар яшәешендә төрле хәлләр, һәммәсе Әдәби фонд катнашында уза иде. Әдәбиятнын җәмгыятькә кирәк, язучыларнын кадерле чаклары иде ул еллар! 60 нчы еллардагы язучылар тормышын яхшы белгән кешеләр бик сирәк калды хәзер. Яше 75-80 нәргә житкәннәр ике дистәдән артмый. Аларнын һәммәсе дә язучылар тормышынын үзәгендә—казанында кайнамаган бит әле! Редакциядә еш кына үткән гасыр урталарына яки аннан ераграк елларга караган язмалар, фотосурәтләр белән эш итәргә, редакцияләргә туры килә. Кайчак теге яки бу фактны төгәлрәк ачыклыйсы, теге яки бу сурәттәге кешене таныйсы, кемлеген beләсе килә. Кемнән сорарга? Кем белергә мөмкин? Р. Мостафин? М. Госманов? Ш. Галиев? Л. Ихсанова? Алардан яшьрәкләрдән—Батулла? Г. Рәхим? Р. Харис? Менә шундый чакларда Лирон ага Хәмидуллинга мөрәҗәгать итәм мин. Шөкер, күп чакта сорауларыма җавап та табам. Язучылар берлеге тарихын чагылдырган, «Гыйбрәтле үткән юл» дигән хезмәтемне язганда һәм бүтән очракларда (мәсәлән, «Аккош күле» ижат йорты турында материаллар туплаганда) өлкән каләмдәшемнен ярдәмен күп тойдым. Шуна күрә, мин аны әдәбиятыбызнын сирәк калган аксакал әдипләреннән берсе дип саныйм.

Лирон Хәмидуллин (Л. Хәйдәр) турында библиографик әдәбиятта беркадәр белешмә-материал булса да (мәсәлән, Р. Даутов һәм Н. Нуруллина әзерләгән «Татар совет язучылары» китабы, 1984), анын тормышы һәм ижат юлы турында кин катлам укучылар тиеш кадәр белмиләр дип уйлыйм. Шуна күрә анын хакында беркадәр мәгълүмат биреп китү урынлы булыр.

Лирон Хәйдәр улы Хәмидуллин 1932 елнын 10 ноябрендә Ульян өлкәсенен Яна Малыклы районы Иске Төгәлбуга авылында хезмәткәр гаиләсендә туа. 1941 елда шул авыл мәктәбенә укырга керә, башлангыч белемне анда ала. Унбер яшьтән әнисе туган Иске Белогор авылында (Оренбург өлкәсе) яшәп жидееллык мәктәпне тәмамлый. Аннары укуын Казакъстаннын Актүбә шәһәрендә тимерьюлчылар техникумында дәвам иттерә. 1951-54 елларда Мәскәүне һава һөҗүменнән саклаучы гаскәрдә радиолокаторчы булып хезмәт итә. Аннан кайткач Орск (Оренбург өлкәсе) шәһәрендә төп белгечлеге буенча эшли. Мәскәү политехника институтынын Орск филиалында югары техник белем үзләштерүен дәвам иттерә (1960 елнын июлена чаклы дүрт курс тәмамлый). Шул елда Уфа университетынын татар филологиясе бүлегенә керергә талпынып карый. Һәм ярты ел чамасы шул шәһәрдә эшләвен дәвам итә. Орск шәһәрендә яшәгәндә татар-башкорт яшь һәвәскәрләре белән бергә әдәби-музыкаль кичәләр оештыруда катнаша.

1961 елдан Казан шәһәрендә яши.

1961-67 елларда шәһәр транспорты оешмасында тимер юл бүлеге инженеры, баш инженеры, партком секретаре була.

60 нчы еллар урталарыннан башлап Л. Хәмидуллиннын тормышы турыдан-туры әдәбият, язучылар даирәсе белән бәйле. Әдәбиятка бирелгән, шул ук вакытта хуҗалык эшләрендә дә зур тәҗрибә туплаган ир-егетне Язучылар берлеге аппаратына эшкә чакыралар.

Л. Хәмидуллин 1967 елдан СССР Әдәби фондынын Татарстан бүлеге директоры. Ул дәртләнеп яна эшкә керешә. Ә яна эш дигәннәре шактый ук дәвамлы булып чыга. Уналты ел эшләү дәверендә, Язучылар берлеге идарәсе рәисләре Мирсәй Әмир, Ибраһим Гази, Зәки Нури һәм Гариф Ахунов белән бергәләп язучыларнын тормыш-көнкүрешен җайлауда байтак игелекле гамәлләр башкарыла. Әдәби фондның Мәскәүдәге житәкчеләреннән дәлилләп-даулап алынган акчалар исәбенә берничә дистә язучының фатир шартлары унайлаштырыла.

Лирон Хәмидуллин 1977 елны СССР Язучылар берлегенә әгъза итеп кабул ителә. Бу инде җәмәгатьчелекнең аны язучы итеп тануы дигән сүз. Бу урында, әдипнең ижади хезмәтләре турында тәфсилләбрәк сөйләү алдыннан беркадәр ретроспектив

планда чигенеш ясап алу кирәктер. Һәрбер аерым язучы хакында уйланганда, гомумәдәби хәрәкәт турында фикер йөртми мөмкин түгел.

Еш кына татар әдәбиятын Зур Иделгә тиңлиләр. Иделгә төрле тарафлардан эреле-ваклы бихисап күп елгалар һәм чишмәләр килеп кушыла. Аларның куе урман төпкелләреннән каралып агып чыкканнары да, тигез-иңкүлек яктан сабыр гына агып төшкәннәре дә бар. Һәрбер елгачыкның үз куәте, үз төсе һәм тәме булган кебек, татар әдәбиятына төрле тарафлардан килеп кергән иҗат әһелләренең дә үзләренә генә хас сыйфатлары һәм үзенчәлекләре сизелеп тора. Әйе, Зур Иделгә тиң татар әдәбияты мохитына килүчеләр дә язмышлары һәм иҗатлары белән төрле-төрле. Бигрәк тә бу төрлелек узган гасыр әдәбиятына хас иде. Аңа төрле тарафлардан үзенчәлекле үз биографияләре һәм тормыш тәҗрибәләре белән бик күпләр килеп кергән, илһамланып иҗат иткән. Өлкән буын әдипләребезне тудырган җирлек бик киң. Күренекле язучылардан Шәриф Камал белән Кәрим Тинчурин Пенза губернасында, Габдрахман Әпсәләмов белән Һади Такташ «Тамбов урманнары» төбәгендә туып-үскәннәр. Гадел Кутуй мәктәп тәрбиясен Самарада, Сәгыйть Рәмиев, Шамил Усманов һәм Муса Җәлил Оренбург шәһәрендә алганнар. Ибраһим Салахов, Нури Арслан, Мәхмүт Хөсәен ерак Казакъстан җире балалары. Әнвәр Давыдов белән чордашым Рөстәм Миңгалим күрше Самара өлкәсе авылларыннан. Себер-Урал тарафларында үскән Сәрвәр Әдһәмова белән Абдулла Әхмәт, Нижгар якларында туган Кави Нәҗми һәм башка бик күпләр татар әдәбияты мохитына урау юллар белән килгәннәр. Ләкин шунысы хак—башлангыч милли белемне алар үз туган төбәкләрендә үзләштергән шәхесләр. Үз авылларында, үз калаларында башлангыч белем алгач кына Казан җирлегендә белемнәрен камилләштерә төшеп, язучы буларак танылганнар. Хәзер Татарстаннан читтәге төбәкләрдән (Башкортстанны санамаганда) килеп, татар әдәбияты дөньясына кереп китә алырдай каләм әһелләре бик сирәк. Чөнки ул төбәкләрдә хәзер татар мәктәпләре бетерелгән, бик күпләр өчен үз милли телендә белем үзләштерү мөмкинлеге бик тә чикләнгән. Никита Хрущевның милли мохтариятлардан читтә урнашкан мәктәпләрне ябуга юнәлтелгән мәгълүм карары чыкканчыга чаклы үз телендә бераз булса да белем үзләштергән кайбер олырак буын вәкилләре генә ара-тирә күренгәләп куя. Шундый язмышлы язучылардан без бүген берничә исемне генә атый алабыз. Алар арасында Лирон ага Хәмидуллин да бар. Әйе, быел җитмеш биш яшен тутыручы язучы Лирон Хәмидуллин әнә шундый соңгыларның берсе инде.



*Уңнан: Лирон һәм Булат Хәмидуллиннар, академик Миркасыйм Госманов, тарихчы галимнәр Шамил Мөхәммәдъяров һәм Искәндәр Измайлов. 2002 ел.*

Әдәби фондтагы хезмәтеннән соң Л. Хәмидуллин ун елдан артыграк вакыт Татарстан китап нәшриятында матур әдәбият мөхәррире булып эшләде. Татар укучысы кулына кергән йөз иллеләп китапның саф әдәби телдә, зәвыклы булып чыгуы өчен тырышты. 1998—2005 елларда Татар энциклопедия институтында өлкән фәнни хезмәткәр вазифасын башкарды. Энциклопедияләрнең татар телле вариантын әзерләп чыгаруда катнашты. (Энциклопедик сүзлектә һәм томнарда егермеләп үз мәкаләсе дә бар.)

Аңа 1982 елны Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре дигән мактаулы исем бирелде.

Лирон Хәмидуллинның әдәби әсәрләре алтмышынчы еллар урталарыннан күмәк әдәби җыентыкларда, газета-журнал битләрендә күренә башлый. Яшь һәм башлап язучыларның «Яшьлек таңы», «Кайнар хисләр» җыентыкларында дөнья күргән һәм башка хикәяләре җирлегендә 1968 елда аның беренче хикәяләр китапчыгы басылып чыга. 1971 елда тимер юл төзүчеләр тормышын сурәтләгән «Дала иртәсе» повесте басыла. Бу китапларда дөнья күргән әсәрләргә карата үз вакытында вакытлы матбугатта уңай фикерләр әйтелә. Мәсәлән, 1972 елда басылган бер мәкаләсендә Хәсән Сарьян, каләмдәше иҗатына тукталып, түбәндәге сүзләрне яза: «Бүген үк инде күз уңыннан төшермәс яшь иҗатчыларыбызның берсе—Лирон Хәмидуллин. «Дала иртәсе» повесте аның икенче китабы... Әдәбиятка ул, кайбер яшьләребез кебек, институт яки университетның филология факультетыннан гына сикереп төшми, ә тормышның эченнән үз дөньясы белән килә. Бу да язучы өчен бик кирәкле шәйдер... Автор күзәтә белә, шул күзәтүләрен детальләр аша уйлый белә, шуларга үз сүзен таба белә».

Проза үзенчәлекләрен яхшы белүче әдәбият тәнкыйтьчесе Фәрваз Миңнуллин да соңрак язучы Л. Хәмидуллин хикәяләрен уңай бәяләп язды. Аның 1989 елда нәшер ителгән «Затлылык» китабында мондый юллар бар: «Матур әдәбият дөньясында «Бу мин» дип, әллә каян кычкырып торган талантлар арасында һәрвакыт тыныч һәм салмак кына үз эшен эшләп, шунардан тәм һәм ямь табып яшәүче тыйнак язучылар була. Лирон Хәмидуллин—шундыйларның берсе. Ул безнең әдәбиятның күгәрчен күзе үләне... Әйбәт тәрҗемәче булу белән бергә, Лирон Хәмидуллин үзенчәлекле прозаик та... Үзенчәлеге нидән гыйбарәт? Ышандырырлык һәм тормышчан булулары өстенә, аның әсәрләрендә тел белән сөйләп, аңлатып бирүе кыен булган, әмма укучыны иләсләндерә, аның күңелен нечкәртә торган үзгә бер моң, настроение, эчке көй бар. Әйтик, «Кыш үткән юл буйлап»... яки «Буранда» хикәяләрендә...»

Л. Хәмидуллин үз иҗади эшчәнлегенең кимендә яртысын тәрҗемә эшенә багышлагандыр, мөгаен. Шуңа күрә аның ул өлкәдә башкарган кайбер хезмәтләрен дә барлап үтү кирәк шәйдер. Заманында, ягъни Язучылар берлегендә эшләү дәверендә, аңа кардәш әдәбиятлар белән элемтә тоту, тәрҗемә эшен җайга салу бурычлары да йөкләнә. Ун ел чамасы ул тәрҗемәчеләр секциясе җитәкчесе булып эшли. Җитмешенче, сиксәненче елларда ул Казакъстанда татар повестьлары китабын, Үзбәкстан белән Каракалпакстанда хикәя җыентыкларын туплап чыгара. Күренекле казакъ әдипләреннән Абайның шигырь һәм чәчмә хезмәтләре җыентыгы «Абай»ны, Әнүәр Әлимҗановның ике повестен берләштергән «Отрар хатирәсе» китабын, Сайн Моратбәковның повесть һәм хикәяләрен туплаган «Әрем исе» җыентыгын, Мохтар Магауинның «Кара кыз» повестен, үзбәк телендә иҗат итүче милләттәшебез Әсгать Мохтарның «Чинара» романын татар укучысы бүген Лирон Хәмидуллин хикәяләвендә укый. Мәшһүр белорус әдибе Василь Быковның сугыш темасына багышланган ике повестен берләштергән «Һәйкәл» китабы да Лирон аганың зур хезмәте булып саналырга лаек.

Бу уңайдан тәрҗемә турында язучының үз фикерләрен искә алып узу да кызыклы. Бүгенге көндә милли телләргә тәрҗемә итү эше бик актуаль һәм шул ук вакытта бәхәсләргә дә сәбәп булган мәсьәлә. Моннан берничә ел элек, хәбәрченең «Татар укучысына бүген дә тәрҗемә әсәрләре кирәкме?» дигән соравына Лирон аганың җавабы мондый: «Бик кирәк. Бер генә әдәбият та үз-үзенә бикләнеп кенә яши алмый, һәркемгә башкалар белән көндәлек аралашу зарур булган кебек, әдәбиятлар да үзара аралашмыйча зур уңышка ирешә алмый. Ә казакъ әдипләре әсәрләренә өстенлек бирелүнең ике сәбәбе бар. Беренчедән, авыл мәктәбеннән соң мин дүрт ел Казакъстанда укыдым, казакъ яшьләре белән дә аралаштым. Икенчедән, мәктәп елларыннан бирле мин тарихи әдәбиятка өстенлек бирә килдем. Борынгы төрки дөнья мине элек-электән кызыксындыра. Татар әдәбиятында төркиләр тарихын чагылдырган әсәрләргә юл ябык булган елларда казакълар бу өлкәдә алга баралар иде. Шул сәбәпле мин иң әүвәл казакъ әдәбиятына мөрәҗәгать иттем... Бүген дә тәрҗемә әсәрләре бик кирәк. Шул ук төркиләр тарихына багышланган әдәби яки иҗтимагый эчтәлекле күпме китап басылып чыга хәзер. Бездә аларны язардай

әдипләр дә, галимнәр дә сирәк. Ул өлкәне яхшы белеп һәм бирелеп эшләгән Миркасыйм Госманов, Нурихан Фәттах, Мөсәгыйт Хәбибуллиннар гына ул эшне башкарырга өлгерә алмыйлар».

Тарих һәм әдәбият галиме, академик Миркасыйм Госманов Лирон аганың эшчәнлегенә багышланган мәкаләсендә болай дип яза: «Анын әдәби иҗатында махсус тәкъдир итүгә лаек бер юнәлеш бар. Ул—элекке чор күренекле әдипләребезнең тормыш юлларын, мирасын өйрәнүгә багышланган эзләнү һәм бастырып чыгару эшләре. Мәгълүм драматургыбыз Мирхәйдәр Фәйзи белән атаклы шагыйребез Дәрдемәнд хакында махсус эзләнүләр башкарылу, шул максат белән алар эзеннән йөреп, Башкортстандагы Жиргән, Юлык авылларына, Баймак шәһәренә барып чыгулар, Чиләбе өлкәсендәге Балкан, Требия авылларында, Уфа, Оренбург шәһәрләрендә эзләнүләр, әлеге әдипләрнең оныкларын, туганнарын эзләп табу, алар белән хат алышулар, ниһаять, архивларда казынулар. Шулар нәтиҗәсендә җәмәгатьчелек игътибарын җәлеп иткән «Офыктагы рәшәләр» китабы һәм «Галиябану туган якларда» исемле юлъязмасы барлыкка килә... Бал корты кебек гел эзләнүләрен, шау-шусыз гына нәтиҗәле эшләвен дәвам итә.»

Әйе, Оренбург өлкәсенең Орск шәһәрендә эшләү дәверендә үк Лирон Хәмидуллин тормыш-яшәешләре шул шәһәргә бәйле булган кайбер олуг шәхесләрнең иҗаты һәм мирасы белән кызыксына, аларны белгән кешеләр белән аралаша. Шул рәвешле үзенчәлекле шагыйрь, атаклы нашир һәм җәмәгать эшлеклесе Закир Рәмиев-Дәрдемәндкә, күренекле драматург Мирхәйдәр Фәйзигә, узган гасыр башында «Таңчылар» хәрәкәтендә актив катнашкан, Г. Исхакый, Г. Тукайларга сердәш-дус булган Шакир Мөхәммәдъяровка, герой-шагыйрь Муса Җәлилнең Орск, Оренбург чоры эшчәнлегенә мөнәсәбәте булган документаль әсәрләре барлыкка килә. Ул хезмәтләрнең бер өлеше язучының 1989 елда нәшер ителгән «Офыктагы рәшәләр» китабында урын алды. Дәрдемәндкә багышланган «Офыктагы рәшәләр» документаль повестен үз вакытында «Казан утлары» журналы да бик теләп бастырып чыгарган иде. Соңрак шул вакытта тупланган язмалар һәм Дәрдемәнднең дүрт оныгы белән аралашулар нәтиҗәсе буларак «Тарихта үз эзләре бар» һәм «Рәмиевләр матбагасы» документаль очерклары да язылды. Алар «Бертуган Рәмиевләр» күмәк җыентыгында дөнья күрде. (Күп санлы фотолар белән баетылган ул җыентык Миркасыйм Госманов житәкчелегендә 2002 елда нәшер ителә.) Дистә еллар дәвамында Дәрдемәнд баскан эзләрдән йөрү, аның рухы сакланган җирләрдә һәм архивларда булу нәтиҗәсендә Дәрдемәндкә багышлап фотоальбом чыгару хыялы туа. 2003 елда ниһаять ул хыял да тормышка аша, «Дәрдемәнд» альбомы басылып чыга. Альбомдагы төп текст авторы Лирон ага Хәмидуллин.



*Лирон, Дания—бергә гомер итүләренә кырык ел тула.*

Лирон Хәмидуллинның соңгы ике китабына кергән яки вакытлы матбугатта, шул исәптән «Казан утлары» журналында басылган соңгы дәвер әсәрләренең төп темасы милләт язмышын кайгыртып яшәгән шәхесләр эшчәнлегенә бәйле (укучыларның исенә төшереп китик: мәшһүр гармунчы Фәйзулла Туишевка багышланган повесте журналыбызның быелгы сигезенче санында басылды). Үз милләтенең киләчәге өчен жан атып яшәгән зыялыларыбыздан Дәрдемәнд, Галимҗан Ибраһимов, Габделбари Баттал, Йосыф Акчура, Камил Мотыйгый һ. б. багышланган документаль повесть, очерк, эссе кебек әсәрләрен автор, минем карашымча, шулай ук үз халкына файда китерим дигән максаттан чыгып башкарды. Әйтик, Г. Ибраһимовның биографиясен һәм иҗатын барлаудагы кайбер

проблемаларны күтәргән бер язмасы туксанынчы елларда безнең журналда дөнья күргән иде. Хәзер ул хезмәт житди бер фәнни басмада да урын алды (кара: «Галимҗан Ибраһимов», 2007).

Әйе, әсәрләре геройларына хас рәвештә, авторның үзенең дә тоткан төп мәсләге— үз халкына хезмәт итү. Узганнар мисалында яшь буынга дөрес юл күрсәтергә тырышу. Хәер, һәр житди иҗат иясенә—прозаикмы ул, шагыйрьме, абруй казанган журналистмы—хас бер изге максат инде ул. Кулына каләм алган күпчелекнең хыялында халкы күңеленә хуш килердәй әсәр иҗат итү. Алда әйтелгәнчә, һәркем ул максатка үз юлы белән килә. Зур Иделгә койган инеш-елгалар төрле булган кебек, һәр каләм иясенең дә иҗат юлы төрлечә булуга карамастан, төп максаты әдәби мохит дигән зур диңгезгә халкы өчен мәгънәле дип тапкан үз сүзен ирештерергә теләү. Лирон аганы шул максатына ирешүгә якын торучылар исәбенә кертеп буладыр, шәт. Иҗат юлын иртәрәк башлаган булса, бәлки, иҗат хәзинәсе күбрәк тә булган булыр иде... Нишлисең?—язмыш. Булганына шөкер итеп, куанырга кала. Шунысы куандыра: ул һаман эштә, хәрәкәттә, иҗат юлында. Аның әле башлам чорын үткән, әмма дөнья күрергә өлгермәгән хикәя һәм повестьлары да бар.

Кеше, әгәр дә ул шәхес дәрәҗәсендә икән, аның максаты иманнан, сүзе эшеннән аерылмаска, үткәне хыялдагы киләчәгенә табигый һәм эзлекле тоташкан, гамәлләр төене бербөтен булырга тиеш. Бу җәһәттән Лирон аганы мин шәхес дип саныйм. Ул үзенең гаиләсен, якыннарын үз кыйбласына юнәлтә алды. Хатыны Дания ханым гомере буе әдәбият-сәнгать кешеләрен хөрмәт итеп яшәде, озак еллар Язучылар берлегендә эшләде, исәп-хисап эшләрендә, булдыра алганча, язучыларга ярдәм итәргә тырышты. Бер сүз белән әйткәндә, үзебезнең кеше. Улы Булат Хәмидуллин хәзер инде үзе күренекле зат. Ул—галим, тарих фәннәре кандидаты, Татарстан Язучылар берлеге әгъзасы, «Фән» нәшриятының баш мөхәррире. Күп кенә фәнни хезмәтләр авторы. «Народы Казанского ханства» дигән зур хезмәте Татарстан китап нәшриятында аерым китап булып та чыкты. Ул, шулай ук, әтисе кебек үк, тәрҗемә өлкәсендә дә уңышлы эшләп килә. Кызы—Зөһрә Хәмидуллина, КДУны тәмамлап дәүләт оешмасында эшли, милли рухта бала тәрбияли... Күренеп тора: гаиләдә уртак максатта дәвамчылык бар. Димәк, киләчәккә өмет-ышаныч бар.

Лирон аганың 2002 елда нәшер ителгән «Ак төннәр хәтере» китабына соңгы елларда иҗат ителгән әдәби очерк, эссе, хатирәләре кергән. Русча ул китап «Белые ночи памяти», ягъни йокысыз төннәр хәтере буларак тәкъдим ителә. Ул китапның тулы эчтәлегенә тукталып тормастан, андагы әсәрләрнең дә башлыча татарның күренекле вәкилләре эшчәнлегенә багышланган булуын әйтеп үтү кирәктер. Андагы язмаларның исемнәре үк шул хакта сөйли: «Онытылган якын исем», «Милләт хадименең көрәш юллары», «Күләгәдә калган шәхес», «Тирәннән типкән чишмәләр» һ. б.

Бүгенге көндә Лирон Хәмидуллинның нәшер итүгә әзерләнгән ике китабы бар. Берсенә аның документаль эчтәлекле очерк, эссе һәм хатирәләре тупланган. Татарстан китап нәшриятына тәкъдим ителгән «Кичке шәфәкъ» китабына төрле вакытларда төрле җыентыкларда, журнал битләрендә дөнья күргән хикәя һәм повестьлары туплап бирелгән. Иншалла, аларның тиз көндә нәшер ителәчәкләренә өметләнеп калыйк.

**Равил ФӘЙЗУЛЛИН**

**Редакциядән:**

*Лирон ага Хәмидуллинны редакция һәм укучылар исеменнән житмеш биш яшьлек юбилее белән чын күңелдән тәбриклибез. Аңа киләчәк иҗади хезмәтендә уңышлар һәм исәнлек-саулык теләп калабыз.*

# СӘНГАТЬЧӘ ТАБЫШЛАР

Заманның иҗтимагый, рухи-әхлакый мәсьәләләрен укучы игътибарына җиткерүдә драматург Ризван Хәмид кулланган традицион сәнгатьчә чаралар белән бергә яңа табышлар, образ-символлар да зур роль уйный. Болар барысы да драматургның шәхес концепциясен бирүдә үзенчәлекле сәнгатьчә дөньясын бербөтен күзаллауга ярдәм итә, заман билгеләрен сәнгатьчә тулы яктыртырга мөмкинлек бирә. «Һәр заманның үзенчәлеге, үз йөзе, үз «характеры» бар—монысы диалектик үсеш кануннары белән билгеләнә... Әдәбиятта заман билгеләре никадәр сәнгатьчә тулы һәм кабатланмас төстә чагылса, ул әдәбият шулкадәр заманча да була, киләчәк буын укучылар өчен художество кыйммәтен дә тулырак саклый»,—дип язган иде А. Әхмәдуллин. *(Дөреслеккә ирешү юлында: Мәкаләләр.—Казан: Татар. кит. нәшр., 1993.)*

Р. Хәмид драмаларында татар гадәтләренең бозылуы, татар гаиләсе мөнәсәбәтләренең катлаулылыгы, фикер кискенлеге, драматургның боларны бик тә үзенчә тасвирлавы күзгә ташлана. Пьесаларда күңелне ертып керерлек вакыйгалар, катлаулы язмышлар сурәтләнә.

Бу драматургиядә конфликт кискенлеге өстәвенә характерлар да кырыслыгы белән аерылып тора. Кырыс, катлаулы, тормышчан, кабатланмас характерлар тудыру — Р. Хәмид иҗатының үзенчәлекле һәм иң көчле якларыннан берсе.

Р. Хәмид драмаларында төрле-төрле гаиләләр яктыртыла. Әлеге гаиләләрдә еш кына киеренкелек хөкем сөрә. Илдәге үзгәрешләрне, иҗтимагый әһәмиятле мәсьәләләрне бер гаилә әгъзаларының үзара мөнәсәбәтләре рәвешендә бирү—драматургның А. П. Чеховтан ук килгән бер сыйфаты. Шул рәвешчә, гаилә Р. Хәмид иҗатында «тормыш көзгесе» булып тора. Персонажларның үзсүзлелеге, кырыслыгы артында аларның тирән күңел кичерешләре ята. Драмалардан күренгәнчә, язучы чынбарлыктан канәгать түгел. Әлеге канәгатьсезлек геройларның эш-гамәлләрендә, сүзләрендә чагыла.

Аларның бер-берсенә мөнәсәбәтләре диалог-көрәш, диалог-бәхәс рәвешендә бирелә. Әлеге диалогларда индивидуаль йөзләр, рухи кичерешләр, дөньядан канәгатьсезлек күренә. Характерлар кырыслыгы персонажларның бер-берсенә һәм әйләнә-тирә мохиткә мөнәсәбәттә ачыла. Кырыс тирәлекнең яшүсмерләргә тәэсире бигрәк тә көчле, алар да өлкәннәр кебек үк кырыс, усал, үпкәчел. Драмаларда шәхес белән тирәлекнең бәйләнеше шул дәрәҗәдә көчле ки, шәхес мохитне чагылдыручы чып-чын көзге кебек.

«Китәм инде», «Кайтыр идем», «Каен җиле», «Майның унбишләрендә», «Җиде бажа», «Олы юлның тузаны», «Синең урыныңа кайттым», «Айсберг», «Пыяла кыз» драмаларында язучының сәнгатьчә позициясе социализм дәверенә канәгатьсезлек белән сугарылган. Биредә әхлакый кыйммәтләр һәм шәхес өчен борчылу язучы иҗатының рухи-әхлакый юнәлеше булып тора.

Тормыш, яшәешнең әһәмиятле мәсьәләләрен, тормыштагы мөһим күренешләрне образ-символлар аша яктырту элек-электән үк халык иҗатына хас күренеш. Моны әдәби иҗат та үзенә өлге итеп ала. Р. Хәмид тә кеше характерын, аның рухи дөньясын ачканда, иҗтимагый әһәмиятле мәгънәне биргәндә еш кына символик-аллегорик, символик-метафорик образлардан, аерым детальләрдән файдалана. Мәсәлән, Р. Хәмид драмаларында ир-ат характерлар еш кына көчле, курку белмәс, кайнар холыклы, горур, кыю, максатчан шәхес буларак бирелә. Аларны драматург кайчак бүре образы белән бәйләп бирә. «Алып китәргә, дип бер чәмнәнгән икән, сүзен сүз итми калмый да калмый инде ул!.. Бүре нәселе, диләр иде аның атасын—Галимҗан бабагызны!..»—дип сөйләнә Нәүхәбәр әби улы Тәфкил турында «Олы юлның тузаны» пьесасында. Димәк, Нәүхәбәр әбинең улы Тәфкил—бүре кебек үҗәт, үз дигәнен эшли торган кеше. «Синең урыныңа кайттым» драмасында туганы Мәгънәви турында Нигъмәтҗан

агай: «Бүре кебек усал яшәдең, үлемеңне дә бүредән таптың»,—ди. Ә «Жиле бажа» драмасында күпне күргән, күпне кичергән, әмма нинди генә авыр хәлләрдә дә татар дигән олы исеменә тап төшермәгән Күгәйне «татар бүресе» дип йөртәләр. «Идегәй» тарихи драмасында газиз Йорт өчен жан атып йөрүче, үз халкына тугры татар егетләре Бәдри белән Сәлимне дә «бүре балалары» диләр. Норадын Сәлим турында «Сәлим атлы бүре» ди. Туктамыш кызларының берсен кулга төшерү турында әйткәч, Идегәй улы Норадынга бүре әнисеннән бүре балаларын урлап алып кайткан бер колның ана бүре тарафыннан бугазлап ташлануын сөйли. Монда бүре йөзендә Туктамыш ханны күзаллыйбыз. Газиз балаларына тисән, ул да ана бүре кебек үчлегәчәк, имеш. Аксак Тимерне дә «чүл бүресе» дип атыйлар. Әлеге тарихи шәхесләргә карата кулланылган «бүре» кушаматы, аларның үз дигәненә һичшиксез ирешә торган максатчан, кулга төшкәнне ычкындырмый торган принципиаль көч, кодрәт ияләре булуларын ача. «Бүре» шулай ук аларга хас усаллык, явызлык, мәрхәмәтсезлекне дә гәүдәләндерә. Ә драматург үз әсәрләрендә бүре йөзендә кеше характерына хас усаллык, кырыслык, характер ныклыгы, тугрылык, үзсүзлелек, үҗәтлек кебек сыйфатларны бирә.

Мылтык образы драматург иҗатында аерым бер урын алып тора. Яшьләр кулына да, өлкәннәр кулына да килеп эләгә ул. Ятимлек, үгилек тойгысыннан усалланган, усалланып кына калмаган, явызланган яшь егет Инзар, кулына мылтык алып, күршесенә өрмәгән өчен этен атып үтерә («Китәм инде»). «Ике сәгать—бер гомер» пьесасында мылтык бер-берсенә дошманга әйләнгән ата белән ул арасына да килеп керә. Бу уңайдан атаның улына әйткән сүзләре ихтирамга лаек: «Ата белән бала арасында мылтык булырга тиеш түгел». «Актамырлар иле»ндә авылның йөз аклыгы булган Мөштәри карт кулында да күрәбез мылтыкны. Татар рухын мәсхәрә итүче оныгына каршы көрәштә кулына мылтык алырга мәҗбүр ул. «Олы юлның тузаны» драматик хикәясендә исә олы тормыш юлы узган, гомере буе халкыбызның гореф-гадәтләренә, йола-традицияләргә тугъры булып гомер кичергән саф күңелле Нәүхәбәр әби кулында да күренә мылтык. Нәүхәбәр әби башта ук сәхнәгә кулына иске мылтык тоткан хәлдә килеп керә. Ләкин әле мылтык «тыныч халәттә», биатисенең истәлеге буларак кына искә алына. Әмма бу күренеш алга таба хәлләрнең киеренкелегенә ишарә итә. Әсәр дәвамында үсә барган рухи киеренкелекне көчәйтеп, әсәр азагында мылтык образы яңадан пәйда була. Гомер иткән йортының сатылуы турындагы хәбәрдән соң, рухи киеренкелеге соңгы чиккә җиткән карчык кулындагы мылтыкның тавыш килгән якка төбәлүе, бөтен дөньяга протест рәвешен ала.

Мөштәри, Нәүхәбәр кебек татарның йөз аклыгы булган карт-карчыклар кулына нигә килеп керә соң ул мылтык? Нәкъ менә шул мылтык образлары аша ачыла да инде аларның рухи фаҗигаләре. Үз язмышларыннан кычкырып зарланмасалар да, кеше гомерен «эх» тә итми өзүче мылтыкка ябышу—бу инде чарасызлык галәмәте.

Әйе, пьесалардагы мылтык—явызлык, дошманлык һәм көрәш символы. Дөньяда әле рәтләп яши дә башламаган яшьләр, тормышның ачысын-төчесен күргән карт-карчыклар кулына килеп кергән мылтык—шул чордагы яшәү тәртипләреннән канәгатьсезлек билгесе ул.

Үзәк идеяне тулырак ачу өчен аллегорик образларга мөрәҗәгать итү татар драматургиясендә күптәннән килә. Аның беренче уңышлы үрнәген Г. Коләхмәтовның «Ике фикер» драмасында Кызыл һәм Кара фикерләр көрәше мисалында күрәбез. Аллегорик образлар буларак бирелгән Кызыл һәм Кара фикерләр көрәшен сурәтләү ярдәмендә автор татар әдәбиятында пролетар фикерләр үткәрүне башлап җибәрә, идея эчтәлеге ягыннан да, художество формасы җәһәтеннән дә драма поэтикасына зур яңалык кертә. Т. Миңнуллинның «Әлдермештән Әлмәндәр» әсәрендәге Әҗәл дә—аллегорик образ. «Майның унбишләрендә» пьесасында авылга янаган бетү куркынычының җитдилеген төшендерүдә драматург Р. Хәмид тә Кызылтау белән Дүртмангай аллегорик образларына мөрәҗәгать итә. Милләт фаҗигасен бирүдә капма-каршы позициядә торган ике тау сөйләше иҗтимагый әһәмияткә ия. Кызылтауда рух күтәренкелеге сизелсә дә, Дүртмангайның һәр сүзендә—тирән сагыш, ачы күз яше.

Р. Хәмид үз драмаларында кеше тормышындагы төрле хәлләрне, фаҗигале күренешләрне табигать күренешләре белән бәйләп бирә. Җәмгыять «корбан»ына

әверелгән, газиз анасын, туган йортын оныткан улы сагышын ана «Каен җиле» драмасында йортлары каршында үскән, ана күнеле кебек үк ялгыз каенга сыенып күз яше түгә.

Татар-башкорт халыкларында каенлы йорт— кайгылы йорт санала.

«Бездә кырда, далада ялгыз үскән агачларга аеруча бер ихтирам белән караганнар, аларга табынуга кадәр барып җиткәннәр: ялгыз каен, ялгыз нарат, ялгыз карама. Алар янында ниндидер шомлы күренешләр, хәлләр булуы мөмкин дип уйланылган»,— дип яза Ф. Урманчиев. *(Дастаннарга лаек замана. Борынгы фольклор һәм хәзерге поэзия. Казан: Татар. кит. нәшр., 1990.)* «Пыяла кыз» драмасында халык теленә «Зөләйха өянкесе» дип кереп калган, гасырлар буе тарихи хәтер булып үскән карт өянкенең дә фаҗигале тарихы бар. Кайчандыр, кызларга егетләр белән ялгызы очрашырга ярамаган заманнарда, Камил сүзләре белән әйтсәк, «үзенең мәхәббәте өчен көрәшкән» Зөләйха исемле кызның егетен таш белән башын ярып үтерәләр. Бу хәлгә түзә алмыйча, кыз агачка асылынып үлә. «Зөләйха өянкесе» турындагы әлеге риваять аша драматург фаҗигале чишелешкә ишарә итә. Чөнки Камил дә үзенең әнисен яшерен генә сөеп йөрүче Мотыйк абыйсына кул сала. Бу фаҗига ялгыз өянке янында була. Председательнең суга баткан машинасын бәйләп тарттырганда, әлеге өянке авып төшә. Шулай итеп тарихи шаһитнең юкка чыгуы, аның янында булып узган фаҗигане яңару мөмкинлеге рухи-әхлакый тормышка янаган афәтне ассызыклый.

Р. Хәмид иҗатында җыр да әһәмиятле урын тота. Аның пьесаларында җыр персонажларның рухи халәтләрен билгели, чор атмосферасын ача. «Олы юлның тузаны» пьесасында яңгыраган «Нардуган», «Диде кардәш»тә—«Әллүки», «Ике сәгать—бер гомер»дә «Герман көе» кебек халык җырлары җәмгыятьнең рухи халәтен, халыкның моң-зарын, кичерешләрен чагылдыра, әсәрләргә лирик тон бирә.

Драмаларда яшьләр җыр аша сөюләрен дә белдерәләр. Мәсәлән, «Хан кызы» тарихи драмасында яшь егет белән кыз—Таңай белән Язгөле—үзләренең сөюләрен җырга салып аңлаталар:

*Таңай: «...Хан кызы, ач ишегең, мин керием,*
*Мине сөйсәң, миңа дисәң, бер үбием!»*
*Язгөле: «Сине генә сөйгәнемне белмиемсең?*
*Сөям диеп алдап кына йөрмиемсең?!*

Драматург тормышның безгә билгеле күренешләрен, гадәтине сәнгатьчә чаралар ярдәмендә янача күрсәтә, алай гына да түгел, кеше аңына суга торган тетрәндергеч вакыйгаларны бирүдә уңышлы ситуацияләр таба. Бу унайдан драматургның «Ике сәгать—бер гомер», «Көзнең соңгы яфраклары», «Ирем китте войнага» драмаларына, «Актамырлар иле» трагедиясенә тукталып үтик. Әлеге пьесалар драматургның сәнгатьчә дөньясын билгеләүче образ-символлары белән бигрәк тә үзенчәлекле.

«Ике сәгать—бер гомер» драмасы—ике персонаждан гына торган әсәр. Пьесада сугышның күпчелеккә таныш булмаган гайре табигый бер күренеше бирелә. Татар авылыннан чыккан совет солдаты Шаталак Мәхмүт немец офицеры Фрид Тильне кулга төшерә. Ә бу егет исә Шаталак Мәхмүтнең... үз улы булып чыга!

Ундүртенче елгы сугышта Мәхмүт авылдашы Озын Хәбиб белән немецларга пленга төшкән була. Аларны бер-ике ай лагерьда ябып тотканнар да, төрле утарларга таратканнар. Мәхмүт бу егетнең әнисе Лизолетталар йортына эләккән...

Бер-берсенә капма-каршы позициядә торган ата белән улны очраштырып, автор геройларны кискен сынау астына куя. Аларның кайсы да булса шәһит китәргә тиеш, чөнки бер яктан алар очрашкан алачыкка Кызыл армия гаскәрләре киләчәк, икенче яктан яшерен каравыл группасы командиры Фридның юкка чыгуы немец солдатларын күтәрәчәк. Димәк, аны да эзләп чыгачаклар... Яисә биредә ата белән ул арасындагы якынлык җинәрме: мондый чакта икесенең берсе каршы якка чыгарга тиеш була. Әмма, пьесадан аңлашылганча, ата да, егет тә үз илләренә тугры.

Ата белән улны бер-берсен танырга мәҗбүр иткән деталь—атаның кайчандыр үз кулы белән ясап калдырган зажигалкасы. Шушы зажигалка туганлык җепләренең очына чыгарга ярдәм итә.

Беренче карашка, ата белән ул арасында инде җылы мөнәсәбәт барлыкка килеп

өлгергән. Ата үз башыннан кичкәннәрне улына сөйли. Сүзләренә караганда аның улы алдында гаебе юк та кебек. Аларның бергә була алмауларына сугыш гаепле... Улы да әтисен аңлый кебек. Шулай да хәрби бурычлары, ил алдындагы җаваплылык, вөҗданнары аларга артык онытылырга ирек бирми. Драматург сугыш тудырган дошманлык хисенең никадәр явыз көч булуын ата белән бала образы, алар мөнәсәбәте аша бирә. Бу хиснең, хәтта иң газизләр арасында да бер-берсенә карата нәфрәт хисе уятырга мөмкин булуын ассызыклый. Шул ук вакытта туганлык җепләренең дә ныклыгын раслый. Мондый каршылыклы көрәш әсәрнең психологизмын көчәйтә. Сугыш вакытында кешене шәхес иткән кешелек сыйфатлары сугыш кырында, аның да иң хәлиткеч мизгелендә сынала. Бик тә аяныч хәлгә тарыган Мәхмүт белән Фриднын шәхси сыйфатлары да шундый вакытта ачыла. Тәрәзәдән алар алачыгына якынаеп килүче солдатларны күреп, Мәхмүт аларны кызыллар дип уйлый. Үзенә трибунал буласын яхшы белсә дә, немец офицерын азат итә ул. Аталык хисе җиңеп чыга. Бу эшенә үзе дә бик гаҗәпләнә: мондый нәрсәне көтмәгән идем мин синнән, Шаталак Мәхмүт»,—ди ул үз-үзенә. Ләкин улы чыгып йөгергән җиреннән кире әйләнеп керә. Кызыллар түгел, аларныкылар якыная икән алачыкка. Шуны сизәтергә кергән егет. Моның үз атасына нәрсә булуын яхшы аңлый ул. Шуңа борчыла. Туган иленә мәхәббәте никадәр көчле булса да, аларны бер кан белән бәйләп торучы, аны дөньяга бар иткән атасына булган якынлык хисе газиз кешесенә хыянәт итәргә юл куймый. Ата белән ул күңелендә бурыч хисе белән туганлык хисе арасында барган рухи конфликт психологик киеренкелекне тагы да көчәйтә. Улын исән калдырып та, Фрид белән бер туфрактан булган, аның белән бергә сугышучы немец солдатларына каршы Мәхмүт ут ача. Үз халкын яраткан, шул ук вакытта газиз әтисен дә ташлап китә алмаган егет ике ут арасында кала. Аныкыларга ата бит әтисе! Ләкин ул атасын гаепли дә алмый. Ул бит сугышчан бурычы кушканча эш итә: туган җирләренә юлбасарларча басып кергән дошманнары белән аяусыз көрәшә. Дошманнарына каршы ялгызы сугышучы атасын ул гына коткара ала хәзер. Шул рәвешчә, ата белән ул күңелендә ике үтә көчле хис—Ватанга тугрылык хисе һәм туганлык, якынлык хисе—арасында көрәш бара. Шушы ике хис персонажлар күңелендә психологик киртә барлыкка китерә. Атасын дошманнарыннан саклап калу максаты белән егет, аны күргәч атудан туктамаслармы дигән өмет белән, тәрәзәгә ташлана. Атмаска кушып кычкыра. Тик ана игътибар итмиләр: үзен атып егалар. Үз кешеләрен үзләре үк атып үтерүче кабахәт җаннарга йөрәге ярсып, ата газиз улының гомерен өзгән дошманнарга тагын да нәфрәтләнеп ата башлый. Тик үзенең дә гомере өзелә. Шул рәвешчә драмада сугыш темасы гаять киеренке психологик призма аша бирелә.

Р. Хәмид драмаларындагы буш бишек образы—тормышка ашмаган хыяллар, өметсезлек билгесе. «Диде кардәш» пьесасында сугыш афәтеннән хәтерен җуйган Минзаһит үз куллары белән ясаган бишекне танымый. Ә аннан туган яшь баласы белән тол калган Фәүзия, тыныч тормыш шартларында бергә була алу өметен өзә.

«Ике сәгать—бер гомер» пьесасында драматург буш бишек һәм фашистлар образларын янәшә куя. Бу көчле антитеза тудыра. Пьеса башында ук драматург Мәхмүт алачыгында түшәмгә эленгән буш бәлүнең күзгә ташлануын әйтеп уза. «Нәкъ шушы минутта көтмәгәндә үзәк өзгеч сабый бала тавышы яңгырар кебек»,—ди автор. «Үзәк өзгеч сабый бала тавышы»—кешеләр тормышына бары һәлакәт кенә китерүче сугышка ләгънәт кебек. Пьеса азагында да драматург фашистлар тарафыннан атып үтерелгән атаның «бала бәллүенә бәрелеп, иләнгә авуын» билгеләп үтә. Шулай итеп буш бәллү—фашизмның явызлыгын, ерткычлыгын ассызыклый, аның кешелек дөньясына үлем китерүче көч булуын символлаштыра. Ул явызлык, ерткычлык, үлем булган җирдә яшәү дәвам итә алмый дигән мәгънәне бирә.

«Көзнең соңгы яфраклары» исемле әсәрдә хәзерге заманның акылга да, йөрәккә дә сыга торган фаҗигале яклары ачып салына. Намуссыз бәндәләр тарафыннан мәсхәрәләнгән кыз язмышын сурәтләүдә автор оригиналь ситуация тапкан. Пьесаның иң отышлы ягы дип профессор А. Әхмәдуллин саф йөрәкле, намуслы Гөфран образын күрсәтә. Аның «бүгенге сәхнәдә торган саен сирәгрәк кунак булган матур унай образ-персонаж» булуына басым ясый. *(Әхмәдуллин А. Офыклар киңәйгәндә. Әдәби*

*мәкаләләре.—Казан: Татар. кит. нәшр., 2002.)* Урыны белән драматург шартлы детальгә дә мөрәҗәгать итә. Бу—гашыйк иттерә торган хушбуй. Хушбуй драмада тылсымлы көчкә ия. Шул хушбуйны сөрткән Гофранга хатын-кызлар сихерләнгән кебек «ябыша».

«Ирем китте войнага» драмасы—«Көзнең соңгы яфраклары» әсәренең дәвамы. Пьесада үз абыйсы тарафыннан мәсхәрәләнгән Гөлназа акыллы, тәрбияле, булдыклы ир Гофран йортында яши. Кыз үзенең трагедиясен башкалардан бик яшерә, сер бирмәскә тырыша. Пьесадагы Сәһия дә—Гөлназа хәлендә калган гөнаһсыз кыз. Гөлназага кул сузган мәрхәмәтсез бәндә аны да кайчандыр мәсхәрәләгән була. Сәһия Гофранны эзләп килә. Ә Гөлназа туачак баласының әтисе Гофран дип ялганлый. Бу сүз исә Сәһиядә нәфрәт һәм үч алу тойгысын уята. Гофран йортына үзе белән килгән дус хатыны Рәүфәгә: «Теге кабахәтнең сеңлесе булып чыкты, димәк, бу нәмәрсә?! Кызык кына килеп чыга: абыйсы мине мәсхәрә итеп ташлый, ә сеңлесе—миңа өйләнергә теләгән егетне арканлый!.. Болай булгач, бу акай-чукайга бирмим Гофранны! Миңа өйләнмәсә өйләнмәс—аларны да тантана иттермим!»—ди.

Әлеге хатын-кыз образлар катлаулы һәм каршылыклы характерлар буларак бирелә. Сәһия—гади генә кеше түгел. Анарда сихер көче бар. Ул, гипноз белән кызны йоклатып, сихерләп аның көмәнен юкка чыгарырга ниятли. Драматург гипноз, ырым, бозу күренешен фәнни фактлар белән нигезләп, тормышчан ышандырырлык итеп бирә.

«Актамырлар иле» трагедиясе яшәү һәм үлем фәлсәфәсе, аның асылы, яшь буынның хиләчәгендә өлкән буынның роле, милләт язмышы турында. Яшәү һәм үлем төшенчәләре трагедиядә киң фәлсәфи мәгънәгә ия. Әлеге фәлсәфә Мөштәри карт һәм аның гаиләсе, нәселне дәвам итәргә тиеш булган баланың үлүе, татар рухын сакларга тиеш бердәнбер оныкның да, тәре тагып, үз диненнән, үз теленнән ваз кичүе кебек күренешләр аркылы бирелә.

Драматург чынбарлыкның вәхшилегенә төшендерүдә тетрәндергеч ситуацияләр таба белә. Трагедиядә егетнең кызны ата-бабалар рухын саклап торучы иң изге урын—зиратта мәсхәрәләве—бернинди чикләргә дә сыймый торган вәхшилек күренеше. Юк, драматург шаккаттыру максатыннан бирми бу ситуацияне. Зират ташландык хәлдә: «... чардуган-фәлән дә сакланмаган. Кабер өстендәге ташлар да җиргә сеңеп беткән, кайберләре генә чирәм астыннан борын төртеп тора. Аларын да бик нык игътибар белән караганда гына чамалап танып була. Шуңа күрә, тугайлык буйлап йөргән Гәрәй белән Фәридәнең зират агачларын чын урман дип уйлавы сәер түгел».—дип яза автор. «Урман түгел икән бу, Гарри! Зират бу! Без кемнеңдер кабере өстендә ятабыз! Коточкыч бит!.. Бәлки, ул синең карт бабаңнарның берсенекедер!!!»—дип, кызның ачыргаланып кычкыруы да аны ерткычлык эшләүдән туктата алмый, чөнки әлеге егетне өлкәннәрне хөрмәт итәргә, ата-бабалар рухына изге дип карарга өйрәтмәгәннәр. Егет—Мөштәри карт оныгы Гәрәй—Гарри. Әлеге күренешләр, ягъни татар зиратының аерып булмаслык ташландык хәлдә булуы, ата-бабаларыбыз кабере өстендә җинаять кылу—татарның милли-әхлакый йөзе юкка чыга баруны күрсәтә.

Катнаш никахларны, татарның милли йөзен юкка чыгаруда аларның тискәре йогынтысын драматург Актамырлар һәм Күктамырлар ыруы легендасы аша эзоп теле белән яктырта. Бу да сәнгатьчә табыш булып тора. Легенда түбәндәгедән гыйбарәт. Алдашу белән хәйләне, куркаклык белән хыянәтне белмәгән Актамыр ыруы кешеләре бер-берсенә гашыйк булганчы гына адәм сурәтендә йөргәннәр. Егет белән кыз беренче үбешүгә, чәчәккә күмелгән агачка әйләнеп, җиргә тамыр җибәрә торган булганнар. Тирә-яктагы урманнар—шул актамыр ыруының дәвамы икән. Ләкин бервакыт бу якларга икенче төрле ыру—Күктамыр ыруы—килеп чыга. Башта ике арада тарих күрмәгән орыш-талашлар була. Тора-бара, солых төзеп, ике ыру бергә аралашып яши башлый. Тик актамырлар ыруы өчен бик хәтәр солых була икән ул: күктамырларга актамырлар арасыннан кем кушылса да, күктамыр агачына әйләнәләр икән. Бары рухлары бик көчле булган актамырлар гына үз төсләрен саклап кала алганнар, ди. Менә ни өчен безнең як урманнарында күбрәк күк төстәге агачлар очрый, имеш һәм драматург Актамырларның «чибәрләрдән чибәр, гүзәлләрдән гүзәл» кызы Таңсылу белән Күктамырларның кыюлардан-кыю егете Ядомир кебек мифик-

фантастик образларның мәхәббәтен бирә. Әмма егет белән кыз ничәнче яз инде икәү бергә мәхәббәт таулары арасыннан үтсәләр дә, кызның йөрәге күктамыр ыруы егетенә ризалыгын бирергә ашкынмый.

Пьесада явыз көчне символлаштыручы образ булып шәүлә тора. Шәүлә—әһәмиятле мифологик архетипларның берсе. Аның кешеләрне сискәндереп, бөтен дөньяны янгыратып көлүе—татарның аянычлы хәлен күреп тантана итүе кебек.

Пьесада сискәндерерлек бер ситуация бар. Гәрәй имчәк баласына бабаларыннан сөт таба алмый кайта да, тамагы ачыккан булу сәбәпле елаган баласына «эксперимент ясап карамакчы» була: имчәк баланы ана дуңгызның аягы астына куеп, ана дуңгызның имчәген каптыра! Ә дуңгыз баланы таптап үтерә. Бу—тормышта булмаган, акылга сыймаслык хәл. Абсурд күренеш. Әмма нәкъ менә шул абсурд күренеш аркылы драматург татарның үзе өчен, үз язмышы өчен әһәмиятле мәсьәләләргә игътибарын юнәлтергә тели. Әлеге күренеш тирән иҗтимагый-символик мәгънәгә ия. Болай дәвам итсә, татар халкының киләчәге «ана дуңгыз астында тапталып үлгән сабый» язмышы кебек булачагы аңлашыла.

Трагедиядә персонажлар үзләре дә сизмәстән «фаҗигале хата» ясыйлар. Үз гомерендә кешегә начарлык эшләмәгән Мөштәри картның ялгышы—гомере буе «бала үз ата-анасына охшап үсә» дип ышануында. Бу аның гаебе дә булып тора. Балаларына, оныкларына милли телне, милли рухны сеңдермәүдә, дөрес тәрбия бирмәүдә, шул сәбәпле татар милләтенең «тамырын корытуда», шул хакыйкатьне соң гына аңлауда аның гаебе һәм трагик хатасы. Шуңа күрә аны аллалар кичерми. Үзенә каберне ата-бабалар күмелгән зиратта түгел, ә читтә, тау итәгендә казуы да символик мәгънәгә ия. Димәк, ата-бабалар рухы аны үзләренә кабул итми. Бу Мөштәри картның үзенең дә милли рухтан читләшкән булуына басым ясый. Димәк, әсәрдә трагизмны Мөштәри картның үлеме генә билгеләми. Төп трагизм Хода сүзләре белән әйтсәк, Мөштәри картның «ата-бабаларының телен һәм денен оныгына тапшыра алмый дөнья куюында. Нәсел җебен сузарга тиешле сабый баланың үлеме дә шуны раслый.

«Актамырлар иле»—метафорик мәгънәгә ия. Икенче төрле без моны татар иле, татар дәүләте дип аңлыйбыз. Пьесала Мөштәри картның милли рухны яклап хәзерге чынбарлык белән көрәше—бүгенге көндә татар милләтен таркалуга китергән конфликтлы ситуацияләрнең чагылышы ул. Белүебезчә, трагик конфликт хәл ителмәслек характерга ия. Мөштәри карт көрәше дә хәл ителмәслек фаҗига төсен ала. Балалар язмышына, алар тәрбиясенә битараф, үзе алардан өркеп торучы улы Мәрәс; дөньяның тоткасын акчада, байлыкта күрүче, әхлаксыз, дорфа, үз телендә сөйләшмәүче килене Кифая; шулай ук акча колы булган, урлап мал җыючы Борһан; акыллы кешеләргә хас түгел гамәлләр кылучы Гәрәй—болар барысы да хәзерге җәмгыятьнең рухи-әхлакый йөзен билгеләүче персонажлар.

Иҗтимагый әһәмиятле мәсьәләләрне яктыртканда, трагик характерлар иҗат иткәндә, драматург, күргәнебезчә, төрле сәнгатьчә чаралардан файдалана: абсурдлык, явызлык театры элементлары, дини-мифик, фантастик образлар, метафора, образ-символлар, образ-билге, гипербола.

Р. Хәмид драмаларында акылдан язган кеше, дивана образлары белән дә очрашабыз. Әлеге образлар—илебезнең иҗтимагый-сәяси, әхлакый торышын билгеләүче персонажлар. Монын белән драматург сәламәт булмаган җәмгыятьтә кешеләр сәламәт яши алмый дип әйтергә тели. Әйе, бу—безнең көннәрдә җәмгыятебездә үсеш алган олы фаҗига.

**Гүзәл КАЮМОВА**,
*Казан Дәүләт Гуманитар-педагогика университеты аспиранты*

Адлер Тимергалин

# МИЛЛИЯТ СҮЗЛЕГЕ

***ЧӘЧ КИТӘРҮ (ЯКИ КЫСКАРТУ), ЧӘЧ ЙӨРТҮ*** — Ислам әһелләре арасында чәч китәрү—ирләр өчен сөннәт эш. Ләкин Рәсүлуллага охшау нияте белән җитү йөртелсә, саваплы булачагы мәгълүм. Хатын-кызларга чәч кыскарту йә китәрү дөрес түгел, чөнки алар өчен чәч бер зиннәтдер. Гомумән, ирләрнең яланбаш йөрүләре Шәригать буенча хәләл дә, хәрам дә түгел, башны каплап йөрү хакында да боерык юк. "Чәч җиткереп йөрүдә башка дин халкына охшаулык булса, башын кырып йөртүдә дә башкаларга охшау бар, шулай булгач, берсен дөрес күреп тә, икенчесен манигъ итүдә хикмәт ни нәрсә?" (Р.Фәхреддин). Мөхәммәд Пәйгамбәрнең ихрамнан чишелгән вакытларда гына чәчен такыр итеп алдырганлыгы риваят ителә.

"Үз чәчен кисеп кеше чәченә ялгаучы вә кеше чәчен кистереп үз чәченә ялгатучы, башкаларның йөзләренә вә тәннәренә энә белән тишеп миң ясаучы вә үзенең йөзенә вә тәненә миң ясатучы хатыннарга Аллаһы Тәгалә ләгънәт итсен." Хәдис.

Мөхәммәд Пәйгамбәрнең оныгы *Хөсәеннән* килә торган *сәедләр* озын чәч йөртү хокукына ия булганнар.

***ЧЕЛЛӘ*** *ф.* — "Кырык" мәгънәсендәге *чәл, чэл* сүзеннән. 25 июньнән 5 августка кадәр дәвам итә торган эссе вакыт, кызу чак, *челлә ае*. Аның беренче атнасы *аяу атнасы* дип атала. Мәләкәс якларында челлә вакытын *ырҗа вакыты* диләр. // *"Сәратән аеның 26 көне, 1786. Татар хисабы белән челлә керде."* Борынгы кульязма календарьдан. Җәйнең челләсен *җәйнең сәратаны* дип тә атыйлар..

Телдә *кышкы челлә* төшенчәсе дә бар, ул иң суык утыз-кырык көнне (25 декабрьдән алып 5 февральгә кадәр булган вакытны) белдерә.

Тагын кара: ***ЧИЛЛӘ.***

***ЧЕЛЛӘ БАБАЙ*** *тар.* — Электә *кышкы нардуган* бәйрәме уеннарында катнаша торган персонаж, хәзерге Кыш бабайга тартым булган.

***ЧИ*** *бор.* — Элек даладагы ихатасыз өй тирәли үскән каты кура яки камыш киртә. // *Өйдән чыккан кыз чидән тышкары.* Мәкаль.

***ЧИН*** — Эш-хезмәттәге дәрәҗә, сан. Бу сүз рус теленә монголлар аша кергән кытай сүзе дип исәпләнә (И.Г.Прыжов. История кабаков в России). Шуннан чиновник сүзе ясалган.

***ЧИН, ЧИН ВИЛАЯТЕ*** — Кытай, Кытай мәмләкәте. Иранда Кытай шушы Чин исеме белән билгеле була. Атама Кытайда яңа эрага кадәр 221 елда тәхеткә менгән *Цинь* династиясе атамасыннан килеп чыккан. В.А.Никонов үзенең "Краткий топонимический словарь" сүзлегендә Европа илләренә *Чин* атамасын XVI гасырда португаллар Һинд-Кытайдан алып кайтканнар дип яза, ләкин татар теленә ул сүз фарсы-гарәп чыганаклары аша кергән. VI-VIII гасырларга караган төрки язулы Енисей-Орхон истәлекләрендә Кытай *Табгач* дип атала. // *Чин касә* — чынаяк; чини чәнак.

---

*Дәвамы. Сүзлек 2004 елның 1нче санының басылып килә.*

*Бәхре Чин* — Кытай диңгезе. *Сәдде Чини* — Бөек Кытай дивары. *Һинд Чине*-Һинд-Кытай (Индокитай).

Хәзерге вакытта Кытай иң күп халык (1200 млн. кеше, шуларның 15 миллионлабы мөселманнар) яши торган дәүләт (1949 елдан Кытай Халык республикасы — *Чжунхуа женьминь гунхэго*).

**ЧИН ВӘ МА ЧИН (МАЧИН)** *ф.* — Кайчагында *Эчке Кытай* вә *Тышкы Кытай* (яки Япония) мәгънәсендә кулланылган атама. Башка бүленеш буенча: Чин — *Төньяк Кытай*, Мачин — *Көньяк Кытай*. Мачинны башкача *Табгач* (Тавгач) дип тә йөрткәннәр. *Урта Чин (Син)* — "Хытай" дип аталган. *Түбән Чин* дип Кашгарияне атаганнар.

**ЧИРУТ ЧИРТҮ** — Кайбер сөйләшләрдә "авыл көтүен көтәргә алынган көтүчеләрнең өй борынча акча җыеп йөрүләре" ("Татар теленең диалектологик сүзлеге", 1969). Бер сыер, ике куй бер чирут (русча *"очередь"* чират сүзеннән) саналган.

**ЧИРҮ** — Гаскәр, яу, армия; һөҗүм,ябырылу. Сәйф Сараида *чәри* язылышы очрый. *//Дошман чәрисе. Аксак Тимер чирүе. Яңа чирү* (Төркиядә — "янычарлар"). Соңга таба бу сүз татар телендә "ишле халык" мәгънәсендә дә кулланыла башлаган. Инҗилнең русчадан татарчага тәрҗемәсендә *чирү* сүзе "көч(ләр)" ("силы") мәгънәсендә очрый: *"Шул кайгылы көннәрдән соң, кинәт кояш караңгыланып, ай үз яктысын яктыртмас, йолдызлар күктән коелырлар; күктәге чирүләр кузгалышырлар"*. (Матфей, 25:29). Бүгенге татар телендә "кораллы көчләр" дигәндә шулай ук "гаскәр" күздә тотыла, ягъни бу сүз Инҗилдән үк килә икән.

Галимнәр, татар телендәге "чирмеш" этнонимы да *чирү* сүзенә барып тоташа, диләр. Г.Й.Рамстедт русча "шеренга" сүзе борынгы кыпчак диалектларыннан (*шәри, шәрин* — гаскәр) кергән дип исәпли.

**ЧУК БӘЙРӘМЕ** — Керәшеннәрдә мәҗүсилек чорыннан ук калган җәйге төп бәйрәм, яңа стиль белән 7 нче июльгә туры килә. Башкача *Ибан-пүснәй* дип тә атыйлар икән. Бәйрәм вакытында төнлә учаклар ягып, гөнаһлардан арыну өчен шул ут аркылы сикереп чыкканнар, такыялар үреп, шуларның суда йөзүенә карап юраганнар, бер-берсенә су сибеп яңгыр теләгәннәр һ.б. "Чук бәйрәме чуашларда һәм удмуртларда да булган. Болгар-татарлар Чук бәйрәме көнне туган ир балага Чук исемен кушканнар. [Бу исем] Чуков, Чукин фамилияләрендә сакланган." ("Татар исемнәре сүзлеге".)

**ЧУКМАР** *тар.* — Сугыш күсәге, суел, гөрзи. Гадәттә бер метр озынлыктагы саптан һәм 6-7 тешле тукмактан торган. Америкадагы сиу кабиләсе һиндусларының томогавкына тәңгәл. *Томоговк* һәм *тукмак* сүзләренең охшаш яңгырашына игътибар итегез.

**ЧУКЫНУ** — **1.** Үз тәнеңдә яки берәр нәрсәдә бармаклар белән тәре сурәте ясап күрсәтү галәмәте. Хәзерге керәшеннәр бу хәрәкәтне *"кач кылу"* диләр. Бу турыда иң борынгы хәбәрләр Тертулианнан һәм Киприаннан (III гасырның беренче яртысы) дип исәпләнелә. Гадәттә уң кул белән чукыналар. Бармаклар башта маңгайга, аннары күкрәккә, шуннан соң бер-бер артлы җилкәләр турысына куела (католиклар бармакларны башта сул җилкәгә, ә православныйлар башта уң җилкәгә куялар). Бу вакытта католикларда бармакларны ничек тотсаң да ярый, ә православныйлар баш, имән һәм урта бармакларны бергә сузып, атсыз һәм чәнти бармакларны уч төбенә бөгеп тоталар. Иске йола тарафдарлары (старообрядцы) имән һәм урта бармакларны гына кушырып сузалар, ә баш бармак калган бармакларга орынып тора.

Татар телендә синонимы — *тәртену*. Удмурт телендә — *чукин-*, марилларда *чокын* — шул ук мәгънәдәге тамырлар. Кайбер галимнәр *чукыну* сүзен борынгы төрки *чөк* — "утка табыну, утка корбан китерү йоласы" белән бәйләп аңлаталар (Р.Әхмәтьянов).

**2.** Гадәттә христиан динен кабул итү (йола) мәгънәсендә.

Күп кенә тикшеренүчеләр фикеренчә, "Коръән"дә бер урында "чукыну" төшенчәсе кулланылган. Бу — "Сыер" сүрәсенең 138 (132) нче аяте. Аның мәгънәсен В.Порохова түбәндәгечә бирә: "Вот каково крещение Господне. А может кто-нибудь, помимо Бога-

лучше окрестить? И лишь Ему мы предаемся!", ягъни: "Мене Тәңре чукындыруы шундый. Ә Аллаһыдан башка кем генә яхшырак чукындыра алсын? Һәм без бер Аңа гына табынабыз." Комментарийлар өлешендә исә мондый искәрмә бар: "Чукыну — Алла диненә дүнү буларак — сыйбгать." Ягъни, тәрҗемәче фикеренчә, монда "чукыну" сүзен туры мәгънәсендә аңламаска кирәк булып чыга (*сыйбгать*-яратылыш).

Коръәннең Г.С.Саблуков тәрҗемәсендә бирелгән әлеге аятьнең татарчасы түбәндәгечә яңгырар иде: "Без — Алла чукынмышлары; ә кем Алла чукынмышыннан яхшырак? Һәм без Аңа сәҗдә кылабыз." Бит астындагы искәрмәдә бу аять "Христианнар өндәвенә җавап дип аңлатылган."

Аять чыннан да күбәүләрне аптырашта калдыра. Ничек инде мөселман кешесе Аллаһы тарафыннан чукындырылган булсын? "Ногмани тәфсире"ндә аятьтә "чукыну" сүзе гомумән юк: "Коръән хөкемнәре Аллаһ динедер, шул дингә керегез! Аллаһ диненнән күркәмрәк дин булырмы? Шулай булгач, Аллаһ динен кабул итегез, һәм Аллаһуга гына гыйбадәт кылабыз һәм Аңа гына итагать итәбез, диегез!"

И.Ю.Крачковский үзенең тәрҗемәсендә бу урынны эшләп җиткерергә өлгермәгән (ләкин, комментарийларына караганда, уйланган булырга тиеш): "По религии Аллаха! А кто лучше Аллаха по религии? И мы ему поклоняемся."

Кыскасы, 138 нче аять мәсьәләсендә фикер төрлелеге хөкем сөрә. Ихтимал, иң дөресе "Ногмани тәфсире"нә таяну булыр, әмма аңа төпле искәрмә бирү сорала.

***ЧУЛПАН ЙОЛДЫЗ*** — *Зөһрә йолдыз, Венера* планетасы. Чулпан сүзе чабан, ягъни көтүче мәгънәсенә ия. Алим Гафуров бу сүз "юлъкүрсәткеч" семантикасына ия булган дип яза. Борынгы төркиләр, күрәсең, төнге күктә маяк, ориентир булып хезмәт итәрлек якты йолдызларның барысын да Чулпан дип атаганнардыр. Соңрак мондый атама күктәге иң якты "йолдыз"га — Венера планетасына беркетелгән. Төрки һәм кайбер башка халыклар телендә бу якты планета охшаш яңгырашлы атама алган: *Цолмон* (Себер татарларында, монголларда, шулай ук тунгусларда), *Чолпон* (кыргызларда), *Шолпон* (казакъларда), *Чолмон, Чормон* (Алтай төркиләрендә), *Чолбон* (якутларда), *Солбон* (бурятларда) *Солбан* (хакасларда), *Чолбан, Шолбан* (эвенкларда). Бу халыклар күчмә көтүчелек белән көн күргәннәр.

Тагын кара: ***ЗӨҺРӘ ЙОЛДЫЗ.***

***ЧУМЫЛДЫРУ*** — Керәшеннәрдә бала чукындырганда аны суга чумдырып алу (русча — *купель*). Гомумән чукындыру мәгънәсенә дә ия (*чумылган* — чукынган). "Татар теленең диалектологик сүзлеге"ндә (1993) шактый кызыклы бер факт теркәлгән. Чистай керәшеннәреннән язып алынган сүз: "Чапый Бәчкәсен беләм мин, башларына чалма чалалар ыйы, пуп үгетлидер ийе, сез чумылган кешеләр, сез былай кермәскә, дидер ийе."

***ЧУРА*** *тар.* — Төрки каһанатта, Идел буе Болгар илендә, Алтын Урдада һәм татар ханлыкларында хезмәттәге аксөякләрнең титулы (аны Болгар чоры кабер ташларындагы *йуари, йөри* атамасы белән тәңгәлләштерәләр).

Соңрак бу сүз *буйсынган кеше, вассал, кол* мәгънәсен алган. Рус телендәге *холоп* мәгънәсенә дә туры килә. Р.Әхмәтьянов аны санскрит теленнән үк кергән дип фараз итә (*яугир, хәрби* сүзеннән). "Чура" сүзе *Акчурин, Байчурин, Канчурин, Карачурин, Колчурин, Синчурин, Тинчурин* фамилияләрендә катнаша. Русларда сакланган *Чуриков, Чуренных* кебек фамилияләрне дә шушы рәткә кертеп карарга кирәк. // *Кол — чура, чура кол.*

***ЧУХУР*** *иск.* — Элек Казан татарлары арасында "мещан" сүзе урынына кулланылган сүз. //*Казан чухурлары белән берлектә, Николай патша рәсемен күтәреп, "Яшәсен падишаһы әгъзам хәзрәтләре!" дип, Казан урамнарында демонстрация ясап йөргән Галимҗан хәзрәт әлеге революция хәрәкәтенә катнашкан шәкертләргә каршы кискен чаралар күрә башлады.* Зариф Бәшири.

***ЧЫҢГЫЗ ХАН*** (1155 еллар тирәсе — 1227) — Монгол ханы, җиһангир. Чын исеме *Темуҗин (Тимучин)*, русча чыганакларда — *Темучин. Йөсугәй* баһадир угылы. Чыңгыз

ханның татар телен белгәнлеге мәгълүм, аның әнисе татар нәселеннән булган дигән томанлы хәбәрләр дә бар. Чыңгыз ханның атасы Йосугәй баһадир заманында татарларның юлбашчысын әсир төшергән була һәм соңыннан татарлар аның үзен дә үтерәләр (бу вакытта Тимучинга 13 яшьләр була). Шул чакта Тимучин барлык татарларны кырып бетерергә чакыра. Шуңа да карамастан, яулап алу сугышларын башлап җибәргәндә ул үзенең алдан баручы гаскәрләренә нәкъ менә татарларны керткән. (Хәер, бу алым XX гасырда штраф батальоннарында тагын да нечкәрәк хәйлә белән кулланылды.) Яулап алынган илләрнең гаскәрен Чыңгыз хан татарлар дип аталырга мәҗбүр итә һәм шул рәвешле, мәсәлән, руслар Көнбатыш Европада монгол-татар исеме астында яулап алу сугышларында катнашалар.)

Тимучин 1206 елда Каракорым шәһәрендә тәхеткә чыгып, каһан (бөек хан) дип игълан ителә һәм Чыңгыз хан исемен ала ("җиңүче", "мөстәкыйль" хан мәгънәләренә ия-*Ризаэддин Фәхреддин*).

Чыңгыз ханның беренче һәм яраткан хатыны Бурт Фучин (Бортэ-фужин) исемле булган (русча чыганакларда *Бортгэльджин-хатун* рәвешендә дә очрый). Ул аңа 1182 елда өйләнгән. Бурт ханбикә — Чыңгыз ханның Җучи, Чагатай, Угэдәй (Үгдәй) һәм Толуй (Тули) исемле дүрт улының анасы. Чыңгызның икенче хатыны Хулан-хатуннан тагы Кулкан исемле улы булган, анысы бер рус шәһәрен алган вакытта һәлак була.

Әхмәдзәки Вәлиди Чыңгыз хан мәмләкәтендә "рәсми дин юк иде" дип яза. Чыңгыз һәм аның балалары шаманилыкта торганнар, ләкин монголлар дин әһелләренең һәммәсен ихтирам иткәннәр, аларны дине өчен кысмаганнар, ягъни мәмләкәттә дин иркенчелеге хөкем сөргән. Ризаэддин бине Фәхреддин Чыңгыз ханны мовәххид (бер аллага ышанучы) дип атый һәм Ислам диненә керү ихтималы зур булган дигән фикердә тора. Әхмәдзәки Вәлиди "Мөселман төрекләр дә Чыңгызны бик яратканнар, чөнки ул Ислам динен һәммә диннәрдән артык, хөрмәтле күргән" дип яза. Шулай да Заһир Бигиев язганча, 617 һиҗри елында Чыңгыз хан Бохараның астын-өскә китергән һәм атка атланган хәлендә, масаеп, "Мәсҗиде Кәлан"га кергән икән.

Замандашларының хатирәләренә караганда, Тимучин зәңгәр күзле, сары сакаллы булган.

Чыңгыз хан укый-яза белмәгән.

Чыңгыз хан чыгарган кануннардан берсе буенча, фәкыйрь-фокра, Коръән укып көн күрүчеләр, канун белгечләре, табиб һәм галимнәр, гомумән гомерен гыйбадәткә һәм дәрвишлеккә багышлаучылар, шулай ук мәетләрне юып соңгы юлга озатучылар салымнардан азат ителгән.

Чыңгыз хан үзе һәм аның варислары башлаган яулап алу сугышларында 10 миллион чамасы кеше кырылган дип исәпләнелә.

Үзенең империясен, олысын идарә итү өчен Чыңгыз хан кануннар җыелмасы — *яса* ("ясак" язылышы да бар) төзеп игълан итә. Ясаның нигезе канунга һәм ханга буйсынудан гыйбарәт. Шул кануннары ярдәмендә Чыңгыз хан мәмләкәттә ныклы тәртип һәм тынычлык урнаштырган. Күренекле тарихчы Әбелгази бу хакта мондый сүзләр язып калдырган: "Чыңгызхан патшалык иткәндә бөтен илдә — Иран белән Туран арасында — шулкадәр тыныч иде ки, баш өстенә ләгәне белән алтын күтәргән килеш кояш чыгышыннан алып кояш баешына кадәр һичберкемнән рәнҗетү-мазар күрмичә барырга мөмкин иде."

Мәмләкәттә ханнар Чыңгыз нәселеннән булу шарты белән халык тарафыннан сайланып, корылтайда расланалар.

Сугыш вакытында кануннар кыска һәм ачык аңлаешлы булганнар:

"Игътибарсыз каравылчы үлемгә хөкем ителә."

"Исергәнче эчкән чапкын үлемгә хөкем ителә."

"Качкынны яшереп яткыручы үлемгә хөкем ителә."

"Хакы булмаган килеш ганимәт малын үзләштергән сугышчы үлемгә хөкем ителә."

"Сәләтсез яубашы үлемгә хөкем ителә."

"Күмәк сунардан һәм сугыш вакытларыннан башка, халыкка корал йөртү рөхсәт ителми, кораллар дәүләт амбарларында саклана."

"Караклар — асып, зиначылар буып үтерелә."

Чыңгыз ханның империясе көнчыгыштан көнбатышка таба 4000 километрларга сузылган.

Чыңгыз ханның диктаторлык психологиясе аның түбәндәге сүзләрендә ачык чагыла: "Ирдар кеше өчен иң зур ләззәт шуннан гыйбарәттер: фетнә куптаручыны бастыру һәм дошманны җиңеп, аның бар булган мөлкәтен талап алу; никахлы хатыннарын үкереп җыларга һәм яшь коярга мәҗбүр итү, аның шоп-шома сыртлы чаптар атына менү, чибәр хатыннарының корсакларын төнге йокы күлмәгең һәм түшәгең итү, аларның гөлчәчәктәй битләренә карап ләззәтләнү һәм үбү, ә имчәк җиләгедәй татлы ирennәрен имү булыр!"

Чыңгыз хан 1227 елның август ае ахырында вафат булган. Елъязмачылар олуг хан аттан егылып имгәнү аркасында үлгән дип раслыйлар. Монголстаннан 1247 елда Европага әйләнеп кайткан Плано Карпини ханны яшен суккан дип хәбәр итә. Кайберәүләр аңа кәнизәге агулы эчемлек биргән дип тә сөйлиләр. Кыскасы, Чыңгызның ни сәбәптән үлгәнлеге турында ышанычлы мәгълүматлар юк.

Олуг хан авырып киткәч, аның юртасы алдына озын сөңге кадап куялар һәм аның очлыгына кара киез эләләр. Бу — ханның авыруын белгертергә тиеш була.

Әхмәдзәки Вәлиди Чыңгыз ханның җәсәден "үзенең туган җиренә — Онон буена алып киткәннәр һәм Дилигун Булдакта җирләгәннәр" дип яза. Ләкин аның кабере бүгенгә кадәр табылганы юк. Гомумән, монголлар ханнарының зиратын яшереп тотканнар. Бер ривайәткә караганда, Чыңгыз ханның кабере өстеннән 20 мең баш ат көтүе үткәреп, аны җир белән тәмам тигезләгәннәр дип сөйләнелә.

Чыңгыз ханның утыз икенче буында туры һәм соңгы варисы, Кытайда Эчке Монголия провинцияләре вице-президенты Очир Хукият дигән кеше 1984 елның 2 июлендә сиксән дүрт яшендә рак авыруыннан үлгән. Аны Ордоста мәшһүр "бабасы"на багышланган җирләр тирәсендә дәфен кылганнар.

1990 еллар башында Кытайда Чыңгыз ханга һәйкәл куелды.

Ләкин Көнбатышта һәм, әлбәттә, Россиядә Чыңгыз хан вәхшилек һәм золым символы булып кала. Хәтта Брэм Стоукер үзенең хыялый романында мәшһүр вампир граф Дракуланы Чыңгыз ханның туры варисы дип атый.

***ЧЫРШЫ БӘЙРӘМЕ*** *тар.* — Русиягә XIX гасыр урталарында Германиядән үтеп кергән яңа ел бәйрәме. (Чыршы бәйрәмен Петр патша керткән дигән сүз дөрес түгел.) Тарих эченәрәк керсәк, Европада беренче чыршы бәйрәменең 1374 елда Парижда үткәрелгәнлеген күрәбез.

Казанда татарлар арасында чыршы бәйрәме беренче тапкыр 1913 елда "Шәрык" клубында тамаша төсендә уздырылган. Балаларга чыршы бүләкләре-уенчыклар өләшү ике-өч көн дәвам иткән. Дин әһелләре моңа мәҗүсилек, агачка табыну һәм урыска ияру дип караганнар, әлбәттә. Шуңа күрә бу бәйрәм Мөхәммәд Пәйгамбәр туган көнгә туры китерелгән һәм Мәүлид бәйрәме рәвешендә узган (Исмәгыйль Рәми).

Ләкин асылда "чыршы бәйрәме" борынгы төркиләрдә үк булган. Тагын кара: ***ҖИР-СУ; ПЕТР ПАТША.***

***ШАГЫЙРЬ*** *г.* — Шигырь язучы. Коръән-кәримдә "Шагыйрьләр" сүрәсе бар. Аның ахырындагы аятьләрдән шагыйрьләрнең Хакка каршы булулары, аларга юлдан язганнарның гына иярүләре аңлашыла. Ривайәткә караганда, заманында Мәккәнең йогынтылы кешеләре арасында Пәйгамбәргә "шагыйрь" дигән кушамат тагу турында да фикер кузгалган була, ләкин ахырда шәһәр урамнарында аны "сихерче" дип игълан иткәннәр (бу турыда кара: *Әбү Җаһил*).

Шулай да Пәйгамбәрнең җыр-шигырьгә һәм музыкага уңай мөнәсәбәте билгеле (бу турыда кара: *Ислам һәм җыр-шигырь, музыка*).

Шагыйрьгә курку белән өркү хәрам. Тукайдан. Һәр милләтнең шагыйрьләре — шул милләтнең теленең сакчысы вә төзәтүчесе. Ф.Әмирхан.

Күплек саны шәкеле — *шөгара.*

Хатын-кыз булганда — *шагыйрә. Шагыйрә*-нең күплек саны шәкеле-*шәвагыйрь.*

Шунысы кызык, әдәбият тарихында "шагыйрь" сүзен куллануга каршы чыккан очрак та билгеле. Мәс., 1913-14 елларда Оренбургта чыгып килгән "Мөгаллим" газитендә: "..."шагыйрь" сүзләре безгә ят сүзләр, "акын" сүзе безнең үземезнеке, борынгы төрек бабаларымыздан калган, без аны сөямез, хуплап язамыз...",-дигән фикергә тап булабыз.

*Дәвамы киләсе саннарда*

Фирдәвес
Гарипова

# АВЫЛЛАРЫБЫЗ ТАРИХЫ

## Алат авыллары

Матур да соң безнең туган ягыбыз! Жил искән саен тирбәлеп-тирбәлеп ала торган камышлы күлләр, мон тулы чишмәләр, балыклы һәм кыслалы инешләр, күркәм итеп бизәлгән чиста авыл йортын хәтерләткән түгәрәк урман аланнары, әби-бабаларыбыз тыныч йокыга талган зиратлар һәм шундагы картайган каеннар, янәшәдәге зирек, миләш h.б. агачлар туган ягыбыз табигатенен бер кисәген тәшкил итәләр. Жанга якын Мөкәши, Төкәши, Болак буе, Әтрәч, Урта жыен, Югары жыен, Мәчет урамы, Атау очы, Ясак очы, Казак очы кебек урам атамалары—олы буыннан безгә калган мирасның гәуһәр ташыдай ялтырап торган ядькәрләре.

Татарстан төбәгендә исемнәре безгә гасырлар тирәнлегеннән үк килеп ирешкән авыл, су-инеш, күлләр h. б. географик берәмлекләр шактый. Аларнын мәгънәсен ачыклау тарихның серле сандыгына күз төшерергә мөмкинлек бирә. Монлый яссылыкка куеп караганда, борынгы Алат атамасы аеруча игътибарга лаек.

Тарихи h. б. хезмәтләрдә Алат юлы топонимы еш телгә алына.

Алат спирт заводы авылы район үзәге Биектаудан 36 чакрымда, Рус Алаты район үзәгеннән—33, Кече Алат исә Биектаудан—32, Урта Алат авылы район үзәгеннән—31 чакрым ераклыкта урнашкан. Урта Алат, Кече Алат, Рус Алаты, Алат спирт заводы авыллары Ашыт суына килеп тоташа торган Алат елгасы буена утырганнар. Алат елгасы атамасы телдә төрле әйтелештә йөри (Алат, Алатка Барская). Урта Алат, Кече Алат авылларының исеме күп кенә тарихи чыганакларда, шул исәптән Казан ханлыгы чоры документларында искә алына. 1602—1603 еллардагы мәгълүматларны туплаган Казан өязе теркәү кенәгәсендә Алат гидронимы, Алат шәһәре, Алат юлы, Урта Алат, Олы Алат, Кече Алат авыллары еш телгә алына. Аларда йомышлы, ясак түли торган кешеләр (ясашные люди), ягъни чувашлар (ясаш-ные чуваши—ясак түли торган татарларнын сословие титулы) күрсәтелә. Урта Алат авылы да XVI йөз тарихи чыганакларында еш телгә алына. Борынгы тарихи чыганакларда шул ук райондагы Олы Солабаш авылын Олы Алат дип йөртүләре турында мәгълүматлар бар. 1672 елның сентябре һәм 1673 елның август аена нисбәтән Алат авылында яши торган йомышлы татар Уразмәмәт Тлевлев исеме тарихи чыганакка кереп калган.

Тарихи чыганакларда борынгыдан кулланылган юл атамалары (алар административ берәмлекне дә анлатканнар) арасында Алат юлы да әйләнештә йөргән. И. П. Ермолаевнын «Казанский край во второй половине XVI—XVII вв.» дигән хезмәтендә 1567 елның сентябрь—1568 елның август ае белән Нугай, Чуваш (Югары һәм Урта), Арча, Алат, Атыз, Иске Йорт юллары искә алына.

Бер өлеше Ашыт суы ярына урнашкан Алат торак пункты турындагы мәгълүматларны Н. А. Спасскийның тарихи хезмәтендә дә табабыз.

Казан ханлыгы яулап алынганчы ныгытылган татар шәһәре булган Алат ханлыгы буйсындырылганнан соң да ныгытылган кальга (баструк—острог) булып кала.

XVIII йөздә Алатта бакыр эретү заводы эшләгән. Аның янында элекке шәһәр исталекләре булып өек һәм ур эзләре сакланып калган. Ханлык жимерелгәннән соң Алатка укчылар (стрелецлар) китереп утыртыла. Алар арасында Баженовлар нәселе дә булган. Алатта зур базар үткәрелгән. Халык күн эшкәрткән, балчык савыт-

*Дәвамы. Башы журналның 2006 елгы 6 санында.*

саба ясаган, балта эше белән шөгыльләнгән. Алат янындагы известьташ катламында мәгарә бар. Ашыт елгасының икенче ярында, Алатка каршы урнашкан Потаниха (Ивановское) авылының чиркәве астында Ашыт елгасына һәм Алатка таба юнәлгән җир асты юлы сузыла. Потаниха авылында 1758 елда төзелгән аракы заводы булган. Алатта 744 кеше яшәгән, бер земский училище булган.

В. П. Семенов редакциясендә дөнья күргән тарихи чыганакта Алатка түбәндәге сыйфатлама бирелә. Казан ханлыгы яулап алынганнан соң, XVII йөздә Алат җинелгән халыклардан татарларны, мариларны, удмуртларны буйсындырып торучы сакчы шәһәр (сторожевой город) вазифасын үтәгән. 1708 елда Россияне губерналарга бүлгәләгәндә Мәскәү хакимияте, Казан губернасы ясап, андагы 72 шәһәр исәбенә Алатны да кертә. 1766 елда Алат шәһәрләр исемлегеннән төшерелеп калдырыла.

XVIII йөз тарихи мәгълүматлары тупланган бер чыганакта Олы Алатта (икенче төрле Солабаш) ясак түли торган 96 татар, Кече Алатта (икенче төрле Диривинкә) 102 кеше, Алатбаш авылында 31 ясак түли торган крәстиән, Урта Алатта 23 алпавыт крәстиәне, 9 ясак түли торган крәстиән, 39 ясак түли торган татар, 37 йомышлы татар, Алат бистәсендә (Пригород Алаты) 186 мещан, иген игүче 29 солдат яшәве күрсәтелә.

А. Артемьев китабында күрсәтелгәнчә, Урта Алат (Корманай) авылындагы 48 хуҗалыкта ислам динендәге 233 ир-ат һәм 248 хатын-кыз гомер кичергән, мәчет эшләгән. Кече Алаттагы (Диривинкә) 63 хуҗалыкта 269 ир-ат һәм 277 хатын-кыз исәпләнгән. Алатбаштагы 13 хуҗалыкта—66 ир-ат, 81 хатын-кыз, Алат авылындагы 68 хуҗалыкта 244 ир-ат һәм 299 хатын-кыз яшәгән, анда бер чиркәү булган һәм ял көнне базар үткәрелгән.

Алат заводында 26 хуҗалык булып, анда 75 ир-ат һәм 86 хатын-кыз исәпләнгән. 1766—1861 елларда үткәрелгән Генераль ызанлау документларында Урта Алат (Кырманай) авылының Поварна чишмәсе буена утыруы һәм анда чукындырылмаган ясаклы һәм йомышлы татарлар яшәве күрсәтелә. Н. Н. Вечеслав чыганагында Алат бистәсе (Пригород Алаты) Барски инеше янына утырган дип күрсәтелә. Андагы 46 хуҗалыкта 650 ир-ат һәм 682 хатын-кыз яшәгән. Халык Алат авылы җәмгыятенә кергән. Авылда волость идарәсе, әйбер ману кярханәсе, ике җил тегермәне, кабак булган. Дүшәмбе көнне авылда базар үткәрелгән. Кече Алат авылында 108 йорт булган. Авылда ике җил тегермәне, ике ярма яргыч, бер тимерче алачыгы һәм кабак булган. Халык Алат авылы җәмгыятенә кергән. Урта Алат (Корманай) авылының 5 хуҗалыгында ислам динендәге 31 ир-ат һәм 32 хатын-кыз яшәгән. Урта Алат (Корманай) авылы халкы Урта Алат җәмгыятен төзегәннәр. Авылдагы 92 йортта 546 ир-ат һәм 382 хатын-кыз яшәгән. Анда агачтан эшләнгән мәчет, ярма яргыч, тимерче алачыгы, ике җил тегермәне булган. Алатбаш авылы халкы Урта Алат җәмгыятенә кергән. Анда 26 хуҗалык, бер әйбер ману кярханәсе булган. Чик чишмәсе янындагы (Посреди Межевого ключа) Яна Корманай авылы халкы Урта Алат җәмгыятенә кергән. Анда 17 йорт исәпләнгән. Уржум сәүдә юлының сул ягына урнашкан Алат бистәсе, Алат, Кече Алат, Диривинкә, Алатбаш, Урта Алат, Кырманай авыллары И. А. Износков хезмәтендә теркәлгән. Урта Алаттан кала алат сүзе кергән башка авылларда руслар яшәгән.

Урта Алат, Кырманай, Поварна чишмәсе янындагы Пүчинкә Мулла чокыры тирәсенә, Уржум сәүдә юлының сул ягына утырган. Кырманай исеме аны беренче тапкыр нигезләгән кешегә нисбәтле рәвештә бирелгән. Авыл ике бистәдән оешкан: беренчесе Татар Кырманае, икенчесе Алпавыт Кырманае (Барское Курманаево). Авылдагы 95 хуҗалыкта ислам динендәге 406 ир-ат һәм 355 хатын-кыз яшәгән. Алар Урта Алат авылы җәмгыяте төзегәннәр, тормыш-көнкүрешләре уртача булган. Алпавыт Кырманае авылында руслардан 34 ир-ат һәм 34 хатын-кыз яшәгән. Тормыш-көнкүрешләре ярлы булган. Алар Алат, Алат бистәсе авылы җәмгыятенә кергәннәр.1898 елда руслар яши торган авыллар дип Кече Алат (Диривинкә), Алат (Алат бистәсе), Алатбаш авыллары билгеләнә. Н. К. Берстель хезмәтендә күрсәтелгәнчә, Алатта—712, Кече Алатта (Диривинкә)—713, Алат башында—165, Яңа Кырмакайда—181 рус милләте кешесе, ә Урта Алатта (Кырманай) 914 татар яшәгән.

Зур шәһәр булып гөрләп яшәгән заманнардан ук Алат халкының үз традицияләре, йола-кануннары булган һәм ул традицияләр буыннан-буынга күчә килгән. Шуның бер мисалы—элек жыеннар, хәзер инде сабан туйлары үткәрү. Казаклар, Өлә Казаклары, Матмыр авыллары белән алатлылар элек июнь ахырында «Бәрәзә жыены» үткәргәннәр. Жыен сабан беткәч, каты сука эшләре тәмамлангач башланган. Гадәттә жыеннар пәнжешәмбе, ягъни атна кич көнне башланып, дүрт көн дәвам иткән

Жыен һәрбер авылда булган. Мәсәлән, әлеге «Бәрәзә жыены» атнасында бер тирәнен авыллары жыенны һәрберсе үзендә ясаган. Бу көннәрне кунакка йөрешкәннәр, күнел ачканнар, төрле уеннар, бәйге-ярышлар үткәргәннәр, жырлаганнар,биегәннәр. Кунакны барып алу гадәте да булган. Парлы кешеләрне бер үк төсле пар атларда тарантаста алып кайтканнар. Ялгыз кунакларны кунакка ялгыз атта, худ арбасына утыртып кайтканнар. Ат дирбияләренен тәнкәләре агартылган, каешлары майланган, буялган булган. Жыенда исереп йөрү булмаган. Яшьләр «Так каравыл», «Түгәрәк» уеннары уйнаганнар. Болыннарда, су буйларында, авыл урамнарында скрипка, гармун кебек музыка коралларына кушылып, яшьләр һәм картлар аерым-аерым, жырлап йөри торган булганнар. Алатта һәм башка авылларда да бәйрәмнәр күнелле үткән.

Элек Алат авылы халкы кулланган тамгалар да шактый кызыклы. Тамгалар күбрәк жир билгеләү өчен файдаланылган. Алар жиргә 40—50 сантиметр озынлык калдырып күмелгәннәр. Авыл крәстиәне Әскәров Шәрифнен тамгасы дуга, Төхфәтуллин Зарифныкы божра тамга, Әхмәтов Бикмөхәммәтнеке ыңгырчак тамга булган. Башка төрле тамгалар да кулланылган.

Татар Алаты авылында яши торган Галиева Галимә апа (1918 елда туган) Урта Алат авылы тарихына кагылышлы мондый сүзләр сөйли (1970 ел): «Урта Алат авылында элек безнең бабабыз Кырманай яшәгән. Шуңа күрә авылны элек Кырманай (русча Курманаево) дип йөрткәннәр. Кырманай бабай кабере бүгенге көндә дә бар. Ул авыл уртасында калган Иске зиратта. Чардуганы да бар. Берәр кешенең кул-аягы яисә башка жире авыртса, адарынып шул кабергә килгәннәр дә дога кылганнар». Галимә апа сөйләгәннәр тарихи чыганаклардагы мәгълүматларга туры килә. Казан өязенен язу кенәгәләрендә (1602-03 еллар) Урта Алат авылында йомышлы татар Кырманай Киллербышев искә алына.

Галимә апаның бабасы каен агачы турында гыйбрәтле сүз язып калдырган: «Догачылары булмаганнарга каен агачлары дога тәслим итеп (укып), яфракларын тәсбих тарткандай шыбырдатып утырсыннар дип, кабер өстенә, мәет башына каен утырту кулай күрелгән».

Алат авылларының тарихы шактый катлаулы.

XX йөзнең беренче яртысында язылган һәм экспедиция вакытында филология фәннәре докторы Марсель Әхмәтжанов тапкан «Бәрәзә авылы тарихы» дип аталган кульязма чыганакта Казан ханлыгы яулап алынганга кадәрге чорда Алат авылында нугай кавемнәре яшәве турында сөйләнә. Бу чыганакка караганда, нугайларның (Нугай Урдасы татарларының) төп йорты хәзерге Биектау районына кергән Рус Алаты авылы урынында булган. Ханлык тар-мар ителгән вакытта бу авыл да туздырыла. Исән калган кешеләр күрше, аерым алганда Югары Масра, Иске Масра, Әшиасты, Олы Бәрәзә, Күшәр һ. б. авылларга күчеп утыралар. Фәнни экспедицияләр вакытында без бу авылларны йөреп чыктык. Авылда яши торган кайбер нәселләр үзләрен Алат авылыннан күчеп килгән нугайлар дип таный. Олы Бәрәзә авылында бер урам Нугай очы дип йөртелә, ә Бәрәзә авылыннан Алатка таба сузылган тауны Нугай тавы дип атыйлар. Бәрәзә тарихында тасвирланган вакыйгалар Казан артында, аерым алганда анын Арча төбәгендә булып узган катлаулы этногенетик процессларга ишарәли. Кульязмада бик әһәмиятле факт—Казан артында нугай татарлары компоненты булуы күрсәтелә.

Алат исемен алган этнотопоним һәм этногидронимнарны нугай татарлары кабилә-кавемнәре белән бәйләп карыйбыз.

Марсель Әхмәтжановның 2002 елда басылып чыккан «Нугай Урдасы: татар халкының тарихи мирасы» хезмәтендә «Алат авылының Казан ханлыгы чорында

Нугай мирзалары каласы булуы, аларның хәрби сословие тәшкил итүе аңлашыла»,— дип язылa.

Алат—татар кабиләсе исеме. Аларның Казаннан төньяккарак утыртылуы башкаларны төньяктан бертуктаусыз һөҗүм итеп торучы рус ушкуйникларыннан саклау өчен кирәк булган» (276-278 битләр).

Алат атамасы һәм этнонимы Татарстаннан читтәге төбәкләрдә, ягъни тарихи ватаныбыз җирләрендә дә шактый очрый. Тураш идарәсенә керә торган Тартас һәм Тары суының югары агымында утырган бараба далаларында яши торган татарларының бер авылы Алат исемен йөртүен тел галиме В. Радлов билгеләгән. Казахларның Кече Жузында алчин ыруы бар. Н. Аристов фикеренә караганда, бу ыру бик атаклы булган. 1718 елда Тобол губернаторына язган хатында Әбел-Хәир-Хан үз биләмәләрен «Алат олыслары» дип атый. Казахларның өч Жузы халкы да үзләренә нигез салучы шәхесне Алач дип атыйлар. Казах ривайәтләрендә кайчандыр аларның алатлар белән бер халык булуы, төньяк юнәлештә яшәве, ә сонрак алардан аерылып китүе турында сүз алып барыла. Кыргызларда да алат ыруы булган. В. Радлов аларны Бохара белән Шәрҗә арасындагы Кара Күл янында очрата. Алат этнонимы, төрлечә язылыш белән, ярым күчмә һәм күчмә үзбәкләрдә дә очрый. Төрекмәнстанның Казах районында төрекмәннәрнең ала-эли ыруын дәвам итүчеләр яши. Г. И. Карпов фикеренә караганда, ала-әлилар урта гасыр кыпчакларыннан килеп чыккан һәм аларда алат этнонимының бер төрдәше билгеләнгән. Төрекмән гидронимиясендә Алат атамасы алган кое бар. Енисей кыргызлары тарафыннан тар-мар ителгәннән соң алатлар Урта Азия җирләренә өч юнәлештә күчеп китәләр һәм кардәш төрки халыклар, аерым алганда, казах, кыргыз, үзбәк һәм төрекмән этногенезында катнашалар. Төрки телле алатларның Урта Азия җирләренә килеп керүе, тарихи чыганакларга караганда, безнен эраның беренче һәм икенче йөзләрендә булган, Төрки телле алатлар татар халкы этногензында да катнашкан. Алардан истәлек булып калган Алат этнотопонимнары һәм этногидронимнары шул хакта сөйли.

Авыл, бистә, тау, күл һәм башка географик атамаларны җентекләп өйрәнү нәтиҗәсендә телгә китерсән, алар җирле тарихны ачыклау өчен өстәмә мәгълүмат бирәләр. Мәктәп балаларын туган як тарихы, үткән гасырлар белән кызыксындыру өчен алар—менә дигән чыганак.

## Айбаш авылы

Айбаш авылы Биектау районына керә, ул район үзәге Биектаудан—41, Казаннан 36 чакрым ераклыкта урнашкан.

Айбаш авылы Казан ханлыгы чорыннан ук билгеле. Казан өязенең теркәү кенәгәсендә аның атамасы еш телгә алына. Археологлар Айбаш авылы зиратында XVI йөзнең беренче яртысына мөнәсәбәтле кабер ташы тапканнар. Бу таш Һ. В. Йосыпов хезмәтендә дә теркәлгән. Татар шәҗәрәләрен, кабер ташларын тикшерә торган галим, филология фәннәре докторы Марсель Әхмәтҗанов: «Биектау төбәгендә борынгы татар кабер ташлары Айбаш, Мәмдәл, Өбрә, Красна, Чуваш иле һ. б. кайбер авылларда да саклана. Ләкин алар әлегә өйрәнелмәгән»,—дип яза. 1793—1803 елларда үткәрелгән Генераль ызанлау документларында Айбаш искә алына. Авылдагы 60 хуҗалыкта 172 ир-ат һәм 198 хатын-кыз көн итә дип теркәлгән.

Авыл атамасы тарихчы галимнәр Д. А. Корсаков, И. Н. Ермолаев, А. Артемьев, И. А. Износков, Н. К. Берстель, Н. Н. Вечеслав хезмәтләрендә искә алына. Д. А. Корсаков җыентыгында (XVIII йөз) Айбашта 175 ясак түли торган татар, Питиал суының югары агымына утырган яна аерылып чыккан Түбән Айбаш авылында 37 ясаклы татар яшәве әйтелә. А. Артемьев җыентыгында күрсәтелгәнчә, авылда 78 хуҗалык булып, аларда 317 ир-ат һәм 338 хатын-кыз яшәгән. Авылда бер мәчет булган. XIX йөз тарихи мәгълүматларын туплаган китапта күрсәтелгәнчә, авылдагы 60 хуҗалыкта 201 ир-ат хатын-кыз яшәгән. Авылда бер агач мәчет эшләгән. И. А. Износков Бәкара чишмәсе янына, Гәреч сәүдә юлының уң ягына урнашкан авылны Олы Айбаш дип атый һәм түбәндәгечә сурәтли: «Авылдагы 154 хуҗалыкта ислам

дине тота торган 445 ир-ат һәм 446 хатын-кыз яши. Алар Олы Айбаш авылы җәмгыятенә керәләр. Авылда халык бай яши, араларында он тартучылар, балта осталары, мич чыгаручылар, башмакчылар, пыяла куючылар, умартачылар бар». 1898 елгы китапта авыл Олы Айбаш дип атала һәм анда татарлар яшәгәнлеге күрсәтелә. К. П. Берстель җыентыгында әйтелгәнчә, Айбаш авылында 429 татар көн иткән.

Нажия Борһанова мәгълүматларына күрә, Айбаш авылы халкы күршедәге Чуаш иле, Зур Кавал, Кече Кавал, Олы Күлбаш, Кече Күлбаш, Мажар, Мәмдәл, Юртыш, Янавыл, Чүрчиле һәм Упса башы авыллары белән берләшеп июль уртасында Кабак җыены үткәргән.

Авыл халкы җыен бәйрәмнәрен көтеп алган, яраткан. Каюм Насыйри «Җыен бәете»ндә җыен турында мондый сүзләр яза:

*Ушбу җыен дигәнебез буладыр матур җәй көне,*
*Һөнәр иясе булганнар, бик хуплап көтә моны.*
*Атамыздан, бабамыздан кала килгән ушбу дип,*
*Сарыф итә җыен өчен, юкларыны бар итеп.*
*Өч ай алдан хәзерләп куядыр киракләре,*
*Гәр бәнагаһ (әгәр көтмәгәндә) бармый калса, янадыр йөрәкләре...*

*Килә чәһәршәмбе көн алырга сала кешесе,*
*Күп вакыт өлгермәгән буладыр кала кешесе.*
*Җитешкәч тә утырып чыгып китә,*
*Бара азрак та чәй эчәр җиргә җитә,*
*Чәй эчәр җиргә җиткәч, сайлый урынның яхшысын,*
*Юлда чәй эчкән булып, бетерә күчтәнәченең яртысын.*
*Юлда күрсәң син аны, белерсең гүя купец;*
*Барлык алган нәрсәсе һәм акчасы,—бары бурыч...*

*Имди ушбу рәвештә авылга кайтып җитә,*
*Өсте-башы яхшы булса, авыл кешесенең исе китә...*
*Өч-дүрт көне үткәч, кайта җыеннан әйләнеп,*
*Хисап итеп карасалар, бурычка беткән бәйләнеп.*
*Бәгъзысыннан чәен алган, бәгъзысыннан шикәрен,*
*Бәгъзысыннан көмәч алган, бәгъзысыннан икмәген.*

Гомәр Саттаров Айбаш авылы атамасын: «Айбаш—Биектау районындагы татар авылы. Бу атаманың килеп чыгышы борынгы телебездә кеше исеме булып йөргән Айбаш белән мөнәсәбәтле»,—дип аңлата.

Айбашта мәчет бинасы сакланып калган. Казан губернасындагы мөселман мәхәлләләренең 1909 елгы кәгазьләрендә Айбаш авылы мәхәлләсенең 319 ел элек, ягъни 1590 елда барлыкка килүе хакында мәгълүматлар бар. XX гасыр башында мәхәлләдә 548 ир-ат һәм 555 хатын-кыз исәпләнгән. Мәчет бинасының кайчан төзелүе мәгълүм түгел. Шул ук хәбәрләрдә 1858 елда салынган мәчет телгә алына. Күрәсең, яңа бина 1910—1917 еллар арасында төзелгән булган.

Чыганакларда руханилар хакында мәгълүматлар бирелә. 1831 елның 25 апрелендә имам булып Зәбир Исхаков билгеләнгән, икенче мулла булып 1863 елның 3 июнендә аның улы Мифтахетдин Зәбиров сайланган (туган вакыты 12. 04. 1838). Мифтахетдин хәзрәт, руханилыкның барлык баскычларын да узып, ахун дәрәҗәсенә ирешкән. 1900 елның августында аңа ярдәмгә туганының улы Габделкаюм Габделгалләм улы Зәбиров билгеләнгән (туган вакыты 13.11.1875). Ул Казандагы Апанаев мәдрәсәсендә укыган.

Мәхәллә мәдрәсәсендә 55 ир бала һәм 48 кыз бала белем алган.

Явыз Иван Казанны буйсындырган заманда, урыс патшасы тарафыннан зәрлекләнгән бер югары катлау кешесе үзенең уллары белән бу якларга килеп утырган. Үзенең Айбаш исемле бер улын ул Айбаш авылы оешачак урынга

калдырган. Авыл атамасы шушы кешенең улы исеменнән алынган дип фараз ителә. Бай кеше улы урнашкан урман буендагы Коләле дип аталган күл буенда авыл барлыкка килә. Монда авыл булганлыгын раслаучы фактлар хәзерге көнгә кадәр сакланган. Ул урында кабер урыннары билгеле.

Ул заманнарда авыл тирәләрендә калын урманнар үскән. Кыргый җәнлекләр кешеләргә шактый зыян китереп торганнар. Шунлыктан авыл халкы тынычрак урынга күчеп утыру ягын кайгырта башлаган. Авыл халкының бер өлеше Яңавыл дип аталган авылны нигезли.

Еллар узган, авыллар үсә һәм зурая барган. Айбаш авылыннан тагын берничә хуҗалык чәчүлек җире булган ачык урынга күчеп китәргә уйлаган. Алар мари урманы буендагы аланга килеп урнашканнар. Күчеп китүчеләр авылларын Көек дип атаганнар. 1935 елга кадәр бу авыл рәсми әйтелештә һәм язылышта Айбаш Көеге дип йөртелгән.

Заманнар үткән, Айбаш авылы күп хуҗалыклы зур авыл булып үсеп киткән. Аннан тагын берничә хуҗалык аерылып чыккан.

Айбаштан якын гына үзенең матурлыгы белән күпләрне гаҗәпкә калдыра торган бер күл бар. Күл урман буенда урнашкан һәм ерактан каралып күренеп торган. Шунлыктан халык аны Кара күл дип атап йөрткән. Авыл халкы арасында аерылып чыгу турында сүз куергач, халык шушы матур урынны сайлаган. Авыл исемен дә Кара күл дип кушканнар. 1930 елларга кадәр авыл рәсми рәвештә Кече Айбаш дип аталган. Бу хәл аның Айбаш авылы белән турыдан-туры бәйләнеше барлыгын күрсәтә.

Яңавыл исеме алган авыл да шактый үскән. Аннан да берничә гаилә аерылып чыккан. Алар мари урманы буендагы Ужа дип аталган урман буена барып утырганнар. Авыл Упса яки Упса башы (Апсабашы) дип атала.

Шулай итеп, Айбаш авылыннан Яңавыл, Каракүл, Көек һәм Упса авыллары аерылып чыккан.

1930 елларга кадәр Айбашта барлыгы 200 крәстиән хуҗалыгы, 2 җил тегермәне, 2 байлар кибете, тимерчелек булган.

Айбаш авылы табигатьнең матур урынында урнашкан. Авылның ике ягында зур урманнар җәелеп ята. Авыл тирә-юнендә сигез чишмә ага. Авыл тирәсендәге атамаларның тарихы ерак чорларга барып тоташа.

Авылдан ерак түгел Аракы чокыры дип аталган болын һәм шул исемдә чишмә бар. Бу урында күл дә булган. Берничә грузин милләте кешесе бу урында аракы заводы корганнар һәм аракы кайнатып сатканнар. Завод инде күптәннән юкка чыкса да һәм күлнең урыны гына калса да, болын һәм чишмә әле дә Аракы чокыры дип йөртелә.

Айбаш һәм Мәмдәл авыллары арасында Чиркәс болыны дигән урын бар. Күп еллар элек бу болынга бер чиркәс кешесе килеп зур сарай салган (постоялый двор). Ул атлар белән йөрүче кешеләрнең кунып китү урыны булган.

Авыл янындагы бер болын Келәтле елга дип атала. Күп еллар элек бу болын башында, урман буенда салкын сулы чишмә булган. Монда су тегермәне корып куйганнар. Заманалар узган, су саеккан, тегермәне беткәч тә аның келәте озак вакытлар сүтелмичә сакланган. Шунлыктан бу болын хәзер дә Келәтле елга дип атала.

Авылда Ташлы чишмә, Тау асты чишмәсе, Куш чишмә, Каран чишмәләре ага. Халыкның изге урын дип саный торган җире—Ташбилге. Бу урында бер изге әби күмелгән дип сөйлиләр. Авыл халкы бу каберне карап һәм чистартып тора. Олылар килеп кабер янында дога укыйлар һәм нәзер сәдакалары куялар.

Мулла печәнлеге болыны, Хәбибулла кабыргасы аланы, Шәйхи сазы атамаларын да еш ишетәсең. 1930 елларга кадәр бу урыннар ул кешеләрнең шәхси милке булып исәпләнгән.

Авылдан якын гына урнашкан урманны халык Кәҗүнни дип йөртә. Бу атама урыс телендәге казенный яки казна урманы дигән сүздән барлыкка килгән. Электә урман казнаныкы булган һәм гади халыкка урманнан файдалану тыелган.

Авыл янында бер тау бар. Аны халык Бәрәңге тавы дип йөртә. Бу тирәләрдә

элек бәрәнге басулары булган.

Янавыл янындарак Мослы тавы урнашкан. Бу урын тирә-юньдә иң биек урын булып исәпләнә. Күренекле таулардан тагын Абдул тавын искә алып китәргә мөмкин.

Авыл башында гына бер кечкенә буа бар. Аны халык зурлап Елмаем күле дип йөртә. Бу буа әле чагыштырмача яшь. Аны Елмаем кушаматлы авыл егете ясаган дип сөйлиләр. Егет яшьли үлеп китә, буа һаман аның кушаматын йөртә.

Айбаш халкы тәртипле һәм динле булган. Авылның соңгы мулласы Мифтах хәзрәтнең дәрәҗәсе бик югары исәпләнгән. Авылда элек аракы эчү һәм тәмәке тарту каттый тыелган.

30 нчы елларда мәчетләрнең манараларын кисү афәте килгәч, Айбаш авылы мәчете манарасы киселми кала. Сәбәбе гади генә. 1936 нчы елда авылга Ленинград хәрби округыннан җибәрелгән хәрби топограф Мөбәрәкшин хәрби карта ясау белән шөгыльләнгән. Мәчет манарасын кисәргә хәзерләнүләрен ишеткәч, топограф авыл советы рәисен: «Мин эшне бетереп киткәнче мәчет манарасына кагылмагыз, авыл тирә-ягын картага төшерү өчен бу манараны ориентир итеп алам»,—дип кисәтеп куя. Район военкоматына да шундый ук кисәтү була. Нәтиҗәдә инде клубка әйләндерелгән мәчет манарасы исән кала.

1981 елда мәчеткә дәүләт хисабына ремонт ясатыла. 1993 елда мәчет халыкка кире кайтарыла.

Айбаш хәзер зур, хуҗалыгы 200 дән артык. Урамнарның исемнәре түбәндәгечә: Югары як яисә Мәчет урамы, Аръяк, Тегермән (Тирмән) урамы, Арт урам, Түбән як, Тимерче урамы. Бер урамны Котылдым дип йөртәләр. Бу урамда элек-электән төп йорттан аерылып чыгып, кайнана-кайнаталардан аерым яшәгән гаиләләр шактый булган.

Авылда мәктәп унберьеллык, бинасы ике катлы, матур итеп салынган. Клуб, элемтә үзәге, китапханә һәм балалар бакчасы бар, ике ел элек газ кергән. Юллар асфальтланган.

Авыл халкы зиратны тәртиптә тота, ул зурайтылып, өр-яңадан тотып алынган.

Ил һәм хәтта чит илләр күләмендә билгеле шәхесләрнең дә тамырлары Айбаш авылы белән бәйләнешле. Дингезче, контр-адмирал, географ-гидролог Исхак Ибраһим улы Исламовның (1865—1923) тамырлары Айбаш авылыннан, анда аның әтисе Ибраһим Исламов туган.

---

## Авторлар игътибарына

Редакциягә кульязма җибәргәндә түбәндәге мәгълүматлар булу мәҗбүри:

1. Фамилиягез, исемегез, әтиегезнең исеме
2. Яшәү урыныгыз
3. Туган ел, ай, көнегез
4. Паспорт мәгълүматларыгыз
5. Дәүләт пенсия страховкасының страховка таныклыгы номеры
6. ИНН номеры
8. Вертикаль портрет рәвешендәге яхшы сыйфатлы фоторәсемегез
7. Телефоныгыз (шәһәр кодын да күрсәтеп)



***—Галим һәм педагог буларак, Сез һаман яшьләр, студентлар арасында. Бүгенге көн студенты кем ул, нинди сыйфатларга ия? Педагогик белем алганнан соң халкыбыз тарихын, туган телебезне һәм милли гореф-гадәтләрне яшь буынга җиткерүдә лаеклы өлеш кертергә әзерме алар?***

**Әнвәр ХУҖИӘХМӘТОВ, Татар дәүләт гуманитар-педагогика университеты профессоры, РФ югары һөнәри белем бирү тармагының мактаулы хезмәткәре:**

—Бүгенге көн студенты моннан 15-20 ел элекке яшьтәш студентларыннан бик нык аерыла, билгеле. Кайсы яклары белән дигәндә, беренче нәүбәттә буыннар алмашы һәм җәмгыятьтәге тулаем вәзгыять җәһәтеннән дияр идем. Барыбыз да шаһит булдык: туксанынчы еллар башында, күз ачып йомган арада диярлек, СССР дигән дәүләт юкка чыкты. Кесә һәм кәнәфи сәясәтен беренче планга куеп, демократия дигән булып, барлык рухи-әхлакый кыйммәтләрне җимереп, вакытында иң куәтле, иң көчле саналган мәгариф системасын пыран-заран китерделәр.

Әйтик, элек укытучылар өчен льгота, ягъни ташламалар байтак иде: электр, утын бушлай, колхоздан хәтта ашлык та бүлеп бирелә иде. Боларны сагынып сөйләргә генә калды. Югарыда әйтелгән күп кенә сәбәпләр аркасында укытучыларның иң яхшы, алдынгы гвардиясе 1990 нчы еллар башында мәктәптән китеп барды, читләштерелде. Мәктәпләргә яңа китаплар кайтмады. «Демократик» сәясәтнең җимеше буларак, укытучылык мөнбәренә, мөгаллимлек эшенә әзерлеге түбән булган яңа кешеләр күтәрелде.

Менә шуның өчен дә без университетта уку елларында студентлар өчен татар халкының тарихы, гореф-гадәтләре, милли педагогика, сынлы сәнгать өлкәсенә аеруча игътибар бирергә тырышабыз.

Татар сәнгатенең барлык төрләрен өйрәнүне дә максат итеп куйдык. Биш ел дәвамында студентлар (ягъни булачак укытучылар) башкалабыз Казандагы барлык музейларны әйләнеп үтәргә тиеш. Халкыбызның, бүгенге Татарстан республикасының тарихын шундагы байлык-хәзинәләр аша гына ныклап өйрәнергә мөмкин. Иң аяныч—безнең мәгърифәтебез тарихы беркайда да өйрәнелмәгән. Югыйсә заманында Ушинский һәм Сухомлинскийлар безнең тәрбия мәктәбенә бик югары бәя биргәннәр. Иң мөһиме: алар балага фәкать туган телендә тәрбия бирүне алга сөргәннәр!

Безнеңчә, һәр студент бер ай эчендә бер татар спектаклен, яисә иҗат кичәләрен карарга тиеш. Бу инде безнең милләт өчен төнге клубларга йөрүгә караганда күпкә кыйммәтлерәк! Карау, тамаша кылу гына түгел, алар үзләре караган һәр спектальгә бәя, анализ да бирергә тиешләр.

Игътибар итәсездер: язучыларның Тукай клубында берәр очрашу, иҗат кичәләре булдымы, безнең студент яшьләр һәрвакыт шунда. Татарстанда, төгәлрәге башкалабыз Казанда сынлы сәнгать музее бар. Шаккатамын, менә шунда студент-яшьләр бер дә юньләп йөрмиләр икән. Югыйсә, бушлай гына керәсе бит...

Тагын бер максат куябыз: һәр студент бер ай эчендә берәр әдәби әсәрне укырга һәм аңа кыскача бәяләмә бирергә тиеш.

Яшьләр зур максат куеп, матурлыкка, яхшылыкка омтылып, киләчәккә таба карап яшәсеннәр иде.

# *Габделҗәббар Кандалыйның тууына 210 ел*

*Татар халкының мәшһүр шагыйре Габделҗәббар Габделмәҗит улы Кандалыйның (1797-1860) тууына быел 210 ел тула.*

*Габделҗәббар Кандалый элекке Самара губернасының (хәзерге Ульянов өлкәсенең) Иске Кандал авылында мулла гаиләсендә дөньяга килгән. Үз авылында башлангыч белем алганнан соң Чистай ягындагы Кизләү һәм Казан артындагы Кышкар кебек танылган мәдрәсәләрдә укыган.*

*Кандалыйның шигъри әсәрләре халык сөйләменә якын телдә иҗат ителүләре белән үз чорында ук шөһрәт казанган. Аның шигырьләре шәкертләр тарафыннан кулдан-кулга күчерелеп, халык арасында күп таралган.*

*Басмаларга килгәндә, Кандалыйның бер шигыре Салихҗан Күкләшев хрестоматиясендә (1859 елда) дөнья күргән, аннан соң бүтән әсәрләре башка җыентыкларга да кертелгәннәр. Шагыйрьнең иҗатына галим Каюм Насыйры киң игътибар биреп, үзе туплап чыгарган «Фәвакиһелҗөләсаэ фил-әдәбият» китабына (1884) Г.Кандалый әсәрләрен шактый күләмдә керткән.*

*Әдәбият һәм тел галиме, тәнкыйтьче Җамал Вәлиди Кандалый иҗатын беренче тапкыр фәнни яктан тикшергән. Ул 1912 елда басылган «Татар әдәбиятының барышы» хезмәтендә шагыйрь әсәрләренә хас үзенчәлекләр һәм лирик нәфасәт турында тәфсилләп язган.*

*Бай шигъри мирас калдырган әдипнең иҗаты совет хакимлеге елларында да әдәбият галимнәренең игътибар үзәгендә була. Г.Кандалыйның беренче шигъри китабы 1960 нчы елда дөнья күрә.*

*Күренекле галимебез Миркасыйм Госманов шагыйрьнең әдәби мирасын тирәнтен өйрәнеп, 1988 елда Г.Кандалыйның шигырьләре һәм поэмаларының тулы басмасын чыгарды. Шул җыентыктагы кайбер шигъри үрнәкләрне укучыларыбыз игътибарына тәкъдим итәбез.*

## Габделҗәббар Кандалый

* * *

**Иляһи, бу асыл кошны**
**Тубай агачына кундыр,**
**Иляһи, мин сабырсызны**
**Сабырлык юлына күндер!**

**Каләмем дә тая инде,**
**Ки яза алмай турыдан;**
**Яна бәгърем, сула йөзем**
**Авырлыклардин, гуредан.**

**Языйм микән, җитәр микән?**
**Язу файда итәр микән?**
**Бу кайгулар бетәр микән,**
**Гомерлеккә китәр микән?!**[1]

Тубай (туба) агачы – җәннәт агачы.
Гуредан – горедан (русча – горе): кайгыдан.

* * *

Ерак йирдә газиз башың,
Янында һич юк юлдашың,
Мөшкелдер сәнең тормышың,
Сабырлык булсын юлдашың.

Пароходлар төшкән чакда,
Газиз балам, сәне көтдем;
Әткәң-әнкәңне калдырып,
Туган илдән ерак китдең.

* * *

Тагын азрак [бән] язаем, йитәрме,
Бу хәсрәтләр йөрәкемдән китәрме?

Балакаем, сәна һич юк бүләгем,
Кауышмакда хәер-дога теләгем.

* * *

Бу сүземә инангыл, и гүзәл йар.
Мәңа юкдыр сәндин үзгә вәфадар.

Мәнем бер сәндин үзгә сәрдәшем юк,
Хода белүр: сәнеңдик тиңдәшем юк.

Дидем сәңа тәмами сүзләремне,
Тулидүбән йәш илә күзләремне.

Моны яздыкда итдем берничә аһ,
Дәйүб: «Мәңа мәдәд бир, раббым, аллаһ!»

* * *

Бәнем җаным сәнең җаның имәсме,
Бәнем җаным сәңа кабул имәсме?
Сәнең җаның бәнем корбаным улсын,
Кулың—ястык, сачең юрганым улсын!

* * *

Җөмлә гөлнең нуры китә
Сачак вакытлары үткәч;
Матур кызның кадре китә
Егерме йәшенә йиткәч.

Җиһан багълары ки нурлана
Җөмлә гөлләр сачак аткач;
Бәнем күңлем тынычланыр
Сәнең куйын гынаңа яткач!

* * *

Бу хатымны кабул итеп аласың,
Кабул итсәң, читен өзеп каласың[1].

Сәнең өчен аһе-ваһ органларым,
Бер күрергә тилмереп торганларым!

Каным, сәүгән йөрәгем парәсе сән,
Тәнем рухы, күземнең карасы сән.

Хода язсын мөкъәддәр каләмендә:
Кауышдырсын бу дөнья галәмендә.

---

Вәфадар – ышанычлы, тугърылыклы.
Тулидүбән – тулы идубән: тулы итеп.
Мәдәд – ярдәм.

**Кыяфәтең, сыйфатың суда кондыз,**
**Үзең былбыл, күзең мисальдә йолдыз.**

**Сәнең дәрдең беләң даим йөримен,**
**Сәне күргәч, сары майтик эримен!**

**Сәнең дәрдең билә булдым герифтар,**
**Хода кыйлса иде сәне, гүзәл йар!**

**Сәнең буең Ак Иделнең камышы,**
**Сүләгән сүзләрең былбыл тауышы.**

**Сәнең өчен акыздым күздә йәшем,**
**Бу хәсрәтдин чыкар микән бу башым?!**

* * *

**Китабларда бу сүзне күргәнем бар:**
**«Оялган кемсәнең ризкы булыр тар;**

**Икеләнеп, оялып корган эшләр**
**Сүтеләдер, сүреләдер!»—димешләр.**

**«Биреңез ук!»—дигел, бер дә оялма,**
**Сүзем будыр сәңа, жаным, багалма.**

**Сәнеңчөн нә дәкле бән әйләдем зар,**
**Әгәр ялган дисәң, бер ходаем бар!**

**Бу инәлүләрем таш да белерде,**
**Урыс кызы динен ташлап кәлерде.**

**Ишетмәдең, жаным, фөрйади-зарый,**
**Йитәр инде, инәлмәм мондин арый.**

**Күп ирде лә язсам хатка тагы да,**
**Туласы булды ла ике ягы да.**

**Йитәр, сүзне йибәрмә күп озынга,**
**Дәхи инәлдерәм диеп кузынма.**

**Әйа жаным, вәйа жаным, жәмалем,**
**Сәнең өчен өзеләдер бу жаным!**

**Әдәбле диделәр ки әһле инсаф,**
**Тәнигә кул тимәгән диделәр: саф.**

**Нә хурлыкдыр сәнең кебек матурга**
**Надан астында мимылдап ятырга!..**

---

Мөкъәддар—тәкъдир, язмыш.
Мисальдә—чагыштыруда.
Герифтар—дучар.
Фөрйади-зарый—зардан кычкырап еглауны.
Кузыну—кызулану, исәрләнү; кәпәренү (куз—«утлы күмер» тамырыннан).

# ХӘТЕРЛӘРДӘ КАЛДЫ

Хәтерлим әле: университетның татар теле һәм әдәбияты бүлегендә укый башлагач ук, без Кояшны группабызның комсоргы итеп сайлап куйдык. Үз-үзен шактый җитди тотуына игътибар иткәнбездерме, кураторыбыз Фәрит Хатипов тәкъдименә болай гына кушылганбыздырмы, без бу кандидатураны бер тавыштан якладык. Ул безнең өметләрне чыннан да аклады. Взнос җыю, җыелыш үткәрү генә димәгән, безне төзүчеләрнең тулай торакларына агитатор итеп тә билгеләде әле ул. Кем халыкара хәлләр турында сөйли, кем әдәбият һәм сәнгать яналыклары белән таныштыра, кем театр спектакльләренә культпоходлар оештыра...—беркемне дә буш тотмый. Кайбер кызлар (ә алар төркемебездә безгә караганда шактый аз иде), үзен эрегә саный ул, дип йөрсәләр дә, егетләр алай вакланып маташмадылар—чөнки һәркайсы диярлек, яшерен булса да, бу чая һәм чибәр туташка гашыйк иде. Хәер, без генә микән?!

Кояш җәмәгать эшләрендә дә, уку буенча да актив булды. Менә дигән педагог чыгар әле аннан, дип уйлый идек без. Ә ул, университетны тәмамлагач, бөтенләй икенче юлдан китте—журналистлык һәм язучылык һөнәрен сайлады. Югыйсә Мидхәт Миншиннан, Фаяз Дунайдан һәм миннән башка шагыйрь яки прозаик булырга дәгъва иткән кеше юк иде бугай безнең арада! Кояш, университетны тәмамлар-тәмамламас борын ук, «Азат хатын» журналы редакциясендә эшли башлады. Иң гаҗәбе: ул анда мәкалә һәм очерклар гына бастырып калмады, әдәбият дөньясына да үтеп керде. Хикәя һәм повестьлар язу гадәти белем генә түгел, ул әдәби талант өстенә ниндидер хыялыйлык, чынбарлыктан аерылганлык һәм бай тормыш тәҗрибәсе дә таләп итә бит әле! Ә Кояш барыннан да бигрәк дөньяви зат, бөтенесен акыл бизмәненә сала торган кеше иде. Аның кырыс укытучылар гаиләсендә тәрбия алып үсүе, дөньяны фәкать ак һәм кара төсләргә генә бүлеп каравы, ярымтоннарны өнәп бетермәве дә үз ролен уйнагандыр. Алтмышынчы елларда Татарстан һәм Башкортстан газета-журналларында, Татарстан китап нәшрияты чыгарган күмәк җыентыкларда басылган хикәяләренең күбрәк журналистикага нисбәтле булуы күп очракта автор иҗат манерасының әле анык билгеләнмәве белән дә аңлатылгандыр. Әйе, журналистлык шаукымы аның зуррак күләмле әсәрләрендә—повестьларында да сизелә иде. Бу яктан аның «Кышкы талпыну» һәм «Ярлар биек» повестьлары гына аерылып тора. Хәер, жанрларның чикләрен тиешенчә тоя алмау бүгенге яшь буын язучыларында да, хәтта Мәскәүнең бүген актуаль темаларга алынган кайбер прозаиклар иҗатында да чагыла. К. Тимбикованың Чаллы автогигантын төзүчеләргә багышланган очерклар сериясе өчен «КамАЗ төзелеше ударнигы» билгесе, БАМ турындагы язмалары һәм журналистика өлкәсендәге казанышлары өчен Татарстан журналистларының Х. Ямашев исемендәге премиясе һәм «Республиканың атказанган мәдәният хезмәткәре» дигән мактаулы исем алуы үзе үк—гыйбрәтле фал. Ул барыннан да бигрәк тырыш, тынгысыз, эзләнүчән журналист-язучы иде. Аның карашлары университетта уку дәверендә үк калыпланган һәм алар гел үзгәреп торган чынбарлыкның ничек бәяләнүенә һич кенә дә бәйләнмәгән иде. Мондый хәлләрне безнең буын кешеләренең байтагы кичерде.

Теге яки бу язучының иҗат юнәлеше, идеологик мәсләге, әсәр сюжетының корылышы, конфликтларның катлаулылыгы, ниһаять, персонажларның үзенчәлеге турында аның үзеннән башка бер тәнкыйтьче яки әдәбият

белгече дә тәгаен генә аңлата алмыйдыр. Биниһая ихлас җанлы Кояш Тимбикованың әдәби әсәрләре, уйдырма булудан бигрәк, реаль күренешләрне сурәтләве, «шагыйрәнә ялган»нан качып, конкрет ситуацияләргә мөрәҗәгать итүе, очеркларында һәм истәлек язмаларында исә чын әдәбилеккә омтылуы, нәфис сәнгать таләпләренә буйсынырга тырышуы—бу игезәк жанрларны якынайта, аларны тормышчанрак итә иде. Аның илле еллык бәйрәме алдыннан «Казан утлары» журналында басылган «Ник сагынам икән?» дигән автобиографик әсәре бик күп сорауларга җавап бирә, минемчә. Бу әсәр интонацияләрнең ачыклыгы, авторның ихласлылыгы белән җәлеп итә. Аның мәшһүр шагыйрәбез Сажидә Сөләймановага багышланган «Шагыйрәнең хыялында йөрткән китабы», атаклы артистка Наилә Гәрәева турындагы «Мәхәббәт—бер генә» исемле язмаларын да «мәкалә» дигән жанр белән тамгаламас идем мин. Аларда язучының үзенең бай тормыш тәҗрибәсе, шәхси уйланулары, шатлыкборчулары чагылган. Бер гыйбрәтле мисал гына китерим: «Олуг иленнең иң зур җитәкчеләре дә, бөтен дөнья алдында ялган сөйләүдән, кеше җанын кыюдан тартынмыйлар икән, гаделсез сугышларда сөлектәй егетләрнең гомере өзелә икән, күпме булачак галимнәр, талант ияләре кырыла икән,—каләм очы белән көн кичергәннәр арасында гына рәхим-шәфкатьне кем күрсәтсен?..»—ди ул. Әле телләр бәйле, әйтәсе килгәнне «ачык текст» белән аңлатырга гына җыенган еллар иде ул. Әле генә телгә алынган автобиографик әсәрендә дә ул бер партия җитәкчесенең аны «сәяси сукырлык»та гаепләвен ачыктан-ачык язып чыккан иде. Кемнең кемлеген гомер кичә-кичә генә аңлыйсың шул!



*Венера Ихсанова һәм Кояш Тимбикова.*
*Үткән гасырның 60 нчы еллары.*

Әле университетта уку елларында Кояшның, безнең егетләр «тәртәгә типкәләгән» чакларда, аларга каты кагылуы, нәсыйхәтләр укуы да, материаль яктан безгә караганда әйбәтрәк тәэмин ителсә дә, безнең белән Тәмтенең Идел сусаклагычы астында калачак урманнарын кисешеп йөрүе дә, бер генә физик эштән чирканмавы да, хәтта соңыннан, инде аякка баскач, еллар буе түли-түли кооператив фатир төзетеп, тотрыклы гаилә корырга тырышуы да минем күңелдә матур хисләр уятты.

Байтак еллардан соң, мин аның ахири дусты язучы Мәдинә Маликовага өйләнгәч, безнең аралашулар бигрәк тә ешаеп китте. Үзара кунакка йөрешүләр, эчкерсез сөйләшүләр гадәти күренешкә әйләнде, уйлар-фикерләр һәрвакыт уртак булды. Хәтта Васильеводагы бакча йортларын да без янәшә, бер үк урыннан юнәтелгән төзелеш материалларыннан салдык. Берәр кунак килеп чыкса, алар өенә дә, безгә дә сугылмыйча калмый иде.

Кояш ире белән бәхетле идеме—анысын кистереп кенә әйтә алмыйм. Иң күңелне төшергәне—хатын-кыз өчен бигрәк тә—аларның дәвамчылары, балалары булмады. Аннан, йөрәкне тагын бер кат җәрәхәтләгәне: күпме гомер бергә яшәгәннән соң, ире Рейнның авыруы башлавы. Ул чорларда бәлаләр Кояш өстенә бер-бер артлы килеп кенә торды. Карт укытучы әнисен карап тәрбияләүне дә ул үз җаваплылыгына алган иде. Абыйсының, тәмам паралич сугып, урын өстенә калуы да шул ук Кояшка өстәмә мәшәкатьләр

тудырды. Югалту артыннан югалту... Газиз әнисенең үлүе... Күпме гомер иткән ире Рейн белән бәхилләшү... Нечкә күңелле Кояшка—хәтта спектакльләрнең фаҗигале мизгелләрен караганда да күзләреннән яшьләр атылып чыккан, хискә бирелүчән Кояшка—бу авыр хәлләрне кичерү җиңелдән булмагандыр. Йөрәк бер генә бит ул! Болар аны иҗаттан аерса, эшендәге аңлашылмаучылыклар да аны чыгырыннан чыгара, җан тынычлыгын боза иде. Сабакташыбыз торган саен күңел төшенкелегенә бирелә барды. Әмма горур холыклы каләмдәшебез кем алдында булса да зарлануны, күз яше түгүне кирәк санамады. Бәлки эч серләрен күршедә генә яшәгән композитор Сара Садыйковага, җырчы Вафирә Гыйззәтуллинага, артистка Наилә Гәрәевага, журналистка Фәния Хуҗиәхмәтовага сөйләштергәләгәндер—соңгы елларында алар белән дус иде ул. Ә бәлки сөйләмәгәндер дә... Кем белә?! Ул бик тырышып төзеткән бакча йортларының бик серле рәвештә янып китүе дә, халык әйтмешли, чүп өстенә чүмәлә булгандыр. Иҗат өлкәсендә Каф тауларын яулый алмау, гаиләсендәге күңелсез вакыйгалар аны көннән көн күңел төшенкелегенә этәрде, элекке көләчлекне гаделсезлекләргә рәнҗү, яшьлектәге хыялларның җимерелүенә ачыну хисләре алыштырды. Алар кайчандыр үз бәясен үзе белгән, горур Кояш Тимбикованы тормыш дилгезенен читенә этәргәннән этәрә баргандыр.

...Кышның да иң зәмһәрир суык көннәренең берсендә хушлаштык без аның белән. Берничә сабакташы, элекке хезмәттәшләре, якын туганнары өчен бу хәбәр гайре табигый да, ышанмаслык та иде. Чөнки аны якыннан белгән кешеләр Кояш Тимбикованың озаклап авырып ятканын да, сәламәтлегеннән зарланганын да хәтерләмиләр, ул аларның күз алдында һаман да шаян, елмаючан, кинаяле сүзле, ләкин һәрвакыт мөлаем ханым булып күңелгә сеңгән иде.

Әлбәттә, ул көнне кайгы сүзләре сөйләнде, уфтанылды. Аннан өсте ябык машина, акрын гына кузгалып, Чистай тарафларына—язучының туган ягына—юл алды...

Менә аның да тууына 70 ел үтеп киткән икән. Үзе исән булса, без бу көннәрдә аның иҗат бәйрәменә җыелыр идек...

**Әхмәт РӘШИТ**

---

# ХИКӘЯЛӘР КОНКУРСЫ ДӘВАМ ИТӘ!

«Казан утлары» журналының 1000 нче саны чыгу уңаеннан, узган ел **«Яңа дәвер кешесе»** дигән хикәяләр конкурсы игълан иткән идек. Бу иҗади ярыш—хикәянең укучылар өчен дә һәм әдипләребез өчен дә тансык жанр икәнлеген күрсәтте. «Конкурска!» дигән тамга белән хикәяләр өзлексез килә тора. Шул сәбәпле әлеге конкурсны 2008 елның азагына чаклы дәвам итәргә булдык.

Исегезгә төшерәбез, конкурска килгән хикәяләрнең күләме бер табактан артмаска тиеш, җиңүчеләрне акчалата бүләкләр көтә:

**I урынга—25 мең сум**
**II урынга—15 мең сум ( ике бүләк)**
**III урынга—10 мең сум (өч бүләк)**

*«Казан утлары» журналы редакциясе*

## *«Татар энциклопедиясе» битләреннән*

# Г

**ГАФФАР** (Гаффаров) Әхәт (Габделәхәт) Габдрахман улы (1.1.1949, Балык Бистәсе р-ны Олы Әшнәк а.), прозаик, драматург, ТАССРның атказ. сәнгать эшлеклесе (1990). Казан ун-тын тәмамлый (1971). «Яшь ленинчы» (1971-74), «Социалистик Татарстан» (1974-79) г-таларында, «Казан утлары» ж-лында (1979-82) эшли. 1982-87 дә ТАССР Язучылар берлегенең Әлмәт бүлегендә җаваплы сәркәтип. Бүлек мөдире, хәбәрче вазифасында «Шәһри Казан», «Ватаным Татарстан», «Казан утлары» редакцияләрендә эшли. Г. әсәрләренә татар халык иҗатының, фольклорның йогынтысы зур. Әсәрләрендә тормыш вакыйгалары, заман проблемалары фәлсәфи планга корылган, метафора, символ-мәгънә синтезы өстенлек итә. Ул «Язлар моңы» (1973), «Гозер» (1975), «Кашан җыры» (1977), «Су астындагы чишмә» (1980), «Бишек» (1980), «Дәрья башы» (1985), «Яшиселәр алда әле» (1987) кебек психологик повестьлар авторы. «Әҗәт» (1972; русчага тәрҗемәсе «Долг», М., 1983) хикәясендә фронтта һәлак булганнар алдында әхлак бурычы, дуслары һәм туганнары өчен җаваплылык хисе тою турында сүз бара. «Яра» (1973) повесте катлаулы язмышлы геройлар, аларның борчулы уй-кичерешләренең сурәтләнүе б-н аерылып тора. «Бодай бөртеге һәм тегермән ташы» (1983; русчага тәрҗемәсе «Зерно и жернова», М., 1991), «Олы юлның тузаны (1989), «Богау» (1998) романнарында, «Энә күзе» (2006) җыентыгында тупланган драма, повесть, хикәләрендә заманның аеруча да четерекле проблемалары күтәрелә: экологик һәм әхлакый һәлакәт, халыкта милли үзаң уяну, авыллар бетү куркынычы, сталинизм китергән бәла-казалар. Г.ның драматургиясе дә үзенчәлекле. «Иртәгә улың булам» (1977 дә сәхнәләштерелә), «Җиләк вакыты бер генә», 1978 дә сәхнәләштерелә), «Соңгы ләкләк» (1980 дә сәхнәләштерелә), «Бер картлыкта, бер яшьлектә» (1981 дә сәхнәләштерелә) пьесалары Татар драма һәм комедия т-рында, Минзәлә, Яр Чаллы, Стәрлетамак, Оренбург т-рларында куела. Замандашлары образларын чагылдырудан тыш, Г.ның күренекле тарихи шәхесләргә багышланган пьесалары да бар: Мулланур Вахитовның тормышыннан «Сызылып таңнар атканда» (1984 тә сәхнәләштерелә), Муса Җәлилгә багышланган «Хөкем» (1981 дә сәхнәләштерелә), Габдулла Тукай турында «Соңгы сәгать» драмалары. Г. шулай ук балалар өчен хикәяләр, татар әдәбияты һәм сәнгате турында публицистик һәм әдәби-тәнкыйть мәкаләләре, татар мәдәниятенең күренекле шәхесләре турында очерклар авторы. Әсәрләре рус, башкорт, эстон, әрмән, инглиз, испан, француз, немец телләренә тәрҗемә ителгән.

Әд.: Скальская Е. Жизнь - как продолжение поэзии // Сов. Эстония. 1976. 9 дек.; Алексеева Т. С верой человека // Лит. газета. 1986. 28 мая ; Идрисов Р. Кече күңелле һәм горур // Ватаным Татарстан. 1999. 22 гыйнв.

*Р.Ә.Мостафин.*

**ГАШЕК** (Hasek) Ярослав (30.4.1883, Прага - 3.1.1923, Липнице ш.), чех язучысы. Танылган «Солдат егет Швейк» («Похождения бравого солдата Швейка во время мировой войны», 1921-23, язылып бетмәгән) сатирик романы авторы. 1915 елда Австро-Венгрия гаскәренә алына, тиздән русларга әсирлеккә төшә. 1918 нең апрелендә Кызыл Армия сафларына баса, Гражданнар сугышында катнаша, күп кенә г-таларда (ш.и. армия г-таларында) язышa. 1919 да Кызыл Армия частьлары б-н хәзерге ТР җирләрендә була, октябрьдән декабрьгә кадәр Бөгелмә шәһәре хәрби коменданты ярдәмчесе булып тора. Бу вакытта булган вакыйгаларны 1921 дә Прагада басылган «Бөгелмә шәһәре коменданты» («Комендант города Бугульмы»), «Тәре күтәреп йөрү» («Крестный ход»), «Стратегик уңайсызлыклар» («Стратегические затруднения»), «Бөгелмәнең шөһрәтле көннәре» («Славные дни Бугульмы»), «Яңа куркынычлар» («Новые опасности»), «Потёмкин авыллары» («Потёмкинские деревни») исемле сатирик, юмористик хикәяләрендә һәм очеркларында чагылдыра. 1960 нчы елларда гротеск формада рев-ция вакыйгаларын тасвирлаган бу әсәрләр Татарстан периодик басмаларында С.И.Антонов тәрҗемәсендә басылып чыга. 1966 дан Бөгелмәдә Г. музее эшләп килә.

Әсәр.: Собр. соч.: В 6 т. М., 1983-85.

Әд.: Антонов С. Гашек шагает по Поволжью. К., 1964; Если бы имел десять жизней. М., 1990.

*Р.Ә.Мостафин.*

**ГАЯЗОВ** Мансур Гаяз улы (5.10.1917, хәзерге Марий Эл Респ-касы, Бәрәңге р-ны Бәрәңге а. - 19.11.1943), шагыйрь. Бәрәңге пед. уч-щесын тәмамлаганнан соң

*Дәвамы. Журналыбызның 2005 ел, 4 саныннан басылып килә.*

(1932) туган авылында укыта. 1936 елдан вакытлы матбугат битләрендә аның патриотизм белән сугарылган шигырьләре һәм поэмалары күренә башлый («Тормышны сөю», «Испанка»). Аерым шигырьләре «Алмаш» балалар альманахына (1938), «Бәхетле яшьләр» (1939), «Дуслык» (1940) күмәк җыентыкларына керә. Бөек Ватан сугышында катнаша. Фронт г-таларында язышa. 1959 дә «Шигырьләр» исемле җыентыгы дөнья күрә. Витебск өлкәсенең Ускорово авылы өчен барган сугышта һәлак була.

Әд.: Даутов Р.Н., Нуруллина Н.Б. Совет Татарстаны язучылары: Биобиблиогр. белешмә. К., 1986.

**ГӘРӘЕВА** Салисә Гәрәй кызы (6.11.1938, Минзәлә р-ны Тулыбай а.), шагыйрә, ТРның атказ. мәдәният хезмәткәре (1993). Казан ун-тын тәмамлый (1968). 1963 елдан Чиләбе шәһәрендә яши. 1963-69 да китапханә бүлеге мөдире, 1969-85 тә өлкә радиотапшырулар комитетында, 1986-89 да «Сигнал» производство берләшмәсенең җирле радиотапшырулар редакциясендә мөхәррир булып эшли. 1989-91 дә «Дуслык», «Туган як» г-таларында җаваплы сәркәтип, бер үк вакытта өлкә телевидениесендә татарча «Чишмә» тапшыруларын алып бара. 1991дә Казанга кайта. «Татарстан хәбәрләре» г-тасы редакциясендә эшли, 1995 тән «Мәдәни җомга» г-тасында. «Уралым» (1979), «Тау сукмагы» (1988), «Офыклар-Прозрение» (Чиләбе, 1991), «Йолдыз яңгырлары» (2006) исемле шигъри җыентыклар авторы. Шигырьләрендә Урал табигатенең матурлыгын, аның олы җанлы кешеләрен мактап җырлый.

Әд.: Әхмәтҗанов М. Матурлык җырчысы // Килер бер көн. К., 1998.

**ГӘРӘЙ** (Гәрәев) Әюп Гәрәй улы (22.4.1910, Уфа губ., Минзәлә өязе Иске Дөреш а. - 1967, Пермь шәһәре), шагыйрь. Алабуга педагогия техникумын тәмамлагач, укытучылык итә. «Эшче» (Мәскәү) г-тасы белән хезмәттәшлек итә, Мәскәү чит телләр педагогия ин-тында укый. 1927 елда «Азат хатын» ж-лында «Буранлы таң» исемле беренче хикәясе дөнья күрә. Матбугатта шигырь, поэма, очерклары басыла. «Межасыз шигырьләр» (1932), «Яз шатлыгы» (1966) исемле шигырь китаплары авторы. Поэзиясенә эмоциональлек, нечкә лиризм хас.

**ГӘРӘЙ** Йосыф Ибраһим улы (20.3.1904, Уфа губ., Бәләбәй өязе Базгыя а. - 2.3.1988, Уфа ш.), язучы. Башкорт, татар, рус телләрендә иҗат итә. 1923 елдан Башкортстан АССРның Чакмагыш, Шаран, Бакалы һәм Бәләбәй р-ннарында укытучылык итә. 1929-30 елларда мәктәпләрдә һәм оешмаларда башкорт телен гамәлгә кертү буенча Бәләбәй кантон комиссиясенең җаваплы сәркәтибе. 1931-36 да Башкортстан АССР Мәгариф халык комиссариатында читтән торып укыту буенча инспектор, башкорт телен һәм әдәбиятын укыту буенча инспектор-методист. 1937-39 да Башкортстан АССР Язучылар берлеге идарәсе җаваплы сәркәтибе. 1940-58 дә Казакъстан һәм Таҗикстанда төзелешләрдә эшли. 1958 дән кабат Уфада. Шигырьләр, поэмалар, хикәяләр, повестьлар, әдәби-тәнкыйть мәкаләләре, башкорт теле һәм әдәбияты буенча урта мәктәпләр өчен дәреслекләр һәм методик кулланмалар авторы. Беренче китаплары татар телендә басыла («Истәлекләр», М., 1930; «Тимер», К.-М., 1932; «Пионерлар килде», 1932). Балаларга багышланган «Суртан әмере буйынса» (1937), «Өрөргә нисек өйрәнде көсөк» (1962), «Зирәк Куян» (1969) кебек җыентыклар, Социалистик Хезмәт Герое Батырова Банат турында язылган «Банат Батырова» (1966) документаль повесте авторы. Г. башкорт теленә А.С.Пушкин, Н.В.Гоголь, А.П.Чехов, С.Я.Маршак, Г.Тукай һ.б.ларның әсәрләрен тәрҗемә итә. 1940 елда нахакка гаепләнә; 1957 дә аклана.

Әсәр.: Шигырзар. Өфө, 1964; Якташтарга хат: Шигырзар, поэмалар, балладалар. Өфө, 1984.

Әд.: Сафуанов С. Шагир тураһында һүз // Агизел. 1974. N5; Әхмәзиев В. Тынгыһыз ижад // Агизел. 1979. N3.

**ГӘРӘЙ** (Гәрәев) Рәшит Гәрәй улы (15.4.1931, Минзәлә р-ны Малтабар а. - 23.6.1999, шунда ук), шагыйрь, ТАССРның атказ. мәдәният хезмәткәре (1981). Әдәбият ин-тын тәмамлый (Мәскәү, 1959). 1959-80 елларда «Казан утлары» ж-лында бүлек мөдире, соңрак Татарстан китап нәшриятында балалар-яшүсмерләр әдәбияты бүлегендә мөхәррир булып эшли. «Беренче хисләр» дип аталган тәүге шигырьләре һәм поэмалары тупланган җыентык 1952 дә басыла. Иҗатының баштагы чорында Г. нең шигырьләрендә яшьлек романтикасы, мәхәббәт, тугрылык, туган як табигате кебек мотивлар өстенлек итә. Соңрак үзәктә авыл кешеләре, аларның хезмәте, гадәт-йолалары; шагыйрь геройларының күңел дөньясын тирәнрәк сурәтләргә омтыла. «Һаваларда йолдыз» (1965), «Төнге учаклар» (1968), «Сиңа тартыла күңел» (1970), «Синдә калам» (1981), «Син бер генә» (1989), «Тургайлы тугайларым» (1991) җыентыклары авторы. Г. шигырьләре кыска һәм ачык, сәнгатьле яңгырыйлар.

Әд.: Рәшит Гәрәйгә 60 яшь // Казан утлары. 1991. N5.

Автор: Г.М.Габделхакова.

**ГӘРӘЙ** (Гәрәев) Шамил Мөхәммәтгали улы (31.12.1916, Казан -22.3.1946, Гливице ш., Польша), шагыйрь. Бөек Ватан

сугышында катнаша. «Сигналчы жыры» исемле беренче жыентыгы 1932 елда басыла. Ижатында төп мотивлар — мәхәббәт, табигать матурлыгы. «Звено жыры» (1934), «Тормыш иртәсе» (1937), «Тормыш чәчәкләре» (1941) шигъри жыентыклары авторы. Татар теленә М.Ю.Лермонтов, А.П. Чехов , А.Л.Барто әсәрләрен тәрҗемә итә.

**ГЕРКЕН** Евгений Юрьевич (Георгиевич) (17.10.1886, Казан - март 1962, Мәскәү), шагыйрь, драматург, тәрҗемәче. Е.А.Баратынскийның оныгының улы. Казан ун-тының юридик ф-тын тәмамлый (1910). Шигырьләрендә Г.нең төрле йогынтыларга тартылуы хас, бүтәннәрнең стилистик алымнарын кабатларга һәвәслеге сизелә. Казан шәһәр театрында барган «Бөек Калиостро» («Великий Калиостро», 1908), «Пыяла киртәләр» («Стеклянные перегородки», 1909), «Алар гашыйк иделәр» («Они любили», 1910), «Дәртле хатын» («Страстная женщина», 1912) пьесалары авторы. 1917 дән соң Петербургта яши, «Бөтендөнья әдәбияты» («Всемирная литература») нәшрияты өчен тәрҗемәләр башкара. 1932 дә нахакка репрессияләнә; 1954 тә аклана.

Әсәр.: Башня. Л., 1926; Лирические стихотворения. К., 1928.

**ГИНЗБУРГ** Евгения Соломоновна (7.10.1903, Мәскәү - 25.5.1977, шунда ук), язучы, тәрҗемәче. Язучы В.П.Аксёновның әнисе. Казанда 1909 елдан яши. Шәрекъ пед. ин-тын тәмамлый (1924), 1925-30 да шунда ук укыта. 1933 кә кадәр - М.Вахитов исем. Шәм-стеарин, сабын кайнату, гөлсирин житештерү химия з-ды каршындагы ВТУЗда, 1935 кә кадәр - Казан ун-тында (1934-35 елларда ленинизм тарихы каф. мөдире). 1934-35 тә «Красная Татария» г-тасында язышa. 1937 гә кадәр ТАССР Язучылар берлегенең рус бүлеген житәкли, актив рәвештә әдәбият тәнкыйтьчесе һәм тәрҗемәче буларак эшли. Рус теленә Г.Тукай, Галим Мөхәммәтшин, Ә.Ерикәй, М.Садри h.б. әсәрләрен тәрҗемә итә. 1937 дә репрессияләнә (контррев. троцкийчылар түгәрәгендә катнашуда гаепләнә), 18 ел Колыма лагерьларында һәм сөргендә уздыра. 1955 тә аклана. «Текә юллар» («Крутой маршрут»; 1 кис. 1967; СССРда 1988-90 елларда басыла) китабында золымга каршы тора алган кеше рухының көче чагыла.

Әд.: Аксёнов П.В. Последняя вера // Казань. 1993-95; Быков В. Предисловие // Гинзбург Е. Крутой маршрут. М., 1990.

**ГОБӘЙ** (Гобәйдуллин) Гариф Шакир улы (26.8.1907, Казан -27.4.1983, шунда ук), язучы. Казан педагогия ин-тын тәмамлый (1936). Студент елларында ук Татар радиокомитетында әдәби тапшырулар мөхәррире булып эшли. 1936-40 та Әдәбият һәм нәшрият эшләре буенча баш идарә (Главлит) вәкиле, 1940-46 да Татарстан радиокомитеты рәисе. 1950-53 тә ТАССР Язучылар берлеге идарәсе рәисе. «Көмеш канат» дигән беренче хикәясе 1934 тә басыла. Балалар өчен дистәләгән повесть һәм хикәяләр авторы. «Маякчы кызы» (1938; русчага тәржемәсе «Дочь бакенщика», 1951) повесте татар әдәбиятында Гражданнар сугышына багышланган әсәрләрнең иң яхшыларыннан берсе. Г.нең әсәрләрендә сурәтләнгән яшь геройлар һәрвакыт вакыйгалар үзәгендә биреләләр. Сугыш елларында тылда авыл балаларының катлаулы тормышын сурәтләгән «Замана балалары» (1945), Ленинград блокадасы вакытында балаларның хәле, совет кешеләренең намуслылыгы, фидакарьлекләре турында «Маратның язмышы» (1956; рус теленә тәрҗемәсе «Судьба Марата», 1963) повестьлары шундыйлардан. Сугыштан соңгы яшь буынның жилкәсенә төшкән авырлыкларны тасвирлаган «Ләйсән яңгыр» (1961) повесте дә Г. гә уңыш китерде. Революциягә кадәрге Бишбалта бистәсе тормышын чагылдырган «Без үскәндә» (1959; рус теленә тәрҗемәсе «Когда мы росли», М., 1964) повесте тарихи-революцион теманы үз эченә ала. Г. ның атеистик күзлектән чыгып язган «Коръән серләре» (1967; 3 басма 1977) исемле әдәби-публицистик повесте да билгеле. Г. — әдәби тәрҗемә өлкәсендә күп эшләгән язучы. Ул татар теленә «Тысяча и одна ночь» («Мең дә бер кич», 1940) жыентыгын, А.Первенцевның «Честь смолоду» («Намуслы яшьлек», 1950) повестен, А.Толстойның «Пётр Первый» («Пётр патша», 1966) романын h.б.ларны тәрҗемә итә. Октябрь Революциясе, ике тапкыр Хезмәт Кызыл Байрагы һәм «Почёт Билгесе» орденнары б-н бүләкләнә.

Әсәр.: Сайланма әсәрләр: 3 томда. К., 1968-69.

Әд.: Советские детские писатели: Биобиблиогр. словарь. М., 1961; Тәрҗеманов Ж. Балалар дөньясы аксакалы // Ялкын. 1977. N9; Рахмани Р. Тормыш чынлыгын эзләп // Казан утлары. 1997. N8.

*Дәвамы киләсе саннарда*

К. Әдһәмов

# ТЕЛЕҢНЕ КҮРСӘТ...

МОНОЛОГ

Докладымны йомгаклап шуны әйтергә телим: татар теле һәм милләте турында сөйләрлек вакытым калмады... Сайлаулар турында күбрәк сөйләп аттык.

Пнимаете, мине бер сорау борчый, ни өчен безнең татар ике телле? Аның әле берсен дә тыяр хәл юк! Урысның пичәтендә ике башлы бөркет була торып та теле бер генә! Ә безнең канатлы барс бер башы белән ике телдә сөйләшә, ике гражданство иметь итә. Безгә нимидленно Рәсәй белән пичәтләрне алмашырга кирәк! Татарга ике башлы бөркет таман булачак! Аның бер башы татарча вәгазь сөйләп торыр, ә икенче башы урысчалатып гел «каравыл!» кычкырыр. Пчему? Птамушты бер Казанга ике бөркет башы сыя.

Пнимаете, ике тел берьюлы сөйли алмый. Берең сөйләгәндә, икенчең юл куярга тиеш. Ягъни мәсәлән, Фәүзия Бәйрәмова булган җирдә Владимир Жириновский ... кысып кына йөрергә тиеш. Бөтен вопрос та шунда, урыс сөйләгәндә татар дәшми түзәрме? Юк, кәнишне! Ну элек булса кирегә сукаламыйча тыелып калыр идек. Ә хәзер—юк! Телебез озынайды соңгы елларда. Кабатлап әйтәм, телебез үсмәде, ә озынайды! Йә, апаем, теленне күрсәтеп кара әле!.. Тәк, тәк, оялып торма, чыгарып күрсәт! Әнә, күрдегезме! Разве мондый телне тыеп була?! Бик әйбәт. Телнең хәзер бик кирәк чагы. Хәзер Рәсәйдә бөтен нәрсә тел белән генә эшләнә! Кем сөйли—шул ашый! Кем тыңлый—шул эшли! Татарга да тел бик кирәк! Пчему? Птамушты телең булмаса, ике башлы бөркет күтәрә дә китә!

Пнимаете, ике телдә берьюлы сөйләп булмагач бер генә телдә сөйләшәсе кала. Гел татарчага гына күчсәк—безне урыс дәдәң анламас инде, ник дисәң, безнең өйдә җитмеш ел яшәп ул татарча җиде сүз дә өйрәнә алмады. Гел урысча сөйләшүне генә калдырсак—татарларга тагын сүгенергә туры килә, чөнки урысча сүгенүе рәхәтрәк.

А все же выход бар, иптәшләр! Безгә шундый җайлы телдә сөйләшергә кирәк—урыс та, татар да шундук анлап алсын. Ике телне бергә кушып сөйләшик. Татар сүзлегеннән утыз мең сүз, урыстан йөз мең сүз алабыз да шуларны бер казанга салып болгатабыз. Һәр икенә дә анлаешлы тел килеп чыга. Без инде күптәннән бирле: пнимаете, кәнишне, гупчым, значит, мужыт, зәмичәтелни, әбизәтелни, как раз кебек алты-җиде һәм тагын өч хәрефле сүзләрне бик удачны кулланып сөйлибез. Урыска да бераз татар телен өйрәнергә туры килер. Пчему? Птамушты сүз сыер теле турында бармый!

Национальный вопроска килеп терәлгәч кенә телсез калды димәгез, сөйлим әле...

Кем белә, бүген урысларда күпме татар бар? Җиде миллионмы? Уникеме, бәлки егерме биштер, ә? Мин дә белмим. Перепись үткәрергә вакыт юк—референдумнар күбәйде. Ну шунысын яхшы беләм—халык саны кими, иптәшләр... Кавышучылар көннән-көн арта, гүләйт итүчеләр дә җитәрлек, ә халык үрчеми. Пчему? Птамушты көн саен бала ясап була, ә көн саен бала

табып булмый. Бала үстереп баракларда-общежитиеләрдә чиләнеп ятканчы дүрт ваучерлы хатынга йортка керүен жайлырак.

Пока халык санын качаклар хисабына арттырабыз. Правды, кемнен кайсы милләттән икәнен ачыклавы көннән-көн кыенлаша. Тышкы кыяфәтенә карап кына кешене танып булмый хәзер. Элек кемнен кем икәнен психбольницаларда барыбер ачыклый торган идек. Бүген исә кешенен милләтен ухо-горло-нос врачы да ачыклый алмас. Чөнки бездә хәзер кечкенә борынлы яһүдләр, зәнгәр чәчле татарлар, кысык күзле урыслар һәм сап-сары башлы негрлар күбәйде. Нотык сөйли-сөйли тел очына төер чыкса кемгә төкерергә белмәссен!

Кешенен милләте ни өчен кирәк, диярсез инде сез. Кирәк! Бөтен халык бер тишеккә тулмасын өчен кирәк ул. Буталмасын дөнья! Юкса, айга карап чукынырга ярамаган кебек, дунгыз итеннән бәлеш пешерергә ярамый! Чалманы муенга шарф итеп урарга ярамаган кебек, чапанны мини-юбка итәргә ярамый! Урысны сөннәткә утыртырга ярамаган кебек, комганнан чәй эчәргә ярамый!

Күзгә күренеп үзгәрәбез...

Кешечә булсын, дип, без дә буй-буй байрак астына тезелдек. Тарихта беренче тапкыр үзебезнен гимнны яздык. Правды, халыктан күптөрле тәкъдимнәр килде, ник ул депутатлар «Их сез, матур кызлар!» дигән жырны гына гимн итеп алмадылар, дип жанга тиделәр. Во-первых, иптәшләр, яңа жыр чыккан саен гимн алыштырып булмый, икенчедән—Асаф Вәлиев жырлап йөри торган ул жыр удмуртларнын күптән списать ителгән жыры!

Таким образым, телебез бар, милләтебез яши, гимныбыз янгырый, байрагыбыз жилферди! Калганы—базарда!

Пнимаете, милли мәсьәлә буенча артык теленә салынырга ярамый, күп сөйләсәң—теленне кыскартырлар. Пчему? Птамушты!..

---

# Маннур Саттаров

## ЯШЕНЛЕ ЕЛЛАРЫМ...

**Биек тауның башларында**
**Жил әйләндерә ташны.**
**Кыйбласы кайда Рәсәйнең?—**
**Шул әйләндерә башны.**

**Дәүләт салган йортым бар,**
**Эшләп тапкан милкем бар.**
**Төп Законның маддәсендә**
**Сүз әйтергә иркем бар.**

**Нәшер өчен җаваплылар**
**Мөхәррир дип йөртелә.**
**Шигырь язсам, алар хуҗа**
**Закон биргән иркемә.**

**Иртә торып тышка чыксам,**
**Җил каерган түбәне.**
**Җилгә-яңгырга тидерми,**
**Саклый түрә түрәне.**

**Безнең илләр сахра җирләр,**
**Сахрада үсә гөлләр.**
**Үз күләгәсеннән курка**
**Үтә сак мөхәррирләр.**

**Яшенле яшьлек елларым**
**Исемә төшә таңда.**
**Шушындый «ирек» өчен, дим,**
**Каным түктемме юуда?**

## Гыймран Сафин



Сафин Гыймран Вәлиәхмәт улы 1943 елда Чаллы (хәзерге Тукай) районы Мус-Завод авылында туа. Үз авылларындагы җидееллыкны тәмамлаганнан соң, шул районның Борды һәм Теләнче Тамак урта мәктәпләрендә укый, мәктәпне «Көмеш медаль»гә тәмамлый. Бер ел туган авылында авыл хуҗалыгы техникасын ремонтлаучы слесарь булып эшли. 1963 елда Казан авиация институтына укырга керә. Аны тәмамлаганнан соң Г. Сафин Ижау радиозаводына эшкә җибәрелә. Утыз елдан артык эшләү дәверендә төрле вазифалар башкара: инженер-конструктор, конструкторлык бюросы җитәкчесе, бүлек җитәкчесе. Хәзер дә шул ук заводта эшли. Фидакарь хезмәте өчен Дәүләт бүләкләренә лаек була.

Әдәби иҗат белән туган авылы мәктәбендә укыганда ук шөгыльләнә башлый: Чаллы район газетасында беренче шигырьләре басыла. Мәктәп елларында Чаллы һәм Сарман районнары газеталарында шактый шигырьләре дөнья күрә...

Үзгәртеп кору чорында милли хәрәкәт җанланып, Ижау шәһәрендә дә татар телендә «Яңарыш» газетасы чыга башлагач, Гыймран Сафин зур активлык белән иҗат итә башлый. «Яңарыш» газетасы битләрендә шигырьләре, публицистик мәкаләләре еш урын ала Шулай ук, Г. Сафинның шигырьләре Татарстан матбугатында да басыла башлый. 2003 елда «Язлар көтә күнел» һәм 2005 елда «Гомер бер генә» дип исемләнгән китаплары басылып чыга. Соңгы вакытта Г. Сафин яңа шигырьләр китабын әзерләде һәм ул тиздән басылып чыгачак.

2007 елның мартында Кабул итү коллегиясе карары нигезендә (тәкъдимнамә бирүчеләр: Шәһинур Мостафин, Габдулла Галиев, Ринат Батталов, Ибраһим Биектаулы) язучылар берлеге идарәсе Сафин Гыймран Вәлиәхмәт улын Татарстан Язучылар берлегенә әгъза итеп алды.

---

*Алхәбәр. «Казан утлары»—2008*

Марат Әмирхан

# ҮРБӘТ ХАНӘКӘ ГЫЙШКЫ

ТАРИХИ РОМАН

Рәсәйдә Иван—III идарә иткән чорлар.

Казан ханы Мөхәммәдәмин, йола кушканча, агасы Илһамнан яшьләй тол калган Үрбәтне өченче хатынлыкка ала.

Үзенең тугрылыгы, чибәрлеге һәм зиһенлелеге белән Үрбәт ханәкә Казан ханлыгының үсешенә шактый зур йогынты ясый.

...Алыптай мәһабәт баһадир гәүдәле Мөхәммәдәмин янында Үрбәт зифа камышны хәтерләтә. Алар бер-берсенә шулай туры киләләр ки, әйтерсең лә, Йосыф белән Зөләйха. Мөхәммәдәмин—каһарман, Үрбәт—алиһә. Икесе—бербөтен.

—Мин сине күреп тә, сөеп тә туймадым, Үрбәт бикә, иншаллаһ, Ходай ахирәттә дә беребезне беребездән аермас,—диде Мөхәммәдәмин хатынының йомшак кулларыннан сыйпаштыра-сыйпаштыра.

* * *

Исәнмесез, хөрмәтле редакция!

Журналның яңа, сигезенче саны белән китапханәдә укып танышкач, сезгә үз фикерләребезне язып җибәрергә булдык.

Иң элек якташыбыз Рөстәм Зәкуанов өчен сөенечебезне белдерәбез, Язучылар берлегенә әгъза итеп кабул ителгән икән. Шигырьләре дә басылмавы гына кызганыч. Мәдинә апа Маликованың «Тылсым» романын кызыксынып укыдык. Тормышчан, мавыктыргыч әсәрнең дәвамын көтеп калабыз.

Луиза Янсуар шигырьләрен һәрвакыт яратып укыйбыз. Безнең өчен сабый гына, ә хисләр дөньясы ничек ургый!

Инде сүзебез Р. Мингалим һәм Ә. Яһүдиннең «Өч балдызга бер ялгыз» пьесасы турында. Дөресен генә әйткәндә, пьесаның исеменә, мәртәбәле журналда басылуына карап зур өметләр баглаган идек. Күңелдән генә рольләрне бүлгәләп, үзешчән драма коллективы әгъзалары белән сәхнәләштерергә дә ниятебез бар иде. Әмма, әсәрне укып чыккач, әйтер сүз таба алмадык. Иң элек исеме турында. Имам бит ялгыз түгел! Аның үзе белән гомер буе тормыш иткән Мәрьямгә тагын өч (!!!) көндәш өстәлүгә каршылыксыз риза булуы бер дә ышандырмый.

Сүз дә юк, авыл тормышы авыр һәм катлаулы. Ирсез яшәү дә күңелле өстәми. Әмма, гафу итегез, беренче күргән иргә өч хатын-кызның мөкиббән китүе гайре табигый хәл. Бу мәхлук җаннар гашыйк булып кына калмый, шушы ир кисәге белән чиратлап яшәргә дә риза була! Сезнең, җан кисәкләрем, авылга кайтып хәзерге авыл хатыннарын күргәнегез бармы? Бер генә хатын да, гәрчә ул ялгыз, ярдәмчесез булса да, шушы түбәнлеккә бармаячак. Авыл хатынын мескен дип кабул итсәгез дә, аның да горурлыгы бар бит. Бигрәк тә татар авылында яшәүче мөселман хатын-кызының!

Хәзерге заманда хатын-кызның күбесе тормыш дилбегәсен үзе тарта, балаларын үзе үстерә, әдәби әсәрләр укырга да җитешә.

Яратып укый торган журналыбызда хатын-кызны кимсетә торган түгел, ә аның горурлыгын, сабырлыгын, тапкырлыгын күрсәтә торган әсәрләр көтәбез бит без.

Сезгә иҗади уңышлар теләп, журналны яратып укучы хатын-кызлар.

**Азнакай районы,**<br>**Әлкәй авылы.**

---

*Алхәбәр.*<br>*«Казан утлары»—2008*

«Ул—туган туганның хәлен дә белешми торган битараф заман корбаны. Аның күңел халәте беркемне дә кызыксындырмый. Әмма аның бәхетле булырга хакы бар. Гөлкәйнең күңеленә кем тынычлык алып килер, өшегән йөрәген кем җылытыр»—**Рәмзия Габделхакованың «Нишләттегез Гөлкәйне?»** повесте әнә шул хакта.



*Казан—Уфа юлларында эзләр суынмый иде! Сулдан уңга—Сәгыйт Агиш, Зәки Нури, Гариф Гомәр, Габдрахман Әпсәләмов. 1958 ел.*



*Шагыйрь Мәхмүт Хөсәен. 80нче еллар.*



*Котлашулар. Сулдан уңга: Хәлим Җәләлев, Айдар Хәлим, Шәүкәт Биктимеров. 1992 ел.*



*Җырчы Вафирә Гыйззәтуллина. 1975 ел.*



*Шагыйрь Камил Мостафин. 1981 ел.*



*Бер төркем язучылар Норлат районы хакимияте бинасында. Сулдан уңга—Марсель Галиев, Резеда Вәлиева, Фатыйх Сибагатуллин (хакимият башлыгы), Бикә Рәхимова, Флера Тарханова. 2002 ел.*

### «АЛТЫН МӨНБӘР» БИЕКЛЕК ЯУЛЫЙ

«Пирамида» мәдәни-күңел ачу комплексында III Халыкара «Алтын мөнбәр» мөселман киносы фестивален ябу тантанасы үткәрелде. Фестивальне оештыручыларның уртак фикеренчә, кино бәйрәме уңышлы үтте. Татарстан башкаласында 30 илдән 49 конкурс фильмы күрсәтелде. Фестиваль эшендә дөньякүләм мәшһүр артистлар катнашты—Катрин Денев, Сафия әл-Әмри... Атаклы режиссерлар—Сергей Говорухин, Вадим Әбдрәшитов...

Бүләкләүләр махсус призлар тапшырудан башланды. Казан шәһәре мэры Илсур Метшин беренче призны фестивальнең почетлы кунагы, Россиянең халык артисты Евгений Мироновка «Мөселман» фильмында баш рольне башкаруы өчен тапшырды.

«Ислам дөньясы» телевизион компаниясенең махсус призын «Бог Ибрахима» фильмы режиссеры Захир Әхмәдкә фестивальнең генераль директоры Зауди Мамиргов тапшырды. Захир Әхмәд бик җылы каршылаулары өчен кино бәйрәмен оештыручыларга рәхмәт белдерде.

Төрек дөньясы халыкларының мәдәниятләрен һәм традицияләрен чагылдырулары өчен «Бабай» фильмы режиссеры Альберт Шакиров «ТЮРКСОЙ» халыкара оешмасының махсус призына лаек булды.

Режиссер сәхнәгә сценарий авторы Мансур Гыйләҗев белән бергә чыкты. Аларга призны төрек кино актрисасы, «Королек птица певчая» популяр сериалының баш героинясы Айдан Шенер һәм «ТЮРКСОЙ» вәкиле Мостафа Балчик тапшырды.

Россия кино белгечләре һәм кино тәнкыйтьчеләре гильдиясе президенты Виктор Матизен призларны режиссер Николь Балливьянның «Поездка в Зигзигленд» һәм Мөхәммәд әль-Дараджиның «Ахлям» («Бәхет») фильмнарына тапшырды.

Тамашачы симпатиясе призы «Дилемма» фильмы өчен режиссер Рамил Төхвәтуллинга тапшырылды. Рамилне Татарстан мөфтие Госман хәзрәт Исхакый тәбрикләде.

Кино сәнгатенә зур өлеш кертүе өчен үлгәннән соң режиссер Мостафа әль-Аккаду бүләкләнде. Әлеге призны фестиваль спонсорларының берсе, Төмән өлкәсе татарлары конгрессы президенты Нурулла Саттаров кулыннан алдылар. «Иң яхшы телевизион фильм» номинациясендә «Полигон» фильмы режиссеры Асад Таха җиңүче дип табылды. Россиянең халык артисткасы Наталья Бондарчук «Цвет маслин» фильмы режиссеры Каролина Ривасны «Иң яхшы режиссерлык эше» номинациясендә җиңүче дип игълан итте.

Шагыйрь Олжас Сөләйманов «Иң яхшы фильм» номинациясендә җиңүче дип Кувейт режиссеры Абуллах Бушахриның «Теряя Ахмада» фильмын атады. Жюри әгъзасы актриса Сафия әль-Әмри «Иң яхшы кыска метражлы уенлы фильм» номинациясендә җиңеп чыгуы өчен «Ике хатын» (Башкортстан) фильмы авторларына приз тапшырды. Г. Тукай иҗаты темасын яхшы ачулары өчен Бөтендөнья татар конгрессы вәкилләре «121» фильмы режиссеры Салават Юзеевка приз тапшырдылар.

«Иң яхшы оператор эше өчен» «Баба Азиз» фильмы операторы Махмуд Калари, «Иң яхшы ирләр роле өчен» Джеффа Ренфроның (АКШ) «Гражданлык бурычы» фильмында Терри Алена ролен башкаручы Питер Краузе, «Иң яхшы хатын-кызлар роле өчен» режиссер Ясмила Жбаничның «Грбавица» фильмында Әсма ролен башкаручы Мирана Каранович ия булды.

Нагеш Кукунурның (Һиндстан) «Нить» фильмы сценарие «Иң яхшы уенлы кино сценарие», «Грбавица» фильмы режиссеры Ясмила Жбанич «Иң яхшы уенлы кино режиссеры» дип табылды, һәм, ниһаять, «Алтын мөнбәр» фестиваленең «Иң яхшы уенлы фильм» номинациясендә абсолют җиңүчесе итеп режиссер Насер Хемирның «Баба Азиз» фильмы табылды. Бу картинаны иҗат итүдә 7 ил вәкилләре—Швейцария, Германия, Тунис, Франция, Венгрия, Иран, Бөекбритания катнашкан.

Татарстан Президентының «Кино сәнгатендә гуманизм өчен» махсус призын «Древо мира» фильмы өчен профессор Кристина Вагнерга Татарстан Премьер-министры урынбасары—мәдәният министры Зилә Вәлиева тапшырды.

Ул, шулай ук, «Алтын мөнбәр» мөселман кинофестиваленең Казанда өченче мәртәбә уңышлы узуында Татарстан Президенты Минтимер Шәймиевнең хәлиткеч роль уйнаганын билгеләп үтте.

### БӨТЕНДӨНЬЯ ТАТАР ГАЛИМНӘРЕ ҖЫЕНЫ

19-22 сентябрьдә Казанда татар галимнәренең Бөтендөнья форумы булып узды. Әлеге эшлекле очрашуда дөньяның төрле

почмакларыннан һәм Россиядән 500дән артык галим катнашты. Форумны Татарстан Фәннәр академиясе һәм Бөтендөнья татар конгрессы оештырды.

Татар галимнәре форумын Татарстан Фәннәр академиясе президенты Ә. Мазһаров ачты. Шуннан соң тәбрикләү өчен сүз Дәүләт Советы Рәисе Ф. Мөхәммәтшинга бирелде. Дәүләт Советы Рәисе, иң элек, татар галимнәренә Президент М. Шәймиевнең котлау сүзләрен ирештерде. Ул, әлеге эшлеклe очрашуга зур бәя биреп, аның Татарстан тарихындагы бик истәлекле вакыйга булуын искәртеп үтте.

Форумны ачканда тәбрикләү сүзе белән Премьер-министрның беренче урынбасары Р. Моратов, Россия һәм Татарстан Фәннәр академиясе академигы К. Вәлиев, Казакъстан Милли Фәннәр академиясе президенты М. Журинов, Румыниянең Төркмәнстандагы илчесе, академик Т. Җәмил, Бөтендөнья татар конгрессы башкарма комитеты рәисе Р. Закиров чыкты.

Аннары форумның пленар утырышы башланып китте. Анда Татарстан Фәннәр академиясе президенты Ә. Мазһаров, ТР Президентының сәяси мәсьәләләр буенча Дәүләт киңәшчесе, Ш. Мәрҗани исемендәге Тарих институты директоры Р. Хәкимов, Татарстанның икътисад министры М. Сафиуллин, М. Планк исемендәге җәмгыятьнең Астрофизика институты (Германия) директоры Р. Сүнәев, Россия Фәннәр академиясенең Океанология фәнни-тикшеренү институты директоры Р. Нигъмәтуллин, РФ Тышкы эшләр министрлыгының Мәскәү дәүләт халыкара мөнәсәбәтләр институты профессоры А. Әхтәмҗан, Казан дәүләт университетының татар әдәбияты кафедрасы мөдире, профессор Х. Миңнегулов, Россия Хәрби Фәннәр академиясе президенты, армия генералы М. Гәрәев докладлар белән чыгыш ясадылар.

Җомга көнне форум ике секциягә бүленеп эшләде. Гуманитар фәннәр, табигать һәм техник фәннәр секцияләрендә иртәдән кичкә кадәр бик күп докладлар тыңланды. Соңыннан форум махсус резолюция кабул итте. Анда Татарстан Фәннәр академиясе каршында бөтендөнья татар галимнәрен берләштерүне максат иткән координация советы төзү, аларның инновацион идеяләре банкын булдыру һәм моны Татарстан җирендә тормышка ашыру, читтә яшәүче милләттәш галимнәребез арасында фәнни элемтәләрне ныгыту, татар галимнәренең мондый эшлекле форумнарын өч елга бер тапкыр даими уздыру кирәклеге турында әйтелә.

## СЕБЕРДӘ ҖӘЛИЛ ҺӘЙКӘЛЕ

25 сентябрьдә Төмән өлкәсе Ханты-Манси автономияле округының Түбән Варта шәһәрендә тарихи вакыйга булды—бирелдә халкыбызның каһарман улы Муса Җәлилгә һәйкәл ачылды. Ул каланың гаҗәеп матур урынында—Обь елгасы ярында, шагыйрьнең үз исемен йөрткән урамда урнашкан. Шәһәрдә иң беренче булып барлыкка килгән әлеге урамда бүген шулай ук 800 урынлы Җәмигъ мәчете һәм 50 шәкерткә исәпләнгән мәдрәсә дә төзелеп килә.

Һәйкәлне ачу тантанасында Дәүләт Советы Рәисе урынбасары Римма Ратникова җитәкчелегендәге Татарстан делегациясе дә катнашты. Делегация составында Татарстанның Дәүләт Советының мәдәният, фән, мәгариф һәм милли мәсьәләләр комитеты рәисе Разил Вәлиев, Язучылар берлеге рәисе Илфак Ибраһимов, Рәссамнәр берлеге рәисе Абрек Абзгильдин, Татарстанның халык шагыйре Роберт Миңнуллин, «Мәдәни җомга» газетасының баш мөхәррир урынбасары Газинур Моратов, һәйкәлнең авторы, сынчы Мәхмүт Гасыймов бар иде. Тантанада Ханты-Манси автономияле округы—Югра губернаторы Александр Филиппенко, Югра Думасы Рәисе Василий Сондыков, шәһәр мэры Борис Хохряков катнашты һәм чыгыш ясады. Алар Себердәге нефть һәм газ ятмаларын үзләштерүдә зур көч куеп эшләүче милләттәшләребезнең хезмәтенә югары бәя бирде, Җәлил һәм аның тиңдәшсез иҗаты барлык халыкларның уртак байлыгы булуын әйтте.

Татарстан Дәүләт Советы Рәисе урынбасары Римма Ратникова үз чыгышында Җәлил һәйкәлен торгызуда зур тырышлык куйганнары өчен Югра җитәкчелегенә, финанс ярдәме күрсәткән күпсанлы милләттәш эшмәкәрләребезгә Президент Минтимер Шәймиев, Дәүләт Советы һәм Хөкүмәтебез исеменнән зур рәхмәт белдерде.

Соңыннан Түбән Вартаның Сәнгать сараенда зур концерт булды. Анда Татарстанның халык артистлары Салават Фәтхетдинов, Фердинанд Сәлахов һәм шәһәрнең үзешчән сәнгать коллективлары чыгыш ясады.

## ЗУР ӘДИПЛӘР КИЧӘСЕ

2-3 октябрьдә Казанда башкала мэры инициативасы белән «Аксенов-фест-2007» дип исемләнгән I халыкара әдәби-музыкаль фестиваль үткәрелде. Әлеге чара якташыбыз, дөньякүләм танылган язучы Василий Аксеновның 75 яшьлек юбилее уңаеннан оештырылды.

Фестивальнең беренче көнендә башкалабызның Үзәк китап кибетендә әдәбият сөючеләр белән очрашу булды. Кичен М. Җәлил исемендәге Татар дәүләт опера һәм балет академия театрында В. Аксеновның иҗат кичәсе үтте. Кичәдә Россиянең күренекле әдәбият-сәнгать әһелләре Анатолий Гладилин, Евгений Попов, Белла Әхмәдуллина, Светлана Васильева, Михаил Веллер, Борис Мессерер, Андрей Макаревич, Алексей Козлов катнашты. Кичәне

Татарстанның беренче вице-премьеры Равил Моратов тамаша кылды.

Икенче көнне В. Аксеновны һәм анын дусларын Татарстан Президенты Минтимер Шәймиев кабул итте. Кабул итүдә Премьер-министр урынбасары—мәдәният министры З. Вәлиева, Казан мэры И. Метшин, Язучылар берлеге рәисе И. Ибраһимов катнашты.

Аннары кунаклар КДУ студентлары белән очрашты. Ә кичен М. Җәлил исемендәге Татар дәүләт опера һәм балет академия театрында Белла Әхмәдуллинаның 70 яшьлек юбилеена багышланган иҗат кичәсе булды. Кичәдә Татарстан Премьер-министры урынбасары—мәдәният министры Зилә Вәлиева катнашты.

### МИЛЛИ МӘГАРИФКӘ ХӘВЕФ ЯНЫЙ

РФ Дәүләт Думасы «Россия Федерациясенең кайбер закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» федераль закон проектын кабул итте. Ул РФ Хөкүмәте тарафыннан кертелгән иде. Әлеге закон проекты дәүләт мәгариф стандарты структурасына һәм анын төшенчәсенә үзгәрешләр кертүне күздә тота, һәм нәтиҗәдә ул РФ халыкларының милли-мәдәни үсешкә хокукларын чикләүгә китерәчәк. Татарстан Дәүләт Советының 28 сентябрьдә узган сессиясендә әлеге закон проектына тискәре бәя бирелде һәм РФ житәкчелегенә түбәндәге мөрәҗәгать юлланды.

*Россия Федерациясе Президенты В. Путинга, Россия Федерациясе Хөкүмәте Рәисе В. Зубковка, Россия Федерациясе Федераль Жыены Федерация Советы Рәисе С. Мироновка, Россия Федерациясе Федераль Жыены Дәүләт Думасы Рәисе Б. Грызловка Татарстан Республикасы Дәүләт Советы*

МӨРӘҖӘГАТЕ

Россия Федерациясе Дәүләт Думасы «Россия Федерациясенең кайбер закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан кертелгән 448303-4 санлы федераль закон проектын (дәүләт мәгариф стандарты төшенчәсен һәм структурасын үзгәртү өлешендә) беренче укылышта кабул итте.

Тәкъдим ителгән закон проекты концепциясе дәүләт мәгариф стандартының өч компонентлы структурасыннан бер компонентлыга күчүне күз алдында тота, региональ (милли-региональ) компонентны һәм мәгариф учреждениесе компонентын юкка чыгара.

Дәүләт мәгариф стандарты төшенчәсен һәм структурасын закон проектында тәкъдим ителгәнчә үзгәртеп коруларны гамәлгә ашыру Россия Федерациясе халыкларының милли-мәдәни үсешенә хокукларын чикләүгә, туган тел һәм әдәбият укытуны, милли мәдәниятне һәм үз халкы тарихын милли мәктәпләрдә һәм милли-мәдәни компоненты булган мәктәпләрдә өйрәтүне юкка чыгаруга китерәчәк. Әлеге закон проекты кабул ителгән очракта, кайбер регионнарда эшләп килүче милли мәктәпләрне һәм милли-мәдәни компоненты булган мәктәпләрне ябунын әле генә башланып килгән тискәре процессы чынлыкта дәүләт хуплавына ирешәчәк һәм ахыр чиктә Россия милли мәгарифен бетерүгә китерәчәк. Нәтиҗәдә, милли телләрне һәм мәдәниятләрне саклап калу һәм үстерү мәсьәләләрендә житди проблемалар тудырачак.

Моннан тыш, закон проекты концепциясе Россия Федерациясе Конституциясенә турыдан-туры каршы килә, анын нигезендә «Россия Федерациясе үзенен барлык халыкларына туган телләрен саклау, аны өйрәнү һәм үстерү өчен шартлар тудыру хокукын гарантияли» (68 нче маддә, 3 нче пункт), мәгариф өлкәсендә федерализм принцибын кире кага.

Закон проектында анда күрсәтелгән төп мәгариф программаларынын федераль дәүләт мәгариф стандартын, «региональ (милли) үзенчәлекләрне исәпкә алып», гамәлгә ашыруны тәэмин итүе алдан әйтелә. Әмма закон проекты концепциясе нигезендә моны гамәлгә ашыру мөмкин түгел, чөнки дәүләт мәгариф стандарты составында региональ (милли-региональ) компонент булмаячак.

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы, дәүләт мәгариф стандартының гамәлдәге милли-региональ компонентын һәм мәгариф учреждениесе компонентын бетерүне күз алдында тота торган закон проектын кабул итүгә карата борчылу белдереп, әлеге федераль закон проектын алга таба караудан төшереп калдыруны һәм дәүләт мәгариф стандартынын гамәлдәге өч компонентлы структурасын саклап калуны тәкъдим итә.

### ТАТАРЛАР КИЛЕШЕП БЕРЛӘШӘ

Татарга бары татар гына ярдәм итә ала. Россиянен милләттәшләребез күпләп яши торган төбәкләрендә татар телен, мәдәниятен саклау һәм үстерү буенча хезмәттәшлекне камилләштерү максатыннан, Татарстан Министрлар Кабинеты һем Россия татарларынын федераль милли-мәдәни автономиясе советы арасында килешү төзелде. Ул төбәкләрдә дини һәм халык традицияләрен яңартуга, татар телен, халык сәнгатен һәм кәсепләрен өйрәнүгә бер этәргеч булыр дип көтелә. Килешү төрле тарафларга сибелгән татар халкынын фәнни һәм эшлекле даирәләрен дә якынайтыр, дигән ният белән төзелде. Бу килешү төбәкләрдәге татар иҗтимагый берләшмәләренен уртак фәнни, мәдәни, социаль һәм икътисадый программаларда катнашуына да ярдәм итәчәк дип уйланыла.

### БҮЛӘКЛӘҮЛӘР

Халыкара Иҗтимагый фәннәр академиясе, «Шәфкатьлелек дөньясы» дип аталган

халыкара хәйрия оешмалары берлеге тарафыннан оештырылган конкурсның төбәкара этабында Татарстан Язучылар берлеге җиңеп, изге ниятләр һәм гамәлләр өчен «Милли казаныш» алтын медале белән бүләкләнде. Берлек рәисе Илфак Ибраһимовка «Намус һәм игелек» ордены тапшырылды. Туфан Миңнуллин, Равил Фәйзуллин, Зиннур Мансуров хәйрия өлкәсендә «Фидакарь хезмәт өчен» медальләре белән бүләкләнде. Разил Вәлиев Халыкара Иҗтимагый фәннәр академиясенең мөхбир-әгъзасы итеп сайланды.

### КАМАЛ ТЕАТРЫ ГАСТРОЛЬЛӘРДӘ

Көз айларында Камал театры артистлары Россиянең һәм БДБ илләренең төрле төбәкләрендә гастрольдә булдылар. Башта алар ун көн дәвамында Уфада спектакльләр күрсәттеләр, аннан соң Кырымга барып, Симферопольдә (Ак мәчет) халыкара театры фестивалендә катнаштылар. Октябрь башында театр труппасы Казакъстанга юл тотты. Алма-Атада Т. Миңнуллинның «Гөргөри кияүләре», З. Хәкимнең «Телсез күке» спектакльләре куелды. Алма-Атада дүрт кич чыгыш ясагач, бишенче көнен театр Кыргызстанга барып, Бишкәк каласы тамашачысына багышлады. Камал театры совет чорында бу якларда бик еш гастрольдә булса, бу соңгы егерме елда беренче барулары икән.

### СЕЗОН АЧЫЛУ

Салих Сәйдәшев исемендәге Дәүләт Зур концерт залы яңа иҗат сезонын ачып җибәрде. Ул танылган композитор Шамил Тимербулатовның «Ышаныч» исемле симфония-оратория белән башланып китте. Габдулла Тукай һәм Равил Фәйзуллин сүзләрен файдаланып язылган күләмле бу әсәрне сәхнәгә чыгаруда Фуат Мансуров (дирижер), Нурия Җураева (хормейстер) зур көч куйганнар. Икенче бүлектә Россия һәм Украинаның мәшһүр тенорлары—Михаил Векуа, Александр Гурец һәм Руслан Кадыйров чыгыш ясады.

### «ӘКИЯТ»ТӘГЕ ӘКИЯТЛӘР

25 октябрьдә «Әкият» Татар дәүләт курчак театры Р. Харис әсәре буенча куелган «Кәкрүшкә» спектакле белән 74 нче иҗат сезонын ачып җибәрде. Быелгы сезонда шулай ук Р. Бохараевның «Водяной конь», Р. Давыдовның «Репка», А. Хәировның «Три дочери», А. Алишның «Сертотмас үрдәк», Г. Тукай әсәренә нигезләнеп, З. Хөснияр эшләгән инсценировка буенча «Су анасы», Р. Батулланың «Тылсымлы курай» әсәрләрен сәхнәләштерү каралган.

Премьер-министр урынбасары—мәдәният министры З. Вәлиеваның әйтүенә караганда, «Әкият» театрына яңа бина төзү өчен каралган 800 миллион сум акчаның 200 миллионы киләсе ел бюджетына кертелгән. Киләсе елдан Офицерлар йорты янында, «Туган авылым» комплексы каршында әкияти кыяфәттә уйланылган яңа бинаны төзи башлау да ниятләнелә икән. Ә ноябрь ахырында «Әкият» театры Төркиянең Бурса шәһәрендә курчаклар һәм шәүләләр театрларының XII фестивалендә катнашачак.

### МӨСЛИМӘЛӘР ҖЫЕНЫ

Сентябрь аенда «Казан» милли мәдәният үзәгендә Россия мөслимәләре I корылтаеның 90 еллыгына багышлап «XXI гасыр хатын-кызы: гаилә һәм җәмгыять» дигән форумы үтте. Бу дәрәҗәле җыенга Россиянең 46 төбәгеннән, Төркия, Финляндия, Ливан кебек чит мәмләкәтләрдән дә делегатлар килгән иде. Форумның максаты—XXI гасырда хатын-кызларның җәмгыятьтәге урынын ачыклау, әхлакый тотрыклылыкны ныгыту юнәлешендә хатын-кызларны берләштерү һәм активлаштыру. 90 ел элек тә Россия мөслимәләре хатын-кызның җәмгыятьтә һәм гаиләдә тоткан урыны турында бергәләшеп фикерләшкәннәр, мөһим карарлар кабул иткәннәр.

### ЕФӘК СӘНГАТЕНӘ—5000 ЕЛ!

ТР Милли музеенда «Ефәк юлы. Ефәк сәнгатенә—5000 ел» дигән тиңдәшсез күргәзмә булып узды. Әлеге чара Россиядә Кытай елына багышлап оештырылган иде.

Тамашачылар хозурына 115 экспонат тәкъдим ителгән иде. Аларның күпчелеге Кытай милли музее коллекциясеннән, шул исәптән 97 әйбер—борынгы Кытай культурасы ядкәрләре.

Күргәзмәдә Кытай ефәк культурасы үсешенең, асылда, бөтен тарихы чагылдырылган. Ул өч бүлектән тора. Беренчесендә ефәк корты фермасының моделе һәм борынгы ефәк туку станогы тәкъдим ителә. Икенче бүлектә моннан инде 5 мең ел элегрәк кулланылышта булган борынгы станок детальләрен һәм ефәк җепләрне, кием-салым, баш киеме, ефәктән тукып эшләнгән император кафтанын күрергә була. Күргәзмәнең өченче бүлегендә—XIX-XX гасырлардан калган үтә závыклы ципао күлмәкләр.

Бу борынгы экспонатларны билгеле бер температура һәм дымлылык шартларында сакларга кирәк. Шуңа күрә алар махсус тартмаларга урнаштырылган.

### СӨЕП КАЙТТЫМ СИНЕ

10 октябрьдә Г. Тукайның әдәби музеенда шагыйрьнең Казанга кайтуына 100 ел тулуга багышланган «Сөеп кайттым сине» дип исемләнгән әдәби-музыкаль кичә булды. Кичәдә Тукайның Казандагы тормышы һәм иҗаты турында сүз барды, шигырьләре, җырлары яңгырады һәм туганнарына, дусларына язган хатлары укылды. Анда танып-

ган галимнәр, язучылар, шагыйрьләр, шулай ук жырчылар Мөнир Якупов, Резеда Галимова һәм Г. Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры, Г. Кариев исемендәге Яшь тамашачылар театры артистлары катнашты.

Мәгълүм ки, 1907 елда Тукай шагыйрь буларак танылa. Аның иҗаты Уральск шәһәре кысаларында гына чикләнеп кала алмый, шагыйрьне Казанда да, Уфада да, Оренбургта да таныйлар, хезмәттәшлек итәргә чакырып торалар. Әмма ул Казанны сайлый.

Шулай итеп, Г. Тукай 1907 елның 10 октябрендә Уральскидан Казанга кайта. Шагыйрьнең Казан чоры—халкына шигъри сүзен әйтер өчен бирелгән 5 ел да 8 айлык дәвере башлана.

## БЕЗНЕҢ ГОМЕР

М. Сәлимҗанов исемендәге Актерлар йортында шагыйрь, икътисад фәннәре докторы, профессор, Татарстан Республикасының атказанган мәдәният хезмәткәре Фарсель Зыятдиновка 70 яшь тулуга һәм шагыйрә, Татарстан Республикасының атказанган мәдәният хезмәткәре Фирая Зыятдинованы искә алуга багышланган «Безнең гомер» дип исемләнгән әдәби-музыкаль кичә булды. Кичәне язучы К. Кәримов алып барды.

Кичәдә юбилярны Татарстан Дәүләт Советының мәдәният, фән, мәгариф һәм милли мәсьәләләр комитеты рәисе, шагыйрь Р. Вәлиев, Татарстан Фәннәр академиясе вице-президенты, академик Р. Юсупов, Татарстан мәдәният министры урынбасары А. Җаббаров, Татарстан Язучылар берлеге идарәсе рәисе, шагыйрь И. Ибраһимов, Казан финанс һәм икътисад институтының кафедра мөдире Н. Якупова, Казан авыл хуҗалыгы университетының кафедра мөдире Ф. Сафиуллин, «Татарстан» радиосыннан мөхәррир Д. Гайнетдинова, режиссер Ә. Гыйләҗи, якташлары исеменнән Актаныш муниципаль районы башлыгы Э. Фәттахов, шулай ук күпсанлы каләмдәшләре, хезмәттәшләре котлады.

Иҗат кичәсе Казан театр училищесы студентлары чыгышы белән бизәлеп, З. Сәхабиева, З. Шәрифуллина, Р. Төхфәтуллина, М. Галиев, А. Галимов, Ф. Мирзануров, С. Исламова җырлары белән үрелеп барды.

## «КУБРАТ ХАН» БОЛГАР ТЕЛЕНДӘ

Язучы Мөсәгыйт Хәбибуллинның «Кубрат хан» дигән тарихи романы Мәскәүнең «Наука» нәшриятында Дунай болгарлары телендә басылып чыкты. Аны болгар теленә Гергана Стойчева тәрҗемә иткән. Редакторы—Ирина Желязкова.

Редакторның язучыга юлланган махсус хатында: «Безнең нәсел тамырларыбыз бер икән бит»,—диелгән.

## ХЕЗМӘТНЕ БӘЯЛӘҮ

Татарстан Республикасы хакына күпьеллык нәтиҗәле хезмәте, мәдәният һәм сәнгатьне үстерүдәге, халыклар арасында дуслыкны ныгытудагы зур казанышлары өчен Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары—мәдәният министры **Вәлиева Зилә Рәхимьян кызы** Татарстан Республикасы Президентының Рәхмәт хатына лаек булды.

## КОТЛЫЙБЫЗ!

Күпьеллык нәтиҗәле фәнни-педагогик эшчәнлеге өчен «Казан дәүләт финанс-икътисад институты» югары һөнәри белем дәүләт мәгариф учреждениесенең производство икътисады кафедрасы профессоры, Татарстан Язучылар берлеге әгъзасы, шагыйрь **Зыятдинов Фарсель Сәхап улына** «Татарстан Республикасының атказанган фән эшлеклесе» дигән мактаулы исем бирелде.

* * *

16 октябрьдә күренекле язучы, Ватан сугышы ветераны, Россиянең атказанган мәдәният хезмәткәре **Геннадий Александрович Паушкин** 86 яшендә вафат булды.

*Тышлыктагы сурәтләр*

*Тышлыкның беренче битендә:* «Кышны көткәндә».

*Тышлыкның дүртенче битендә:* язучы **Вакыйф Нуриев**.

## Яңа китаплар




**Рифат Сәлах.** Күнел бөртекләре: шигырьләр, поэма.—Казан: Татар. кит. нәшр., 2007.—111 б. Тиражы—2000 данә.

Рифат Сәлах—Әдәбият дөньясында соңгы елларда пәйда булган яшь исем. Яшь шагыйрь бүгенге көндә Казан дәүләт университетының юридик факультетында укый. Шигырьләре республика көндәлек матбугатында, шулай ук безнен журналда да даими басылып килә. Ул—«Иделем акчарлагы—2006» конкурсынын «Гран-При» иясе.

«Күнел бөртекләре»—Рифат Сәлахнын беренче китабы. Жыентыкта авторнын лирик-фәлсәфи шигырьләре һәм «Урман сылуы» дигән поэмасы урын алган.




**Алмаз Хәмзин.** Озак яшисегез килсә... Юмор һәм сатира.—Казан: Татар. кит. нәшр., 2007—175 б. Тиражы—2000 данә.

Алмаз Хәмзин—эстрада аша тамашачыларга яхшы таныш шәхес. Ул Казан дәүләт педагогия институтының музыка факультетын тәмамлаганнан соң, мәдәниятның төрле өлкәләрендә хезмәт итте: жырчы, режиссер, концертлар алып баручы... Хәзерге көндә Казан театр училищесында мөгаллим. А. Хәмзин, шулай ук, юмор-сатира әсәрләре белән укучыларга яхшы билгеле язучы да. «Озак яшисегез килсә...»—авторнын беренче китабы. Китапка А. Хәмзиннең дистә еллар буе сәхнәләрдә яңгыраган һәм әлегә укучыларга таныш булмаган көлке әсәрләре тупланган.



Вакыйф Нуриев

КАЗАН УТЛАРЫ
QAZAN UTLARI
ОГНИ КАЗАНИ

Ежемесячный литературно-художественный
и общественно-политический журнал
(на татарском языке)